**Сөнгатулла Бикбулат**

# Хәзрәти Мөхәммәд

**(аңа Аллаһының салаваты һәм сәламе булсын)**

www.darul-kutub.com

«Хузур» нәшрият йорты
1436/2014

Үзәкләшкән дини оешма — Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте Экспертлар шурасының 14-39 нчы номерлы карары белән басарга хупланган

**Бикбулат С.**
**Хәзрәти Мөхәммәд (аңа Аллаһының салаваты һәм сәламе булсын) /** Сөнгатулла Бикбулат. – Казан: Хузур, 1436/2014. – 436 б.

Атаклы татар дин галимебез Сөнгатулла хәзрәт Бикбулатның (1886-1955) пәйгамбәребез Мөхәммәд салэллаһу галәйһи вәссәламнең тәрҗемәи хәленә вә тормышына багышланган әлеге хезмәте Мәүлид бәйрәме уңае белән дөнья күрә.

Әлеге китапта, автор кереш сүздә үзе үк әйтеп узганча, “рәсүлуллаһның сирасын, тормышын, Исламиятнең баштан ахырга хәтле, ягъни рәсүлуллаһның вафатына кадәр нинди агым белән барганын һәм шул мөнәсәбәт белән байтак кына дини мәсьәләләрне бәян итүгә” зур әһәмият бирелә.

Үз гомерендә С.Бикбулатның уналты хезмәте дөнья күрә, шулар арасында – ислам тарихына һәм гарәп теленә караган дәреслекләр бар. Сөнгатулла Нигъмәтулла улының Исламга кагылышлы кайбер хезмәтләре Япониядә дә басыла. Әмма аңа иң зур танылуны “Хәзрәти Мөхәммәд” (Казан, 1914) китабы китерә. Биредә авторның төп игътибары Пәйгамбәр галәйһиссәлам өйрәтмәләрен җиткерүгә һәм аннан безнең тормышыбызга алырга кирәк булган мөһим сабакларны бирүгә юнәлтелә.

Китап киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

© “Хузур” нәшрият йорты, 2014
© Бикбулат С.Н.

www.darul-kutub.com

# Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

## *Мөәллифтән*

Дин һәм шәригать китереп, безне һидәят юлына төшергән зат – Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәламдер. Шуңа нигезләнеп, безгә иң мөкатдәс һәм иң мөхтәрәм кеше дә ул булу табигыйдер. Аның тәрҗемәи хәлен белү һәм тормышы белән танышу дин ягыннан иң зур бурычыбыз булган кебек, рухыбызга иң бөек ризыктыр.

Гөнаһсыз мәктәп балаларының саф калебләренә, фитри утыртылган дини тойгы һәм яхшылыкка тарту куәтләрен үстерүгә, яшүсмерләрнең дини һәм милли хисләрен тормыш агымына кергән чакта төрле агымнарның бәрелеше белән юылып китмәслек итеп ныгытуга, аларның әзер булган калебләренә фазыйләт, камиллек һәм күркәм әхлак орлыкларын чәчүгә иң беренче ярдәмче, әлбәттә, пәйгамбәребезнең тәрҗемәи хәлен уку һәм укыту, динебезнең нинди юл белән таралуын белү, аның әхлак һәм тормыш юлы белән танышу булачактыр.

Рәсүлуллаһның тормышы белән таныш булу – һәркайсыбызның бурычы, халкыбызга аны таныту дин галимнәребезнең вазыйфасы булган хәлдә, якын заманнарга кадәр бездә бу хакта язылган китаплар юк, мәктәп вә мәдрәсәләр программалары бу дәрестән мәхрүм иде. Бу хакта иң башлап дәреслек китабы төзү шәрифе яшь гәлимнәребездән Ш. Шәрәф әфәндегә насыйп булды. Аңа

www.darul-kutub.com

Аллаһы гасыр сәгадәте өчен бәхет бүләк итсен. Аннан соң олуг галимебез Ризаэтдин бине Фәхретдин «Мөхәммәд галәйһи вәссәлам» исемле кечкенә күләмдәге бөек әсәрен мәктәпләребезгә бүләк итте. Аннан соң билгеле матбугат галиме З. Кадыйри әфәнде дәреслек китабы булу өмете белән «Хәятү Мөхәммәд» дигән әсәрен мәйданга куйды. Менә бездә хәзергә кадәр күзгә күренгән дәрес китаплары – шушы рисаләләрдер. Фәкать болар мәктәп балалары өчен кыскартылып язылган рисаләләр булып, мәдрәсәләребездә укытыр өчен һәм халык укысын өчен тулырак китапларга ихтыяҗ бик зур иде. Мәктәпләрдә сира һәм Ислам тарихы укытучыларының укытыр өчен үз телебездә бер китап таба алмаулары ихтыяҗны тагын да арттыра төшә иде.

Моннан өч ел элек «Хөсәения» мәдрәсәсенә дин һәм гарәб теле дәресләренә мөгаллим итеп билгеләнелгәч, укыту оешмасы миңа әзерлек сыйныфларында «сира нәбәвия» дәресен укытуны йөкләде. Үз телебездә бу фәндә мәйданда бер китап булмаганлыктан, моңарчы «Хөсәения»дә дәрес китабы булып килгән «Нуре-л-якыйн»ны укыта башладым. Фәкать бу китапның алдан ук минем хушыма бик үк килмәве һәм бер фәннең икенче тел белән бирелүе, максатка бик кыенлык белән алып баруы, аның өстенә үз телебезгә мәхәббәтем мине икенче елда дәресемне яздырып укытырга мәҗбүр итте. Шулай итеп, бик мәшәкатьле булса да, төрле китапларга мөрәҗәгать итеп, сираны ике ел яздырып укыттым. Шушы дәресне укыткан шәкертләрем дә, иптәш мөгаллимнәр дә, ел ахырындагы имтиханга әзер булган кайберәүләр дә, язган нәрсәләремне нәшер итәргә миндә кызыксыну уяттылар. Әдәбиятыбызның әлегә тәфсиллерәк сира китапларыннан бөтенләй мәхрүм булуы, мөгаллим һәм мөгаллимәләргә мөрәҗәгать өчен гарәпчә яисә кайбер

төрекчә әсәрләрдән башка мәйданда сыеначак һичбер нәрсә булмавы, хәлбуки, әйтелгән әсәрләрдән файда алу, яисә аларны кулга төшерү бик күп кешеләргә җиңел булмавы мине кылган хезмәтләремне мәйданга чыгарырга һәвәсләндерде. Шулай итеп, укыткан дәресләремне бераз төшереп калдырып яки арттырып, бер китап шәкеленә салдым.

Рисаләне тәртип итүдә махсус бер китапка гына иярмичә, төрле һәм иң ышанычлы чыганакларны алырга тырыштым. Бу хосуста бигрәк тә әһәмият иткән әсәрләр: Ибне Һишамның «Әс-сира әл-һишамия»се, Ибне-л-Әсирнең «Әл-кәмил»е, Ибне Кайййимнең «Зәде-л-мәгад»е булып, һәрбер вакыйганы язганда бу өч әсәрне җентекләп карадым. Вакыйгаларны бер-беренә туры китерергә каршылыклы булган урыннарын узып китмичә, өстенрәк күренгәнен алырга тырыштым. Болар эчендә иң ышанычлы әсәр «Зәде-л-мәгад» булганга, аны һич тә күз алдыннан җибәрмәдем. Тарих төгәллегендә Ибне-л-Әсирнең дикъкате, дини мәсьәләләрдә һәм рәсүлуллаһның сирасын тасвирлауда Ибне Кайййим дикъкате хәтеребездә булды.

Моннан башка «Әл-үмәму вә әл-мүлүк», «Әсәде-л-габәти», «Әл-әсабәтү фи тамйизи әс-сәхабәти», «Әс-сирте-л-хәләбия», «Тарихы Әбү-л-Фәдәи», «Нуре-л-якыйн» кебек әсәрләрдән файдаландык. Вакыйга булган урыннар исемнәрен һәм атамаларны тәгаенләүдә «Мугъҗәме-л-Бүлдән», «Камусе-л-әгъләми», «Укыянус»ларга мөрәҗәгать иттем, керештә гарәпләр хакында язганым «Булуге-л-гарәб фи әхвали-л-гарәб», «Әл-гарәб каблә-л-Ислам», «Тарихы әдәби әл-лөгати» кебек яңа әсәрләрдән. Рисаләне тәртип иткәндә Коръәни Кәрим, Бохари, Мөслим китаплары күз алдымда булды. Үзебезчә мөһим саналган яисә тарихчылар билгеләгән кайбер урыннарда кайдан алганлыгымны

www.darul-kutub.com

астөшермәдә күрсәттем. Астөшермәдә күп урында китап исемен язмыйча, авторны гына язып киттем.

Тарих фәнен харитасыз[1] укыту кимчелекле булганлыктан, рисаләмәгә бер харита куймакчы булдым. Фәкать сира хосусында безгә мәгълүм тәфсилле харита булмаганга, бу өлкә байтак мөшкел бер эш булды. Шулай да

«مَا لَا يُدْرَكُ جُلُّهُ لَا يُتْرَكُ كُلُّهُ»[2]

дип Джурджи Зәйдан, Рафикъ бәк, әл-Худриларның хариталарына мөрәҗәгать итеп, бер харита төзедем. Күп урыннарда үз тарафымнан да арттырылды. Кайбер вак-төяк вакыйга булган урыннарны «Фәлән урынның фәлән тарафында, фәлән кадәр ераклыкта» кебек сүзләр белән рисаләдә әйтеп кителде. Харита күз алдында булгач, боларның урынын белү, әлбәттә, җиңел булачак. Мәктәпләрдә сира дәресе укытучыларына хританың файдасы күп булыр дип өметләнәм. Хаританың төгәл булуын ышандыра алмыйм. Чөнки Гарәбстан хакында миннән элек харита ясаучыларның да моны раслый алмауларына иманым камил.

Рисаләдә, бигрәк тә, рәсүлуллаһның сирасын, тормышын, Исламиятнең баштан ахырга хәтле, ягъни рәсүлуллаһның вафатына кадәр нинди агым белән барганын һәм шул мөнәсәбәт белән байтак кына дини мәсьәләләрне бәян итүгә әһәмият бирдем. Зур кереш сүзләр һәм фәлсәфәләрдән мөмкин кадәр читләшергә тырыштым. Анысына укучы үзе төшенер дидем. Исламиятнең таралуында беренче этәргеч Коръәни Кәрим булганга могҗизаларны карап китүгә китапта урын бирмәдем. Шулай ук изге китапларны игълан итү хосу-

1 Харита – карта. – тәрҗ.

2 Асылын белмәгәнгә бөтенләеннән баш тартмыйлар. – тәрҗ.

сында гомуми сүзләр белән генә чикләнеп, тәфсилләп язуны тагы да уңайлырак бер форсатка калдырдым. Рәсүлуллаһның үз кавеме һәм башлап аларны дәгъват итүгә әмер бирелгән гарәпләрнең бүленешләре, иҗтимагый хәлләре, әхлак һәм гадәтләре, диннәре, дәүләт һәм мәдәниятләре, әдәбиятлары хакында рисаләнең башында күпмедер мәгълүмат бирдем. Гарәпләрнең гадәтләренә бәйле булган кайбер нәрсәләр бәгъзе вакыйгалар белән бергә карап кителде.

Сира язганда газвә[1] һәм сәрияләр, башка төрле вакыйгаларның тарихлары билгеләнеп китү тиеш булганлыктан, рисаләне төзүдә хәзерге гасыр тарих язучылары тәртибенә иярмичә, Табари, Ибне Кәсир һәм алардан үрнәк алган әл-Худриларга иярдем. Һиҗрәттән соңгы вакыйгаларны елларга бүлеп, аннан элегрәкләрен берничә зуррак темалар астына алып яздым. Рәсүлуллаһның күркәм якларын, балаларын һәм хатыннарын, әтисе ягыннан бертуганнарын һәм сира атап киткән башка шундый затларны соңгы тема астында яздым.

Беренче мәртәбә буларак язган әсәремдә, бәлки каләмнең карышуы, бәлки фикернең абынуы сәбәпле кимчелекләр, әлбәттә, булыр. Хезмәт һәм төзәтү нияте белән кимчелекләремне күрсәткән затларга рәхмәтле булырмын. Рисалә укучыларның, мөгаллим һәм мөгаллимәләрнең игътибарына лаек булып, икенче мәртәбә бастырыла калса, кимчелекләремә игътибар биреп, хәзер үк уйлап калдырылган кайбер мәсьәләләрне кушып, аны булдыра алганча камилләштерергә әзермен.

***Сөнгатулла Бикбулат***
***Оренбург, 1 март, 1914 ел***

1 Газвә – сугыш сәфәре, сугыш хәрәкәтләре – тәрҗ.

# Гарәбстанның географик урнашуы

Гарәбстан Азия континентында урнашкан бер ярымутрау булып, көнчыгыштан Ефрат елгасы, Фарсы култыгы һәм Гарәб диңгезе белән, көньяктан Гаден култыгы белән, көнбатыштан Бәбе-л-Мәндеб бугазы, Кызыл диңгез һәм Гакабә култыгы белән чикләшә.

Гарәбстан Йәмән, Тиһамә, Хиҗаз, Нәҗед һәм Йәмамә исемнәре белән аталган бөек биш җирлеккә бүленгән.

Йәмән Гарәбстанның көньяк бүлеге булып, Сангъа, Мәэриб (Сәбә), Зәбид, Мәха, Гадән, Зафәр, Шәбвәдер, Хәдрамәүт, Мәһра, Шихр, Гумән, Нәҗран кебек мәшһүр шәһәрләрне үз эченә ала. Коръәни Кәримнең кырык алтынчы сүрәсендә аталган Әхкаф Йәмәндә урнашкан Хәдрамәүт комлыкларыннан гыйбарәт булып тора. Мәшһүр Әсвәде-л-ганси дә Йәмәндәге Санга әһеленнән иде.

Тиһамә Кызыл диңгезнең көнчыгышында, Хиҗазның көнбатышында һәм Йәмәннең төньягында урнашып, үзенең мәшһүр Мәккә, Йәнбүгъ һәм Җиддә шәһәрләре белән танылган.

Хиҗаз Нәҗед белән Тиһамә арасында урнашып, Йәмәннән алып Шам сахраларына кадәр сузылган Сәравәт тауларыннан гыйбарәттер. Мәшһүр шәһәрләре: Йәсриб (Мәдинә), Таиф һәм Хайбар.

Нәҗед Хиҗаз белән Гыйрак арасында урнашкан. Мәшһүр шәһәрләре: Рияд һәм Хәил. Күләйб Вәилнең «Әрдун галия» дигән җире шушы Нәҗед җирлегендәдер.

Йәмамә Йәмәннең төньяк-көнчыгышында һәм Нәҗеднең көнчыгышында урнашкан һәм «Бәхрайн» җирлеге

дә аңа керә. Бөек шәһәрләреннән Йәмамә белән Һәҗар санала. Һәм бу ике шәһәрнең беренчесе Йәмамә каласы, ә икенчесе Бәхрайн каласы булып исәпләнә. Күпләргә билгеле булган *Мусәйләмә әл-Кәззаб* шушы Йәмамә әһелләренең берсе иде. Шулай ук гарәпләр арасында үткен күзлелеге һәм зирәклеге белән шөһрәт казанган Зәрка Йәмамәдә тора иде. Йәмамә җирлеге тагын «Гаруд» дип тә йөртелә. Шушы ярымутрау электән үк гарәпләрнең ватаны иде.

## Гарәпләр һәм аларны хасил иткән кабиләләр

Гарәп бәидә. Гарәп бәкыя. Кахтән һәм Гаднән гарәпләре.

Гарәпләр Сәм бине Нухка тоташкан Үмәмү Сәмиядән бер кавем. Гарәпләр «бәидә» һәм «бәкыя» дип аталган ике төркемгә бүленәләр. Гарәп бәидә дип, элекке вакытларда юкка чыгып, тарих сәхифәләрендә генә калган гарәп кабиләләренә әйтәләр. Шушы кабиләләрнең иң мәшһүрләре:

• Гад – боларның ватаннары Йәмән җирлегендәге Әхкаф исемле урында иде. Аллаһы Тәгалә боларга Һуд (Аллаһы аннан разый булсын) исемле пәйгамбәрне җибәрсә дә, аны ялганчы итеп кабул иткәннәре өчен Аллаһы аларны һәлак итте.

• Сәмуд – боларның ватаннары Хиҗр[1] исемендәге җир иде. Бу кабиләгә Салих (Аллаһы аннан разый булсын) пәйгамбәр җибәрелә.

• Әмим – болары Гумән белән Әхкаф арасындагы «Убәр» исемле җирдә торалар иде.

1 Хәзерге вакытта “Мәдәинү Салих” дип танылган.

• Габил – болары Йәсрибтә яшиләр иде.

• Тасм һәм Җәдис – болары Йәмәмә җирлегендә көн күргәннәр.

• Гыймликъ – болары  Гумән, Хиҗаз, Нәҗед, Тиһамә, Тәймә, Бәтраэ, Филистыйн кебек төрле җирләрдә торганнар. Муса (Аллаһы аннан разый булсын) пәйгамбәрнең кавеме алар белән сугышудан тартынган һәм Коръәни Кәримдә «кауму җәббәрин» дип килгән кавем, «Гыймәләка» дип атала. Тагы Коръәндә зикер ителгән Җәлут та шушы кавемнән санала.

• Җурһум – болары Йәмәндә көнкүреш иткәннәр. Менә шушы кәвем Мәккәгә килеп Исмәгыйль (Аллаһы аннан разый булсын) белән туганлашкан.

• Вәбар – бу кавем Йәмәндә Вәбар исемле җирдә тора иде.

**Кахтән гарәпләре.** Гарәп бәкыя үзе ике төркемгә бүленә: 1) Ибне Кахтән, 2) Ибне Гаднән. Ибне Кахтән гарәпләренең баш бабалары Ягъруп бине Кахтән санала. Нәселләренә чит кавемнәр каны кушылмаганга, боларны *«Гарәб гарибә»* яки *«Гарәб Гарбә»* дип йөртәләр. Ибне Кахтән башта Йәмән җирлегендә торганнар һәм боларның ата-бабалары «Ибне Сәбә»[1] дәверендә Йәмән җирлегендә гадәттән тыш бөек цивилизация төзегән. Һәм бу дәүләт дөньяның җәннәте булып саналган. «Сәддү мәэраб» дигән мәшһүр буа да шушы Ибне Сәбә тарафыннан төзелә. Әмма соңыннан болар кәеф-сафага бирелеп, төзелеш турында кайгыртуны оныталар һәм нәтиҗәдә платиналары җимерелә. Мәшһүр «сәйлү-л-гарим» вакыйгасыннан соң күпләре ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булып, Гарәп ярымутравының төрле

1 Ибне Сәбә дәүләте б.э. га кадәр 850 елда төзелә һәм б.э кадәр 115 елга хәтле яшәп килә. – “Тәрихү-л-гарәб каблә-л-ислам”,1 т.,111 б.

тарафларына күченәләр. Шушы кавемнәр арасыннан Шам тарафларына күченеп киткән «Гассан», Йәсрибкә күчкән «Әус» һәм «Хазраҗ», Хирага күчкән «Ләхм», Мәккәгә күчкән «Хузага», Нәҗедкә күчкән «Киндә» кабиләләре санала[1]. Әйтелгән кабиләләрнең ватаннарыннан күченеп таралуында икенче сәбәп булып аларның бәдәви булганлыклары тора. Йәмәндә калган кабиләләрнең мәшһүрләреннән «Химьяр», «Һәмдән», «Мәзһиҗ» кебекләрне әйтергә була. Химьяр гарәпләре бөек мәдәнияттә кәсеп иткәннәр[2].

**Гаднән гарәпләре.** Гаднән гарәпләре асылда гыйбрани булган Исмәгыйль (Аллаһы аннан разый булсын) нәселеннән булганлыктан, боларны *«гарәб мустәгърибә»* дип йөртәләр. Ягъни, әүвәлдә гарәп булмыйча, соңыннан гарәпләшкән кавем дигән мәгънәне аңлата.

Гаднәннең Мәгад һәм Гак исемендәге ике улы булып, нәселе күбрәк Мәгаддән таралган. Шуңа күрә гаднән гарәпләре баш бабалары дип Мәгадне атыйлар. Мәгаднең Низар һәм Канас исемле ике улы була. Һәм күпчелек гарәп кабиләләре Низардан таралганнар. Шушы Низардан таралган кабиләләр бишәү: Кудага, Модар, Рабига, Ияд һәм Әнмар.

*Кудага ыруглары*. Югарыда әйтеп кителгән кабиләләр башта бер кабилә кебек һәрвакытта бер-берләре белән аралашып, бер җирдәрәк, Тиһамә һәм Хиҗаз җирлекләрендә яшәсәләр дә, соңрак, бер яктан җирләренең тараюы сәбәпле, икенче яктан араларында фетнә һәм сугышлар чыгу сәбәпле, төрлесе төрле якка күчеп китәргә мәҗбүр булалар. Болардан иң беренче күчеп киткән Кудага кабиләсе була. Үз чиратында Кудага берничә ыругдан гыйбарәт булып, төрле җирләрдә урнаша:

1 “Тәрихү-л-гарәб каблә-л-ислам”,181-182 б.,1 т.

2 Безнең эрага кадәр 115 елдан алып безнең эраның 522 елына хәтле.



www.darul-kutub.com

• Тәймү-л-Лат – Бәхрайнда;

• Тәзид бине Хүлвән – Гыйрак җирлегендәге «Габкар» исемле урында;

• Сәлих – Шам һәм Филистыйн җирләрендә;

• Әсләм (Гузра, Нәһед, Хәүтәкә, Җүһәйнә) – болар башта «Вәди әл-Кура» исемле җирдә, соңыннан Нәҗедкә урнашалар;

• Тәнух – башта Бәхрайнда, соңыннан Хирага урнашып, анда хөкүмәт төзиләр;

• Раббән бине Хүлвән – Шамда;

• Бәлә һәм Бәһра – болар башта Йәмәндә, соңыннан Тимә белән Мәдинә арасына урнашалар. Шушы Кудага гарәпләренең таралулары безнең эра башында булырга тиеш[1].

*Әнмар гарәпләре*. Әнмар кабиләсе «Бүҗәйлә» һәм «Хасгәм» исемле ике нәселгә бүленеп «Сәравәт» исемле тауларда урнашалар.

*Ияд гарәпләре*. Ияд кабиләсе беренче вакытта Гыйрак җирлегендәге Куфа урынында төпләнгәннәр. Әмма фарсылар белән булган сугышларда җиңелеп, Шам тарафларына күченеп китәләр.

• *Рабига гарәпләре*. Рабига кабиләсе Мәгад нәселенең иң бөекләреннәндер. Бу кабилә үзе берничә ыругдан гыйбарәт. Шуларның мәшһүрләреннән Габде-л-кайс, Бәкр, Тәгълиб, Ганәзә, Дубайга, Нимр, Гофәйләләрне атап була. Болардан Габде-л-кайс Бәхрайн җирләренә, Ганәзә белән Дубайга Йәмамә, Бәхрайн һәм Гыйрак тарафларына, ә Нимр белән Гофәйлә кабиләләре Шам тарафларына китеп урнашалар.

• *Модар гарәпләре*. Модар да Рабига кабиләсе кебек Мәгад нәселенең иң бөекләреннәндер. Бу кабилә дә берничә

1 “Тәрихү-л-гарәб каблә-л-ислам”,171 б., 1 т.

вак кабиләләрдән гыйбарәт булып, Гарәп ярымутравында таралып урнашкан. Кайс, Гайлән кабиләләренең күпчелеге Нәҗед җирлегендә, кайберләре (Һәвәзин) Хүнәйн, Әутас, зил-Мәҗәз, Таиф тирәләренә килеп урнашкан. Хиндифтән таралган кабиләләрдән Музәйнә Хиҗаздагы «Радва» исемле тауларда, Тәмим белән Дабба кабиләләре Йәмамә белән Һәҗар арасында урнашалар. Ибне Сәгыдтән булган кайберләре «Йәбрин» тарафларына, кайберләре Гумән тарафларына барып урнашалар. Тагы Мүдрикәдән таралган кабиләләрдән Һүзәйл Сәрават тауларына, Хозәймә бине Мүдрикә «Һүзәйл»нең көньяк тарафларына, Надр бине Кинәнә балалары Мәккә тирәсенә, ә Фиһр (Корәеш) балалары Мәккәгә барып урнашалар

## Җаһилият вакытында гарәпләрдә дин

Гарәпләр жаһилият вакытында (пәйгамбәребез Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам килгәнчегә хәтле) төрле игътикадта вә төрле диндә иделәр. Аларның күбесе пот, сыннарга табынучы булсалар да, араларында мүәххидләр, дәһриләр, сәнәүия, сабия, яһүд вә насаралар бар иде.

*Мүәххидләр*.

Мүәххидләр аз булып, үз акыллары белән Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә һәм кыямәт көненә ышаналар һәм Аллаһыыга гыйбадәт итәләр иде, гарәпләрнең тоткан юллары хата икәнен белеп, аларга вәгазь-нәсыйхәт сөйлиләр иде. Алар Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһи вәссәламнәрдән калган яхшы дини гадәтләргә дә иярәләр иде һәм озакламый туры юлга өндәүче пәйгамбәр киләчәген белеп, аны көтеп то-

ралар иде. Алар арасыннан булган мәшһүр кешеләр: Кус бине Сәгыйдә әл-Әядий, Вәрака бине Нәүфәл, Зәйд бине Гамру бине Нүфәйл, Зүһәйр бине Әбү Сүлмә, Үмәййә бине Әбү әс-Салт, Сүвәйд бине Гамир әл-Мосталка, Вәкигъ бине Сәлмә бине Зөһәйр әл-Әядий, Гомәйр бине Җүндеб әл-Җүһәнә, Әбү Кайс Сирмһ бине Әбү Әнәс, Гамир бине әз-Зариб әл-Гудвәни, Халид бине Синән әл-Габсә һәм башкалар. Кус бине Сәгыйдәнең Гуказ базарында: «Әй, кешеләр, ишетегез һәм аң булыгыз! Әгәр аңласагыз файда алыгыз! Кем дә кем яши – ул үләчәк, кем үлә – шул бетәчәк...» дип башланган хөтбәсендә кыямәт көненә кадәр Аллаһының илчесе киләчәге турында сөйләгәне риваять ителә[1]. Һәм Зәйд бине Гамр бине Нүфәйлнең Кәгъбәтуллаһка арты белән торып: «Әй, Корәеш әһелләре, валлаһи, Ибраһим динендә сезнең арагыздан миннән кала беркем дә юктыр», – дип әйткәне риваять ителә[2]. Шулай ук шушы шигырь дә Зәйд бине Гамр бине Нүфәйлнекедер:

أَرَبًّا وَاحِـدًا أَمْ أَلْفَ رَبٍّ     أَدِينُ إِذَا تَقَسَّمَتِ الْأُمُـورُ
عَزَلْتُ اللَّاتَ وَالْعُزَّى جَمِيعًا     كَذَلِكَ يَفْعَلُ الجَلْدُ الصَّبُـورُ
فَلَا الْعُزَّى أَدِينُ وَ لَا ابْنَتَيْهَا     وَ لَا صَنَمَيْ بَنِي عَمْرٍو أَزُورُ
وَلَا غَنَمًا أَدِينُ وَ كَـانَ رَبّا     لَنَافِي الدَّهْرِ إِذْ حِلْمِي يَسِيرُ
تَرَى الْأَبْرَارَ دَارُهُـمْ جِنَانٌ     وَ لِلْـكُفَّارِ حَامِيَةٌ سَعِيرُ.

1 Әл-Мәсгудий, 92 б., 2 т.

2 Бохари, 41 б., 5 т. Аллаһының илчесе, аңа вәхи иңдерелгәнче Язид бине Гамр белән күрешеп аның белән аралашкан. Бохари, 40 б., 5 т.



www.darul-kutub.com

*Дәһриләр.*

Дәһриләр Аллаһы Тәгаләне һәм кыямәт көнен инкарь итәләр иде. Һәм дөньяда булган бөтен хәлләрне вакытка һәм табигатькә бәйлиләр иде. Алар хакында Коръәндә «Җәсия» сүрәсендә, 24 аятьтә хәбәр бирелә: «Кыямәтне вә терелүне инкарь итүчеләр әйттеләр: «Без бу дөньяда гына яшибез, икенче дөнья юк, бәгъзеләребез үлә, ә бәгъзеләребез анасыннан туып тереләдер, вә безне үтерми һичнәрсә, мәгәр заманаларның үтүе белән картаеп үләбез, аннан сон терелү булмый», – дип. Аларның бу сөйләгән сүзләре белемсез вә дәлилсездер, алар сукыр фикерләре белән шулай зан кылалар».

*Яһүд вә насара.*

Гарәпләрдә яһүдләр ул кадәр күп түгел иде. Яһүдилек, бигрәк тә, Йәмән гарәпләре арасында таралган иде. Һәм Кинәнә, Киндә, Ибне әл-Хәрис бине Кәгъб кабиләләрендә дә яһүд динендә булганнар бар иде. Бу соңгыларда яһүд дине Йәсриб һәм Хайбар яһүдиләреннән кергән булса кирәк. Насаралар яһүдләргә караганда да күбрәк иделәр. Мәсәлән, Ибне Тәгълиб гарәпләре бөтенесе насара иделәр. Хирада да бик күп кабиләләр насара динен кабул иткән иделәр. Моннан тыш Рабига, Гассән гарәпләрендә, Кудага кабиләләренең кайберләрендә дә насара динен тотучылар бар иде.

*Мөшрикләр.*

Югарыда зекер ителгәнчә, гарәпләрнең күбесе мөшрик булып, сыннарга гыйбадәт итәләр иде. Әмма гарәпләрнең сыннарга гыйбадәт итүләрендә, халык һәм юктан бар кылу мәсьәләләрендә Аллаһыга ширек итү юк. Киресенчә, көнне бар кылып, анда идарә итүче бердәнбер

Ятучының барлыгына ышаналар иде һәм Аңа гыйбадәт кылынырга тиеш икәнлекне таныйлар иде. Коръәни Кәримдә моңа дәлил булып «Локман» сүрәсенең егерме бишенче аяте килә: «Әгәр алардан: «Кем күкләрне һәм җирне яратты?» – дип сорасаң, әлбәттә, алар әйтерләр: «Аллаһы». Һәм шулай ук «Ганкәбүт» сүрәсенең алтмыш беренче аятендә: «Күкләрне һәм җирне кем бар кылды, кояшны һәм айны кешеләргә файда өчен кем буйсындырды?» – дип сорасаң, алар сиңа һичшиксез: «Аллаһы», – дип җавап бирерләр», – диелә. Тагы «Әй, Мөхәммәд, әйт аларга: «Җир һәм андагы бөтен мәхлуклар кемнеке? Әгәр сез белсәгез, миңа җавап бирегез?» – алар җавап бирәчәкләр: «Җир – Аллаһыныкы», – дип. Шунда әйт аларга: «Җир Аныкы булган Затның Бер Аңа гына гыйбадәт кылуга лаек булуын аңламыйсызмыни?» (Мөэминун, 84-85) һәм «Әйт: «Кем сезгә күктән һәм җирдән ризык җибәрә? Кем җирдә төрле үсемлекләр һәм агачларга чәчәк атарга һәм җимешләр бирергә ярдәм итә торган суны күктән иңдерә? Кем сезгә ишетү һәм күрү сәләте бирде? Кем үледән терене чыгара – үле җирдән тере үсемлек чыгара? Кешедән тормыш киткәндә, кем тередән үлене чыгара? Кем галәмнең барлык гамәлләре белән Үзенең кодрәте һәм хикмәте белән хакимлек итә? Алар, һичшиксез, җавап биреп әйтерләр: «Аллаһы» – дип» (Юныс, 31) кебек аятьләр әйтелгән игътикадларына дәлил булып торалар.

Мөшрикләр үзләренең потларын Аллаһыга якынаюда арадашчы итеп куеп, алардан Аллаһы каршында шәфәгать өмет итәләр иде. Шулай ук алар, ул сыннардан файда вә зарар килүен дә игътикад итәләр иде. Шуның өчен сыннарның алдына барып сәҗдә кылалар, ялваралар, хаҗәтләрен сорыйлар, бәла-казаларны бетерүләрен өмет итәләр иде. Шул

хаҗәтләренә ирешү өчен аларга хадимнәр куялар, хозурында корбан чалалар, алар исемнәренә сәдакалар аерып куялар, игеннәр чәчәләр, аларның ризалыгы өчен бәгъзе хайваннарны үзләренә хәрам итәләр иде. Мөшрикләрнең потларга гыйбадәт кылуларының мәгънәсен Аллаһы Коръәни Кәримнең «Юныс» сүрәсенең 18 аятендә: «Мөшрикләр Аллаһыдан башка файда да, зарар да ирештерә алмый торган сыннарга гыйбадәт кылалар һәм әйтәләр: «Бу сыннар – Аллаһы хозурында безнең шәфәгатьчеләребез», – дип. Син аларга әйт: «Сез Аллаһыга җирдәге вә күкләрдәге Үзе белмәгән нәрсәләрдән хәбәр бирәсезме? Ягъни, Аның тиңдәше булып та, Үзе белми, сез беләсезме? Мөшрикләр тиңдәш кылган нәрсәләрдән Аллаһы пакь вә бик бөек дәрәҗәдә» һәм «әз-Зүмәр» сүрәсенең 3 аятендә ачык әйтелә: «... Аллаһыдан башка сыннарны дус тоткан мөшрикләр: «Без аларга гыйбадәт кылмыйбыз, мәгәр безне Аллаһыга якын кылсыннар өчен генә аларга гыйбадәт кылабыз, – дияләр».

Гарәп мөшрикләренең иң зур адашулары Мөхәммәд галәйһиссәлам пәйгамбәрлеген һәм кыямәт көнен инкарь итүдән гыйбарәт иде. Алар бигрәк тә кешенең[1] илче булып килүен кабул итмиләр иде. Кыямәт көненә дә булмас нәрсә дип һәм ниндидер бер хорафат[2] дип кенә карыйлар иде. Бу хакта

www.darul-kutub.com

1 “Аллаһыдан пәйгамбәрләр аркылы һидәят килгәннән соң иман китерүдән кешеләрне нәрсә тыйды? Тыймады һичнәрсә, мәгәр: “Аллаһы кеше затыннан пәйгамбәр җибәрәме? Аллаһыдан килгән пәйгамбәр булса, әлбәттә, фәрештәдән булыр иде”, - дигән сүзләре Коръәнгә вә пәйгамбәргә иман китерүдән тыйды. (Исра, 94).

2 “Ул имансызлар, дөньяда яшәвебездән башка яшәү юк, үлгәннән соң терелүчеләрдән түгелбез, диләр” (әл-Әнгам, 29). “Һәм алар әйттеләр: “Әйе, без череп сөяк, туфрак булсак та, яңадан терелеп кубарылырбызмы? Бу эш мөмкин түгел” (Исра, 49).

حَيَاةٌ ثُمَّ مَـــوْتٌ ثُمَّ نَشْـرُ          حَدِيثُ خُرَافَةَ يَا أُمَّ عَمْرٍو يُحَدِّثُنَا
يُحَدِّثُنَا الرَّسُولُ بِأَنْ سَنَحْيَا          وَكَيْفَ حَيَاةُ أَصْدَاءٍ وَهَامِ . [1]

кебек шигырьләр күптер.

*Сәнәвияләр*.

Болар карашы буенча хәерлелек кылучы һәм начарлык кылучы ике санигъ бар дип әйтәләр иде. Шуларның хәерлелек кылучысы нур булса, начарлык кылучысы караңгылык булыр. Һәм һәр икесен дә бик борынгы дип күргәннәр. Бу ике санигъ нәфес һәм сурәттә каршылыклы булган кебек, гамәл белән идарә итүдә дә каршылыклы булып торалар. Нурны, сурәттә күркәм итеп, хәким, юмарт, файда китерүче сыйфатлары белән сыйфатлыйлар иде. Тормыштагы яхшылык аңардан килгәнлегенә һәм төрле зарарлар кылучы түгел икәнлегенә иман китерәләр иде. Ә караңгылык, киресенчә, нурга капма-каршы булып, тормыштагы начарлык һәм бозыклык китерүче икәнлегенә иман китерәләр иде.

Сәнәвияләр гомернең җидедән берен руза тоталар, һичбер җан иясен рәнҗетмиләр, ялган, саранлык, зина һәм урлашу кебек начар эшләр белән шөгыльләнмиләр иде. Бер көнлектән артык ризык сакламау аларның диннәреннән иде.

*Сабияләр*.

Болар 7 йолдызга һәм 12 йолдыздан гыйбарәт булган тамгага гыйбадәт итәләр иде вә аларга һәйкәлләр дә куялар иде. Сабияләр элекке вакытлардан ук билгеле булган

www.darul-kutub.com

1 Йә Үммү Гамр, үлгәннән соң яңадан терелү хорафәттән булган бер сүз генәдер. Рәсүл безгә терeләчәкбез дип сөйли, бу булачак түгел. - Авт.

өммәтләрнең берсе. Ибраһим галәйһиссәламнең кавеме дә Сабия. Гарәпләрдә дә бу дингә ияргәннәр бар иде. Ләкин Сабияләр вә Сәнәвияләр бик аз иделәр.

Бу диннәрдән башка фәрештәләргә, утка, кояшка, ай һәм йолдызларга табынучылар да бар иде. Җаһилият вакытында гарәпләр шулай төрле диндә булган. Исламият килеп, боларны бер хак дингә – Ислам диненә җыйды.

Мәшһүр сыннар:

1. Вәддә – Дәүмәте-л-Җәндәл исемле урында урнашкан Кәлб кабиләсенең поты.

2. Сүвәгъ – Һузәйл кабиләсенең поты булып Йәнбәгъка якын җирдә урнашкан.

3. Ягусь – Йәмәндә Мәзхәҗ кабиләсе вә бәгъзе Йәмән кабиләләрнең поты.

4. Ягукъ – Санга янында урнашкан булып, аңа Һәмадән гарәпләре гыйбадәт кылган.

5. Нәср – Йәмәндә аңа хәмириләр гыйбадәт итәләр.

Ошбу биш сын турында Коръәндә «Нух» сүрәсенең 23 аятендә зекер ителә: «Вә олугълары әйттеләр: «Әлбәттә, сыннарыгызга гыйбадәт кылуны ташламагыз, әлбәттә, Вәддә, Сүвәгь, Ягусь, Ягукъ, Нәср исемле сыннарыгызны ташламагыз, – дип».

6. Мәнәт – Кызыл диңгез янында Кудәйд исемле җирдә Мүшәллəл тавында булып, Әус вә Хазраҗ кабиләләрнең поты.

7. Лат – «Таиф» дигән җирдә булып, Сәкыйф кабиләсенең поты. Ул бер таштан гыйбарәт булып, бина эчендә иде.

8. Гоззә – Нәхъләдә бер бина эченә алынган, агачтан гыйбарәт булып, Корәеш вә Ибне Кинәнә кабиләләренең

www.darul-kutub.com

поты иде. Зекер ителгән өч сынны бөтен гарәпләр зурлыйлар вә аларны Аллаһының кызлары дип игътикад итәләр иде. Бу өч сын турында Коръәннең «Нәҗем» сүрәсендә, 19-23 аятьләрдә зекер ителә:

«أَفَرَأَيْتُمُ اللَّاتَ وَالْعُزَّى. وَمَنَاةَ الثَّالِثَةَ الْأُخْرَى.
أَلَكُمُ الذَّكَرُ وَلَهُ الْأُنثَى. تِلْكَ إِذًا قِسْمَةٌ ضِيزَى»[1]

Гozзә бу өч сын арасында иң бөеге санала. Аны бигрәк тә Корәеш гарәпләре зурлый. Гоззә алдында һәрвакыт корбан чалынган.

9. Һөбәл – Кәгъбә эчендә булып, Корәеш кабиләсенең поты иде.

10-11. Исаф һәм Наилә дигән сыннар Зәм-зәм урынында иделәр. Гарәпләрнең игътикадләренә караганда, Исаф – бер егет, Наилә – бер кыз булып аңлатыла. Гарәпләр аларны Кәгъбә эчендә зина кылганнары өчен ташка әйләнгәннәр дип уйлыйлар.

12. Фөлс – Тай кабиләсенең поты.

Зекер ителгән бу сыннар гарәпләрнең иң бөек потлары булып саналган. Әмма аларның моннан башка да сыннары күп иде. Гарәпләрдә сыннарның ни дәрәҗәдә күп булуын белү өчен, Мәккә алынган көндә, Кәгъбәтуллаһның үзендә генә дә мөселманнар тарафыннан 360 сын җимерелүен искә төшерү җитә. Моның өстенә һәр өйдә кечкенә сыннар да була.

---

1 «Лат, Гоззә исемле сыннарны күрдегезме? Вә алардан башка өченче Мәнәт исемле сынны күрәсезме? Сезнең нәселегез ир-ат булып, ә Аныкы хатын-кызмы? Бу гаделсез бүлү булыр иде». – тәрҗ.

# ГАРӘПЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ ХӘЛЕ

## Никах

Җаһилият вакытында гарәпләрдә никах берничә төрле була, аларның киң таралганнары ошбулар:

1. Хәзерге вакыттагы кебек егет, кызның вәлисенә яучы җибәреп, мәһер билгеләп никахлашу;

2. Хатынга бер микъдар нәрсә биреп, бер атна яки бер ай кебек бер кыска арага сөйләшеп өйләнү. Бу «Вакытлыча никах» диелгән.

3. Хатыннарны алыштыру, моңа «Никах бәдәл» дигәннәр.

4. Бер ирнең икенче кешегә, ул кеше дә аңарга кызын яки сеңлесен бирү шарты белән, аңа үзенең кызын яки сеңлесен бирү. Моңа «Никах шигарь» диелгән.

5. Яшерен хәлдә сөяркә тоту. Моңа «Никах хидн» дигәннәр.

6. Ир хатынын баһадир, гыйлемле яки башка күркәм сыйфатлы кеше белән кавыштырып алу да булган. Монысы «Никах истибза» дип аталган.

Зекер ителгән никахлар һәрберсе гарәпләр каршында мәшругъ [законлы] булып, бу эшләрне эшләүче кешеләр халык алдында гаепле саналмыйлар. Ислам дине килгәч, шул әйтелгән никахларның беренчесеннән башкалары бете-

релде, хәрам кылынды[1]. Бу никахлардан башка гарәпләрдә зина да киң таралган иде. Аның белән бигрәк кол хатыннар шөгыльләнә. Азат хатыннар арасында зина кылу сирәк була. Шуның өчен дә Әбү Сафүәнның хатыны мәшһүр Һинд бинте Гутбә Мәккә шәһәре мөселманнар кулына төшкән көндә Аллаһының илчесенә бәйгать биргәндә, гаҗәпкә калып: «Ирекле хатын зина кыламыни?!» – дип әйтте.

Зина кылу гарәпләрдә бик зур гаеп саналмый. Бу гадәтнең гарәпләрдә никадәр тамыр җәйгәнен белү өчен, бәгъзе гарәпләрнең Ислам динен кабул иткәндә рәсүлуллаһтан: «Миңа зинага рөхсәт бирче, ансыз тора алмыйм», – дигәннәрен вә бәгъзе кабиләләрнең, Исламда зина һәм хәмер хәрам булганы өчен, Ислам динен кабул итми маташуларын искә төшерү җитсә кирәк. Җаһилият заманында мәшһүр фәхишәләр бар иде ки, үзләрен белдерер өчен ишекләренә махсус әләм элеп куялар иде[2]. Исламият зинаны катгый сурәттә тыеп, аны эшләүчеләргә тиешле җәзалар билгеләде.

# Талак

Талак, Зыйһар, Иләэ, Холәгъ, Гыйддә кебек Исламияттә булган нәрсәләр җаһилияттәге гарәпләрдә дә бар иде. Ләкин болар хатыннар өчен зур җәбер булып, аларның хакын талаудан гыйбарәт. Мәсәлән, иләэ мөддәте гарәпләрдә бер-ике елга хәтле сузыла иде. Ислам шәригате моны бары дүрт айга калдырды.[3]

www.darul-kutub.com

---

1 Бохари, 16 б., 7 т. - авт.

2 Бохари, 16 б., 7 т. - авт.

3 Бу турыда Бәкара сүрәсендә, 226 аятьтә әйтелә:”لِّلَّذِينَ يُؤْلُونَ مِن نِّسَآئِهِمْ تَرَبُّصُ أَرْبَعَةِ أَشْهُرٍ فَإِنْ فَآؤُوا فَإِنَّ اللّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ“

[“Хатыннарына якынлык кылмаска ант иткән ирләргә дүрт ай көтү тиешле, әгәр ниятләреннән кире кайтсалар, Аллаһы ярлыкаучы һәм рәхимледер”] – авт.

Гыйддә вакытында [ире үлгәч, хатын-кызга кияүгә чыгарга ярамый торган вакыт] Ислам диненә хәтле тол хатыннар начар бер хәлгә куелганнар иде: ул хатыннар иң начар бер өйдә, иң начар киемен киеп, бер елга кадәр беркая чыкмастан гыйддәтен саклыйлар иде. Шул вакыт эчендә тәненә су тидерми, тырнагын кисми, чәчен тарамый иделәр. Бер ел үткәч, ул хатын өйдән бер коточкыч кыяфәттә чыга иде.

Ислам дине моны җиңеләйтте: ире үлгән тол хатынның гыйддәтен дүрт ай да ун көнгә калдырды яки әгәр хатын йөкле булса, бала тудырганчыга хәтле. Гыйддә саклаучы хатынга кирәк булганда Ислам дине өйдән чыгуны да рөхсәт итте.

Талак гарәпләрдә чикләнмәгән иде. Ир хатынын теләгәнчә талак кыла һәм теләгәнчә кайтарып ала иде. Моның хатын-кызга никадәр җәбер-золым булуында шөбһә юк. Ислам дине бу хосуста да ирнең йөгәнен кыскартты. Ягъни,талакка билгеле бер чик куйды.

Исламияттә никахы хәрам булган хатыннар гарәпләрдә дә хәрам санала иде. Ләкин аларда ике кыз кардәшне бергә никахлап алу бар. Шулай ук ата вафат булгач, үги ананы алу бар иде. Гадәт буенча, ул олы улга тиешле була иде. Ул, атасы үлгәннән соң, үги әнкәсе өстенә киемен ташлый, шуның белән ул аның хатыны була. Шуның белән бергә, аңа яңадан мәһер бирү тиеш түгел иде. Әгәр олы угыл аңарга никахланмаса, башка угыллар никахланырга ихтыярлы иделәр. Фәкать бу вакытта аларга яңадан мәһер бирү тиешле була иде. Бу гадәт гарәпләрдә булса да, яхшы гадәт дип саналмый иде. Шуның өчен алар бу никахны «Никахе-л-макт» [җирәнгеч], шушы никахта барлыкка килгән баланы «Мак-

ти» яки «Макыйт» дияләр иде. Ислам дине бу ике никахны бетерде[1].

## Күпхатынлылык

Башка өммәтләрдә булган кебек, җаһилияттә гарәпләрдә дә күп хатын алу гадәте бар иде. Алар арасында унар хатын алган кешеләр дә күп очрый иде. Ир хатыннары арасында гаделлек кылмый, аларны үз шәһвәте өчен генә тота иде яки малларына кызыгып ала иде. Бу хатыннар күбрәк ирнең якыннарыннан калган акчалы ятим кызлар булып, ир, гадәт буенча, аларны малларына кызыгып, үзенә җәберләп ала иде һәм яратса да, яратмаса да никахында тота иде. Күп вакытта мондый хатыннар, үз малларын ташлап, ирдән үзләрен коткарырга мәҗбүр булалар иде. Ислам дине бу мәсьәләдә хатыннарның хәлен җиңеләйтте. Ирләргә дүрт хатынга хәтле генә никахланырга рөхсәт бирде һәм хатыннар арасында гаделлекне шарт итеп куйды. Ә инде хатыннар арасында гаделлек саклап булмаса, бер хатын белән генә разый булырга кушты.

Күпхатынлылык  Исламда рөхсәт ителгән булса да, таләп ителгән гамәлләрдән саналмый, бары тик зарури иҗтимагъ өчен генә мөбәх кылынган нәрсәдер. Исламият гомуми бер дин булып, аны тормышта куллану һәр заман-

---

1 Коръәндә “Ниса” сүрәсендә 22-23 аятьләрдә:

”وَلاَ تَنكِحُواْ مَا نَكَحَ آبَاؤُكُم مِّنَ النِّسَاء إِلاَّ مَا قَدْ سَلَفَ إِنَّهُ كَانَ فَاحِشَةً وَمَقْتًا وَسَاء سَبِيلاً“

**[Аталарыгыз никахында булган хатыннарга никахланмагыз, әгәр дә бу алдан эшләнелгән булмаса. Ул эш, әлбәттә, фәхеш һәм ачулы эштер һәм ул эшне эшләгән кешеләрнең юлы – кабахәт юлдыр.]**

”...وَأَن تَجْمَعُواْ بَيْنَ الأُخْتَيْنِ إَلاَّ مَا قَدْ سَلَفَ إِنَّ اللّهَ كَانَ غَفُورًا رَّحِيمًا“ [Сезгә берьюлы ике бертуган кыз кардәшкә никахланырга тыела, әгәр алдан бу эшләнелгән булмаса. Чынлыкта исә, Аллаһ гафу итүче һәм рәхимле] – авт.

да һәм һәр урында мөмкин булырга тиеш. Әгәр Исламият дистәләгән хатыннар алырга гадәтләнгән кавемнәргә күпхатынлыкны тыйса, гамәлдә бу чынга ашар идеме? Һәм төрле сугышлар сәбәпле, ирләр әзәеп калган җирләрдә хатын-кызларны фәхешлеккә төшүдән саклап калучы бер чара шушы күпхатынлык түгелме? Хатында бала таба алмау кебек кимчелекләр булганда, аның рөхсәте белән ирнең икенче хатын алуында нинди зарар бар? Кыскасы, күпхатынлылык Исламда мактаулы нәрсә булмаса да, рөхсәт ителгән эштер. Исламият аны тар кысалар эченә куйган һәм шулкадәр авыр шартлар билгеләгән ки, аларны үтәмәгән очракта гөнаһлы буласың. Әлбәттә, хәзерге көндәге кебек, хайвани шәһвәтләргә ияреп, хатыннан үч алу нияте белән хатын өстенә хатын алу Исламияттән түгелдер.

## Хатын-кызның дәрәҗәсе

Тормыш авырлыгының яртысын ирләр белән бергә тарткан хатыннар җаһилият вакытындагы гарәпләрдә кеше хокукыннан мәхрүм иделәр. Алар хатын-кызга ирләрнең шәһвәте өчен генә бар ителгән бер мәхлукка караган шикелле генә карыйлар иде. Гарәпләрнең Исламияткә чаклы хатын-кызга нинди күз белән карауларына үзләренең кызларын терелә́й жиргә күмүләре зур бер дәлил булып тора. Аларда ирнең вафатыннан соң хатын, үзе мирас булып саналып, мәет варисының аны хатынлыкка мәһерсез генә алырга хакы бар иде. Хатын аларга берничек тә каршы килә алмый. Шулай ук кызларның да этиләреннән мирас алырга хокуклары булмый. Мирас корал күтәргән ир балаларга гына тотыла иде. Һәм бер кешенең никахында унар, унбишәр хатынның

www.darul-kutub.com

булуы да аларның тигез хокуктан мәхрүм ителүләрен күрсәтеп тора иде. Җаһилият вакытында Һинд бинте Гутбә, Сүлмә бинте Гамр кебекләрнең батырлыклары һәм кыюлыклары белән, Хәдичә бинте Хөвәйлид кебекләрнең акыл, фикер йөртүләре, Хансә кебекләрнең шигъри куәтләре белән мәшһүр хатыннар булсалар да, алар кебекләр бик аз иделәр. Ул вакытларда хатыннар гәүдәләре, рухлары, фикерләре белән олуг булсалар да, элекке вакытлардан килгән тәрбия нәтиҗәсендә зәгыйфь, түбән булып, ирнең кулында бер уенчык кебек иделәр. Ә Ислам дине хатыннарны бу әсирлектән коткарды. Хәзерге көндә дә иң мәдәниятле милләтләрнең хатыннары ирешә алмаган хокукларны аларга бирде. Моның нәтиҗәсе буларак, хатыннар хәлифәләр хозурында басып, үзләренең хокукларын яклау дәрәҗәсендәге хөррият һәм кыюлык ияләре булдылар.

## Хиҗап

Җаһилият гасырында хатыннарда каплану (ихтиҗаб) гадәте юк иде. Гарәп хатыннары һәрвакыт ирләр белән аралашалар, базарларда йөреп сәүдә итәләр, сугышларда катнашып, ирләренә булышлык итәләр иде. Берәр хатынның теләсә нинди ир-ат белән сөйләшүе алар каршында гаеп түгел иде. Ләкин гарәпләрдә ихтиҗабның булмавы хатыннарның иҗтимагый тормыштагы урыннарын, аларның да ирләр кебек кеше икәнлеген, ирләрдә булган хокук аларда да булырга тиеш икәнлеген төшенгәннән түгел, бәлки бәдәви табигатеннән килә иде. Сахрада күчмәлек хәлендә тормыш иткән кавемнәрдә бөркәнү табигый бер эш иде. Кыргызларда һәм кайбер башкорт вә татарларда качу гадәте юк.

Исламият гарәпләрнең башка бик күп гадәтләренә каршы килмәгәнлеге кебек, моны да шул көенчә калдырды (Бу турыда алда тәфсилләп язылыр).

## Вәэд

Гарәпләрнең начар бер гадәтләре була: алар үзләренең кызларын тереләй җиргә күмәләр. Тереләй күмелгән кызга *«вәидә»* яки *«мау'үдә»* диелер. Әүвәл кызларын тереләй күмү бөтен гарәп кабиләләрендә дә булган. Соңыннан ул гадәт бетә бара һәм Исламият килер алдыннан бик аз кабиләләрдә генә кала. Фәкать Бәнү Тәмим кабиләсендә бу гадәт, киресенчә, киң таралышта иде. Гарәпләрнең үз кызларын тереләй күмүләренең сәбәбе, аларның сугыш вакытында әсирлеккә алынып, ата-анасына һәм якын кардәшләренә гарьлек килүеннән куркулары иде. Чөнки гарәп кабиләләре һәрвакыт бер-берсе белән сугышалар, һөҗүм итәләр, җиңеп чыкканнары җиңелгәннәренең малларын, хатын вә балаларын алып китәләр иде. Ир бала яшьтән үк сугыш коралыннан файдаланырга өйрәнә, әсирлеккә төшкән вакытта да, аның качып котылуы яки икенче сәбәпләр белән яңадан үзенең кабиләсенә кайтуы бик ихтимал иде. Кыз бала исә зәгыйфь булуы аркасында, әсир төшкән кабиләдә кәнизәк булып яшәргә мәҗбүр, аның котылуы мөмкин түгел диярлек иде. Менә шушы сәбәптән гарәпләр кыз баланы сөймиләр, аңа начар күз белән карыйлар иде. Кыз бала дөньяга килсә, гадәттә кайгыралар, ачуланалар, аны үзләре арасында хурлык дип саныйлар иде[1].

1 “وَإِذَا بُشِّرَ أَحَدُهُمْ بِالأُنثَى ظَلَّ وَجْهُهُ مُسْوَدًّا وَهُوَ كَظِيمٌ. يَتَوَارَى مِنَ الْقَوْمِ مِن سُوءِ مَا بُشِّرَ بِهِ أَيُمْسِكُهُ عَلَى هُونٍ أَمْ يَدُسُّهُ فِي التُّرَابِ أَلاَ سَاء مَا يَحْكُمُونَ” [Алардан кемгә дә булса кызы туды дип хәбәр ителсә, кайгыдан аның йөзе карала һәм аның йөрәге ачу белән тула. Яман хәбәр ишеткәч, ул кешеләрдән кача. Хурлык белән ул баласын калдырырмы, әллә җиргә күмеп куярмы? Аларның сайлаган хөкемнәре ни дәрәҗәдә яман!] Ән-Нәхл, 58-59. – авт.

Шулай ук гарәпләр арасында кызларын фәкыйрьлектән куркып яки кызларда булган сыйфатлардан шомланып күмүчеләр дә була иде. Кайбер гарәпләр кызларын күммичә, суга батыралар яки чалалар иде. Ә кайбер гарәпләр ир балаларым унга җитсә, берсен корбан итәр идем дип нәзер әйтеп, унга тулгач, шуларның берсен корбанга чалалар иде. Ошбу җөмләдән, нәзер әйткәннәрдән берсе Мөхәммәд галәйһиссәламнең бабасы Габделмоталлиб иде. Әлбәттә, акыллы гарәпләр бу вәхши гадәтләргә разый булмый. Алар бу эшләргә мөмкин кадәр каршы торалар, аны бетерергә тырышалар, терeләй күмеләчәк кызның атасына маллар биреп, кызның гомерен сатып алалар. Мәшһүр Зәйд бине Гамр бине Нүфәйлнең, Сагъсага бине Наҗиянең һәм башкаларның бик күп кызларны вәэдтән коткарганнарын риваять итәләр. Һәм мәшһүр шагыйрь Фәраздак терeләй күмеләчәк кызларны коткарып калган бабалары белән горурланып шушындый сүзләр язган:

وَمِنَّا الَّذِي أَحْيَا الوَئِيدَ وَغالِبٌ وَعَمْرٌوٌ وَمِنَّا حَاجِبٌ وَالْأَقَارِعُ

أُولَئِكَ آبَائِي ، فَجِئْنِي بِمِثْلِهِمْ ، إِذِا جَمَعَتْنَا يَا جَرِيرُ الْمَجَامِعُ[1]

Кызларны күмү ошбу рәвештә була иде: кыз алты яшькә җиткәч, ир хатынына: «Балаңны киендер, зиннәтлә, хушбуй сөрт, агаларына кунакка алып барам», – дия. Алдан сахрада бер чокыр казып куя. Чокырга барып җиткәч, балага чокырны күрсәтә, бала карап торганда, артыннан төртеп төшерә һәм өстенә туфрак ташлый. Кайбер гарәпләр, кызларның махсус яшькә үсеп җиткәнен көтмичә, бала туу белән күмәләр иде: хатын, алдан казылып куелган чокыр

---

1 Галиб, Гамр, Хәҗиб, Акрагълар кыз балаларны үлемнән коткаручы затлар. Алар безнең якыннарыбыз. Менә болар минем бабаларым. Җәрир, берәр мәҗлестә җыелышсак, син дә шулар кебек бабаларыңны китер.



www.darul-kutub.com

өстендә бала таба, әгәр ир бала туса, аны алып калалар, әгәр кыз бала туса, шунда күмәләр иде.

Җаһилият вакытындагы гарәпләрнең никадәрле каты бәгырьле, рәхимсез икәнлекләренә, иҗтимагый хәлләре никадәр начар нигезгә корылганлыгына дәлил буларак шушы гадәтләрне атау да җитәдер. Коръәни Кәрим шушы гадәтне гамәлдән чыгарып, берничә аять белән моның наданлык икәнлеген аңлатып бирә:

﴿وَلاَ تَقْتُلُواْ أَوْلادَكُمْ خَشْيَةَ إِمْلاقٍ نَّحْنُ نَرْزُقُهُمْ
وَإِيَّاكُم إنَّ قَتْلَهُمْ كَانَ خِطْءًا كَبِيرًا﴾ [1]

﴿وَإِذَا الْمَوْؤُودَةُ سُئِلَتْ بِأَيِّ ذَنبٍ قُتِلَتْ﴾ [2]

﴿قَدْ خَسِرَ الَّذِينَ قَتَلُواْ أَوْلاَدَهُمْ سَفَهًا بِغَيْرِ عِلْمٍ وَحَرَّمُواْ مَا رَزَقَهُمُ
اللّهُ افْتِرَاء عَلَى اللّهِ قَدْ ضَلُّواْ وَمَا كَانُواْ مُهْتَدِينَ﴾[3]

﴿وَكَذَلِكَ زَيَّنَ لِكَثِيرٍ مِّنَ الْمُشْرِكِينَ قَتْلَ أَوْلاَدِهِمْ شُرَكَآؤُهُمْ﴾[4]

## Хәмер хакында

Җаһилият вакытындагы гарәпләрдә исерткеч бик нык таралган иде. Бу авыруга ир вә хатыннар бөтенесе бергә дучар булган иделәр. Хәмер эчү гарәпләрдә су эчү дәрәҗәсендә табигый булып, аны ташлау аларга гаять авыр иде. Хәтта

1 “Хәерчелектән куркып, балаларыгызны үтермәгез! Без – аларны һәм сезне дә ризыкландыручыдыр. Чынлыкта исә, балаларны үтерү зур гөнаһтыр!” (әл-Исра/31) – тәрҗ.

2 «Тере килеш күмеп куелганнан нинди гөнаһлары өчен үтерелгәнен сорагач». (Тәквир/8-9) – тәрҗ.

3 «Акылсызлык белән балаларын үтергән кешеләр хәсрәттә. Алар Аллаһының ризыгын үз-үзләренә тыйдылар һәм Аллаһыга яла яктылар. Алар адаштылар һәм туры юлда булмадылар». (әл-Әнгам/140). – тәрҗ.

4 «Шулай ук күп кенә мөшрикләргә үзләренең иптәшләре бала үтерүне матур итеп тасфирлап күрсәттеләр…» (әл-Әнгам/137). – тәрҗ.

www.darul-kutub.com

Ислам килгәч, аны тиз арада хәрам итмәде. Ә киресенчә, берничә дәрәҗә үтеп, ахыргы вакытта гына катгый тыелды. Хәмер турында иң беренче иңдерелгәне

«يَسْأَلُونَكَ عَنِ الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ قُلْ فِيهِمَا إِثْمٌ كَبِيرٌ وَمَنَافِعُ لِلنَّاسِ وَإِثْمُهُمَآ أَكْبَرُ مِن نَّفْعِهِمَا...»[1]

аяте булып, беркадәр халыкның аңардан тыелуына сәбәп булды. Соңра

«يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ لاَ تَقْرَبُواْ الصَّلاَةَ وَأَنتُمْ سُكَارَى حَتَّىَ تَعْلَمُواْ مَا تَقُولُونَ...»[2]

аяте иңдерелеп, аны  хәйран киметте. Соңрак

«يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُواْ إِنَّمَا الْخَمْرُ وَالْمَيْسِرُ وَالأَنصَابُ وَالأَزْلاَمُ رِجْسٌ مِّنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ .فَاجْتَنِبُوهُ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ  إِنَّمَا يُرِيدُ الشَّيْطَانُ أَن يُوقِعَ بَيْنَكُمُ الْعَدَاوَةَ وَالْبَغْضَاء فِي الْخَمْرِ وَالْمَيْسِرِ وَيَصُدَّكُمْ عَن ذِكْرِ اللّهِ وَعَنِ الصَّلاَةِ فَهَلْ أَنتُم مُّنتَهُونَ»[3]

---

1 «Синнән хәмер һәм отыш уены хакында сорашалар. Әйт: «Ул нәрсәләрдә зур гөнаһ бар һәм кешеләргә аз гына файдасы да бар, ләкин файдасына караганда гөнаһы һәм зарары зуррак». (әл-Бәкара/219). – тәрҗ.

2 «Әй, мөэминнәр, исерткеч эчеп, исереп, ни сөйләгәнегезне белмәсәгез, намазга якын бармагыз!...» (ән-Нисә/43). – тәрҗ.

3 "Әй, мөэминнәр! Исертә торган эчемлекләрнең, отыш уеннарының һәртөрлесе дә, сыннарга гыйбадәт итү - Аллаһыдан башка мәхлукларга табыну эшләре, шулай ук ырымлау-багучылык эшләре - хәрамдыр, шайтан эшләреннән булган пычрак эшләрдер, һәлак булудан котылу өчен бу нәҗес эшләрдән ерак булыгыз! Саклансагыз, шаять, котылырсыз - өстенлек табарсыз.

Хәмер эчүегез һәм отыш уеннары уйнавыгыз белән, әлбәттә, шайтан арагызда дошманлыкны һәм бер-берегезгә һөҗүм иттерә торган ачуны булдырырга тели вә Коръән вәгазеннән, намаз укудан сезне тыярга тели, шулай булгач, ул шайтан эше булган нәҗесләрдән тыеласызмы?" (әл-Мәидә/90-91). – тәрҗ.

www.darulkutub.com

аятьләре иңеп, хәмерне катгый рәвештә хәрам кылды.

Кайбер кешеләрнең, хәтта кайбер кабиләләрнең хәмер хәрам булганлыгы өчен Исламны кабул итмәүләре гарәпләрдә хәмернең нинди дәрәҗәдә таралуына дәлил булып тора. Һәм гарәпләр хәмер белән шул кадәр агуланганнар иде ки, аның өчен актык киемнәреннән, хәтта үзләренә иң кадерле, иң хөрмәтле нәрсәләреннән мәхрүм калырга риза иделәр. Моңа мисал – Кәгъбәтуллаһның ачкычларына хуҗа булган Әбү Габшән әл-Мүлкәний Кусай бине Киләб бер турсык хәмер бәрабәренә әйтелгән ачкычларны сатуга хәтле килеп җиткән иде. Шушы сәбәптән Кәгъбәтуллаһка хезмәт итү Хузага кабиләсеннән Корәеш кабиләсенә күчә. Моның хакында бер шагыйрь шушы шигырьне яза:

بَاعَتْ خُزَاعَةُ بيْتَ اللهِ إِذْ سَكِرَتْ    بِزِقِّ خَمْرٍ فَبِئْسَتْ صَفْقَةُ الْبَادِي
بَاعَتْ سِدَانَتَهَا بَالخَمْرِ وَ انْقَرَضَتْ    عَنِ الْمَقَامِ وَ ظَلَّ الْبيْتُ وَ الْنَادِي[1]

Гомумән, гарәпләр хәмерне мәҗлес ясап, җыелышып эчәләр иде. Күп вакытларда күңел ачу, кәеф күтәрү өчен хәмерле мәҗлесләрдә җарияләр барабаннар сугып җырлап бииләр иде. Җаһилият вакытында хәмер сата торган махсус урыннар да бар иде. Шуның белән хәмерне үзләренә тыйган кайбер төркемнәр халыкка хәмернең зарарларын сөйләп, аны мөмкин кадәр бетерергә тырышалар иде. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шулар арасыннан булып, асылда хәмер эчми иде.

1 Хузага исереклек белән Аллаһы йортын бер турсык хәмер бәрабәренә сатты. Монда алып-сату булырмы? Аллаһы йортына хезмәт итүне аз бер нәрсә бәрабәренә сатты да, мәкаменнән, Аллаһы йортының күләгәсеннән, андагы мәҗлестән мәхрүм булды. – авт.

www.darulkutub.com

# Истикъсәм би-л-әзләм
# [Уклар белән хөкем итү, ачыклау]

Җаһилият гасырында гарәпләр сәфәргә чыкмакчы яки берәр сәүдәгә керешмәкче булсалар, я берәр кызга өйләнмәкче яки башка бер эшне ачыкламакчы булсалар – Гоззә, Һөбәл кебек мәшһүр сыннарга барып, бу эшнең хәерле булуын яки булмавын белер өчен, «Әзләм» дигән махсус уклар кулланалар иде. Мәсәлән, бер кеше сәфәргә чыгарга теләсә, берсенә «раббым әмер итте» дип, икенчесенә «раббым тыйды» дип язылган ике укны алып капчык кебек берәр нәрсәгә салып болгата да, «раббым әмер итте» дип язылганы чыкса, эшен дәвам итә иде. Ә инде икенчесе чыкса, эшеннән ваз кичә иде. Тагы берәүнең нәсебенә шик туса, берсенә «минкүм», икенчесенә «мин гайрикүм», өченчесенә «мүлсак» дип язылган өч укны бергә салып бутыйлар да, беренчесе чыкса, ул кешене үзләреннән саныйлар, икенчесе чыкса, аны читләштерәләр, ә өченчесе чыкса, ул кеше алар арасында билгесез нәсебтән булып кала иде. Гомумән, бу күренеш Һөбәл янында була иде. Әмма башка потлар янында да бу гадәтне башкаралар иде[1]. Инде бу гадәтнең бер хорафатка ияртү икәнлеген сөйләүдә хәҗәт юктыр. Ислам килгәч, бу гадәтне тыйды[2].

---

1 Мәшһүр шагыйрь Имре-л-Кайс, атасы үтерелгәнен ишеткәч, үтерүчеләрдән үч алу хакында Зү-л-хилс каршында истикъсәм кылып, үз теләгәне чыкмагач, потка ачуланып шушы шигырьне сөйләгән:

"لم تنه عن قتل العادة زورا  لو كنت يا ذا الخلص الموتورا" - авт.

2 "Сезгә шулай ук билгесез киләчәкне уклар буенча белергә омтылу һәм шулай ук берәр нәрсәне ук атып бүлү тыела", әл-Мәидә/3. "Әй иман китерүчеләр! Чынлыкта исә, исерткеч эчемлекләр, отышлы уеннар, сыннар һәм багу уклары шайтанның шакшы гамәлләреннәндер. Алардан ерак торыгыз, бәлки сез җиңүчеләр арасыннан булырсыз", әл-Мәидә/90.



www.darul-kutub.com

# Мәйсир

Мәйсир отыш уенының бер төре иде. Һәм ул гарәпләрдә киң таралган, күркәм вә мактаулы эшләрдән санала иде. Бу уен күбесенчә ачлык вакытында уйналып, аңардан килгән отышлардан уйнаучылар үзләре файдаланмыйлар, ә фәкыйрьләр файдалана иде. Гарәпләрдә күркәм вә мактаулы эш булып саналуы да шуның өчен. Җаһилияттәге гарәпләр мәйсирнең дәрәҗәсен күтәреп шушындый сүзләр дә әйткәннәр:

سَهْلِ الْخَلِيفَةِ مَشَّاءٍ بِأَقْدَامِهِ      إِلَى ذَوَاتِ الذَّرى حَمَّالِ أَثْقَالِ[1]

Ләкин мәйсир уйнаучылар күп вакытта бер-берсе белән уйнаганда кызып китеп, бөтен малларын да оттырып бетерә иделәр. Шуның өчен дә бу эшне Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримендә хәрам кылды[2].

# Ракыйт – коллык мәсьәләсе

Ул вакытта, башка халыклардагы кебек кол асрау гадәте гарәпләрдә дә бар иде. Сугышта әсирлеккә эләккән кешеләрне үзләренә кол итеп, аларга төрле авыр хезмәтләр йөклиләр иде. Гарәпләр кол булган кешеләргә гаять түбән караш белән, хайванга караган шикелле карый иделәр. Хуҗа колга теләгән мөгамәләсен кылырга, аны теләгәнчә газапларга ихтыярлы иде. Гарәпләр кәнизәкләрне фәхешлеккә көчли иделәр.

Коллык мәсьәләсе гарәпләрдә нык таралганга күрә, аны шунда ук бетерү бик мөшкел булганлыктан, Ислам дине

1 Хуш табигатьле, укларын күтәреп мәйсир уйнау өчен баручан, эшчән. – авт.

2 Мәйсир хакында «Булугуль-Әраб»кә мөрәҗәгать ителде.56-70 б., 3 т. – авт.



www.darul-kutub.com

аны кинәт хәрамга чыгармады, ә бик тар кысага алды. Ислам шәригате, хуҗаларга колларына карата кардәшчә мөгамәләт итәргә, үзләре кигән киемнәрне кидерергә, үзләре ашаган ашлар ашатырга, аларга көчләре җитмәгән авыр хезмәтләр йөкләмәскә һәм аларга төрлечә ярдәм итәргә кушты. Ислам шәригате «*зиһар*», «*йәмин*», «*хаталык белән үтерү*» кебек эшләрнең кәффәратендә кол азат итүне таләп итеп куйды. Һәм бу әмернең ишарәсе коллыкны бетерүгә юл әзерләп кую иде[1]. Аллаһының илчесе Мөхәммәд галәйһиссәлам Бәне-л-Мосталак сугышында әсир алынган Җүвәйрияне азат итеп, үзенә хатын итүе шул сугышта әсиргә төшкән кешеләрне сәхабәләреннән азат иттерүгә нигез булып тора иде. Тагы колын кыйнаган кешегә рәсүлуллаһның шул колны азат итүне боеруы Мөслими, Әбү Давыд, Тирмизи кебек хәдис китапларында зекер кылынган[2]. Кояш тотылганда кол азат итүе илә әмере Бохари җыентыгында да зекер ителгән[3]. Болар коллыкны бетерү максатына нигездер. Ислам әһелләре исә монда да һәм башка бик күп мәсьәләләрдә дә Аллаһының илчесе Мөхәммәд галәйһиссәлам артыннан иярмәделәр. Әгәр рәсүлуллаһтан соң да шул юл белән кителгән булса, коллык күптән беткән булыр иде. Хәзер (XX йөз башында) бөтен дөньяда, бөтен милләтләрдә коллык беткән чорда, коллыкка каршы иң беренче башлап көрәш ачкан Гарәбстанда – Мәккә шәһәрендә хайван урынына кол вә кәнизәкләр сатылмактыр. Оят түгелме Ислам әһелләренә?

1 Кара: “ән-Нисә” 92 аять, “әл-Мәидә” 89 аять, “әл-Мүҗәдәлә” 3 аять. – авт.

2 “әт-Тирмизий” 199 б., 1 т. – авт.

3 “әл-Бохари” 38 б., 2 т. – авт.

# Бәхира, Сәибә һәм башкалар

Гарәпләрнең начар эшләреннән тагын берсе шул: бәгъзе бер хайваннарны үзләренә хәрам кылалар иде. Мәсәлән: дөя биш бала тудырып, соңгысы иркәк булса, шул дөянең колагын ярып җибәрәләр, аны җикмиләр, саумыйлар, суймыйлар, дөя теләгән җирдә утлап йөри, теләгән җирдә су эчә, аны һич нәрсәдән тыймыйлар. Моңа «*Бәхира*» дияләр иде. Шулай ук бер дөя ун бала тудырса, аңардан файдаланмыйлар, аны үз юлына җибәрәләр. Моңа «*Сәибә*» дияләр иде. Ата дөядән ярālып, ун баласы туса, шул ата дөяне гарәпләр үзләренә хәрам кылалар, аңа менмиләр, йонын кырмыйлар, аңардан берничек тә файдаланмыйлар. Моңа «*Хәми*» дияләр иде.

Сарык тоташтан биш тапкыр икешәр бала китерсә, моннан соң сарыктан туган бәрәннәрне ирләргә ашау дөрес, хатыннарга ашарга дөрес түгел. Әгәр үлек туса, барына да ашау дөрес иде[1]. Моңа «*Вәсыйлә*» дияләр иде.

Дөянең иң беренче баласын гарәпләр үзләренең потларына якынаю нияте белән алар исеменә корбан чалалар иде. Моңа «*Фәрагъ*» дияләр иде. Рәҗәб аенда да потларга якынаю нияте белән корбан чалалар иде. Моңа «*Гатира*» дип әйтәләр иде.

Ошбу зекер ителгән юл белән хәләл хайваннарны һичбер сәбәпсез үзләренә хәрам кылу гарәпләрдә нык таралган иде. Бу эшләр барысы да потларының хәтерен табу, аларга якынаю өчен эшләнә иде.

Кешеләргә бернинди зарар да, файда да китерми

1 "Бу хайваннарның карынындагы туачак балалары ирләребезгә генә хәләл булып, хатыннарыбызга хәрамдыр, әгәр үлсә, ул үлгән хайван иргә дә, хатынга да хәләл булыр", - дип батыл хөкемнәрен дин хөкемнәре дип сыйфатлаганнары өчен тиздән җәза кылырбыз, бит Аллаһы - хөкем итүче вә белүче". әл-Әнгам 139. – авт.

www.darulkutub.com

торган ташлардан, агачлардан куркып, хәләл кылынган нәрсәләрдән тыелу – Аллаһы тарафыннан бүләк ителгән акыл нигъмәтен кире кагу һәм Аңа карата ихтирамсызлык буладыр. Шуның өчен Коръәндә бу турыда күп аятьләр иңеп, боларны хатага чыгара һәм бу начар гадәтләрнең ата-бабадан килгәнен аңлатып, кешеләрне шул эшләрдән тыя[1].

# Гадәт, әхлак, хорафат

**Нәселне кайгырту**. Гарәпләрнең гадәтләре – алар нәселгә нык игътибар итәләр. Аларда нәселләренең бөеклеге белән мактану вә горурлану бик таралган иде. Алар Гукәз базарында һәм башка ярминкәләрдә оста сөйләүчеләр, шигырь укыган шагыйрьләр, юмартлык белән танылган һәм гарәпләргә хуҗа була алган мәшһүр ата-бабалары белән мактаналар иде. Бу күп вакытта араларында сугыш утының кабынып китүенә дә сәбәп була иде. «Әйямү гарәб» дигән мәшһүр вакыйгаларның күбесе шул сәбәптән барлыкка килгән. Ислам дине бу жаһилият гадәтен дә юкка чыгарды. Һәм кешенең дәрәҗәсе ата-бабасының дәрәҗәсе белән бәйле булмыйча, шул кешенең үз гамәле белән генә бәйле булуын бәян итте.

**Тәгәссуб жинси [үз милләтен чиктән тыш яратып, башка милләтләрне түбән санау].** Гарәпләр үз милләтләрен бик каты күтәрәләр иде. Алар башка милләткә түбәнчелек белән карап, үзләрен генә кешегә саныйлар иде. Ислам дине бу карашны бетерде[2].

1 “Аллаһы кешеләрнең кулындагы хайваннарга: Бәхира, Сайбә, Вәсыйлә, Хами дип исем бирмәде һәм аларны хәрам да кылмады, ләкин кәферләр Аллаһыга ялганны ифтира кылдылар: ”Бу хайваннарны Аллаһы хәрам кылды,” - дип, аларның күпләре аңламыйлар”. әл-Мәидә/103. “Фәрагъ та гатира да юк”. әт-Тирмизий 195 хәдис. – авт.

2 “Аллаһы хозурында хөрмәтлеләрегез – Аллаһыдан куркып, гөнаһлардан сакланучыларыгыздыр” (әл-Хуҗурат/13). “Гарәпләрнең башка халыклар арасында өстенлекләре юк, мәгәр тәкъвалыкта гына өстенлек бардыр”. Хәдис. – авт.

**Хәрам айларын хөрмәтләү.** Гарәпләрдә хәрам айларын (рәҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррәм айларын) хөрмәтләү бар иде. Бу гадәт Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәрдән калган яхшы гадәтләр җөмләсеннән иде. Гарәпләрнең зекер иткән айларга ихтирамы шул дәрәҗәдә иде ки, берәүнең атасын яки кардәшен үтерсәләр, ул шул айларда үтерүче кешеләрне эзләп табып, форсат булса да үчен алмый иде.

Хәрам айларда сугышлар булмый, һәркем рәхәтләнеп сәфәрләрдә йөри иде. Ләкин кайсы вакытта бу тәртип бозыла һәм хәрам айларда сугыш булып, шул сугыш булган хәрам ай икенче вакытка күчерелә иде. Нәтиҗәдә хәрам айлары кайбер елларда хөрмәт ителә, ә кайбер елларда ихтирамга битараф булып, аның урынына башка айларда сугышмый иделәр[1].

**Юмартлыклары**. Гарәпләр юмартлыклары белән мәшһүр иделәр. Аларда кунакны тәрбия итү, аны кадерләү иң зур бурыч санала иде. Гарәпләрдә шулкадәр юмарт кешеләр бар иде ки, актык дөясен, актык атын суеп, кунакны тәрбия итәләр иде. Гарәпләрнең юмартлыгы хакында сүз озайтырга да хаҗәт юк. Аларның әдәбиятларында күпчелек урынны алып торган шигырьләренә күз салу да җитеп торадыр. Гарәпләрдә юмартлык һәм кунакчыллык белән шөһрәт тапкан, үрнәк күрсәткән кешеләр бик күптер. Мәсәлән, Кәгъб

1 Аллаһы Тәгалә "Тәүбә" сүрәсендә 36-37 аятьләрдә:

"Дөреслектә, Аллаһының Китабында айларның саны – унике, алардан дүрт ай – рәҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам – хәрам айлары, алар вакытында сугыш алып бару тыела. Бу – Аллаһы диненең кануны һәм аны юкка чыгарып булмый. Үзегезгә зарар китермәгез – бу айларда сугыш башламагыз. Ләкин әгәр сезгә дошман һөҗүм итсә, чигенмәгез, әй мөэминнәр, алар сезгә каршы сугышкан кебек үк, бөтен мөшрикләр белән дә көрәшегез. Белегез, Аллаһы тәкъвалылар беләндер. Бу тыелган айларны – Аллаһы кануннарын бозу. Мөшрикләр шулай эшли иде, алар бу вакытта сугыш алып барырга теләсәләр, хәрам айны гади айга әйләндерәләр, шуннан соң, ел эчендә Аллаһы билгеләгән кадәр тыелган айлар саны булсын өчен, рөхсәт ителгән айны тыелган дип саныйлар иде. Начар гамәлләре аларга яхшы булып тоелды. Аллаһы кәферләрне туры юлдан алып бармый". – авт.

бине Мәмә, Әус бине Хәрисә, Һәрим бине Синән, Габдулла бине Җүдган, Кайс бине Сәгъд.

**Шүҗәгать [батырлык, кыюлык]**. Гарәпләр бик йөрәкле, батыр, сугышчан бер халык. Аларның батыр булулары, бигрәк тә, табигатькә бәйле иде. Чөнки алар иген чәчү, бакча карау шикелле эшләр белән бик шөгыльләнми, аларның күп вакытлары бер-берсе белән сугышып үтә иде. Әлбәттә, кавемнең мондый табигать белән батырлыгы һәм кыюлыгы артуы мәгълүмдер. Гарәпләрнең ни дәрәҗәдә батыр булуларын сөйләп торырга да хаҗәт юк, бу турыда аларның әдәбиятларына бер күз салу да җитә. Ләкин гарәпләр ошбу батырлыкларыннан асылда файда күрмиләр, ә киресенчә, үзләренә зарар гына итәләр. Алар үзләренең батырлыкларын кардәшләре белән сугышуга, тартышуга сарыф итеп, үз-үзләре куәтләрен бетерә иде. Әгәр шул көчләре белән дошманнарына каршы торсалар, алар Рум белән фарсыларга буйсынып тормас, ә киресенчә, үзләре аларга хужа булырлар иде.

**Вафә – сүздә тору, ышанычлы булу.** Гарәпләрдә кешенең иң мактаулы сыйфатларыннан берсе – тугры булу. Аларның карашы буенча, вәгъдәдә тору, эштә һәм сүздә тугры булу иң әйбәт сыйфатлардан санала, вәгъдәне бозу, сүздә тормау, ялган сөйләү исә иң начар эшләр җөмләсеннән иде. Шулкадәр кырыслык һәм тупаслык белән данлыклы булган гарәпләрдә ошбу күркәм холыкларның булуы искитәрлек. Шулардан Сәмавәл бине Гадия, Хәнталә бине Гафрә, әл-Харис бине Залим, Әбү Хәнбәл әт-Таий, Фүкәйһә бинте Катәдә Үмм Җәмил кебек шәхесләр гарәпләрдә бик күптер.

**Горурлык.** Гарәпләр горур һәм ирекне сөя торган,

www.darul-kutub.com

золымлыкны, җәбер һәм хурлыкны күтәрә алмый торган бер кавем. Бу холык гарәпләрдә гомуми иде. Гарәпләрдә *«Бәсүс»*, *«зи карр»* һәм башка мәшһүр сугышларның сәбәпләре горурлыкка һәм хурлыкны күтәрә алмауга кайтып кала. Мәсәлән, фарсылар белән гарәпләр арасында булган мәшһүр *«зи карр»* сугышының сәбәбе түбәндә аңлатылыр. Кисра[1] Ногман бине Мөнзирне Мәдинәгә чакырткач, Ногман үзенең үтереләчәген сизеп, бөтен коралларын һәм гаиләсен Һәни бине Мәсгүд әш-Шәйбанидә калдырып тора. Ногман төрмәдә үтерелгәч, кисра шул заттан Ногман калдырганнарны бирүен сорады. Һәни үзенең горурлыгы белән аларны бирмәде һәм кисра белән сугышка әзерләнә башлады. Гарәп кабиләләрен дә бу сугышта катнашырга өндәде. Нәтиҗәдә, шул гарәп кабиләләре белән кисра гаскәре арасында сугыш булып, гарәпләр җиңүгә ирешәләр.

«Бәсүс» сугышы да берәүнең горурлыгы һәм кирелеге сәбәпле булды. Җәссас бине Мурраның халиясе Бәсүснең кул астындагы бер хезмәтчесенең дөясе Җәссас дөяләре белән бергә утлап йөри иде. Бер көнне Күләйб үзенең *«ард галия»* исемле җирдәге утарында Бәсүс хезмәтчесенең дөясен үзенең утарында күреп, ук белән атып үтерә. Бәсүс моны белгәч, «Мине түбәнсеттеләр», – дип ярдәм сорый. Җәссас халиясенең кул астындагы кешегә тигән Күләйбне хурлыкны үз өстеннән төшерер өчен форсат табып үтерә. Шуннан соң Күләйб белән Җәссас кабиләләре арасында 40 елга кадәр сузылган сугыш башлана. Нәтиҗәдә бик күп кешеләр, баһадир егетләр кырыла. Шулай ук *«Дәхисү габра»* сугышының һәм башка сугышларның да сәбәпләре ошбу холык иде.

Горурлыкның олы бер холык икәнлегенә шөбһә

1 Кисра – борынгы фарсы илендә патша дәрәҗәсе.

юктыр. Әмма гарәпләр бу холыкны яхшы якка куллана алмыйлар иде. Бу холыктан файда күрмичә, бәлки зыян гына күрәләр иде. Юк кына нәрсәне дә горурлыкка тия дип, әллә нинди зур вакыйгаларның чыгуларына сәбәпче булалар иде. Үзара кырылышып, куәтләрен башка кавемнәр белән чагыштырганда киметәләр һәм үз дәрәҗәләрен төшерәләр иде. Шушы холыкларын *«зи карр»* сугышындагы кебек башка чит кавемнәргә карата куллансалар, шөбһәсез, иң бөек милләтләрдән булырлар иде. Моны аларга аңлатучы кеше генә юк иде. Моны, ягъни егетлекләрен нинди юлда сарыф итәргә кирәклекне аларга Аллаһының илчесе һәм аның варислары аңлатты. Һәм алар бер вакытны җирдә варисчы булдылар.

Бу холыктан кала гарәпләр зирәклелек, сүзгә оста булу, фикер йөртү, күркәм әхлак, сабырлык кебек гүзәл холыкларга да ия булдылар. Сүзнең ахырында, гарәпләрдә шушындый гүзәл холыкларның булуы аларның зур инкыйлабларга әзер булуларын да күрсәтеп торадыр.

**Хорафат – юк-барга ышану.** Гарәпләр башка жаһил милләтләр кебек хорафатка бирелгән иделәр. Һәм аларда төрле хорафатлар күп урын алып тора. Шулардан:

1. Үлгән кешенең исән вакытта утырып йөргән атын яки дөясен бер җиргә бәйләп куеп, аңа ашарга да, эчәргә дә бирмичә ачтан үтерү[1].

2. Һәммәгә ышану. Ягъни гарәпләрдә үтерелгән мәетнең кырыеннан бер кош чыгар. Әгәр үч алынмыйча, каны бушка китсә, кош үч алынганчы мәет өстендә: «Мине эчертегез (үч каны белән)!» – дип кычкырып очып йөрер.

---

1 Гарәпләр мәетнен аты яки дөясе шулай үтерелмәсә, мәет җәяү кубарылачак дип игътикад итәләр иде. Моның турында бер шагыйрь болай ди:

"أبنيَّ لا تنسَ البَلِية إنّها لا بيك يوم نشوره مركوب." – авт.

Шушы кошны «Һәммә» яки «Садә» дип атаганнар. Бу хорафатны Ислам: *«Авырулар белән, Һәммә кошы белән, Сәфәр ае белән, сахра җене белән бәйле нигезсез юраулар дөрес түгел»,* кебек хәдисләр белән батыйл кылды.

3. Чит шәһәргә яки авылга керер алдыннан, андагы берәр җеннән яки чума кебек йогышлы авырудан сакланып, капкага килеп җиткәч, ишәк кебек кычкыру һәм соңыннан капкага куян тырнагы элеп кую.

4. Берәр җиргә сәфәргә киткәндә, хатыны хыянәт иткәнме-юкмы икәнлеген белү өчен, агач ботагына бау бәйләп кую.

5. Бала тапмый торган хатын, бөек затларның каберен таптап йөрсә, бала таба дип ышану.

6. Җен сугылудан куркып, үзенә пычрак чүпрәкләр, сөякләр тагу.

7. Күз кабагы тартышканда, берәр сөйгән кешене күрүгә ышану.

8. Ерткыч хайваннарның итләрен ашаган кешедә батырлык һәм куәт артуны игътикад итмәк.

9. Елан, чаян чакканнан хатыннарның зиннәтләрен тагып шифа табачагына ышану.

10. Җен кагылу вә күз тиюдән саклану өчен куян аягы, мәче вә төлке кебек хайваннарның теш вә тырнакларын тагу, төрле бөтиләр ясау.

11. Куркыныч сахраларда төнгә калырга туры килгән вакытта, дөяне бер агачка бәйләп, тирәсеннән сызык сызып *«Әгүзе би-сахиби һәзә-л-вәди»* дип, җеннән ярдәм сорау[1].

12. Берәр кыз озак вакыт кияүгә чыкмый торса, төн

1 “Тәхкыйк, кеше затыннан булган ирләр, җен затыннан булган ирләргә сыгына иделәр, ул кешеләр шул җеннәргә ахмаклыкны арттырдылар.” Җинн/6. – авт.

житкәч бер як чәчен туздырыр, шуннан соң күзенә сөрмә тартыр һәм бер аягына халхал киеп *«Йә әл-Кәх, әбгый әнниках каблә әс-сабах»* дип әйтер.

13. Бер кунакның икенче мәртәбә килүен теләмәсәләр, артыннан берәр савыт ваталар иде.

Тагы төчкергәндә карга яки башка кошлардан шомлану, җен вә шүрәлеләрне күрү, хәтта аларга өйләнү кебек хорафатлар дә бик күп иде. Зекер иткән хорафатларның күбесе хәзерге көндә дә гарәпләрдә бардыр.

## Хөкүмәт һәм мәдәният

Гарәбстанның уртасында яшәгән гарәпләрдә оештырылган хөкүмәт һәм телгә алырлык берәр мәдәният булмаса да, Гарәбстанның читләрендә исә бөек хөкүмәтләр төзелеп, үз заманнарында мәдәниятта яхшы ук алга киткән халыклардан санала иделәр. Гарәбстан читләрендә хөкүмәт төзегән гарәпләр Йәмән, Гассан, Ләхм һәм Киндә гарәпләре иде. Йәмән гарәпләре бер-бер артлы өч бөек дәүләт оештырдылар: Мәгыйн, Сәбә, Химьяр.

**Мәгыйн дәүләте**. Мәгыйн дәүләте милади буенча безнең эрага кадәр XIV гасырда барлыкка килә. Әмма бу дәүләтнең тарихы караңгы булганга, табылган хәрабәләрдән чыгып, бертөрле фаразлар гына бардыр. Мәгыйн патшалары *«Мизвәд»* исемле титул белән аталганнар. Һәм аларның саны, әсәрләрдән чыгып, егерме алтыга тула. Мәгыйн дәүләте сугышчан дәүләт булып саналмаган, ә финикиялеләр кебек сәүдә белән шөгыльләнүче дәүләт булган.

**Сәбә дәүләте.** Сәбә дәүләте безнең эрага кадәр 850 елларда барлыкка килеп, безнең эрага кадәр 115 елга

www.darul-kutub.com

хәтле яши. Бу дәүләт Мәгыйн дәүләтеннән өстен чыгып, ул җимерелгәннән соң аның урынына барлыкка килә. Бу дәүләтнең беренче башкаласы Сыйрвәх шәһәре, соңыннан Мәэраб шәһәре булды. Бу дәүләттә никадәр падишаһлар булганы төгәл билгеле булмаса да, калган әсәрләрдән чыгып, 27 падишаһ исеме мәгълүмдер. Сәбә дәүләте, үз вакытына карата бөек мәдәнияткә ирешкән була. Һәм алар сәүдә эшендә, сәнәгатьтә, җир эшендә бик алга киткәннәр. Һиндстаннан, Хәбәшәдән [Эфиопия] килгән товарларны сәбәлеләр кәрваннарга төяп, Мисырга, Шамга илтә торган булганнар. Ә инде аннан төрле товарлар китереп, Һиндстанга һәм Хәбәшәгә җибәргәннәр. Бу чорларда Йәмән җирлеге халык белән тулы булып, шәһәрләре гаять бөек һәм бизәкле сарайлар, һәйкәлләр, оҗмахтагы кебек бакчалар белән тулы булган. Патша сарайларын урап алган гаять бөек диварлар ерактан ук беленеп торган. Бу дәүләтнең падишаһлары башта «Зү Сарвах» дип, соңыннан «Мәликү Сәбә» дип йөртелгәннәр. Сәбә падишаһларыннан Бәлкыйс Тәүратта һәм Коръәни Кәримдә искә алына (Коръәндә исеме белән искә алынмаган).

**Химьяр дәүләте**. Химьярлылар сәбәлеләрдән соң киләләр. Аларның дәүләте безнең эрага кадәр 115 елдан алып, безнең эраның 525 елына хәтле яшәп килә. Химьяр дәүләте алдагы ике дәүләткә караганда сугышчанрак була. Бу дәүләт падишаһларыннан иң мәшһүрләре Шүммәр Йәргыйш, Ифрикс Зөлкарнәйн һәм Әсгад Әбү Кәрб. Гарәп тарихчыларының сүзләренә караганда, Йәмәнгә яһүдият керткән зат шушы Әсгад санала. Химьярның иң соңгы патшасы булган Зүнәвас дәверендә Йәмән хәбәшәлеләр тарафыннан яулап алына һәм Химьяр дәүләте шуның белән

www.darul-kutub.com

юкка чыга. Гарәп тарихчылары әйтүе буенча, моңа сәбәп булып Зүнәвасның яһүдияткә карата артык кырыс булуы, насара динендәгеләрне кысуы тора.

Йәмән мәмләкәте хәбәшәлеләр кулында 72 ел булды[1]. Соңыннан Химьяр әкъялләреннән [рәисләреннән] Сәйф бине Зи Йәзән, кисра ярдәме белән Йәмәнне кайтаруга ирешге. Шул көннән Йәмән фарсыларның бер вилаяте булып калды. Сәйф бине Зи Йәзән унбиш ел дәверендә кисра тарафыннан җирле идарә башлыгы булып торды. Ул Йәмәндә калган хәбәшәлеләр тарафыннан үтерелгәч, кисра үз кешеләреннән берсен аның урынына куя. Аллаһы рәсүленең пәйгамбәрлеге вакытында Йәмән фарсылар кулы астында булып, Бәзан исемле бер вәли тарафыннан идарә ителә иде[2]. Мәшһүр «Фил» вакыйгасы да Йәмәндә хәбәшәлеләр хөкүмәте вакытындагы Әбраха исемле кеше идарә иткән чорда була. Ул вакытта Мәккә башлыгы Аллаһы илчесенең бабасы Габделмоталлиб иде. «Фил» вакыйгасы хакында Коръәни Кәримдә зекер ителә. Гарәпләр бу вакыйга булган елны фил елы дип йөртәләр. Хәбәшәлеләрдән соң Йәмән күп еллар фарсы идарәсендә булса да, үзләренә бик ерак булганга, аңа бик зур әһәмият бирмиләр иде. Шуңа күрә, һаман да, Икъял токымыннан булып, кайбер җирлекләрдә әмир дип исемләнгән түрәләр бар иде. Һиҗрәттән соң 6 елны Аллаһының илчесе падишаһларга хатлар язганда Йәмәндәге шушы әмирлекләрнең берничәсенә дә хат җибәргән иде.

Йәмәндә әйтелгән өч бөек хөкүмәттән кала да, вак-вак мөстәкыйль һәм буйсынган хөкүмәтләр булып, падишаһлары «Зү» яки «Кайл» титуллары белән аталганнар.

---

1 Ибне-л-Әсир,159 б., 1 т. – авт.

2 Ибне-л-Әсир,159 б., 1 т. – авт.

Йәмән гарәпләрендәге мәдәният тарихларда исемнәре мәшһүр булган сүриялеләр, мисырлылар һәм финикиялеләр мәдәниятеннән күпкә ким түгел иде. Йәмәнлеләр үзләренә махсус хәрефләр дә иҗат иткәннәр. Бу хәрефләрне «Мөснәд» дип атаганнар. Шулай ук махсус акчалар сугып, анда падишаһларның сурәтләрен нәкыш иткәннәр һәм акча сугылган шәһәрләрнең исемнәрен язганнар.

Йәмәннең иң мәшһүр шәһәрләре «Мәэраб» белән «Санга» иде. Мәэраб гүзәл бер шәһәр булып, төрле биналар белән тулы иде. Шулардан Сәлхин, Һәҗәр-Кашиб кебек мәрмәрдән төзелеп, түшәмнәре алтын белән йөгертелгән сарайлар бар иде.

Санга шәһәре хәзерге вакыткача сакланып килгән. Бу шәһәрдә гаять бөек һәм бизәкләнгән егермегә якын сарай бардыр. Шуларның иң мәшһүре – Гомдән сарае. Гомдән Госман хәзрәтләре заманына кадәр сакланып килде. Мәшһүр тарихчы Һәмадәний Гомдән сараен шәхсән үзе күргән. Аның әйтүенчә, бу сарай егерме каттан торган. Әлбәттә, Һәмадәнийнең сүзләрен Арну, Һәлифий һәм Гыйләзу кебек галимнәр дөресләмәгән булсалар, бер хорафат кебек кенә каралыр иде.

Йәмәнлеләрнең мәдәнияттә алга киткәнлекләренә мәшһүр буа-диварлар бер дәлил булып тора. Йәмәндә йөзләрчә буа билгеле, әмма аларның иң мәшһүрләре – Мәэраб буасы. Йәмәндә елгалар булмаганлыктан, йәмәнлеләр шушы буалар белән яңгыр суларын бер җиргә җыялар иде. Һәм бу җайланмалар шәһәр һәм авыл кешеләрен ташудан саклау вазыйфасын да үтиләр.

Гассан гарәпләренең Кахтан балаларыннан булып, «сәйлүл-гарим» вакыйгасыннан соң Йәмәннән күченеп

www.darulkutub.com

китүләре турында алдагы бүлекләрдә язылган иде. Болар Йәмәннән күченеп киткәч, иң элек Гассан (Тиһамә җирендә) исемле суга якын урнашалар. Шуңа күрә алар «Гассасинә» яки «Ибне Гассан» дип йөртелгәннәр. Соңрак алар Шам сахраларына барып, андагы Даҗәгыймә гарәпләрен җиңеп, җирләреннән куып чыгарып, үзләре шунда төпләнеп калалар. Нәтиҗәдә, көч һәм куәт җыеп, Хоран һәм Бәлка җирләрендә бер дәүләт төзиләр. Бу дәүләт тарихта «Гассасинә дәүләте» дип мәшһүрдер. Хоранның башкаласы Бусра[1] шәһәре иде. Гассасинә дәүләте рәсми рәвештә румлыларга буйсынып, хөкемдарлары да алар белән килешеп гамәл кылалар иде. Бу дәүләт өченче гасырның беренче яртысында барлыкка килеп, яшәвен Ислам тарала башланганчыга хәтле дәвам итә. Бу дәүләтнең иң беренче хөкемдары кем икәнлегендә төрле фикерләр булса да, ахыргы хөкемдарның Җәбәлә бине әл-Әйһәм исемле икәнлегендә тарих галимнәре арасында каршылыклы фикерләр юктыр. Гассәсинә дәүләтенең иң мәшһүр башлыгы сан буенча бишенче булган Харис бине Җәбәлә белән улы Мүнзир Әбү Кәрбтер. Харис бине Җәбәлә вакытында Гассан хөкүмәте шактый гына зурайды. Аның вакытында Хоран, Бәлка, Тәдмур, Әзрух һәм бөтен Шам җире аларның кул астында иде. Һәм бөтен Фәлистин, Сүрия, Лүбнән гарәпләренә баш булып торалар иде. Харис бине Җәбәлә Рум императорларыннан Юстинианус заманында фарсылар белән булган сугышта зур ярдәм күрсәтте. Мәшһүр гаскәр башлыгы Близариусның фарсыларга каршы сугышында иң зур ярдәмчесе шушы Харис иде. Харис 40 ел дәверендә идарә иткән чорда дәими рәвештә сугышларда

1 Бусра шәһәренең хәрабәләре хәзерге көндә дә “иске Шәм” дип билгеле. Мәшһүр манах Бәхираның монастыре шушы Бусра кырыенда иде. – авт.

булып, зур шөһрәт казанган иде. Хәтта рум хатыннары үзләренең балаларын Харис исеме белән куркыталар иде. Фарсыларга каршы көрәшкәне өчен Рум императорлары аңа «Басилиус» дигән, соңыннан «Бәтрикъ» дигән кушамат бирде. Харис 563 елда Константинопольга баргач, аны Рум императорлары гадәттән тыш ихтирам белән каршы ала. Харис бине Җәбәлә Хира падишаһларыннан Мүнзир бине Мәис-сәмәгә замандаш иде. Аның белән булган «Зәтү Хыяр» дип аталган сугышта Харис Мүнзирне җиңеп, аны үтерттерә.

Харис бине Әбү Шәмрдан соң идарә иткән Мүнзир Әбү Кәрб румлыларга гаять зур хезмәт күрсәтә. Ул атасы заманында рум гаскәрендә зур урын алып торган. Хөкемдар булып идарә иткән вакытында да шөһрәткә ирешкән иде. Мүнзир милади буенча 580 елда Константинопольгә барганда, румлыларның гаять зур хөрмәт күрсәтүе аның дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Хәтта император Тибариус аңа таҗ кидерә. Ә бу вакытка кадәр Гассан хөкемдарларының таҗ кигән очраклары булмады.

Гассанлылар Рум кулы астында, ә Хира падишаһлары фарсылар кулы астында булганга, бу ике дәүләт арасында еш кына сугышлар булып тора иде. Шушы сугышлардан иң зурлары «Зәтү хыяр» белән «Мәраҗү Хәлимә» дип аталганнарыдыр. Мәраҗү Хәлимә сугышы Мүнзир бине Мәис-сәмә белән Харис Әгъраҗ арасында булды һәм нәтиҗәдә Харис Мүнзирне җиңде. Бу сугышта Мөнзир тарафында бөтен Гыйрак һәм аның янында булган гарәпләр катнашты, ә Харис тарафында бөтен Шам гарәпләре катнашты.

**Хира дәүләте**. Хира дәүләте Йәмәннән күченеп килгән Ләхм гарәпләре тарафыннан III гасыр урталарында

төзелеп, Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә хәтле сакланып килде. Бу дәүләтнең башкаласы Хира шәһәре иде. Һәм Хира дәүләте рәсми рәвештә фарсыларга буйсына иде. Бу дәүләттә егермедән артык падишаһ булганлыгы билгеле. Шуларның иң беренчесе – Мәлик бине Фәһмдер. Аннан соң иң зур хөкемдар – гарәпләр арасында мәшһүр булган Җәзимә әл-Әбраш. Җәзимәдән соң кыз кардәшенең улы Гадә бине Нәср килә. Моннан соң килгән хөкемдарларның күбесе шушы Гадә нәселеннән саналалар. Шуның өчен дә Хира хөкүмәте «ән-Нәср хөкүмәте» дип тә йөртелгән. Хира хөкемдарларның иң мәшһүрләре: Ногман бине Имре-л-Кайс, Мүнзир бине Ногман бине Имре-л-Кайс, Әсвәд бине Мүнзир, Мүнзир бине Имри әл-Кайс бине Мәис-сәмә, Гамр бине Һинд (Һинд, Гамр анасының исеме, атасыныкы Мүнзир), Ногман бине Мүнзир Әбү Кабус. Ногман бине Имре-л-Кайс кисралардан Йәздәҗрад һәм Баһрам Җәур белән замандаш булып, 28 ел идарә итте. Берничә мәртәбә Шамга барып дошманнары булган гассанлыларга зур бәла-каза китерде, күп кенә ганимәтләр һәм әсирләр алып кайтты. Ногман Хира падишаһларыннан һичкем ия булмаган мал-мөлкәткә ия булды. Мәшһүр Хәварнак һәм Сәдир сарайларын төзеткән зат шушыдыр[1].

Мүнзир бине Ногман 44 ел идарә иткән дәвердә румлылар һәм гассанлылар белән сугышып, аларны җиңүгә иреште.

Мүнзир бине Имре-л-Кайс бине Мәис-сәмә 49 ел идарә итеп, кисралардан Кобәз белән Анушырванга замандаш иде. Рум императорларыннан Юстинианускa, гассанлылардан Харис бине Җәбәлә бине Әби Шәмргә замандаш иде. Харис белән булган «Зәте-л-Хыяр» сугышында үтерелде. Мүнзир бине Имре-

1 “Әбе-л-Фидә”, 70 б., 1 т. – авт.

л-Кайсның сәер бер ягы бар иде: шатлыклы көне булса, кемне генә булса да хөрмәт итә иде, ә менә кайгылы көне булса, туры килгән кешене үтерә иде. Шулай, мәшһүр шагыйрь Гобәйд бине әл-Әбрас моның кайгылы көненә туры килеп үтерелде.

Гамр бине Һинд Хира хөкемдарларыннан иң куәтлесе һәм иң абруйлысы иде. Ул үзен гадәттән тыш горур тота һәм ифрат дәрәҗәдә тәкәббер бер адәм иде. Шушы тәкәбберлеге һәм горурлыгы аны үзенең үлеменә дә китереп җиткерде[1].

Ногман бине Мүнзир Әбү Кабус, Һәрмус IV һәм Пәрвиз белән замандашлар иде. Ногман идарә иткән чорда Хира дәүләте гаять бай булып, купшылык һәм исраф итүләр арткан иде. Әүвәлрәк кисралар балаларын тәрбиягә Хира гарәпләренә биргәннәр һәм Хира падишаһлары да үз балаларын алар кебек башкаларга бирәләр иде.

Бервакыт кисраның Ногманга ачуы килеп, аны Мәдинәгә чакыртып, төрмәгә ябып куя. Мәшһүр «Зи Карр» сугышына шушы вакыйга сәбәпче була. Мәшһүр шагыйрь Нәбига әз-Зубьян Ногманның хәдимнәреннән иде. Ногман белән Нәбига арасында булган маҗаралар мәшһүр булганга, алар кабат сөйләнмәс.

Ногман Әбү Кабус Гахм гаиләсеннән иң соңгы хөкемдардыр. Аннан соң кисралар Хирага идарә итүчене турыдан-туры билгели торган булдылар. Ислам пәйда булгач, Хира гарәп хөкүмәте буларак искә алынмады, бәлки Иран дәүләтенең бер вилаяте булып санала иде[2]. Хира дәүләте бөтен Гыйрак җирлегендә хөкем сөргән кебек,

---

1 Гамр бине Һиндне Гамр бине Күлсүм үтерә. – авт.

2 "Хуләсату тәрихе-л-Исләм лил-Галәм", 29-30 б. Гарәп тарихчылары Хирада иң соңгы хөкемдар Әбү Кайсның улы Мүнзир әл-Мәгъръур(628-633)дип никадәр әйтсәләр дә, аның Хира хөкемдары дәрәҗәсендә булуы дөрес түгел. Әбү Кабустан соң Наср гаиләсенең кисралар алдында ышанычлыгы бетеп, кисралар башка гаиләдән вәлиләр билгели торган булдылар. Мүнзир әл-Мәгъръур кисра тарафыннан вәли буларак билгеләнелсә дә, ата-бабалары кебек падишаһ дәрәҗәсенә күтәрелмәде. Аллаһы илчесе галәйһиссәламнең Хира хөкемдарларына хат язмавы, моңа дәлил булып торадыр. – авт.

башка бәдәви гарәпләрендә дә хөкеме үтәлә иде. Бөтен Гарәп ярымутравындагы булган гарәп кабиләләре алардан куркалар һәм аларны олылыйлар һәм аларның кул астына алынырга тырышалар иде. Хира падишаһлары әдәбиятка бик тартылучан иделәр. Аларның мәҗлесләре һәрвакытта төрле шагыйрьләр белән тулы иде. Нәбига, әз-Зүбьяни, Мүнәххәл, Хәссән бине Сәбит, Мүтәләммис кебек бөек шагыйрьләр һәрвакыт боларның мәҗлесләрендә булып, ихтирам күрәләр һәм төрле бүләкләр алалар иде. Шуңа күрә дә гарәп әдәбиятында Хира падишаһлары турында искә алулар күп.

**Киндә дәүләте**. Киндә гарәпләре Кахтан нәселеннән булып, Химьяр дәүләтенең кул астында иделәр. Химьяр падишаһлары Киндә башлыкларын үз хезмәтләренә тоталар һәм аларга мөһим йомышларны да йөклиләр иде. Химьяр падишаһларыннан Хәссән бине Түббәгъ Гарәп ярымутравындагы гарәпләргә каршы яудан кайткач, Киндә башлыгын һәм аның бертуган кардәшен Хуҗр бине Гамрны Мәгад гарәпләренә баш итеп куйган иде. Соңыннан Хуҗрның Нәҗдкә урнашуы шул тарафларга буйсындыру нияте белән килгән Хира падишаһлары белән сугышып, кайбер Нәҗд кабиләләрен аларның яулап алуларыннан коткарды. Хуҗрдән соң хөкүмәт башлыгы аның улы Гамр бине Хуҗр, аннан соң Харис бине Гамр иде. Йәмәннең хәбәшиләр тарафыннан алынуы моның заманында булды. Харис кисра Куббәзнең Мүнзир бине Мәис-сәмәгә ачулануыннан файдаланып, Куббәзгә якынлашты һәм аның тарафыннан Хирага вәли итеп билгеләнелде. Моннан соң Хариснең шөһрәте бөтен гарәп кабиләләре арасында таралды һәм аларга карата йогынтысы да артты. Һәр тарафтан гарәп кабиләләре аны



www.darul-kutub.com

тәбрикләргә килделәр. Һәм үзләреннән соң улларын әмир итеп билгеләүне үтенделәр.

Шулай итеп, Харис үз якыннары арасыннан Хожрне Әсәд һәм Гатафан кабиләләренә, Шурахбилне Бәкр бине Вәил кабиләләренә, Мәгъди Кәрибне Кайс Гайлән һәм боларга күрше булган кабиләләргә, Сәләмәне Нимр бине Касыйт һәм Тәгълиб кабиләләренә әмир итеп билгеләп куйды. Куббәз вафат булганнан соң тәхеткә Әбүширван Гаҗм утыргач, Мүнзир бине Мәис-сәмәне яңадан үз урынына кайтарды. Ә Харис гаиләсе һәм маллары белән качарга мәҗбүр булды. Мүнзир Харис артыннан кудыртып, малларын тартып алуга иреште. Харис, үз чиратында, качып котылса да, Бәнү Киләб җирендә үтерелде. Харистан соң калган уллары Шүрәхбил һәм Сәләмә, Мүнзир котыртуы сәбәпле, үзара сугышып, милекләреннән коры калды. Хуҗр исә, үзенең кирелеге аркасында, халкы тарафыннан үтерелде. Мәгъди Кәриб кенә берникадәр хөкем сөрә алды. Ислам килгән вакытта, Киндә дәүләте бөтенләй таралып беткән иде диярлек. Ул төрле җирләрдә, вак аерым әмирлекләргә бүленеп беткән иде. Алардан мәгълүмнәре: Дәүмә әл-Җәндәл, Нәҗран, Гамр Зү Киндә әмирлекләре иде. Болар һәркайсы мөстәкыйль иде. Ислам килгәч, болар берәр-берәм Ислам дәүләте астына кереп беттеләр.

Гарәбстанда булган хөкүмәтләр шушылардан гыйбарәт. Болардан фәкать Киндә хөкүмәт билгеләмәсенә тулы мәгънәдә туры килмидер. Киндә хөкүмәт булса да, анда һичбер төзелеш һәм мәдәният әсәре юктыр. Хөкемдарларының да башка гарәп башлыкларыннан аермасы исемнәрендә генә.

Әйтелгәннәрдән кала, гарәп кабиләләре башка күчмә

кавемнәр кебек башлыклар белән идарә ителәләр иде. Араларында кыюлыклары һәм күркәм холыклары белән шөһрәт казанган затлар болар белән идарә итәләр иде. Гарәпләр шул башлыкларның сүзләреннән чыкмый иделәр, аларның кул астында сугышалар, араларындагы булган низагларны алардан хөкем иттерәләр иде. Гарәбстанның иң мәшһүр һәм иң хөрмәтле кабиләләреннән булган Корәеш кабиләсе белән дә шундый башлыклар җитәкчелек итә иде. Корәеш башлыкларыннан иң мәшһүре – Кусай бине Киләб.

Кусай акыллы, тугры фикерле, тапкыр бер зат иде. Ул үзенең тапкырлыгы һәм сәләтле булуы белән бу вакытка кадәр Хузәга гарәпләрендә булган Кәгъбәтуллаһ белән хуҗалык итүне үз кул астына алды. Моннан соң Кусайның Корәеш арасында абруе тагын да күтәрелде. Аның фикерен дәрәҗәле санап, һәр эштә аннан киңәш сорый башладылар. Кусай Мәккә тирәсендә булган Корәешләрне Мәккәгә урнаштыруда тырышлык күрсәтте, аларга җирләр бүлеп бирде. Бу юл Корәеш кабиләсен мәдәнияткә якынайтты. Кәгъбәтуллаһны зиярат итәргә килгән фәкыйрь хаҗиларны ашату һәм эчертү өчен ул Корәешкә күпмедер салым билгеләде. Шуның өчен дә аның башка гарәп кабиләләре арасында абруе күтәрелде. Корәеш гарәпләре мөһим эштә киңәшләшкәндә, Кусай өендә җыелалар иде. Һәм сугыш әләмен дә Кусай гына тегә иде.

Кусайдан соң Корәеш сәидләреннән иң мәшһүре – Габделмоталлиб бине Һашимдер. Габделмоталлиб Мәккәдә алтмыш ел башлык булды. Мәшһүр «Фил» вакыйгасы да Габделмоталлиб заманында булып, аның гарәп арасында дәрәҗәсен арттырды. Йәмән хөкүмәтендә Сәйф бине Зи Йәзин хәбәшәлеләрдән Йәмәнне кайтаргач, тәбрикләү белән барган делегациядә Габделмоталлиб та бар иде.

www.darul-kutub.com

Габделмоталлибнең ун улы һәм алты кызы бар иде. Тәржемәи хәлен язмакчы булган улларының берсе – Мөхәммәд галәйһиссәламнең атасы – Габдуллаһтыр. Корәеш бөек бер кабилә булып, рәсүлуллаһ (салләллаһу галәйһи вәссәлам) килгәндә унике нәселдән гыйбарәт иде:

1. Ибне Габде Мәннәф;
2. Ибне Габде-д-Дәръ;
3. Ибне Әсәд бине Габде-л-Гоззә;
4. Ибне Зуһра бине Киләб;
5. Ибне Мәхзум бине Якъза бине Мурра;
6. Ибне Тәмим бине Мурра;
7. Ибне Гади бине Кәгъб;
8. Ибне Сәһм бине Гәмру;
9. Ибне Гамр бине Лүэйә;
10. Ибне Харис бине Фәһр;
11. Ибне Мүхәриб бине Фәһр;
12. Ибне Җәмх бине Гамр – Гамр улы Җәмхнең балалары.

Зекер ителгән нәселләрдән Мәккә эчендә торганнарын *«Корәеше-л-бәттах»*, Мәккә тирәсендә торганнарын *«Корәеше-з-завәһир»* дип йөрткәннәр.

## Әдәбият

Гарәпләр җаһили милләтләр арасында әдәбият буенча иң бай милләтләрдән иде. Аларның әдәбиятларының байлыгына беренче сәбәп – телләренең байлыгыдыр. Гарәп теленең байлыгы турында әллә никадәр сөйләп торырга хаҗәт юктыр. Әйтик, гарәп телендә бер нәрсәгә әллә никадәр исемнәрнең булуы – телнең байлыгына иң беренче дәлилдер.



www.darulkutub.com

Гарәп телендә унар, егермешәр, утызар исемле нәрсәләр күп булганы кебек, йөзәр исемгә лаек булган нәрсәләр дә байтак. Синонимнарның һәр телдә булуы мәгълүм. Әмма гарәп теле бу яктан бөтен телдән өстен тора.

Җаһилият гасырында гарәп әдәбияты язылмаган иде. Чөнки гарәпләр надан бер кавем булып, укый, яза белми иделәр. Аларда укый-яза белгән кешеләр булса да, бармак белән генә санарлык, бик аз иделәр. Гарәп әдәбияты, авыздан-авызга күчеп килгән шигырьләрдән, мәкальләрдән һәм нотыклардан гыйбарәттер.

**Мәкальләр.** Мәсәлләр[1] гарәп әдәбиятында мөһим бер урын тәшкил итәләр. Гарәпләрнең үз нотыкларына, шигырьләренә хикмәтле хикәяләр катыштырып сөйләүләре, аларга аерым бер матурлык өстидер. Аларның хөтбә һәм шигырьләре мәкальләрдән тыш булмаган кебек, гел мәсәлдән тәркиб кылынган касыйдәләре дә бардыр. Һәр кавемдә мәсәлләр кулланылса да, гарәпләр бу очракта башкаларга караганда өстенрәк торалар. Аларда башка кавемнәрдән килгән хикмәтле мәкальләр булган кебек, үзләренең махсус вакыйгаларына нигезләнгән мәкальләр дә бик күп.

Гарәпләрдә мәкальләр ике төрле: 1) «әл-Җәр кабләд-дәр» [йортыңа хәтле күршеңне сайла], «әл-Хата зәде-л-Гаҗел» [хаталык – ашыгуның нәтиҗәсе], «әл-Гыйтаб кабләл-гыйкаб» [шелтә – җәза алдыннан], «әл-Хәрбү хыйдга» [сугыш – ул үзе алдау] кебек хикмәтле мәкальләрнең кайсылары бөтен кавемнәр арасында уртак булып, берсеннән икенчесенә күчкәннәредер. 2) Монысы гарәпләрнең үз араларында булган кайбер вакыйгаларга нигезләнгән мәкальләрдер. Бу мәкальләр гарәпләрнең үзләренә генә хас. Мәсәлән, «раҗәга

1 Мәсәл-хикмәтле хикәяләр – тәрҗ.

би-хуффәй Хунәйн», «әс-сайфү дайгу-л-ләбән», «бәлага әс-сәйлү-з-зүбә» кебек мәкальләр, ягъни ниндидер бер вакыйгага бәйле булган мәкальләр җаһилият вакытындагы гарәпләрнең сүзләрендә һәм шигырьләрендә бик күп. Ислам дине таралып, гарәпләр мәдәният юлына кергәч, гыйлем һәм белемнәрен яза башладылар. Шул вакытта мәкальләрне махсус китапларга яздылар. Мәшһүр китаплардан күбесе югалса да, хәзерге вакытка кадәр сакланганнары да бардыр. Хәзерге көндә мәсәлләр китабыннан иң мөһим һәм иң мәшһүрләре – «әл-Мүстәкъса ли-з-Зәмәхшәрий» белән «Мәҗмәгы-л-әмсәл лил-Мәйдәний» китаплары. «Әл-Мүстәкъса»ның оригинал китабы сакланмаган, әмма күчерелмәләре Мисыр, Истанбул һәм Аурупа китапханәләрендә бардыр. «Мәҗмәгы-л-әмсәл» китабы берничә мәртәбә бастырылды.

**Хотабәт [сөйләү]**. Гарәпләр үзләренең нәселләре белән мактана һәм горурлана, бер-берсе белән һәрвакыт низаглашып һәм сугышып тора торган бер кавем булганлыктан, аларда хотабәт бик таралган һәм араларында ут чәчә торган оста сөйләүчеләр булган. Мәзкүр сүз осталары үзләренең нәселләре белән мактаналар, башка кабиләләр арасында үзләренең дәрәҗәләрен, намусларын саклыйлар һәм яклыйлар. Сугышлар вакытында үзләренә аерым төркемнәр җыя иделәр. Шуның өчен дә гарәпләр арасында хатибларның [сүз осталарының] кадере гаять зур була. Алар балаларын яшьтән үк хатиблыкка өйрәтәләр. Гарәпләрдә һәр кабиләнең махсус бер яки берничә хатиблары була иде.

Гарәп хатиблары үз араларында булган масаеп мактанышуларда, низаг һәм бәхәсләрдә, сугыш вакытларында бик зур роль уйнаган кебек, башка өлкәләрдә дә, мәсәлән, чит ил падишаһларына, Хира, Гассан хөкемдарларына, Йәмән

дәүләтенә делегация булып та баралар иде. Йәмән дәүләтендә Сәйф бине Зи Йәзин Йәмән хөкүмәтен хәбәшәлеләрдән кайтаргач, тәбрикләү өчен Корәеш гарәпләренең баруы мәгълүмдер. Әйткәнебезчә, бу делегация эчендә Габделмоталлиб та бар иде.

Кисра Әнушәрванның тәхеткә менүе белән Әксәм бине Сайфи, Хәҗиб бине Зурара, Харис бине Залим, Кайс бине Мәсгуд һәм башка берничә гарәп хатибларының кисра янына барып, аның алдында чыгыш ясаганнары әдәби китаплардан мәгълүмдер.

Гарәп хатиблары хотбә сөйләгәндә башларына чалма кияләр, кулларына кечкенә таяк тоталар, җиргә җәя белән таяналар, сүз арасында урыны белән таякларын селкиләр. Хатиблар хөтбәләрен гадәттә аягүрә, кайбер вакытта дөя өстендә дә сөйлиләр.

*Мәшһүр хатиблар.* Җаһилият вакытындагы хатибларның иң мәшһүрләре: Кусса бине Сәгидә әл-Әйәди, Сәхбән Вәил әл-Бәһили, Зүһәйр бине Җәнәп, Мәрсәдү әл-Хайр, Үксүм бине Сайфи, Зүләсбәгъ  әл-Гадвәни һәм Гамр бине Күлсүм. Болардан башка да хатиблар күп. Санап кителгән хатиблардан иң мәшһүре – Кусса бине Сәгидә. Аның Гокәз базарында, дөя өстендә хөтбә сөйләгән чагында, пәйгамбәрлеккә хәтле Аллаһының илчесе шунда булуы турында югарыда әйтелгән иде. Сәхбән Вәил дә иң бөек хатиблардан булып, сүзгә осталыгы үрнәк итеп куела иде. Сәхбән хөтбә сөйләргә керешсә, тирләп бетә, әйткән сүзен кире кайтармыйча, сүзе беткәнче бер туктамый сөйли иде. Сәхбән Ислам динен кабул итеп, һиҗри белән 54 елда вафат булды. Зүләсбәгъ белән Үксүм бине Сайфи да бөек хатиблардан иде. Алар хатиб булулары өстенә философ та иделәр. Гамр бине

www.darul-kutub.com

Күлсүм хатиб булуы өстенә бөек шагыйрь дә иде. Аларның бик күп хөтбәләре «әл-Бәян вә-т-тәбәййүн», «әл-Гакд әл-фәрид», «әл-Әгани» кебек әдәбият китапларында язылган.

**Шигырь.** Шигырь гарәп әдәбиятының иң мөһим өлешен тәшкил итә. Алар бу өлкәдә бик алга китәләр. Телләренең байлыгы, метафора һәм кинаянең күплеге шигъриятләренә бик зур ярдәм бирә. Гарәпләрдә шагыйрьләр шул кадәр күп иде ки, бу өлкәдә алар бөтен милләтләргә караганда да өстенрәк иде. Гарәпләр Исламга хәтле булган чорда, башка кавемнәрдә берничә гасырда сөйләнмәгән шигырьләрне сөйлиләр иде. Юнән [грек] шигырьләренең күпчелеген тәшкил иткән Һүмирус [Гомер]ның «Илияда» һәм «Одиссия»се 30 000 бәеттән артык түгел. Һиндларның «Мһабһәрата» – 20 000, ә «Рамәйәнә» 48 000 бәеттер. Хәлбүки, җаһилият[1] чорындагы гарәпләрнең шигырьләре болар белән чагыштырып булмаслык дәрәҗәдә күп. Гарәп шигырьләре бәет белән түгел, ә касыйдә белән санала. «Әл-Хәмәсә» исемле шигырь җыентыгы сахибе Әбү Тәммәмнең җаһилият шигырьләре 14 000 урҗүзә, «Хәммәде-р-Ривәя»нең 27 000 касыйдә, «Исмәгый»нең 16 000 урҗүзә, Әбү Дамдамның Гамру исемендә генә йөз шагыйрьнең шигырьләрен ятлаганы риваять ителәдер. Монда күпмедер арттыру булса булыр, шулай да бу җаһилият чоры гарәпләре шигырьләренең гадәттән тыш күплеген күрсәтәдер[2].

Җаһилият гарәпләренең шигырьләре күбрәк горурлык, батырлык, яшьлекне сагыну, мактау яки кемнәндер көлү турында иде. Алар үз кабиләләрен, шәех вә рәисләрен, баһадирларын мактыйлар, үзләренең нәселләре, ата-ба-

1 Гарәпләрдә җаһилият чоры якынча 150 ел тәшкил итә. – авт.

2 “Әдәбе-л-луга әл-гарәбия” Җурҗи Зәйдән, 72 б., 10 т. – авт.

балары кылган эшләрен горурланып язалар, үзләренең кыюлыклары турында сөйлиләр, дошманнарын хурлыйлар, хатын-кызларының яхшылыкларын, матурлыкларын тасвирлап язалар иде. Бары тик сагыну темасы гына җаһилият гарәпләрендә бик аз иде. Җаһилият шагыйрьләрдә мәрсияләре, мәдхияләре үз кабиләләренә, үз якыннарына махсус була иде. Алар арасында Ислам һәм Ватан турында язучы шагыйрьләр кебек бүләкләр алу өчен чыгыш ясаучы мактаулы шагыйрьләр бик аз иде. Әлбәттә, Әгъшә, Нәбига әз-Зубьяни, Мүнәххәл әл-Бәшкүра, Хүтайә кебек шигырьне сатучы кешеләр дә юк түгел иде.

Гарәпләрдә шагыйрьнең кадере гадәттән тыш зур иде. Чөнки шагыйрь аларның намусын яклый, аларның башка кабиләләр арасында дәрәҗәсен һәм абруен саклый, шөһрәтләрен арттыра иде. Гомумән, шагыйрь кабиләнең тел дәрәҗәсен күрсәтүче иде. Шуның өчен дә гарәпләр шагыйрьләрен ихтирам итәләр иде. Үз араларында берәр шагыйрь килеп чыкса, мәҗлесләр ясап шатланышалар, икенче кабиләләр килеп, аны тәбрик итәләр иде.

Гарәпләр табигатьләре буенча хис һәм тойгыларга бирелүчән бер кавем булганга, аларга шигырь гадәттән тыш нык тәэсир итә иде. Бөек шагыйрьләр берәр кабиләне яки берәр кешене мактап шигырь сөйләсәләр, ул кабилә яки шул кеше күтәрелә, әгәр яманлап язса, дәрәҗәләре төшә иде. Шуның өчен гарәпләр мөмкин кадәр шагыйрьләрнең һөҗүменә эләкмәскә тырышалар, киресенчә, төрле юллар белән алардан үзләрен мактатырга тырышалар иде. Гарәпләргә иң нык тәэсир иткән шигырьләр Әгъшә, Нәбига, Имре-л-Кайс һәм Зүһәйр шигырьләре иде. Мәсәлән, Әгъша Гокәз базарына барырга юлга чыкса, үзләрен аңардан макта-

ту, ә бигрәк тә аның тәнкыйтеннән котылу өчен юлда туры килгән кабиләләр аны алып килеп, дөя суеп хөрмәт итәләр иде. Әгъшаның Мүхәлләкъ исемле бер фәкыйрьне Гокәз базарында мактап бер касыйдә әйтүе белән Мүхәлләкъның кияүгә чыга алмый яткан сигез кызының бер ел эчендә кияүгә чыгып бетүләре, шигырьнең гарәпләргә ни дәрәҗә тәэсир итүен ачык күрсәтә. Тагы гарәпләрнең шигырьгә ни дәрәҗәдә әһәмият бирүләренә кайбер гүзәл касыйдәләрне алтын су белән язып, Кәгъбәтуллаһка элеп куюы иң зур дәлилдер. Кәгъбәтуллаһка эленгән касыйдәләр җиде булып, аларның ияләре Имре-л-Кайс, Зүһәйр бине Әбү Сүлмә, Тарафә бине әл-Габди, Ләбид, Гантара, Гамр бине Күлсүм, Харис бине Хилзә[1]. Шушы касыйдәләр Кәгъбәтуллаһка куелганлыклары өчен «могаллләкать» дип, алтын белән язылганлыклары өчен «мүзәһһәбәт» дип йөртеләләр. Җаһилият шагыйрьләренең иң алдынгылары мугалләкать сахибләре булып, болар эчендә иң бөекләре – Имре-л-Кайс, ән-Нәбига әз-Зүбьяни һәм Зүһәйр бине Әбү Сүлмә.

Имре-л-Кайс гарәп шагыйрьләренең имамы иде. Аның шигырьләре оста теллелектә үрнәк булып тора. Аллегория һәм метафорада Имре-л-Кайсның бик күп сахибе бар иде. Ул күбрәк атын һәм дөясен тасфирлау, хатын-кызларның яхшы һәм гүзәл якларын сыйфатлау белән аерылып тора. Аның халык телендә мәсәлләр урынына йөртелгән шигырьләре дә аз түгел. Аның иң гүзәл касыйдәсе «Кыйфә нәбки мин зикра хәбибин вә мәнзили» белән башланган икеюллык могалләкасыдыр. Имре-л-Кайс ирекле бер зат булып,

1 Бу Зүзни фикередер. Ибне Халдун фикере буенча, Харис белән Ибне Күлсүм бу төркемгә кертелми, алар урынына ән-Нәбига әз-Зүбьяни белән Әгъшәне куя. "Җәмһара" сахибе Әбү Зәйд исә, Нәбига белән Әгъшәне кертеп, Харис бине Хилзәне дә өсти. Нәтиҗәдә могалләка сахибләрен сигез саныйдыр. – авт.



www.darul-kutub.com

беркемнән курыкмый иде. Шуның өчен шигырендә кызарта торган урыннары да юк түгел. Имре-л-Кайс 560 елларда вафат була.

Ән-Нәбига әз-Зүбьяни дә Имре-л-Кайс дәрәҗәсендә иде. Хәтта кайбер кешеләр аны Имре-л-Кайстан да өстенрәк күрәләр. Нәбиганың шигырьләре күбрәк мактаудан гыйбарәт. Ул Хира хөкемдары Ногман бине Мүнзирның якыннарыннан иде. Нәбига аны мактап, бик күп байлык җыеп, алтын һәм көмеш савыт-сабалардан гына ашый торган булды. Ул үз заманы шагыйрьләре арасында иң хөрмәтлесе иде. Мәсәлән, Гокәзга барса, аңа чатыр корып бирәләр, шунда аны хәким [судья] кылып, шагыйрьләр уздырыштан шигырьләрен сөйлиләр иде. Мондый дәрәҗә җаһилият шагыйрьләре арасында башка һичкемгә насыйп булмады. Чыннан да, Нәбига бөек шагыйрь иде. Әгәр ул падишаһларны мактап шигырьләре белән кәсеп итмәгән булса, аны, әлбәттә, шагыйрьләрнең шагыйре дип атап булыр иде. Нәбиганың мәшһүр касыйдәләре Ногманның хатыны Мүтәҗәрридәне тасвирлап язган «гавәҗәү ...» бәете белән башланган могалләкасыдыр.

Зүһәйр бине Әбү Сүлмә шагыйрь булуыннан да күбрәк философ иде. Аны башка шагыйрьләрдән өстен күреп, Нәбигалар дәрәҗәсенә күтәрүләренең сәбәбе дә шушы фәлсәфи сүзенә сокланудан. Ә алда әйтелгән ике шагыйрь белән чагыштырганда, әлбәттә, шагыйрьлеге түбәнрәк иде. Зүһәйр үзе олуг, диндар һәм йомшак бер зат иде. Аның күп шигыре Һәрим бине Синәнне мактап язылган. Иң мәшһүр касыйдәсе мугалләкасыдыр. Зүһәйр бер Аллаһыка һәм үлгәннән соң терелүгә иман китергән кеше иде. Әмма Исламият килгәнче вафат булды.

Әгъшәнең дә гүзәл һәм озын касыйдәләре күп. Аның



www.darul-kutub.com

шигырьләре халыкка бик нык тәэсир итә. Бер касыйдә белән Мүхәлләкъның кызларын кияүгә чыгарып бетерүе алда әйтелгән иде. Ул үз вакытында бүләк алу нияте белән Аллаһының рәсүлен мактап, бер касыйдә чыгарган иде. Әмма моны Әбү Софьян белгәч, Исламга килүеннән куркып, йөз дөя биреп, Әгъшәне кире кайтарып җибәргән иде. Әгъшәнең иң мәшһүр касыйдәсе

« مَا بُكَاءُ الكَبِيرِ بِالْأَطْلَالِ ، وَسُؤَالِي ، فَهَلْ تَرُدُّ سُؤَالِي»

дигән бәете белән башланган могалләкасыдыр.

Ләбид Фәрис абруйлы һәм юмарт бер зат булып, озын гомер яшәгән. Исламият килгәч, Исламны кабул итте. Һәм кайбер риваятьләр буенча, зөһедлеккә бирелеп, шигырь сөйләвен ташлаган диләр.

Шулай ук башка могалләка әһелләреннән әл-Мүһәлһил бине Рабига, Үмәййә бине Әбү әс-Салт, Хәтим әт-Таий, Зәйде-л-Хайл, Галкамә әл-Фәхл, Куссу бине Сәгыйдә, Вәрака бине Нәүфәл, әш-Шәнфәра, Тә’әббәта Шәрран, Горвә әл-Вәрд, Сәмәүәл бине Гадийәә, Хәссән бине Сәбит, әл-Хансә, әл-Хотыйә, Габдулла бине әз-Зәбәгъра, ән-Нәбига әл-Җәгъдий, Әус бине Хожр, әл-Мүтәләммис, әл-Мөнәххаль әл-Яшькәви, Кәгъб бине Зүһәйрдер.

Гарәпләрнең бөтенесе хатиб һәм шагыйрь дип әйтсәк тә, арттыру булмастыр. Гарәп әдәбиятының иң алга киткән чоры Ислам килер алдыннан иде. Югарыда әйтелгән хатиблар һәм шагыйрьләр дә Исламга хәтле ярты гасыр дәверендә булган кешеләрдер. Аллаһы илчесенең пәйгамбәрлегенә дәлил буларак, башка пәйгамбәрләргә җибәрелгән могҗизалар кебек билгеле бер вакытта гына

www.darul-kutub.com

булмыйча, гарәпләрдә матур сөйләм биек ноктада булган чорда Коръән Кәримне җибәрү олуг бер могҗизадыр.

## Гарәпләрдә гыйлем һәм мәгърифәт

Җаһилият вакытында гарәпләрдә хәзерге мәгънәне аңлаткан фән һәм мәгърифәт юк иде. Шулай да үз заманына күрә кайбер гыйлемнәр һәм мәгърифәт була. Мәсәлән, гарәпләр инсәп гыйлемен бик яхшы беләләр иде. Алар үзләренең нәсел-нәсәпләрен саклап, читләрне катыштырырга тырышмыйлар иде. Һәм башка җаһили кавемнәр кебек, инсәп гыйлеменә бик зур әһәмият бирәләр иде. Гарәпләрдә нәсәп алты дәрәҗәдән гыйбарәт: шәгъб, кабилә, гыймәра, батн, фәхиз һәм фәсыйлә. Шәгъб иң ерак нәсәптер. Мәсәлән, Кахтан, Гаднән кебекләргә бүленү. Шәгъбдән аерылган тармакларны кабиләләр дип әйтәләр. Рабига, Модар кебек кабиләләрдән аерылган тармакларны гыймәра diләр. Аның тармакларына батн, аннан соң фәхиз килә һәм иң соңында фәсыйләгә тармаклана. Гарәпләрдә инсәп гыйлеме белән шөгыльләнгән кешеләр бик күп иде. Хәтта бер кабиләдә берничә «нәссәбәләр» бар иде. Гарәпләрнең иң мәшһүр нәссәбәләреннән – Дәгъфәл әс-Сүдүси, Гомәйр Әбү Дамдам, Ибне Лисән әл-Хамра (Вәрака әл-Әшгарь). Болардан иң мәшһүре – Дәгъфәл. Гарәпләр нәсәпләрен Дәгъфәлдән дип әйтеп дәлил китерәләр иде. Вәрака әл-Әшгарь нәссәбә булуыннан тыш хатиб та иде. Һәм Әбү Бәкер әс-Сиддыйкның да нәсәп гыйлемендә зур белеме бар иде.

**Тарих**. Гарәпләрдә тарих гыйлеме ата-бабалардан авыздан авызга күчерелеп килгән төрле хәбәрләрдән һәм кыйссалардан гыйбарәт. Гарәпләр куәтле хәтер ияләре бул-

ган бер кавем булганлыктан, ата-бабаларының бик күп вакыйгаларын хәтердә саклап, телдән-телгә йөртәләр иде. Аларның шигырьләрендә дә бик күп тарихи вакыйгалар чагыла. Мәсәлән, гарәпләрнең «Әййәме-л-гарәб» дип аталган мәшһүр сугыш, «Әсхабе фил» кыйссасы, Кәгъбә тарихы, потлар хакындагы хикәяләр, Гамр бине Лүхә кыйссасы, Зү Йәзиннең хәбәшиләр белән сугышы, Зүнәвәснең вакыйгалары, «Әсхабе Ухдуд» кыйссасы, Каса бине Күләбнең тарихы, «Хилфе-л-мутайййибине» һәм «Хилфе-л-фудуль» кыйссалары, әл-Фүҗҗәр сугышы турындагы кыйссалар кебек, Исламияттән соң тарихчылар тарафыннан язып куелган тарихи вакыйгалар җаһили гарәпләрдән авыздан авызга күчеп килгән тарихи мәгълүматлардан гыйбарәтдер.

**Дәвалау**. Гарәпләрдә авыруны ике юл белән дәвалыйлар иде. Шуларның берсе бөтиләр, өшкерү, Кәгъбадагы потлар хозурында догалар кылу, аларга корбаннар чалу белән дәвалау иде. Бу юлны күбрәк шул потларга хезмәт итүче кәһиннәр сайлый иде. Икенче ысул хакыйкый дәвалау иде. Ягъни бу юл төрле үләннәр, эчемлекләр (бал кебек) белән дәвалаудан гыйбарәт иде. Мәсәлән, эч авыруларыннан, бигрәк тә, бал кулланалар иде, ә төрле җәрәхәтләрдән *кәй* [тимер кыздырып басу] эшлиләр иде. Гарәпләр күп авыруларны *хиҗәмә* [кан алдыру] ысулы белән дәвалыйлар иде. Гарәпләрнең үз заманына күрә дәвалау турында күп кенә мәгълүматлары бар иде. Аларда үзләренә күрә шөһрәт казанган табиблары да бар иде. Шулардан иң мәшһүрләре – Ибне Хизьям, Харис бине Кәлдә, Назр бине әл-Харис бине Кәлдәдер. Харис бине Кәлдә тыйб гыйлемен Иранда өйрәнеп, анда беркадәр табиб булып йөргән. Соңрак Таифка кайтып, анда халыкны дәвалап, зур

www.darul-kutub.com

шөһрәткә иреште. Хәтта Аллаһының илчесе галәйһиссәлам авыру кешеләргә Хариска барып дәваланырга киңәш бирә торган иде. Мәккәдә Сәгъд бине Әбү Ваккас авырганда, Аллаһының илчесе галәйһиссәлам кушуы белән, Харисны китереп дәваланганлыгы риваять ителәдер. Харис бине Кәлдәнең кисра Әнушерван белән тыйб хакында булган озын сөйләшүдә кисраның аның сүзләрен хуплавы мәшһүрдер. Харис эчке авырулар буенча белгеч иде. Ул Могавия заманына кадәр яшәде. Назр бине әл-Харис та мәшһүр табиблардан иде. Әле ул табиблыктан тыш фәлсәфә белән дә мавыга иде. Әмма Назр Аллаһы илчесенең зур дошманы иде. Аның хакында күп кенә ялган сүзләр сөйләде. Һәм ахырда Бәдер сугышында әсир ителеп, үлем белән җәза кылынды.

Ибне Хозәйм дә гарәпләрнең иң мәшһүр табибларыннан иде. Ул җәрәхәтләр буенча белгеч иде. Җаһили гарәпләренең шигырьләрендә аны мактап язган шигырьләр дә күп. Шулай ук гарәпләрнең байтарлыкта да яхшы ук галимнәре бар иде. Шулардан әл-Гас бине Вәил кебек мал табиблары да бар иде.

Болардан башка гарәпләрдә кәһанәт [күрәзәчелек], ягъни киләчәктәге эшләрнең чынга ашуыннан алдан мәгълүмат бирү дә бар иде. Бу гыйлем гарәпләргә кәлдәниләрдән[1] керсә кирәк. Гарәпләрнең ышанулары буенча, күрәзәчеләр һәр нәрсәне беләләр, һәр нәрсәгә кодрәтләре җитә. Шуңа күрә һәр мәсьәләдә аларга мөрәҗәгать итәләр, авыруларын караталар, төшләрен юраталар, киләчәкләре турында алардан мәгълүмат алалар һәм бәхәсләрен алардан чиштерәләр иде. Мәшһүр потларның хезмәтчеләре шушы кәһанәтлек белән дә шөгыльләнәләр. Күрәзәчелек белән бигрәк тә ха-

1 Кәлдәний – халдей, ассириец. – тәрж.

тын-кызлар шөгыльләнгән. Мәсәлән, гарәпләрдә Сәлмә әл-Һәмдәния, Фатыйма әл-Хәсгамия, Зәркаү-л-Йәмамә кебек мәшһүр күрәзәче хатыннар бар иде.

Гарәпләрдә кыяфә гыйлемле, ягъни аяк эзеннән табучы эзтабарлар бар иде. Гарәпләр аяк эзләреннән качкан кешеләрне, югалган хайваннарны эзәрлекләп табалар. Алар бу шөгыльдә шундый оста булган ки, карт белән яшьне, ир-ат белән хатын-кызны, хәтта кыз белән хатынны эзләре буенча аерганнар.

Гарәпләрдә фираса, ягъни кешенең кыяфәтенә карап, әхлакын аңлау гыйлеме дә бар иде. Моннан башка гарәпләрнең йолдызлар буенча да байтак гыйлемнәре бар иде. Алар кояш һәм ай мәнзилләре, планеталар, йолдызлыклар хакында бик күпне беләләр иде. Гарәпләр айның мәнзилләрен 27 гә бүләләр һәм исәп-хисапларын гел ай белән йөртәләр иде.

## Гарәпләрдә сәүдә эше, һөнәрчелек һәм игенчелек

Гарәбстан тарафларындагы Йәмән, Хира һәм Гассан гарәпләре сәүдә эшендә, һөнәрчелектә, игенчелектә үз заманнарында алга киткән милләтләрдән булсалар да, Урта Гарәбстан халкы бу өлкәләрдә бик түбән дәрәҗәдә иделәр. Аларның җирләре уңдырышлы булмаганга, игенчелек белән бөтенләй шөгыльләнмиләр иде. Күчмә тормышта яшәү сәбәпле, һөнәрчелеккә дә бик ихтыяҗлары юк иде. Әмма Таиф һәм Йәсриб гарәпләре кебек бакчачылык белән шөгыльләнүчеләр, Нәҗд һәм Йәмамә гарәпләре кебек иген чәчүчеләр дә булгалый. Сәүдәгәрлек исә, бу ике шөгыльдән дә өстенрәк иде.

Гарәпләр Йәмән, Шам, Хира, Иран, Хәбәшә кебек чит илләр белән сәүдә итәләр иде. Сәүдә эшләре белән бигрәк Корәеш гарәпләре шөгыльләнә. Алар кыш көннәрендә Йәмәнгә, җәй көннәрендә Шамга кәрваннар җибәреп, аннан товарлар алып кайтып, үз ярминкәләрендә саталар. Гарәпләрдә махсус ярминкәләр дә була. Шуларның иң мәшһүрләре – Гокәз, Миҗәннә һәм зүл-Мәҗәз дигәннәре.

Гокәз ярминкәсе Таиф белән Мәккә арасында хөрмәлектән гыйбарәт бер җир булып, ярминкәсе зил-кагъдә аеның башыннан егермесенә кадәр дәвам итә. Аннан соң гарәпләр Мәккәгә килеп, хаҗ вакытына кадәр анда сәүдә белән мәшгуль булалар иде. Гокәз – ярминкәләрнең иң зурысы иде. Аңа Гарәбстанның һәр тарафыннан кешеләр килә. Хира башлыгы Ногман бине Мүнзир Гокәзгә һәр елны кәрван җибәрә иде. Кисралардан да Гокәзга товар җибәргәннәре риваять ителә.

Гокәз сәүдә урыны булудан бигрәк, әдәбият мәйданы да иде. Аңа һәр тарафтан мәшһүр шагыйрьләр һәм хатиблар килә, кара-каршы шигырь сөйлиләр, ата-бабалары, кабиләләре, шәих вә рәисләре белән мактаналар иде. Гарәпләрдән золым күргән кешеләр Гокәз ярминкәсенә килгән гарәп башлыкларына шикаять итәләр иде. Берәр кабиләдә әсире булган кешеләр, шул кабиләнең башлыкларыннан әсирләрен коткару өчен ярдәм сорыйлар иде. Мәшһүр могалләкалар шул Гокәз базарында сөйләнгәннән соң, күркәмлекләренә карата Кәгъбәтуллаһка элеп куелдылар.

Ярминкәнең башлыгы күбрәк Бәнү Тәмим кабиләсеннән була. Зүл-Мәҗәз ярминкәсе белән Миҗәннә дә Мәккәгә якын җирдә булып зур ярминкәләрдән санала иде. Аллаһының илчесе дә шушы ярминкәләрдә булгалый һәм



www.darul-kutub.com

пәйгамбәрлек килгәч, анда кешеләрне дингә өнди. Мәсәлән, шушы ярминкәләр искә алынган шигырьләр дә күп:

سَأُنْشِرُ إِنْ حُيِيْتُ لَهُمْ كَلَامًا    يُنْشَّرُ فِي الْمِجَنَّةِ مَعْ عُكَاظ[1]

Бу ярминкәләрнең, бигрәк тә Гукәз базарының телне берләштерүдә һәм әдәбиятның алга китешендә хезмәте зурдыр. Болардан тыш Дүмә-л-Җәндәл, Һәҗәр, Гомән, Мөшәккар, Санга, Хадрамәүт, Гадн кебек мәшһүр ярминкәләр дә бар иде.

## МӨХӘММӘД (АЛЛАҺНЫҢ САЛАВАТЫ ҺӘМ СӘЛАМЕ БУЛСЫН) ПӘЙГАМБӘРЛЕККӘ КАДӘР

**Хөрмәтле нәсел.** Мөхәммәд галәйһиссәламнең атасы – Габдулла бине Габделмоталлиб бине Һашим бине Габдеманнаф бине Кусай бине Киләб бине Мурра бине Кәгъб бине Лүәй бине Галиб бине Фиһр бине Мәлик бине ән-Надр бине Кинәнә бине Хозәймә бине Мудрикә бине Ильяс бине Модар бине Низар бине Мәгадд бине Гаднән. Анасы Ибне Зуһра башлыкларыннан Вәһб бине Габдүманнаф бине Зуһра бине Киләб бине Мурра кызы иде. Ата һәм ана ягыннан булган бабалары Киләб бине Муррага барып тоташадыр.

Нәсәп-шәрифнең шушы кадәрлесенә килгәндә, тарих галимнәре арасында каршылыклы фикерләр юк. Инде моннан соңгысы каршылыклы булса кирәк. Әмма нәсәп-шәрифнең Исмәгыйль галәйһиссәламгә барып тоташуында шөбһә юктыр. Шулай ук нәсәп-шәриф кирәк ата ягыннан булсын, кирәк

1 Хәссән бине Сәбитнең Мәккә мөшрикләреннән көлеп язган шигырьләреннән берседер. Мәгънәсе: «Исән булсам, алар хакында Гукәз һәм Миҗәннә ярминкәләрендә таралачак сүзләр сөйләрмен». – авт.

ана ягыннан булсын югары нәсәпле, шәриф һәм хуҗа кешеләр булып, үз заманнарының абруйлыларыннан иде. Барлык ата-бабаларының никахлары гарәп гадәтенчә законлы булып, зиналы кебек түбәнчелекле тормыштан пакъ иделәр.

Шушы нәсәп-шәрифтә булган Фиһр Корәеш исеме белән дә мәшһүр иде. Һәм аннан таралган гарәпләргә Корәеш гарәпләре дип әйтә башладылар.

Мәккә шәйхе Габделмоталлиб улы Габдулланы Ибне Зуһра башлыкларыннан Вәһәб бине Габдеманнаф исемле бер затның Әминә исемле кызына өйләндермеш иде. Бу вакыт Габдулла 18 яшендә иде. Ләкин Габдулла озак яши алмады. Сәүдә эшләре белән Шамнан кайтышлый авырып, Мәдинәдә вафат булды һәм ән-Нәбига әл-Җәгъди йортында күмелде. Ул вакытта аңа якынча 25 яшь иде[1]. Габдулланың вафатыннан соң Мөхәммәдкә калган малы биш дөя һәм Үмм Әймән дип танылган Бәрәкә исемле кәнизәк хатын иде.

Габдулланың вафатыннан соң ике ай үткәч, Әминә бер ир бала тапты. Бу хәбәргә Габдулланың атасы Габделмоталлиб һәм туганнары бик шатландылар. Баланың тууы турында хәбәр китерүчеләргә бүләкләр бирделәр. Хәтта Әбү Ләһәбнең сөенеч хәбәрен китергән кәнизәк хатынны азат итүе риваять ителәдер.

Ошбу бала барлык кешелеккә сөенеч булган, Ислам шәригатенең сахибе һәм пәйгамбәрләрнең соңгысы – Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам иде.

Мөхәммәд галәйһиссәлам тууы гарәпләр арасында мәшһүр булган фил елында, рабигыль-әүвәл аеның тугызынчы көнендә иртә белән Мәккә шәһәрендә Әбү Талибнең йортында булды. Милади белән 571 елның 20 апреленә туры килә[2].

1 “Ибне-л-Әсир”, 2 т., 4 бит. – авт.

2 Гасырыбызның галиме тарафыннан кабул ителмеш Мәхмуд паша Фәләкинең фикеренә иярдек. – авт.

Мөхәммәд галәйһиссәламне иң әүвәл имезгән хатын әтисенең бертуганы Әбү Ләһәб кәнизәге – Сүвәйбә иде[1]. Тәрбиячесе дә атасыннан калган кәнизәк Үмм Әймән иде[2].

Бу вакытларда Мәккә гарәпләрендә балаларын имезү һәм тәрбияләү өчен сахра гарәпләренә бирү гадәте бар иде. Чөнки бала, сахрада таза һәм әрсез булып үсеп, тормыштагы һәртөрле вакыйгаларга чыдамлы һәм куәт иясе булып җитешәдер. Шул гадәт буенча, Мөхәммәд галәйһиссәламне дә сахра гарәпләренә имезергә бирергә карар кылынды һәм Ибне Сәгъд кабиләсендәге Әбү Зүвәйб кызы Хәлимәгә тапшырылды. Хәлимәнең ире Харис бине Габделгоззә исемле зат иде.

Мөхәммәд галәйһиссәлам Хәлимә кулында булган вакытта, бу гаиләгә күп бәрәкәтләр килгәнлеге дә риваять ителәдер. Ул Хәлимә кулында 5 яшенә кадәр тәрбия кылынды[3].

**Әминәнең вафаты.** Әминә һәр ел саен Мәдинәгә барып, сөекле ире Габдулланың каберен зиярат итә һәм иренең туганнарын (Ибне Гади бине Нәҗҗар) күреп китә иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам алты-җиде яшькә җитеп,

1 Сүвәйбә моннан элек Хәмзә бине Габделмоталлибне, соңра Әбү Сәлимә бине Габдүл Әсәдны имезгәне өчен, алар өчесе дә сөт кардәшләрдер. Сүвәйбә Мәккәдә вакытта Аллаһының илчесенә килә торган иде һәм анардан зур хөрмәт күрә иде. Аллаһының илчесе һиҗрәт кылгач, Әбү Ләһәб бу хатынны азат итте. Фәтх һәм Хайбар елында Сүвәйбә вафат булды. – авт.

2 Үмм Әймән “Бәракә” исемендә Хәбәши кабиләсеннән бер хатындыр. Рәсүлуллаһка атасыннан мирас булып калды. Хәдичәгә өйләнгәндә, ул аны азат итте. Үмм Әймән элек Габид бине Зәйд исемендә берәүгә кияүгә чыгып, аңардан Әймән исемле бала тудырды. Аннан соң рәсүлуллаһның тәрбиягә алынган Зәйд бине Хәрискә барып, аңардан Әсәмәне китерде. Рәсүлуллаһның вафатыннан соң бик нык кайгырып елады. Хәтта тәэсирле сүзләр әйтеп Әбү Бәкер белән Гамрны да елатты. Рәсүлуллаһ аны бик ярата вә ихтирам итә иде. Аның турында: “Үмм Әймән минем анам, соңында икенче анам”, - дия иде. – авт.

3 Хәлимә Аллаһының илчесе белән Әбү Софьян бине әл-Харисны да имезде. Шунлыктан, бу икәү сөт кардәшләрдер. Хәлимәнең Габдулла исемле улы һәм Әнисә белән Җүзәмә исемле кызлары бар иде. Җүзәмә Мөхәммәдне (галәйһиссәлам) карый иде. Мөхәммәд (галәйһиссәлам) Хәдичәгә өйләнгәч, Хәлимә аларга кунакка килгәч, аңа күп рәхмәтләр һәм бүләкләр бирелде. Фәтхү Мәккәдән элек вафат булды. Мәккә фәтх кылынгач, Хәлимәнең кыз кардәше рәсүлуллаһка килеп бүләкләр алды. Сөт анасының үлгәнен ишеткәч, рәсүлуллаһның күзләреннән яшь акканлыгы риваять ителәдер. – авт.

www.darul-kutub.com

беркадәр уңны-сулны аера башлагач, атасының каберен зиярат иттерү һәм атасының якыннарын күрсәтү өчен Әминә улын да Мәдинәгә алып китте. Яннарында Үмм Әймән дә бар иде. Мәдинәдән кайтышлый, Әбвәэ дигән авылда Әминә хасталанып вафат була һәм шунда күмелә. Мөхәммәд галәйһиссәлам исә тәрбиячесе кулында Мәккәгә кайта. Әминә Габдулладан соң беркемгә дә кияүгә чыкмаган. Габдулла да Әминәдән элек беркемгә дә өйләнмәгән иде. Шулай итеп, Мөхәммәд галәйһиссәлам алты-җиде яшендә ата-анасыннан мәхрүм калды.

Моннан соң Мөхәммәд галәйһиссәлам бабасы – Габделмоталлиб тәрбиясендә кала. Габделмоталлиб Мөхәммәдне бик ярата, киләчәктә аның бөек зат булачагын сизенә, шуның өчен аны тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Мөхәммәд галәйһиссәлам бабасы өендә ятимлек ачысын күрмичә үсә иде. Әмма бу хәл озак бармады. Мөхәммәд галәйһиссәлам сигез яшенә җиткәндә, Габделмоталлиб та вафат булды. Бабасы белән аерылырга теләмәүдән Мөхәммәд галәйһиссәламнең күз яшьләрен түккәне риваять ителәдер.

Габделмоталлибтан соң, аның васыяте буенча бала Мөхәммәд галәйһиссәламнең атасы Габдулланың бертуганы Әбү Талиб тәрбиясендә калды. Әбү Талиб акыллы, дәрәҗәле, шәфкатьле вә мәрхәмәтле бер зат иде. Ул Ибне Һәшимнең рәисе, шуның өстенә бөек бер шагыйрь булганлыктан, Мәккә халкы арасында мөхтәрәм һәм мәртәбәле бер зат иде. Ул Мөхәммәдне үз улларыннан да артык сөя, аңа шәфкать, мәрхәмәт күзе белән карый, аны тәрбияләүгә кулыннан килгән кадәр әһәмият бирә иде. Әбү Талиб үзе фәкыйрь, гаиләсе дә зур булганлыктан, Мөхәммәд башка аксөяк балалары шикелле нәзберек тәрбия күрә алмый, әрсез

үсә иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам гәүдәгә таза һәм нык булып үскән кебек, акыл һәм фикерләү ягыннан да балалар арасында аерылып тора иде.

## Рәсүлуллаһның Шамга беренче сәфәре

Корәеш гарәпләре һәрвакыт кәрван белән мал алып Шамга баралар, аннан Шам әйберләрен алып кайтып, Гарәбстанга тараталар иде. Әбү Талиб, сәүдәгәр булу сәбәпле, Шамга бик еш бара иде.

Бервакыт Мәккә кәрваны белән Әбү Талиб Шамга сәфәргә чыкмакчы булды, Мөхәммәд аннан аерыласы килмичә елагач, аны да үзе белән шул сәфәргә алып китте. Бу вакытта Мөхәммәд тугыз яшьләрендәге бер бала иде[1]. Кәрван кайтышлый Бусра шәһәре янына җиткәндә, бер йортта гыйбадәт белән мәшгуль булган Бәхира исемле бер раһиб [монах] алар белән сөйләшер өчен каршыларына чыкты һәм: «Китап мокаддәснең хәбәренә күрә, якын араларда гарәбләрдән бер пәйгамбәр чыгарга тиеш, сездә моңа дәлилләр була алган берәр төрле галәмәтләр күренмиме?» – дип кәрван кешеләреннән сорады. Шул вакыт Мөхәммәдне күреп, аның шул китап мукаддәс хәбәр биргән кеше булачагын фарыз итте. Әбү Талибка да аның хакында киңәш бирде. Чыннан да, бу вакытта рәсүлуллаһның пәйгамбәрлегге алдыннан, мондый сүзләр яһүди вә насара галимнәре арасында һәрвакыт сөйләнә, тиздән аның килүе көтелә иде. Мөхәммәднең Әбү Талиб белән сәфәре шушы бер мәртәбә

---

1 Ибне-л-Әсир, 13 б., 2 т. “Зәде-л-Мәгад” сахибе бу сәфәрнең унике яшендә булганын сөйли. – авт.

генә булмышдыр[1]. Әбү Талибның Мөхәммәдне Шамга ияртеп баруының максаты аңа ил күрсәтеп, мәгълүмат җыю һәм сәүдәдә тәҗрибә җыю булмыйча, ә югарыда әйткәнчә, елавын күреп, кызганудан иде. Юкса, аны башка сәфәрләргә дә алып барыр иде. Мөхәммәднең Бәхираны күрүе шул бер тапкыр гына булды[2]. Ул вакытта Мөхәммәд галәйһиссәлам акны карадан аера алмаган бер бала булганлыктан, Бәхира белән күрешүдән күп нәрсә аңлый алмаганы табигыйдер.

**Әл-Фүҗҗәр сугышы.** Мөхәммәд галәйһиссәламгә егерме биш[3] яшь тирәләре булган вакытта Корәеш һәм Кинәнә белән Кайс кабиләсе арасында сугыш булды. «Хәрбү-л-Фүҗҗәр» дип аталган бу сугышның сәбәбе түбәндәгечә иде: Хира падишаһы Ногман бине әл-Мүнзир Кайс улларыннан Горвә бине Готбә әр-Руххәл исемле бер затның кул астында Гокәз ярминкәсенә кәрван белән мал җибәргән иде. Кинәнә гарәпләреннән Бәррад бине Кайс исемендәге берәү форсат китереп, Горвәне үтереп, кәрванны талап китә. Горвәнең кавеме табигый Кинәнә гарәпләреннән аның үлеме өчен түләү таләп итәчәгеннән, Бәррад боларның һөҗүмнәренә каршы торсыннар өчен кавеменә бу вакыйга хакында хәбәр бирә. Кайс кабиләсе Горвәнең үтерелүеннән хәбәр алгач, су-

1 Рафикъ бәк хәзрәтләренең бөек “Тарих гомуми” китабында, 5 томының 28 битендә: “Әбү Талиб бөтен сәфәрләрендә хәзрәти Мөхәммәдне үзе белән бергә алды, сәүдә мөгамәләтен акрын гына бер сурәттә алыштырды”, – дигән сүзе туры килмидер. – авт.

2 Насара галимнәре(шәрык белгече)Бәхираны Мөхәммәд галәһһиссәлам хәзрәтнең укытучысы буларак кабул итәләрдер. Алар Әбү Талиб Мөхәммәдне һәрвакыт үзе белән бергә Шамга алып бара иде дип фаразлыйлар. Мөхәммәд галәһһиссәлам һәрвакыт Бәхира белән күрешә һәм аңардан файда ала иде дип әйтәләр. Тәүрат һәм Инҗил хакында да аңардан күп мәгълүматлар алды, диләр. Тагы үзе башлы һәм зирәк булганлыктан, кирәк Бәхирадан булсын, кирәк күпсанлы сәяхәтләреннән булсын, бик күп мәгълүматлар туплады диләр. Әмма бу сүзләрне тарих бизмәненә салып караганда күзгә күренмәгән тузан бөртекләре генәдер. – авт.

3 Ибне Исхак риваятенә нигезләнеп, кайберләр әл-Фүҗҗәр сугышы рәсүлуллаһның ундүрт яшендә булды диләр. – авт.

www.darul-kutub.com

гышка әзерләнеп Нәхлә[1] дигән җирдә Кинәнә һәм Корәеш кабиләләре белән очрашалар. Араларында каты сугыш булып, нәтиҗәдә Корәеш һәм Кинәнә гарәпләре җиңелә һәм Харамга кереп сыеналар. Кайс кабиләсе Горвәнең канын таләп итүдән ваз кичмәенчә, киләсе елда Гокәз вакытында сугышка киләчәкләрен игълан итеп кайтып китәләр.

Икенче елны Гокәз вакытында ике арада зур сугыш була. Кайс кабиләсенә ярдәмгә Сәкыйф һәм шул тирәдә булган гарәпләр килә, ә Корәеш һәм Кинәнә гарәпләренә әхәбишләр [2] кушыла. Корәеш һәм Кинәнә гарәпләренең хәрби башлыгы атаклы Хәрб бине Үмәййә иде. Тагы һәрбер ыругның да махсус үз хәрби башлыклары бар иде. Мәсәлән, Бәнү Һашимның хәрби башлыгы Зөбәйр бине Габделмоталлиб булып, болар эчендә Зөбәйрнең кардәшләре Әбү Талиб, Хәмзә, Габбас һәм абыйсының улы Мөхәммәд галәйһиссәлам иде. Бәнү Габде-д-Дәрның хәрби башлыгы Гыйкримә бине Һәшим, Бәнү Мәхзүмнеке Хишам бине әл-Мугира. Һәм башка ыругларның да рәисләре хәрби башлык булдылар. Кайс гарәпләре тарафыннан иң зур хәрби башлыклары Әбү Бәраэ Мүләгыйб әл-Әсиннә, Сүбәйгъ бине әр-Рабигъ, Гауф бине әл-Хәрисә, мәшһүр шагыйрь һәм фәрис Дүрәйднең атасы Саммә һәм башкалар иде. Шушы сугышта Хәрб бине Үмәййә һәм кардәшләре Суфиян белән Әбү әл-Гас гаять батырлык күрсәттеләр. Бу сугыш алдан кайс гарәпләре файдасына барса да, соңрак Корәешләр өстен чыктылар. Ахырда, ике тараф та юкка кан түккәннәренә

1 Мәккә белән Таиф шәһәрләре арасындагы бер җир исемедер. – авт.

2 Мәккә тирәсендәге җыентык гарәпләргә әхәбиш дигәннәр. Боларның үзләренең башлыклары булып Корәеш гарәпләренең союздашларыннан иде. Ислам белән булган берничә сугышта Корәеш тарафыннан болар да бар иде. – авт.

үкенеп, кайсы тарафта мәет күп булса, шуларның диясен[1] икенче тарафтан түләтү шарты белән килешү төзеделәр. Кайс тарафында Корәеш белән чагыштырганда егерме мәеткә артык булганлыктан, Корәеш кабиләсе дия түләде. Бу сугыш гарәпләр арасында булган сугышлардан иң зурысы саналадыр. Шушы сугышта мөхтәрәм һәм изге саналган Кәгъбәгә карата ихтирамсызлык кылынганга «әл-Фүҗҗәр» сугышы дип атаганнар.

**Фодүл берлеге.** Шушы сугыштан соң Корәеш башлыклары Габдулла бине Җәдган өендә җыелып, кайчандыр төзелгән һәм хәзер онытылган «әл-Фодүл берлеге»[2] исемле танылган җәмгыятьне яңарттылар. Әйтелгән җәмгыятьтә катнашучылар Бәнү Һәшим, Бәнү Габделмоталлиб, Бәнү Әсәд, Бәнү Зуһра, Бәнү Тәйм бине Мурра ыруглары иде. Бу җәмгыятьнең максаты – ирексезләү һәм золымлыкны бетерү, Мәккәдә торучы кирәк Корәеш, кирәк башка кабиләгә золымлык кылынса, аңа ярдәм итү. Мөхәммәд галәйһиссәлам дә шушы җәмгыять әгъзаларыннан була. Мөхәммәд галәйһиссәлам рисәләт илә пәйгамбәр кылынгач та, шушы җәмгыятьтә булганлыгын ачыклап шушындый сүзләр әйтте:

«لَقَدْ شَهِدْتُ مَعَ عُمُومَتِي حِلْفًا فِي دَارِ عَبْدِ اللهِ بْنِ جُدْعَانَ مَا أُحِبُّ أَنَّ لِي حُمْرَ النَّعَمِ وَ لَوْ دُعِيتُ بِهِ فِي الْإِسْلَامِ لَأَجَبْتُ»[3]

---

1 Үтергән кеше өчен биреләчәк түләү – тәрҗ.

2 Бу җәмгыять башта әл-Фүдәйл бине әл-Харис, әл-Фадыйль бине Вәдәга, әл-Мөфәддаль бине Фодалә исемле өч кеше тарафыннан төзелгән иде. Һәм вакытлар үтү белән тәмам онытылып беткән иде – авт.

3 Гомумләр белән бәрабәр Габдулла бине Җәдган өендә җәмгыятьтә катнашкан идем. Ул җәмгыять миңа кызыл дөяләрдән дә кыйммәтлерәктер. Әгәр Исламияттә дә шундый эшкә чакыручы булса, әлбәттә, кабул итәр идем – авт.



www.darul-kutub.com

# Шамга икенче сәфәр һәм Хәдичәгә никахлану

Мөхәммәд галәйһиссәлам егерме биш яшьләрендә Мәккә шәһәренең олуг сәүдәгәреннән Хәдичә бинте Ховәйлиднең малы белән Шамга сәфәр кылды. Бу вакытта Хәдичә Мәккәнең иң бай кешеләреннән санала иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам Корәеш кавеме арасында гадел, ышанычлы һәм тугры булуы белән дәрәҗә казанган иде, хәтта аны «әл-Әмин» [ышанычлы] дип тә йөртәләр иде. Хәдичә моңа зур хак биреп, Шамга сәүдә белән чыгарга күндерде. Аның янында Хәдичәнең колы Мәйсәрә дә бар иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам бу сәфәреннән күп табышлар белән әйләнеп кайтты. Хәдичәнең Мөхәммәд галәйһиссәламгә күзе төшүенең сәбәбе дә бәлки шушындадыр.

Хәдичә Корәеш кабиләсендә зур гаиләдән булып, кырык яшьләрендәге бер хөрмәтле һәм бай тол хатын иде. Мөхәммәд галәйһиссәламне Корәеш арасында начар эшләрдән ерак булган иң ышанычлы һәм иң тугрыыклы бер зат булуын белеп, өстәвенә Шам сәүдәсеннән күп файда китергәнен күреп, Хәдичә кияүгә чыгу нияте белән Мөхәммәдкә Нәфисә бинте Мүнәййә исемле хатын аркылы үзен димләде. Мөхәммәд хәзрәт тә акыллы, абруйлы, өстәвенә дәүләтле бу хатынның үтенечен кире кайтармады. Мөхәммәд галәйһиссәлам этисенең абыйсы Әбү Талиб белән Хәдичәнең этисенең абыйсы Гамр бине Әсәдкә барып, Хәдичәне сорадылар. Гамр бине Әсәд:

«ذَاكُ فَحْلٌ لَا يُقْدَعُ أَنْفُهُ»[1]

1 «Бу хөрмәтле зат кире кагылмас» – тәрҗ.

www.darul-kutub.com

– дип ризалыгын белдерде. Шулай итеп, Хәдичә Мөхәммәднең никахы илә мәңгелек бәхеткә ия булды. Мөхәммәднең Хәдичәгә мәһәр итеп егерме дөя бирүе риваять ителә.

**Кәгъбәтуллаһны яңарту.** Мөхәммәд галәйһиссәламгә утыз биш яшьләр булган вакытта, Корәеш гарәпләре Кәгъбәне янарту фикеренә килделәр. Моңа кадәр Кәгъбәтуллаһ кеше буе кадәр генә булып, ачык түбәле иде. Мәккәлеләр моны Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәр бина кылган нигезгә кадәр сүтеп, яңадан бина кылырга һәм түбәсен дә ябарга ният иттеләр. Бөтен гарәп милләте каршында Кәгъбә изге вә мөхтәрәм бер бина булганлыктан, алар аны риба, зина кебек эшләр белән тапкан малларны катнаштырмыйча, хәләл көч белән табылган маллары исәбенә яңартырга булдылар. Җитәрлек мал җыелгач, Кәгъбәне нигезенә хәтле җимереп, яңадан төзергә керештеләр. Корәешнең өлкәннәреннән алып кечкенәләренә кадәр шушы эштә катнашып, аркаларында таш ташыдылар. Һәм шулар арасында Аллаһының илчесе Мөхәммәд галәйһиссәлам дә мөбәрәк җилкәләренә таш салып ташып йөрде. Бина сигез аршин биеклектә булып, түбәсе такта[1] белән ябылды. Ишеге җирдән күтәренке ителеп, баскыч белән менә торган ителде. Бинаны карап торып эшләтүче кеше Бакум исемле румлы балта остасы иде.

Бина тәмам булгач, хәҗәр әсвәдне [кара ташны] әүвәлге урынына кую хакында гарәп башлыклары арасында сүз чыкты. Һәр кабилә рәисе ошбу шәрәфле эшне үзенә алырга теләде. Низаг дүрт көнгә сузылып, араларында сугыш та чыга язды. Ниһаять,

1 Бу такта Кызыл диңгез буенда тишелеп туктаган бер көймә такталарыннан гыйбарәт иде. – авт.

Вәлид бине Мугыйраның тәкъдиме буенча Бәйтүллаһка кем беренче килеп керсә, шуның хөкемен тыңларга булдылар. Иң беренче Бәйтүл Харам ишегеннән Мөхәммәд галәйһиссәлам килеп керде. Моңа Корәеш рәисләре гадәттән тыш разый булып, аның килеп чыккан низагны чишәчәгенә канәгатьләнделәр. Нәтиҗәдә, Мөхәммәд галәйһиссәлам кара ташны җиләненә салып, кием тирәсен бөтен кабилә башлыкларыннан тоттырды һәм бөтенесе бергә ташны Кәгъбәтуллаһга алып бардылар. Соңрак Мөхәммәд галәйһиссәлам үз кулы белән ташны алып урынына урнаштырды. Шулай итеп, Мөхәммәд галәйһиссәламнең акыллы хөкеме белән гарәп кабиләләре арасында сугыш булмый калды.

## Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлек килгәнчегә кадәрге тормышы

Мөхәммәд галәйһиссәлам әтисеннән фәкыйрь хәлдә ятим калганлыктан, яшь вакытын куй көтү кебек эшләр белән уздырды. Хәтта Ибне Сәгъд кабиләсендә тәрбияләнгәндә дә, үзе кебек балалар белән куйлар көтә иде. Мәккәгә кайткач үзенең якыннарына бик аз хак белән куй көтүе турында сөйләде. Бу имам Бохариның хәдисләр китабында риваять ителгән. Яшь вакытта куй көтү Мөхәммәд галәйһиссәламгә генә хас булмыйча, башка пәйгамбәрләр дә бу эш белән шөгыльләнгәннәр.

Мөхәммәд галәйһиссәлам дә башка кардәшләре кебек мәктәп дигән нәрсәне күрмәде, ишетмәде һәм уку-язуны белмәде. Башка күчмә кабиләдә үсүче балалар кебек

мал-туар тирәсендә балалык дәверен кичерде. Мөхәммәд галәйһиссәлам егетлек дәверенә кергәч, сәүдә белән шөгыльләнә башлады. Егерме биш яшендә Хәдичәнең маллары белән Шамга сәфәр чыкты. Хәдичәгә өйләнгәч тә, аның малын үстерергә тырышты. Аның малына гына салынып ятмыйча, маңгай тиресе илә тапкан үз малын ашар булды.

Гомумән, гарәпләр сыннарга гыйбадәт итәләр, аларны арадашчы итеп куялар, файда һәм зарар китергәннәренә ышаналар иде. Ләкин Мөхәммәд галәйһиссәлам аларга гыйбадәт кылмый иде. Мөшрикләр тарафыннан үткәрелә торган бәйрәмнәргә әзерләнми һәм аларга бармый иде. Зина һәм фәхеш кебек җәмгыять авырулары бөтен кавемне каплап алса да, ул алардан ерак тора иде. Хәмер эчү гарәпләрдә киң таралса да, ул бу түбәнчелектән пакъ булып гомерендә бер мәртәбә дә шәраб эчмәгән. Сыннар исеменә чалынган корбаннарның итен ашамый иде. Гомумән, начар гадәтләрдән һәм җаһили гамәлләрдән ерак тора иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам яшьтән үк үз кавеме арасында тугры сүзлелек вә әманәтне үтәү белән билгеле иде. Шуның өчен Мәккә гарәпләре аны «Мөхәммәд-әмин» [тугрылыклы, ышанычлы] дип йөртәләр иде. Пәйгамбәр булып, халыкны хак дингә чакыра башлаганнан соң, кайсар Һираклийның: «Бу сүзләрне сөйләмәстән, элек аның ялган сөйләгәнен беләидегезме?» – дигән соравына Әбү Суфиянның: «Юк!» – дип җавап бирүе дә моңа дәлилдер.

Мөхәммәд галәйһиссәлам йомшак күңеллелек, сабырлык, гаделлек, тыйнаклык, гыйффәтлек, кыюлык, юмартлык кебек күркәм әхлакның иң югары дәрәҗәсендә иде. Пәйгамбәр булганнан соң, аның иң зур дошманнарыннан Надир бине әл-Харисның үз кавеменә: «Мөхәммәд

www.darulkutub.com

яшь чагында сезнең арагызда иң сөекле, иң тугры сүзле, иң ышанычлы бер кеше иде. Инде аның чигә чәчләренә чал кереп: «Аллаһы бер, үлемнән соң терелү бар», – дигән сүзләрне сөйли башлагач, сез аны сихерче дидегез. Валлаһи, ул сихерче түгел», – диюе дә Мөхәммәд галәйһиссәламнең күркәм әхлакның иң югары мәртәбәсендә танылганлыгына дәлилдер.

Мөхәммәд галәйһиссәламнең пот һәм сыннарга гыйбадәт итеп, аларның файда һәм зарар китергәннәренә ышанган, үз куллары белән ясаган таш һәм агачларга баш иеп, аларда әллә нинди яшерен көчләр бар  дип ышанган, аларның ризалыгын алу өчен каршыларында тез чүккән, аларның ачуыннан котылу, аларга якынаю нияте белән корбан чалган, аларның исемнәренә сәдака бирә торган, зина, фәхеш һәм хәмер эчү кебек гөнаһлар белән буялган бер мохит эчендә ялгыз, әйтелгән күркәм әхлакта яшәве сәер һәм гаҗәпләнерлек бер нәрсәдер. Бигрәк тә Мөхәммәднең яштән ятим булып, ата-анадан мал-мөлкәт калмавы һәм үз гаиләсе дә фәкыйрь булган Әбү Талибта тәрбияләнеп, шушындый әхлакка ирешүе, чыннан да, бик гаҗәп. Бөтен гаиләсе, яшьтәш иптәшләре, кавем һәм кабиләсе потларга табынганда, Мөхәммәд галәйһиссәламнең бер Аллаһыны гына танып үсүе акылларны хәйран калдыручы бер могҗиза түгелме? Әхлак һәм гадәт буенча түбән бер мохит эчендә яшәгән Мөхәммәд галәйһиссәламнең яшь вакытында ук үз мохитенең капма-каршысы булган күркәм әхлагы иң югары дәрәҗәдә булу гаҗәпләнерлек хәл түгелмени соң? Гарәпләр иллюзия һәм хорафатлар арасында адашкан, ата-бабаларыннан мирас булып калган начар гадәтләр әсирләре һәм ахмаклык белән батылның коллары булган хәлдә, бер Мөхәммәд

www.darul-kutub.com

галәйһиссәламнең мондый гөнаһлардан саф булып үсүе дикъкатьне җәлеп итәрлек бер күренеш түгелме? Кавеме тоткан диннең батыл булганлыгы хакында аңлатучы берәр остазы бар идеме әллә? Яки бөтен кавеме хөрмәт иткән гадәтләргә каршы тәрбия бирүче берәрсе бар идеме? Әллә Мөхәммәд бу турыда мәктәптә укыдымы? Әллә Хәлимә әс-Сәгъдия яки Әминә әз-Зуһрия Мөхәммәдкә бу тәрбияне бирдеме? Әллә Габделмоталлибның бу тәрбиядә тәэсире бар идеме? Бәлки Әбү Талиб Мөхәммәдкә бөтен кавеме арасында аермалы башка тәрбия биргәндер?

Әлбәттә, юк! Мөхәммәд галәйһиссәламнең табигый әхлагы һәм җәмгыятькә каршы буларак шушы хәлендә тормыш итүе илаһи тәрбиянең нәтиҗәсе иде. Мондый тәрбия бирүче Ибраһим, Муса һәм Гайсә кебек бөек пәйгамбәрләрне үз мохитларына каршы торырлык иткән һәм аларны халыкка имам һәм үрнәк буларак әзерләгән зат Аллаһы Тәгалә иде.

## Пәйгамбәрлек

Мөхәммәд галәйһиссәлам пәйгамбәрлек иңдерелгәннән элек үк бабалары Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһиссәламнәрдән калган кайбер яхшы гадәтләрне үти иде, моннан башка эшләрдә дә фитра сәлимә кушканча хәрәкәт итә һәм дөрес акылы илә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәттә була иде.

Мөхәммәд галәйһиссәлам кырык яшенә җиткәндә серле хәлләр була башлады. Һәм бу хәлләр гадәттән тыш дәвамлы булды. Бу серләрнең башы төшләр иде[1]. Мөхәммәд

1 Вәхи иңер алдыннан төш күрүләр алты айга кадәр сузылды диләр. “Зәде-л-Мәгад”, 20 б., 1 т. – авт.

галәйһиссәлам күргән төшләре барысы да ачык һәм дөрескә чыга иде. Моннан соң ул халыктан ерагаеп, аулак урыннарда үзен яраткан Аллаһыга гыйбадәт кыла, туры бер динне эзли һәм кавеменең киң таралыш алган ширек вә сыннарга табынудан котылуының чараларына төшенә башлады. Моның өчен Мәккә янындагы Хира тавына барып, ун-унбиш көн, хәтта бер айга кадәр ялгыз гыйбадәт белән мәшгуль булды. Азыгы бетә калса, Хәдичә янына кайтып, яңадан ризык алып китә иде.

## Мөхәммәд галәйһиссәламгә вәхи килүе

Мөхәммәд галәйһиссәлам Хира тавында гыйбадәттә булган вакытта күзенә бер зат күренеп, үзен Җәбраил фәрештә икәнлеген әйтте һәм Мөхәммәд галәйһиссәламне пәйгамбәрлек белән сөендерде. Соңра Мөхәммәд галәйһиссәламгә: «Укы!» – дип әмер бирде. Моңа Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Мин укый белмим», – дип җавап бирде. Шуннан соң Җәбраил фәрештә Мөхәммәд галәйһиссәламне каты иттереп кысты да, җибәрде. Бу хәл өч мәртәбә кабатланганнан соң Җәбраил Мөхәммәдкә:

1. «Бөтен нәрсәне яратучы Раббың исеме белән укы!
2. Ул барлыкка китерде кешене оешкан каннан.
3. Укы! Синең Раббың – Аллаһы бик хөрмәтле һәм юмарттыр.
4. Ул – Аллаһы каләм белән язуны өйрәтте.
5. Кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте», – диде[1].

1 Коръәндәге “Чынлыкта, Без аны кадер кичәсендә иңдердек” – “кадер”, 1., “Чынлыкта Без аны бәрәкәтле кичәдә иңдердек һәм Без кисәтүчеләрдер” – “әд-Духан”, 3., “Рамазан аенда Коръән иңдерелде...” – “Бакара”,185., аятьләреннән чыгып, Коръән Рамазан аенда кич белән иңдерелә башланганы аңлашыладыр. Фәкать моның кайсы көн икәнлеге төгәл билгеле түгелдер. – авт.



www.darul-kutub.com

Мөхәммәд галәйһиссәлам шушы хәлдән соң курка калып өенә кайтты һәм Хәдичәгә булган вакыйга хакында сөйләде. Аңа каршы Хәдичә: «Син күркәм холыклар иясе, Аллаһы Тәгалә сиңа жен һәм шайтаннарны хуҗа итмәс. Сиңа күренгән зат – чыннан да Аллаһы Тәгаләнең фәрештәседер. Син – шөбһәсез пәйгамбәр булачаксың», – дигән сүзләрне әйтте.

## Вәрака янына бару

Мөхәммәд галәйһиссәлам бу хәлдән соң беркадәр тынычлангач, Хәдичә бу мәсьәләне чишәр өчен һәм фикеренең дөреслеген раслау өчен аны үзенең атасы белән бертуган абыйсының улы янына алып барып, вакыйганы сөйләде. Ул Вәрака исемле, электән насара динен кабул иткән бер карт иде. Ул гыйбрани [иске иврит] телен белә, Инҗил китабын укый иде. Инҗил һәм Тәүрат китапларыннан Мөхәммәд галәйһиссәлам турындагы мәгълүматлардан хәбәрдар, пәйгамбәрлек һәм вәхи хакында белеме бар иде. Вәрака Инҗилне гыйбрани язуыннан гарәпчәгә тәрҗемә дә итә иде. Мөхәммәд галәйһиссәлам аңа вакыйганы сөйләгәч, Вәрака һич уйлап тормастан: «Син пәйгамбәр булачаксың, сиңа күренгән зат – Мусага күренгән вә аңа вәхи китергән Нәмус (Җәбраил). Син кавемеңне тәухидкә [бер Аллаһыга ышануга], пот-сыннарны ташларга, җаһили гадәтләрдән арындырырга өндәгәндә, сиңа дошман булачаклар, сине иза вә җәфа кылачаклар, ниһаять, сине илеңнән дә сөрәчәкләр. Мин яшь бер егет булсам, сиңа зур хезмәтләр күрсәтер идем. Әгәр шул көннәрне күрсәм, әлбәттә, сиңа ярдәм итәрмен», – дип сөйли. Кавеме арасында игътибарлы вә сөекле булган Мөхәммәд галәйһиссәлам Вәраканың бу сүзләренә



www.darulkutub.com

гаҗәпләнгәч, Вәрака: «Һичбер пәйгамбәр үз кавеменең дошманлыгыннан һәм аларның иза вә җәфасыннан котылмаган, син дә котылмаячаксың», – диде. Бу вакыйгадан соң озак та үтмәде, Вәрака вафат булды[1].

## Вәхинең киселеп торуы

Моннан соң вәхи беркадәр киселеп торды[2]. Моның хикмәте Аллаһының илчесен вәхигә шәукынын арттыру иде. Рәсүлуллаһ вәхинең киселеп торуына бик тәэсирләнде. Мондый бөек нигъмәттән мәхрүм булуына көн-төн кайгырды һәм хәсрәттә булды. Бу бөек нигъмәтнең ләззәтеннән мәхрүм булуына, кайгы-хәсрәттән үзенә кул салу нияте белән биек тау башларыннан ташлану да уена килгәләде. Шушы вакытларда әлеге рух күренеп: «Син Аллаһының илчесе», – дип әйтеп аның күңелен тынычландырып, әүвәлге хәленә кире кайтуына өметләндерде, тау башларыннан атылудан ваз кичтерде.

## Вәхинең яңадан башлануы

Вәхи килер алдыннан күз аллары караңгыланып, фикер һәм хыял дәрьяларында чумып йөргән бер вакытта әлеге

1 Вәрака вәхигә ирешмәгән булса да, Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә ышанганы өчен Исламга килгән кешеләрдән ин әүвәлгесе саналырга тиештер. Рәсүлуллаһның Вәраканы төшендә гүзәл кыяфәттә вә ак киемнәрдә күргәне өчен аны әһел Җәннәттән санарга булганлыгы "Тирмизи" җыентыгының 2 томының 58 хәдисендә риваять ителәдер. – авт.

2 Вәхинең туктап торуының вакыты хакында тарихчылар төрле фикердәдер. Кайберләре бу вакытны өч көн диләр, кайберләре өч ел диләр. Бу фикерләр арасында да күп фикерләр бар. Рәсүлуллаһның кайгыдан тау башыннан ташлану фикеренә килү вәхинең озак вакытка тукталып торуына дәлилдер. Вакытны билгеләмәү тагы да бер фикердер. – авт.

www.darulkutub.com

Җәбраил кабат килеп, «вәд-Духә» сүрәсен иңдерде[1]. Моннан соң:

«يَا أَيُّهَا الْمُدَّثِّرُ. قُمْ فَأَنذِرْ. وَرَبَّكَ فَكَبِّرْ. وَثِيَابَكَ فَطَهِّرْ. وَالرُّجْزَ فَاهْجُرْ. وَلَا تَمْنُن تَسْتَكْثِرُ. وَلِرَبِّكَ فَاصْبِرْ»[2]

кебек аятьләр иңеп, рәсүлуллаһка кавемен тәүхидкә дәгъвәт итеп, ширек һәм сыннарны бетерергә әмер ителде. Аллаһы илчесенең пәйгамбәрлеге «Бөтен нәрсәне яратучы Раббың исеме белән укы!» – дигән аятьләрнең иңүе белән булса да, рисаләт шушы аятьләрнең соңында булмыштыр.

## Яшерен дәгъвәт

РәсүлАллаһыка йөкләнелгән вазыйфа гадәттән тыш бөек һәм аны үтәү авыр булган бер йомыш иде. Чөнки гарәп кавеме кебек ширекнең һәм сыннарга табынуның иң түбән дәрәҗәсенә төшкән, ата-бабаларыннан калган иске хорафатларны, җаһили гадәтләрне дин буларак кабул итеп, бер-берләренең каннарына ач бүреләр кебек сусап, ызгыш-талашларда вакыт уздырган, кызулык, горурлык, кыюлык кебек мактаулы сыйфатларны кире якка куллана торган, йөрәк кисәкләре булган балаларны тереләй күмәргә әзер булган мәрхәмәтсез, каты бәгырьле, әле болардан кала да,

1 “Ибне Һишам”, 120 б., 1 т. Сира галимнәренең һәм тәфсирчеләрнең күпчелеге “Галәкъ” сүрәсеннән соң “Мөддәссир” сүрәсе иңдерелде дисәләр дә, аятьтән чыгып “Духә” сүрәсенең алдан иңүе аңлашылганнан Ибне Исхак һәм Мөхәммәд Габду сүзләреннән чыгып, вәхи киселеп торганнан соң “Духә” сүрәсенең иңүен өстенрәк күрдек. Бохаридагы “Духә” сүрәсенең иңү сәбәбендә хәбәр ителгән вакыйга гадәттән тыш сәердер. Кара: Бохари, 6 т., 172 б. – авт.

2 “Әй, нүбүввәт киеме белән бөркәнгән зат! Тор, кешеләрне Аллаһы газабы белән куркыт! Раббыңны олыла. Вә киемеңне пакь кыл. Потлардан читләштер. Күп нәрсә алу өмете белән бирмә. Раббың өчен сабыр ит!” (әл-Мүддәссир/1-7) мәгънәсендә. – авт.

www.darul-kutub.com

башка җәмгыять авырулары белән авырган бер кавемне тәүхидкә, күркәм әхлакка һәм үзләренең карашларын кире кагуга дәгъвәт итү үзеңне һәлакәткә илтерлек бер эштер. Әлбәттә, бу эштә фидакарьлек һәм саклык кирәктер. Шуның өчен дә рәсүлуллаһ галәйһиссәлам бу эшкә ачыктан-ачык керешмичә, саклык һәм яшерен рәвештә тотынды. Ул иң әүвәл үз гаиләсен һәм сүзе үтәрлек кешеләрне генә дәгъвәт итә башлады.

Башлап Исламияткә килүчеләрдән хөрмәтле хатыны Хәдичә бинте Ховәйлид, әтисенең бертуган абыйсының улы[1] Гали бине Әбү Талиб, хезмәтчесе Зәйд бине Харис[2] һәм Зәйднең хатыны – Үмм Әймән иде. Моннан соң үзенең иң якын дусты булган Әбү Бәкер бине Әбү Кәхафне дәгъвәт итте. Әбү Бәкер Корәеш арасында бик күренекле бер зат иде. Күркәм йөзле, гүзәл холыклы, мөлаем табигатьле, хуш мәҗлесле, нәсеп гыйлеменнән дә күп мәгълүматлы мөхтәрәм бер карт иде ул. Сәүдәгәр булганга, малы күп булып, халыкка йогынтысы да зур иде. Әбү Бәкер рәсүлуллаһ белән күп вакытлардан бирле дус булып, аңардан һичбер

1 Бу вакытларда Гали 8-10 яшьләрендә рәсулуллаһ галәйһиссәлам тәрбиясендә иде. Чөнки пәйгамбәрлеккә кадәр Корәешкә бер ачлык килгәч, Мөхәммәд галәйһиссәлам Галине, ә Габбас Җәгъфарны Әбү Талибтан тәрбия өчен алган иделәр. Югарыда әйтелгәнчә, Әбү Талиб фәкыйрь бер кеше иде – авт.

2 Зәйд бине Харис, әүвәл Хәдичәнең колы булып, рәсүлуллаһка бүләк итеп бирелгән иде. Бер вакыт Зәйднең атасы һәм якыннары Мәдинәгә килеп рәсүлуллаһтан Зәйдне мал бәрабәренә алмаштырып алмакчы булдылар. Рәсүлуллаһ аларга: “Бик яхшы, әүвәл үзеннән сорыйк, сезне ихтыяр кылса, алып китәрсез, мине ихтыяр кылса, миндә калыр”, – диде. Зәйдкә мәсьәләне сөйләгәч, Зәйд: “Мин Мөхәммәд галәйһиссәламнән башка һичкемне ихтыяр итмәячәкмен. Ул минем атам да, анам да, атамның абыйсы да”, - диде. Ата вә якыннары елап: “Ий Зәйд, хөрриятkә коллыкнымы ихтыяр итәсең?” – диюләренә, Зәйд: “Мөхәммәд галәйһиссәлам янында кол булып тормак хөрriяттән артыктыр”, – дип җавап бирде. Рәсүлуллаһ Зәйднең шулкадәр ихласлыгын белгәч, аны азат итте вә үзенә угыл ясады. Ул вакытларда гарәпләрдә уллыкка алып, аны хакыйкый угыл кебек санау гадәте бар иде. Моннан соң Зәйдкә – Зәйд бине Мөхәммәд дип әйтелде. Соңрак мәшһүр Зәйд һәм Зәйнәб вакыйгасыннан соң үз әтисенә нәсеп итәргә Аллаһыдан әмер килде. Күп кенә тарихчылар Зәйд бине Харисны ирләр арасында иң беренче Ислам кабул иткән зат булуын әйтәләр – авт.



www.darul-kutub.com

ялган ишетмәгән, аның холкын иң югары дәрәҗәдә дип белгәнлектән, рәсүлуллаһ дәгъвәт итә башлаганда ук аңа ышанды. «Ата-анам сиңа йолым булсын, син тугры кешесең. Шәһадәт итәм, Аллаһытан кала башка иләһ юктыр һәм чынлыкта син Аллаһының илчеседер!» – дип, Ислам кабул итеп, дәрәҗәгә иреште.

Мондый бөек вә абруйлы бер затның һич шикләнмичә шунда ук иман китерүе рәсүлуллаһны бик шатландырды һәм киләчәккә өметен арттырды. Гамәлдә дә Әбү Бәкер рәсүлуллаһка зур ярдәмче булды. Аның тырышлыгы аркасында күп кешеләр Исламны кабул итеп, абруйлы булдылар. Шуның өчен рәсүлуллаһ Әбү Бәкерне бик сөя, аңа бөтен серләрен ача һәм һәр эштә аңардан киңәш сорый иде. Рәсүлуллаһ Әбү Бәкер хакында: «Исламга дәгъвәт иткән кешеләр арасында Әбү Бәкер генә Исламны тоткарланмыйча кабул итте, калганнары беркадәр уйланып, шикләнеп кенә кабул иттеләр», – дигәне риваять ителәдер.

## Әбү Бәкер тырышлыгы аркасында Ислам динен кабул итүчеләр

Рәсүлуллаһка әледән-әле вәхи иңеп торды. Рәсүлуллаһ үзе яки Әбү Бәкер сүзләре үтә торган кешеләрне яшерен сурәттә дингә дәгъвәт итә тордылар. Корәеш мөшрикләренең исә аларның эшләреннән хәбәрләре юк иде. Әбү Бәкер тырышлыгы белән Исламга килгән кешеләр шулардыр:

1. Госман бине Гаффан – егерме яшьләрендәге бер егет иде. Атасының абыйсы әл-Хәкәм аның Исламга кергәнен белгәч, иске диненә кайтарырга төрлечә тырышып карады, арканнар белән дә бәйләде. Ләкин Госман: «Теләсәң, мине

үтер, ләкин динемнән кайтачак түгелмен», – дип әйткәч, атасының абыйсы аны үз ихтыярына калдырды.

2. Әз-Зөбәйр бине әл-Гаввәм – яңа балигъ булган бер егет иде. Аның атасының абыйсы да аңа гаять җәфа вә газап кылды: бер җиргә бәйләп куеп, авыз-борынына төтен җибәреп газаплый иде. Ләкин Зөбәйр бу җәфаларга әһәмият бирмәде. Үз динендә нык булып кала бирде.

3. Габдеррахман бине Гауф – җаһилият вакытында исеме Габде Гамр булып, Ислам кабул иткәч рәсүлуллаһ аңа Габдеррахман дип исем бирде.

4. Талха бине Гобәйдулла – насара монахларыннан пәйгамбәрләр турында ишетеп, рисаләт хакында беркадәр мәгълүматы бар иде. Дәгъвәт кылынган нәрсә акылга муафыйкъ вә файдалы булып күренгәч, озак уйламыйча иманга килде.

5. Сәгъд бине Әбү Вәкъкас – аның анасы Хәмнә бинте Әбү Суфиян бине Үмәйя улының Исламга килгәнен белгәч, бик каты кайгырды. Улын чакырып: «Улым, син ата-бабаңның динен ташлагансың дип ишеттем, әгәр ул динеңнән кайтмасаң, миңа ашау, эчү, эссе һәм суыктан яшерену хәрам булсын», – дип нәзер әйтте һәм шул нәзерендә өч көн торды. Сәгъд анасының бу хәлдә булуын күреп, рәсүлуллаһка мәсьәләне җиткерде. Рәсүлуллаһ: «Ата-анага ихтирам, аларга итагать вәҗиб булса да, мондый эштә аларга итәгать тиеш түгел», – дип җавап бирде. «Ганкәбүт» сүрәсендәге 8 аять шул хактадыр: «Без кешегә ата вә анасына карата гүзәл мөгамәләт итәргә әмер бирдек. Әгәр ширеккә дәгъвәт итсәләр, бу очракта аларга итәгать итмәскә боердык».

Болардан башка Исламга кергән шәхесләр арасын-

да Гаммәр бине Йәсир[1] һәм аның анасы Сүмәййә, Сухайб әр-Румий, Габдулла бине Мәсгуд[2], Әбү Зәрр әл-Гыйфәрий, Сәгыйд бине Зәйд әл-Гадәви[3] һәм хатыны Фатыйма бинете әл-Хаттап, Габбас бине Габделмоталлибның хатыны Үммел-Фадл Лүбәбә бинте әл-Харис әл-Һиләлия, Гобәйдә бине әл-Харис бине Габделмоталлиб[4], Әбү Сәлмә Габдулла бине Габделәсәд әл-Мәхзумий[5] һәм хатыны Үмм Сәлмә, Госман бине Мәзгун[6] һәм кардәшләре Кудәмә белән Габдулла, әл-Әркам бине Әбү әл-Әркам әл-Мәхзумий, Халид бине Сәгыйд бине әл-Гас әл-Үмәви һәм кардәше Гамр бине Сәгыйд, Әбү Гобәйдә Гамир бине әл-Җәррах, Әсмә бинте Әбү Бәкер, Хаббәб бине әл-Әратт, Җәгъфәр бине Әбү Талиб һәм хатыны Әсмә бинте Гомәйс[7], Гамир бине Фүһәйра[8] кебек бөек шәхесләр иде.

Ошбу юл белән Мәккә эчендә Исламият әкрен-әкрен таралды. Гарәп мөшрикләре моны белсәләр дә, ул кадәр әһәмият бирмиләр, рәсүлуллаһка бу эштә зур ярдәм күрсәтә

1 Олуг сәхабәләрдән санала. Сыйффин вакыйгасында Гали тарафында шәһид булды. Моның хакында рәсүлуллаһның: “Гаммәр, аны залимнар төркеме үтерер”, – дип алдан ук әйтеп куйганы “Сахих Бохари”да риваять ителәдер. – авт.

2 Олуг сәхабәләрдән, расүлуллаһтан аерылмаган кешеләрдән берсе, Исламның факыйһларыннан булган шәхес. – авт.

3 Олуг сәхабәләрдән берсе. Рәсүлуллаһка килеп, иман китергәннән соң Кәгъбәтуллаһ янында җыелган гарәп мөшрикләренә үзенең динен ачыклап биргәндә мөшрикләр тарафыннан каты кыйналды. Тик Габбасның яклавы белән генә сәламәт калды. – авт.

4 Гобәйдә рәсүлуллаһның әтисенең бертуган кардәше иде. Бәдр сугышында Гутбә бине Рабига белән сугышканда вафат булды – авт.

5 Олуг сәхабәләрдән саналып, Хәбәшәгә һиҗрат кылды. Мәдинәгә һиҗрәт алдыннан вафат булды. Вафатыннан соң рәсүлуллаһ хатыны булган Үмм Сәлмәгә никахланды – авт.

6 Олуг сәхабәләрдән саналып, гадәттән тыш зәһид бер кеше иде.

7 Атаклы сәхабияләрдән булып, күп хәдисләр риваять иткән бер хатын-кыз. Ире Җәгъфәр белән Хәбәшәгә һиҗрат кылып Хайбар сугышы азагында Мәдинәгә кире кайттылар – авт.

8 Бу кеше Әбү Бәкернең колы иде. Һиҗрәт вакытында рәсүлуллаһ һәм Әбү Бәкер белән бергә иде.

www.darul-kutub.com

торган Әбү Бәкергә кагылмыйлар иде. Ислам динен кабул итүчеләр гыйбадәтләрен яшерен кылалар, мөмкин кадәр мөшрикләрнең ачуларын кабартмаска тырышалар, Ислам турында аларга бер сүз дә сөйләмиләр, аларның дошманлашуыннан саклаunion иде.

## Ачык дәгъвәт

Пәйгамбәрлекнең дүртенче елы башларына кадәр дәгъвәт гел яшерен дәвам итте[1]. Исламиятне кабул иткән кешеләр диннәрен мөмкин кадәр мөшрикләргә белдермәскә тырышалар, гыйбадәтләрен дә тау араларына барып, яшерен сурәттә генә кылалар иде. Исламга кергән кешеләрнең саны утызга житеп, рәсүлуллаһның аларга дин вә шәригатьне өйрәтүе зарур булганлыктан, алар әл-Әркам бине Әбү-л-Әркам дигән сәхабә өендә җыелалар иде. Сәхабәләр һәр көн диярлек яшерен төстә шунда җыелып гыйбадәт кылалар, рәсүлуллаһтан дин өйрәнәләр иде. Бу вакытларда мөшрикләр рәсүлуллаһның яңа бер дингә дәгъвәт итеп вә халыкны ияртеп йөрүен беркадәр белсәләр дә, мөселманнар аларның диннәренә тимәгәнлектән, яшерен гыйбадәт кылганнары өчен тавыш чыгармый иделәр. Аллаһы Тәгалә тарафыннан Мөхәммәд галәйһиссәламгә «Хиҗер» сүрәсенең: «Инде хәзер Ислам динен ачык кыл! Кешеләрне иманга вә Коръән белән гәмәл кылырга ачыктан-ачык өндә! Һичкемнән курыкма! Вә мөшрикләрдән кисел, алар белән булышып, вакытыңны әрәм итмә!» – дигән 94 аяте һәм «Шүгарә» сүрәсендәге: «Якыннарыңны Аллаһы газабы белән куркыт!» – дигән 214 аяте иңгәннән соң, рәсүлуллаһ ачык дәгъвәткә ке-

1 Ибне Һишам, 138 б., 1 т. – авт.

реште. Иң беренче үзенең якыннары булган Габдемәннаф ыруларыннан Бәнү Һашим, Бәнү-л-Мотталиб, Бәнү Нәүфәл һәм Габдешшәмсләрне җыеп мәҗлес ясады. Аларга үзенең Аллаһы тарафыннан халыкны, шул исәптән үзенең якыннарын хак дингә чакырырга әмер ителгәнен бәян итте. Әгәр шул дингә иярсәләр дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирешәчәкләрен, юк икән, киресенчә, дөньяда һәм ахирәттә хәсрәттә булачакларын сөйләде. Рәсүлебез аларга шундый сүзләр сөйләгәне риваять ителәдер: «Мин бөтен кешегә ялган сөйләсәм дә, сезгә раид[1] кебек ялган сөйләмәсмен, бөтен кешене алдасам да, сезне алдамасмын. Аллаһы берлә ант итеп әйтәмен ки, мин – гомум халыкка, шулай ук сезгә дә Аллаһының рәсүлемен. Сез йоклаган кебек үләчәксез, уянган кебек кубарылачаксыз, кылган эшләрегезгә хисап бирәчәксез, яхшылыкка яхшылык белән, начарлыкка начарлык белән җәза кылыначаксыз. Сезнең барачак җирегез — я мәңгелек җәннәт, я җәһәннәм булачак. Әй, Габделмоталлиб балалары! Кавеменә мин китергән нәрсәдән артык нәрсә китергән кешене белмим, мин сезгә дөнья вә ахирәт сәгадәте китердем».

Мәҗлестәге халыклар, Әбү Ләһәбтән башкалары, рәсүлуллаһка бик каршы килмәделәр. Әбү Ләһәб исә якыннарын Мөхәммәд галәйһиссәламне бу эшеннән тыярга чакырды. Әгәр тиз арада чарасына керешелмәсә, Корәеш гарәпләре бу эшкә каршы килеп, безнең арада унайсыз хәлләр килеп чыгачак, диде. Моңа каршы Әбү Талиб рәсүлуллаһны үзе үлгәнче яклаячагын сөйләде.

1 Раид – кәрванга төшлек урынын карарга алдан җибәрелгән кеше. Кайбер вакытта илче мәгънәсендә дә килә. – авт.

# Сафа тавында Корәешләрне дәгъвәт кылу

Шуннан соң рәсүлуллаһ барлык Корәеш гарәпләрен дәгъвәт итәргә кереште. Бер көн Сафа тавына менеп, Мәккә халкын чакырды. Тавышны ишеткәч, Мәккә халкы жыела башлады. Үзе чыга алмаган кеше алмашка башканы җибәрде. Халык җыелып беткәч, рәсүлуллаһ аларга: «Әгәр дә мин сезгә бу тау артында атлы гаскәр бар, Мәккәгә һөҗүм итәчәк дип хәбәр бирсәм, сүземә ышаныр идегезме?» – дип сорады. Мәккә гарәпләре: «Әлбәттә, ышаныр идек, чөнки синнән бу көнгә чаклы аз гына ялган да ишеткәнебез юк иде», – дип җавап бирделәр. Рәсүлуллаһ дәвам итте: «Алай булса, мин сезне сын вә потларга гыйбадәт итүегездән тыям, бер Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт итәргә чакырам, әгәр шул батыл динегездә калуны дәвам итсәгез, сезне каты газаб көтәчәк», – диде. Анда җыелган кешеләр рәсүлнең бу сүзләренә артык әһәмият бирмәделәр. «Мөхәммәд шашкан булса кирәк, мондый юк нәрсәләр сөйләмәс иде», – дигән сүзләр әйтеп таралдылар. Халык арасында Әбү Ләһәб тә бар иде, ул рәсүлгә каршы каты-каты сүзләр әйтеп китте.

Рәсүлуллаһ дәгъвәт иткән дин – яратылышка якын, аңлаешлы, кабул итү өчен бик җиңел бер дин булуына карамастан, элек-электән хорафатларга иярү әсире булып килгән, ата-бабаларының юлын изге дип санаган надан гарәпләргә ул бик ят күренде. Пәйгамбәрне һәм аңа ияргән кешеләргә (сәхабәләргә), алар адашкан кешеләр дип карыйлар, аларга төрле мыскыллар яудыралар, форсат булган саен мәсхәрә итәләр иде. Рәсүлуллаһ үтеп барганда: «Бу Әбү Кәбшә улы, ул күктән сөйли яки бу Габделмоталлиб егете, ул күктән

сөйли», – диләр иде. Аны каршыларында очратсалар: «Әле бүген күктән сөйләдеңме?» – дип көләләр иде. Сәхабәләрдән берәрсен күрсәләр: «Сезгә җирнең падишаһы килде», – дип әйтәләр иде.

Соңрак рәсүлуллаһ, сукырларча ата-бабаларына иярүләрен ахмаклык диеп, ата-бабаларын адашканнар[1] дип хөкем итә башлагач, гыйбадәт кылган потларында зарар да, файда да тидерү куәте булмаган һәм башка агач вә ташлардан аермалыклары юклыгын бәян иткәч, Ибраһим динендә дип ышанган хәлдә аңа бөтенләй туры килмәгән юлда икәнлекләрен сөйләгәч, Мәккә мөшрикләре бик нык каршы төштеләр. Ачулары нык кабарган хәлдә, рәсүлуллаһны ничек булса да бу юлдан туктатырга булдылар. Әмма Мөхәммәд галәйһиссәлам Әбү Талиб кебек абруйлы шәех кулы астында булганлыктан, аңа турыдан-туры бәйләнергә мөмкин түгел иде. Шуңа күрә Әбү Талибтан Мөхәммәдне тыюын үтенергә булдылар.

## Мөшрикләрнең Әбү Талиб янына барулары

Моның өчен Корәеш олугларыннан Вәлид бине әл-Могыйра, Әбү Суфиян бине Хәрб, Гутбә бине Рабига, Шәйба бине Рабига, Әбү әл-Бухтәри бине Һишам, Гамр бине

1 Коръәни Кәримдә бу мәгънәдә бик күп аятьләр бардыр: “Аларга: “Аллаһы иңдергән нәрсәгә – Аның Хакыйкатенә туры юл белән һәм үгет-нәсыйхәтләр белән иярегез, – дип әйтелгәч алар, - Юк, без аталарыбыз тапкан нәрсәгә иярәбез”, – дип җавап бирәләр. Әллә шайтан аларны җәһәннәм уты җәзасы юлына китереп, адашуга чакырса да, алар артыннан иярерләрме?”, Локмән/21., “Юк, бөтен дәлилләре беткәч, мөшрикләр: “Дөреслектә, без аталарыбызның билгеле бер ышануга таянуларын белдек һәм без аларга иярәбез, – дип әйттеләр.”, әз-Зухруф/22., “Әгәр бу кяферләргә: “Аллаһы Коръәндә иңдергәннәргә һәм илче сезгә һидаять итеп җиткергәннәргә килегез, – дип әйтсәләр, шунда алар, - Безгә аталарыбызда тапкан нәрсәләр җитәрлек – дип җавап бирәчәкләр. Болай әйтергә ярыймыни? Әгәр аларның аталары, терлек кебек, Аллаһының Хаклыгы турында бер нәрсә белмәсәләр һәм Хаклыкка туры юлны белмәсәләр дә?”, әл-Мәидә/104. – авт.



www.darul-kutub.com

Һишам[1] һәм башкалар Әбү Талибка килеп: «Әй Әбү Талиб, Мөхәммәднең ата-бабасының динен ташлап, халыкны яңа бер дингә дәгъвәт итүен беләсең, без Мөхәммәднең бу эшенә түзә алмыйбыз. Син я Мөхәммәдне бу эшеннән тый, я бу эшне безгә тапшыр», – диделәр. Әбү Талиб аларны йомшак сүзләр белән кайтарып җибәрде, рәсүлуллаһка бу хакта бер сүз сөйләмәде. Рәсүлуллаһ үз юлы белән баруны дәвам итте.

Корәеш башлыкларының Әбү Талибның рәсүлуллаһны тыймавына кәефләре китеп, икенче мәртәбә бардылар: «Әй, Әбү Талиб, син безнең арабызда хөрмәтле аксакаллардансың. Синнән Мөхәммәдне бу эшеннән тыюны үтендек, син кабул итмәдең. Без аның ата-бабаларыбызның юлын мәсхәрә итүенә түзә алмыйбыз, син я Мөхәммәдне бу эштән тыячаксың яки без икегез белән дә сугышачакбыз», – диделәр. Бу башлыкларның янауларыннан соң Әбү Талиб бик нык тәэсирләнеп, рәсүлуллаһны чакырды да: «Әй Мөхәммәд, миңа Корәеш рәисләре шундый сүзләр сөйләделәр, син үзеңне кызган, миңа да күтәрә алмаслык авырлык йөкләмә!» – диде. Рәсүлуллаһ Әбү Талибның бу сүзләреннән, аны үз канаты астыннан чыгарачагын сизеп: «Бу эшне ташлату өчен кояшны уң ягыма, айны сул ягыма китереп куйсалар да, динемне ташлаячак түгелмен, үлгәнче шул юлымнан аерылмаячакмын», – дип җавап биреп, күз яшьләрен агызды. Әбү Талиб рәсүлуллаһның бу сүзләренә шәфкате килеп: «Әй, Мөхәммәд, теләгәнеңне сөйлә, мин сине яклаячакмын!» – диде.

Әбү Талибның Аллаһы илчесен яклавын күреп, мөшрикләр ни эшләргә белмәделәр. Әбү Талиб игътибарлы

1 Кушаматы Әбү-л-Хәкәмдер. Рәсулуллаһны бик нык изалаганга "Әбү Җәһл" дигән кушаматка алмаштырдылар. Һәм мөселманнар арасында бу кеше "Әбү Җәһл" дигән кушамат белән шөһрәт казанды.

www.darul-kutub.com

вә мәрхәмәтле бер шәех булганга, аңа каршы сугыш ачканда, аңа ияргән кабиләләр белән бик канлы сугыш чыгу ихтималы булганлыктан, эшне зурга җибәрмичә, мөмкин кадәр килешү төзеп узарга булдылар. Иң соңгы чара буларак Корәеш башлыкларыннан Вәлид бине әл-Могираның улы Гомәраны[1] Әбү Талибка алып барып: «Әй, Әбү Талиб, бу егет Корәеш егетләренең каймагыдыр. Аны сиңа бирәбез, үзеңә угыл яса, ә алмашка Мөхәммәдне безгә тапшыр. Гомәр Мөхәммәдтән яхшырак!» – диделәр. Әбү Талиб моңа гаҗәпләнеп: «Сез гаҗәп сүз сөйлисез, мин сезнең егетегезне алып ашатыйм, эчертим, тәрбия итим, ә сез аңа алмаш итеп минем улымны үтерәсезме?! Бу булачак эш түгел!» – диде.

Рәсүлуллаһ Корәеш мөшрикләренең дошманлашуларына, мыскыл итүләренә карамыйча, үзенең вазыйфасын башкаруын дәвам итте. Форсат булганда, халык җыелган урыннарга барып, халыкны Исламга чакыра, тәэсирле бер тавышы белән Коръән аятьләрен укый иде. Кирәк булса, хаҗ вакытында яки Миҗәннә, зүл-Мәҗәз, Гокәз базарларында барча халыкны Исламга чакыра иде. Надан һәм мөтәгассиб Корәеш гарәпләре исә рәсүлуллаһка бөтен көчләре белән каршы торалар, базарларга читтән килгән гарәпләргә рәсүлуллаһ сүзләрен тәэсирсез калдырырга тырыштылар. Әмма Ислам әкрен-әкрен булса да тарала иде.

Габдеманнаф балаларыннан Бәнү Һашим (Әбү Ләһәбдән башкасы) Бәнү әл-Мотталиб бу мәсьәләдә Әбү Талиб тарафында булып, Бәнү Габдүшшәмс белән Бәнү Нәүфәл Корәеш гарәпләре тарафында калдылар. Әбү Талиб барлык гарәпләрнең үзләренә каршы дошманлашуларыннан саклану нияте белән тәэсирле касыйдәләр чыгарып, үзләрен Корәеш

1 Ибне Һишам, 14 б.,1т.

гарәпләре тарафыннан хаксыз рәнҗетелүләре турында бәян итә, гарәп башлыкларының күңелләрен табарга тырышты һәм Мөхәммәдне үлгәнче яклаячагын сөйли иде. Ул вакытларда шигырьнең тәэсире бүгенге көндәге иң бөек шәхесләрнең тәэсире кадәр, бәлки аннан да артыграк булгандыр. Бу касыйдәләр гарәпләрне яхшы ук йомшарта иде.

Әбү Талибның рәсүлуллаһны үзенең яклавыннан чыгармыйча, аны үтергән булсалар, кирәк Әбү Талиб, кирәк аңа ияргән бәну Һашим белән Бәнү әл-Мотталиб гарәпләре каршы торачакларын бик яхшы белгән Корәеш гарәпләре, рәсүлуллаһны көч белән туктатырга җөрьәт итмәделәр. Шулай да рәсүлуллаһка аяк чалу, Исламны тараттырмау, рәсүлуллаһка ияргән кешеләрне киметү хосусында мөмкин булган чараларны кылдылар.

Рәсүлуллаһ һәм аның сәхабәләрен төрлечә мәсхәрәләделәр, бигрәк тә яклаучылары булмаган мөселманнарны каты газаплыйлар иде. Рәсүлуллаһка такмаган кушамат, якмаган яла калмады: аны күрәзәче дип тә, сихерче һәм мәҗнүн, сихерләнгән дип тә әйттеләр. Әмма рәсүлуллаһ боларның яла ягуларына әһәмият бирмәде, үзенә әмер ителгән вазыйфасын һәмишә үти барды. Боларның мәсхәрә итүләренә һәм яла ягуларына каршы иңдерелгән Коръән аятьләре белән күңеленә юаныч табып, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кылып, бөтен авырлыкларга карамастан, Исламны таратуын дәвам итте.

## Мүстәһзиүн

Рәсүлуллаһны һәм аның сәхабәләрен иза вә җәфа кылуда бөтен Корәеш гарәпләре катнашкан булсалар да, кайберләре рәсүлуллаһка гадәттән тыш дошманлык кы-

лып, бөтен көч-куәтләрен фәкать аңа каршы килүгә, аны һәм сәхабәләрне газаплауга сарыф итәләр иде. Аларга «Мөстәһзиүн» [мәсхәрә итүчеләр] диделәр. Шушы җәмәгать эчендә иң дошманы Әбү Җәһил бине Һишам иде. Әбү Җәһил рәсүлуллаһка һәрвакыт бәйләнә, бигрәк тә намаз кылу өчен Кәгъбәтуллаһга барса, гыйбадәтенә каршы төшәргә тырыша иде. Бервакыт Әбү Җәһил Корәеш рәисләре белән бергә утырганда: «Мин инде Мөхәммәднең бу эшләренә түзә алмыйм. Иртәгә Мөхәммәд Кәгъбәтуллаһга килеп, намаз укыганда зур таш күтәреп барып, аны изәчәкмен, теләсәгез мине Габдеманнаф балаларына тапшырыгыз, теләсәгез мине яклагыз, мин бу эшне кылачакмын!» – диде.

Чыннан да, иртәгесе көнне рәсүлуллаһ гыйбадәт белән мәшгуль вакытта, зур таш алып, аңа таба китте. Корәеш башлыклары моның ни эшләячәген карап торалар иде. Әбү Җәһил рәсүлуллаһка якынлашкач кына, кинәттән кулындагы ташны ташлап, гадәттән тыш курыккан вә төсе үзгәргән хәлдә кире кайтты. Корәеш мөшрикләре: «Сиңа ни булды, сүзеңдә тормадың?» – дип сорагач, Әбү Җәһил: «Мөхәммәдкә якынлашкач, алдыма бер ата дөя чыгып һөҗүм итте, шунлыктан куркып кире борылдым», – диде.
Рәсүлуллаһ белән Әбү Җәһил арасында булган башка вакыйга да риваять ителәдер: Әбү Җәһилгә бурычка биргән акчасын алачагы булып, озак вакыт ала алмый йөргән бер кеше, Корәеш башлыклары җыелган бер мәҗлескә килеп, Әбү Җәһилдән шикаять итте һәм аңардан хакын алып бирүләрен үтенде. Мәҗлестә булган башлыклар, форсаттан файдаланып, бурыч хуҗасын рәсүлуллаһка җибәрделәр һәм аңа: «Әбү Җәһилдән хакыңны алып бирергә без вәкаләтле түгелбез. Син Мөхәммәд галәйһиссәламгә бар, ул абруйлы,

сүзе үтемле кеше, ул алып бирер!» – диделәр. Максатлары рәсүлуллаһны Әбү Җәһилдән сүктерү иде. Бурыч хуҗасы рәсүлуллаһка килеп, ярдәм итүне сорагач, рәсүлуллаһ бер сүз әйтмичә, шул кеше белән бергә Әбү Җәһилгә барып капкасын дөмбердәтте. Ишек тавышына төсләре качкан Әбү Җәһил чыкты. Рәсүлуллаһ Әбү Җәһилне күргәч, әмер иткән бер сурәттә: «Моның хакын тиз бирәчәксең!» – диде. Әбү Җәһил исә тиз арада чыгарып бирде.

Мәсхәрә итәргә тырышучыларның берсе Әбү Ләһәб иде. Әбү Ләһәб рәсүлуллаһның атасының абыйсы булган хәлдә, башка кешеләргә караганда да күбрәк дошман иде. Ул рәсүлуллаһның күршесе булганлыктан, һәрвакыт аның ишеген пычрак белән буяп китә иде. Рәсүлуллаһ шикаять итә калса, төрле каты сүзләр белән каршы чыга иде. Әбү Ләһәбнең хатыны Үммү Җәмил бинте Хәрб та ире кебек, рәсүлуллаһның иң зур дошманы булып, хатын-кыз мәҗлесләрендә аның хакында төрле-төрле ялган сүзләр сөйли иде. Болар хакында «Тәббәт» сүрәсе иңгәч, бигрәк тә дошманлыкларын арттырдылар.

Мөстәһзиүннәрдән өченчесе – Гокбә бине Әбү Мигъят, ул да Әбү Ләһәб кебек рәсүлуллаһның күршесе иде. Ул да рәсүлуллаһның ишекләрен пычрак белән буяп бетерә, аны күргән саен мәсхәрә кыла, каты сүзләр әйтә иде. Беркөн рәсүлуллаһ Кәгъбә янында гыйбадәт кылганда, Гокбә бине Әбү Мигъят аны киеме белән бик каты буды. Кәгъбә тирәсендә сәхабәләр булсалар да, рәсүлуллаһны коткарырга җөрьәт итә алмадылар. Шулвакыт Әбү Бәкер килеп житеп, рәсүлуллаһны аерып алды.

Икенче вакыт пәйгамбәребез Кәгъбатуллаһта намаз укыганда Гокбә бине Әбү Мигъят Әбү Жәһилнең ишарәсе

белән яңа суелган дөя карыннарын китереп, сәждә вакытында рәсүлнең аркасына салды. Сәхабәләрдән һичберсе бу пычракны алып ташларга батырчылык итмәде. Рәсүлуллаһ һаман сәждәдә кала бирде. Ниһаять, хазрәти  Фатыйма туры килеп атасының аркасыннан карын вә эчәкләрне алып ташлый. Рәсүлуллаһ сәждәдән торгач, шушы башлыкларның исемнәрен атап дога кылганлыгы риваять ителәдер. Гокбә рәсүлуллаһның йөзенә төкерү, чигәсенә сугу кебек түбәнчелекле эшләрдән дә тартынмый иде.

Мөстаһзиүннән тагын берсе Вәлид бине әл-Мугира иде. Вәлид Корәеш кабиләсенең бөекләренә вә байларына сүзе үтемле кеше иде. Бервакыт рәсүлуллаһтан Коръән сүзе ишетеп, гадәттән тыш әсәрләнде вә үзенең тәэсирен кавеме Ибне Мәхзүмгә сөйләде: «Мин Мөхәммәдтән бер сүз ишеттем, ул сүз кеше сүзе дә, җен сүзе дә булырга ошамый. Мөхәммәднең бу эше бервакыт алга чыгачак», – диде. Вәлиднең якыннары аның бу сүзеннән соң Ислам диненә чыгуыннан куркып хәйран калдылар. Вакыйганы ишеткән Әбү Җәһил аның янына барып, каты сүзләр сөйләде. Вәлид бине әл-Мугира кызып китеп: «Сез Мөхәммәдне мәҗнүн дисез, аның мәҗнүнгә охшаган берәр эшен күргәнегез бармы? Аны кәһин[1] дисез, аның багучылык кылганын күргәнегез бармы? Аны шагыйрь дисез, аның шигырь белән шөгыльләнгәнен ишеткәнегез, күргәнегез бармы?» – диде. Моңа җавап итеп һәркайсы: «Юк», – дип тордылар. Соңрак: «Соң аның хакында фикерегез нәрсә?» – диделәр. Вәлид беркадәр уйлап торганнан соң: «Мөхәммәд – сихерче ул. Күрмисезме, ул ир белән хатын, бала белән ата арасын аерып бетерде», – диде. Вәлид бине әл-Мугира хакында «Мөддәссир» сүрәсендәге:

1 Кәһин – багучы. – тәрҗ.

«ذَرْنِي وَمَنْ خَلَقْتُ وَحِيدًا {المدثر/11} — سَأُصْلِيهِ سَقَرَ {المدثر/26}»

аяте һәм «Нун» сүрәсендәге:

«وَلَا تُطِعْ كُلَّ حَلَّافٍ مَّهِينٍ {القلم/10} — سَنَسِمُهُ عَلَى الْخُرْطُومِ {القلم/16}»

аяте иңдерелде диелә. Бу риваятьнең Вәлид кебек кешеләр турында икәнлеге шөбһәсездер.

Моннан башка әл-Әсвәд бине Габде Ягус, әл-Гас бине Вәил, әл-Әсвәд бине әл-Мутталиб, Назр бине әл-Харис кебекләр рәсүлуллаһны вә хөрмәтле сәхабәләрне мәсхәрәләүдә алга киткән кешеләрдер. Аллаһ Тәгаләнең болар турында башта «Хиҗер» сүрәсендәге:

«إِنَّا كَفَيْنَاكَ الْمُسْتَهْزِئِينَ الَّذِينَ يَجْعَلُونَ مَعَ اللَّهِ إِلَهًا آخَرَ فَسَوْفَ يَعْلَمُونَ»[1]

аятенең тәэвиле килде. Болардан бик күбесе Бәдер сугышында үтерелделәр, бәгъзеләре төрле авыруларга дучар булып үлделәр.

Корәеш гарәпләре рәсүлуллаһны иза һәм җәфа кылганнары шикелле сәхабәләрне дә гаять каты изалыйлар иде. Бигрәк тә якыннарыннан якларлык дәрәҗә һәм куәт иясе булмаган сәхабәләрне төрле газапларга дучар иттеләр. Мәккә мөшрикләренең аларны газаплаулары диннәреннән кире кайтару өчен иде. Ләкин хаклыкны бер тапкан кеше, аңардан кире кайтырмы? Вөҗдан канәгать булган бер нәрсәне мыскыл һәм мәсхәрә кылу яисә җимерү һәм газаплау белән генә тар-

1 «Сине һәм сәхабәләреңне мәсхәрә итүче мөшрикләрнең эшен без үзебез күрәчәкбез. Алар эшләренең нәтиҗәсе яман булганлыгын тиз арада белерләр» – авт.

www.darulkutub.com

тып алып булырмы? Хөрмәтле сәхабәләрнең рәсүлуллаһка иярүләре дөньяви мәртәбәләргә һәм дәрәҗәләргә ирешү яисә мал һәм милек хасил итү өчен түгел иде. Аларның бәла һәм җәфаларга дучар булулары сайлаган юлларыннандыр. Аларның рәсүлуллаһка иярүләре – Ислам динен кабул итүләре, аның хаклыгына иман китерүләре, аңардан дөнья вә ахирәт бәхетенә өметләнүләре иде. Бер мәртәбә хакыйкать шәрабын эчүгә ирешкән кеше батылга, әлбәттә, күчмәс. Гасырлар буенча таш вә агачларга гыйбадәт итеп, Лат, Мәнәт, Гоззә, Һөбәл кебек кулдан ясалган нәрсәләрнең файда бирүләренә, зарар тидерүләренә иман китерү кебек ахмаклыктан котылган кешеләр яңадан шул ахмаклыкка кире кайтырлармы? Менә шуның өчен дә мөшрикләрнең иза һәм золым итүләре аларга тәэсир итмәде, алар үз игътикадларыннан кире кайтмадылар, киресенчә, иманнарының куәтләнүенә генә сәбәпче булдылар. Әйтелгән кыенлыкларга чыдаулары, бәла-казаларга әһәмият бирмәүләре сәбәпле, бервакыт Аллаһы Тәгаләнең шатландыруына лаеклы булып, дөньяда имамнар һәм варислар булдылар[1].

## Газапка дучар булган сәхабәләр

**1. Биләл бине Рабах**. Биләл Умәйя бине Халәфнең колы иде. Үмәйя аны муенына бау тагып, балаларга бирә, ә балалар аны ат итеп уйнап йөриләр һәм аның аларга каршы килергә хакы юк иде. Умәйя аны көн үзәгендә эссе комга алып чыгып яткырып, күкрәгенә зур таш куйдыра иде һәм аңа: «Я шул хәлдә үләчәксең, яисә Мөхәммәдне кире кагып

1 “Без, җирдә түбәнсетелгәннәргә рәхмәт теләп, аларны имамнар һәм варислар иттек.” “әл-Касас”, 5. – авт.

Лат һәм Гоззәгә гыйбадәт итәчәксең!» – дип әйтә иде. Билал моңа: «Әхәд, Әхәд»[1] сүзеннән башка җавап кайтармый иде.

Бервакыт шул рәвешле газап чигеп ятканда яныннан Әбү Бәкер үтте. Үмәйянең шушындый каты мөгамәләсенә түзә алмыйча: «Әй, Үмәйя! Кайчанга кадәр бу мескенне газаплаячаксың инде, Аллаһытан бер дә курыкмыйсыңмыни?» – диде. Үмәйя моңа җавап итеп: «Аны син наздырдың, җәлләсәң, сатып алып коткар», – диде. Һәм Әбү Бәкер Биләлне сатып алып азат итте[2].

Әбү Бәкернең моннан башка да газаптан коткару өчен сатып алып азат иткән кешеләре бар. Биләлнең анасы Хәмәмә, Гамир бине Фүһәйра, Әбү Фүкәйһә, Зәннизә, Үмм Губәйс[3] – боларның барчасын да Әбү Бәкер азат иткән. Гамир бине Фүһәйра шул дәрәҗәдә газап кылына иде ки, чыдый алмаганнан, ни сөйләгәнен белми иде. Зәннизә дә гадәттән тыш каты газап күрде. Хәтта газап астында күзләре дә сукырайды. Ләкин һаман да иманында кала бирде.

Әбү Җәһил шул кешеләрне кимсетеп: «Мөхәммәднең диненә гаҗәпләнмәслек түгел. Мөхәммәднең дине хак булса, бу кешеләрдән элек аңа иярер идек. Хакыйкатьне вә тугрылыкны бездән узып, Зәннизәме инде таба?» – дип әйтә иде һәм моның белән пәйгамбәрлекне дә сүгеп маташа иде. Ул нәрсәгәдер иярген кешеләрнең мал һәм милек хуҗалары, дәрәҗә һәм мәртәбә иясе булмауларын, шул нәрсәнең батыл булганлыгына дәлил итеп карый иде. Әмма Әбү Җәһил моны белмәслек кеше түгел иде. Ул хаталы нәтиҗәләр

1 Аллаһы бердер, Аллаһы бердер. – авт.

2 Мофассирләр, "әл-Ләйл" сүрәсендәге 14-20 аятьләрне шушы вакыйгадагы Әбү Бәкер белән Үмәйя хакында иңдерелде диләр. – авт.

3 Кайберләр моны "нун" белән билгелиләр, ә Ибн Хәҗәр "Исабә"сендә "бә" белән билгели. 257-258 б. – авт.

ясый, тәкәбберлегенә һәм горурлыгына сыймыйча, үзенең дәрәҗәсен һәм сүзенең үтемлелеген рәсүлгә каршы куллана иде. Һәм моның белән табигатен һәм яраклылыгын боза, бөек нигъмәтләрдән булган акылын көфрана кыла һәм аны яман эшләрдә куллана иде[1].

Аллаһы юлында газап кылынган кешеләрнең берсе Гаммәр бине Ясир, аның әтисе, әнисе вә кардәше иде. Рәсүлуллаһ боларның газап кылынган вакытларында үткәндә: «Әй, Ясир гаиләсе, сабыр итегез! Сезнең барачак урыныгыз – җәннәттер! Әй, Раббым, Ясир гаиләсенең гөнаһларын гафу ит», – дип әйтә иде.

Гаммәрнең атасы вә анасы газап астында вафат булдылар. Гаммәр исә, газапка түзә алмыйча, тыштан гына көферлек сүзен әйтте. Сәхабәләр моны ишеткәч рәсүлуллаһка: «Гаммәр диненнән чыкты бит», – диделәр. Рәсүлуллаһ боларга: «Юк, Гаммәр башыннан аягына чаклы иман белән тулы», – диде[2].

Хаббәб бине әл-Әрат шулай ук каты газап кылына иде. Ул җаһилият вакытында әсирлеккә алынган бер тимерче иде. Рәсүлуллаһ пәйгамбәрлеккә хәтле үк һәрвакыт аның янына барып, аны якын итә иде. Соңыннан пәйгамбәрлек килгәч, Хаббәб рәсүлуллаһка иярде. Аның хуҗабикәсе кызган тимер белән аркасына баса иде. Бер мәртәбә Хаббәб рәсүлуллаһ янына барып, күргән зәхмәтләреннән зарланды һәм Аллаһы

1 Аллаһы Тәгалә “Әхкаф сүрәсендә” Әбү Җәһил кебек тәкәбберләр турында сөйләп, аларны куркытып әйтәдер: “Иман китермәгәннәр мөэминнәргә әйттеләр: “Әгәр дә бу хәерле булса, алар бездән бу эштә алдан булмаслар иде”. һәм алар аңа иярмәделәр һәм шуңа күрә алар әйттеләр: “Бу – искедән калган ялган сүздер.” 11 аять. – авт.

2 Бу мөнәсәбәт белән Аллаһы Тәгалә мөртәт хакында: “Берәү иман китереп, мөселман булганнан соң Аллаһыга кәфер булса, аңа җәһәннәм газабы тиешле булды. Мәгәр кәферләр көфер сүзне көчләп әйттерсәләр, шул вакытта күңеле иман белән карарланган булса, ул кешенең иманына зарар килмәс. Әмма күңелләре көфергә риза булып, хуш күңел белән көфер сүзен әйтсәләр, аларга Аллаһының ачуыдыр һәм аларга ахирәттә олы газап булыр”. 106 аять. – авт.

илчесеннән бу хакта дога кылуын үтенде. Рәсүлебез моңа каты кызып: «Сездән элекке кавемнәрнең күргән газаплары болай гына түгел иде. Алардан кайберләренең тәннәрен тимер тараклар белән тараганнар, хәтта башларыннан аякларына кадәр пычкы белән кисеп чыга торган булганнар. Шул вакытта да алар үз диннәреннән кайтмаганнар. Исламият бервакыт, әлбәттә, куәт табачак, куркынычлар бетәчәк, иминлек таралачак һәм ялгыз кешегә Сангадан Хадрамәүткә чаклы хәвефсез йөрү мөмкин булачак», – диде. Чыннан да, Аллаһы илчесенең сүзе туры килде һәм бервакыт Гарәп ярымутравы иминлек вә гаделлек мәркәзе булды.

Корәеш гарәпләренең җәфаларыннан Әбү Бәкер кебек иң саф күңелле бер хөрмәтле зат та котыла алмады. Аны изалауларының сәбәбе, әлбәттә, рәсүлуллаһка ярдәмче булуы һәм бик күп кешеләрне үзенә ияртүе иде. Әбү Бәкер Корәешләрнең изалаулары куәт ала башлагач, Хәбәшәгә күченү нияте белән чыгып китте. «Бәркүлгыймәд» дигән җиргә җиткәндә, Карә кабиләсенең рәисе Ибн әд-Дәгыйннә моны күреп: «Әбү Бәкер, кая барасың?» – диде. Әбү Бәкер җавабында Корәешнең изасына түзә алмыйча, Хәбәшәгә күченүен сөйләде. Ибн әд-Дәгыйннә аңа: «Әй, Әбү Бәкер, син куылырга тиешле кеше түгел, син туганнарыңа карата рәхимле, фәкыйрьләргә вә ятимнәргә, бәла-каза күргән кешегә ярдәм итәсең һәм кунакчыл да үзең. Мин сине үземнең кул астына алачакмын, әйдә Мәккәгә кайтыйк», – дип, кире Мәккәгә алып китте. Ибн әд-Дәгыйннә Мәккәгә килгәч, Корәешнең дәрәҗәле башлыкларын берәм-берәм күреп, Әбү Бәкерне үз канаты астына алганын белгертте. Ибн әд-Дәгыйннә бөек бер адәм булганга, Мәккә мөшрикләре аңа каршы килә алмадылар. Ләкин Әбү Бәкергә өендә генә гыйбадәт итәргә, Коръәнне

ачык укымаска, үзе генә укырга куштылар. Әбү Бәкер башта шул шартларны үтәсә дә, соңрак йортына бер мәчет кебек бина салып, шунда гыйбадәт кыла вә Коръән укый башлады. Әбү Бәкер Коръәнне гаять тәэсирле итеп укый һәм тәэсирдән елый иде. Мөшрикләрнең хатын һәм бала-чагалары килеп, Әбү Бәкерне тыңлый иделәр. Мөшрикләр моны күреп куркыштылар. Ибн әд-Дәгыйннә янына барып, Әбү Бәкер хакында шикаять иттеләр. Ибн әд-Дәгыйннә моңа: «Я тиешле шарт буенча укы яисә химаямне кире кайтар», – диде. Әбү Бәкер: «Мин Аллаһының химаясенә разыймын», – дип, аның химаясеннән чыкты. Изаланган кешеләр болар гына түгел иде. Ләкин алар күргән газаплар гаять дәрәҗәдә каты иде[1].

## Хәмзәнең Исламиятне кабул итүе

Мәккә мөшрикләренең рәсүлуллаһка ифрат дәрәҗәдә изалаулары, аңа җәбер һәм җәфа кылулары Хәмзәнең Ислам кабул итүенә сәбәп булды. Бер көн Әбү Җәһил бине Һишам рәсүлуллаһны бик пычрак сүзләр белән сүкте. Рәсүлуллаһ аңа каршы һичбер җавап бирмичә торды. Бу вакыйганы күргән бер хатын Хәмзәгә сөйләде. Хәмзә исә якларга дип, Кәгъбатуллаһка килде һәм күп кешеләр каршында Әбү Җәһилнең башына җәрәхәтләнгәнче сукты вә аңа: «Мин аның динендә булган вакытта, син ничек Мөхәммәдне шулай мәсхәрә итәргә батырчылык иттең?» – диде. Кайбер кешеләр Әбү Җәһилне яклап, Хәмзәгә һөҗүм итмәкче булсалар да, Әбү Җәһил Хәмзәнең Исламга килүеннән куркып: «Тукта-

1 Аллаһы Тәгалә шушы изаланган затлар хакында “Ганкәбүт” сүрәсендә әйтәдер: "Әллә кешеләр иман китердек дигәннәреннән соң төрле авырлыклар белән Аллаһы тарафыннан имтихан ителмәбез, дип уйлыйлармы? Тәхкыйк болардан элек тә төрле сыйныф кешеләрен бәла-каза һәм авыр мәшәкатьләр белән сынап карадык, әлбәттә, Аллаһы белер, кемнең иманы хак һәм кемнеке ялган икәнлеген!" 1-3 аятьләр.

гыз, Хәмзәнең миңа сугарга хакы бар, мин аның абыйсының улын кабәхәт сүзләр белән сүктем», – диде.

Шушы вакыйгадан соң Хәмзә Ислам кабул итүе белән шәрифлеккә ирешеп, Исламияткә иң күп хезмәт иткән кешеләрдән булып китте. Хәмзәнең Исламга керүенә Мәккә мөшрикләре бик нык кайгырдылар. Аннан соң пәйгамбәребезгә каршы мөшрикләр тарафыннан һөҗүмнәр берникадәр кими төште. Хәмзә Корәеш эчендә игътибарга лаеклы бер баһадир кеше иде.

## Могҗиза китерүне сорау

Рәсүлуллаһ мәккәлеләрнең иза вә җәфа кылуларына карамастан, үз өстенә йөкләнгән вазыйфасын үтәүне дәвам итте. Ул берсе артыннан берсе иңеп торган Коръәни Кәрим аятьләрен, теләсәләр дә теләмәсәләр дә, боларның мәҗлесләренә килеп укый иде. Коръәни Кәрим аларны төрле юллар белән тәүхидкә[1], кыямәт көненә ышанырга, изге гамәлләр кылырга, потларын ташларга һәм аларны арадашчы итеп куймаска, араларында таралган начар гадәт һәм әхлактан арынырга чакыра иде, төрле дәлилләр белән Мөхәммәд галәйһиссәлам пәйгамбәрлеген исбат итә иде. Кайбер вакытта турыдан-туры кисәтүләр яудыра иде. Матур сөйләмнең иң югары дәрәҗәсендә булган Коръәни Кәрим матур сөйләмгә сәләтләре булган гарәпләргә гадәттән тыш нык тәэсир итә иде. Алар моңа каршы ни эшләргә дә белмиләр иде. Рәсүлуллаһка мәҗнүн, кәһин, шагыйрь, сихерче кебек ифтиралар әйтсәләр дә, бу үзләрен алдау яки үзләрен юату гына иде. Чөнки мәҗнүннән андый сүзләр чыга алмаганын, кәһиннәрнең дә күрәзәлек кылу кебек нәрсәләр генә

1 Тәүхид – бер Аллаһыга гына иман китерү – авт.

булганлыгын, Мөхәммәд галәйһиссәлам моңа кадәр асылда шигырь белән шөгыльләнмәгәнгә, кинәт шагыйрь була алмаганын, аның өстенә Коръәннең шигырьгә бер дә охшамаганлыгын һәм чагыштырып та булмаслык өстен икәнлеген алар бик яхшы беләләр иде.

Алар рәсүлуллаһны бигрәк тә сихерче диделәр. Китергән дәлилләре дә атадан баланы, баладан атаны аерып алып, үзенә ияртүе иде. Ләкин бу да күз буяу гына, моңа каршы башка юл таба алмаганлыктан гына мәҗбүри әйтелә иде. Аның сихер түгеллеген дә алар бик яхшы беләләр иде.

Гарәпләр рәсүлуллаһның фәрештә булмыйча, үзләре кебек бер кеше булып, аның базарларда сәүдә итеп йөрүен, ашау-эчүен пәйгамбәрлеккә шөбһә итеп китерәләр иде[1].

Ләкин бу да ни әйтергә белмәгәннән генә әйтелгән сүзләр иде. Чөнки алар үзләре үк кайбер вакыт: «Бу Коръән зуррак бер кешегә килгән булса, без аны кабул итәр идек», – дип тә әйтәләр иде[2].

Нәтиҗәдә гарәпләр, Коръәни Кәримгә карата бик нык аптыраашта калдылар һәм алар башларына ни килсә шуны әйтәләр иде. Мәсәлән, Коръән ул әүвәлгеләрдән калган әкиятләр, Мөхәммәд аны башкалардан өйрәнде дип тә әйтә иделәр[3].
Коръәни Кәрим боларның шушы шөбһәләрен төрле-төрле

---

1 “Һәм алар әйттеләр: “Бу нинди рәсүл? Ул ризык ашый, базарларга йөри...” әл-Фуркан/7. – авт.

2 "Һәм алар тагы әйттеләр: “Ни өчен бу Коръән ике шәһәрнең олуг бер ир-атына иңдерелмәде?” – дип” Әз-Зухруф/31. Тәфсир кылучы галимнәрнең сүзләренә карап,бу ике шәһәр Мәккә белән Таиф булыр, ә олуг кешене Вәлид бине әл-Мугыйра белән Гарвә бине Мәсгуд әс-Сәкафиләрдер. – авт.

3 “Имансызлар әйттеләр: “Бу – башка кавемнәр ярдәмендә уйлап кына чыгарган алдау”. Чынлыкта исә, алар золымлык кылалар һәм ялганлыйлар” Әл-Фуркан/4.

“Тәхкыйк, без беләбез: “Чынлыкта исә, аны кеше генә өйрәтә.” Алар ишарә иткән тел – чит телдер. Ә бу – аңлаешлы булган гарәп теледер” Ән-Нәхл/103.

“Һәм алар әйттеләр: “Ул – әүвәлге өммәтләрнең уйдырмасыдыр. Ул аны күчереп яздырды һәм аңа иртәләрен һәм кичләрен укыйлардыр” Әл-Фуркан/5. – авт.

ысуллар белән инкарь итә, рәсүл булу өчен фәрештә булу кирәк түгеллеген, фәрештә рәсүл итеп җибәрелгәндә дә, кеше сурәтендә булуы зарури булып, һаман шул ук шөбһәләрне китерәчәкләрен, Мөхәммәд салаллаһу галәйһи вәссәламнән башка илчеләр дә аның кебек кеше булып, ашый, эчә, базарларга йөри торганлыкларын, рәсүл булу өчен дәрәҗәле һәм мәртәбәле булу шарт түгеллеген сөйли, рәсүлуллаһның пәйгамбәрлеген исбат итү өчен Коръәни Кәримне дәлил итеп тотарга, аларны шул Коръән белән чакырырга, Коръән кебек бер сүрә, ниһаять, бер генә аять китерүләрен сорарга әмер итә иде һәм китерә алмаячакларын алдан ук әйтеп куярга куша иде. Бәкара сүрәсенең 23 һәм 24 аятьләрендә килгән:

وَإِن كُنتُمْ فِي رَيْبٍ مِّمَّا نَزَّلْنَا عَلَى عَبْدِنَا فَأْتُواْ بِسُورَةٍ مِّن مِّثْلِهِ وَادْعُواْ شُهَدَاءكُم مِّن دُونِ اللّهِ إِنْ كُنْتُمْ صَادِقِينَ {البقرة/23}
فَإِن لَّمْ تَفْعَلُواْ وَلَن تَفْعَلُواْ فَاتَّقُواْ النَّارَ الَّتِي وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ أُعِدَّتْ لِلْكَافِرِينَ {البقرة/24}[1]

кебек каршы чыккан аятьләр берничә җирдә бардыр.

Ләкин бу вакытларда гарәпләр әдәбиятта бик каты алга киткән, матур сөйләмдә алдынгылардан булган, араларында авызларыннан ут чәчә торган хатиблар, акылны үзенә буйсындыра торган шагыйрьләре була торып, Коръән шикелле китап яза алмадылар, гажиз калдылар. Тик җавапсыз калмас өчен:

«لَوْ نَشَاءُ لَقُلْنَا مِثْلَ هَذَا إِنْ هَذَا إِلَّا أَسَاطِيرُ الْأَوَّلِينَ»

1 Әгәр Коръәннең Мөхәммәдкә безнең тарафтан иңдерелгәненә шикләнсәгез, шул Коръән кебек бер сүрә китерегез, бу хакта теләгән кешеләрегездән ярдәм дә сорагыз. Әгәр дә бу эшне кыла алмасагыз, кәферләргә әзерләнгән газаптан куркыгыз. Ләкин бу эшне сез асылда ук кыла алмассыз.» Һәм моның мәънәсендәге аятьләр: «Һуд»/13,38., «Тур»/34., «Исра»/88. – авт.

– дип әйттеләр[1]. Шунлыктан алар Коръәннең кеше сүзе булмыйча, Аллаһ сүзе икәнен белсәләр дә, инкарь һәм карышу юлына кереп, рәсүлуллаһның пәйгамбәрлеген кабул итмәделәр. Ялгыз хакыйкать күзе белән карый торган акыл ияләре әкрен-әкрен генә Исламга керә тордылар. Әмма күпчелек әүвәлге юлларында дәвам итеп, кирелек, тәкәбберлек белән каршы киләләр иде.

Корәеш гарәпләре рәсүлуллаһны һәм күркәм сәхабәләрне рәнҗетү һәм газаплау белән генә диннән чыгара алмаганнарын аңлап, киресенчә, бу эшләр Ислам әһелләренең дингә карата мөнәсәбәтләрен тагы да ныгытканыннан, эшне икенче юл белән йөртмәкче булдылар. Бу хакта бер киңәш мәҗлесе ясап, Гутбә бине Рабиганың фикере белән Мөхәммәд галәйһиссәламне яңа дин оештырудан туктатыр өчен түбәндәге мәсьәләләрне ачыкларга булдылар:

1. Мөхәммәднең бу эштә максаты мал җыю булса, аңа мал җыеп бирергә;

2. Әгәр сәид буласы килсә, аны сәид итеп куярга, аңардан башка һичбер мәсьәләне хәл кылмаска;

3. Әгәр патша буласы килсә, үзләренә патша ясарга;

4. Әгәр бу эш җен кагылу кебек берәр сәбәптән килсә, аны табиблар чакырып дәваларга.

Ошбу мәсьәләне ачыклар өчен, Гутбә бине Рабиганы җибәрделәр. Гутбә рәсүлуллаһка барып: «Әй, Мөхәммәд, син безнең арада хөрмәтле бер кеше идең, син бу эшең белән кавемеңнең арасын боздың, аларны бер-берсеннән аердың, аларның акылларын ахмаклыкка чыгардың, потларын кимсеттең, ата-бабаларын томаналык һәм адашуда

1 «Бу – борынгылар хакындагы әкиятләрдән гыйбарәт. Без теләсәк, моның кебек нәрсәләрне сөйләр иде, әмма теләмибез генә».



www.darul-kutub.com

гаепләдең, синең бу эшеңнең максаты нәрсә? Әгәр максатың мал җыю булса...» – диде. Гутбә сүзен сөйләп бетергәч, рәсүлуллаһ: «Инде сүзең беттеме? Моны миннән ишет инде!» – дип, «Фуссиләт» сүрәсенең башыннан берничә аять укыды. Бик аңлаешлы һәм гаҗәп Коръән аятьләрен ишетеп, Гутбә бик нык тәэсирләнде. Чыдый алмыйча, рәсүлуллаһның авызыннан тотып туктатты. Соңра кавеменә кайтып, ошбу сүзләр сөйләде: «Мин Мөхәммәдтән шундый сүзләр ишеттем, аның шикелле сүзләрне гомеремдә ишеткәнем юк иде. Ул шигырь дә, багучылык, күрәзәчелек тә, сихер дә түгел. Мин сездән Мөхәммәдне үз юлына куюыгызны, аны изаламавыгызны үтенәм! Әгәр Мөхәммәд өскә чыкса, ул сезнең өчен бик шәриф булачак. Әгәр башка кабиләләр кулы белән җиңелсә, мәшәкатьсез сез аннан котыласыз!» – диде.

Гутбәнең бу сүзләрен ишеткәч, мөшрикләр: «Мөхәммәд сине дә сихерләгән икән», – диделәр. Аларга каршы Гутбә: «Бу – минем үземнең шәхси фикерем, кабул итсәгез – итегез, итмәсәгез – итмәгез», – диде.

## Коръәннән үзләренә ошамаган сүзләрне алып ташлауны үтенүләре

Моннан соң Корәеш гарәпләре Мөхәммәд галәйһиссәламнән сүзләрен йомшартуны, Коръәндәге сыннарны яманлаган, потларын кимсеткән, газап белән куркыткан аятьләрне чыгаруны, шулай ук аларга ачуларын китерә торган, нәфрәтләрен арттыра торган аятьләрне укымауларын үтенделәр. Әмма бу таләпләренең барысы да буш бер нәрсә иде. Чөнки Коръән рәсүлуллаһның үзе тарафыннан әйтелгән бер сүз булмыйча, Аллаһы Тәгалә тарафыннан

иңдерелгән иде. Рәсүлуллаһ моны җиткерергә мәҗбүр булган хәлдә һәм шуңа нигезләнеп, аны үзгәртүе мөмкин түгел иде. Шуңа күрә дә моңа каршы Аллаһы Тәгалә рәсүлуллаһка аларга ошбу сүзләр белән җавап бирергә әмер итте: «Син аларга әйт: «Үзлегемнән аны (Коръәнне) алыштыру миңа мөмкин түгел. Мин бары тик миңа иңгән вәхи артыннан гына иярәм...» «Юнус»/15, һәм «Әгәр ул (Мөхәммәд галәйһиссәлам) без әйтмәгән бәгъзе сүзне Аллаһыдан дип, ялганлап сөйләсә, әлбәттә, без аны каты тоту илә тотар идек. Соңрак аның йөрәк тамырларын кисеп алыр идек» «әл-Хәкка»/44-46.

Рәсүлуллаһ белән һичничек килешү мөмкин булмагач, җәбер вә изалау белән дә аны туктатырга тырышу нәтиҗәсез булгач, аңардан үзенең рәсүлуллаһ икәнлегенә дәлил итеп, могҗизалар күрсәтүен сорадылар. Алар: «Мөхәммәд, син әгәр пәйгамбәр булсаң, башка пәйгамбәрләр кебек дәлилләр һәм могҗизалар китер, без синең бу Коръәнеңә генә ышана алмыйбыз», – диделәр. Боларның нәрсәләр һәм нинди юллар белән таләп иткәнлекләре Коръәни Кәримдә бик күп сүрәләрдә искә алына. Алар рәсүлдән Гарәбстан сахраларында чишмәләр агызуын, эчләрендә елгалар агып яткан хөрмә һәм йөзем бакчаларын булдыруын, үзенә алтын вә көмеш өйләр булдыруын, Хиҗаз тауларын күтәреп ташлап, җирне тигез итеп ясавын, күккә менеп, үзенең пәйгамбәрлеге хакында язу алып төшүен, фәрештәләр алып килеп, үзенең рәсүллеген тәсдыйкъ итүен, Кусай бине Күләб кебек бабаларын терелтеп, шулардан пәйгамбәрлеген исбатлатуын һәм моннан башка да күп нәрсәләр сорадылар[1]. Әмма боларның

1 Могҗизалар таләп иткән турындагы аятьләр: "Ганкәбүт"/50-51, "әл-Фуркан"/7-8, "әл-Хиҗр"/7-8, 14-15, "әр-Рагъд"/7, 13, "Юнус"/20, "әл-Әнгам"/8-9, 37, 111, 124, "әл-Әнбия"/5, "әл-Исра"/91-93. – авт.

могҗизалар таләп итүләре Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә китергән дәлилләренә канәгать хасил итмәгәннән булмыйча, бары тик үзләренең кирелегеннән һәм рәсүлуллаһны җавапсыз калдырырга тырышудан гына иде һәм могҗизалар күрсәтелгәндә дә кабул итмәячәкләр иде. Шуның өчен Аллаһы Тәгалә боларга сораган нәрсәләрен бирмәде, ә киресенчә:

«...قُلْ سُبْحَانَ رَبِّي هَلْ كُنتُ إَلاَّ بَشَرًا رَّسُولاً» {الإسراء/93}[1]

«...وَمَا يُشْعِرُكُمْ أَنَّهَا إِذَا جَاءتْ لاَ يُؤْمِنُونَ» {الأنعام/109}[2]

«أَوَ لَمْ يَكْفِهِمْ أَنَّا أَنزَلْنَا عَلَيْكَ الْكِتَابَ يُتْلَى عَلَيْهِمْ ...» {العنكبوت/51}[3]

«أَوَ لَمْ يَكُن لَّهُمْ آيَةً أَن يَعْلَمَهُ عُلَمَاءُ بَنِي إِسْرَائِيلَ» {الشعراء/197}[4]

кебек аятьләр белән җавап бирергә кушты. Корәеш гарәпләренең сораганнары бирелсә дә, алар кабул итмәячәкләреннән, Аллаһы сөннәте буенча аларның һәлак ителүләре максат түгеллеген

«وَمَا مَنَعَنَا أَن نُّرْسِلَ بِالآيَاتِ إِلاَّ أَن كَذَّبَ بِهَا الأَوَّلُونَ ...» {الإسراء/59}[5]

---

1 «Әйт син аларга: «Сөбхәналлаһ, мин бит сезнең кебек бер кеше генә, миндә андый нәрсәләргә кодрәт юк.» «әл-Исра»/93. – авт.

2 «Сез беләсезме соң, аларның таләп иткән дәлилләре бирелгәндә дә иман китермәүләрен?» «әл-Әнгам»/109. – авт.

3 «Без сиңа иңдергән китап могҗиза булырга җитмиме инде аларга?!» «әл-Ганкәбүт»/51. – авт.

4 «Синең пәйгамбәрлегеңне бәни Исраил галимнәре белү аларга дәлил була алмыймы?» «әш-Шугара»/194. – авт.

5 «Без аларга могҗизаларны җибәрмәдек, чөнки алдан килгәннәр аларга инанмадылар.» «әл-Исра»/59. – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

кебек аятьләр белән җавап бирде. Мөшрикләрнең иман китерүләрен бик нык теләгән, аларны нинди генә юл белән булса да, һидәяткә бастырырга тырышкан рәсүленә дә Аллаһы Тәгалә: «Әгәр аларның иманга килмәүләренә борчылсаң, аларның синнән качулары сиңа авыр булса, бар көчеңнән килсә җир астыннан яисә күктән аларга могҗизалар китер!» мәгънәсендәге могҗизалар бирүдән өметен өздерәчәк аятьләр иңдерде[1].

## Ай ярылу мәсьәләсе

Сира галимнәре бу урында айның ярылу мәсьәләсен зекер итәләр: Мәккә башлыклары рәсүлуллаһка килеп, пәйгамбәрлегенә дәлил буларак, айны икегә ярып күрсәтүен сораганнар, шул могҗизаны күрсәткән дәвердә иман китерәчәкләренә сүз биргәннәр. Рәсүлуллаһның догасы буенча Аллаһы Тәгалә мөшрикләрнең сораган нәрсәләрен биргән. Ләкин мөшрикләр: «Мөхәммәд безнең күзне буды, безне сихерләде», – дип иман китермәгәннәр диләр.

Ай ярылу турында төрлечә сөйлиләр. Мәзкүр вакыйга Ибне Мәсгуд, Ибне Габбас, Әнәс, Ибне Гомәр, Хозәйфә, Җәбир бине Мутгәм вә башкалардан риваять кылынмыштыр. Ике сахих хәдисләр җыентыкларында[2] исә бу вакыйга Ибне Мәсгуд, Ибне Габбас, Әнәстән риваять кылынып, башкалардан риваять юктыр. Күпчелек тәфсир галимнәре дә Коръәндәге «Камәр» сүрәсендәге «Вәншәккаль камәр»[3] дигәнне дәлил тотып, ошбу вакыйганы аңлаталар.

1 "وَإِن كَانَ كَبُرَ عَلَيْكَ إِعْرَاضُهُمْ فَإِنِ اسْتَطَعْتَ أَن تَبْتَغِيَ نَفَقًا فِي الأَرْضِ أَوْ سُلَّمًا فِي السَّمَاء فَتَأْتِيَهُم بِآيَةٍ وَلَوْ شَاء اللّهُ لَجَمَعَهُمْ عَلَى الْهُدَى فَلاَ تَكُونَنَّ مِنَ الْجَاهِلِينَ" {الأنعام/٥٣}

2 Бохари һәм Мөслими җыентыклары. – тәрҗ.

3 “Һәм ай ярылды.” – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

Ләкин безнең карашыбыз буенча бу мөшкел бер мәсьәләдер. Мәсьәләнең мөшкеллеге ай ярылуның гадәттән тыш бер күренеш булуыдыр. Пәйгамбәр булгач, аның берәр могҗиза эшләве бер дә гаҗәп эш түгел. Аллаһының пәйгамбәрләрен куәтләндерү өчен кайбер могҗизалар бирүе мәгълүм нәрсә. Муса галәйһиссәлам таягы булмас нәрсә түгел икән, инде айның ярылуына ышанмаска ни сәбәп бар? Шәхсән рәсүлуллаһның да үз сәхабәләренә төрле гадәттән тыш нәрсәләрне күрсәткәнлеге мәгълүм нәрсә. Хәдис китапларында бу хакта күп риваятьләр бар. Әмма монда мәсьәләнең икенче ягы бар. Ике сахих хәдис җыентыкларында зекер ителгәнгә күрә, айның ярылу вакыйгасы мөшрикләрнең сораулары буенча булмыштыр. Хәлбуки, Коръәни Кәримдә мөшрикләрнең бик күп сораулары зекер ителгән хәлдә, ай ярылу хакында бер ачык әйтелгән сүрә дә юктыр. «Камәр» сүрәсендәге «Вәншәккаль камәр» гыйбарәсе айның ярылган булуына дәлил түгелдер. «Иншәкка»га үткән заман мәгънәсе бирү мөмкин булган кебек киләчәк заман мәгънәсен дә бирү мөмкин. Булуы мөмкин булган нәрсәләрдә киләчәк заман урынына үткән сыйгасын[1] куллану гарәп телендә киң таралгандыр. «Сурга өрелде», «Әйтteләр: «Ни үкенеч безгә, кем терелтте безне», «Шул көндә күк аерылыр һәм болытлар белән капланыр һәм фәрештәләр төшерелерләр», «Һәм сурга өрелер һәм күкләрдә вә җирдә булган барлык җан ияләре аңларын югалтыр (яки үлерләр), мәгәр Аллаһы теләгәннәр генә калырлар», «Шул көндә җәһәннәм китерелде», – кебек киләчәк заман урынына үткән заман сыйгасы кулланылган урыннар Коръәни Кәримдә шыгрым тулыдыр. Шунлыктан монда да «вәншәккаль камәр» дөнья харап булган вакытын-

1 Сыйга – форма. – тәрж.

www.darul-kutub.com

да булырга мөмкин, бәлки озакламас та. Коръәни Кәримдә бу мәгънәдә:

«إِذَا السَّمَاءُ انشَقَّتْ» {الإنشقاق/1},
«وَيَوْمَ تَشَقَّقُ السَّمَاءُ بِالْغَمَامِ وَنُزِّلَ الْمَلَائِكَةُ تَنزِيلًا» {الفرقان/25},
«إِذَا السَّمَاءُ انفَطَرَتْ» {الإنفطار/1}

кебек аятьләр бар. Димәк, Коръәни Кәримдә иншикакның беренче мәгънәсен төгәл аңлатырлык бер аять тә юктыр. «Ай ярылу» гыйбарәсе белән бәйле булып килгән

«وَإِن يَرَوْا آيَةً يُعْرِضُوا وَيَقُولُوا سِحْرٌ مُّسْتَمِرٌّ» {القمر/2}[1]

гыйбарәсе дә шушы мәгънәне ныгыта. Чөнки монда бу могҗизаны билгесез итеп китерә. Аның соңында «һәрвакыт килеп торган [مُسْتَمِرٌّ] сихер» гыйбарәсеннән куллана. Кулланылган «истимрар» сүзенең ачык мәгънәсе «даими» икәнлегендә шөбһә юктыр. Бәйзави да бит аны шул мәгънәгә туры китереп: «Бу – аңа кадәр бер-берсенә охшаш һәм берсе артыннан берсе килгән могҗизаларны күрүләренә ишарә булып тора», – дип әйтә. Әгәр монда могҗиза мәгънәсендә килгән «Әят»тән ярылу могҗизасы әйтелсә, «Әят» сүзен билге итеп, «әл-Әят» дип кулланылыр иде: «вә ин йәрау әл-Әятә йугъриду вә йәкулу сихрун мүстәмирр» кебек. Кыскасы, аятьнең мәгънәсе: «Кыямәт якынлашты, ай да ярылачак. Әгәр Мәккә мөшрикләре кыямәтнең булачагына ишарәт итә торган Коръән могҗизаларын күрсәләр, аларны инкарь итәләр. Ул – Мөхәммәдтән һәрвакыт булып тора торган тәэсир итүче сихер дип әйтәләр», – димәктер. Ярылуны шушы соңгы мәгънә

1 «әл-Камәр»/2. – тәрж.

www.darulkutub.com

белән аңлату Хәсән әл-Басри һәм Гата кебек галимнәрдән риваять кылынадыр. Күпчелек тәфсир галимнәренең бу могҗизаны беренче мәгънә белән аңлатулары зекер ителгән риваятьләр тәэсиреннән генә килмештер.

Коръәни Кәримдә мәзкүр могҗизаларның һичберсе бирелмәгәндә шөбһә булмас. Инде шулай булгач, бирелгән могҗизалар Коръәндә әллә ничә урында зекер ителеп, булган могҗизаның зекер ителмәве акылга сыямы?

Мөшрикләр рәсүлуллаһтан могҗизалар сорап йөдәтеп бетерәләр иде, ике сүзнең берендә аңа: «Пәйгамбәр булсаң, башка пәйгамбәрләр кебек могҗиза китер!» – дияләр иде. Рәсүлуллаһ үзе дә аларга могҗиза китерергә бик тели иде. Шулай булгач, ай ярылуы могҗизасы бирелгән булса, аларга: «Без сиңа иңдергән Коръән аларга могҗиза булырга җитмимени, ул Коръән аларга даими укыладыр...»[1] – дип җавап бирү белән генә канәгатьләнмичә: «Сезгә ай ярылу могҗизасын бирдек бит, шул җитмиме? Тагын нәрсә кирәк инде сезгә?» – кебек сүзләр белән җавап бирү тагы да яхшырак булмыймы? Ник Коръәндә бер дә мондый җавап бирелми? Ни өчен бик гади бер төр белән «... Әйт: «Минем Раббым һәр кимчелектән пакътер, мин үзем бары тик кеше затыннан булган илче генә»,[2] – дип кенә җавап бирә. Мәккә мөшрикләре бит рәсүлуллаһтан могҗиза китерүен тилмереп-тилмереп сорыйлар иде. Алар үзләре сораган могҗизаларның берсен генә китергән вакытта, иман китерәчәкләренә бар көчләре белән ант итәләр иде[3]. Шулай булгач: «Әйт: «Хакыйкый бе-

1 “әл-Ганкәбүт”/51. – тәрҗ.

2 “әл-Исра”/93. – тәрҗ.

3 “Мөшрикләр, әгәр аларга Аллаһыдан бер могҗиза килсә, иман китерер идек дип, Аллаһы исеме белән бик каты ант итәләр. Әйт: “Могҗиза - Аллаһы ихтыярында. Һәм каян сез беләсез, әгәр аларга ул килгән очракта да иман китермәгәннәрен?” “әл-Әнгам”/109. – авт.



www.darul-kutub.com

лем – Аллаһы хозурындадыр. Мин исә бәян итеп, кисәтеп үгетләүче генә»[1], «Синең пәйгамбәрлегеңне Ибне Исраил галимнәре белү аларга дәлил була алмыймы?»[2], «Бәс әйт: Яшертен нәрсәләрне белү Аллаһыга гына хас»[3] кебек аятьләр белән канәгатьләнү тиешле булыр идеме? Мондый урыннарда «вәншәккаль камәр» кебек гаять кыска гыйбарә белән генә китү бәләгатьтән түгел. Монда әллә ничә кат ай ярылу вакыйгасын зекер итеп, авызларын каплау тиеш иде.

Аның соңында мөшрикләрнең могҗиза сораганнарына әһәмият бирмәгән очракта да, мондый бөек бер вакыйганың Коръәндә шулай томанлы гына зекер ителеп китүе сәеррәктер. Мондый вакыйганың Коръәндә кабатланып зекер ителүе тиеш булган кебек беренче гасырлардагы кешеләрдән үзләре күргән сурәттә риваять ителергә тиеш иде.

Хәлбуки, бу хосустагы риваятьләр асылда ук ирешмидер. Аны тәвәтүр дәрәҗәсенә күтәрергә тырышкан кешеләр дә, «Мүтәвәтир кебек» дип әйтүдән уза алмыйлар. Иншикаку камәр вакыйгасы бик чикле кешеләрдән генә риваять ителгән. Шул вакыйганы риваять иткән сәхабәләр үзләре аларга әзер булмаганнар. Бу вакыйга бигрәк Ибне Мәсгуд, Ибне Габбас вә Әнәстән риваять ителә. Хәлбуки, Әнәс ул вакыт Мәдинәдә дүрт-биш яшьлек бер бала иде. Ибне Габбас ул вакыт тумаган да иде әле. Ибне Гомәр ул вакыт бик бәләкәй иде. Ул Хандак елында гына балигъ булды. Шулай булгач, хәдисне төп риваять итүчеләр бик чикле кешеләр генә булып калалар. Дөрес, бу урында рәсүлуллаһның пәйгамбәрлеген исбат итүче ниндидер табигатькә бәйләнгән могҗизалар

---

1 “әл-Ганкәбүт”/50. – тәрҗ.

2 “әш-Шугара”/194. – тәрҗ.

3 “Юнус”/20. – тәрҗ.



www.darulkutub.com

булмыйча, ул – Коръән иде. Шуңа күрә, беренче гасыр халкы аның риваятенә әһәмият бирмәгәннәр диячәкләр. Шулай, аңа без дә кушылабыз. Ләкин монда, әйтелгән могҗизаның күрсәтелүе һәм башка могҗизаларның Коръәндә әллә никадәр урында әйтелүе әһәмияткә алынсын.
Аллаһы Тәгалә:

«وَمَا مَنَعَنَا أَن نُّرْسِلَ بِالآيَاتِ إِلاَّ أَن كَذَّبَ بِهَا الأَوَّلُونَ»[1]

аяте белән Мәккә мөшрикләренә могҗиза күрсәтмәвенә сәбәп итеп, үткән кавемнәрнең пәйгамбәрләре китергән могҗизаларны ялганга чыгаруларын, Мәккә мөшрикләре дә, сораган нәрсәләре бирелсә, алар кебек үк кабул итмәячәкләрен, шуңа нигезләнеп үткән кавемнәр кебек һәлак ителәчәкләрен күрсәтә. Шушы аятьтә килгән «әл-Әят»нең морады Мәккә мөшрикләре таләп иткән могҗизалар икәнлегендә шик юктыр. Тәфсир галимнәре аны шулай аңлаталардыр[2]. Хәлбуки, Мәккә мөшрикләре таләп иткән могҗизалар эчендә ай ярылуын сорау да бар иде. Монда могҗизаларны ай ярылу могҗизасыннан башкага тәгаенләүгә асыл сәбәп юктыр. Инде мөшрикләргә ай ярылу могҗизасы бирелгәч, ни өчен аларга башка кавемнәргә килгән кебек газап килмәде? Әйтелгән могҗиза бирелгән булгач, «Пәйгамбәрләргә төрле

1 «Пәйгамбәрләргә төрле могҗизалар иңдерүдән безне һич нәрсә тыймады, мәгәр әүвәлге кавемнәрнең могҗизаларны ялганга тотулары тыйды» «әл-Исра»/59. – тәрҗ.

2 Мәшһүр тәфсир галимнәренең имамы Ибн Җәрир бу хакта шулай диде: “Аллаһы Тәгалә әйтә: “Әй, Мөхәммәд, синең халкың сораган могҗизаларны җибәрергә Безгә, аларга хәтле яшәгән, пәйгамбәрләрен ялганга санаган халыклар сәбәпче булды. Алар, болар [Мәккә кяферләре] кебек сорадылар. Сораган нәрсәләре аларга килгәч, алар пәйгамбәрләрне ялганга чыгардылар. Могҗизалар килүенә карамастан, иман китермәделәр. Шуның аркасында аларга тиз арада газап килде. Шуңа күрә дә Без синең халкыңа сораган могҗизаларын җибәрмәдек. Әгәр дә без, аларга могҗизалар җибәреп, алар аны ялганга санасалар, элеккеге халыклар кебек аларга газапны ашыктырыр идек.” Тәфсир Ибн Җәрир, 15 т., 69-70 б. – авт.



www.darul-kutub.com

могҗизалар иңдерүдән безне һич нәрсә тыймады, мәгәр әүвәлге кавемнәрнең могҗизаларны ялганга тотулары тыйды» аятенең ни мәгънәсе кала? Мәккәлеләрнең аны ялганга чыгарачакларын Аллаһы белә бит. Шулай булгач, ник бу эш аларга ай ярылу могҗизасын бирүдән тыймый? Кыскасы, әгәр ай ярылу могҗизасы бирелгән булса,

«...وَمَا يُشْعِرُكُمْ أَنَّهَا إِذَا جَاءَتْ لاَ يُؤْمِنُونَ», «وَمَا مَنَعَنَا أَن نُّرْسِلَ...»,

«قُلْ إِنَّ اللَّهَ قَادِرٌ عَلَى أَن يُنَزِّلِ آيَةً وَلَكِنَّ أَكْثَرَهُمْ لاَ يَعْلَمُونَ»[1]

кебек аятьләрнең мәгънәсе калмый. Тәфсир язучылар үзләре дә ошбу аятьләрне тәфсир кылганда Мәккә мөшрикләренә могҗиза бирелмәгәнлеген, рәсүлуллаһның пәйгамбәрлегенә Коръәни Кәрим дәлил булырга җиткәнлеген, аның өстенә башка могҗизалар биреп торуның кирәкмәгәнлеген сөйлиләр. Фәкать «Камәр» сүрәсенә килеп җиткәч, әүвәлге сүзләрен бөтенләй онытып, риваятьләр тәэсире белән, ай ярылу могҗизасы булды, дип тәфсир итәләр.

Үзебезнең мәшһүр Бәйзави искә алган аятьләрне тәфсир кылганда, «Чынлыкта исә, Аллаһы Тәгалә могҗизаларны җибәрергә кодрәтледер. Һәм ул могҗизаны җибәрү артыннан бәла килүне белдерәдер. Җибәрелгән очракта, кичекмәстән башкаларга кебек бәла килер иде»[2], «Һәм монда, Аллаһы Тәгаләнең аларның иман китермәүләрен алдан ук белүе белән җибәрмәвен дә искәртүдер.»[3], «Һәм монда Коръәни Кәримнең үзе могҗиза булуы һәм үзенең хакыйкате

1 “әл-Әнгам”/37. – тәрҗ.

2 1 т., 218 б. – авт.

3 1 т., 130 б. – авт.



www.darulkutub.com

белән башка могҗизаларга хәҗәт юктыр»,[1] – дип әйткәндә, «Камәр» сүрәсендәге

«وَإِن يَرَوْا آيَةً يُعْرِضُوا وَيَقُولُوا سِحْرٌ مُّسْتَمِرٌّ»

аятен тәфсир кылганда: «Бу аларның охшаш һәм бер-берсе артыннан килгән могҗизаларны аңлатып килә», – дигән алдагы сүзенә капма-каршы.

Гаҗәп, Мәккә мөшрикләре нинди могҗизалар, нинди гадәттән тыш әйберләр күрделәр икән? Мәккәлеләргә ай ярылу могҗизасыннан башка могҗиза бирелү турында сөйләүче, белүче кеше бармы?

Мәккә мөшрикләре сораган могҗизалардан берәрсе (мисал өчен, ай ярылу) бирелгән булса, Аллаһы аны Коръәндә зекер итәр иде. «Аларга ай ярылу могҗизасын бирдек, алар иман китермәделәр. Башка могҗизалар күрсәтсәк тә, шулай ук иман китермәячәкләр. Син аның өчен борчылма. Юлыңда дәвам ит!» – кебек сүзләр Коръәндә булу тиешле иде.

Кирәк рәсүлуллаһ, кирәк сәхабәләр, аларның каршы килүләренә борчылалар, аларга могҗиза китереп, авызларын каплауны телиләр иде бит. Хәлбуки, Коръәндә мондый вакыйга зекер ителми. Киресенчә,

«فَإِنِ اسْتَطَعْتَ أَن تَبْتَغِيَ نَفَقًا فِي الأَرْضِ أَوْ سُلَّمًا فِي السَّمَاء فَتَأْتِيَهُم بِآيَةٍ وَلَوْ شَاء اللّهُ لَجَمَعَهُمْ عَلَى الْهُدَى فَلاَ تَكُونَنَّ مِنَ الْجَاهِلِينَ»[2]

кебек аятьләр белән җавап бирелә.

1 1 т., 131 б. – авт.

2 «әл-Әнгам»/35. – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

Нәтиҗәдә, Исламият бер гомуми дин булып, Мөхәммәд галәйһиссәлам дә иң соңгы пәйгамбәр булганлыктан, Аллаһы аның пәйгамбәрлегенә дәлил буларак, махсус кавемгә генә могҗиза китермичә, кыямәт көненә хәтле барачак могҗиза бирде, ул – Коръәни Кәримдер.

Рәсүлуллаһ дәгъвәтен башлап җибәрүгә үк, үз кавеменә каршы җавап буларак, пәйгамбәрлегенә дәлил итеп Коръәни Кәримне тотты, шул ышанмаганнарга Коръән аятьләре кебек бер аять китерүләрен таләп итте. Могҗиза сораганнарына каршы да:

«أَوَ لَمْ يَكْفِهِمْ أَنَّا أَنزَلْنَا عَلَيْكَ الْكِتَابَ يُتْلَى عَلَيْهِمْ إِنَّ فِي ذَلِكَ لَرَحْمَةً وَذِكْرَى لِقَوْمٍ يُؤْمِنُونَ»[1]

дигән сүзләр белән Коръәннең дәлил булырга җиткәнлеген бәян итте.

Рәсүлуллаһның үзеннән соңгыларга да дәлил – шул ук могҗиза Коръәни Кәримдер.

«أَفَلاَ يَتَدَبَّرُونَ الْقُرْآنَ وَلَوْ كَانَ مِنْ عِندِ غَيْرِ اللّهِ لَوَجَدُواْ فِيهِ اخْتِلاَفًا كَثِيرًا»[2]

Исламиятнең ахмак нәрсәләргә нигезләнмәве – аның иң беренче үзенчәлегедер. Коръәни Кәримнең бөеклелеге, аның могҗизалыгы Исламиятнең илаһи дин икәнлегенә дәлил булырга җитәдер. Аңа үзе игътираф[3] кылмаган, киресенчә, үзе

1 «Без сиңа иңдергән һәм аларга укыла торган Коръән аларга могҗиза булырга житмимени? Чынлыкта исә, анда мөэминнәр өчен рәхмәт һәм вәгазьләр бар» «әл-Ганкәбүт»/51. – тәрҗ.

2 «Ни өчен алар Коръәннең мәгънәсен фикерләп, уйлап карамыйлар? Әгәр дә Коръән Аллаһыдан җибәрелмәсә, алар анда бик күп каршылыклар табар иделәр» «ән-Нисә»/82. – тәрҗ.

3 Игътираф – кимчелеген өстенә алу – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

аның булмавын сөйләгән нәрсәне сылтау итәргә мәҗбүрилек юктыр. Башка милләт галимнәре Исламиятнең ахмак нәрсәләргә нигезләнмәгәненә көнләшкән хәлдә, без тартып-сузып булса да аңа нигезсез гаепләр такмакчы булабыз.

## Сәхабәләрнең Хәбәшәгә һиҗрәте [күчүләре]

Корәеш гарәпләре бөтен көчләре белән каршы торуларына карамастан, Исламият әкрен-әкрен тарала барды. Исламият көчәйгән саен, Мәккә мөшрикләре үзләренең җәбер вә золымнарын арттырдылар, Ислам әһелләренә күз ачарга да ирек бирмәделәр. Кайбер яклаучысы булмаганнарны шул кадәр газапладылар ки, бичаралар газапка чыдый алмыйча, көфер сүзләрен әйтеп, Лат белән Гоззәне «Аллаһы» дип әйтәләр иде. Боларның газап кылынулары шул кадәр каты булды, хәтта берсенең алдыннан берәр хәшәрәт барганда «Бу синең «Аллаһың» – дип әйткәч, «Үт, Аллаһым» – дип җавап бирәләр иде.

## Хәбәшәгә беренче һиҗрәт

Рәсүлуллаһ Гарәбстанның күршесе булган Хәбәшәдә гадел бер патша булганын ишетеп белә иде, шуның өчен мөшрикләрнең золымы чиктән чыгып китсә, сәхабәләрне шунда һиҗрәт итәргә кушу фикерендә йөри иде. Иза һәм җәфаның чиктән чыгуын күргәч, күркәм сәхабәләргә шунда һиҗрәт итәргә киңәш итте. Унике ир вә дүрт хатын туган вә үскән җирләрен ташлап, күрмәгән вә белмәгән бер мәмләкәткә һиҗрәт иттеләр. Мәккә мөшрикләренең боларның артыннан куып килүеннән сакланып, күбесе яше-

рен сурәттә киттеләр. Кайберләре мөшрикләр күз алдында китсәләр дә, кайда барачакларын белдермәделәр.

Хәбәшәгә беренче һиҗрәт иткән кешеләр шулар иде:

1. Госман бине Гаффан;
2. Рукайя бинте рәсүлуллаһ (Госманның хатыны);
3. Әбү Хузәйфә бине Гутбә;
4. Сәһлә бинте Суһәил (Әбү Хузәйфәнең хатыны);
5. Әбү Сүләмә;
6. Умм Сүләмә (Әбү Сүләмәнең хатыны);
7. Гамир бине Рабига;
8. Ләйлә бинте Әбү Һәйсәмә (Гамирның хатыны);
9. Зүбәйр бине Гаввәм;
10. Габдеррахман бине Гаүф;
11. Госман бине Мәзгун;
12. Әбү Сәбүраһ;
13. Хәтиб бине Гамр;
14. Сүһәил бине Вәһб[1];
15. Габдулла бине Мәсгуд;
16. Мусгәб бине Гумәйр[2].

Хәбәшә мөһаҗирләренең Мәккәдән чыгулары пәйгамбәрлек килгәннән 5 елның рәҗәб аенда булды[3]. Шушы мөһаҗирләр Кызыл диңгезгә килеп җиткәч, ике көймә туры килеп, Хәбәшә мәмләкәтенә алып китте. Мәккә мөшрикләре, вакыйгадан хәбәрдар булып, боларның артыннан куа чыксалар да, очрата алмый кайттылар. Башка сәхабәләрнең кайберләре кешеләр яклавында калдылар, кайберләре никадәр иза вә җәфа күрсәләр дә, ватаннарыннан

1 “Сүһәйл бине әл-Бәйда” дип тә йөртелә. – авт.

2 Мусгәб, “Зәдүл-мәгад”да зекер ителми. – авт.

3 “Зәде-л-мәгад”, 1 т., 299 б. – авт.

аерыласы килмичә, бервакыт Аллаһының ярдәменә ирешү өмете белән Мәккәдә калдылар.

## Гомәр бине әл-Хаттабның Исламга килүе

Хәбәшәгә беренче һиҗрәттән соң, мәккәлеләрнең башлыкларыннан һәм мәшһүрләреннән булган Гомәр бине әл-Хаттаб Исламга килде. Гомәр әүвәлдә Ислам әһелләренә бик каты дошман, аларны мөмкин кадәр җәберләүгә асылда ук тартынмый торган һәм аларга мөшрикләр арасыннан иң каты мөгамәлә кыла торган кеше иде. Аның хакында Хәбәшә мөһаҗирләреннән Ләйлә дигән хатын: «Хәбәшәгә чыгу нияте белән дөямә менгән идем. Ирем бер эш белән мәшгуль иде. Шул арада Гомәр бине әл-Хаттаб килеп чыгып миңа: «Үмм Габдулла, кайда сәфәр итәсез?» – дип сорады. Моңа каршы мин: «Безне җәфа вә золым кылдыгыз, динебезне тотарга ирек бирмәдегез, шунлыктан җәбер күрми торган җиргә китәргә мәҗбүр булдык», – дидем. Гомәр бине әл-Хаттаб сүземә каршы: «Сезгә Аллаһы ак юл бирсен!» –диде. Гомәр бине әл-Хаттабтан мондый сүз ишетеп таң калдым. Ирем килгәч, аңа бу вакыйганы сөйләдем. Моңа каршы ирем: «Бу эшне сөйләмә, Гомәрнең Исламга килүен өмет итәргә дә ярамый. Кайчан Хаттабның ишәге мөселман булса, Гомәр дә мөселман булыр», – диде», – дип сөйләде. Гомәр бине әл-Хаттабның Исламга килүе әл-Әркам бине әл-Әркам өендә булмыштыр. Рәсүлуллаһ, Гомәр бине әл-Хаттабның Исламга килүен өмет итә, ул Исламга килсә, Исламият беркадәр тын алыр иде дип ышана иде. Чыннан

да, Гомәр Исламга килгәч, Исламият күпмедер тын алды[1]. Гомәрнең саклавы белән намазларын Кәгъбәтуллаһта ачык рәвештә укый башладылар. Бу вакытка кадәр һәркем намазын яшерен укый иде һәм Кәгъбә каршында намаз кыла алмыйлар иде.

Гомәр бине әл-Хаттабның Исламны кабул итүе мөшрикләрне каты кайгыга салды. Аңа бик нык ачулары килде һәм хәтта җыелышып аны үтерү теләге камап алды. Ләкин шул арада вакыйгадан хәбәрдар булып, әл-Гас бине Вәил әс-Сәһми килеп җитеп, Гомәр бине әл-Хаттабны үз кулы астына алуын игълан итте. Шул сәбәпле мөшрикләр максатларына ирешә алмыйча калдылар.

## Мөһаҗирләрнең кайтуы

### *Мөһаҗирләрнең кайтуы*

Хәбәшә мөһаҗирләре Мәккәдән чыгып, өч ай Хәбәшәдә торганнан соң, Мәккә халкы рәсүлуллаһны вә сәхабәләрне җәберләүдән туктаганнар дигән хәбәр ишеттеләр. Туган вә үскән җирләреннән аерылган, чит җирләрдә яшәргә өйрәнмәгән, рәсүлуллаһны вә сәхабәләрне сагынган мөһаҗирләр шул хәбәрнең хаклыгын тикшереп тормыйча, Мәккәгә кайтып китте. Ләкин Мәккәгә житәр алдыннан андагы хәлләр ачыклангач, кайберләре кире Хәбәшәгә китте, кайсылары яшеренеп йә якыннары химаясенә кереп, Мәккәдә калды.

Хәбәшә мөһаҗирләреннән Мәккәгә кергән кешеләр арасында Габдулла бине Мәсгуд, Госман бине Гаффан вә ха-

1 "مَا زِلْنَا أَعِزَّةً مُنْذُ أَسْلَمَ عُمَرُ" Ибн Мәсгуд хәдисе. Бохари, 11 т., 5 б. – авт.

тыны Рукайя, Госман бине Мәзгун вә Әбү Сәлмә бар иде. Әбү Сәлмә Әбү Талиб кул астында, Госман бине Мәзгун Вәлид бине әл-Мугыйра кул астында калдылар.

## Бойкот

Мәккә мөшрикләре рәсүлуллаһка вә хөрмәтле сәхабәләргә дошманлыкларын һаман арттыра барды. Моңа кадәр тоткан юллары белән генә максатларына ирешмәгәч, башлыклар киңәшләшеп, Ибне Һашим вә Ибне Мутталиб кабиләләренә бойкот ясарга карар бирде. Бу турыда бер игълан язып, Кәгъбәтуллаһның эченә куйдылар. Бу карар буенча Корәеш гарәпләре Ибне Һашим вә Ибне Мутталиб кабиләләре рәсүлуллаһтан киселмәгән вакытта, алар белән һичбер мөгамәләдә булмаска, алар белән сату-алу итмәскә, утырдаш булмаска, сөйләшмәскә, алардан хатынлыкка кыз алмаска һәм кыз бирмәскә булдылар. Моның нәтиҗәсендә, Габдү Мәннаф балаларыннан ике тармак – кабилә Һашим һәм Мутталиб, мөэмин вә кәферләре бәрабәр Корәешләрдән аерылып, Әбү Талиб шигъбына керделәр. Шигыбка керү пәйгамбәрлекнең җиденче елында мөхәррәм аеның башында булды[1]. Әбү Ләһәб Ибне Һәшимнән булса да, болар белән шигыбка кермичә, киресенчә, аларга зур дошман булып, мөшрикләрне аларга каршы котыртып тора иде.

## Хәбәшәгә икенче һиҗрәт

Мәккә мөшрикләре мөселманнарга бойкот игълан иткәч, рәсүлуллаһ сәхабәләргә Хәбәшәгә икенче мәртәбә ба-

1 “Зәдуль-Мәгад”, 1 т., 301 б. ”Шигыб” дип ике тау арасындагы ачыклыкка әйтәләр. Бу урындагы шигъб, Мәккәдәге Ибне Һашим мәхәлләсенең исемедер. Бу шигыб “Әбү Йосыф шигъбы” дип танылгандыр. – авт.

руны әмер итте. Бу һиҗрәттә 83[1] ир һәм 19 хатын Хәбәшәгә юнәлделәр. Мәккәдә Ислам әһелләреннән бик аз кеше генә калды. Бу вакытта һиҗрәт иткән кешеләр арасында Госман бине Гаффан һәм хатыны Рукайя, Җәгъфар бине Әбү Талиб һәм хатыны Әсма бинте Гумәйс, Габдулла бине Мәсгуд, Гобәйдулла бине Җәгъш һәм хатыны Үмм Хәбибә бинте Әбү Суфиан, Габдулла бине Җәгъш, Гамру һәм Халид (Сәгыйд бине әл-Гас балалары), Әбү Хузәйфа бине Гутбә, әл-Микъдад бине әл-Әсвад бар иде. Болар янына Хәбәшәгә Йәмәндә булып та, Исламга килгән Әбү Муса әл-Әшгари һәм якыннары һиҗрәт итеп[2], Хәбәшәдә Ислам әһелләре байтак кына күбәеп, чит җирләрдәге ачлыкларны бергә уртаклаштылар.

Шушы мөһаҗирләрдән кайберләре ватаннарын, якыннарын күрә алмый тора алмаганлыкларыннан, Мәккәгә кайткаладылар. Шул кайтучылардан Мәдинәгә һиҗрәт әмере булгач, Мәдинәгә һиҗрәт иттеләр. Хәбәшәдә булганнары, рәсүлуллаһның һиҗрәтен ишеткәч, Мәдинәгә килделәр. Моннан башка берәм-сәрәм кайтканнары да булырга кирәк. Ләкин Хәбәшә мөһаҗирләренең иң соңгы кайтулары һиҗрәтнең җиденче елында «Фәтхү Хайбәр» вакытында Җәгъфар бине Әбү Талиб кул астында булды[3].

Корәеш гарәпләре мөселманнарның Хәбәшәгә

---

1 “Зәдуль-Мәгад”, 1 т., 300 б. – авт.

2 Саннары утыздан күбрәк иде: “Бохари”, 4 т., 90 б. – авт.

3 Сира галимнәре, Хәбәшә мөһаҗирләренең ике этапта гына кайтуын искәртеп китәләр. Берсе байкутка кадәр Мәккәгә кайту һәм икенчесе Хайбәр елында Җәгъфар бине Әбү Талиб кулы астында Мәдинәгә кайту. Ләкин Хәбәшәгә һиҗрәт иткән кешеләрдән кайберләренең “Бәдер” сугышында булулары һәм кайберләренең Мәдинәгә һиҗрәт итүләре, мәзкүр мөһаҗирләрнең бу ике мәртәбәдән башка вакытта кайтуларын да аңлата. Чынлыкта шулай булырга да тиеш, чөнки рәсүлуллаһны күрергә шул кадәр сагынган кешеләрнең рәсүлуллаһның һиҗрәтен ишетә торып, һаман Хәбәшәдә чит урынны ихтияр итеп торулары аңлашылмый. Хәтта Җәгъфәр бине Әбү Талибның җиденче елга кадәр калуы гаҗәп күренәдер. Ибнү әл-Каййим хәзрәтләре Хәбәшә мөһаҗирләренең кайтуы турында мөһим сүзләр сөйли. “Зәдүль-Мәгад”, 1 т., 299-301 б. – авт.

күчүләренә һәм анда гадел патша кул астында тыныч, рәхәт торганнарына гаять эчләре пошты. Алар Исламның Гарәб ярымутравыннан башка җирләрдә таралуыннан курыкты. Шуның өчен алар үзара киңәшләшеп, төрле бүләкләр белән Гамр бине әл-Гас һәм Гаммәрат бине әл-Вәлидне Хәбәшәгә җибәрделәр. Шушы ике кеше Хәбәшәгә барып, Нәҗашинең якыннарын күреп, бүләкләрен аңа тәкъдим иттеләр. Ләкин Нәҗаши боларның сүзләренә әһәмият бирмәде. Нәтиҗәдә, алар икесе мәхрүм булып кайттылар.

## Бойкотның бетерелүе

Ибне Һашим вә ибне Мутталиб кабиләләре, бойкот сәбәпле, бик нык тарлыкта калдылар, ачыктылар, хәтта агач яфракларын ашый торган булдылар. Ләкин Корәеш башлыкларыннан кайбер вөҗдан һәм кешелек ияләре шул бойкотның хаксызлык вә золым булуын аңлыйлар, эчләреннән бу эшкә каршы иделәр. Шулай да калган мөшрикләргә каршы килергә куркалар иде. Әйтелгән башлыклар эчендә бойкотка эләккән кешеләргә иң мәрхәмәтлесе Һишам бине Гамр иде. Ул караңгы кичләрдә дөясенә ризык йөкләп, шигъбның авызына килеп, дөянең йөгәнен салдырып, үзен генә шунда кертеп җибәрә иде.

Һишам бине Гамр шул золымга чыдый алмады: үзенең ышанычлы кешеләреннән булган Заһир бине Үмәйягә барып, бойкотны бозу фикерендә булганын сөйләде вә тәэсирле сүзләр белән Заһирны үз фикеренә күндерде. Соңра икәүләп Мутгам бине Гади, Әбү әл-Бухтари бине Һишам Зәмга бине Әсвадкә барып, бойкотны бетерү карарына килделәр. Соңра шул карарларын гамәлдә күрсәтер өчен Кәгъбәтуллаһта бу

турыда сүз сөйләргә вә үз куллары белән игълан кәгазен ертырга булдылар. Кичтән сөйләшкән карар буенча Заһир бине Умәйя иртә торып, Кәгъбәтулланы тәваф кылды. Соңра жыелган халыкка мөрәҗәгать итеп: «Әй, Мәккә халкы, без ашыйбыз, эчәбез, киенәбез, шул вакытта Ибне Һашим белән Ибне Мутталиб кабиләләре ачлыктан интегеп яталар, аларга сатуга да, алуга да ирек бирелми, бу зур золым түгелме? Валлаһи, мин игълан кәгазе ертылмастан урыныма утырмаячакмын!» – диде. Моңа каршы Әбү Җәһил: «Ялган сөйлисең», – диде. Зәмга бине Әсвад: «Син үзең ялган сөйлисең, без бу эшкә әүвәл дә разый түгел идек», – дип каршы әйтте. Соңра Әбү әл-Бухтари торып, Зәмганең сүзен хуплап алды. Мутгәм бине Гади һәм Һишам бине Гамр дә аларның сүзләрен куәтләп алдылар. Соңра Мутгәм бине Гади торып, игълан кәгазен ерткалап ташлады. Шул сурәттә бойкот мәсьәләсе хәл ителде. Рәсүлулланың вә якыннарының шигъбтә ябылып куелулары өч елга кадәр сузылды. Әбү Талиб үзенең мәшһүр ләмиясен[1] шушы шигъбтә вакытта язды. Ул ләмиясендә хөрмәтле Корәешнең күңелен табарга тырыша, үзләренә җәбер һәм золым кылган кешеләргә нәфрәтен бәян итә, үз якларыннан Бәнү Нәүфәл белән Бәнү Габдүшшәмскә үзен ташлаганнары өчен бәддога кыла, рәсүлулланы беркайчан да химаясеннән ташламаячагын, аның юлында иң соңгы чиккә кадәр торачакларын сөйли.

## Кайгы елы

Рәсүлулланың һәм якыннарының бойкоттан чыгуларына пәйгамбәрлектән ун ел һәм һиҗрәткә кадәр өч ел элек

1 Ләмия – касыйдә. – тәрҗ.

иде. Бойкоттан чыгуга 6 ай[1] үтү белән Әбү Талиб вафат булды. Яше 80нән узган иде инде. Әбү Талибның авыруын ишеткәч, Корәеш рәисләре җыелышып, хәлен сорашырга бардылар һәм Әбү Талибка: «Син безнең каршыбызда мөхтәрәм бер затсың, хәлең дә авырайды. Мөхәммәд белән безне килештер, ул безнең динебезгә тотынмасын, без дә аның динен гаепләмәбез», – диделәр. Моның нәтиҗәсендә, Әбү Талиб рәсүлне күреп, бу үтенечләрне аңарга сөйләде. Рәсүлуллаһ та боларга каршы бик гүзәл: «Алар белән килешү – минем иң беренче максатым. Минем белән килешү өчен алар: «Лә иләһә илләллаһ» кәлимәсен әйтергә вә Аллаһыдан башка һичбер нәрсәгә гыйбадәт кылмаска тиешләр. Бары тик шул гына», – диде. Моны ишеткәч, Корәеш башлыклары өметләрен өзеп чыгып киттеләр.

Әбү Талиб рәсүлуллаһның пәйгамбәрлеген ялганга тотмаса да, шәһадәт кәлимәсен әйтмәде. Хәтта ахыр сулышларына кадәр, рәсүлуллаһ ялынып, ялварып иманга китертергә тырышса да, Әбү Талиб: «Үземнән соң якыннарым ата-баба диненнән чыгуым өчен гарьләнерләр дип куркам», – диде, Исламны кабул итмәде[2].

Әбү Талиб вафат булгач, рәсүлуллаһ тагын да уңайсыз хәлгә төште. Ул вафат булмас борын мәккәлеләр рәсүлуллаһны сүзләр белән рәнҗетмичә үтә алмыйлар иде.

---

1 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 301 б. Ибнү әл-Каййим, Хәдичәне Әбү Талибтан өч көн соңрак вафат булды ди. Ибү әл-Әсир исә, башта Хәдичә вафат булды, ди һәм аннан 35 яки 55 көннән соң Әбү Талиб вафат булды, ди. 2 т., 34 б. – авт.

2 {65/القصص} "إِنَّكَ لَا تَهْدِي مَنْ أَحْبَبْتَ وَلَكِنَّ اللَّهَ يَهْدِي مَن يَشَاء وَهُوَ أَعْلَمُ بِالْمُهْتَدِينَ" [Чынлыкта исә син, үзең яратканнарыңны туры юлга бастыра алмассың. Бары тик Аллаһы кына теләгәннәрен туры юлга бастырыр. Ул туры юлдан баручыларны яхшырак беләдер. ”әл-Касас”/٥٦];

"مَا كَانَ لِلنَّبِيِّ وَالَّذِينَ آمَنُواْ أَن يَسْتَغْفِرُواْ لِلْمُشْرِكِينَ وَلَوْ كَانُواْ أُوْلِي قُرْبَى مِن بَعْدِ مَا تَبَيَّنَ لَهُمْ أَنَّهُمْ أَصْحَابُ الْجَحِيمِ" {311/التوبة} [Пәйгамбәргә һәм иман китергәннәргә, җәһәннәм әһелләре икәнлекләре ачык беленгән мөшрикләр өчен гафу сорау ярамастыр, гәрчә алар туганнар булсалар да. “әт-Тәүбә”/ 113]. Шушы аятьләр Әбү Талиб хакында иңдерелгәндер. “Бохари”, 5 т., 52 б. – авт.

Инде башка төрле җәфалый башладылар: өстенә туфраклар ату, Кәгъбәтуллаһта намаз кылганда өстенә нәҗәсәтләр китереп салу, бәгъзе вакытта камап алып тарткалау, суккалау кебек түбәнчелекле эшләрдән дә тартынмадылар.

Әбү Талибның вафатыннан соң озак та үтмәде, Үмм әл-мүэминин Хәдичә дә вафат булды. Хәдичә гаять акыллы һәм галиҗәнаб бер хатын булып, рәсүлуллаһка иң зур таяныч, аның кайгыларын уртаклашучы, аны һәрвакыт юатучы иде. Хәдичә бөек бер гаиләдән, өстәвенә мал сахибе бер зат булганнан, рәсүлуллаһка башкаларның тиюеннән бер сакчы иде. Рәсүлуллаһ бу икәүнең вафатына бик каты кайгырды. Шул елны рәсүлуллаһ «кайгы елы» дип атады.

## Сәүдәткә өйләнү

Хәдичә вафат булгач, рәсүлуллаһ Сәүдәт бинте Зәмга әл-Гамириягә никахланды. Сәүдәт ире Сәкран бине Гамр белән Хәбәшәгә ике мәртәбә һиҗрәт иткән иде. Хәбәшәдән кайтып, аз гына тору белән ире вафат булып, хатыны яклаучысыз калды. Рәсүлуллаһ аның якыннарының яңадан иске дингә кайтаруга көчләүләреннән куркып, үзенә никахлады. Рәсүлуллаһның моннан соң алган хатыннарының күбесе дә шушы сәбәптән булганлыгы аңлашыладыр.

## Гайшәгә өйләнү

Хәдичә вафатыннан соң рәсүлуллаһ Әбү Бәкернең кызы – Гайшәгә өйләнде. Гайшә бу вакытта 6-7 яшендә генә иде. Рәсүлуллаһның кызлата алган хатыны ошбу Гайшә генәдер. 50 яшьлек бер картның 7 яшьлек бер сабыйга

www.darul-kutub.com

өйләнүе безгә, бездән дә бигрәк Европа милләтләренә бик ят һәм гаҗәп кебек күренсә дә, шәрыкъ әхвәленнән, моннан унөч ярым гасыр элеккеге Гарәбстан тарихыннан хәбәрдар булган кешеләргә монда бер дә гаҗәпләнерлек урын юктыр. Ул вакытларда 7-8 яшьлек кызларны 50 яшьлек кенә түгел, хәтта 60-70 яшьлек картлар да ала торган иде. Яшь кызларның картларга чыгуларын беркем дә кимчелек итеп санамый иде. Ул вакытта яшьлектән бигрәк тә дәрәҗә, шәрәфлек һәм идарә итү алда тотыла иде. Кызлар ирнең карт булуында үзләренә гарьлек хис итмиләр, ә гарьлек – яшь булса да хөрмәтсез, түбән, куркак кешегә чыгуда дип беләләр иде. Исламга тап төшерергә тырышкан кешеләр рәсүлуллаһның Гайшәгә өйләнүен, аның нәфесе сәбәпле дип пәйгамбәрлегенә шөбһә кертмәкче булалар. Ләкин болар Гайшәнең рәсүлуллаһка кияүгә чыгуына ничек шатланганын, рәсүлуллаһ никахында булуны үзенә никадәр зур дәрәҗә санаганын, рәсүлуллаһтан соң аның белән булган мөгамәләләрен ачыктан-ачык ләззәт һәм горурлык йөзеннән сөйләвен, моның өстенә рәсүлуллаһка хатын булу сәбәпле рухи ләззәтләргә ирешүен, «Умме-л-мүэминин» исеме алу шәрәфенә лаек булганын белсәләр яки белергә тырышсалар, бу сүзләреннән үзләре оялырлар иде. Кыскасы, Гайшәнең рәсүлуллаһка кияүгә чыгуында, румлылар горефенә караганда, асылда ук аңа кимчелек һәм золымлык юктыр. Гайшә шул яшендә башка шәрәф бер кешегә соралса, әлбәттә, атасы бирер иде. Гайшә дә бармыйм дип тормас иде. Шулай ук аның үз яшьтәшләре дә бик яшьли шундый кияүләргә чыгалар иде. Ләкин рәсүл, пәйгамбәр була торып, ничек мондый яшь кызны алды диярсез. Моның хикмәте шул иде.

Гайшә бик акыллы һәм зиһен иясе була. Бу кыз

пәйгамбәр янында тәрбия кылынган очракта, аннан Ислам хөкемнәрен өйрәнәчәге, шуңа нигезләнеп иҗтимагый тормышның яртысын тәшкил иткән хатын-кызларга зур остаз булачагы билгеле иде. Шуңа күрә рәсүлуллаһ аны теләде. Чыннан да, Гайшә соңрак фикыһ галимнәреннән саналды. Аның тарафыннан бик күп хәдис риваять ителде. Һәм Гайшәнең үзенчәлекле бик күп мәсьәләләре дә бардыр. Икенчедән, рәсүл тарафыннан Гайшәне алу Әбү Бәкернең күңелен табу иде. Әбү Бәкер рәсүлуллаһка ышанганнардан беренчесе, аның белән бергә бик күп кешеләрне Исламга дәгъвәт итүче, рәсүлуллаһ өчен һәрвакыт үзен фида итәргә әзер бер кеше булганнан, кызын аңа тапшырды.

## Таифкә дәгъвәт белән бару

Әбү Талиб вафат булганнан соң, Корәеш мөшрикләренең золымнары бик артты. Рәсүлуллаһ Таифкә барып, аның башлыкларыннан яклауларын сорарга булды. Таиф гарәпләре Корәешләрнең дошманнары булганлыктан, шуның өстенә анда рәсүллуллаһның якыннары торганлыктан, пәйгамбәребез аларның ярдәм итәчәкләренә өметләнде. Шулай итеп, рәсүлуллаһ Зәйд бине Хәрисә белән Таифкә сәфәргә китте. Ул вакытта Таиф башлыклары Гамр бине Гумәйр әс-Сәкафи балаларыннан Габдулләйл, Мәсгуд, Хәбиб исемендәге кешеләр иде. Рәсүлуллаһ Таифтә ун көн торып, андагы башлыкларны күреп ярдәм таләп итсә дә, һичбер нәтиҗә булмагач, җавапларыннан күңелсезләнеп, бу мәсьәләне Корәеш мөшрикләренә җиткермәүләрен үтенде. Ләкин алар моны да кабул итмәделәр. Киресенчә, алар рәсүлуллаһка Таифтән тизрәк китәргә куштылар һәм халык-

www.darul-kutub.com

ны пәйгамбәргә каршы котырттылар. Рәсүлуллаһ кайгылы хәлдә Зәйд бине Хәрисә белән Таифтән чыгып китте. Юлда рәсүлуллаһның артыннан азгын яшьләр ташлар атып кудылар һәм мөбарәк үкчәләрен җәрәхәтләделәр. Юлда Гутбә һәм Шәйбәнең бакчасы янында бер йөзем агачы төбенә хәл жыярга утырдылар. Ошбу жирдә рәсүлуллаһ «Таиф догасы» исемле мәшһүр догасын кылды. Доганың бер өзеге шуннан гыйбарәттер:

«اَللَّهُمَّ إِنِّي أَشْكُو إِلَيْكَ ضَعْفَ قُوَّتِي وَ هَوَانِي عَلَى النَاسِ
يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ أَنْتَ رَبُّ الْمُسْتَضْعَفِينَ وَ أَنْتَ رَبِّي
إِلَى مَنْ تَكِلُنِي إِنْ لَمْ يَكُنْ بِكَ غَضَبٌ عَلَيَّ فَلَا أُبَالِي»[1]

Бакчада Готбә белән Шәйбә дә бар иделәр. Алар рәсүлуллаһның бу хәлдә булуын күргәч, җәлләп бер салкум йөзем бирделәр. Рәсүлуллаһка йөзем китереп бирүче Гаддәс исемендәге насрани кулыннан йөземне алып, «Бисмилләһи әр-рахмәни әр-рахим» – дип ашый башладылар. Насрани моңа гаҗәпләнеп: «Бу җирнең халкы мондый сүзне әйтми бит», – диде. Рәсүлуллаһ моңа: «Син кай җирдән, нинди диндә син?» – диде. Егет: «Мин Нинәвәдән насрани бер кешемен», – диде. «Ә, изге кешенең Юныс бине Мәтәнең авылдашы икәнсең», – диде рәсүлуллаһ. Гаддәс тагын да гаҗәпләнеп: «Син Юнысны каян беләсең?» – диде. Шунда рәсүлуллаһ моңа Юныс хакында булган Коръән аятьләрен укыды. Бу вакытта Гаддәс тәэсирләнеп, Исламияткә килде.

Рәсүлуллаһ Нахләгә җитеп, төн вакытында намаз

1 «Ий Аллаһым минем, көч вә куәтем калмады! Халык күзендә хөрмәт вә игътибарлыгым калмады, ий Әрхамә әр-Рахимин! Син зәгыйфьләргә ярдәм бирүчесең, мине кемгә тапшырасың инде? Әгәр Синең миңа ачуың булмаса, бу мәшәкатьләргә әһәмият бирмәячәкмен» – диде. – авт.



www.darul-kutub.com

укыганда берничә женнең Коръән сүзен тыңлап, Исламга кергәннәрен сира галимнәре риваять итәләр. «Әхкаф» [Комлык] сүрәсендәге 29-32 аятьләр бу хакта диләр. Моннан башка женнәр хакында «Жен» сүрәсендә күбрәк мәгълүматлар булып, анда женнәрнең Коръәнне тыңлап, иман китерүләре аңлатыладыр. Бу риваятьнең дөреслегендә шөбһә юктыр. Коръәннән мүтәвәтир хәбәр килгәндә, әлбәттә, ышанабыз.

## Мутгыйм бине Гади химаясында Мәккәгә керү

Рәсүлуллаһ Мәккәгә якынлашкач, Хузәга кабиләсеннән бер кешене туры китереп, Мутгыйм бине Гадигә җибәрде вә аңардан химаясына алуын үтенде. Мутгыйм моны кабул итте вә кичекмәстән улларына һәм якыннарына мәсьәләне анлатып, Кәгъбә янына барды. Шул арада рәсүлуллаһ та, Зәйд бине Хәрисә белән Мәккәгә кереп, Кәгъбәтуллаһ янына килде. Мутгыйм дөя өстендә булган хәлдә халыкка үзенең Мөхәммәд галәйһиссәламне химая астына алуын игълан итте. Бу вакыт рәсүлуллаһ рөкенгә китеп, аны истиләм кылды һәм ике рәкәгать намаз укыды. Соңра Зәйд бине Хәрисә белән өенә кайтып киттеләр. Мутгыйм һәм якыннары коралларын таккан хәлдә рәсүлуллаһны өенә кадәр озаттылар[1].

Монда бер уй килә: ни өчен Мөхәммәд галәйһиссәлам бу кадәр мәшәкатьләрне үзенә йөкли соң? Нәтиҗәсе мәгълүм булмаган бер эш өчен ник ул кадәр газаплана? Үзен бо-

1 Рәсүлуллаһ Мутгыйм бине Гадинең бу яхшылыгын һәм бойкотны бетерү өчен түккән хезмәтен бер дә онытмый, аны һәрвакыт исенә төшерә иде. Бәдер сугышында җитмеш мөшрик әсир ителгән соң: “Бу әсирләрне Мутгыйм бине Гади сәламәт булып килеп сораса,аның хәтере хөрмәтенә җибәрер идем” – дип Бохарида (4 т., 91 б.) килә. Чыннан да, Мутгыймның бу эшләре аның вөҗдан иясе галиҗәнап бер кеше икәнлеген күрсәтә. – авт.

www.darul-kutub.com

тарлап ташлаулары мөмкин булган каты бәгырьле Таиф гарәпләреннән ник ярдәм сорамакчы була ул? Мәккәдә тыныч кына, рәхәт кенә тормыш итсә булмас идеме? Аның бөтен теләкләрен Мәккә мөшрикләре үтәячәкләр иде бит!

## Исра һәм мигъраҗ

Исра – рәсүлуллаһның бер кич Мәккәдә Хәрам мәчетеннән Бәйтүл Мукәддәскә барып кайтуыннан гыйбарәттер. Мигъраҗ исә, шул кич күккә ашып, рухани галәм белән танышуыннан гыйбарәттер. Исра һәм мигъраҗ хәдис һәм игътикад китапларында тәфсилләнәдер. Шуңа күрә бу урында аны искә төшереп торуда хәҗәт юктыр. Исра Коръәндә зекер ителәдер[1]. Мигъраҗ исә, Коръәндә зекер ителмичә, сахих һәм сахих булмаган хәдис китапларында искә алынадыр. Ләкин галимнәр «исра» белән «мигъраҗ»ны икесен бергә китерәләр. Хәлбуки, болар аерым йөртелергә тиеш иде. Чөнки мигъраҗ турында әйтелгән хәдисләрнең күбесендә Хәрам мәчетеннән Бәйтүл Мукәддәскә бару зекер ителсә дә, Коръәни Кәримдә күккә ашу турысында һичбер сүз зекер ителмидер. Шуның өчен болар икесе ике төрле нәрсә итеп йөртелергә тиешләр.

Хәрам мәчетеннән Бәйтүл Мукәддәскә баруның да, күккә ашуның да, уяу хәлдә булумы яисә төштә булуымы арасында сәләф һәм Ислам галимнәре арасында ихтилаф бардыр. Күпчелек бу хәлләрне уяу булган хәлдә дигәндә,

1 “Исра”/1. – авт.

“Үзенең колы Мөхәммәд галәйһиссәламне бер кичтә Мәккә шәһәрендәге Хәрам мәчетеннән Коддус шәһәрендәге Әкъса мәчетенә йөртеп кайтаручы Аллаһы һәр кимчелектән пакь дип белегез! Ул Коддус шәһәренең тирәсен бәрәкәтле кылдык, Мөхәммәд галәйһиссәламне шулай кодрәтебез белән йөрттек, гаҗәп галәмәтләребезне күрсәтмәк өчен. Әлбәттә, Аллаһы – ишетүче вә күрүчедер" – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

кайберәүләр төштә булган диләр. Төштә булды диючеләр сахих хәдистә Коръәндәге исра хакында булганлыгы аңлатылган:

«وَمَا جَعَلْنَا الرُّؤيَا الَّتِي أَرَيْنَاكَ إِلاَّ فِتْنَةً لِّلنَّاسِ» [1]

аяте белән «шәрик» хәдисен дәлил итеп тоталар. Шул аятьтәге «руэя» - төш мәгънәсендәдер. «Шәрик» хәдисендә (Әнәстән риваять ителә) «шуннан соң уянды» дигәне, моның төштә булганлыгын ачык күрсәтә. Шулай ук мигъраҗ хәдисләрендәге, «Мин өйдә идем, бу эш төш белән уяну арасында булды» сүзләре дә моның төштә булуын белдерә диләр. Исра вә мигъраҗның төштә булуы Гайшә, Мугавия вә Хәсән Басридан риваять ителәдер. Гайшә: «Дөреслектә, Аллаһы пәйгамбәренең тәне югалмады, әмма Аллаһы аның рухын исра кылды», – дип әйтә торган булган. Мугавия исра хакында сораганда: «Аллаһыдан булган төш хактыр», –дия торган иде[2].

Исра шөбһәсез булганга, Коръәни Кәрим белән исбат ителгәнгә, аңа ышану тиешледер. Ул хәлнең төштә яки уяу хәлдә булуын Аллаһының үзенә тапшыру артыграктыр.

Мигъраҗ хакында хәдисләр бик күп булып[3], эчтәлекләре гаять каршылыклы булган хәдисләр дә аз түгелдер. Шуның өчен галимнәр мигъраҗ хәдисләрен берләштерүдә күп мәшәкатьләр чигәләр. Ошбу ихтилаф хәдисләрнең бәгъзеләре мигъраҗның әллә ничә мәртәбә булуын сөйләгәннәр. Мигъраҗ хәдисләрендә гакылга ерак нәрсәләр дә юк түгел. Мигъраҗ хәдисләренең нигезе

1 «Сиңа күрсәткән төшне кешеләргә фетнә иттек» «әл-Исра»/60. – тәрҗ.

2 “Тәфсирү Ибн Җәрир”, 15 т., 13 б. – авт.

3 Мигъраҗ хәдисләренең күбесе Әнәс ибн Мәликкә кайтып кала – авт.



www.darul-kutub.com

һәм мәтеннәре дөрес булган тәкъдирдә дә игътикад вәҗиб мәсьәләләрдән түгелдер. Чөнки әхәд хәбәр шикле генә мәгълүмат биреп, игътикади мәсьәләләрдә катгый дәлил белән исбат ителүе ләземдер[1].

Исра кичәсендә Аллаһы Тәгалә мөселманнарга биш вакыт намаз фарыз кылды. Бу вакытка кадәр рәсүлуллаһ иртән ике рәкәгать, кич ике рәкәгать намаз гына укый торган иде. Исра күпчелек сүзенә караганда, һиҗрәттән бер ел элек булды.

## Мәдинәгә һиҗрәт

Рәсүлуллаһ Мәккәдә ун ел буе халыкны ачык сурәттә иманга дәгъвәт итте. Хаҗ вакытында җыелган төрле гарәп кабиләләренең башлыкларын Исламга өндәде. Моннан башка Миҗәннә, зүл-Мәҗәз, Гукәз кебек зур ярминкәләргә килеп, төрле кабилә башлыкларын күреп, аларны Исламияткә чакырып, үзен яклауларын үтенә иде. Бу ысул белән рәсүлуллаһ үзен бик күп кабиләләргә танытса да, һичбер кабилә аны якламады. Киресенчә, аны начар рәвешчә кагалар иде.

Кәгъбәтуллаһны зиярат итәр өчен килүче гарәпләр арасында Ясрибтә торган «Әус» һәм «Хазраҗ» кабиләләре бар иде. Ул кабилә кешеләре Ясриб яһүдиләреннән шул көннәрдә Ибне Исмәгыйльдән ахыргы заман пәйгамбәре киләчәге турында ишетәләр иде. Чыннан да, Мөхәммәд рәсүлуллаһның пәйгамбәрлеге алдыннан яһүд һәм насара галимнәре авызыннан һәрвакыт мондый сүзләр ишетелер иде.

Бервакыт хаҗ вакытында рәсүлуллаһ Әус кабилә-

1 Мигъраҗ хакында риваять ителгән хәдисләр: Бохари 1 т., 78 б.; 2 т., 201 б.; 4 т., 109 б., 135 б., 152 б., 163 б.; 5 т., 52 б. 53 б; Тирмизи 1 т., 29 б.; 2 т., 141 б; Нәсәи 1 т., 76 б., 77 б; Мөслими 1 т., 78 б. – авт.

сендәге Сүвәйд бине Самит исемле кешегә Исламны дәгъвәт итте. Сүвәйд кабул итмәсә дә, бөтенләй каршы да тормады. Икенче хаҗ вакытында Әяс бине Мүгаз исемле кеше рәсүлуллаһның сүзен кабул итү дәрәҗәсенә килгән иде. Өченче хаҗ вакытында рәсүлуллаһ Хазраҗ гарәпләреннән Әсгад бине Зирара, Гаүф бине Харис, Рафигъ бине Мәлик, Кутбә бине Гамир, Гукбә бине Гамир, Җәбир бине Габдулла исемендәге алты[1] кешене Гакабәдә очратып, Исламга дәгъвәт кылды[2]. Шул зекер ителгән кешеләр Исламиятне кабул итеп, Ясрибкә кайтып киттеләр. Болар Ясрибкә кайткач, сүзләре үтә торган кешеләрне диннәренә дәгъвәт иттеләр. Боларның дәгъвәты илә Ясрибтә байтак кына кеше Исламны кабул итте. Икенче елны Ясрибтән хажга унике кеше барды: Әсгад бине Зирара, Гаүф бине әл-Харис, Мугаз бине әл-Харис, Рафигъ бине Мәлик, Зәквән бине Габдүкайс, Губәдә бине әс-Самит, Йәзид бине Сәгъләбә, Габбас бине Губәдә, Гукбә бине Гамир, Әбүлһәйсәм бине әт-Тәйһән, Гувәйм бине Сәгыйдә.  Болардан бишесе элек Исламны кабул иткән кешеләр булып, калган җидесе мөшрикләр иде.

Рәсүлуллаһ боларны Гакабәдә күреп, Ислам хакында сөйләде. Бу мөшрикләр дә Ислам динен кабул иттеләр һәм рәсүлуллаһка Аллаһыдан башка һичберәүне ширек тотмаска, урламаска, зина кылмаска, балаларны үтермәскә, ифтира һәм боһтан кылмаска, мәгъруф эшендә рәсүлуллаһка каршы килмәскә сүз бирделәр. Мәккәне алу көнендә хатыннардан ошбу нәрсәләргә бәйгать алынганы өчен, шул бәйгатькә «Бәйгатү ниса»[3] диделәр.

---

1 “Зәдүл-Мәгад” 1 т., 306 б. Ибнү әл-Әсир, Гамир бине Габдү Харисәнең дә булуын сөйли. Аңа нигезләнеп саннары җиде булыр. – авт.

2 Гакабә – Мина белән Мәккә арасында, Мәккәгә өч чакрым ераклыктагы бер чокырлык урыныдыр. Хаҗда таш атыла торган урыннарның берсе шулдыр. – авт.

3 Хатыннар бәйгате. – тәрҗ.

Рәсүлуллаһ боларга Коръән вә дин өйрәтер өчен Мусгәб бине Гумәйрне җибәрде[1]. Мусгәб Мәдинәгә баргач, Әсгад бине Зирараның өенә төште. Мусгәб белән Әсгаднең дәгъвәт тырышлыгы белән Ясрибтә Ислам көчәя башлады. Хәтта Ислам кермәгән һичбер өй калмады. Әус башлыкларыннан мәшһүр Сәгъд бине Мугаз вә Усәйд бине Хузәйр дә Мусгаб бине Гумәйр кулы астында Исламны кабул иттеләр. Мусгәб икенче елның хаҗы алдыннан яңадан Мәккәгә кайтып китте[2].

Икенче елны хаҗга Ясриб гарәпләреннән бик күп кеше килде. Болар арасында мөселманнардан 75 кеше (2се хатын) бар иде. Рәисләре Бәрра бине Мәгъруур иде. Болар хаҗ гамәлләрен башкаргач, Гакабәдә рәсүлуллаһ белән күрешеп, бәйгать бирергә вәгъдә кылдылар. Рәсүлуллаһ белән күрешүләрен Мәккә мөшрикләреннән һәм үзләренең иптәшләреннән яшерү өчен төн уртасында берәм-берәм Гакабәгә юнәлделәр. Иптәшләре исә һичбер нәрсә сизмәделәр. Рәсүлуллаһ Гакабәгә әтисенең бертуганы Габбас бине Габделмоталлиб белән килде. Рәсүлуллаһ Габбасны ясриблеләр белән булган килешүен ныгыту өчен алып килгән иде. Габбас ул вакытта әле Исламга кермәгән иде. Халык җыелып беткәч, Габбас аларга: «Мөхәммәднең безнең арада никадәр хөрмәте барын беләсез, якыннары аны һәрвакыт саклаячак. Ләкин аның сезнең белән буласы килә.

1 "Ибн Һишам" 1 т., 237 б. "Зәдүл-Мәгад"тә, 1 т., 306 б., Мусгаб белән бергә Ибн Умм Мәктүм дә бар иде диелә. Ләкин моңа күңел бик тулып җитми. Чөнки ул вакытта Ясрибдә Исламиятне кабул иткән кеше бик аз иде. Бигрәк тә Ибн Умм Мәктүм сукыр да булгач, анда тору бик һәлакәтле иде. Шуңа күрә андый һәлакәтле вакытта аның җибәрелүе, акылга сыймаслыктыр. Ибн Умму Мәктүмнең җибәрелүе Гакәбәдәге икенче бәйгатьтә булса кирәк. Бохаридагы, 5 т.,66 б., "Безгә беренчеләрдән Мусгаб бине Гумәйр һәм Ибн Умм Мәктүм килде. Алар икесе дә Коръән укый иделәр. Алардан соң Биләл, Сәгъд һәм Гаммәр бине Йәсир, шуннан соң Гомәр бине әл-Хаттаб килде..." хәдисендә бу аңлатылып килә. – авт.

2 "Зәдүл-Мәгад" 1 т., 306 б. – авт.

Әгәр дә сез вәгъдә иткән нәрсәләрегезне үтәячәк булсагыз, бик әйбәт, әгәр дә вәгъдәгездә тора алмасагыз, Мөхәммәднең күңелен кузгатмагыз!» – мәгънәсендәге сүзләр сөйләде. Ясриблеләрнең башлыгы Бәрра бине Мәгърур: «Без, әлбәттә, сүзебездә торачакбыз, кылган вәгъдәбезне җиренә җиткерәчәкбез, әгәр без сүзебездә торачак булмасак, монда килмәс идек», – дип җавап бирде. Соңра рәсүлуллаһтан бәйгать алуны үтенделәр. Рәсүлуллаһ әүвәл Коръән укыды вә аларга вәгазь сөйләде, соңра: «Хатын-балаларыгызны химая иткән шикелле, мине дә химая кылырга бәйгать бирегез!» – диде. Аннары Бәрра бине Мәгърур рәсүлуллаһның кулыннан тотып, бәйгать бирде. Шул арада Әбүлһәйсәм бине әт-Тәйһән сүзгә керешеп: «Әй рәсүлуллаһ, безнең белән яһүдиләр арасында килешүләр бар. Без сиңа бәйгать бирү белән ул мөнәсәбәтләребезне кисәчәкбез. Син мөшрикләрне җиңеп чыксаң, безне ташлап Мәккәгә үз якыннарың янына кайтып китмәссеңме?» – диде. Рәсүлуллаһ моңа каршы елмаеп: «Юк. Мин һәрвакыт сезнең белән булачакмын!» – диде. Аннан соң халык берәм-берәм рәсүлуллаһка бәйгать бирә башладылар. Бу бәйгатькә «Гәкабату сәния» бәйгате диләр. Бәйгать тәмам булгач, рәсүлуллаһ болар арасыннан унике кешене рәис итеп билгеләде: 1) Бәрра бине Мәгърур, 2) Рафигъ бине Малик, 3) Сәгъд бине Әбү Хайсәмә, 4) Әсгад бине Зирара, 5) Әбүлһәйсәм бине әт-Тәйһән, 6) Әсид бине Хузайр, 7) Сәгъд бине әр-Рабигъ, 8) Сәгъд бине Губәдә, 9) Габдуллаһ бине Равәхә, 10) Габдуллаһ бине Гамру бине Харам, 11) Губәдә бине әс-Самит, 12) әл-Мунзир бине Гамру. Соңра рәсүлуллаһ боларга бик саклык белән генә өйләренә кайтып йокларга кушты.

Бәйгать хәбәре ничектер Корәеш гарәпләренә

беленгәнлектән, Корәеш гарәпләре иртән Ясриб гарәпләренең урнашкан җирләренә килеп: «Сез безнең белән сугышу өчен Мөхәммәд саләллаһу галәйһи вәссәлам белән сүз куешкансыз. Хәлбуки, сезнең белән бозылышуыбыз һәм сезнең белән сугышуыбыз, аслән, матлүб түгел», – диделәр. Моны аңламаган ясрибле мөшрикләр антлар белән инкарь итә башладылар: «Бу эш булырга мөмкин түгел. Булса да без белми калмас идек», – диделәр. Соңра Ясриб гарәпләре кайтып китте. Рәсүлуллаһ Ясрибкә килгән очракта, Ясриб гарәпләре үлгәнче аны сакларга, аңа кулдан килгәнчә ярдәмне кызганмаска вәгъдә биргәнгә, аларга «Әнсари» диделәр.

## Ясрибкә һиҗрәт

Моннан соң рәсүлуллаһ сәхабәләргә Ясрибкә һиҗрәт итәргә әмер бирде. Шуңа күрә сәхабәләр, бер-бер артлы Ясрибкә һиҗрәт итә башладылар. Мәккәдә яклаучысы булмаган кайбер кешеләрдән һәм рәсүлуллаһ белән гаиләсе, Әбү Бәкер гаиләсе һәм Гали бине Әбү Талибтан башка мөселманнар калмады.

Мәккә мөшрикләре сәхабәләрнең Мәдинәгә күчеп бетүен, рәсүлуллаһның да бервакыт анда барачагын вә Ясриб гарәпләре белән куәт җыеп, аларның башларына зур бәла булачагын исәпкә алып, моның чарасын күрергә юл эзли башладылар. Моның өчен «Дәру ән-Нәдвә»дә зур киңәш мәҗлесе ясап, рәсүлуллаһка карата нинди чаралар күрү турында киңәшләшә башладылар. Төрле кеше төрле фикер сөйләде, кайсылары: «Аны богаулап, зинданга ябып куйыйк, шунда үлсен», – диделәр. Ләкин бу хәбәр рәсүлуллаһның иярченнәренә ишетелеп, алар аны коткарырга киләчәкләре

www.darul-kutub.com

мәгълүм булганнан, бу фикер кабул ителмәде. Мәккәдән куу фикере куелса да, «Ул барган җирендә халыкны үзенә каратыр, аның татлы теленә халыкның әсир булуы күз алдында, ул үзенә халык җыеп, соңра башыбызга бәла булыр», – дип кабул итмәделәр. Иң ахырда Әбү Җәһил бине Һишам шушы фикерне ачыклап бирде: «Без, бөтен Корәеш кабиләләреннән берәр егет сайлап, кулларына үткен кылыч бирик, алар Мөхәммәднең өен камап алсыннар һәм Мөхәммәд өеннән чыккан вакытта, бөтенесе бердәм һөҗүм итеп, аны үтерсеннәр. Бу вакыт Мөхәммәднең якыннары булган Бәну Габдүмәннаф Мөхәммәдне үтерүчеләрдән касас таләп итә алмас, бәлки үтергән өчен акча алып канәгатьләнер», – диде. Бөтенесе шул фикерне  уңай күрде, шул кич унике егеткә рәсүлуллаһның өен камап алып, ул ишектән чыккан вакытта бердәм һөҗүм итеп, үтертергә карар биреп таралдылар.

Мәккә мөшрикләренең шул карарларын Аллаһы Тәгалә рәсүленә белдерде һәм Мәккәдән шул төндә чыгып китәргә әмер бирде. Рәсүлуллаһ Әбү Бәкергә барып мәсьәләне сөйләде. Әбү Бәкер: «Я рәсүлуллаһ, мине дә үзең белән бергә алып китәсеңме?» – дип сорагач, рәсүлуллаһ: «Әйе, бергә китәчәкбез», – диде. Әбү Бәкер моны ишеткәч, шатлыгыннан елап җибәрде. Бу вакытка кадәр Әбү Бәкер Ясрибкә һиҗрәт кылырга рөхсәт сораса да, рәсүлуллаһ рөхсәт бирми тора иде. Әбү Бәкер юлга чыгарга ике дөясен әзер тота иде. Шуларның берсен рәсүлуллаһка биреп маташса да, акчасыз алырга риза булмады. Соңыннан акчасын түләргә булып алды. Әбү Бәкер гаиләсе мосафирлар өчен азык әзерләде. Мөсафирлар үзләренә юл күрсәтеп Мәдинәгә алып бару өчен Габдулла бине Урайкыйт исемле бер мөшрикне яллап, дөяләрен аңа тапшырдылар вә өч

www.darul-kutub.com

көн үткәч «Сәур» тавындагы тау тишегенә дөяләрне алып барырга куштылар. Рәсүлуллаһ кич белән Әбү Бәкер өенә килеп, аннан икесе бергә Сәур тавына барырга булып өенә кайтып китте. Өенә кайткач, Гали бине Әбү Талибны чакырып мәсьәләне сөйләде. Аңа мөшрикләрнең күзен буяр өчен үз ятагына ятарга кушты. Үзеннән соң алачак-бирәчәкләрен башкарырга, соңрак Ясрибкә барырга боерды.

Караңгы төшү белән әлеге Корәеш егетләре рәсүлуллаһның өен камап алдылар. Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә ышанган рәсүлуллаһ беркадәр вакыт өйдән чыкмады. Озакламый ул мөшрикләр бөтенесе каты йокыга киттеләр. Шул вакытта гына рәсүлуллаһ өеннән чыгып, Әбү Бәкер янына китте. Аннан бик саклык белән алар Сәур тавына юнәлделәр һәм анда бер тау тишегенә кереп яшеренделәр. Корәеш егетләре таңга кадәр рәсүлуллаһның өен саклап, рәсүлнең чыкмаганын күргәч, өйгә басып керсәләр дә, рәсүлуллаһның ятагында Галине күргәч, шашып калдылар. Галидән рәсүлуллаһ турында сорап та җавап ала алмагач, аны каты сурәттә кыйнадылар. Соңра вакыт үткәрмәстән, рәсүлуллаһны эзләргә керештеләр. Һичбер ханәне, Мәккә тарафларындагы чокырларны, тауларны калдырмадылар, барысында да эзләделәр. Рәсүлуллаһ белән иптәшен табып китергән кешегә Мәккә башлыклары зур бүләкләр әзерләде. Мөшрикләр рәсүлуллаһны эзләгәндә Сәур тавына әллә ничә мәртәбә барсалар да, тау тишегенә кермәделәр. Шул вакыт Әбү Бәкер мөшрикләрнең аяк тавышларын ишетеп бик нык курка, хәтта елый иде. Рәсүлуллаһ: «Кайгырма, Аллаһы безгә ярдәм бирәчәк», – дип аны юата иде. Шул рәвешчә рәсүлуллаһны өч көнгә кадәр эзләүләре дәвам итсә дә, табудан гаҗиз булып туктадылар. Рәсүлуллаһ белән Әбү Бәкер

өч көн буена шул Сәүр тавындагы куышлыкта яттылар. Әбү Бәкернең улы Габдулла һәр төн шул куышлыкка барып, мөшрикләрнең ни эшләгәннәрен хәбәр итеп, аларга азык илтә иде. Әбү Бәкер азат иткән колы Гамир бине Фүһәйра Әбү Бәкернең куйларын шул тирәдә йөртеп, Габдулланың аяк эзләрен югалттыра иде.  Өч көн үткәннән соң, вәгъдә буенча Габдулла бине Урайкыйт дөяләрне алып килде. Бер дөягә рәсүлуллаһ, икенчесенә Әбү Бәкер белән Гамир бине Фүһәйра атланып, төн уртасында юлга чыктылар. Габдулла бине Урайкыйт алдан юл күрсәтеп китте. Ясрибкә туры юл белән бару хәтәр булганга, алар Кызыл диңгез буеннан киттеләр. Кудайд тирәсендә яшәгән Ибне Мүдлиҗ кабиләсеннән үткәндә, бер кеше боларны ерактан күреп калып, бер җиргә җыелган халыкка килеп: «Мин яңа гына шул тарафта дөягә атланган кешеләрне күрдем, алар Мөхәммәд һәм аның иптәшләре булырга тиеш», – диде. Мәҗлестә Сурака бине Малик дигән кеше бар иде. Ул рәсүлуллаһ тотылган өчен бирелә торган түләүне үзенә генә аласы булып, аларны алдау нияте белән: «Юк, алар фәлән-фәлән кешеләр булырга кирәк, алар югалган малларын эзләргә чыкканнар», – диде. Халык икенче мәсьәләгә күчкәч, Сурака өенә кайтып, коралланып, атына атланды да, рәсүлуллаһ артыннан төште. Әбү Бәкер бик курыкканга, һәрвакыт артына әйләнеп карый, рәсүлуллаһ исә бик тыныч бер хәлдә бара иде. Әбү Бәкер бервакыт артына әйләнеп караса, Сураканың артларыннан килеп җитеп барганын күреп бик курыкты вә рәсүлуллаһка әйтте. Рәсүлуллаһ моңа: «Курыкма, Аллаһы безгә ярдәм бирер», – диде.  Чыннан да озак та үтмәде, Сураканың аты абына, сөртенә башлады. Ахырдан алгы аяклары җиргә бата башлап, бара алмас булды. Сурака мәсьәләне аңлап,

рәсүлуллаһтан дога кылуын үтенде һәм аңа начар эш кылмаска сүз бирде. Рәсүлуллаһка кайбер азык һәм киемнәр бирергә теләсә дә, ул: «Безгә кирәге юк, син безгә хезмәт итәсең килсә, безне эзләп килә торган халыкны кире җибәр», – диде. Сурака боларга халыкны кире җибәрергә сүз биреп, кайтып китте вә юлда рәсүлуллаһны эзләп барган кешеләргә: «Ул тарафта бер кеше дә юк», – дип кире кайтарды. Ошбу вакыт Сураканың таләбе белән рәсүлуллаһ аңа килешү язуы бирүе риваять ителә.

## Әнсариларның рәсүлуллаһны каршы алырга чыгулары

Рәсүлуллаһның Мәккәдән Ясрибкә хиҗрәт итүе әнсариларга ничектер ишетелгән иде. Шунлыктан, алар рәсүлуллаһны каршы алыр өчен һәр көн Хәррагә чыгып, көн эсселәнгәнче көтәләр, юлчылар күренмәгәч, кире кайтып китәләр иде[1]. Бер көн, гадәттәгечә, хәррага чыгып көн эссе булганчы көтеп торсалар да, мосафирларны күрмәгәч, тагын кайтып киттеләр. Шул вакыт үзенең бер йомышы белән Ясрибнең калку урыннарыннан берсенә менгән бер яһүди, ерактан юлчылар килгәнен күреп, каты тавыш белән: «Көткән мосафирларыгыз килә, көткән бәхетегез әнә!» – дип кычкырды. Шул ук вакыт әнсарилар рәсүлуллаһны каршы алырга хәррагә киттеләр. Бөтен Ясриб шатлык һәм сөенеч авазлары вә тәкъбир тавышлары белән тулды. Хатын-кыз, бала-чага рәсүлуллаһ хакында шигырь вә мөнәҗәтләр әйтеп, аның Ясрибкә килеп төшүен сабырсызлык белән көтеп торалар иде.

1 Зур кара ташлыктан гыйбарәт җиргә "Хәрра" диелер. Мәдинәнең хәрраләре күп булып, зекер иткәнебез хәрра Куба янындадыр. Ул "Хәррату Куба" дип йөртелер. – авт.



www.darul-kutub.com

Рәсүлуллаһ вә иптәшләре, каршыларга килгән әнсарилар белән чолганып алынган хәлдә, Ясрибтән ике ярым чакрым ераклыкта булган, Ясрибнең көньяк-көнчыгышында урнашкан Куба авылында яшәгән Ибне Гамр бине Гауф гарәпләренә төшеп, Күлсүм бине әл-Һәдем өендә кунак булды. Әбү Бәкер исә Синх мәхәлләсендә Харижә бине Зәйд өенә төште. Бу вакыт пәйгамбәрлекнең унөченче елы, рабигыль-әүвәлнең сигезе, дүшәмбе көне иде[1]. Милади белән 622 ел, 20 сентябрь буладыр. Рәсүлуллаһ Кубада дүрт көн[2] (дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе) торды. Анда «Мәсжидү Куба» дип мәшһүр мәчеткә нигез салды.

Соңра җомга көн Ясрибкә юнәлде. Бәнү Сәлим мәхәлләсендә җомга вакыты ирешкәннән, анда җомга намазын укыды. Бу – рәсүлуллаһның беренче мәртәбә кылган җомгасы иде. Җомга намазы Мәккәдә үк фарыз кылынган булса да, анда бөтенесе җыелып гыйбадәт итү мөмкин булмаганлыктан, анда җомга намазын укый алмады. Мәдинә халкы исә рәсүлуллаһ килгәнче үк җомга намазын укый иде. Мәдинә халкын җыеп, иң башлап җомганы укыган кеше Әсхәд бине Зурарадыр[3]. Ошбу җомгада рәсүлуллаһның түбәндәге хөтбәне сөйләве риваять ителәдер: «Әй, җәмәгать! Ахирәтегез өчен әзерләнегез, изге гамәлләр кылыгыз, шәфкатьлелек вә яхшылык кылыгыз! Сез, әлбәттә, бер вакыт үлеп, дөнья малларыгыздан аерылып, Раббыгыз

1 Астрономия галимнәреннән мисырлы Мәхмүд пашаның исбатлавы буенча бу көн рабигыль-әүвәлнең сигезе, дүшәмбе көненә туры килә. Сира галимнәре исә, уникесендә диләр. Мәхмүд пашаның фикере гасырыбызның галимнәре тарафыннан кабул ителгәнгә күрә, без дә аларга иярдек. – авт.

2 Рәсүлуллаһның Кубада күпме калуы хакында сира һәм тарих галимнәре арасында ихтилаф булып, күпчелек Ибн Исхакка ияреп, дүрт көн булуын өстенрәк күрәләр. Ибнү әл-Кайим хәзрәтләре Кубада тору ундүрт көн иде диде. Кубада ундүрт көн тору Бохарида (5 т., 68 б.) Әнәс хәдисендә киләдер. Ләкин бу кадәр тору акылга ерактыр. – авт.

3 “Зәдүл-Мәгад” 1 т.,101 б. – авт.



www.darul-kutub.com

хозурына барачаксыз. Раббыгыз сезгә: «Мин сезгә рәсүл җибәрмәдемме? Сезгә мал бирмәдемме? Кайда кылган гамәлләрегез, кайда яхшылыкларыгыз?» – дип сораячак. Ул вакыт сезгә гамәлләрегездән башка арка таянычы булмаячак. Алдыгызда җәһәннәмнән башка бернәрсә дә күрмәячәксез. Шулай булгач, сез вә яхшылык кылып, җәһәннәм газабыннан котылырга тырышыгыз, ярты хөрмә булса да бирегез, шәфкатьлелек кылырга көче җитмәгән кеше хуш вә мөлаем сүзләр белән ярдәм итсен, чөнки Аллаһы һәр яхшылыкны арттырып кайтарачак».

Җомга көне – Ислам әһеле өчен бер бәйрәм көнедер. Рәсүлуллаһ ул көнне зурлый, ул көндә гыйбадәтен арттыра иде. Җомга көн госелләнә, хушбуй сөртә, жомга өчен иң яхшы киемен кия иде һәм сәхабәләргә дә шулай эшләргә куша иде. Рәсүлуллаһ җомга намазына халык җыелып беткәч чыга иде. Мәчеткә кергәндә, халыкка сәлам бирә. Минбарга менеп, халыкка каршы утыргач, Билал азан әйтә, азаннан соң рәсүлуллаһ торып, халыкка хотбә сөйләргә керешә иде.

Хөтбәне икегә бүлеп сөйли, ике хөтбә арасында аз гына утырып ала. Хөтбә тәмам булгач, Билал камәт әйтә дә, ике рәкәгать җомга намазы укыла. Ул вакыт азан бер генә мәртәбә әйтелә торган иде. Азан белән хөтбә арасында һичбер намаз укылмый иде. Бу җомгадан элек сөннәт намазлар укылмаганлыгын ачык күрсәтәдер[1]. Хөтбә укып торганда мәчеткә килеп кергән кешегә рәсүлуллаһның намаз укырга кушуы ике сахих [Бохари, Мөслими] һәм башкаларда искә алынса да, ул сөннәт булмыйча, «Тәхыййәтү әл-мәсҗид» намазыдыр[2]. Җомга фарызыннан элек исә сөннәт булырлык на-

1 “Зәдуль-Мәгад”, 1 т., 121 б. – авт.

2 “Зәдуль-Мәгад”, 1 т., 122 б. – авт.

маз юктыр. Рәсүлуллаһ мәчеткә чыгып хөтбәгә керешкәнче, сәхабәләр намаз укысалар да, ул сөннәт намаз түгел, бәлки тәтаувугъ намаздыр. Шуның өчен дә сәхабәләр җомга фарызыннан элек төрлесе төрле микъдарда нәфел намазы укыйлар иде. Җомгадан соң рәсүлнең өенә кереп, ике рәкәгать сөннәт намазы укыганлыгы ике сахихта, сәхабәләргә җомгадан соң дүрт рәкәгать укырга кушканлыгы Мөслимидә мәгълүмдер. Рәсүлуллаһ заманында «Ихтыятү зуһр» [өстәмә өйлә намазы] дип аталган намаз да укылмый иде[1].

Рәсүлуллаһ хөтбә сөйләгәндә халыкны үзенә якын утырырга, хөтбәне ихласлык белән тыңларга куша, сөйләшүдән тыя иде. Хөтбәсендә халыкка Ислам кануннарын, шәригать нигезләрен бәян итә, халыкны изге гәмәлләргә, яхшылык кылырга өнди иде. Рәсүлуллаһның хотбәләре, табигый, гел бер төсле генә булмыйча, төрле хәлләргә кагылышлы була иде. Хөтбә сөйләгәндә хаҗәте төшсә, хөтбәсен кыскарта да иде. Сәхабәләрдән берсе сорау бирсә, хөтбәдән туктап, аңа җавап бирә, соңра хөтбәсен дәвам итә иде. Хөтбә укыганда таякка таяна. Басып хөтбә укыр өчен, өч баскычлы бер минбары бар иде. Минбары ясалганчы, бер хөрмә бүкәненә сөялеп сөйли иде.

Хәзерге көндә имамнарыбыз бер хөтбәне өйрәнеп, 20-30 ел буенча шуны тәкърар итүләре, минбарга менеп каккан казык кебек катып, хөтбәләрне рифмага салып, салмак кына яшел тавышлар белән көйләп, халыкны тирбәтеп йоклатулары, укыган хөтбәләренең халык белмәгән вә аңламаган телдә булуы сөннәткә муафикъ булып бетәр микән?

1 “әл-Мәнар”, 7 т., 30-34 б., 221-224 б. – авт.

# Ясрибкә керү

Җомгадан соң рәсүлуллаһ дөясенә атланып юлын дәвам итте. Ясрибнең мәхәлләләреннән үткән саен, мәхәлләнең байлары вә бөекләре рәсүлуллаһ каршына чыгып, үзләренә төшүен үтенәләр, дөянең тезгененә ябышып, үз өйләренә борырга тырышырлар иде. Рәсүлуллаһ исә аларга дөяне үз ихтыярына куярга кушты вә дөя чүккән урынга төшәчәген әйтте.

Рәсүлуллаһның туганы булган Ибне Нәҗҗәр мәхәлләсенә җиткәч, дөя Әбү Әюб[1] (Халид бине Зәйд) әнсари өенә каршы бер урынга чүкте. Рәсүлуллаһ дөясеннән төшеп: «Урыныбыз, инша Аллаһы, ошбу булачак», – диде. Әбү Әюб рәсүлуллаһ дөядән төшү белән, аның әйберләрен өенә алып китте. Рәсүлуллаһ: [2] «الْمَرْءُ مَعَ رَحْلِهِ» – дип, Әбү Әюбда кунак булды. Әсгад бине Зурара дөянең тезгененнән житәкләп, үз йортына алып китте. Шулай итеп, рәсүлуллаһ белән аны алып килгән дөяне тәрбияләү хөрмәте бу ике затка насыйп булды. Әбү Әюбнең өе ике катлы булып, Әбү Әюб рәсүлуллаһны өске катка урнаштырмакчы булса да, рәсүлуллаһ янына килгән кешеләргә мәшәкать булуыннан куркып, аскы катны ихтыяр итте. Рәсүлуллаһ, үзенә өй салганга кадәрле, ошбу өйдә кунак булып торды. Үзенә Әбү Әюбның тәрбиясе өстенә әнсариларның бөекләреннән (Сәгыйд бине Губәдә, Әсгад бине Зурара кебек) һәр кич өч-дүрт табак ашамлык килеп тора иде.

Рәсүлуллаһ күчеп килгәч, Ясриб шәһәре «Мәдинәту әр-расүл» яки «әл-Мәдинә» дип йөртелә башлады, әүвәлге исеме онытылды. Мәдинәгә килгәндә рәсүлуллаһ 53 яшендә иде.

---

1 Мугавия халифә булган чорда Истанбул шәһәрен камап торганда вафат булды. Шәһәрнең тышына күмелде. Кабере хәзерге көндә дә бардыр – авт.

2 “Ир-ат үзенең багажы белән” – тәрж.

# Һиҗрәттән беренче ел

## *Рәсүлуллаһның гаиләсе килү*

Рәсүлуллаһ Мәдинәгә килгәч, Мәккәдәге гаиләсен алып килү өчен Зәйд бине Харисә белән Әбү Рафигъны Мәккәгә җибәрде. Алар Рәсүлуллаһның кызлары Үмм Гөлсем, Фатыйманы, Үмм әл-мүэминин Сәүдә бинте Зәмганы, Зәйд бине Харисәнең хатыны Үмм Әймән белән улы Усәмә бине Зәйдне алып килделәр. Рәсүлуллаһның кызы Зәйнәб исә, ире Әбү әл-Гас җибәрмәгәнгә килә алмады. Алар белән бергә Әбү Бәкернең улы Габдулла бине Әбү Бәкер дә этисенең гаиләсен (Әбү Бәкернең хатыны Үмм Рауман һәм кызлары Әсма белән Гайшә) алып килде. Хәзрәти Гали исә Рәсүлуллаһ Кубада булганда ук килеп җитте. Җәяү килгәнгә, каты арыган вә аяклары шешеп беткән иде. Рәсүлуллаһның аны күреп елаганлыгы риваять кылына.

## *Мәчет төзү*

Рәсүлуллаһ Мәдинәгә килү белән дөясе чүккән урынга мәчет салмакчы булды. Бу урын әнсари Мугәз бине Гафра[1] тәрбиясендә булган Сәһел вә Суһәйл исемле ике ятим баланыкы иде. Мугәз бине Гафра бу урынны бушлай биреп, ятимнәрне үзе ризалатмакчы булса да, рәсүлуллаһ моны кабул итмәде, ун динарга шул урынны сатып алды. Мәчет урынында хөрмә агачлары вә мөшрикләрнең каберләре бар иде. Рәсүлуллаһ агачларны кистерде, каберләрне казып тигезләтте. Мәчет гаять садә[2] суръәттә төзелде. Үзе кирпечтән, яңаклары таштан, баганалары хөрмә агачыннан булып,

1 "Зәдүл-Мәгад" сахибе бу ятимнәрнең Әсгад бине Зурара тәрбиясендә булуларын әйтәдер. 1 т., 311 б. – авт.

2 Садә – гади. – тәрҗ.

түбәсе хөрмә ботаклары белән ябылды. Идәненә вак ташлар җәелде. Мәчетнең биеклеге – 3 зирагъ (Гарәп зирагы ¾ аршин чамасыдыр) кадәр, озынлыгы – 100 зирагъ, киңлеге – 100 зирагъка якын иде. Мәчетнең өч ишеге булып, берсе зур ишек (төп керү ишеге), икенчесе караңгы ишек, өченчесе рәсүлуллаһның бүлмәсенә керә торган ишек иде. Бу вакыт рәсүлуллаһның хатыннары икәү генә иде. Моннан соң хатыннары арткан саен, бүлмәләр дә арттырылды. Мәчет бинасын төзегәндә бөтен әнсари катнашкан кебек, рәсүлуллаһ үзе дә эшли иде. Әнсарилар мәчет бинасын төзегәндә төрле касыйдәләр, шигырьләр көйлиләр иде. Арада рәсүлуллаһ та:

«اَللَّهُم لَا عَيْشَ إِلَّا عَيْشُ الْآخِرَةِ فَاغْفِرِ الْأَنْصَارَ وَ الْمُهَاجِرَةِ» [1]

– дип көйли иде.

## *Ахирәт дуслыгы*

Һиҗрәтнең беренче елында рәсүлуллаһ мөһәҗирләр белән әнсарилар арасында дуслык вә мәхәббәт урнаштыру өчен аларны бер-берсенә ахирәт дусты ясады. Шушы кардәшлек буенча берсе вафат булса, икенчесе аның мирасын ала иде. Бу кардәшлек бәйләнеше буенча мирас малын алу Бәдер сугышына кадәр дәвам итте. Соңра

«وَأُوْلُو الْأَرْحَامِ بَعْضُهُمْ أَوْلَى بِبَعْضٍ فِي كِتَابِ اللَّهِ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُهَاجِرِينَ» [2]

аяте иңдерелгәч, моның хөкеме бетерелеп, мирас якын туганнар арасында бүленә торган булды.

1 “Йә Раббым, ахирәт тормышыннан кала, тормыш юктыр. Әнсариларны һәм мөһаҗирләрне гафу ит” – тәрт.

2 «Аллаһының китабы буенча, якын туганнар бер-берсенә карата әнсарилар белән мөһаҗирләр арасына караганда да якынрактыр» «әл-Әхзәб»/33. – тәрҗ.

www.darul-kutub.com

Әнсарилар бу туганлык килешүен төземичә дә, мөһаҗирләргә кулларыннан килгән яхшылыкларны кызганмыйлар иде. Мал вә милекләреннән аерылып фәкыйрь бер хәлдә килгән мөһаҗирләрне тәрбия итүдә бер-берсе белән ярышалар, аларны үз өйләренә алалар, аларга үзләренең җирләрен, малларын бүлеп бирәләр иде. Кардәшлек килешүе төзегәч, бу дуслык вә мәхәббәт тагын да артты. Әнсарилардан Сәгыйд бине әр-Рабигъның ахирәт дусты Габдрахман бине Гауфкә ике хатыныннан үзе теләгәнен бирергә булуы бу туганлыкның ни дәрәҗәдә куәтле булуына дәлилдер[1].

## *Азан әйтелә башлау*

Мәккәдә вакытта намаз алдыннан азан әйтү юк иде. Чөнки анда вакытта рәсүлуллаһ һәм сәхабәләрнең җыелышып җәмәгать намазы укырлык мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә иде. Азан исә халыкка намаз вакытын белдерү һәм аларны намазга җыю өчен шәригатьтә каралгандыр. Шуның өчен дә рәсүлуллаһ Мәдинәгә килгәч, җәмәгать намазын укырга мөмкинлек тапкач, халыкка намаз вакытын ни рәвештә белдерү турында сәхабәләр белән киңәште. Сәхабәләрнең кайсысы әләм күтәрергә, кайсылары калку бер урынга ут ягу яки яһүдиләр кебек быргы куллану яки насаралар кебек чаң кагу шикелле киңәшләр бирсәләр дә, рәсүлуллаһ аларны кабул итмәде. Ниһаять, намазга тавыш белән чакырырга булдылар. Моның өчен махсус кешеләр дә билгеләнелде. Тавыш

1 Аллаһы Тәгалә “әл-Хәшер” сүрәсендә бу хосуста әнсариларны мактап әйтә: "وَالَّذِينَ تَبَوَّؤُوا الدَّارَ وَالْإِيمَانَ مِن قَبْلِهِمْ يُحِبُّونَ مَنْ هَاجَرَ إِلَيْهِمْ وَلَا يَجِدُونَ فِي صُدُورِهِمْ حَاجَةً مِّمَّا أُوتُوا وَيُؤْثِرُونَ عَلَى أَنفُسِهِمْ وَلَوْ كَانَ بِهِمْ خَصَاصَةٌ وَمَن يُوقَ شُحَّ نَفْسِهِ فَأُوْلَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ" {الحشر/٩}

[Кайсылары йортта (Мәдинәдә) яшәп аларга хәтле иманлы булдылар, алар үзләренә күченеп килгән мөһаҗирләрне яраталар һәм үзләренә бирелгәнгә хәҗәтләре юктыр. Аларның хаҗәте булган нәрсәләргә үзләренә караганда мөһаҗирләрне хаклырак дип табалар. Нәфесенең саранлыгыннан сакланган кешеләр – ахирәттә өстенлек тапкан кешеләрдер] “әл-Хәшер”/59. – авт.

белән чакыруга йөкләнелгән кешеләрдән Габдулла бине Зәйд әл-Әнсари, бервакыт төшендә бер кеше килеп, хәзерге көндә мәгълүм булган азанны өйрәтүен күрде. Йокыдан уяну белән рәсүлуллаһ хозурына барып мәсьәләне сөйләде. Рәсүлуллаһ та моңа каршы: «Синең төшең – тугры төш. Моннан соң шушылай чакырырбыз», – диде. Бу төшне сәхабәләрдән Гомәр дә күргән иде. Ул да моны рәсүлуллаһка сөйләп бирде. Шулай итеп һәр намаз алдыннан азан әйтелә башлады.

Рәсүлуллаһның Мәдинәдә мөәзиннәре ике иде: Билал һәм Ибне Үмм Мәктум. Ибне Үмм Мәктум иртә намазында: «Хәйя галәлфәләх»тән соң үзлегеннән ике мәртәбә: «Әссаләтү хайрүм минәннәүм»,[1] – дип әйтә иде. Рәсүлуллаһ моңа каршы бер сүз дә әйтмәде. Рамазан айларында иртә намазыннан элек сәхәр өчен дә бер азан әйтәләр иде. Икамәт исә, азан кебек булып, намазга керешер алдыннан әйтелә иде. Әбү Хәнифә мәзһәбендә азан белән икамәт икесе бер төследер. Шәфигый мәзһәбендә азан сүзләре икешәр әйтелеп, икамәттә берешәр генәдер. Малик мәзһәбендә исә азан һәм икамәт сүзләре берешәр генәдер. Азан һәм икамәтнең төрле булуы Мәдинә вә Мәккә мөәзиннәренең (Билал, Әбү Мәхзүра) төрлечә әйтүләреннән килеп чыккандыр.

Рәсүлуллаһ заманында җомга азаны бер генә мәртәбә әйтелә иде. Госман хәлифә булган вакытта, халык күбәеп, Мәдинә зурая башлагач, тагын бер азан арттырылды. Моның нәтиҗәсендә башта Зәурада бер азан әйтелә, соңрак имам минбарга менгәч, манарада бер азан әйтелә иде. Һишам бине Габделмалик моны да үзгәртте. Башта манарада бер азан, соңрак хатыйб минбарга менгәч, икенче азанны әйттерә башлады.

Мәдинә янында яһүдләрнең Бәну Курайза, Бәну

www.darul-kutub.com

1 “Намаз йокыдан хәерлерәк” – тәрҗ.

Нәзыйрь вә Бәну Кайнукагъ исемендә өч зур кабиләләре бар иде[1]. Рәсүлуллаһ Мәдинәгә килгәнче, шул яһүдләрнең Исламга килүләренә ышанычы бик зур иде. Чөнки алар китап әһелләреннән булып, аларның пәйгамбәрлек һәм Коръән хакында мәгълүматлары бар, Тәуратларында да рәсүлуллаһның килүе турында хәбәрләр бар иде. Ләкин эш рәсүлуллаһ уйлаганча булып чыкмады. Гомумән, яһүдләр рәсүлуллаһның дәгъвәтен кабул итмәделәр. Кайнукагъ яһүдләренең галимнәреннән булган Габдулла бине Сәлам һәм аңа ияргән берникадәр яһүд кенә Ислам динен кабул итеп, шәрафәткә ирештеләр. Башкалары исә, ахырзаман пәйгамбәренең Ибне Исраилдән килмичә, гарәпләрдән килүенә хөсед кылдылар. Үзләренең китапларын тәсдыклый торган Коръәни Кәримнең тәгълиматларына әһәмият бирмәделәр. Рәсүлуллаһ хакындагы хәбәрләрне дә төрлечә аңлатып, үзгәртеп, аннан башка пәйгамбәр киләчәк диделәр. Рәсүлуллаһка иң беренче башлап иярүче алар булырга тиеш иде. Киресенчә, алар рәсүлуллаһның дингә өндәвенә каршы төштеләр. Үзләре Исламиятне кабул итмичә генә калмадылар, башкаларны да аңардан биздерергә бөтен көчләрен сарыф кыла торган булдылар. Исламга яңа килгән гарәпләрне фетнәләүдә көчләрен җәлләмәделәр.

## *Яһүдләр белән килешү төзү*

Мәдинә яһудләре Исламны кабул итмәгәч, рәсүлуллаһ алар белән тыныч тору өчен килешү төзеде. Ошбу гаһед буенча яһүдләр һәрвакыт тыныч торачаклар, рәсүлуллаһның дошманнарына яһүдләр, яһүдләрнең дошманнарына

1 Әйтелгән яһүдләрнең урыннары гавәли тарафы булып Бәнү Нәзыйрь Батхан вәдисендә, Бәнү курайза "Мәһзур" исемендәге вәдидә, Бәнү Кайнукагъ "Кайнукагъ базары" дип аталган урында торалар иде. – авт.

рәсүлуллаһ ярдәм бирмәячәк. Рәсүлуллаһ белән сугыш башлаган кавемнәргә яһүдләр, яһүдләр белән сугыш башлаган кавемгә рәсүлуллаһ ярдәм бирәчәк иде. Ләкин озак вакыт үтмәде, яһүдләр берәм-берәм гаһедләрен боза башладылар. Моның нәтиҗәсендә, кайберләре җирләреннән сөрелергә, кайсылары кылычтан кичерелергә хөкем ителделәр.

## *Мәккәлеләр белән сугышырга рөхсәт килү*

Мәдинәгә һиҗрәт иткәнгә кадәр рәсүлуллаһ дошманнарына каршы корал кулланмый иде, бу эш моңа кадәр мөмкин дә түгел иде. Мәккәдә вакытта Корәеш мөшрикләренең иза һәм җәзалауларына, җәбер һәм золымнарына сабыр вә түземлек итүдән башка кораллары юк иде. Мәккәдә Аллаһы Тәгалә рәсүленә һәрвакыт аятьләр иңдереп, аның күңелен юата иде, башка пәйгамбәрләрнең дә кавемнәреннән әллә никадәр авырлыклар килгәнен сөйли иде. Дошманнары никадәр иза һәм җәфа кылсалар да, дәгъвәтны әзәйтмәскә, сабырлык һәм түземлелектән аерылмаска, аларга каршы дәлилләр белән эш кылырга куша иде.

«فَاصْبِرْ كَمَا صَبَرَ أُوْلُوا الْعَزْمِ مِنَ الرُّسُلِ وَلَا تَسْتَعْجِل لَّهُمْ كَأَنَّهُمْ يَوْمَ يَرَوْنَ مَا يُوعَدُونَ لَمْ يَلْبَثُوا إِلَّا سَاعَةً مِّن نَّهَارٍ بَلَاغٌ فَهَلْ يُهْلَكُ إِلَّا الْقَوْمُ الْفَاسِقُونَ»[1] {الأحقاف/35}

кебек сабыр һәм тотрыклы булуга чакырган аятьләр Коръәни Кәримдә күптер. Бу вакытта Исламиятнең таралуы гел дәлил, үгетләү, куркыту, шатландыру нәтиҗәсендә икәнлегендә шөбһә юктыр.

---

1 «Нык түземлелек белән сабыр иткән пәйгамбәрләр кебек сабыр ит һәм Мине аларга газап бирергә ашыктырма.» «әл-Әхкаф»/46.- тәрҗ.

Рәсүлуллаһ Мәдинәгә һижрәт итеп, Ислам беркадәр куәт һәм олуглыкка ирешкәч, ватаннарыннан куган, аларны газаплаган Корәешләргә каршы корал белән сугышырга Аллаһы тарафыннан рөхсәт килде[1].

Моннан соң рәсүлуллаһ Корәеш мөшрикләренә каршы сугышка әзерләнә башлады. Аларның көч-куәтләрен сындыру өчен рәсүлуллаһ сәүдә белән Шам юлыннан йөргән кәрваннарга һөҗүм итүләрне оештырды. Моның өчен сәрияләр[2] җибәрде. Корәеш мөшрикләренең хәленнән дә һәрвакыт хәбәрдар булып, аларның рухи һәм хәрби куәт җыюлары турында мәгълүмат алды.

## *Хәмзә бине Габделмоталлибның сәриясе*

Һиҗрәттән беренче елның рамазан аенда рәсүлуллаһ Шамнан кайтып килгән Корәеш кәрванындагы малны алып калыр өчен, Хәмзә бине Габделмоталлиб кул астында утыз мөһаҗирдән гыйбарәт бер сәрия җибәрде. Байрак Әбү Мәрсәд әл-Ганәви кулында иде. Кәрван рәисе Әбү Җәһил бине Һишам булып, кәрванны саклап килгән өч йөз мөшрик бар иде. Сәрия Кызыл дингез буенда «Гыйс» дигән җиргә җиткәндә кәрванга очрады. Ике тараф сугышка әзер булып сафлансалар да, Җүһәйнә кабиләсенең рәисе булган Мәҗди бине Гамр арага төшеп аларны килештерде. Нәтиҗәдә, сәрия сугышсыз Мәдинәгә кайтты. Мәҗди бине Гамрның ошбу эшенә рәсүлуллаһның тәшәккүр итүе риваять ителәдер.

---

1 [Сугышырга чыканнарга каршы сугышу рөхсәт ителде. Чөнки алар золымлык кылдылар. Чынлыкта исә, Аллаһы Тәгалә аларга булышырга кодрәтледер. Алар үзләренең йортларыннан “Безнең раббыбыз Аллаһы” – дигәнгә хаксыз куылып чыгарылдылар... ”әл-Хаҗ”/39-40.] – авт.

2 Сәрия – бер төркем гаскәр димәктер. Күп вакытта рәсүлуллаһ, үзе катнашмаган гаскәргә әйтелә. – авт.

www.darul-kutub.com

## *Губәйдә бине әл-Хәрис сәриясе*

Шул ук елны шәүвәл аенда мөшрикләрнең кәрванын тоту өчен Губәйдә бине әл-Хәрис кул астында сиксән мөһаҗирдән гыйбарәт бер сәрия җибәрелде. Байрак Мистах бине Үсәсәдә иде. Сәрия «Бәтнү Рабигъ»[1] дигән җиргә җиткәндә кәрванны очраттылар. Кәрванда ике йөз мөшрик булып, башлыклары Әбү Сафүән иде. Арада каты сугыш булмыйча, бары ук атышу белән генә канәгатьләнделәр.

Мөшрикләр Губәйдә гаскәренең артында өстәмә гаскәр булуыннан куркып качтылар. Ислам гаскәре дә бик аз булганлыктан, аларның артларыннан кумадылар. Мөшрикләр арасында Исламиятне кабул итеп тә, Мәдинәгә килә алмаган Микъдад бине Гамр вә Гутбә бине Газвән дә бар иде. Болар бер форсат туры китереп, Ислам гаскәре ягына күчтеләр.

Ошбу ел әнсариларның бөекләреннән Бәрра бине Мәгърур вә Әсгад бине Зурара вафат булды. Әсгад бине Зурара «Ибне Нәҗҗәр»нең башлыгы булганлыгыннан, ул вафат булгач, рәсүлуллаһ аларга үзе баш булды. Бу елда Мәккә мөшрикләренең бөекләреннән Вәлид бине әл-Мугыйра белән әл-Гас бине Вәил әс-Сәһми вафат булдылар.

# Һиҗрәттән икенче ел

## *Вәддән газвәсе*

Икенче елның башында рәсүлуллаһ үзе Корәеш кәрванына каршы чыкты. Мәдинәдә үз урынына Сәгъд бине Губәйдәне калдырды. Байрак Хәмзә бине Габделмо-

1 Җүхфә белән Вәддән арасында бер урын исемедер.

www.darul-kutub.com

таллибта иде. Вәддәнгә[1] кадәр барсалар да, мөшрикләрнең котылып киткәннәрен ишеткәч, сугышсыз кире кайтырга мәҗбүр булдылар. Ислам гаскәренең мөшрикләрне бик сирәк очратуларының сәбәбе: алар бик сак йөриләр, мөселманнардан гел хәбәрдар булырга тырышалар иде. Ошбу сәфәрендә рәсүлуллаһ Ибне Замра гарәпләренең башлыгы Мәхши бине Гамру белән солых төзеде. Солых буенча рәсүлуллаһ аларга, алар рәсүлуллаһка ярдәм итәчәкләр иде. Шушы сәфәрендә рәсүлуллаһ унбиш көнгә кадәр йөрде. Бу – рәсүлуллаһның иң беренче газвәсе иде[2].

## *Бувәт газвәсе*

Шул ел рабигыль-әүвәл аенда рәсүлуллаһ Үмәйя бине Халәф җитәкчелегендә вә йөз мөшрик сагы астында Шамнан зур кәрван кайтып килгәнен ишетеп, ике йөз мөһаҗирдән гыйбарәт бер гаскәр белән кәрванга каршы чыкты. Байрак Сәгъд бине Әби Ваккас кулында иде. Мәдинәдә рәсүлуллаһ урынына Сәгыйд бине Мугәз калды. Бувәт[3] исемендәге җиргә җиткәч, мөшрикләрнең үтеп котылганнарын ишетте. Шуңа күрә сугышсыз кайтып китте.

## *Гаширә газвәсе*

Шул ук ел җөмадиәл-әүвәл аенда рәсүлуллаһ Әбү Сафүәнның зур кәрван белән Шамга барганын ишетеп, йөз илле мөһаҗир белән каршы чыкты. Байрагы Хәмзә бине Габ-

1 Вәддән – Мәккә белән Мәдинә арасындагы бер авылдыр. Бу авыл Әбвага якын булганнан газвә “Газвәтү Әбва" дип әйтелә. - авт.

2 Газвә – сугыш мәгънәсендәдер. Сира галимнәре терминында – рәсүлуллаһның үзе катнашкан сугышны әйтәләр. – авт.

3 Бувәт – Җүһәйнә кабиләсе тавларыннан берсе булып Радвә тавы янындадыр – авт.

делмоталлиб кулында иде. Мәдинәдә үз урынына Әбү Сәлмә бине Габдүл Әсәдне калдырды. Гаскәр «Гаширә»[1] исемле җиргә кадәр барып җитсә дә, кәрванның үтеп котылганын белгәч, алга китмәде. Бу сәфәрдә рәсүлуллаһ Ибне Мудлиҗ гарәпләре белән солых төзеде.

## *Беренче Бәдер газвәсе*

Рәсүлуллаһ Гаширә газвәсеннән кайтып бераз торгач, Кәрз бине Җәбир әл-Фәһри Мәдинә малларын куып алып киткән иде. Моны белеп, рәсүлуллаһ гаскәр белән артыннан куса да, җитә алмадылар. Кәрз котылды. Бу сәфәрдә гаскәр Бәдергә якын бер җиргә җитеп туктаганга бу сәфәргә «Беренче Бәдер газвәсе» диделәр. Байрак Гали бине Әбү Талибта иде. Шул сәфәрдә Мәдинәдә башлык булып Зәйд бине Хәрисә калган иде.

## *Габдулла бине Җәһеш сәриясе*

Ошбу елда рәсүлуллаһ Габдулла бине Җәһеш кулы астында сигез кешедән гыйбарәт бер сәрия әзерләде. Сәрия башлыгы Габдулла бине Җәһешкә бер хат биреп, ике көннән соң ачып укырга һәм анда язылган буенча гамәл кылырга боерды. Габдулла ике көн йөргәч, хатны ачты. Хатта: «Бу хатны укыгач, Нәхләгә юнәл, анда Корәеш гарәпләрен күзәтеп, алар хакында мәгълүмат алып кайт!» – дип язылган иде. Сәриягә Мәдинәдән әүвәл кайда барачакларын әйтмичә хат бирүнең хикмәте – хәбәр халыкка таралмасын өчен иде. Сәрия рәсүлуллаһның әмере буенча Нәхләгә юнәлде. Юлда Гутбә бине Газвән белән Сәгыйд бине Әбү Ваккасның дөяләре югалу сәбәпле, сәриядән аерылып калдылар. Сәрия

1 Мәдинә белән Йәнбүгъ арасындагы бер урындыр – авт.

Нәхләгә җиткәч, алар янында Гамр бине Хазрами, әл-Хәкәм бине Кәйсән, Госман бине Габдулла, Нәүфәл бине Габдулла кул астында Корәеш гарәпләренең бер кәрваны үтеп китте. Кәрван сакчыларының азлыгыннан файдаланып, болар кәрванга һөҗүм иттеләр. Гамр бине Хазрами үтерелде. Нәүфәл качып котылды. Калган икесе әсирлеккә алынып, кәрван белән Мәдинәгә алып кителде. Мәккә мөшрикләре аларның артларыннан куа алмадылар. Бу вакыйга хәрам айларыннан булган рәҗәб аеның соңгы көнендә иде.

Боларның хәрам айда сугыш кылганнарын белгәч, рәсүлуллаһ та, хөрмәтле сәхабәләр дә аларны шелтә кылды. Мөшрикләр вә яһүдләр исә бу форсаттан файдаланып, төрле сүзләр сөйли башладылар. Хәрам айның хөрмәтен сакламауларын зур бер гаеп итеп дөнья кубардылар. Ошбу сәрия әһелләре дә рәсүлуллаһ вә сәхабәләрнең шелтә кылуларын күргәч, бик кайгырдылар вә үкенделәр. Фәкать Аллаһы Тәгалә аларны шелтә кылулары урынсыз икәнен, рәсүлуллаһка вә сәхабәләргә әллә нинди зур кабахәтлекләр кылган мөшрикләргә мондый мөгамәләнең бер дә гаепкә алырлык эш түгеллеген бәян итеп:

«يَسْأَلُونَكَ عَنِ الشَّهْرِ الْحَرَامِ قِتَالٍ فِيهِ قُلْ قِتَالٌ فِيهِ كَبِيرٌ وَصَدٌّ عَن سَبِيلِ اللّهِ وَكُفْرٌ بِهِ وَالْمَسْجِدِ الْحَرَامِ وَإِخْرَاجُ أَهْلِهِ مِنْهُ أَكْبَرُ عِندَ اللّهِ وَالْفِتْنَةُ أَكْبَرُ مِنَ الْقَتْلِ...»

аятен индерде[1].

1 “Синнән хәрам аендагы сугыш хакында сорыйлар. Әйт син аларга: “Хәрам айда сугышу гаять зур эш. Ул айда сугышу – Хәрам мәчетененең хөрмәтен сакламау. Аңа көфран була, Аллаһы юлында тыюга сәбәп була. Ләкин хәрам әһелен Хәрам мәчетеннән чыгару тагы да зуррак эш. Диндә фетнә кылу (диннән чыгарырга тырышу) үтерүдән дә яман эш.” “әл-Бәкара”/217. – авт.

Әйтелгән әсирләрдән берсе – әл-Хәкәм бине Кәйсән Ислам динен кабул итү белән, мөшәрраф булып Мәдинәдә калды. Берсе фидия [йолым] түләп, Мәккәгә кайтып китте. Ганимәт малыннан биштән бер өлеше рәсүлуллаһка бирелеп, калган дүрт өлеше сәриядә катнашканнарга бүленеп бирелде. Бу ганимәт Ислам гаскәре тарафыннан беренче мәртәбә алынган ганимәт иде.

## *Бәдер сугышы*

Җөмадиәл-әүвәл аенда чыгып та, туры китерә алмаган әлеге зур кәрванның Мәккәгә кайтуын рәсүлуллаһ көтеп, күзәтеп тора иде. Рамазан башларында зур кәрванның Мәккәгә кайтып баруын ишетү белән, рәсүлуллаһ сәхабәләргә әзерләнергә кушты. Кәрванда мөшрикләрнең саны бик аз булганга, рәсүлуллаһ бу сәфәргә ул кадәр әһәмият бирмәде. Сәхабәләрне дә бик җитди сурәттә дәгъвәт итмәде. Шунлыктан, байтак кешеләр бу сәфәргә чыкмады. Аның өстенә кәрванның китеп баруы мөмкин булганлыктан, сәфәргә бик ашыгыч хәлдә киткәнгә, кайбер кешеләр дә өйләрендә булмаганга яки ат вә дөяләре әзер булмаганга, чыга алмый калдылар. Шуңа күрә бик ашыгыч рәвештә 313 кешедән гыйбарәт бер төркем оештырып, сәфәргә чыктылар. Алар арасында 86 мөһаҗир булып, калганы әнсарилар иде[1]. Атланып бару өчен җитмеш дөяләре булып, аларга икешәр, өчәр, дүртәр кеше алмашып утырып бардылар[2]. Гаскәр эчендә атлылар икәү генә иде: әл-Микдәд бине Әсвад һәм Зүбәйр бине Гаввәм. Мәдинәдә рәсүлуллаһ урынына Ибн Үмм Мәктум калды. Мәдинә шәһәреннән чыккач, Буютү әс-

1 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 346 б. – авт.

2 Рәсүлуллаһ Гали бине Әби Талиб, Мурсәд бине Әби Мурсәд Ганәви – өчесе бер дөядә Әбү Бәкр, Гомәр, Габдеррахман бине Гауф – өчесе бер дөядә алмашып утырып бардылар. – авт.

Сукъядә[1] туктап, рәсүлуллаһ гаскәрне карап чыкты. Сугышка барырга кулларыннан килмәгән кайбер яшьләрне Мәдинәгә кире кайтарып җибәрде. Алар эчендә Габдулла бине Гомәр, Рафигъ бине Хүдәйҗ, Барра бине Газиб, Зәйд бине Сәбит бар иде. Раухага җиткәч Мәдинәгә вәли итеп Әбү Лубәбәне җибәрде. Зур байракны Мусгаб бине Гумәйргә, мөһәҗирләр байрагын Гали бине Әбү Талибка, әнсарилар байрагын Сәгъд бине Мугәзгә бирде. Сафрага[2] якынлашкач, Бәсбәс бине Гамр белән Гади бине Әбү Зәгъбәне кәрван хакында мәгълүмат алып килү өчен Бәдергә җибәрде.

## *Мәккәлеләрнең сугышка әзерләнүләре*

Әбү Сафүән рәсүлуллаһның кәрванга каршы чыкканын ишеткәч, Мәккәгә хәбәр ирештерер өчен Замзам бине Гамр бине әл-Гаффәрине яллап Мәккәгә җибәрде. Замзам Мәккәгә килеп Әбү Сафүәнның хәбәрен ирештергәч, Корәеш гарәпләре хәмияткә[3] килеп, кәрванны коткарыр өчен ашыгыч әзерләнә башладылар. Чөнки моннан бераз гына вакыт элек булган Гамр бине Хазрами вакыйгасының ачысы да йөрәкләреннән китмәгән иде. Моның өстенә рәсүлуллаһның шундый зур кәрванга һөҗүм ясарга җөрьәт итүе аларга ук кебек барып кадалды. Ачуларыннан ни эшләргә белмәделәр. Халыкны кәрванны коткару һәм Гамр бине Хазраминең үчен алу өчен кешеләрне кызыктыра вә өнди башладылар.

Халыкны сугышка иң нык өндәгән кеше Әбү Җәһил бине Һишам иде. Ул моңарга бөтен көчен сарыф итте: су-

1 Мәдинәнең көнбатыш тарафында Мәдинәгә якын татлы чишмәсе белән танылган бер урындыр. – авт.

2 Игенлек һәм хөрмәлек бер урын булып, Бәдер белән ике ара, бер мәрхәлә [тукталыш] ераклыгындадыр. – авт.

3 Хәмият – ярдәм итеп яклау. – тәрҗ.



www.darulkutub.com

гышка чыгарга теләмәгән кешеләрнең кайсысын куркытып, кайсысын гарьләндереп чыгарга мәҗбүр итте. Бу сәфәргә Ибне Гади ыруыннан башка бөтен Корәеш ырулары кушылды. Ялгыз Ибне Гади ыруы гына аерылып калды. Дәрәҗәле кешеләр һәм башлыклардан Әбү Ләһәбтән башка бөтенесе әзер булдылар. Әбү Ләһәб исә үзе урынына калачак әл-Гас бине Һишам исемендәге берсен җибәрде. Үмәйя бине Халәф картлыгы сәбәпле калырга теләсә дә, Әбү Җәһил кебек башлыкларның гарьләндерүләре сәбәпле чыгарга карар бирде. Корәешнең иң бөекләреннән булган Гутбә бине Рабига калырга теләсә дә, кардәше Шәйбәнең өндәве буенча ул да чыгарга карар бирде. Шулай итеп, камил рәвештә әзерләнгән меңгә якын кешедән гыйбарәт бер төркем төзелеп, сәфәргә чыктылар. Болардан ике 200 атлы гаскәр, калганнары җәяүле гаскәр иде. Азык алып бару, гаскәргә ашарга сую һәм кирәк вакытта атланыр өчен 700 дөя алып чыктылар. Гаскәрнең рухын күтәрер өчен алларыннан җәрияләр Исламны хурлап шигырь сөйләп, барабан сугып баралар иде.

Корәеш гаскәре «Җухфә» дигән җиргә җиткәндә, Әбү Сафүәннан бер хат килә. Ул хатында кәрванны коткару өчен Кызыл диңгез буйлап (туры юлдан башка) китеп, Мөхәммәднең гаскәреннән котылуын хәбәр итеп, мәккәлеләргә шәһәргә кайтырга нәсыйхәт итә иде. Хатны укыгач, Әбү Җәһил: «Юк, безнең кайту ихтималы юк, без Бәдергә барып өч көн торачакбыз, анда дөяләр суеп, хәмерләр әзерләп, тирә-як халкын сыйлаячакбыз. Безнең көч-куәт бөтен Гарәбстанга таралсын вә бөтен гарәп моннан соң бездән курка торган булсын», – диде. Башлыклардан Әхнәс бине Шәрикнең өндәве буенча Бәну Зуһра ыруы кире кайтып китте. Бәну Һашим ыруы да кайтырга теләсә дә, Әбү

Җәһилнең гарьләндерүе сәбәпле, гаскәр белән бергә булырга карар кылдылар. Корәеш мөшрикләре арасында әүвәлдән ук дәртсез чыккан кешеләр булган кебек, кәрванның һөҗүмнән котылу хәбәре килгәч, теләмичә баручылар тагын да күбәйде.

## *Киңәш*

Ислам гаскәре Сафра дигән җиргә җитеп, узып барганда, әлеге ике күзәтче килеп, кәрванның Бәдергә якынлашуын турында хәбәр иттеләр. Рәсүлуллаһ Корәеш мөшрикләренең кәрванны коткарырга чыгуларын белмичә, һаман да юлын дәвам итте. Сафрадан үтеп, бер урында туктагач, мөшрикләрнең аларга каршы чыгулары турында хәбәр алды. Шуның өчен рәсүлуллаһ гаскәр башлыкларын җыеп, сугыш башларгамыюкмы дип алардан киңәш сорады. Әбү Бәкер, Гомәр кебек бөек мөһаҗирләр рәсүлуллаһ ни эшләргә боерса, шуңа итагать итәчәкләрен, аңардан кыл кадәр дә аерылмаячакларын сөйләсәләр дә, арада: «Сугышыр булсак, әүвәл үк әйтергә кирәк иде, әзерләнеп чыгар идек», – дигән кешеләр дә булды. Әмма рәсүлуллаһның үз фикере сугыш кылуда иде. Ул Аллаһының ярдәм итәчәгенә ышанды. Халыкка: «Аллаһы миңа ике нәрсәнең берсен вәгъдә итте: я кәрван, я гаскәр», – дия иде. Рәсүлуллаһның сугыш тарафында булганын белгәч, әл-Микъдад бине Әсвәд чыгып: «Әй, рәсүлуллаһ! Аллаһы кушкан эшкә кереш, без сиңа Ибне Исраилнең Мусага әйткәне кебек:

فَاذْهَبْ أَنتَ وَرَبُّكَ فَقَاتِلا إِنَّا هَاهُنَا قَاعِدُونَ[1]

– дип әйтмәячәкбез. Бәлки:

فَاذْهَبْ أَنتَ وَرَبُّكَ فَقَاتِلا إِنَّا مَعَكُمَا مُقَاتِلُونَ [2]

1 «Раббың белән бәрабәр барып сугышыгыз! Без монда утырачакбыз. «әл-Мәидә»/24.» – авт.

2 «Раббың белән бәрабәр барып сугышыгыз! Без дә сезнең белән бәрабәр



www.darulkutub.com

– диячәкбез. Әгәр безне «Бәркү әл-Гумәд»[1]кә кадәр сугышыр өчен алып китсәң дә, артыңнан калмаячакбыз», – диде. Рәсүлуллаһ Микъдадның сүзенә бик шатланды. Әле бу вакытка кадәр әнсарилардан берсе дә сүз сөйләмәгән иде. Хәлбуки, рәсүлуллаһка бигрәк тә әнсариларның ризалыгы кирәк иде. Чөнки мөһаҗирләр рәсүлуллаһның үз кешеләре булып, аларның рәсүлуллаһ артыннан калмаячаклары билгеле иде. Моннан элек тә алар рәсүлуллаһ белән берничә газвәгә чыкканнар иде. Әнсариларның исә рәсүлуллаһ белән беренче сәфәрләре иде. Аның өстенә әнсарилар Гакабә бәйгатендә рәсүлуллаһны яклауны үз өсләренә алсалар да, анда рәсүлуллаһ белән сугышларга чыгу сөйләшенмәгән иде. Менә шуның өчен дә, рәсүлуллаһка әнсариларнын фикерен белү вә алардан ризалыкларын алу кирәк иде. Рәсүлуллаһ әнсарилардан җавап алу максаты белән тагы да халыкның фикерен сорады.

Моңа каршы әнсарилардан Сәгъд бине Мугәз чыгып: «Әй, рәсүлуллаһ! Бу сүзең белән безнең фикерне беләсең киләдер?» – диде. Рәсүлуллаһ та: «Әйе», – дип җавап бирде. Мугәз сүзен дәвам итеп: «Әй, рәсүлуллаһ! Без сиңа иман китердек, сине тасдыйк кылдык, сине якларга һәм ярдәм итәргә вәгъдәләр бирдек, син Раббың кушкан эшкә кереш, без синнән кыл кадәр дә аерылмабыз! Әгәр безгә артыңнан ошбу диңгезгә (Кызыл диңгезгә) төшәргә кушсаң да, һич туктамыйча төшәчәкбез. Без сугышка өйрәнгән, сабыр һәм күнеккән халык. Инша Аллаһы, бездән риза булачак эшләр күрерсең, Аллаһыка тапшырып юлыңны дәвам ит!» – диде. Сәгъддән бу сүзләрне ишеткәч, рәсүлуллаһның йөзе ачылып китте.

Моның нәтиҗәсендә, мөшрикләр белән очрашканда

---

сугышырбыз!» – авт.

1 Йәмәндәге бер урын исемедер. – авт.

алар белән каты сугышырга карар биреп, гаскәр Бәдергә таба кузгалып китте. Кәрван турында мәгълүмат алыр өчен, рәсүлуллаһ Галине, Зүбәйрне вә Сәгыйдне Бәдергә җибәрде. Гаскәр Бәдергә якын бер җиргә төшеп, ял иткән вакытта, болар Корәеш мөшрикләреннән икесен тотып, рәсүлуллаһка алып килделәр. Рәсүлуллаһ алардан кем икәнлекләрен вә нәрсә эшләп йөргәннәрен сорагач, алар Корәешләр өчен су алырга килүләрен, Корәеш мөшрикләренең кайда урнашканлыкларын, күпме булганлыкларын һәм башлыкларыннан кемнәр икәнлеген сөйләделәр. Рәсүлуллаһ болардан Корәеш бөекләре турында ишеткәч, сәхабәләргә мөрәҗәгать итеп:

«هَذِهِ مَكَّةُ قَدْ أَلْقَتْ إِلَيْكُمْ أَفَلاذَ كَبِدِهَا.»[1]

– диде. Гаскәр урнашкан ошбу урын каты тозлы бер җир иде. Шул арада яңгыр явып, аяк астын йомшатып ташлады. Сусызлыктан аптыраган гаскәр буалар ясап, суга рәхәтләнде. Соңра алар рәсүлуллаһ әмере белән кузгалып, Бәдернең иң ерак бер суы янына килеп төште.

## *Хубәб бине Мунзирнең фикере*

Шул вакыт Хубәб бине Мунзир: «Әй, рәсүлуллаһ, бу урынга Аллаһы әмере белән урнаштыңмы яки үз фикерең беләнме?» – дип сорады. Рәсүлуллаһ үз фикере белән урнашканын әйткәч, Хубәб: «Әй, рәсүлуллаһ, монда гаскәрнең урнашуы аслән туры килми. Без Бәдернең мөшрикләргә иң якын булган суына төшик. Аның артындагы бөтен чишмәләрне күмик. Мөшрикләр сусызлыктан зәхмәт чиксеннәр!» – диде. Рәсүлуллаһ Хубәбнең бу фи-

1 «Мәккә сезгә йөрәк парчаларын аткан» – диде. – авт.

www.darulkutub.com

керен гаять акыллы күреп, гаскәргә Хубәб кушкан урынга урнашырга кушты. Нәтиҗәдә, сәхабәләр шул урынга төшеп чишмәләрдән зур бер күл ясады. Мөшрикләрдән су юлын кисү өчен арттагы бөтен чишмәләрне күмделәр. Соңра Сәгъд бине Мугәзнең фикере буенча рәсүлуллаһка сугыш вакытында гаскәрнең хәрәкәтен карап тору өчен калку бер җиргә куыш корылды. Корәеш гарәпләре Бәдергә якын бер йомшак урынга килеп төшкәннәр иде. Әлеге каты яңгыр боларның аяк асларын нык пычратып ташлады. Гаскәргә йөрү бик авырлашты. Шуның өчен мөшрикләр гаскәре зур зәхмәт чикте. Аяк асты пычранып, аякларга ябышу сәбәпле, Ислам гаскәренә кадәр Бәдер суына килеп өлгерә алмадылар. Шуңа күрә рәсүлуллаһның гаскәре тоткан урын җиңүгә китерүче урын булып, мөшрикләрнең позициясе, киресенчә, җиңелүне тизләткән бер урын иде.

Корәеш гаскәре Бәдергә килеп төшеп, ике гаскәр бер-беренә күренгәч, рәсүлуллаһ гаскәрне сугышырга әзерли башлады. Үзе саф арасына кереп, сафларны турылый, алга яки артка чыгып торган кемсәләрне кулындагы кечкенә таягы белән төртеп: «Әй, фәлән, туры тор!» – диер иде. Гаскәрне сабырлык вә чыдамлыкка өндәр, сабыр иткән тәкъдирдә, Аллаһы ярдәм бирәчәген вәгъдә итәр иде.

## *Мөшрикләр гаскәре арасында ихтилаф*

Ислам гаскәре сафка басып, сугышыр өчен бер ишарәт кенә көтеп торганда, мөшрик гаскәре арасында сугышу-сугышмау хакында төрле фикерләр туды. Әбү Җәһил бине Һишам кеби башлыклар бөтен көчләре белән халыкны сугышка өндәгән вакытта, Гутбә бине Рабига вә Хәким бине

Хизам кебекләр халыкны сугыштан суындырырга тырышалар иде. Гутбә Корәеш гаскәрен сугыштан ваз кичтерү өчен мөселманнар тарафыннан үтерелгән үзенең фикердәше Гамру бине әл-Хазраминың диясен[1] туганнарына йолым һәм мөселманнар тарафыннан алынган кәрвандагы малның бәясен түләячәген сөйләде. Әмма Әбү Җәһил бине Һишам моны курkaклык белән гарьләндерде. Гутбәнең сүзен тәэсирсез калдырыр өчен вә халыкның җаһили хәмиятен кузгатып җибәрер өчен Гамр бине әл-Хазраминең кардәше Гамиргә Гамрның канын таләп итеп, гаскәр арасында кычкырырга кушты. Шуннан Гамир каты тавыш белән: «Әй, Гамр!» – дип кычкыра башлады. Моны ишетү белән халык дәртләнеп сугышка әзерләнде. Гутбә дә сүзенең кабул ителмәгәнен күргәч, фикереннән кире кайтып сугышка әзерләнде. Сугыш башланыр алдыннан гына мөшрик гаскәреннән Әсвад бине Габдүл Әсәд әл-Махзуми тәкәббер сурәттә алга чыгып, Ислам гаскәренең су җыелмасыннан су эчәргә ант бирде. Фәкать аның каршысына Хәмзә чыгып, аны үтерде. Соңра гадәт буенча сугыш мүбәразә[2] ысулы белән башланды.

## *Мүбәразә*

Мөшрикләрдән Гутбә бине Рабига, аның улы – Вәлид бине Гутбә һәм Шәйбә бине Рабига чыгып, үзләренә мүбәразә таләп иттеләр. Аларга каршы әнсарилардан өч кеше чыксалар да, алар сугышучыларның Корәештән булуын шарт итеп куйганга күрә, рәсүлуллаһ Гутбәгә каршы Губәйдә бине әл-Харисны, Шәйбәгә каршы Хәмзәне, Вәлидкә кар-

1 Дия – үтергән өчен үтерелгән кеше туганнарына йолым. – тәрҗ.

2 Мүбәразә – сугышыр алдыннан гаскәрләр алдында ике яктан берничә кеше чыгып сугышулары – тәрҗ.

шы Галине чыгарды. Хәмзә белән Гали озак сугышмастан, үзләренең дошманнарын үтерделәр. Гутбә белән Губәйдә озак вакыт берсе-берсе белән сугышып, һәр икесе дә каты җәрәхәтләнделәр. Шул арада Хәмзә белән Гали Гутбә янына килеп иҗһәз (җәрәхәтләнгән кешене үтереп бетерү) ясадылар. Губәйдә бине әл-Харисны, балтырының җелеге аккан хәлдә, саф арасыннан рәсүлуллаһның куышына илттеләр. Куышка китерелгәч, Губәйдә рәсүлуллаһка карап: «Әбү Талиб сәламәт булса, түбәндәге сүзенә без мүстәхкыйрак икәнлегебезне белер иде» – дигән сүзе риваять ителәдер:

«وَ نُسْلِمُهُ حَتَّى نُصْرَعَ حَوْلَهُ فَنُذْهَلَ عَنْ أَبْنَائِنَا وَ الحَلَائِلِ.»[1]

Мүбәразә беткәч, рәсүлуллаһ яңадан сафлар арасында йөреп, аларны тигезләде. Сәвәд бине Газиййә исемле бер әнсариның сафтан чыгып торганын күргәч: «Сәвәд, тигезлән!» – дип кулындагы кечкенә таягы белән Сәвәднең корсагына төртте. Сәвәд моңа каршы: «Әй, рәсүлуллаһ! Тугрылык һәм гаделлек белән җибәрелгән хәлдә миңа суктың. Мин синнән кыйсас таләп итәм», – диде. Рәсүлуллаһ та моңа кыйсас өчен корсагын ачкач, Сәвәд рәсүлуллаһның корсагын үбеп алды. Рәсүлуллаһ моның сәбәбен сорагач, Сәвәд: «Әй, рәсүлуллаһ, алдымда үлем көтә, соңгы сәгатемдә тәнем синең тәнеңә тисен дидем», – дип әйтте. Рәсүлуллаһ сафларны тигезләгәч, гаскәргә: «Мин әмер итмичә һөҗүм кылмагыз, әгәр сезгә мөшрик гаскәре якынлашса, ук белән каршылагыз, алар кылыч белән һөҗүм итмичә торып, кылыч белән һөҗүм итмәгез!» – диде. Соңра Әбү Бәкер белән куышка керде. Куыш ишегендә рәсүлуллаһны Сәгъд ибн

1 Бу бәет Әбү Талибның ләмиясеннәндер. Мәгънәсе: «Аның (Мухәммәднең) тирәсендә егылып ятып, хатын һәм балаларыбыздан зүһүл кылмый торып, без аны сезгә тапшырачакбызмы? Бу – булачак түгел!» – авт.



www.darul-kutub.com

Мугаз белән берничә әнсари саклап тордылар. Соңра яңадан гаскәр янына килеп, сабырлыкка вә чыдамлыкка дәгъвәт итте. Шәһид булачак кешеләргә җәннәт белән сөенеч бирде. Дошманны үтерүчегә сәләбен [үтерелгәннең киеме, коралы кебек нәрсәләр] бирәчәген вәгъдә итте. Соңра каты сугыш башланды. Рәсүлуллаһ та сугышның барышып карап, Аллаһыдан ярдәм сорап дога кылып торды. Бу көн рамазанның 17се – җомга көн иде[1].

## *Җиңү*

Сугыш озакка сузылмады. Ислам гаскәре каты сугышып, башлыкларының итәгатьләре, сабыр һәм чыдамлыклары, Аллаһы ярдәме белән үзләреннән өч мәртәбә артык булган мөшрикләрне җиңеп, җитмешләп кешене үтерделәр һәм шул микъдарда әсир алдылар. Үтерелгән мөшрикләрнең эчендә, мүбәразәдә үтерелгән башлыклардан кала, мәшһүр Әбү Җәһил бине Һишам[2], Ислам динен кабул иткән Әбү Губәйдәнең атасы Җәррах[3], Үмәйя бине Хәләф белән улы Гали[4] Әбү әл-Бухтари

1 Бәдер сугышында Рәсүлуллаһның вә гаскәрнең ифтар кылулары риваять ителәдер. Тирмизи 1 т.,94 б. – авт.

2 Әбү Җәһилне әнсари булган Мүгәз бине Гафра каты сурәттә җәрәхәтләп киткән иде, соңра кардәше Мугаввиз килеп тагы кылыч белән чәнчеде. Әбү Җәһил үлем хәлендә иде, соңра Рәсүлуллаһның әмере буенча Ибн Мәсгуд Әбү Җәһилне табып иҗһәз (җанны чыгарып бетерү) кылды. – авт.

3 Моны улы Әбү Губәйдә үтерде. Әбү Губәйдә атасының һөҗүмен күреп качса да, Җәррах моның артыннан һаман калмагач, каршы торып үтерде – авт.

4 Үмәйя бине Хәләф белән улы Галине, Габдрахман бине Гауф әсирлеккә алган иде. Габдрахман белән Үмәйя арасында Мәккәдә вакытта дуслык бар иде. Сугыш сүнә башлагач, Габдрахман ганимәт алган тимер киемнәрен күтәреп килә иде. Үмәйя бине Хәләф аны күреп үзен әсир алуын үтенде һәм әсирлеккә алган очракта аңа күп йолым бирүен вәгъдә кылды. Шуның өчен Габдрахман тимер киемнәрен ташлап, боларны – атасы белән улын әсирлеккә алып китте. Шул арада Билал аларны күреп әнсарилардан берничә кешене жыеп, аларга һөҗүм итеп, һәр икесен үтерделәр. Шулай итеп, Габдрахман тимер киемнәреннән дә, әсирләреннән дә мәхрүм калды. Соңында Габдрахман: "Аллаһы Билалга рәхмәт итсен, мине тимер киемнәремнән дә яздырды, әсирләремнән дә мәхрүм итте!" – дия торган иде. Билалның боларга (Үмәйя белән улына) һөҗүм итүе Мәккәдә вакытта чиктән тыш аны газаплаганнары өчен иде. – авт.

бине Һишам[1], Әбү Сафүән бине Хәрбнең улы Хәнзалә, Нәүфәл бине Хувәйлид, Сагыйд бине әл-Гас һәм балалары – Губәйдә белән әл-Гас, Гукбә бине Әбү Мугыйт белән ән-Назр бине әл-Харис[2] һәм тагы башкалар да бар иде.

Әсирләр эчендә рәсүлуллаһның атасының абыйсы Габбас бине Габделмоталлиб[3]; атасының абыйлары малайлары: Гукәйл бине Әбү Талиб, Нәүфәл бине әл-Харис, кияве Абү әл-Гас бине Рабигъ[4], Гамр бине Әбү Сафүән[5], Сүһәйл

1 Әбү әл-Бухтари бине Һишамны Рәсүлуллаһ үтермәскә кушса да, ул үзе каршы торганлыгыннан үтерелде. – авт.

2 Гукбә белән ән-Назр бине әл-Харис дә әсирлеккә алынганнар иде, юлда кайтканда Рәсүлууллаһ боларның башларын чаптырды. – авт.

3 Әсирлеккә эләккән Габбасны әнсарилар йолымсыз җибәрү фикерендә булсалар да, Рәсүлуллаһ моны кабул итмәде. Киресенчә, Габбаска һичбер әсиргә куймаган йолым бәһасен куйды. Аңардан үзенең әтисенең бертуган абыйларының балалары Гукәйл һәм Нәүфәл белән Гутбә бине Гамруның фидьясен түләтте. Габбас башта бу кадәр түләргә малым юк дисә дә, Рәсүлуллаһ аңа: “Хатының Уммүл Фазлда калдырган малларың кайда? Сугышка чыкканда Уммүл Фазлга биреп: “Мин үлсәм, Фазлга шулкадәр, Габдуллага шул кадәр, Губәйдуллага шул кадәр бирерсең, димәдеңме?” – диде. Габбас моңа каршы: “Бу мәсьәләне Уммүл Фазлдан башка һичкем белми иде, син хак рәсүл икәнсең”, – дип, иман китерде. – авт.

4 Әбү әл-Гасны йолып алыр өчен Мәккәдә калган хатыны Зәйнәб (рәсүлуллаһның кызы), анасы Хәдичә тарафыннан зөфәф кичәсендә бүләк иткән муенсасын җибәргән иде. Рәсүлуллаһ моны күргәч, күңеле нечкәрде һәм сәхабәләрдән Зәйнәбнең муенсасын алмыйча ирен азат итүләрен үтенде. Сәхабәләр моңа риза булды. Шунлыктан Әбү әл-Гас фидьясез азат ителде. Ләкин Абү әл-Гасны Зәйнәбне Мәдинәгә җибәрү шарты белән азат иттеләр. Рәсүлуллаһ әмере буенча Зәйд бине Хәрисә белән бер әнсари Зәйнәбне алып килде. Рәсүлуллаһ Зәйнәбне Абү әл-Гаска кияүгә пәйгамбәрлек килгәнче үк биргән иде һәм аны гаять ярата иде. Рәсүлуллаһка вәхи килеп, халыкны дингә дәгъвәт итә башлагач, Әбү Ләһәбнең ике улы Рәсүлуллаһның ике кызын (Умму Гөлсем һәм Рукайяне) талак иттеләр. Әбү әл-Гас исә Зәйнәбне аерырга күпме кушсалар да, аермады. Зәйнәбне бер хатынга да алмаштырмаячагын сөйләде. Шуның өчен Рәсүлуллаһ аны һәрвакыт мактап сөйли иде. Әбү әл-Гас Мәккәне фәтх кылыр алдыннан Исламга килгәч, Рәсүлуллаһ элекке никахы белән Зәйнәбне аңа бирде – авт.

5 Гамр бине Әбү Суфьянны әтисе Әбү Суфьян йолым түләп алмады. Бер вакыт мөшрикләр әнсарилардан Сәгъд бине Нугъман гомрә хаҗына килгәч, Гамргә алмаштыру нияте белән әсирлеккә алдылар. Рәсүлуллаһ Сәгъдне азат итәр өчен Әбү Суфьян улына алмаштырып бирде – авт.



www.darulkutub.com

бине Гамр[1], Вәлид бине әл-Вәлид[2], әс-Сәиб бине Йәзид, Вәһәб бине Гумәйр әл-Җумхә, Мусгаб бине Гумәйр бертуган кардәше Әбү Газиз кебек мәшһүр кешеләр бар иде. Бәдер сугышында Ислам гаскәреннән үтерелгән кеше ундүрт иде.

Сугыш тәмам булгач, Рәсүлуллаһ үлгән мөшрикләрне Бәдер чокырларына ташлап күмдерде[3]. Соңра өч көн Бәдердә калып, ганимәт малларын һәм әсирләрне алып, Мәдинәгә юнәлделәр.

Мәдинә халкына җиңү турында алдан хәбәр итү өчен «Галия» әһелләренә Габдулла бине Равәхәне, ә «Сәфилә» әһелләренә Зәйд бине Хәрисәне җибәрде[4]. Мәдинәдәге яһүдләр белән монафикъылар мөселманнарга төрле сүзләр сөйләп, кайгыртып торганда, бер заман болар Мәдинә халкына җиңү хәбәре алып килделәр. Зәйд бине Хәрисә Мәдинәгә килеп кергәндә, халык Рәсүлуллаһның кызы Рукайяне күмеп кайтып киләләр иде.

www.darul-kutub.com

---

1 Сүһәйл бине Гамр Көрәешнең оста теллеләреннән, хатыйбларыннан иде. Гомәр бине Хаттаб: "Әй, рәсүлуллаһ, миңа рөхсәт бирсәң, ошбу кешенең алгы тешләрен суырып алыр идем. Теле салынып йөрсен, моннан соң синең хакта сүз сөйләмәс!" – диде. Рәсүлуллаһ аңа каршы: "Юк, болай кылачак түгелмен, Сүһәйл моңарчы безнең турыда сөйләп йөрсә, моннан соң, Аллаһы теләсә, безгә каршы булганнар турында сөйләр", – диде. Чыннан да, соңыннан Суһәйлнең Исламга бик күп хезмәтләре тиде – авт.

2 Моны бертуганы булган Халид белән Һишам килеп алдылар. Мәккәгә кайткач, Вәлид Исламга килде. "Синең ниятен шундый булгач, йолым түләп алганчы, Исламны кабул итәргә кирәк иде", – диюләренә: "Куркып, Исламиятне кабул итте дигәннәреннән курыктым", – дип җавап бирде – авт.

3 Боларны күмәр алдыннан аларга карап: "Әй, Гутбә бине Рабига! Әй, Шәйбә бине Рабига! Әй фәлән һәм фәлән! Сез Раббыгыз вәгъдә иткән хаклыкны таптыгызмы? Ә мин, Раббым вәгъдә иткән хаклыкны таптым!" – дигәне сахихта риваять ителәдер.

4 Сәфилә – төп Мәдинә булып, Галия – Мәдинәнең көньяк тарафы һәм Кубә ягыдыр – авт.

## *Ганимәт малын бүлү*

Гаскәр Сафрага җиткәч, рәсүлуллаһ ганимәтләрне җәяүлеләргә бер өлеш, атлыларга өч өлеш итеп бүлде. Рәсүлуллаһ кушкан кайбер эш белән катнаша алмаган кешеләргә дә өлеш чыгарылды.

Гусман бине Гаффан сугышка чыгарга теләсә дә, хатыны Рукайя каты авыру булганлыктан, рәсүлуллаһ аны алып чыкмады. Әбү Лүбәбәне Раухадан Мәдинәгә вәли итеп җибәргән иде. Гасыйм белән Гадине Куба белән Галиядә калдырган иде. Харис бине Хаттабны Гамр бине Гауф кабиләсе хакында ишетелгән бер эш хакында кайтарып җибәргән иде. Харис бине Саммә белән Хаввәт бине Җүбәир, гаскәргә иярә алмыйча, Раухада калганнар иде. Талха бине Губәйдулла белән Сәгыйд бине Зәйд дошманнан хәбәр алырга җибәрелсәләр дә, сугыш беткәч генә гаскәргә килеп җиттеләр. Менә шушы кешеләргә дә башкаларга кебек өлеш бирелде. Моннан башка Бәдердә шәһид булган ундүрт кеше дә өлешкә кертелде.

Мәдинә халкы җиңүчеләрне зур шатлык белән каршы алды. Балалар вә җәрияләр Мәдинә урамнарында шатлыкларыннан шигырьләр сөйләп, думбралар кагып йөрделәр. Мәдинәдә һәм тирә-юньдә булган дошманнарга бу җиңү каты тәэсир итте. Исламның көч вә куәте артты. Моннан соң Мәдинәдәге байтак кеше Исламны кабул итте. Хазраҗ башлыкларыннан булган Габдулла бине Убәй һәм аңа ияргән кешеләр дә шул вакыт Исламны кабул иттеләр[1]. Корәеш мөшрикләренең исә, киресенчә, рухлары төште, Мәккә кайгыга батты. Гарәп кабиләләре арасында дәрәҗәләре кимеде.

1 "Зәдүл-Мәгад", 1 т., 347 б. – авт.

Әбү Җәһил бине Һишам, Гутбә бине Рабига, Шәйбә бине Рабига, Гукъбә бине Мугыйт кебек зур башлыклар үтерелде.

## *Әсирләр турында сәхабәләр белән киңәшмә*

Рәсүлуллаһ әсирләр хакында ни эшләү өчен сәхабәләр белән киңәшмә үткәрде. Әбү Бәкер торып: «Әй, рәсүлуллаһ! Без аларны үтермик, аларны мал бәрабәренә азат итик, бу юл белән үзебезнең матди хәлебезне арттырырбыз. Алар хәзер безнең дошманнарыбыз булсалар да, ихтимал, бервакыт синең сәбәпле һидаяткә килеп, синең ярдәмчеләрең булырлар», – диде. Сәгъд бине Мугәз белән Габдулла бине Равәхә да бу фикергә кушылды. Гомәр бине әл-Хаттаб исә: «Әй, рәсүлуллаһ! Бу мөшрикләр сине ялганчыга чыгардылар, сине һәм әсхабеңне ватаннарыннан кудылар, безгә каршы сугыш ачтылар. Миңа үз кардәшемне үтерергә, Хәмзәгә кардәше Габбасны үтерергә, Галигә кардәше Гукәйлне үтерергә ирек бир. Без аларны үтерик. Алар кәфер башлыклары. Боларны, әлбәттә, үтерергә тиешледер», – диде. Рәсүлуллаһ һәр икесенең дә киңәшен ихтирам итте һәм ихласлыклары өчен шөкер белдерде. Соңыннан боларга карап: «Гомәр, син Нух кебек каты бәгырьлесең, чөнки Нух галәйһиссәлам: «Әй, Раббым, җир йөзендә кәферләрне калдырма», – дип дога кылды. Әбү Бәкер, син Ибраһим кебек йомшак күңеллесең, ул: «Кем миңа иярсә, бәс ул миннән, кем карышса, бәс Син Раббым ярлыкаучы, рәхимле затсың», – дип дога кылды», – диде. Ә үзе Әбү Бәкер фикеренә кушылды. Шулай итеп, фидия алынуга карар кылынды. Бер кешенең фидиясе, хәленә карата, мең дирхәмнән алып дүрт мең дирхәмгә кадәр билгеләнелде.

www.darul-kutub.com

## *Мөшрикләрнең тәэсире*

Корәеш мөшрикләре Мәккәгә кайткач, бер айга кадәр үлгәннәрне уйлап, соңра дошманнарының шатлануларыннан куркып, елауларын туктаттылар. Әсирләрне коткарыр өчен күп фидия сорарлар дип, бик ашыкмасалар да, әл-Мотталиб бине Вәдәга исемле берсе чыдый алмыйча, яшерен сурәттә Мәккәдән чыгып Мәдинәгә барды һәм атасын дүрт мең дирхәм биреп йолып алды. Моннан соң калганнары да берәм-берәм Мәдинәгә барып, туганнарын йолым биреп алдылар. Түләргә көчләре җитмәгән әсирләрне акчасыз азат иттеләр[1]. Укый-яза белгән әсирләрнең һәрберсенә ун бала биреп, уку-язуны өйрәттерделәр[2]. Кайберләре Мәккәдәге мөселман әсирләренә алыштырылдылар.

## *Бәдер сугышы хакында аятьләр иңү*

Бәдер сугышы – Корәеш мөшрикләре белән Ислам әһелләре арасында булган зур сугышларның иң әүвәлгеседер. Бу сугышта Ислам гаскәре Аллаһы Тәгаләнең рәхимлелеге һәм ярдәме белән, сәхабәләрнең иман куәте, ныклыклары һәм чыдамлыклары белән үзләреннән өч тапкыр зур булган, яхшы коралланган мөшрикләр гаскәрен җиңделәр. Бәдер сугышы турында Аллаһы Тәгалә «Әнфәл» сүрәсен иңдереп, сугыштагы җиңүнең Үзенең ярдәме белән булганын бәян итте. Бәдер әсирләреннән фидия алу Аллаһы Тәгаләнең әмере белән булмыйча, Рәсүлуллаһның үз иҗтиһады белән иде. Шуның өчен дә Рәсүлуллаһ бу хакта сәхабәләр белән киңәш иткән иде. Бу хосуста Аллаһы Тәгалә шул ук сүрәдә берничә

1 Шагыйрь Әбү Гыйззә әл-Җумхи шулардан берсе иде – авт.

2 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 323 б. “Хәләбия”, 2 т., 204 б. – авт.



www.darul-kutub.com

аятьләрдә[1] боларның мөшрикләрдән фидия алуларының хата икәнлеген, дөнья малына алданып, мондый мөшрикләрне сау калдыру, алардан фидия алу тиеш түгеллеген аңлатты. Моның белән мужтәһиднең ижтиһады өчен газапка лаеклы түгеллеген сөйләп, боларга фидиядән килгән малны рөхсәт итте.

## *Күдр газвәсе*

Рәсүлуллаһ Бәдер сугышыннан кайтып, Мәдинәдә берничә көн торгач, Ибне Суләим гарәпләренең сугышка әзерләнгәннәрен ишетеп, аларга каршы чыкты. Мәдинәдә үз урынына Ибн Умм Мәктумне калдырды. Байрак Гали бине Әбү Талиб кулында иде. Ләкин бу сәфәрдә сугыш булмады. Ислам гаскәре мөшрикләрнең «Күдр» исемле суларына барып туктаганга, бу сугышка «Күдр газвәсе» диелер[2]. Гаскәр Күдрдә өч көн булды.

## *Сәвикъ газвәсе*

Мәккә мөшрикләре Бәдердә җиңелеп кайткач, Мәккәдә рәис булып калган Әбү Сафүән бине Хәрб рәсүлуллаһ белән сугышырга нәзер әйткән иде. Шул нәзерендә тору өчен ул ике йөз гаскәр әзерләп, Мәдинәгә юнәлде. Мөселманнар турында мәгълүматлар алу һәм ярдәм сорау нияте белән Ибне Назыйр яһүдләренә сугылып, рәисләре Хүәй бине Әхтабны күрмәкче булса да, ул кабул итмәде. Соңра Сәлләм бине Мишкәм белән күрешеп сөйләште. Ләкин болардан бер файда да күрә алмаганга, мөселманнар белән сугышырга батырчылык итмәде. Шулай да әйткән нәзерендә тору өчен

1 “Әнфәл”/27-29 аятьләр. – авт.

2 “Ибне Сүләим газвәсе” дип тә йөртәләр. – авт.

берничә кешене Мәдинәнең хөрмәләрен яндырырга җибәрде. Мөшрикләр Мәдинә янына килеп, андагы хөрмә агачларын яндырдылар һәм Мәдинәдән чыккан ике кешене үтерделәр. Моны ишетеп, рәсүлуллаһ 200 кешелек гаскәр белән Әбү Сафүәнны куа чыкты. Мәдинәдә үз урынына Бәшир бине Габдүл Мунзирны калдырды. Ләкин ике гаскәр арасында сугыш булмады. Чөнки мөшрик гаскәре каты сурәттә качты. Хәтта атларга җиңел булсын өчен азыкларын да ташлап калдырдылар. Бу азыкларның күбесе талканлык[1] булып, Ислам әһелләре моны ганимәт иткәнлектән, бу газвәгә «Сәвыйк газвәсе» диелер. Сәвыйк газвәсе зөлхиҗҗә башларында иде.

## *Ибне Кайнукагъ газвәсе*

Бәдердәге җиңү Мәдинә яһүдләренә, бигрәк тә Кайнукагъ яһүдләренә бик начар тәэсир итте. Алар мондый бөек җиңүгә хөсетләнделәр. Арада булган гәһедләрне онытып, Ислам әһеленә каршы кайбер мөнәсәбәтсез хәрәкәтләр кылдылар. Шулай бервакыт Ибне Кайнукагъ базарына барган бер әнсари хатынының намусына тиделәр. Моны ишетеп, рәсүлуллаһ яһудләрне Кайнукагъ базарында җыеп, нәсыйхәт кылды һәм гаһедләрендә торырга кушты, мөнәсәбәтсез хәрәкәтләренең нәтиҗәсе начар булачагын аңлатты. Ләкин алар рәсүлуллаһның мәзкүр нәсихәтен кабул итү урынына аңа каршы сөйләделәр: «Син безне үз кавемең (Мәккә мөшрикләре) белән чагыштырма, аларны җиңүең белән масайма, алар сугыша белми торган халык. Безнең белән сугышсаң, безнең кем икәнебезне белерсең», – диделәр. Дөрестән дә, Кайнукагъ яһүдләре батыр вә сугышчан кавем иделәр.

1 Талкан – бал, май, хөрмә кушып пешерелгән, аннан соң киптерелгән арпа. – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

Рәсүлуллаһ никадәр солых сөючән бер зат булса да, мондый халыктан хәер чыкмаячагын, кайчан булса да алар белән сугышырга туры киләчәген аңлап, алар белән сугышырга карар биреп, гаскәр әзерләде һәм шәүвәл аеның урталарында алар белән сугышырга китте. Мәдинәдә үз урынына Әбү Лүбәбәне калдырды. Байрак Хәмзә кулында иде. Яһүдиләр рәсүлуллаһның гаскәр әзерләгәнен белеп, кальгаларына кереп бикләнгәннәр иде. Ислам гаскәре аларны 15 көн камап тотты. Соңра яһүдиләр, үзләренең җиңелүләрен аңлап, рәсүлуллаһтан солых сорадылар. Нәтиҗәдә, бөтен малларын калдырып, хатын вә балаларын алып Мәдинәдән күчү шарты белән солых төзеделәр. Аларны Мәдинәдән сөрү эше Губәдә бине әс-Самитка тапшырылды. Ул өч көн эчендә аларны чыгарып бетерде. Моннан соң яһүдләр Шамдагы «Әзригать» дигән җиргә киттеләр. Кайнукагъ яһүдләре үзләренең махсус җирләре булмыйча, сәүдә һәм сәнәгать эшләре белән шөгыльләнделәр. Болар 700 сугышчы иде. Кайнукагъ яһүдләреннән алынган ганимәтнең биштән береннән калганы гаскәргә таратылды.

Кайнукагъ яһүдләре электән Хәзраҗилар белән берлектә иделәр. Хәзраҗ башлыгы Губәдә бине әс-Самит аларның рәсүлуллаһка каршы начар мөгамәләләрен күргәч, алар белән мөнәсәбәтен кисте.

Габдулла бине Убәй исә: «Юк, мин аларны ташламыйм, әллә нинди хәлләр булырга мөмкин, ихтимал, бервакыт аларның ярдәмнәренә мохтаҗ булырбыз», – диде.

www.darul-kutub.com

## *Кыйбланың үзгәрүе*

Ошбу ел шәгъбан аенда Кыйбла үзгәртелде. Мәккәдә вакытында рәсүлуллаһ Бәйтүл-Мукаддәскә карап укый иде. Мәдинәгә килгәч тә 16-17 айга кадәр Бәйтүл-Мукәддәскә карап укыды. Фәкать үзенең күңеле белән бабасы Ибраһимның кыйбласы булган «Кәгъбәтуллаһка» юнәлүне тели һәм Кыйбла кылуны Аллаһытан өмет итә иде. Чыннан да, Аллаһы Тәгалә рәсүлуллаһ теләгән Кәгъбәне кыйбла итеп, «Бәкара» сүрәсендә берничә аять иңдерде[1]. Кыйбла үзгәрүенең иң зур хикмәте – халыкны сынау иде. Чыннан да, бу вакыйга халык өчен зур сынау булды. Бәгъзе зәгыйфь иманлы мөселманнарның диннән чыгуларына сәбәп булды. Монафикълар, яһүдләр һәм мөшрикләр бу мөнәсәбәт белән халыкны котырттылар һәм фетнәләндерделәр. Мөшрикләр: «Мөхәммәд Бәйте-л-Мукаддәсне ташлап, Кәгъбәгә карады, озакламый ата-бабасының диненә дә кайтыр инде», – диделәр.

Яһүдиләр: «Мөхәммәд хак пәйгамбәр булса, башка пәйгамбәрләр юнәлгән Кыйбланы ташламас иде, ул хак пәйгамбәр түгел», – диделәр. Монафикълар исә: «Мөхәммәд бөтенләй аптырап калды, ни эшләргә белми, бер анда, бер монда карый», – диделәр. Иманнары камил, чын мөселманнар исә, аслән, шик вә шөбһәгә төшмәделәр, киресенчә, бу мәсьәлә аларның иман куәтләрен тагын да арттырды. Чөнки алар Бәйте-л-Мукаддәснең булсын, Кәгъбәнең булсын, урын вә ташларында һичбер хосусият, изгелек булмаганын, аларның изгелекләре Аллаһының Үзенә нисбәтләп шунда юнәлүне бер гыйбадәт итүгә ихты-

---

1 “Бәкара”/142-152. – авт.

ярлы булуын, колларының Үзенә гыйбадәт иткәндә теләгән якка карарга кушарга ирекле булуын бик яхшы беләләр иде. Шуның өчен дә Бәйте-л-Мукәддәсне ташлап, Кәгъбәгә юнәлергә әмер булгач, алар: «Сәмигънә вә әтагънә» [ишеттек һәм буйсындык], – дип кабул иттеләр. Тегеләр кебек имеш-мимеш һәм мөнәсәбәтсез сүзләр сөйләмәделәр. Аллаһы Тәгалә «Бәкара» сүрәсендә аларның шундый каршы сүзләр сөйләүләрен алдан ук рәсүленә сөйләп куйды, җавапларын да өйрәтте.

## *Рамазан рузасы*

Шул ук елда шәгъбан аенда Аллаһы Тәгалә Ислам өммәтенә рамазан аенда руза тотуны мәшругъ кылды. Бу хакта «Бәкара» сүрәсендә[1] берничә аятьләр иңеп, руза нидән гыйбарәт, кемнәргә мәҗбүри һәм кемнәргә рөхсәт икәнлеген, рөхсәт булганда, кемнәргә казага кылу тиеш, кемнәргә фидия белән генә өсләреннән төшкәнлеген бәян итте. Рамазан рузасы мөнәсәбәте илә фитыр садакасы да вәҗиб кылынды.

## *Зәкәт фарыз булу*

Шул ук ел Ислам өммәтенә зәкәт фарыз кылынды. Бу вакытка кадәр сәдака һәм сарыф итү фарыз ителсә дә, кирәк Коръәни Кәрим булсын, кирәк рәсүлуллаһ үзе зәкәтне түләүгә өндәсә дә, нисаб микъдары, зәкәт күпме микъдарда булуы бәян ителмәгән иде. Зәкәт – Исламиятнең иң бөек рөкеннәреннәндер. Исламияттә зәкәтнең мәшругъ булуы аның иҗтимагый бер дин булуына иң зур шаһиттыр.

Коръәни Кәримдә зәкәтнең гел намаздан соң бирелүе,

1 “Бәкара”/183-187. – авт.

аның бәрабәр күләме зекер кылына. Сарыф итмәгән, малының зәкәтен чыгармаган мал хуҗалары каты сурәттә куркытыла. Зәкәт фарыз булып та, зәкәт бирмәгән кешеләр Коръән буенча камил мөэминнәрдән саналмыйлар[1].

## *Гает намазын кануннлаштыру*

Ошбу елда Аллаһы Тәгалә мөселманнарга гает намазын мәшругъ кылды. Рәсүлуллаһ Кайнукагъ вә Сәвикъ газвәләреннән кайткач, зөлхиҗҗә аеның уны җиткәч, Мәдинә халкын бер җиргә җыеп, ике рәкәгать намаз укыды. Бу – беренче мәртәбә укылган гает намазы иде[2]. Ошбу гаеттә рәсүлуллаһ үзе ике куй корбан кылды. Башка хәлле кешеләр дә корбан чалдылар.

Рәсүлуллаһ гаетне мәйданда укый торган иде. Мәчеттә бер мәртәбә генә, яңгыр яуганда гына укыган[3]. Гает намазы ялгыз ике рәкәгать булып, аның алдында да, артында да һичбер намаз укылмый, гает өчен азан, камәт кебек нәрсәләр дә әйтелми иде. Башта гает намазы укылып, аннан соң рәсүлуллаһ халык каршында хотбә сөйли, вәгазь һәм нәсыйхәт кыла иде. Хатын-кызны хаслап вәгазьли, аларны ярдәм итүгә өнди иде. Гает намазы укылгач, хотбә тыңлауда кеше ихтыярлы иде. Гает җомга көнгә туры килсә, гает намазы белән генә дә канәгатьләнергә рөхсәт ителә иде[4]. Ул вакыт

1 Зәкәт Коръәни Кәримдә гел иман, намаз белән чагыштырылып зекер ителә торып, безнең җәннәт ачкычы үз кулларында диеп уйлап йөри торган кешеләребез дә әллә нинди факыйһларның әллә нинди мәгънәсез риваятьләренә туры китереп, шәргый хәйлә кылган булып, зәкәттән котылалар. Факыйһларның коры фәлсәфәсе белән Коръәни Кәрим бөтенләй җимерелеп ташлана микәнни? Без кечкенә вакытыбызда үзләрен гөнаһ эшләрдән саклап йөрүләренә ышанып йөргән кешеләрнең шундый түбәнчелек кылуларын күргәләдек. Хурлыктан Аллаһыга сыенабыз. – авт.

2 Ибн әл-Әсир, 2 т., 52 б. – авт.

3 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 124 б. – авт.

4 Бохари, 7 т., 103 б. Әбү Дауд, 1 т., 160 б. – авт.



www.darul-kutub.com

гает вә җомгалар ирләргә генә махсус булмыйча, хатын-кызлар да катнаша иделәр. Гомуми эшләрнең күбесе мәчетләрдә эшләнә иде[1].

Шул ук елда рәсүлуллаһ кызы Фатыйманы атасының бертуганы улы Галигә никахландырды. Рәсүлуллаһның Гайшә куенына керүе дә шул елда иде.

Хөрмәтле сәхабәләрдән иң суфыйларыннан Госман бине Мәзгун ошбу елда вафат булды. Бу кеше беренчеләрдән булып Хәбәшәгә дә, Мәдинәгә дә һиҗрәт иткән иде. Рәсүлуллаһ моның каберенә су сиптерде һәм таш куйдырды.

## <u>Өченче ел</u>

### *Зи Әмр газвәсе*

Ошбу елның мөхәррәм аенда рәсүлуллаһ Ибне Сәгъләбә һәм Ибне Мухәриб гарәпләренең Ислам әһеле белән сугышка әзерләнгәннәрен ишетеп, 450 кешелек гаскәр белән аларга каршы чыкты. Мәдинәдә үзе урынына Госман бине Гаффән калды. Юлда рәсүлуллаһ Сәгъләбә гарәпләреннән берсен очратып, иманга дәгъвәт итте. Шул кеше иман китерде. Соңра рәсүлуллаһ аңардан дошманнар хакында сорашты. Ул Ислам гаскәренең килүен ишетеп, мөшрикләрнең тау

---

1 Корбан гаетенең һиҗрәтнең икенче елында укылганы сира китапларында зекер ителсә дә, Фитыр [Рамазан] гаете кайсы елда укыла башлаганлыгы хакында ачык сүзләр таба алмадым. Фәкать, Ибн әл-Әсирнең корбан гаете хакында: “Ошбу укылган гаетләрдән беренчесе иде,” – дигән сүзеннән Фитыр гаете бу елда укылмаганлыгы аңлашыла. Һәм шулай булырга да кирәк. Чөнки рамазан рузасы шул елда фарыз булды. Рамазан аенда рәсүлуллаһ Бәдер сугышы белән мәшгуль иде. Бәдердән бушанып кайтуы рамазан ахырларында яки шәүвәл аеның башында булырга кирәк. Хәлбуки, Бәдердән кайткан вакытта рәсүлуллаһның вак-төяк эшләрен санап язганда, сира галимнәре Фитыр гаете хакында бернәрсә дә язмаганнар. Әгәр юлда укылган булса, әлбәттә, зекерителер иде. Мәдинәдә Рәсүлуллаһтан башка укулары да зекер ителми. Әгәр Мәдинәдә калган сәхабәләр Фитыр гаетен укыган булсалар, әлбәттә, зекер ителер һәм кем имам булып укытуы хакында да сүз булыр иде. Шуның өчен Фитыр гаете өченче ел укылгандыр диясе килә. – авт.

араларына качып беткәннәрен сөйләде. Шунлыктан гаскәр сугышсыз кайтып китте. Гаскәр бу сәфәрдә унике көн йөрде. Бу сәфәрдә Ислам гаскәре «Зи Әмр» исемендәге бер суга килеп туктаганлыктан, «Зи Әмр газвәсе» дип йөртеләдер[1].

## *Кәгъб бине әл-Әшрафнең үтерелүе*

Ибне Нәзыйр башлыкларыннан Кәгъб бине әл-Әшраф исемендәге бер яһүди рәсүлуллаһка һәм Ислам әһеленә бик каты дошман булып, һәрвакыт аларга аяк чалырга, аларга зарар китерергә тырыша иде. Кәгъб бине әл-Әшраф бай һәм хөрмәтле, аның өстенә шагыйрь дә булганлыктан, аның сүзләре халыкка каты тәэсир итә иде. Бәдердәге җиңүдән соң, Кәгъб бине әл-Әшраф Ислам әһеленә хөсеттән ни эшләргә белмәде. Мәккәгә барып, Корәеш гарәпләренең кайгыларын уртаклашып, тәгъзияләр кылды, аларның үлгәннәрен мактап мәрсияләр сөйләде. Соңра мәккәлеләрне мөселманнарга каршы котыртты. Мәдинәгә кайткач Ислам хатыннары турында начар шигырьләр сөйләде. Зарарлы, сүзендә тормыйча килешүне үтәмәве сәбәпле бер кешенең тормышын кисү җәмгыятькә зарур булганлыктан, рәсүлуллаһ Кәгъб бине әл-Әшрафны үтертергә карар бирде. Мәсьәлә сәхабәләргә аңлатылганнан соң әнсарилардан Мөхәммәд бине Мәсләмә моны өстенә алды. Ул үзенә дүрт иптәш алып, Кәгъб бине әл-Әшраф янына барды. Болар арасында Кәгъбнең сөт кардәше Әбү Нәилә дә бар иде. Мөхәммәд Кәгъбкә баргач, якынча шундый сүзләр сөйләде: «Бу кеше (рәсүлуллаһ) бездән ярдәм сорый-сорый ардырып бетерде. Менә тагын сорады. Шуңа күрә синнән бер-ике йөк хөрмә алып торырга

1 Бу сугыш “Гатафән газүәсе” дип тә йөртеләдер. Ибн әл-Әсир моны “Зи әл-Кисса” газүәсе дип атый. 2т., 53б. – авт.

килдем», – диде. Моңа каршы  Кәгъб: «Мин сезгә аның нинди кеше икәнлеген әйтмәдеммени? Аңардан туярсыз әле», – диде. Мөхәммәд бине Мәсләмә: «Без аңа бер ияргәч, бу көенчә генә ташлыйсыбыз килми. Эшнең нәтиҗәсе ни булыр, шуны көтәбез», – диде. Мөхәммәд бине Мәсләмәнең бу сүзләре хәйлә өчен генә әйтелгән иде. Кәгъб бине әл-Әшраф Мөхәммәд бине Мәсләмәнең сүзләренә кәефе килеп, коралларын закладка калдыру шарты белән сораганнарын бурычка бирмәкче булды. Кич белән коралларны алып киләм дип, кайтып китте.  Караңгы төшкәч, Мөхәммәд бине Мәсләмә әлеге иптәшләре белән Кәгъб бине әл-Әшрафкә барып, аны өеннән хәйлә белән алып чыгып үтерделәр. Шулай итеп, Ислам әһеле ошбу адәмнең явызлыгыннан котылды. Кәгъбнең үтерелүе рабигыль-әүвәл аенда иде.

## ***Бәхран газвәсе***

Ошбу ел җөмадиәл-әүвәл аенда Ибне Сәлим гарәпләренең Мәдинәне басып алу өчен «Бәхран» исемендәге бер урынга җыелганлыкларын ишетеп, рәсүлуллаһ 300 гаскәр белән боларга каршы чыкты. Мәдинәдә Ибн Үмм Мәктум калды. Гаскәр Бәхранга барып җиткәндә, мөшрикләр качып беткәннәр иде. Шунлыктан сугыш булмыйча кайтып киттеләр. Бу сәфәрдә Ислам гаскәре ун көн йөрде.

## ***Зәйд бине Хәрисә сәриясе***

Бәдер сугышыннан соң Корәеш мөшрикләре Мәдинә юлыннан Шамга йөрүнең һәлакәтле булуына төшенгәч, Гыйрак юлы белән кәрван җибәрделәр. Кәрванда Әбү Сафүән бине Хәрб, Сафвән бине Үмәйя, Хувәйтыйб бине Габдүлгуззә

кебек башлыклар бар иде. Рәсүлуллаһ, кәрванның хәбәрен ишеткәч, Зәйд бине Хәрисә кул астында йөз кешелек гаскәр җибәрде. Сәрия «әл-Карда»[1] исемендәге җирдә кәрванны барып басты. Кәрван халкы качып котылды, маллары ганимәт алынды. Гаскәрнең чыгуы җөмадиәл-ахир аенда иде. Ганимәт биштән берен алганнан соң гаскәргә бүленеп бирелде.

## *Ухуд сугышы*

Бәдер сугышыннан соң Мәккәдә рәис булып калган Әбү Сафүән бине Хәрбнең Ислам әһелләреннән үч алу максаты белән ике йөз кешелек гаскәр җыеп Мәдинәгә барып та, бу сәфәрдән уңышсыз кайтканлыгы югарыда язылган иде.

Бәдер вакыйгасы ачысы өстенә тагы да бу уңышсызлыкка дучар булган Әбү Сафүән, ничек тә булса Ислам әһелләренән үч алу ниятендә йөри иде. Бәдер сугышында атасы һәм якыннары үлгән Гыйкримә бине Әбү Җәһил, Сафвән бине Үмәйя, Габдулла бине Әбү Рабига кебек мөшрикләр башлыклары уңай бер форсат китереп, халыкны Исламга каршы сугышырга өндәргә һәм Бәдер җәрәхәтләрен төзәтергә йөриләр иде. Моның өстенә Бәдер сугышыннан соң мөшрикләрнең сәүдә юллары да бикләнү дәрәҗәсенә житкән диярлек иде. Шунлыктан куәтле бер гаскәр туплап, Ислам әһелләренең шәүкәт вә куәтләрен сындыру мөшрикләр өчен иң мөһим бер нәрсә иде.

Бәдер вакыйгасына сәбәп булган әлеге кәрвандагы маллар, ияләреннән күбесе Бәдердә катнашулары сәбәпле Мәккәгә кайту белән бүленмәгән, «Дәру ән-Нәдвә»дә сакларга куелган иде. Мөшрик гаскәре Бәдердән кайткач та,

1 Курагъ ягындагы бер урын исемедер. – авт.

кәрванга күбрәк өлешләре кергән башлыклардан күбесе Бәдердә кырылганнан, икенчедән, Бәдердә җиңелүнең ачысы сәбәпле, кәрван малын бүләргә күңелләре төшмичә, үлгәннәргә мәтәм тоту белән мәшгуль булганлыктан, бу мал һаман да ияләренә бирелмичә тора иде. Менә ошбу малларның файдасын мөселманнарга каршы сугышта куллану нияте белән, югарыда әйтелгән мөшрикләр башлыклары Әбү Сафүәнга барып, бу хакта сөйләделәр. Әбү Сафүән да моны бик акыллы фикер дип күреп, бергәләп халыкны шуңа кызыктырдылар. Әлбәттә, бөек башлыклары һәм күбесенең ата вә угыл, якыннары үтерелеп, калебләре яраланган мөшрикләр моңа каршы булмыйча, рәхмәт йөзеннән кабул иттеләр. Нәтиҗәдә, кәрвандагы мал илле мең алтынга исәпләнеп, сугыш кирәк-ярагына сарыф ителде.

## ***Сугышка әзерләнү***

Шушы юл белән сугыш өчен мал тәэмин ителгәч, Корәеш башлыклары бик җитди сурәттә халыкны сугышка өнди башладылар. Мәккә тирәсендә булган сахра гарәпләрен агитацияләү өчен мәшһүр хатыйбларын һәм шагыйрьләрен күндерделәр. Алар арасында Бәдер сугышында рәсүлуллаһ кулына төшеп, фәкыйрьлеге сәбәпле азат ителеп, бары тик мөселманнарга каршы булмау гына шарт итеп куелган шагыйрь Әбү Газзә әл-Җумхә дә бар иде. Әбү Газзә моны исенә төшереп, бу эшкә катнашмаска булса да, Сафвән бине Умәйянең кызыктыруы буенча кабул итте. Шул хатыйблар һәм шагыйрьләрнең күндерүе белән Тиһамә һәм Кинәнә гарәпләреннән, Корәеш белән берлектә булган «Әхабиш»тән бик күп гаскәр жыелды. Мөшрик гаскәре өч меңгә житеп,

ике йөзе атлы гаскәр иде. Гаскәр башлыгы итеп Әбү Сафүән билгеләнде. Гыйкрим бине Әбү Җәһил, Халид бине әл-Вәлид, Сафвән бине Үмәйя фирка башлыклары итеп куелдылар. Корәешләр, сугыштан качмас һәм гаскәрнең рухын күтәрер өчен үзләре белән хатыннарын да алып чыктылар. Болар арасында баш командир Әбү Сафүәнның хатыны – Һинд бинте Гутбә, Гыйкримәнең хатыны – Умм Хәким, Сафвән бине Умәйя хатыны – Бәрзә бинте Мәсгуд, Харис бине Һишам хатыны – Фатыйма бинте Вәлид, Гамр бине әл-Гас хатыны Рита бинте Мунәббиһ, Талхә бине Әбү Талхә хатыны Сүләфә һәм башкалар бар иде. Гаскәрнең рухын күтәрер өчен барабан сугып вә курайлар уйнап, гаскәрне батырлыкка өнди торган шигырьләр сөйләү өчен кәнизәкләрне дә алып чыктылар. Гаскәр эчендә Ислам әһелләре арасында «фәсыйк» дип танылган Әбү Гамир дә бар иде. Ул жаһилият вакытында Ясрибтәге Әус кабиләсенең рәисе булып, рәсүлуллаһ Мәдинәгә һиҗрәт итеп килгәч, аңа хөсет вә дошманлыгыннан Мәдинәне ташлап, берничә иярчен белән Мәккәгә киткән иде. Ул жаһилият вакытында «Раһиб» дигән исем белән дә мәшһүр иде. Мәзкүр эшеннән соң рәсүлуллаһ аны фәсыйк дип атады.

Бәдер сугышында рәсүлуллаһның Хәмзә бине Габделмоталлиб ягыннан абыйсы булган Тугаймә, үтерелгән Җүбәйр бине Мутгыймның атуга бик оста булган «Вәхши» исемендәге колын чакырып, Хәмзәне үтерергә кушты. Моңа бүләк итеп, азат булачагын әйтте. Шуңа күрә Вәхшинең бөтен максаты – форсат китереп, Хәмзәне үтерү иде.

www.darul-kutub.com

## *Гаскәрнең Мәдинәгә төшүе*

Шулай итеп, Әбү Сафүән өч мең һәм камил әзерлекле гаскәр белән Мәдинәгә юнәлде. Байрагы Габдүддәр балаларыннан Талхә бине Әбү Талхә кулында иде. Гаскәр шәүвәл аеның дүртесе шимбә көнендә Мәдинәнең төньяк-көнбатышында урнашкан Ухуд тавы янында «Гәйнәйн» дигән жиргә килеп туктады[1].

## *Рәсүлуллаһка хат килү*

Мөшрик гаскәре Мәккәдән чыккач Габбас бине Габделмоталлиб Гаффар кабиләсеннән бер кешене яллап, рәсүлуллаһка мөшрикләрнең чыгулары хакында хат җибәрде[2]. Мәзкүр илче өч көн эчендә Мәдинәгә килеп җитеп, рәсүлуллаһка хатны тапшырды. Ул вакыт рәсүлуллаһ, эш белән Кубага барган иде. Хаттан хәлне аңлагач, рәсүлуллаһ Кубада Сәгъд бине әр-Рабигъка кереп бу хакта киңәшләште. Аңа эшнең ахыры хәерле булачагына өметләнгәнен сөйләде[3]. Соңра Мәдинәгә кайтып, мөшрикләр хакында мәгълүмат алыр өчен җәсүсләр җибәрде. Җәсүсләр кайтып, мөшрикләрнең Өхедкә якын бер жиргә килеп төшкәнлекләрен сөйләделәр. Шуннан соң рәсүлуллаһ сәхабәләрне җыеп, мөшрикләргә ничек каршы тору хакында киңәшләште. Үзенең фикере дошманга каршы чыгу булмыйча, Мәдинәдә торып, дошман һөҗүм иткәндә саклану икәнлеген бәян итте. Сәхабәләрдән кайберләре, бигрәк тә картыраклары,

1 Ибн Һишам, 1 т., 448 б. Шушы сәбәптән Ухуд көнен "Йәүмү гайнәйн" дип тә әйтәләр. – авт.

2 Габбас Бәдер вакыйгасында күп зыян күрүенә сылтап, бу сугышка чыкмаган иде. – авт.

3 "Хәләбия", 2 т., 230 б. – авт.

рәсүлуллаһның фикеренә кушылсалар да, Бәдер сугышында җиңү сәбәпле рухлары күтәрелгән яшь сәхабәләр дошманга каршы чыгу фикерен куәтләделәр. Бәдер сугышына чыга алмыйча ганимәт малыннан мәхрүм булган кешеләр бу фикерне бигрәк тә хупладылар. Мәшһүр каһарман Хәмзә дә шулар фикерендә булды. Монафикъларның башлыгы Габдулла бине Үбәй рәсүлуллаһ фикерендә иде. Ул: «Әй, рәсүлуллаһ, дошманга каршы чыгып, үзебезне һәлакәткә салмыйк. Әгәр Мәдинәгә һөҗүм итсәләр, ирләребез аларга каршы торыр, хатыннар вә балаларыбыз өй башларыннан ташлар белән атарлар, әгәр һөҗүм итмәсәләр, бик яхшы, өметләре өзелеп кайтып китерләр», – димеш иде. Чыннан да, бу фикер иң муафикъ вә тугры фикер иде. Ләкин күпчелек дошманга каршы чыгу тарафында булганга, рәсүлуллаһ аларга кушылып, шәһәрдән чыгарга карар бирде. Рәсүлуллаһ дөньяви эшләрдә һәрвакыт сәхабәләр белән киңәшләшә, аларның тугры фикерләрен үз фикереннән өстенрәк куя, күпчелек сәхабәләрнең фикере үз фикеренә капма-каршы булса да, аларны кабул итә иде. Менә бу вакыйгада да рәсүлуллаһ Исламиятнең иң бөек нигезләреннән булган «Шура» [киңәш] кагыйдәсенә әһәмият биреп, никадәр хата булса да, күпчелек фикеренә авышты. Бу көн шәүвәл аеның алтысы, җомга көн иде. Рәсүлуллаһ сәхабәләре белән җомга намазы укып, хөтбәдә аларны сабыр вә нык булырга дәгъвәт итте. Сабыр иткән тәкъдирдә җиңү киләчәге турында сөйләде. Җомгадан соң һәркем сугышка әзерлекләр белән мәшгуль булды.

Рәсүлуллаһ өеннән тимер киемнәрен киеп[1], коралларын тагып чыгуга, халык әзерләнеп көтеп тора иде. Бу вакыт шәһәрдән чыгып, сугышырга дип тавыш биргән кешеләр:

1 Рәсүлуллаһ, бу сугышка ике кат тимер кием кигән иде – авт.

«Юкка рәсүлуллаһны ирексезләдек. Аның фикеренчә, Мәдинәдә генә каласы иде», – дип үкенә башладылар. Рәсүлуллаһ коралларын тагып чыккач: «Әй, рәсүлуллаһ, без сине юкка ирексезләдек шикелле. Син үз белгәнеңне эшлә, без сиңа иярәчәкбез», – диделәр. Рәсүлуллаһ аларга: «Юк, пәйгамбәр кешегә бер мәртәбә сугышка карар биреп, коралларын таккач, сугыштан ваз кичү туры килми», – дип җавап кайтарды. Соңра сугыш байракларын өләште. Мөһаҗирләрнең байрагын Мусгаб бине Гумәйргә, Хазраҗ әләмен – Хәббәб бине Мунзиргә, Әүс әләмен – Үсәйд бине Хузайрга бирде.

Бөтен гаскәр бер мең булып, арада берничә сәхабә хатыннар да бар иде. Болар арасында Үммл-муэминин [мөэминнәрнең анасы] – Гайшә, рәсүлуллаһның кызы – Фатыйма, Үмм Сүләйм, Үмм Сәлитъ, Үмм Гаммәра бинте Кәгъб, Үмм Әймән бар иде. Алар сугыш вакытында гаскәргә су ташып, җәрәхәтләнгәннәргә ярдәм күрсәтеп йөрделәр. Мәдинәдә рәсүлуллаһ урынына Ибн Үмм Мәктум калды. Гаскәр шәүвәл аеның алтысында, җомга көн икендедән соң Ухуд ягына сәфәр кылды. Кич белән «Шәйхайн»[1] дигән җиргә туктап, төнне шунда үткәрде. Гаскәрне каравыллау өчен берничә кеше белән Мөхәммәд бине Мүсәлләмә, рәсүлуллаһны саклар өчен Зәквән бине Габдүлкайсны билгеләделәр. Ошбу җирдә рәсүлуллаһ гаскәрне тикшереп, сугышка көче җитмәслек сабыйларны кире кайтарып җибәрде. Алар арасында Зәйд бине Сәбүт, Усәмә бине Зәйд, Габдулла бине Гомәр, Бәрра бине Газиб, Әбү Сәгыйд бине әл-Худри, Зәйд бине Әркам, Гурәбә бине Әүс бар иде. Рафигъ бине Хәдиҗ башта кайтырга тиеш булса да, ук атуда оста икәнлеге беленгәч, Рәсүлуллаһ аны гаскәрдә калдыр-

1 Мәдинәгә якын бер урын – авт.



www.darul-kutub.com

ды. Сәмура бине Җундәб моны күреп елады. Һәм үги атасына шикаять итеп: «Рәсүлуллаһ мине калдырып, Рафигъны кабул итте. Хәлбуки, мин аны көрәшкәндә егам», – диде. Рәсүлуллаһ моны ишеткәч, аларны көрәштереп карады. Сәмура Рафигъны еккач, гаскәргә кабул ителде.

## *Габдулла бине Үбәйнең аерылып китүе*

Гаскәр сәхәр вакытында кузгалып, Мәдинә белән Ухуд арасында әш-Шәут дигән җиргә җиткәндә, Габдулла бине Үбәй: «Мөхәммәд галәйһиссәлам минем фикеремне кабул итмәде, балалар фикеренә иярде. Ни өчен без үзебезне һәлакәткә салыйк», – дип, үзенә ияргән өч йөз гаскәр белән кире кайтып китте. Хазраҗ кабиләсенең башлыгы Габдулла бине Гамр бине Хәрам моны күреп, Габдулла бине Үбәйне ялынып калдырырга тырышса да, тырышуы бушка иде. Габдулла бине Үбәйнең гаскәрдән аерылып китүе Ислам гаскәренә шөбһә вә курку салды. Әнсарилардан Ибне Сәлимә һәм Ибне Хәрисә чак кына кайтып китми калдылар.

## *Гаскәрнең хәрәкәте*

Рәсүлуллаһ калган җиде йөз гаскәр белән Өхед тавында бер ачыклык җиргә урнашты. Гаскәрне арты белән Өхедкә , алды белән Мәдинәгә каратып урнаштырды. Һәр ике тараф гаскәрләрен сафка тезде. Рәсүлуллаһ гаскәрендә 50 кешедән гыйбарәт укчылар фиркасы бар иде. Аларга җитәкче итеп Габдулла бине Җүбәйрне билгеләп куйды. Аларны гаскәрнең арткы ягына урнаштырып, мөшрикләрдән гаскәрнең тылын сакларга һәм мөшрик гаскәре Ислам гаскәренә һөҗүм иткәндә, уклар белән атып каршы алырга кушты. Җиңү Ис-

лам гаскәре тарафында яки дошман тарафында булса да, урыннарыннан һич кузгалмыйча, шунда калырга әмер итте. Соңра гаскәргә карап, аларның рухын күтәрерлек хотбә сөйләде.

Ике тараф гаскәре бер-берсенә якынлашкач, югарыда зекер ителгән Әбү Гамир, мөшрик гаскәреннән чыгып, Әус кабиләсе аны итагать итеп, үз ягына чыгарга чакырырлар дип, аларга үзен танытса да, тырышуы бушка китте. Әнсарилар аңа каты рәвештә каршы җавап бирделәр. Моны күреп Әбү Гамир: «Миннән соң кавемем бозылган икән», – дип, өметсезләнеп урынына басты. Соңра сугыш мубәразә юлы белән башланды: башта мөшрик гаскәреннән берсе чыгып, үзенә каршы сугышырга кеше таләп итте. Аңа каршы Зүбәйр бине әл-Гавәм чыгып аны үтерде. Шуннан соң Талхә бине Әбү Талхә чыкты. Аны Гали үтерде. Габдеррахман бине Әбү Бәкер чыгып, үзенә мубәразә таләп иткәч, каршысына Әбү Бәкер чыкмакчы булса да, рәсүлуллаһ рөхсәт бирмәде:

«مَتِّعْنَا بِنَفْسِكَ يَا أَبَا بَكْرٍ»[1]

– дип кире күндерде. Соңра ике гаскәр бер-беренә һөҗүм итеп, бик каты сугыш башланды. Мөшрикләрнең хатыннары гаскәр артыннан барабаннар кагып, төрле шигырьләр сөйләп, ирләрен рухландырып тора иде. Мөшрикләрнең атлы гаскәрләре өч мәртәбә Ислам гаскәренә һөҗүм итсәләр дә, укчы фиркасы ук атып, аларны кире бордылар. Ислам гаскәре гаять зур батырлык белән сугышты. Бигрәк тә Әбү Дүҗҗәнә[2], Хәмзә, Гали кебек баһадирлар ук кебек атылып

1 «Әй, Әбү Бәкер! Үзеңнең булуың белән безне файдаландыр» – авт.

2 Әбү Дүҗҗәнә гаять көчле баһадир иде. Рәсүлуллаһ аңа сугышыр алдыннан үз кулы белән кылыч тоттырган иде – авт.



www.darul-kutub.com

йөриләр, алларына кем генә очраса да, кылычтан үткәрәләр иде. Бу вакыт Әбү Талхә гәиләсеннән генә дә җиде кеше үтерелде. Моннан соң мөшрик гаскәреннән байрак күтәрергә һичкем батырчылык итмәгәнлектән, әләмнәре жиргә төште, гаскәр дә җиңелеп кача башлады. Хатын-кызлары елый-елый Ухудка таба йөгерә башладылар. Моны күреп, Ислам гаскәре тагын да җөрьәт белән аларны артларыннан куды һәм ганимәтләр жыя башлады.

## *Укчы фиркасының урынын ташлавы*

Ислам гаскәренең артында булган укчы фиркасы мөшрикләрнең җиңелүләрен һәм Ислам әһелләренең аларның артыннан куып, ганимәт җыйганнарын күреп: «Без монда ни эшләп торабыз, әйдәгез, халык кебек ганимәт алырга!» – дип гаскәр артыннан китә башлады. Боларның башлыклары Габдулла бине Җүбәйр рәсүлуллаһның сүзен исенә төшереп, урыннарыннан кузгалмаска кушса да, рәисләренең сүзенә колак салмадылар, дөнья малына алданып, гаскәр артыннан йөгерә башладылар. Тик Габдулла бине Җүбәйр генә берничә кеше белән рәсүлуллаһның әмере буенча урыннарында калдылар. Мөшрик гаскәренең командирларыннан берсе булган Халид бине әл-Вәлид укчы фиркасының урыннарыннан кузгалганын күреп, үз кул астында булган берникадәр гаскәр белән яннарына барып бөтенесен кылычтан кичерде. Соңра ганимәт җыя барган Ислам гаскәренең артыннан төшеп, боларга һөҗүм итте. Ислам гаскәре моны күреп бөтенләй шашып калды. Ул арада мөшрик гаскәре дә Халиднең һөҗүмен күреп, качудан туктады.

www.darul-kutub.com

## *Мөшрик гаскәренең рухы күтәрелүе*

Бу вакытка кадәр мөшрикләрнең әләме ташланган хәлдә булып, аны алырга һичкем җөрьәт итми иде. Шул арада Гамра бинте Галкамә исемле бер хатын, әләмне күтәреп, халыкны үзе янына җыя башлады. Мөшрик гаскәре байрак тирәсенә тупланып, Ислам гаскәренә бердәм һөҗүм итте. Ике яктан һөҗүм астында калган Ислам гаскәре ни эшләргә белмичә аптырап калды, сафлар бозылды, төрлесе төрле якка таралып, берәм-сәрәм сугыша башладылар. Шашуларыннан ни эшләргә белмичә, иптәшләрен үтерүчеләр дә булды.

Бу вакыт мөһаҗирләр әләмен күтәргән Мусгәб бине Гамирне үтергән Ибн Камиәһ исемендәге бер мөшрик: «Мөхәммәдне үтердем!» – дип, гаскәр эчендә сүз таратты. Моны ишетеп, мөшрик гаскәренең рухы күтәрелде, тагы да җитди сурәттә сугыша башлады. Ислам гаскәре исә, бу хәбәрне ишетеп, бөтенләй югалып калды. Арада: «Инде рәсүлуллаһ үтерелгәч, нәрсәгә сугышабыз?» – диючеләр, хәтта бөтенләй сугышны ташлап, Мәдинәгә таба качучылар да булды. Бу соңгылар арасында Госман ибн Гаффан, әл-Вәлид бине Гукбә, Хариҗә бине Зәйд, Рифәга бине Мугаллә бар иделәр. Алар качсалар да, Мәдинәгә керүдән оялып, өч көннән соң гына кайтып керделәр.

Ислам гаскәре шулкадәр аптырап калды ки, хәтта бәгъзеләре: «Безгә Габдулла бине Үбәйдән яклау эзләргә кирәк, ул Әбү Сафүәннан безгә иминлек алыр», – дип әйтү дәрәҗәсенә килделәр. «Мөхәммәд галәйһиссәлам үтерелсә дә, динебезне саклар өчен сугышыйк, ул үлсә дә, динебез бакый бит», – дип сугыш мәйданында бик каты сугышучылар да булды.

## *Рәсүлуллаһ янында сәбит калучылар*

Әбү Талхә әл-Әнсари, Әбү Дуҗҗәнә, Сәгъд бине Әбү Вәккас, Талхә бине Губәйдулла, Әбү Бәкер, Гали, Сәһл бине Хәниф рәсүлуллаһ янында торып калып, мөшрикләр һөҗүменнән аны саклыйлар иде. Әбү Талхә әл-Әнсари рәсүлуллаһны яклауда гаять зур гайрәт күрсәтте: ул һәрвакыт рәсүлуллаһның алдында торып, калканы белән аны мөшрикләрдән саклый иде. Ул ук атуга бик оста булып, укларын рәсүлуллаһның алдында чәчеп ташлап, якын килгән кешеләрне ук белән кире кайтара иде. Рәсүлуллаһ үтеп барган кешеләрдән берәрсендә ук күрсә: «Укларыңны Әбү Талхәгә ташлап кит!» – дия иде. Сәгъд бине Әбү Вәккас та рәсүлуллаһ яныннан аерылмады. Рәсүлуллаһ аңа: «Сәгъд ат! Атам, анам сиңа фида булсын!» – дия иде. Сәһл бине Хәниф тә оста укчы булып, ук атып, дошманны рәсүлуллаһка китерми тора иде. Әбү Дүҗҗәнә дә гел рәсүлуллаһ янында булып, аңа ук тидермәс өчен мөшрикләргә аркасын куеп аны саклый иде. Аркасына никадәр ук төшсә дә, һаман шулай басып тора иде. Зиядә бине әл-Хәрис тә рәсүлуллаһ яныннан аерылмыйча аны саклап тора иде. Ул җәрәхәтләнеп яткач, рәсүлуллаһ аягын аның башы астына куйды. Зиядә рәсүлуллаһның аягына башын куйган хәлдә вафат булды.

## *Рәсүлуллаһ сәламәт*

Рәсүлуллаһның үлеме турында хәбәр таралганнан соң аны беренчеләрдән булып танучы Кәгъб бине Малик әл-Әнсари булды. Ул рәсүлуллаһны күргәч, шатлыгыннан каты тавыш белән: «Әй, әнсарилар, шатлык!» – дип кычкы-



www.darul-kutub.com

рып җибәрде. Ләкин рәсүлуллаһ моңа кычкырмаска кушты. Соңра Сәгъд бине Әбү Вәккас белән Сәгъд бине Губәдә арасында булган хәлдә әүвәлге урынына китте. Артыннан Әбү Бәкер, Гали, Гомәр, Талхә, Зүбәйр килделәр. Барып җиткәч, Фатыйма белән Гали бине Әбү Талиб рәсүлуллаһның җәрәхәтләрен юдылар. Юу белән генә кан тукталмагач, Фатыйма бер киез кисәген яндырып, җәрәхәткә басты. Шуннан соң кан туктады. Соңра рәсүлуллаһ шундагы бер зур ташка менмәкче булды. Җәрәхәте булганга хәле беткәнлектән, үзе менә алмады, Талхә бине Губәйдулла күтәреп менгерде. Бу вакыт мөшрикләрдән бер төркем тау башында тора иде. Рәсүлуллаһ аларга каршы Гомәр бине әл-Хаттаб кул астында бер фирка гаскәр җибәреп, таудан куып төшерде. Ошбу җирдә Үбәй бине Халәф килеп чыгып, рәсүлуллаһны үтермәкче булып каршы килсә дә, рәсүлуллаһ янындагы сәхабәләрнең берсеннән сөңге алып, Үбәйнең бугазына атты вә каты җәрәхәтләде. Үбәй шул җәрәхәттән, Мәккәгә кайтканда юлда һәлак булды. Үбәй бине Халәф Мәккәдә вакытында яхшы бер атын симертә һәм: «Мөхәммәдне ошбу ат өстендә үтерәчәкмен», – дип әйткән. Рәсүлуллаһка бу хәбәр ишетелгәч: «Инша Аллаһы, мин аны үтерермен», – дигән. Һәм шулай туры да килде, ул рәсүлуллаһ тарафыннан үтерелде. Бу сугышта мөшрикләрдән 17 кеше үтерелгәне риваять ителәдер.

Сугыш тукталгач, Әбү Сафүән бине Хәрб калку җиргә менеп, Ислам гаскәренә каршы:

«أَفِيكُمْ مُحَمَّدٌ؟»[1]

1 «Арагызда Мөхәммәд бармы?», «Мөхәммәд сәламәтме?» – димәктер – авт.



www.darul-kutub.com

– дип өч мәртәбә кычкырды. Каршы җавап булмагач, өч мәртәбә:

«أَفِيكُمْ ابْنُ أَبِي قُحَافَةَ»[1]

– дип кычкырды. Моңа да җавап булмагач:

«أفِيكُمْ عُمَر بِن الخَطَّاب»[2]

– дип өч мәртәбә кычкырды. Моңа каршы Гомәр чыдый алмыйча, үзләренең исән булганлыкларын белдереп, җавап бирде. Соңра Әбү Сафүән:

«أُعْلُ هُبَل ، أُعْلُ هُبَل»[3]

– диде. Моңа каршы рәсүлуллаһ:

«اللهُ أعْلَى وَ أَجَلّ»[4]

– дип җавап бирергә кушты. Әбү Сафүән:

«لَنَا العُزَّى وَ لَا عُزَّى لَكُم»[5]

– дип кычкырды. Моңа да:

«اللهُ مَوْلَانَا وَ لَا مَوْلَى لَكُم»[6]

– дип җавап бирде. Моннан соң Әбү Сафүән: «Бу сугыш

1 «Арагызда Әбү Кухәфә (Әбү Бәкер) бармы?» – димәк – тәрҗ.

2 «Арагызда Гомәр бине әл-Хаттаб бармы?» – димәк – тәрҗ.

3 «Һүбәл зур, ә?» – димәктер – авт.

4 «Аллаһы бөегрәк һәм олуграк» – димәк – тәрҗ.

5 «Безнең Гуззәбез бар, сезнең гуззәгез юк» мәгънәсендәдер. – авт.

6 «Безнең хуҗабыз – Аллаһы, ә сезнең хуҗагыз юк» - димәк – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

Бәдер сугышына торырлык сугыш булды, теләсәгез, киләсе елга тагы Бәдердә сугышырбыз», – диде. Рәсүлуллаһ моңа: «Бик яхшы, сугышка без әзербез!» – дип җавап кайтартты.

Әбү Сафүән гаскәре белән кайтып китте. Рәсүлуллаһ боларның кайда киткәннәрен белү өчен Гали бине Әбү Талибне чакырып: «Бар, кара! Әгәр дөяләренә менеп, атларын җитәкләгән булсалар, туры Мәккәгә киткән булырлар, әгәр атларына менгән булсалар, Мәдинәне басарга барырлар. Мәдинәгә бара калсалар, тагы да сугышачакбыз», – диде. Гали боларның артларыннан барып, дөяләренә менеп, атларын җитәкләп киткәннәре турында рәсүлуллаһка хәбәр итте.

## *Өхедтә шәһид булган затлар*

Өхед сугышы Ислам әһеле өчен иң күңелсез вә иң кайгылы бер сугыштыр. Бу сугышта мөселманнардан җитмештән артык кеше шәһид булды, бик күбесе каты җәрәхәтләр алды. Шәһид булган кешеләрнең алтысы мөһаҗирләрдән, калганы әнсарилардан иде. Шәһидләр арасында рәсүлуллаһның атасының бертуганы, мәшһүр Хәмзә бине Габделмоталлиб, Габдулла бине Җәхеш, Мусгәб бине Гумәйр, Хәнзалә бине Әбү Гамир[1], Габдулла бине Гамр бине Хәрам, Гамр бине әл-Җумух[2] һәм улы Халләд бине Гамр, Сәгъд бине әр-Рабигъ, Әнәс бине Нәзр бар иде.

Хәмзә гаскәр эчендә ук кебек атылып, кем очраса шуны кылычтан кичереп йөргәндә, әлеге вәхши бер зур таш артына посып торып, сөңгедән атып шәһид итте. Мус-

1 Фәрештәләр гөселләндереп мәшһүр булганнардандыр. Җөнеб хәлдә чыгып шәһид булмыш. Рәсүлуллаһ та аның хакында: “Аны фәрештәләр юды” – дигән иде – авт.

2 Ул аксак бер карт булып, аның дүрт улы бар иде. Балалары чыгармаска теләсәләр дә, шәһид үлемен өмет итеп чыкмыш иде – авт.



www.darul-kutub.com

габ бине Гумәйрне Ибн Кумиә исемендәге мөшрик үтерде. Ул рәсүлуллаһ янында булып, аны саклап тора иде. Мусгаб үтерелгәч, рәсүлуллаһ байракны Гали бине Әбү Талибка бирде.

Сәгъд бине әр-Рабигъ шулкадәр каты сугышкан иде ки, җитмеш җирдән җәрәхәтләнгән иде. Сугыш беткәч, рәсүлуллаһ мәетләр һәм җәрәхәтлеләрне караганда Сәгъд бине әр-Рабигъ ахыргы сулышларын алып ята иде. Рәсүлуллаһ тарафыннан җибәрелгән кеше Сәгъдка рәсүлуллаһтан сәлам әйтте, Сәгъд моңа: «Рәсүлуллаһка сәлам сөйлә, кавемем әнсариларга минем васыятем шул: алар Гакабә бәйгатен онытмасыннар! Әгәр Рәсүлуллаһка берәр нәрсә була калса, Аллаһы каршында алар гозерле булмаслар», – диде. Әнәс бине ән-Нәзр да сиксән урыннан җәрәхәтләнгән иде. Җәрәхәтләре күп булганга, аны һичкем таный алмады. Бары тик кыз кардәше генә бармак очларыннан таныды.

## *Рәсүлуллаһның җәрәхәтләнүе*

Әбү Дүҗҗәнә әл-Әнсари, Талхә бине Губәйдулла, Әбү Талхә әл-Әнсари, Үмм Гаммәра бик күп җирдән җәрәхәтләнгән иде. Үмм Гаммәра рәсүлуллаһ янында булып, аны саклый иде. Бу сугышта Рәсүлуллаһ та берничә җирдән җәрәхәтләнде. Габдулла бине шәех Әбү Зуһри йөзен җәрәхәтләде. Гутбә бине Әбү Вәккас, таш белән бәреп, алгы тешен төшерде. Ибн Камиәнең сугуы сәбәпле, бәйзасының[1] тимерләре, ике бит уртасына кереп, бит урталарын җәрәхәтләде. Шушы тимерләрне Әбү Губәйдә бине әл-Җәррах тешләре белән суырып алды. Тимерләр каты баткан-

1 Бәйза – башка кия торган махсус тимер кием – авт.

га, аларны суыргарда Әбү Губәйдә ике ал тешен сындырды. Әбү Гамир әр-Раһһаб казып, өстен каплап куйган чокырга рәсүлуллаһ егылып төшеп, мөбарәк тезләрен суйдырды һәм хәлдән тайды. Шул вакытта янында булган Гали бине Әбү Талиб белән Талхә бине Губәйдулла рәсүлуллаһны чокырдан тартып чыгардылар.

Мухәрабә бетеп, мөшрик гаскәре Мәккәгә таба юнәлгәч, рәсүлуллаһ үлекләрне җыеп күмәргә кушты. Мөшрикләр шәһидләрнең колак вә борыннарын кисеп, карыннарын ярып, тәннәрен мыскыллап бетергән иделәр. Хәмзә бине Габделмоталлиб колак һәм борыннары киселгән, карыннары актарылган көенчә ята иде.[1] Бу хәлләрне күреп, рәсүлуллаһ вә сәхабәләр бик каты тәэсирләнделәр, йөрәкләрендә төзәлми торган җәрәхәтләр хасил булды.

Рәсүлуллаһ шәһидләрне үз урыннарында күмдерде. Кайберләре якыннарын Мәдинәгә алып китсәләр дә, рәсүлуллаһ аларны яңадан китертеп күмдерде. Кеше саен кабер казып тору мөшкел булганга, ике-өч кеше бер кабергә күмелде. Алардан кайсысы Коръәнне күбрәк укый торган булса, рәсүлуллаһ шуны ләхеткә беренче куя иде. Шәһидләр юылмыйча, канлы хәлләрендә үз киемнәре белән күмелделәр. Бер-ике кешене генә, киемнәре бөтенләй тетелеп беткәнгә, башка кәфен белән күмделәр. Рәсүлуллаһ Өхед шәһидләренә җеназа намазы укымады[2]. Ул гел шулай шәһидләрне җеназа укымыйча күмә иде.[3]

1 Әбү Суфьян хатыны Һинд бинте Гутбә һәм иптәшләре Хәмзәнең колак вә борыннарыннан муенсалар ясап тагып йөрделәр. Һинд Вәхшигә бүләк йөзеннән үз кулы белән аңа муенса ясап кидерде. Тагы Һинд Хәмзәнең йөрәген алып чәйнәде. Йота алмаганнан гына кире ташлады – авт.

2 Бохари 5 т., 102 б. “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 355 б. – авт.

3 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 355 б. Рәсүлуллаһ үләр алдыннан Ухуд шәһидләренә намаз укыганлыгы ике сахих китапларында риваять ителсә дә, бу шәһидләргә җеназа уку сөннәт булганнан түгел, бәлки рәсүлуллаһ тарафыннан саубуллашу буларак бер эш иде. “Зәдүл-

## *Гаскәрнең Мәдинәгә кайтуы*

Өхед вакыйгасы шәүвәлнең 7сендә иртә белән башланып, шул көн өйләдән соң тәмам булды. Рәсүлуллаһ шәһидләрне күмдереп, шул көн кичкә таба Мәдинәгә кайтты. Тәннәре вә күңелләре җәрәхәтләнгән хәлдә кайткан сугышчыларны күреп, Мәдинә халкы нык тәэсирләнеп кайгыга батты. Һәр өйдә диярлек ата вә якыннарының үлем хәбәрен ишетеп, кайгы-хәсрәт тавышлары яңгырады. Бөтен Мәдинә караңгылык эчендә калды. Фәкать монафикълар моңа шатландылар. Алар, эчләрендәге шатлыкларын күкрәкләренә сыйдыра алмыйча, тышка да чыгардылар: «Юк белән маташып йөрдегез. Безнең кебек Мәдинәдә торсагыз, бу бәлаләр башыгызга төшмәс иде», – диделәр. Шулай ук яһүдләр дә бу вакыйгага шатлыкларыннан ни эшләргә белмәделәр.

## *Җиңелүнең сәбәбе*

Сугышта башлыкка итәгать итү, аның һәр әмерен баш өсте диеп башкару иң кирәк нәрсә һәм җиңүнең иң беренче сәбәпләреннән булган хәлдә, Ислам гаскәре бу сугышта башлыкларына буйсынмадылар. Сугыш башында җиңү алар тарафында булып, дошман гаскәре кача башлаган хәлдә, укчы фиркасы рәсүлуллаһ әмеренә буйсынмавы сәбәпле, соңында җиңелде. Башларына зур бәла һәм мусыйбәтләр килде, бигрәк тә Ислам гаскәре сугышка чыгуда ук хаталанган иде. Аларга шул вакытта ук рәсүлуллаһ сүзенә ияреп, Мәдинәдә генә калырга иде. Ул вакыт мөшрик гаскәре, ихтимал, Мәдинәгә килмәс тә иде. Килсәләр дә, Мәдинә

www.darul-kutub.com

Мәгад”, 1 т., 355 б. – авт.

эченнән саклану җиңел булачак, камауга юньләп күнекмәгән гарәп гаскәре азмы-күпме вакыттан соң борылып кайтырга мәҗбүр булыр иде.

Өхед сугышы Ислам гаскәре өчен никадәр кайгылы булса да, нәтиҗәсе белән боларга файдалы булды. Алар бу вакыйгадан бик зур дәрес алдылар. Аз санлы булсалар да, Бәдер вакыйгасында җиңүләреннән соң аларны беркадәр горурлык алды, һәрвакыт үзләренең җиңүче булачакларын күрделәр. Өхед вакыйгасыннан соң бу хосустагы хаталарын сизеп, төзәттеләр. Гел-гел җиңүгә ирешү буш бер нәрсә булганлыгын, җиңү өчен сәбәп кирәклеген ачык аңладылар.

Өхед сугышы хакында Аллаһы Тәгалә «Әл Гыймран» сүрәсендә 60 аять иңдереп, боларның күңелләрен юатты. Җиңелүләренең сәбәпләрен бәян итте. Бу вакыйгадан соң төшенкелеккә бирелмичә, киләчәк өчен моннан сабак алырга кушты. Бик күп сәяси һәм иҗтимагый хакыйкатьләр бәян итте.

## *Хәмрау әл-Әсәд газвәсе*

Мөшрик гаскәре Мәдинәгә кермичә, туры Мәккәгә китсә дә, яңадан борылып килеп, Мәдинәгә һөҗүм итү ихтималы юк түгел иде. Шунлыктан Ислам әһеле бу кичне саклык белән үткәрде. Иртәгәсен исә рәсүлуллаһ, мөшрикләрнең артларыннан китәргә карар биреп, сәхабәләрен җыя башлады. Сугышка Өхед сугышында булган кешеләргә генә чыгарга кушты. Габдулла бине Үбәй һәм иптәшләре чыгарга теләсәләр дә, рәсүлуллаһ аларны алмады. Байракны Гали бине Әбү Талибка бирде. Мәдинәдә Ибн Үмм Мәктумне калдырды һәм гаскәр Мәккәгә таба юнәлде. Сәхабәләрнең бик

күбесе Өхед сугышында җәрәхәтләнеп, хәлсезләнгән булсалар да, «ләм-мим» димичә, рәсүлуллаһның әмеренә каршы килмәде.

Юлда мөшрик гаскәре дә болай гына кайтып китүләренә үкенделәр: «Бу кадәр җиңүдән соң, аларны кырып бетереп кайтырга кирәк иде, Мәдинәне барып басарга кирәк иде», – дип сөйли башладылар. Рәсүлуллаһ юлда Мәгъбәд әл-Хузәгыйне туры китереп, Әбү Сафүән вә иптәшләренә курку салырга кушты. Хузәга кабиләсе электән рәсүлуллаһ белән берлектә иделәр. Мәгъбәд Әбү Сафүәнны Раүхәдә очратып: «Юлда Мөхәммәдне күрдем, бик күп гаскәр белән артыгыздан килә, Өхедкә чыкмаган кешеләр дә үкенеп, бу сәфәргә чыкканнар, озакламый монда килеп җитәрләр», – диде. Әбү Сафүән Мәгъбәднең сүзен ишеткәч, уйга калды, аңа: «Без үзебез әле Мәдинәне басар өчен кире китмәкче идек», – диде. Мәгъбәд моңа каршы: «Андый фикерләреңне ташла, мин сиңа нәсыйхәт итәм, тиз Мәккәгә юнәл!» – диде. Шул сүзгә нигезләнеп, Әбү Сафүән Ислам гаскәренең күп булуына ышанып, Мәдинәгә бару фикереннән кире кайтты. Ислам гаскәре исә, «Хәмрау әл-Әсәд» дигән җирдә өч көн торганнан соң кире кайтып китте[1]. Хәмрау әл-Әсәддә рәсүлуллаһ әлеге шагыйрь Әбү Газзә әл-Җүмәхыйны тотып үтертте. Әбү Газзә мөшрик гаскәреннән йоклап калган иде. Әбү Газзә бу тотылуында да үзен азат итүен үтенсә дә, рәсүлуллаһ:

«لَا يُلْدَغُ الْمُؤْمِنُ فِي جُحْرٍ مَرَّتَيْنِ»[2]

– дип җавап кайтарды һәм башын чабарга әмер бирде.

1 Хәмрау әл-Әсәд Мәккә юлында, Мәдинәдән сигез миль ераклыктагы бер урындыр – авт.

2 «Мөэмин бәндә бер нәрсәдән ике мәртәбә алданмас» урынында йөртеләдер – авт.



www.darul-kutub.com

Ошбу елда рәсүлуллаһның оныгы Хәсән бине Гали дөньяга килде. Шул ук елда рәсүлуллаһның кызы Үмм Көлсем Госманга кияүгә чыкты. Шулай ук Гомәрнең кызы Хәфса һәм Зәйнәб бинте Хузәймә шул елда рәсүлуллаһка кияүгә чыктылар[1]. Хәфса моннан элек Хунәйс бине Хузәфә никахында булып, ире Бәдер сугышында алган җәрәхәттән вафат иде. Зәйнәб бинте Хузәймә исә, моннан элек Габдулла бине Җәхш никахында булып, ире Өхед сугышында шәһид булды.

## Дүртенче ел

### *Катан сәриясе*

Ибне Әсәд кабиләсеннән Талхә вә Сәлмә исемендәге ике кешенең Ислам әһеле белән сугышырга чакыру вә котыртулары рәсүлуллаһка ирешкән иде. Шуңа күрә рәсүлуллаһ, йөз иллегә кадәр кешедән гыйбарәт булган бер гаскәр төзеп, Әбү Сәлмә җитәкчелегендә аларга каршы сугышырга җибәрде. Шул гаскәр дүртенче ел мөхәррәм ае башында Ибне Әсәд җиренә сәфәр итеп, Катан[2] исемендәге бер тау янында дошманга һөҗүм итте. Дошманнар Ислам гаскәрен күрү белән төрле якка таралды. Ислам гаскәре бу сугышта ун көн йөреп, дөя вә куйдан гыйбарәт беркадәр ганимәт алып кайттылар.

1 “Әсәду әл-Габә”, 5 т., 425-426 б. – авт.

2 Мәдинәнең көньягында, Фәйд ягындагы Бәну Әсәд тауларыннан бер тау. – авт.



www.darul-kutub.com

## *Сафуән бине Халиднең үтерелүе*

Шул ук мөхәррәм ае башында Һүзәйл кабиләсеннән Сафуән бине Халиднең Ислам әһеле белән сугышыр өчен гаскәр җыйганын ишеткәч, рәсүлуллаһ Габдулла бине Әнисне чакырып, мәзкүр дошманны үтерергә җибәрде. Габдулла ерак җиргә барып, бер кешене хәйләсез үтерү мөмкин булмаганнан, рәсүлуллаһтан ялган сөйләргә рөхсәт алды. Габдулла Сафуән янына баргач, үзен Ибне Хузәга кабиләсеннән дип күрсәтте һәм: «Мөхәммәд белән сугышыр өчен гаскәр әзерләгәнеңне ишеттем, шуның өчен сиңа ярдәм белән килдем», – диде. Габдулланың бу сүзләренә Сафуәнның кәефләре күтәрелеп, үзенең рәсүлуллаһ белән сугышка гаскәр әзерләргә теләвен ачыктан-ачык сөйләде һәм Габдулланы кунак итәр өчен чатырына алып китте. Сафуән йоклап киткәч, форсаттан файдаланып, Габдулла аны үтерде һәм Мәдинәгә юнәлде. Аның артыннан куып килүче булмады. Габдулла әлеге сәфәрендә 18 көн йөрде.

## *Ражигъ вакыйгасы*

Ошбу елның сәфәр аенда рәсүлуллаһка Газәл вә әл-Карра кабиләсеннән берничә кеше килеп, үзләренә имам булырлык, дин вә шәригать өйрәтү өчен берничә сәхабәне җибәрүен үтенде. Ләкин аларның бу эшләре бер хәйлә генә булып, алар Исламны кабул итмәгәннәр иде. Аларны Габдулла бине Әнис тарафыннан үтерелгән Сафуән бине Халиднең кавеме Ибне Һүзәйл җибәргән иде. Рәсүлуллаһ алар белән Гасыйм бине Сәбит җитәкчелегендә 10 кеше җибәрде.

Ражигъ исемендә бер суга җиткәч, бу кешеләр

www.darul-kutub.com

мөселманнарга хыянәт итеп, Һүзәйл кабиләсенең бер тармагы булган Ибне Лихьян гарәпләренә килүләре турында хәбәр бирделәр. Тиз арада Лихьяннән ике йөзләп кеше боларның артларыннан төште. Моны аңлап, сәхабәләр бер тауга менеп качканнар иде. Дошман гаскәре болар артыннан куып җитеп, алардан бирелүне таләп итте һәм әсирлеккә төшкән хәлдә сәламәт калачаклары хакында сүз бирде. Мөшрикләрнең сүзләренә ышанып, Хубәйб бине Гади һәм Зәйд бине әд-Дәсиннә әсирлеккә төшсәләр дә, ышанулары бушка китте: мөшрикләр боларны богаулап, ахырда Мәккәгә илтеп, мөселманнарга үчләре булган мөшрикләргә саттылар. Мөшрикләр аларның икесен дә шәһид итте. Калган сәхабәләр, мөшрик кулына төшүдән гарьләнеп, алар белән сугышып шәһид булды. Хубәйб бине Гади үтерелер алдыннан мөшрикләрдән рөхсәт алып, ике рәкәгать намаз укыганы һәм берникадәр бәет сөйләгәне Бохарида риваять итела[1].

## *Биэрү Мәгунә вакыйгасы*

Ошбу ел сәфәр аенда рәсүлуллаһка Ибне Гамир рәисләреннән булган «Мүләгибу әл-Әсиннә» кушаматы белән мәшһүр булган Гамир бине Малик килгән иде. Рәсүлуллаһ аны Исламияткә дәгъвәт итте. Гамир никадәр кабул итмәсә дә, бөтенләй кире дә тормады: «Әй, Мөхәммәд, син дәгъвәт иткән нәрсә бик гүзәл, син минем белән бергә Нәҗд халкына берничә сәхабәңне күндер, дингә дәгъвәт итсеннәр, алар кабул итәрләр дип уйлыйм!» – диде. Рәсүлуллаһ аңа Нәҗд халкына ышанычы юклыгын белдерде. Гамир бине Мәлик күндереләчәк сәхабәләрне үз яклавына алачагын әйткәч,

www.darul-kutub.com

1 وَ لَسْتُ أُبَالِي حِينَ أُقْتَلُ مُسْلِمًا عَلَى أيِّ جَنْبٍ كَانَ فِي اللهِ مَصْرَعِي وَ ذَلِكَ فِي ذَاتِ الإِلَهِ وَ إنْ يَشَأْ يُبَارِكْ عَلَى أوْصَالِ شِلْوٍ ممَزَّعِ

рәсүлуллаһ моның белән Мүнзир бине Гамр кул астында 70 кешене җибәрергә булды. Мәзкүр затлар сәхабәләрнең иң дәрәҗәлеләреннән булып, Коръәнне күп укыганнары сәбәпле «Куррә» дип йөртелә иде. Болар «Биэрү Мәгунә»[1] дигән җиргә җиткәч, сәхабәләрнең араларыннан Хәрам бине Милхән аркылы Бәнү Гамир башлыкларыннан Гамир бине Туфәйлгә хат җибәрделәр. Ләкин Гамир хатка игътибар бирмәде. Киресенчә, хатны китерүче Хәрамга золым итеп, аны үтертте. Хәрамның иптәшләре белән сугышу өчен кавеме Бәну Гамирне котыртса да, Муләгиб әл-Әсиннә химаясендә булган кешеләр белән сугышырга ризалык бирмәделәр. Нәтиҗәдә, Гамир бине Туфәйл Бәнү Сүләйм кабиләсеннән ярдәм сорады. Алар моны кабул итеп, Гамир бине Туфәйл белән барып, сәхабәләрне чолгап алдылар вә бөтенесен шәһид иттеләр. Бары тик Кәгъб бине Зәйд белән Гамр бине Үмәйя генә исән калдылар. Башкалар никадәр баһадирлык белән сугышсалар да, саннары аз булганга җиңелделәр.

Биэрү Мәгунә вакыйгасында шәһид ителгән кешеләр арасында һиҗрәт вакытында рәсүлуллаһка юлдаш булган Гамир бине Фүһәйра да бар иде. Биэрү Мәгунә вакыйгасы белән Раҗигъ вакыйгасы хәбәре Мәдинәгә бер вакытта ирешеп, рәсүлуллаһны вә сәхабәләрне зур кайгы эчендә калдырды. Рәсүлуллаһның шушы сәхабәләргә хыянәт иткән мөшрикләргә бер ай буена намаздан соң дога кылуы риваять ителәдер[2].

Вакыйгада исән калган Гамр бине Үмәйя Мәдинәгә кайтканда, юлда ике мөшрикне туры китереп, Бәну Гамир кабиләсеннән дип уйлап, йоклаган вакытларында үтереп киткән иде. Ләкин бу мөшрикләрнең кулында Рәсүлуллаһтан

---

1 Мәдинәнең көньягында Бәнү Гамир белән Бәнү Сүләйм җирләре арасындагы бер урын – авт.

2 Бохари, 2 т., 26 б. – авт.

алынган килешү кәгазе бар иде. Гамр бине Үмәйя Мәдинәгә кайтып, рәсүлуллаһка вакыйганы сөйләгәч, хатасын аңлап күп кайгырды. Шул вакыйга Бәни Нәзыйр сугышына сәбәп булды.

## *Бәни Нәзыйр газвәсе*

Ошбу ел рабигыль-әүвәл аенда рәсүлуллаһ Мәдинә янында булган Бәни Нәзыйр яһүдләренә Гамр бине Үмәйя үтергән ике адәмнең йолымын түләү өчен бурыч алырга барган иде. Янында бөек сәхабәләрдән Әбү Бәкер, Гомәр, Гали вә башкалар бар иде. Рәсүлуллаһ яһүдләр белән күрешеп, хаҗәтен сөйләгәч, алар аның сүзен кабул иттеләр. Әмма бу ризалык тыштан гына булып, эчләрендә явыз ният иде: рәсүлуллаһ яһүдләрдән берсенең өе алдында утырган чакта: «Безгә моннан да уңай форсат табылмас, беребез өй башыннан Мөхәммәднең өстенә ошбу тегермән ташын ташласын, аңардан котылырбыз», – дип килештеләр. Моның өчен араларыннан Гамр бине Җәххаш исемле берсен билгеләп тә куйдылар. Ләкин аларның фикерләре бушка чыкты: рәсүлуллаһ, аларның хәрәкәтләреннән эшне сизеп алып, тиз генә урыныннан кузгалды һәм Мәдинәгә кайтып китте. Югарыда язылганча, рәсүлуллаһ Мәдинәгә һиҗрәт иткәч, яһүдләр белән солых төзегән иде. Бу солых буенча яһүдләр мөселманнар белән тыныч торырга, сугышмаска һәм бер тараф икенче тараф дошманнарына булышмаска тиеш иде. Яһүдләрнең рәсүлуллаһка мондый мөгамәләләре гаһедне аяк астына салып таптау булып, бу халыктан һичбер вакыт имин булу мөмкин булмаганлыктан, аларны җирләреннән сөрергә карар бирелде. Һәм Мөхәммәд бине Мәсләмәне җибәреп,

ун көн эчендә Мәдинә җиреннән чыгарга кушты. Башта яһүдләр Мәдинәне ташлап китәргә риза булсалар да, Мәдинә монафикъларының ярдәм итәргә вәгъдә биргәннәренә ышанып, рәсүлуллаһның әмеренә каршы килделәр: «Теләсәң ни эшлә, без үз җиребездән китәчәк түгел», – диделәр.

Шуның өчен рәсүлуллаһ гаскәр җыеп, боларга каршы китте. Мәдинәдә үзе урынына Ибн Үмм Мәктумне калдырды. Сугыш байрагын Гали бине Әбү Талибка бирде. Ислам гаскәрен күргәч, яһүдләр ныгытмаларына кереп бикләнде. Гаскәр боларны алты көн камап торды. Рәсүлуллаһ аларны куркыту өчен хөрмә агачларын кисәргә кушты. Яһүдләр дә Ислам гаскәренә каршы торырлык куәтләре булмаганлыктан, Габдулла бине Үбәй вә иптәшләре дә вәгъдәләрендә тормаганлыктан, солых сорарга мәҗбүр булдылар. Солых нәтиҗәсендә болар җир вә коралларын ташлап, дөягә күтәрергә мөмкин булган нәрсәләрне, хатыннарын вә балачагаларын алып, Мәдинәдән китәргә риза булдылар. Күбесе Шам тарафына киттеләр, кайберләре Хайбәрдә туктады. Соңгылары арасында Сәлләм бине Әбү әл-Хукайк, Кинәнә бине Әбү әр-Рабигъ кебек бөекләре дә бар иде. Ибне Нәзыйр яһүдләреннән Исламиятне кабул иткән ике генә кеше бар иде: Йәмин бине Гумәйр һәм Әбү Сәгъд бине Вәһб. Бәнү Нәзыйр яһүдләренең җирләре һәм алардан алынган ганимәт маллары гаскәргә бүленеп бирелмәде. Чөнки бу ганимәт – ат һәм дөяләр кулланып сугышып алынган ганимәт булмыйча, җиңел юл белән алынган ганимәттер. Мондый ганимәтләр гаскәргә таратылмыйча сугыш әзерлегенә, Рәсүлуллаһның үзенә, гаиләсенә, якыннарына, ятимнәргә, мескеннәргә, юл кешеләренә тотыла иде. Шунлыктан, рәсүлуллаһ бу малдан йорт вә җирләреннән, мал-туарларыннан аерылып

килгән фәкыйрь мөһаҗирләргә өлеш бирде. Әнсарилардан бик фәкыйрь булган ике кешегә генә бирде. Ибне Нәзыйр мухәрабәсе хакында Аллаһы Тәгалә «Хәшер» сүрәсен иңдерде[1]. Хәмернең хәрам ителүе дә ошбу газвәдә булды[2].

## *Соңгы Бәдер газвәсе*

Өхед сугышы бетеп, мөшрикләр Мәккәгә кайтырга әзерләнгәч, Әбү Сафүән рәсүлуллаһка: «Киләсе елга Бәдер янында сезнең белән тагын очрашып сугышабыз, әзер булыгыз!» – дигән иде. Рәсүлуллаһ та бер дә каушамыйча: «Бик яхшы, әзер булырбыз», – дип җавап биргән иде. Икенче елны Ислам әһеле белән сугышырга вакыт җитә башлагач, Әбү Сафүән бөтенләй югалып калды, чөнки бу ел Мәккәдә ачлык иде. Сугышка чыкмый калу бөтен гарәп кабиләләре арасында Корәешләрнең дәрәҗәләрен киметеп, Ислам әһеленең шөһрәтен арттыру булыр иде. Шунлыктан, Әбү Сафүән Ислам гаскәрен сугышка чыгармаска бер хәйлә корды: Әшҗәгъ кабиләсеннән Нәгыйм бине Мәсгуд исемендә берәүне яллап, Мәдинәгә җибәрде һәм аңа: «Әбү Сафүән бик күп гаскәр белән киләчәк. Сез аңа каршы тора алмаячаксыз! Үз йортларыгызга килеп, сезгә никадәр күп кайгы китергән дошманга каршы тора алмыйча, Бәдер кебек ерак бер җиргә барып ничек котылачаксыз?» – дип, сугыштан кире сөрәчәк куркыныч сүзләр сөйләргә кушты. Нәгыйм Мәдинәгә барып, Әбү Сафүән кушканча, Ислам әһелләре арасына фетнә салса да, моның сүзләренә колак салмадылар, Аллаһының ярдәменә таянып сугышка киттеләр. Бу мухәрабәгә чыккан Ислам гаскәре 1500дән гыйбарәт булып, шуларның 50се

1 Мөслими, 2 т., 550 б. – авт.

2 Ибн Һишам, 2 т., 74 б. – авт.

атлы гаскәр иде. Әбү Сафүән ике мең кадәр җәяүле вә 50гә кадәр атлы гаскәр белән чыгып, Миҗәннә ярминкәсенә җиткәч, гаскәренә бу елның сугыш өчен мәшәкатьле, ачлык ел икәнен сөйләп кире борылып кайтты. Мөшрик гаскәре Мәккәгә кайткач, Мәккә әһлесе: «Болар талкан ашар өчен чыктылар, болар талкан гаскәре.» – дип көлделәр[1].

Ислам гаскәре Бәдердә бөтен ярминкә буена, 8 көн сәүдә итеп, күп файда күрде. Җиңүләреннән башлары күккә тиеп, Мәдинәгә кайтып китте. Шушы газвәдә Хәсән бине Сәбит һәм Габдулла бине Рауахә тарафыннан Әбү Сафүәнның вәгъдәсендә тормавыннан көлеп, мәсхәрә итеп язылган шигырьләр күптер. Бу газвә шәгъбан аенда булды. Мәдинәдә рәсүлуллаһ урынына Габдулла бине Үбәйнең улы Габдулла калган иде[2].

## *Рәсүлуллаһның Үмм Сәләмәгә өйләнүе*

Ошбу ел сәхабәләрдән Әбү Сәләмә вафат булып, хатыны Үмм Сәләмә тол калды. Әбү Сәләмә рәсүлуллаһның сөт кардәше иде. Беренче һиҗрәттә Хәбәшәгә иң беренчеләрдән һиҗрәт иткән кеше. Рәсүлуллаһ аның яклаучысыз калган хатынын бәхетле итү өчен үзенә никахлады. Рәсүлуллаһ алган хатыннарның күбесе шундый ире үлеп химаясез калган яки нинди дә булса берәр бәлага төшүгә якын булган хатыннар иде.

Рәсүлуллаһның оныгы Хөсәйн бине Галинең тууы да, Габдулла бине Госман бине Гаффәннең вафаты да ошбу елда иде. Шулай ук Рәсүлуллаһның Зәйд бине Сабиткә яһүд язуы өйрәнергә әмер бирүе дә бу елда булды[3].

1 Шуңа күрә бу газвә “Сәвикъ газвәсе” дип тә йөртелә. – авт.

2 Ибн әл-Әсир бу газвәдә Мәдинәдә Габдулла бине Равахә калды, ди. 2 т., 66 б. – авт.

3 Ибн әл-Әсир, 2 т., 66 б. – авт.



www.darul-kutub.com

# Бишенче ел

## *Дүмәтү әл-Җәндәл газвәсе*

Бишенче ел рабигыль-әүвәл аенда рәсүлуллаһка Дүмәтү әл-Җәндәл[1] халкының юлдан үткән кешеләргә җәбер вә золым иткәннәре һәм Мәдинәгә килү өчен гаскәр әзерләүләре ишетелде. Шунлыктан рәсүлуллаһ алар белән сугышка әзерләнеп, меңгә якын гаскәр белән Дүмәтү әл-Җәндәлгә сәфәр итте. Дүмәтү әл-Җәндәлгә җитәр алдыннан, боларның көтүләренә һөҗүм итеп ганимәт алдылар. Бу хәбәр ишетелгәч, Дүматү әл-Җәндәл әһлесе куркып качып беттеләр. Аларның җирләрендә рәсүлуллаһ берничә көн калып, тирә-ягына гаскәр җибәреп, дошманны эзләтсә дә, һичкемне таба алмады. Соңра алган ганимәтләре белән Мәдинәгә кайтып киттеләр. Юлда рәсүлуллаһ Бәни Фәзәра кабиләсенең башлыгы Гуяйнә бине Хисн белән солых төзеде. Гуяйнәнең җире яраксыз бер хәлгә килгәнлегеннән, аңа Мәдинәдән утыз алты миль ераклыкта җир бүлеп бирде.

## *Бәни Мөстәгликъ газвәсе*

Рәсүлуллаһка Бәни Мөстәгликъ[2] кабиләсенең башлыгы Харис бине Әбү Зирарның Ислам әһеле белән сугышу өчен гаскәр әзерләгәнлеге ишетелде. Мәзкур хәбәрне тикшерү өчен рәсүлуллаһ боларга Бәрин бине Хусайб исемендәге бер затны җибәрде. Бу зат Бәни Мөстәгликъка барып, аларның сугышка әзерләнгәннәрен белеп кайтты. Моның нәтиҗәсендә рәсүлуллаһ Мәдинәдә Зәйд бине

1 Мәдинәнең төньягында урнашкан. Мәдинә белән ике ара 15 көнлек юлдыр – авт.

2 Хузәга кабиләсенең бер тармагы – авт.

Хәрисәне калдырып, күп гаскәр белән боларга каршы чыкты. Гаскәр эчендә бу вакытка кадәр һичбер газвәгә чыкмаган монафикълар да бар иде. Алар бары тик ганимәт малына кызыгып чыкканнар иде. Рәсүлуллаһ янында хатыннарыннан Гайшә белән Үмм Сәламә дә бар иде. Юлда Ислам гаскәре, Бәни Мөстәгликъ тарафыннан аларны күзәтү өчен җибәрелгән бер җәсусны [разведчик] тотып, дошман гаскәре хакында мәгълүмат сорадылар. Җәсус җавап бирмәгәч, аны үтерделәр. Бәни Мөстәгликъта рәсүлуллаһның чыгуы һәм юлда аларның җәсусларын үтерүе ишетелгәч, бик каты курыктылар, хәтта кайберләре аерылып та киттеләр.

Ислам гаскәре, «Мурайсигъ»[1] исемендә бер суга җиткәндә, мөшрикләр белән очраштылар. Рәсүлуллаһ гаскәрне сафка тезде. Мөһаҗирләрнең әләмен Әбү Бәкергә, әнсариларның байрагын Сәгъд бине Гүбәдәгә бирде. Мухәрабә башланып, беркадәр ук атышканнан соң, рәсүлуллаһ гаскәргә һөҗүм итәргә әмер бирде. Озак та үтмәде, мөшрикләр жиңелделәр. Унлап мөшрик үтерелде, башкаларын хатын вә балалары белән әсир алдылар. Бу мухәрабәдә алынган әсирләр ике йөз гаилә иде. Ганимәт исә ике мең дөя, биш мең куйдан гыйбарәт иде.

Әсирләр арасында Харисның кызы Бәрра да бар иде. Әсирләр өләшкәндә Бәрра Сәбит бине Кайсның өлешенә чыккан иде. Сәбит аны акча бәрабәренә азат итмәкче булды. Рәсүлуллаһ аңарга түләп, Бәрраны үзенә никахлады. Соңра исемен Җүвәйрия дип кушты. Рәсүлуллаһның Җүвәйриягә никахлануы бик файдалы эш иде. Чөнки Бәни Мөстәгликъ гарәп кабиләләренең иң бөекләреннән иде. Аларның хатын

1 Кудәйд ягындагы Хузәганың суыдыр. Мурайсигъ белән фәргъ арасы бер көнлек юлдыр – авт.

вә балаларын әсир итү боларга, әлбәттә, бик авыр киләчәк иде. Моның өстенә Җүвәйрия Бәни Мөстәгликъның рәисе булган Харисның кызы булганга, мондый бөек затның кызын кол итеп йөртү яки азат итеп башка гади бер кешегә бирү, әлбәттә, туры килми иде. Шунлыктан рәсүлуллаһ аны үзенә никахлап күңелен шатландырды. Рәсүлуллаһның мәзкүр мөгамәләсен күреп, сәхабәләр рәсүлуллаһның кайнишләрен кол итеп тоту туры килмәгәнлектән, әсирләренең бөтенесен азат иттеләр. Пәйгамбәребезнең яхшы сәясәте белән никадәр гаилә коллыктан котылып, хөррият нигъмәтенә иреште. Сәхабәләрнең мондый яхшы мөгамәләләрен күргәч, бөтен Бәни Мөстәгликъ кабиләсе Исламны кабул итте.

Бәни Мөстәгликъ газвәсендә килеп чыккан вакыйгалар:

1. Гомәр бине әл-Хаттабның хезмәтчесе белән Хазраҗ кабиләсеннән бер кеше арасында низаг булып, хезмәтче әнсарины җәрәхәтли. Моның нәтиҗәсендә, әнсари җаһилият гадәтенчә әнсарилардан, ә мөһаҗири моңа каршы мөһаҗирләрдән ярдәм сорыйлар. Һәр ике фирка, үз кешеләрен яклап низагълашып, хәтта сугышу дәрәҗәсенә җиттеләр. Шул чакта рәсүлуллаһ, хәбәрне ишетеп, болар янына килде һәм вәгазь вә нәсыйхәт сөйләп, аларны тату-лаштырды. Габдулла бине Үбәйгә бу вакыйга ишетелгәч, бик нык ачуланып: «Бүгенге кебек хурлык күргәнем юк иде, без аларны йортларыбызга төшердек, өйләребезгә керт-тек, ярдәм иттек, алар безне кыйный башладылар. Этеңне симертсәң, үзеңне тешли дигән мисал безгә туры килде инде. Валлаһи, Мәдинәгә кайтсак, аларны куып чыгарырбыз

(لَيُخْرِجَنَّ الأَعَزُّ مِنْهَا الأَذَلَّ).»

www.darul-kutub.com

– диде. Соңра янында булган иптәшләренә карап: «Менә бу уңайсызлыклар бары да үзегездән килде, аларны йортларыгызга кабул иттегез, малларыгызны алар белән уртаклаштыгыз, ул гына җитмәгән, Мөхәммәд өчен сугышып үтерелдегез, балаларыгызны ятим калдырдыгыз. Шул сәбәпле көннән-көн саныгыз азая бара, алар исә күбәяләр генә. Моннан соң сакланыгыз, аларга ярдәм итмәгез, үзләренә фәкыйрьлек вә зарарлык төшеп, Мөхәммәддән качып бетсеннәр!» – диде.

Мәҗлестә Зәйд бине Әркам исемле иманы куәтле яшь бер егет бар иде. Габдулланың бу сүзләрен ишеткәч, ул саклану йөзеннән, рәсүлуллаһка барып сөйләде. Моны ишеткәч, рәсүлуллаһ Зәйд бине Әркамга: «Әй, егет, бәлки синең аңа ачуың бардыр, шуның өчен аның өстенә мондый сүзләр сөйлисеңдер, ихтимал, хата ишеткәнсеңдер!» – дип әһәмият бирмәскә тырышса да, Зәйд бу сүзләрне Габдулладан ишеткәнен ант белән ныгытты. Рәсүлуллаһ йомшак табигатьле булып, җәза бирүдә бик ашыкмый иде. Габдулланың сүзе катгый сурәттә исбат ителсә дә, мәшәкатьле мәсьәләләр барлыкка килгәнгә, моны алга куймаска тырыша иде.

Гомәр бине әл-Хаттаб, моны ишеткәч, Габдулла бине Үбәйне үтерү тиешлеген әйтсә дә, рәсүлуллаһ моңа каршы килде: «Әй, Гомәр, әгәр халык Мөхәммәд үзенең иптәшләрен үтертә дисәләр, яхшы булырмы?! – диде. Соңрак, көн уртасы булуына карамыйча, кәрванга кузгалырга әмер бирде. Максаты – халыкка бу мәсьәлә турысында җыелышып сөйләшергә мөмкинлек бирмәү иде. Үсәйд бине Хузәйр килеп: «Әй, рәсүлуллаһ, мондый эссе вакытта кузгалуның сәбәбе нәрсә, беркадәр көн салкынайгач чыксак булмасмы?» – диде. Рәсүлуллаһ моңа: «Иптәшегезнең ни сөйләгәнен ишетмәдеңме?» – диде. Моңа каршы Үсәйд:

www.darul-kutub.com

«Я рәсүлуллаһ, ул – хур, син – газизсең, теләсәң, син аны Мәдинәдән чыгарырсың», – дип җавап бирде. Юлда бик каты йөргәнлектән, халык тукталышка килеп җитү белән барысы да йокыга бирелде, арган кешеләр үзара сөйләшергә дә теләмәде. Шул сәбәпле мәсьәлә зурайтылмады.

Габдулла бине Үбәй вә иптәшләре хакында «Монафикълар» сүрәсе иңеп, аларны бөтенләй хур вә рисвай итте, монафикълыкларын ачып бирде. Зәйд бине Әркамның сүзен тәсдыйк итте. Габдулла бине Үбәйнең улы Габдулла хәбәрне ишеткәч: «Рәсүлуллаһ атамны, әлбәттә, үтертер. Башка кеше тарафыннан үтерелеп, аның белән минем арамда дошманлык хасил булганчы, үзем үтерим», – дип, рөхсәт сорау өчен рәсүлуллаһка барса да, ул аның соравын кабул итмәде: «Безнең сохбәтебез дәвам иткән дәвердә аны үтермәбез», – диде. Һәм Габдуллага атасына күркәм мөгамәләт кылырга әмер бирде.

2. Ифкь вакыйгасы.

Бу газвәгә рәсүлуллаһ белән бергә хазрәти Гайшәнең дә чыгуы язылган иде. Ислам гаскәре газвәдән кайтканда Мәдинәгә якын бер тукталышка төшкәннәр иде. Гайшә кайбер хаҗәте өчен кәрваннан читкә китте. Хаҗәтен үтәп, кәрван янына килгәч, муенын сыйпап караса, муенсасын тапмады. Шуны эзләп, тагы әүвәлге урынына китте. Гайшә һәүдәҗен [паланкин] күтәрә торган кешеләр, һичбер уйламастан, һәүдәҗне дөянең өстенә куйдылар, Гайшәнең анда юклыгын сизмәделәр дә. Чөнки ул вакытларда хатыннар бик җиңел булалар иде. Аның өстенә Гайшә бик яшь бер килен иде. Шуңа күрә күтәрүче халык аны һәүдәҗендә дип уйлады. Гайшә муенсаны эзләп табып килгәндә, кәрван кузгалып киткән иде. Кәрван артыннан барып җитү мөмкин булмаган-

га, барыбер эзләп килерләр дип,  урынына төренеп ятты һәм шунда йоклап та китте.

Сәхабәләр арасыннан Сафүән бине Мугаттал исемендә берсе кәрваннан артта калган иде. Ул йоклаучанрак кеше булып, гел шулай артта кала иде. Сафүән кәрван туктаган җиргә килеп җиткәндә, Умму әл-муэминин – Гайшәне күреп таныды һәм аның монда калуына гаҗәпләнеп: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи рәҗигун», – дип кычкырып җибәрде. Бу тавышка Гайшә уянды. Соңра Сафүән, Гайшәгә һич сүз әйтмичә, дөясен якынлаштырды. Гайшә дә дөягә менеп, кәрванның артыннан киттеләр. Сафүән Гайшә утырган дөясен җитәкләп, гаскәр артыннан килеп җиткәндә, нәкъ төш вакыты булып, гаскәр ял итәргә туктаган иде. Гайшәнең кәрваннан калганына халыкның бу вакытка кадәр хәбәре юк иде. Сафүән дөясендә аның килеп төшүен күргән халык төрле уй вә фикергә төште. Монафикълар вә бәгъзе иманы зәгыйфь кемсәләр Сафүән белән Гайшә хакында яман уйга калдылар. Габдулла бине Үбәй, вакыйгадан файдаланып, Гайшәгә әллә нинди ялалар яга, теленә ни килсә, шуны сөйли иде.

Бөек сәхабәләр исә Гайшәнең мондый түбәнчелектән пакъ булуын, иң хөрмәтле, иң олугъ рәсүленә Аллаһы Тәгаләнең зиначы бер хатын туры китермәячәген катгый белгәнлекләреннән, Гайшә вә Сафүән хакында яхшыдан башка бер нәрсә сөйләмәделәр. Кәрван Мәдинәгә кайткач, халык мәсьәләне төрлечә куерта башлады. Рәсүлуллаһ исә бу хакта һич бернәрсә сөйләмәде. Мәдинәгә кайту белән Гайшә, хасталанып, 26 көнгә кадәр түшәктә ятарга мәҗбүр булды. Бу вакыт эчендә Гайшәнең үзе хакында сөйләгән сүздән һичнинди хәбәре юк иде. Шушы хасталануында аңа

рәсүлуллаһ әүвәлге авырган вакытларында шикелле игътибар вә мәрхәмәт күрсәтмәде, торган бүлмәсенә кереп: «Хәлегез ничек?» – дигәннән башка сүз әйтмәде. Шунлыктан Гайшә, бервакыт рәсүлуллаһ аның хәлен сорарга килгәндә, этисенең өендә хасталанып ятарга рөхсәт сорап, шунда күчте.

Бу вакыйгадан соң рәсүлуллаһ гаилә әгъзаларының бөекләре белән Гайшә хакында киңәш итте. Үсәмә бине Зәйд: «Без Гайшә һәм Сафүән турында яхшылыктан башка бер нәрсә дә белмибез, халык сүзенә карап, хатыныңнан аерылма!» – диде. Гали бине Әбү Талиб исә рәсүлуллаһны халык яласыннан бөтенләй коткару максаты белән: «Аннан башка да дөньяда хатыннар бетмәгән, хатыннарга кытлык юк», – дип, аеру ягын куәтләде һәм Гайшәнең хезмәтче хатыныннан[1] Гайшә хакында сорашырга кушты. Рәсүлуллаһ хезмәтче хатынны чакырып, Гайшә хакында белгән вә күргәннәрен сораша башлады. Моңа каршы хатын: «Әй, рәсүлуллаһ, мин аның хакында һичбер нәрсә белмим, аны гаепләрлек бернәрсә дә күргәнем юк. Шунысы гына бар ки, ул озак йоклаучан яшь бер хатын», – диде.

Гайшә вә Сафүән хакында аларны гаепләрлек бернәрсә дә табылмагач, рәсүлуллаһ халыкны җыеп, минбардан ошбу мәгънәдә сүзләр сөйләде: «Әй, җәмәгать! Минем хатыным хакында мине рәнҗеткән кешеләр бар. Мин үземнең хатыным һәм аның белән гаепләнүче ир хакында яхшылыктан башка бернәрсә дә белмим. Мине рәнҗеткән кешеләр хакында ни диячәксез? Бу хакта мине кем гозерле дип табар?» – диде. Моңа каршы Үсәйд бине Хузаир торып: «Әй, рәсүлуллаһ, мин сине аклыйм. Әгәр сине рәнжеткән

1 “Нуруль-якыйн” сахибе, Ибну әл-Әсиргә ияреп, бу хезмәтчене Бәрира диде. Ибну әл-Кайийм, моны Вәһм ди. Зәдүл-Мәгад, 1 т., 374 б. – авт.

кешеләр «Әус» кабиләсеннән булсалар, мин аларның муеннарын чабачакмын, әгәр «Хазраҗ» кардәшләребездән булсалар, ни кушсаң, шуны эшләрбез», – диде. Моңа каршы Сәгъд бине Губәдә торып: «Син боларның үз кавемеңнән булмаганлыкларын белеп, шундый сүзләр сөйлисең, әгәр үз кавемеңнән булсалар, үтертергә разый булмас идең», – диде. Моңа каршы Үсәйд бине Хузәйр: «Син монафикъсың, монафикъларны яклыйсың», – диде. Рәсүлуллаһ эшнең низагъка кереп киткәнен күргәч, минбардан төшеп тавышны бастырды. Шул сәбәпле бу эш тукталып калды.

Гайшә авыруыннан беркадәр савыккач, беркөн Гайшәне гаепләгән кешеләрдән Мистах бине Үсәсәнең анасы белән далага чыккан иде. Юлда Үмм Мистах үз итәгенә басып абынды да: «Мистах дөмексен!» – дип әйтеп җибәрде. Моны ишетеп, Гайшә: «Бу нинди сүз, Бәдер сугышында булган кешегә шундый сүз әйтергә ярыймы соң?!» – диде. Моңа каршы Үмм Мистах: «Син аларның ни сөйләгәннәрен белмисең әле, белсәң, бу сүзне әйтмәс идең», – диде. Соңра Гайшәгә вакыйганы сөйләп бирде. Гайшә бу вакытка кадәр бу турыда бер нәрсә дә ишеткәне юк иде. Үмм Мистахтан бу сүзләрне ишеткәч, өзлегеп тагын түшәккә ятарга мәҗбүр булды. Гайшә мәсьәләне күбрәк белү өчен анасыннан сорады. Моңа каршы анасы: «Кызым, борчылма, үзеңне хафалама! Иренә сөекле, кадерле хатынның көндәшләре күп була, аны чәйнәүчән булалар, андый хатынга кеше сүзе күп ишетелә», – диде. Гайшә анасыннан бу сүзләрне ишеткәч, тагын да хафаланып, төн буенча күзенә йокы кермичә елап чыкты.

Бу көн Гайшә атасы өендә түшәктә ятканда, Рәсүлуллаһ кереп аңа: «Әй Гайшә, синең хакыңда халык

төрле сүзләр сөйли, әгәр син бу эштән пакь булсаң, Аллаһы Тәгалә сине аклар, әгәр гөнаһлы булсаң, тәүбә ит. Кеше үз гөнаһысын аңлап тәүбә итсә, Аллаһы аның тәүбәсен кабул итәчәк», – диде. Моны ишетеп Гайшә бик каты елый башлады. Ата-анасына Рәсүлуллаһка җавап бирергә кушса да, алар: «Рәсүлуллаһка ни дияргә белмибез», – дип җавап бирделәр. Соңра Гайшә аларга: «Сез бу эшкә шулкадәр ышангансыз ки, әгәр мин бу эштән пакьмен дисәм, сүземә ышанмаячаксыз, әгәр пакь була торып өстемә гаеп йөкләсәм, ышаначаксыз. Мин үземә «Әбү Йосыфның» (Ягъкуб галәйһиссәламне күздә тотып):

«فَصَبْرٌ جَمِيلٌ وَاللَّهُ الْمُسْتَعَانُ عَلَى مَا تَصِفُونَ»[1]

– дигән сүзеннән башка күңел юатачак сүз тапмыйм», – дип, түшәгенә ятып тагын елый башлады. Рәсүлуллаһ ошбу мәҗлес вакытында ук Аллаһы Тәгалә «Нур» сүрәсенең ун аятен иңдереп, Гайшәне аклады[2]. Рәсүлуллаһ Гайшәне Аллаһы Тәгаләнең аны аклавы белән сөендергәндә, ата-анасы аңа торып Рәсүлуллаһка шөкер итергә кушсалар да, Гайшә: «Юк. Мине аклаган Аллаһы Тәгаләдән башка һичкемгә шөкер итәчәк түгелмен», – дип җавап бирде.

Хәзрәти Гайшәне гаепләгән кешеләр арасында мәшһүр шагыйрь Хәссән бине Сәбит, Әбү Бәкернең якыны Мистах бине Үсәсә һәм Зәйнәб бинте Җәхшнең бертуганы Хәмнә бинте Җәхш бар иде. Һәм бу кешеләргә җәза бирелде. Габдулла бине Үбәй мәсьәләне иң беренче башлап куертучылардан булса да, җәзасы мәслихәткә калдырылды.

1 «Миңа күркәм сабырлык кирәк, сезнең сыйфатлаган нәрсәләрегезгә каршы Аллаһыдан гына ярдәм сорау кирәк.» «Йосыф»/18. – тәрҗ.

2 “ән-Нур”/11-21. – авт.

## *Хандак яки Әхзәб сугышы*

Бәни Назыйр яһүдләре ватаннарыннан сөрелгәннән соң, Шам тарафларына вә кайберләре Хайбәргә китүләре югарыда язылган иде. Хайбәргә киткән яһүдләр һәрвакыт мөселманнардан үч алырга, җирләрен яңадан үзләренә кайтарырга форсат көтеп торалар иде. Икенче Бәдергә чыгуга сүз биреп тә, чыга алмаган корәешләрнең күңелләрендә дә форсат килгәндә мөселманнарга бик зур бер куәт белән чыгып, каты сугыш бирү нияте бар иде. Моны бик яхшы белгән Хүяй бине Әхтаб, Сәлләм бине Әбү әл-Хукайк, Кинәнә бине Әбү әр-Рабигъ, Сәлләм бине Мишкәм кебек яһүд башлыклары мөселманнардан үч алу вакыты килде дип, гарәп кабиләләрен кыздыра башладылар. Иң элек Корәеш кабиләсенә барып, башлыкларын күрделәр һәм аларга, әгәр Ислам әһеле белән сугышсалар, ярдәм итәчәкләренә вәгъдә бирделәр. Мөшрикләр боларның тәкъдимен шатланып кабул иттеләр. Соңра Гатафан (Фәзәра, Мурра, Әшҗәгъ) кабиләсенә барып, рәисләре Гуяйнә бине Хисну әл-Фәзәри, Харис бине Гауф әл-Мурра, Мисгар бине Рухайлә әл-Әшҗәгый белән сөйләшеп, аларны мөселманнарга каршы сугышырга кызыктырдылар. Аларга Корәеш мөшрикләренең дә сугышка әзерләнгәннәрен сөйләделәр. Болар да аларның сүзләреннән баш тартмадылар. Моннан соң башка гарәп кабиләләрен күреп, алардан да беркадәр тарафдарлар җыйдылар.

## *Мөшрикләрнең сугышка чыгулары*

Шулай итеп, корәешләр һәм аларга ияргән бәгъзе Тиһамә һәм Кинәнә гарәпләре, дүрт меңгә кадәр тупланып,

Мәдинәгә юнәлде. Болардан өч йөзе атлы гаскәр иде. Алмашынып атланып барырга һәм азык-төлек төяргә мең дә биш дөяләре бар иде. Корәешнең әләме Госман бине Әбү Талхә кулында иде. Гатафан кабиләсе Гуяйнә бине Хисн командасында, Ибне Сүләйм кабиләсе Сафүән бине Габду Шәмс командасында, Ибне Әсәд Туләйхә бине Хувәйлид командасында Мәдинәгә чыктылар. Бөтен гаскәр ун меңләп булып, баш җитәкче Әбү Сафүән булды.

## *Хандак казу*

Рәсүлуллаһ белән берлектә булган Бәни Хузәга гарәпләре, мөшрикләрнең куәтле гаскәр белән Мәдинәне барырга чыкканлыкларын рәсүлуллаһка ирештерделәр. Мәдинәдә тору яки аларга каршы чыгу турында рәсүлуллаһ сәхабәләре белән киңәшләште. Сәлман әл-Фәриси Мәдинә тарафына чокыр казып, Мәдинәдә торырга киңәш бирде.

Рәсүлуллаһ вә сәхабәләр, бу фикерне гаять уңай күреп, хандак [чокыр, канау] казырга керештеләр. Рәсүлуллаһ та халыкка үрнәк булып, хандак казу эшендә катнашты. Һәр ун кешегә кырык аршин җир бүленеп бирелеп, шуны бергәләшеп казыдылар. Хандак казыганда рәсүлуллаһ һәм сәхабәләр Габдулла бине Равәханың түбәндәге шигырьләрен тәкърар итәләр иде[1]:

اللهمَّ لَوْ لَا أَنْتَ مَا اهْتَدَيْنَا   وَ لَا تَصَدَّقْنَا وَ لَا صَلَّيْنَا[2]
فَأَنْزِلَنْ سَكِينَةً عَلَيْنَا   وَ ثَبِّتِ الْأَقْدَامَ إِنْ لَاقَيْنَا[3]

1 “әл-Бохари”, 3 т, 26 б. – авт.

2 “Ий, Раббым! Әгәр Синең ярдәмең булмаса, без туры юлга күнмәс идек, намаз кылмас идек вә сәдакалар да бирмәс идек” – авт.

3 “Безгә тынычлык бир, мөшрикләргә каршы килгәндә, безне аларга каршы нык кыл” – авт.



www.darul-kutub.com

وَ الْمُشْرِكُونَ قَدْ بغَوْا عَلَيْنَا    وَ إِنْ أَرَادُوا فِتْنَةً أُبَيْنَا[1]
اَللَّهُمَّ لَا عَيْشَ إِلَّا عِيشُ الأخِرَهْ    فَاغْفِرْ الْأَنْصَارَ وَ المهَاجِرَهْ[2]

Сәхабәләр моңа каршы:

نَحْنُ الَّذِينَ بَايَعُوا مُحَمَّدًا    عَلَى الْجِهَادِ مَا بَقَيْنَا أَبَدًا[3]

Хандак Мәдинәнең төньяк тарафларына «Хәрра шәркыя»дән алып «Хәрра гарбия»гә кадәр казылды. Мәдинәнең башка яклары куе хөрмә агачлары вә кальга вазыйфасын үти алырлык өйләр белән уратылганлыктан, дошман куркыныч түгел иде. Мөселманнарга ел начар килеп, күбесенең ашарга азыклары булмаганлыктан һәм хандак казу өчен җитәрлек дәрәҗәдә кораллары булмаганлыктан, алар хандак казуда бик күп мәшәкатьләр чиктеләр.

Хандак казылып беткәч, рәсүлуллаһ хатын вә балачагаларны Мәдинәдәге нык диварлы өйләргә урнаштырды. Соңра үз урынына Ибн Үмм Мәктумне калдырып, өч мең сәхабә белән мөшрикләргә каршы чыкты.

Мөһаҗирләрнең байрагы Зәйд бине Хәрисәдә, әнсариларның байрагы Сагъд бине Губәдәдә иде. Гаскәр, Мәдинәнең төньяк тарафындагы «Сәлгъ» тавына арты белән, хандакка каршы урнашты.

Корәеш вә иярченнәре исә Мәдинәнең төньяк-көнбатыш тарафында «Җуруф» белән «Зәгабә» арасына, Гатафан һәм аларга ияргән Нәжд халкы «Өхед» тарафына җыелганнар иде.

1 “Мөшрикләр безгә золым кылдылар. Әгәр безне фетнәләмәкче булсалар, без каршы торачакбыз” – авт.

2 “Ий, Раббым! Чын тормыш – ахирәт тормышыдыр! Ахирәт тормышы өчен тырышкан әнсариларга һәм мөһаҗирләргә мәгъфирәт кыл!” – авт.

3 «Без, үлгәнче җиһад кылырга Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәламгә бәягать иткән кешеләр» – авт.

## *Хандак Мәдинәне һөҗүмнән саклый*

Мәдинәне җир белән тигезләү вә «Ислам» исемен җир йөзендә калдырмау максаты белән килгән гарәп мөшрикләре Мәдинә тарафларында хандак казылганын күреп, аптырап калдылар. Чөнки бу вакытка кадәр сугышларда хандак казу гарәпләрдә бөтенләй билгеле түгел иде. Мөселманнарга хандак казуны гарәп булмаган, хәрби эш гыйлемен белгән Сәлман әл-Фәриси өйрәтте. Хандак мөшрикләрнең һөҗүмнәреннән Мәдинәне саклады. Мәдинә шәһәре мөшрикләр тарафыннан бер айга кадәр камалып алынса да, кара-каршы килеп, кылыч белән сугышу булмады. Бары тик хандак аркылы ук атышу гына була иде. Шулай бер вакыт атышу шулкадәр куәтле вә шулкадәр озак дәвам итте ки, мөселманнарны хандак тирәсеннән китмәскә мәҗбүр итә иде.

Бер көн Ислам гаскәре өйлә, икенде, ахшам намазларын вакытында укый алмыйча, бөтенесен төнлә каза кылырга мәҗбүр булдылар[1]. Икенче бер көн икенде намазын ахшам белән бергә укыганнары ике сахих китапларында риваять ителәдер[2].

Рәсүлуллаһ төннәрен мөшрикләрнең хандак аркылы ат сикертеп керүләреннән куркып, гаскәргә каравыл куя иде. Рәсүлуллаһ сәхабәләрне һәрвакыт гайрәтләндереп тора, Аллаһының аларга ярдәм итәчәген вәгъдә итә иде. Аллаһының вәгъдәсенә ышанып, сәхабәләр ашарга җитәрлек азыклары булмавына карамастан, баһадирлык белән Мәдинә шәһәрен яклауны дәвам итәләр иде.

---

1 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 368 б. – авт.

2 “әл-Бохари”, 4 т., 44 б. – авт.

## *Мөшрикләр ат сикертеп хандактан үтәләр*

Озак вакытлар камап атышу белән генә бер нәтиҗә дә булмагач, мөшрикләрнең баһадирлары, хандакның тарырак җиреннән ат сикертеп, Ислам гаскәренә һөҗүм итү ниятенә килде. Шуңа күрә мәшһүр атта йөрүчеләр һәм баһадирлардан Габдүвәдд, Гикъримә бине Әбү Җәһил, Һүбәйра бине Әбү Вәһб, Зирар бине әл-Хаттаб һәм башкалар хандактан ат сикертеп, кечерәк Ислам гаскәренә якынлаштылар. Гамр бине Габдүвәдд горур бер сурәттә үзенә мубәразә таләп итте. Моңа каршы сәхабәләрнең арысланнарыннан булган Гали бине Әбү Талиб чыгып, аны тиз арада үтерде. Моны күргәч, башка мөшрикләр борылып качтылар. Нәүфәл бине Габдулла исемле берсе, хандакка егылып, муенын сындырды.

## *Курайза яһүдләренең хыянәте*

Чолганыш вакытында Ислам гаскәре бик каты кыенлыклар чикте. Чөнки мөшрикләр мөселманнар белән чагыштырганда гаять дәрәҗәдә күбрәк булып, камил коралланган иделәр. Югарыда язылганча, Мәдинәдә ачлык иде, мөселманнарның ашарга азыклары да юк иде. Моның өстенә Мәдинә яһүдләреннән Бәни Курайза форсаттан кулланып, мөселманнар белән араларында булган гәһедне бозды. Моңа сәбәп Мәдинәдән сөрелгән Бәни Нәзыйр яһүдләренең башлыгы Хүяй бине Әхтаб булды. Ул Бәни Курайза яһүдләренең рәисе булган Кәгъб бине Әсәдкә барып, мөселманнар белән арада булган гәһедне бозарга форсат җиткәнлеген сөйләп, аны үз ягына аударды.

Кәгъб аның таләбен элек кабул итмәсә дә, соңра ка-

бул итәргә мәҗбүр булды. Ләкин соңыннан андый-мондый уңайсызлыклар чыкса, икебез дә күрик дип, Хүяй бине Әхтабны үзенең кальгасына керергә өндәде. Хүяй, моны кабул итеп, крепостька керде.

## *Мәдинәне саклау өчен гаскәр җибәрү*

Ошбу хәбәр рәсүлуллаһка ирешкәч, ул нык тәэсирләнде. Хәбәрнең дөреслеген раслау өчен рәсүлуллаһ Сәгъд бине Мугәз, Сәгъд бине Губәдә, Габдулла бине Равәхә һәм Хавәт бине Җубәйрне җибәрде[1]. Алар кайтып, Рәсүлуллаһка хәбәрнең дөрес икәнлеген сөйләделәр. Бу хәбәр Ислам гаскәре арасында таралгач, алар бик каты куркуга төште. Монафикълар үзләренең икейөзлелекләрен ачып: «Аллаһы вә Аның рәсүле безгә ялган вәгъдә бирде. Безнең өйләребез ачык, дошманның хатыннарыбызга вә балаларыбызга һөҗүм итү куркынычы бар», – дип, Мәдинәгә кайтмакчы булды. Мәдинәне Курайза яһүдләреннән саклау өчен рәсүлуллаһ Мусләмә бине Әбү Әсләм командасында ике йөз, Зәйд бине Хәрис җитәкчелегендә өч йөз гаскәри җибәрергә мәҗбүр булды.

## *Рәсүлуллаһ Гатафан белән килешмәкче була*

Рәсүлуллаһ төрле тарафтан мондый авырлыклар астында калгач, Гатафан кабиләсен кайтарып җибәреп, мөшрикләрнең куәтен киметү нияте белән рәисләре Гуяйнә бине Хисн вә Хәрис бине Гауфкә Мәдинә җимешенең өчтән бер өлешен биреп, алар белән тынычлык солыхы төзү фикеренә килде. Бу фикерне әнсариларның рәисләре Сәгъд

1 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 375 б. – авт.

бине Мугәз белән Сәгъд бине Губәдәгә сөйләде. Моңа каршы алар: «Я, рәсүлуллаһ! Бу үз фикереңме, яки Аллаһы тарафыннан әмер килдеме?» – диделәр. Рәсүлуллаһ моның үз фикере икәнлеген белдергәч, Сәгъд бине Мугәз торып: «Без потларга табынган вакытыбызда, алар безнең җимешләребезгә кызыкмыйлар, ялгыз сатып алып яки кунакта булганда гына ашыйлар иде. Инде Ислам белән шәрафәтле булгач, без аларга җимешләребезне бирәчәкбезме? Бу – булачак эш түгел! Без аларга кылычтан башка нәрсә бирмәячәкбез», – диде. Моны ишеткәч, рәсүлуллаһ үз фикереннән кайтты.

Бу вакытта Корәеш, Гатафан һәм яһүдләр каршында ышанычлы вә дәрәҗәле булган Нәгыйм бине Мәсгуд Әшҗәгый рәсүлуллаһка килеп, Исламны кабул итте вә ярдәм йөзеннән берәр хезмәт күрсәтәчәген сөйләде. Рәсүлуллаһ моңа бик шатланып рөхсәт бирде. Нәтиҗәдә, Нәгыйм бине Мәсгуд иң элек Бәни Курайза яһүдләренә барып: «Кардәшләрегез Бәни Нәзыйр вә Кайнукагъ яһүдләре Мөхәммәд белән булган гәһедләрен бозып, йортларыннан, мал вә милекләреннән мәхрүм булдылар. Сез бу хәлдә дәвам итсәгез, мондый бәла сезнең башыгызга да килер. Сез үзегезне гарәпләр белән тиңләштермәгез, алар җиңелсәләр, ватаннарына кайтырлар да китәрләр. Ә сезгә аның белән тату торудан башка чарагыз юк. Сез аның белән сугышырга кадир түгелсез. Сез Корәеш вә Гатафаннан, сезне ташлап китмәүләренә, хөрмәтлеләреннән булган җитмеш кешене раһен [заложник] итеп алыгыз. Юкса, сугышта катнашмагыз!» – диде. Шуннан соң мөшрикләргә барып: «Курайза яһүдләре, сезнең ташлап китүегездән куркып, Мөхәммәд белән араларында булган гәһедләрен бозуга үкенделәр, Мөхәммәдкә кеше җибәреп, сезнең берничә хөрмәтле кешеләрегезне аңа тотып бирергә

вәгъдә иттеләр. Алар сездән берничә могтәбәр булганнарыгызны бирүегезне таләп итәчәкләр, сакланыгыз!» – диде.

## *Мөшрик гаскәрендә курку*

Әбү Сафүән Курайза яһүдләренә илче җибәреп, бергә сугышка чыгуларын таләп иткәч, алар: «Безне ташлап китмәвегезгә раһен алмыйча, Мөхәммәдкә каршы чыкмыйбыз», – дип җавап бирделәр. Моны ишеткәч, мөшрикләр бөтенләй шашып калдылар, күңелләренә курку төште. Нәгыймнең сүзе хак булганлыгына ышандылар. Шул арада гаять караңгы бер кичтә каты җил исеп, мөшрикләрнең чатырларын җимерде, казаннарын аударып бетерде. Мөшрикләрнең күңелләренә тагын да курку төште. Алар яһүдләр Ислам гаскәре белән берләшеп, караңгылыктан файдаланып һөҗүм итәрләр дип, шул төнне үк бик нык ашыга-ашыга өйләренә кайтып китте. Арткы якларын Ислам гаскәреннән саклау өчен Халид бине әл-Вәлид кул астында беркадәр гаскәр дә куйдылар.

## *Мөшрикләрнең җиңелүләре*

Шулай итеп, ун меңгә кадәр мөкәммәл коралланган гаскәр белән килеп, Мәдинәне җир белән тигезләү ниятендә булган мөшрикләр сәхабәләрнең ныклыгы вә чыдамлыгы, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән мәсхәрәләнгән бер сурәттә кайтып киттеләр.

Бу сугыш мөшрикләрнең гарәпләр каршында абруен киметте, халык арасында күздән төшүләренә сәбәп булды. Мөселманнарның исә рухлары күтәрелде, дәрәҗәләре артты. Моннан соң Ислам куәт алып китте. Ширек зәгыйфьлеккә

йөз тотты. Бу сугыш турында Аллаһы Тәгалә «Әхзәб» сүрәсен иңдереп, мөшрикләрнең җиңелүләрен Үзе тарафыннан мөселманнарга ярдәм вә нигъмәт сәбәпле икәнлеген бәян итте.

Хандак сугышында Әус кабиләсе башлыкларыннан булган Сәгъд бине Мугәзгә ук тиеп, каты җәрәхәтләнгән иде һәм Бәни Курайза сугышы тәмамлангач, шул җәрәхәтеннән шәһид булды. Сәгъд бине Мугәз – Исламияткә иң бөек хезмәт иткән кешеләрдәндер. Әнсарилар арасында Сәгъднең дәрәҗәсе – мөһаҗирләр арасында Әбү Бәкернең дәрәҗәсе кебек иде. Рәсүлуллаһ аның вафатына бик каты кайгырды.

## *Бәни Курайза сугышы*

Хандак сугышы беткәч, рәсүлуллаһның иң беренче эше – Ислам әһеленең иң авыр вакытларында арадагы гаһедне бозып, дошманлыкны ачык кылган Бәни Курайза яһүдләренә сабак бирү иде. Хандактан Мәдинәгә кайтып керү белән рәсүлуллаһ сәхабәләргә: «Бу көн Бәни Курайзага каршы сугышка чыгачакбыз.  Курайзага бармыйча, һичкем икенде укымасын!» – диде. Сәхабәләр дә озак вакытлар сугышта булуларына карамастан: «Сәмигънә вә этагънә»[1], – дип сугышка әзерләнделәр. Байрак Гали бине Әбү Талиб кулында иде. Рәсүлуллаһ урынына Мәдинәдә Ибне Үмм Мәктум калды.

Юлда икенде вакыты җиткәч, сәхабәләрнең бәгъзеләре: «Рәсүлуллаһның сүзе хакыйкатькә муафыйкъ түгел, ул бу сүздән тиз баруны гына ниятләде», – дип икендене юлда, вакытында укыдылар. Бәгъзеләре, сүзнең туры

1 “Ишеттек һәм буйсындык” – тәрҗ.

мәгънәсен алып, Бәни Курайзага барып җиткәч, ястүдән соң укыды. Рәсүлуллаһ боларның һичкайсына шелтә кылмады.

Бәни Курайза яһүдләре Ислам гаскәрен күрү белән куркып калды. Арадагы гәһедне бозуларына үкенделәр. Рәсүлуллаһка: «Без гәһедемезне бозмадык», – дип котылмакчы булсалар да, бу мәсьәлә алдан катгый сурәттә исбат ителгәнлектән һәм кылган эшләренә үкенүләре чын күңелдән булмыйча, форсатында алар тагын гәһедләрен бозачакларыннан, рәсүлуллаһ аларның сүзләренә игътибар бирмәде. Моны күреп, яһүдләр каршы торырга карар биреп, кальгаларына кереп бикләнде. Ислам гаскәре боларны егерме биш көн камап торды.

Камап тору озак вакыт дәвам иткәнгә, ачлык вә сусызлыктан һәлак булып бетәчәкләреннән куркып, болар рәсүлуллаһтан Бәни Назыйр яһүдләре белән кылынган тынычлык солыхы шартлары бәрабәренә солых төзиячәкләрен сөйләделәр. Ләкин боларның кабахәтлекләре Бәни Назыйр яһүдләренә караганда бик күп мәртәбә зуррак булганлыктан, рәсүлуллаһ аларның тәкъдимен кабул итмәде: «Безнең хөкемебезгә разый булсагыз, камауны туктатачакбыз, юкса дәвам итәчәкбез», – дип җавап бирде. Моны ишеткәч, рәсүлуллаһтан Бәни Курайза белән килешү өчен Әбү Лүбәбәне җибәрүен үтенделәр. Әбү Лүбәбә Әус кабиләсеннән булып, Бәни Курайзаның ышанычлы кешесе иде. Алар арасында аның бала-чагалары да бар иде. Шуның өчен Курайза яһүдләре аңа ышана иделәр. Әбү Лүбәбә Бәни Курайза яһүдләренә баргач, хатын вә бала-чагаларының елаганнарын күреп, күңеле нечкәреп: «Рәсүлуллаһның хөкеменә төшсәгез, сезне кылычтан кичерәчәк», – дип аңлатты. Әмма шул вакытта ук үзенең хата эш эшләгәнен аңлап, бик каты үкенде. Рәсүлуллаһка

күренүдән оялып, Мәдинәгә кайтып китте. Үзен мәчетнең бер баганасына бәйләп, Аллаһы аның тәүбәсен кабул итмичә торып, шуннан китмәскә үзенә сүз бирде.

Бәни Курайза яһүдләре Ислам гаскәренә каршы торып һич бернинди нәтиҗәгә ирешә алмаганга, рәсүлуллаһка бирелергә мәҗбүр булдылар. Боларның берлектәше булган Әус кабиләсе рәсүлуллаһка килеп, Хазраҗлар белән берлектәге Бәни Кайнукагъ яһүдләренә йомшаклык күрсәткән кебек мөгамәлә итүен үтенделәр. Шунлыктан, рәсүлуллаһ боларга хөкем өчен үз араларыннан берсен сайларга кушты. Нәтиҗәдә, алар үзләренең сәидләре булган Сәгъд бине Мугәзне хаким итеп куйдылар. Ул вакыт Сәгъд бине Мугәз Хандак сугышында җәрәхәтләнгәннән соң авыру иде. Аны ишәккә атландырып Ислам гаскәре янына китергәч, Әус халкы моның янына җыелып, яһүдләрне каты хөкем итмәвен үтенделәр.

Сәгъд боларга: «Сәгъдкә Аллаһының хөкемен үтәүдә вә халыкның сүзеннән һәм шелтәсеннән курыкмаска вакыт җитте», – дип, үзенең гадел хөкем кылачагын һәм беркемнең дә күңеленә яраклашмаячагын анлатты. Сәгъд бине Мугәз хөкем кылыр алдыннан сәхабәләргә карап: «Минем хөкемем башкарылачагына сүз бирәсезме?» – диде. Моңа каршы сәхабәләр сүз бирәчәкләрен аңлаттылар. Соңра рәсүлуллаһ тарафына карап: «Монда булган һәр зат та хөкемемне үтәячәкме?» – диде. Рәсүлуллаһ да: «Әйе, үтәячәк», – дип җавап бирде. Шуннан соң Сәгъд бине Мугәз Курайза яһүдләренең ирләре үтерелүе, хатын вә балаларының әсир алынуы белән хөкем итте.

Шулай итеп, алты-җиде йөздән гыйбарәт булган Бәни Курайза ирләре кылычтан үткәрелде. Хатын вә балалар,

www.darul-kutub.com

ганимәт итеп алынган маллар җәяүлегә бер өлеш, атлыга өч өлеш итеп бүленеп бирелде. Ганимәт 1500 кылыч, 300 тимер кием, 2000 сөнге, 500 калкан, йорт әсбаблары һәм беркадәр дөя вә куйлардан гыйбарәт иде. Сугышта катнашкан хатын-нарга да аз-маз ганимәт бирелде[1]. Алар арасында рәсүлуллаһ этисенең бертуган кыз кардәше Сафийә, мәшһүр Үмм Гимара, Үмм Сүләйт, Үмм әл-Галә, Сүмәйр бинте Кайс, Үмм Сәгъд бинте Мугәз, Кәбшә бинте Рафигъ бар иде.

Ислам гаскәре Мәдинәгә кайткач, Аллаһы Тәгалә югарыда зекер ителгән Әбү Лүбәбәнең тәүбәсен кабул итте. Сәгъд бине Мугәз озак та тормый, шул җәрәхәтеннән вафат булды. Рәсүлуллаһ аны һәрвакыт күз алдында булуы өчен, мәчеттә чатыр кордырып, шунда яткырды. Рәсүлуллаһ вә сәхабәләр аның вафатына бик каты кайгырды. Исламияткә бөек хезмәтләр кылганы өчен пәйгамбәребез аны бик каты сөя иде. Аллаһы Тәгаләнең аны җәннәт белән шатландыруы риваять ителәдер. Хандак вә Курайза сугышларында сәхабәләрдән тугыз кеше шәһид булды[2].

## *Зәйд вә Зәйнәб вакыйгасы*

Шушы елда рәсүлуллаһ Зәйнәб бинте Җәһшкә өйләнде. Зәйнәб рәсүлуллаһның этисе белән бертуган кыз кардәше Үмәймә бинте Габделмоталлиб кызы булып, рәсүлуллаһтан элек аның уллыкка алынып, азат ителәчәк Зәйд бине Харисның никахында иде. Зәйнәбне Зәйдкә рәсүлуллаһ үзе алып биргән иде. Зәйд асылда бер кара кол булып, Зәйнәб Корәешнең Ибне Һашим нәселеннән бөек бер

1 Сугышта катнашкан хатын-кызлар ир-атлар кебек өлешкә кертелмиләр. Бәлки аларга чамалап кына өлеш чыгарганнар – авт.

2 “Зәдүл-Мәгад”. – авт.



www.darul-kutub.com

шәрифнең чибәр кызы булганлыктан, аларның араларында аслән тигезлек юк иде. Рәсүлуллаһ Зәйнәбне Зәйдкә сораган очракта, Зәйнәб моңа катгый рәвештә разый булмаячагы кебек, аның абыйсы вә вәлисе Габдулла бине Җәһш тә моны үзенә бөек кимчелек вә нәселенә зур гарьлек дип санаячак иде. Моны рәсүлуллаһ бик яхшы белә иде. Ләкин аңа Зәйнәбне Зәйдкә никахландырырга Аллаһы Тәгалә тарафыннан әмер ителгән иде. Аллаһының Зәйнәбне Зәйдкә никахландырырга рәсүленә кушуы зур бер файдага нигезләнгән иде, ягъни гарәпләрдә киң таралган начар бер гадәтне юкка чыгаруны күрсәтү иде. Гарәпләрдә балаларны уллыкка алу гадәте бар иде. Бу очракта бөтен хокук та, хәтта нәсебкә кертелү дә хакыйкый угыл кебек игътибарга алына иде. Фәкать бу начар гадәтне иҗтимагый тормыштан алып ташлау зарур булды.

Рәсүлуллаһ пәйгамбәр булганчы, гарәпләрнең гадәтенчә, Зәйд бине Харисәне азат итеп, үзенә угыл кылган иде. Шул вакыттан Зәйд гарәпләр каршында Зәйд бине Мөхәммәд дип йөртелә башлады.

Гарәпләрдә кабул ителеп һәм аларның күңелләренә сеңеп беткән бу гадәтне батыл дип аңлату җиңел бер эш булмыйча, моңа гадәттән тыш зур гайрәт, чыдамлык кирәк иде. Моны шәригать сахибенең гамәлдә юкка чыгаруы тагы да туры килгән бер күренеш иде. Уллыкка алган кешесенең аерылган хатынына никахлану шулкадәр авыр иде ки, әгәр аңа Аллаһы тарафыннан әмер бирелмәгән булса, бу эшкә ул катгый барачак түгел иде.

Аллаһы әмере белән рәсүлуллаһ тарафыннан Зәйдкә Зәйнәбне сораган вакытта, башта Зәйнәб һәм аның вәлисе Габдулла бине Җәһш тә разый булмадылар. Соңра

www.darul-kutub.com

«وَمَا كَانَ لِمُؤْمِنٍ وَلَا مُؤْمِنَةٍ إِذَا قَضَى اللَّهُ وَرَسُولُهُ أَمْرًا أَن يَكُونَ
لَهُمُ الْخِيَرَةُ مِنْ أَمْرِهِمْ وَمَن يَعْصِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ ضَلَّ ضَلَالًا
مُّبِينًا»[1]

дигән Әхзәб сүрәсенең утыз алтынчы аяте иңдерелгәч, авыр булса да кабул иттеләр.

Табигый ки, Зәйнәб белән Зәйд арасында яхшы тормыш булмады. Зәйнәб үзенең нәсел-нәсәбе, шәраф һәм мәртәбәлеге белән горурланып, Зәйдне кимсетә, аны каты сүзләр белән рәнҗетә башлады. Зәйд моңа башта сабыр итсә дә, соңра кодрәте калмаганнан, рәсүлуллаһка бу хакта шикаять итте. Зәйнәб белән тора алмаячагын, аны талак итәчәген сөйләде. Рәсүлуллаһ Зәйднең кайчан да булса бер Зәйнәбне талак итәчәген белә иде. Зәйддән соң Зәйнәб белән никахлашырга аңа Аллаһы тарафыннан әмер ителгән иде. Ләкин ул оялчан булганлыктан, халык арасында төрле сүзләр чыгудан куркып, Аллаһының хөкемен үтәргә бик ашыкмый, һаман да кичектерә, бер форсат чыгуын көтә иде. Зәйд рәсүлуллаһка Зәйнәб турында шикаять иткән саен, хатынына яхшы мөгамәлә күрсәтергә, талак кылмаска куша иде.

(وَإِذْ تَقُولُ لِلَّذِي أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِ وَأَنْعَمْتَ عَلَيْهِ أَمْسِكْ عَلَيْكَ
زَوْجَكَ وَاتَّقِ اللَّهَ وَتُخْفِي فِي نَفْسِكَ مَا اللَّهُ مُبْدِيهِ وَتَخْشَى النَّاسَ
وَاللَّهُ أَحَقُّ أَن تَخْشَاهُ.

«әл-Әхзәб»/37)[2].

---

1 «Мөэмин һәм мөэминә кешегә Аллаһ вә рәсүле бер эш кушса, аларның каршы килергә хаклары юктыр, аларга аны үтәү тиештер. Аллаһ вә рәсүленә карышкан кеше хак юлдан язмыштыр, гаять бөек хата кылган булыр» – авт.

2 «Син (Мөхәммәд галәйһиссәлам) шул вакытны хәтереңә төшер. Аллаһы һәм син аңа, нигъмәт кылынган кешегә (Зәйд бине Харисәгә): «Хатыныңны үзеңдә тот, аны талак итү хосусында Аллаһыдан курык» – дисең. Аллаһы аны бер вакыт мәйданга куячак нәрсәне (Зәйнәбкә өйләнүе) күңелеңдә яшерәсең. Аны халыкка ачарга куркасың. Хәлбуки, Аллаһыдан күбрәк курку тиеш» – авт.



www.darul-kutub.com

Зәйд күп мәртәбәләр үз сүзендә торганнан соң рәсүлуллаһ Зәйдкә Зәйнәбне талак итәргә рөхсәт бирде. Аннан соң Зәйнәбкә никахланды. Моның белән уллыкка алу гадәте батылга чыгарылды һәм «уллыкка алынган» кеше гади бер зат булып, аның аерылган хатынын уллыкка алучыга никахлау дөрес булды.

«فَلَمَّا قَضَى زَيْدٌ مِّنْهَا وَطَرًا زَوَّجْنَاكَهَا لِكَيْ لَا يَكُونَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ حَرَجٌ فِي أَزْوَاجِ أَدْعِيَائِهِمْ إِذَا قَضَوْا مِنْهُنَّ وَطَرًا»

әл-Әхзәб/37[1]

.

«وَمَا جَعَلَ أَدْعِيَاءكُمْ أَبْنَاءكُمْ ذَلِكُمْ قَوْلُكُم بِأَفْوَاهِكُمْ وَاللَّهُ يَقُولُ الْحَقَّ وَهُوَ يَهْدِي السَّبِيلَ. ادْعُوهُمْ لِآبَائِهِمْ هُوَ أَقْسَطُ عِندَ اللَّهِ»

әл-Әхзәб/4-5[2] .

«مَّا كَانَ مُحَمَّدٌ أَبَا أَحَدٍ مِّن رِّجَالِكُمْ وَلَكِن رَّسُولَ اللَّهِ وَخَاتَمَ النَّبِيِّينَ وَكَانَ اللَّهُ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمًا»

әл-Әхзәб/40[3].

Моннан соң Зәйд Зәйд бине Мөхәммәд урынына, Зәйд бине Харисә дип, үз атасына нәсеп кылынып йөртелә башлады.

---

1 «Зәйд талак кылгач, аны сиңа никахландырдык. Болай итүебез мөэминнәргә уллыкка алганнарының хатыннарын алуда тарлык булмасын өчен, уллыкка алу гадәтен батыл итү өчен» – мәгънәсендә. – авт.

2 «Сезнең уллыкка алганнарыгыз хакыйкый улларыгыз түгелдер. Аллаһы алай кылмады. Уллыкка алган кешене «Улым» дип йөрү – авыз сүзе генә. Бу хакта чын һәм тугъры сүзне Аллаһы сөйли. Хак юлга күндерүче дә Улдыр. Сез моннан соң аларны үз аталарына нәсеб кылыгыз. Аллаһы каршында монысы тугрырактыр.» – авт.

3 «Мөхәммәд сезнең һичберегезнең атасы түгелдер. Ләкин ул Аллаһының рәсүле һәм пәйгамбәрләренең соңгысыдыр» – авт.

Бик күп тарихчылар бу вакыйгага сәбәп итеп, бик сәер сүзләр риваять итәләр. Алар: «Бервакыт рәсүлуллаһ зиярат өчен Зәйднең өенә барганда Зәйнәбне күреп, аның гүзәллегенә һәм яхшылыгына сокланып: «Сөбханә Мүкаллиб әл-кулүб»[1], – дип әйткән. Зәйнәб моны ишетеп Зәйд кайткач, вакыйганы аңа сөйләгән. Моның нәтиҗәсендә Зәйд рәсүлуллаһның күзе төшкән бер хатынны никахымда тоту туры килмәс дип, Зәйнәбне талак кылырга карар биргән. Зәйд мәсьәләне рәсүлуллаһка сөйләгәннән соң, рәсулүллаһ күңеленнән моны никадәр теләсә дә, халыкның Мөхәммәд уллыкка алган кешенең хатынына никахланды дигән сүзләреннән куркып, Зәйдне бу эшеннән тыйган. Эшнең ахырында Зәйд Зәйнәбне талак итеп, рәсулүллаһ никахланган», – диләр.

Һәр риваятьне хакыйкать дип кабул итеп, тәфсирләрен хорафат һәм исраилият белән тутырган бик күп мөфәссирләр Ислам дошманнары тарафыннан шәригать сахибен яки Исламиятне орышуга сәбәпче булалар. Ислам дошманнары югарыдагы риваятьләргә нигезләнеп: «Мөхәммәд хатын-кызларны нык яратучы иде; күзе төшкән һичбер хатынны үткәреп җибәрмәде, үзенә алды. Хәтта үз кулында тәрбия ителеп, улы дәрәҗәсендә булган Зәйднең хатынын да тартып алып үзенә хатын итте», – диләр. Шушы риваять акыл һәм тарих үлчәвенә салынган очракта, башка бик күп риваятьләр кебек, әшәке ниятле адәм актыгы булганнар тарафыннан мөселманнарны фетнәгә салу өчен уйдырма икәнлеге көн кебек ачыктыр.

Кирәк җәһилият дәверендә булсын, кирәк Исламият дәверендә булсын гарәпләрдә хиҗаб (йөзне каплау) та-

1 "Йөрәкләрне үзгәртүчегә дан!" – тәрҗ.

нылган нәрсә түгел иде. Ирләр хатыннар белән һәрвакыт аралашалар, бер-берсен күрәләр һәм сөйләшәләр иде. Шулай булгач, «Зәйдне зиярат өчен барганда Зәйнәбне күреп, аның гүзәллегеннән һәм яхшылыгыннан фетнәләнде...» кебек сүзләрнең ни әһәмияте бар? Аның өстенә Зәйнәб, рәсулүллаһның әтисе белән бертуган кыз кардәшенең кызы булып, аның күз алдында тәрбия ителгән иде. Күз алдында үскән якын бер кардәшен күрмәгән дию, рәсулүллаһ сукыр дип әйтү белән бер. Әгәр рәсулүллаһ Зәйнәбкә мәхәббәт багласа, аны кыз вакытында ук алыр иде. Моңа һичбер каршылык булмады. Ярар, рәсулүллаһ Зәйнәбне Зәйдкә килгәнче күрмәгән дә булсын. Ләкин пәйгамбәрлеккә кадәр үк абруй һәм яхшы әхлак илә шөһрәт тоткан бер затның, уллыкка алып азат итәчәк кешенең хатынын күрүгә мәхәббәт көченә бирелүен кем тәсдыйк итәчәк? Иң бөек табигатьле, иң мәрхәмәтле бер затның үзенә якын кешенең хатынын аертып алу дәрәҗәсендә каты бәгырьле булуы нинди акылларга сыйсын?! Ялгыз мөшрикләрне Исламга кертү өчен ибн Үмм Мәктүмнән борылганга

«عَبَسَ وَتَوَلَّى. أَن جَاءَهُ الْأَعْمَى»[1]

аяте белән шелтәләгән Аллаһ Тәгалә, «Сөбхәнә Мүкаллиби әл-кулүб» дип, Зәйнәбкә ишеттереп әйтүенә шелтә белдермәс идеме?

«وَلَا تَمُدَّنَّ عَيْنَيْكَ إِلَى مَا مَتَّعْنَا بِهِ أَزْوَاجًا مِّنْهُمْ زَهْرَةَ الْحَيَاةِ الدُّنيَا لِنَفْتِنَهُمْ فِيهِ»[2]

1 «Ул йөзен үзгәртеп йөзен чытты һәм борылды. Чөнки аның янына дин турында сорарга сукыр кеше килде» «Габәсә»/1-2. – тәрҗ.

2 «Без кайбер кәферләргә биргән нигъмәтләргә күзеңне төшермә. Бу – дөньяның ләззәте һәм зиннәте, алар белән Аллаһы колларын дөньяда сыный» «Та Һә»/131. – тәрҗ.

www.darul-kutub.com

аяте белән хатыннарга күз салудан тыйган Аллаһы Тәгалә алдында, шуның каршысы булган бер эштә Мөхәммәд галәйһиссәлам Зәйддән Зәйнәбне алыр идеме? Бу хакта иңдерелгән аятьләрнең мәгънәсе шулкадәр ачык ки, риваять әсире булмаган затның моннан башка мәгънә бирүен күз алдына да китереп булмый[1].

## *Хиҗаб*

Мөэминнәрнең аналары [рәсүлуллаһның хатыннары] хиҗаб астына алынуы ошбу елда булды. Бу вакытка кадәр алар башка мөселман хатыннары кебек башка ирләргә күренәләр һәм алар белән утырышалар вә сөйләшәләр иде. Хәтта сугышларга чыгып гаскәргә ярдәм күрсәтәләр, аларга су ташыйлар, җәрәхәтләнгән кешеләрне дәвалый иделәр. Мөэминнәр аналарын күргән вә алар белән сөйләшкән кайбер зәгыйфь иманлы кешеләр вә монафикъларның болардан кайберләренең матурлыклары һәм әйбәтлекләре турында сөйләшүләре вә «рәсүлуллаһтан соң фәләнне мин алам» кебек килешсез сүзләр ычкындырулары ишетелә иде.

Фасыйк вә монафикъларның мондый сүзләр белән рәсүлуллаһны рәнҗетүләренә эчләре поша торган вә пәйгамбәр хатыннарының башка гади хатыннардан аермалы булуларын теләгән бәгъзе сәхабәләр рәсүлуллаһтан хатыннарын чит кешеләргә күрсәтмәвен үтенәләр иде. Хәтта хәзрәти Гомәр бу хосуста рәсүлуллаһка киңәш белән генә калмыйча, мөэминнәрнең аналарына, үзләрен качуга мәҗбүр итү нияте белән, аларга очраганда сүз катып та китә иде. Бервакыт Сәүдә бинте Зәмга йомыш белән бер җиргә барганда Гомәр күреп алып: «Сәүдә, сине таныдык», – дигән мәгънәдә сүз

1 Остаз имам Мөхәммәд Габду хәзрәтләренең мәкаләсеннән күчереп алынды – авт.

кычкырган иде[1]. Хәзрәти Гомәрнең бу эше рәсүлуллаһ һәм хатыннарының мәнфәгатен күзәтү вә алар өчен кайгырудан килә иде. Ләкин рәсүлуллаһ, Аллаһыдан бу турыда һичбер әмер булмаганга күрә, бу мәсьәләдә бер эшкә дә керешми иде.

Һиҗрәтнең бишенче елында рәсүлуллаһ, Зәйнәб бинте Җәхшкә өйләнеп, зур туй мәҗлесе ясады. Рәсүлуллаһның хезмәтчесе Әнәс күргән бер кешене өйгә алып керә иде. Халык берсе артлы берсе кереп ашап чыгып китәләр иде. Зәйнәб бинте Җәхш тә шул мәҗлес ясалган өйдә иде. Мәҗлес азагында өч кеше өйдә утырып калып, әңгәмәгә керештеләр. Рәсүлуллаһ берничә мәртәбә өйдән чыгып китеп караса да, болар һаман кузгалмадылар. Ниһаять, болар чыгып китте. Шул мөнәсәбәттән Аллаһы Тәгалә рәсүлуллаһ өенә вакытлы-вакытсыз кереп, аны борчудан котылу һәм дә рәсүлуллаһ хатыннарының чит кешеләргә күренмәүләре тиешлеге хакында Әхзаб сүрәсендәге шушы аятьне иңдерде:

«يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَدْخُلُوا بُيُوتَ النَّبِيِّ إِلَّا أَن يُؤْذَنَ لَكُمْ إِلَى طَعَامٍ غَيْرَ نَاظِرِينَ إِنَاهُ وَلَكِنْ إِذَا دُعِيتُمْ فَادْخُلُوا فَإِذَا طَعِمْتُمْ فَانتَشِرُوا وَلَا مُسْتَأْنِسِينَ لِحَدِيثٍ إِنَّ ذَلِكُمْ كَانَ يُؤْذِي النَّبِيَّ فَيَسْتَحْيِي مِنكُمْ وَاللَّهُ لَا يَسْتَحْيِي مِنَ الْحَقِّ وَإِذَا سَأَلْتُمُوهُنَّ مَتَاعًا فَاسْأَلُوهُنَّ مِن وَرَاءِ حِجَابٍ...»[2]

53 аять. Шул ук аятьнең дәвамында

1 “Бохари”, 1 т., 41 б. – авт.

2 «Бохари», 2 т., 118-120 б. Аятьнең якынча мәгънәсе: «Әй мөэминнәр, чакырылмыйча пәйгамбәрнең өенә кермәгез, аның ашы пешкәнне көтеп утырмагыз. Әгәр чакырылсагыз, керегез. Ләкин ашап бетергәч чыгып китегез, гәп-әңгәмә сугып кылып утырмагыз. Сезнең болай итүегез пәйгамбәргә иза булып төшә. Ул оялганлыктан, бу хакта сезгә сүз әйтә алмый. Фәкать Аллаһ хакны әйтүдән оялмыйдыр. Әгәр пәйгамбәр хатыннарыннан бер-бер нәрсә сорасагыз, хиҗап аркылы сорагыз» – авт.



www.darul-kutub.com

«وَلَا أَن تَنكِحُوا أَزْوَاجَهُ مِن بَعْدِهِ أَبَدًا»[1]

– дип әйтелгән изге сүз белән рәсүлуллаһтан соң мөэминнәр аналарын алу дөрес түгеллеген бәян итте. Шушы аять чыгып рәсүлуллаһ хатыннары чит кешеләргә нәмәхрам (күренмәс) булдылар. Алар белән пәрдә аркылы гына сөйләштеләр.

Моннан тыш рәсүлуллаһ хатыннарына өйдә утырырга әмер иткән, җаһилият вакытында кебек урамнарда бизәнеп, купшы зиннәтләрен күрсәтеп йөрүдән тыйган:

«وَقَرْنَ فِي بُيُوتِكُنَّ وَلَا تَبَرَّجْنَ تَبَرُّجَ الْجَاهِلِيَّةِ الْأُولَى...»[2]

аяте бардыр. Бу аять таләп итүе буенча мөэминнәр аналары өйләрендә утырырга мәҗбүр булып, заруриятсез урамнарда йөрмәделәр[3].

Хатын-кызларның чит ирләргә күренмәүләре һәм өйләрендә булулары хакында Коръәни Кәримдә ике аять зекер ителә. Бу аятьләрнең һәр икесе рәсүлуллаһ хатыннарына гына хастыр.

«وَإِذَا سَأَلْتُمُوهُنَّ مَتَاعًا»

аятенең иңү сәбәбендә булган сахих риваятьтә дә, аятьнең үзендә дә мөэминнәр аналары хакында гына икәнлеген ачык күрсәткән шикелле,

«وَقَرْنَ...»

---

1 «Сезгә пәйгамбәрдән соң, аның хатыннарына никахлану дөрес түгел» – тәрҗ.

2 «Өйләрегездә торыгыз вә җаһилият заманындагы кебек урамнарга чыгып бизәнеп, зиннәтләрегезне күрсәтеп йөрмәгез...» – авт.

3 Хиҗаб әмер ителгәннән соң шул ук Сәүдә бер көн хаҗәте белән чыкканда хәзрәти Гомәр тагы аны күреп алып кычкырган иде. Сәүдә моңардан рәсулүллаһка шикаять белдерде. Моңа карша рәсулүллаһ: “Чынлыкта ул...Ләкин сезгә хәҗәтегез өчен генә чыгарга рөхсәт ителә”. Бохари, 6 т., 120 б. – авт.



www.darul-kutub.com

аятенең мәгънәсе дә болар хакында гына икәнлеге шөбһәсездер. Чөнки бу аятьнең башындагы аятьләр гел мөэминнәр аналары хакында булып, аятьнең калган яртысы да туры аларга ишарә итәдер.

Рәсүлуллаһ хатыннарыннан башка хатыннарга исә чит ирләргә күренмәү мәҗбүри түгел. Алар җаһилият гасырындагы кебек үк ирләргә күренүгә вә алар белән сөйләшүгә ихтыярлы калдырылды. Тик шул аерма бар ки: җаһилият заманында хатыннар баш һәм изүләрен каплауга әһәмият бирмиләр иде. Күп вакыт ачык изүләреннән күкрәкләре күренеп йөри торган иде. Әлбәттә, моның гыйффәтле хатыннарга килешми һәм аларга туры килми торган бер гадәт икәнлегендә шөбһә юктыр. Шуның өчен дә Ислам шәригате хатын-кызларга бу юл белән эчке зинәтләрен, ягъни каплау мөшкел булмаган зиннәтләрен күрсәтүне тыйды. Баш һәм изүләрен киемнәре белән ябарга әмер ителде. Бу турыда иңдерелгән аятьләр «Нур» сүрәсендәге

«وَلَا يُبْدِينَ زِينَتَهُنَّ إِلَّا مَا ظَهَرَ مِنْهَا وَلْيَضْرِبْنَ بِخُمُرِهِنَّ عَلَى جُيُوبِهِنَّ»[1]

31нче аяте белән «Әхзаб» сүрәсендәге

«يَا أَيُّهَا النَّبِيُّ قُل لِّأَزْوَاجِكَ وَبَنَاتِكَ وَنِسَاء الْمُؤْمِنِينَ يُدْنِينَ عَلَيْهِنَّ مِن جَلَابِيبِهِنَّ ذَلِكَ أَدْنَى أَن يُعْرَفْنَ فَلَا يُؤْذَيْنَ»[2]

59 аятьләредер.

www.darul-kutub.com

---

1 «Ачык булган зиннәттән башка зиннәтләрен күрсәтмәсенәр, баш киемнәре (шәл кебек нәрсә) белән изүләрен капласыннар» мәгънәсендә. – авт.

2 «Әй нәбий, хатыннарыңа, кызларыңа һәм мөслимә хатыннарга әйт, җилбәбләрен (Баштан алып аякка кадәр бөтен тәнне каплый торган тышкы кием. Хәзерге көндә Мисырның түбән катлау хатыннарында шундый нәрсә ябыну бар.)үзләренә якын китерсеннәр (ягъни баш һәм изүләрен җилбәбләр белән ябып йөрсеннәр). Болай иткәндә, аларның азат икәнлекләре беленер һәм аларны изаламаслар» мәгънәсендәдер. – авт.

«وَلَا يُبْدِينَ زِينَتَهُنَّ إِلَّا مَا ظَهَرَ مِنْهَا»

сүзендә ачык зиннәтнең морады: йөзек, хна, сөрмә, беләзек кебек һәрвакыт күренә торган һәм аны каплау мөшкел булган зиннәтләрдер. Монда ошбу зиннәтләрнең урыны булган беләкнең ярмиенә кадәр кул керәдер. Мүфәссирләрнең имамы Ибн Җәрир дә ачык зиннәт хакында риваятьләрне зекер иткәннән соң шушы без әйткән мәгънәне өстен кыла һәм шуңа дәлилләр китерәдер[1]. Хәнәфи мәзһәбендәге мәшһүр мүфәссир «Әлүси» дә ошбу аятьләрне тәфсир кылганда йөз һәм учларның гаурәт түгеллеген, шуңа күрә бу әгъзаларны чит ирләр каршында каплау тиеш түгеллеген, Хәнәфи мәзһәбендә шулай икәнлеген сөйлидер[2].

Хатын-кызларга йөз каплау тиешлеге хакында Коръәни Кәримдә һәм рәсүлуллаһ хәдисләрендә бер сүз дә юк. Киресенчә, рәсүлуллаһ вакытында хатын-кызларның йөзләрен капламый йөргәнлекләре турында бик күп хәдисләр булганлыгы шикелле, йөз вә кулларны каплау тиеш түгеллеген ачык бәян иткән хәдисләр дә бардыр[3].

---

1 “Тәфсирү Ибн Җәрир”, 18 т., 84 б. – авт.

2 “Рухуль-Мәгани”, 6т., 52б; 7т., 103б. – авт.

3 Шул җөмләдән Әбү Дәуд, Ибне Мәрдәвия, Бәйхакый риваять кылган Гайшә хәдисе: “Чынлыкта исә, Әсма бинте Әбү Бәкер юка кием киеп пәйгамбәр (саләллаһу галәйһи вәссәлам) янына керә. Рәсүлуллаһ кырыйга борылып: “Әй Әсма, хәезгә ирешкән хатын-кызның шушы өлешеннән кала, – йөзе белән беләзеккә кадәр кулын күрсәтеп, – башкасы күренергә тиеш түгел” – дип әйтә.” Ибне Җәрир риваять иткән хәдистә Гайшә: “Бер көнне минем яныма әниемнең абыйсы Габдулла бине Туфәйлнең кызы зиннәтләнеп керде. Шул вакыт рәсүлебез дә кереп калды, ул кызны күргәч, рәсүлебез йөзен читкә борды. Гайшә: “Я рәсүллулаһ, бу бит абыемның кызы” – диде. Рәсүлебез: “Хатын-кыз тирләсә дә, йөзе белән менә бу урыныннан башка җирен ачу хәләл түгел” – дип кулын беләзектән тагын бер кул тотарлык урын калдырып тотты” – ди. Һәм башкалар.

Нур сүрәсендәге

«وَلْيَضْرِبْنَ بِخُمُرِهِنَّ عَلَى جُيُوبِهِنَّ»

һәм Әхзәб сүрәсендәге

«يُدْنِينَ عَلَيْهِنَّ مِن جَلَابِيبِهِنَّ»

аятьләре йөз каплауга катгый дәлил була алмый. Бәлки, Ибне Җәрир әйткәнчә, чәч вә муеннарны каплау тиешлеген күрсәтәдер. Әгәр аятьтән йөз каплау максат ителсә,

«عَلَى جُيُوبِهِنَّ»

урынына

«عَلَى وُجُوهِهِنَّ»

[йөзләренә],

«عَلَيْهِنَّ»

урынына

«عَلَى وُجُوهِهِنَّ»

кебек гыйбарә булыр иде. Хатын-кызга хиҗабны әмер итү, теләсә йөзгә пәрдә каплау мәгънәсе белән булсын, теләсә өйдә дүрт дивар арасына ябып асрау мәгънәсендә булсын, Шәригать-Исламда юк. Исламият бу хосуста мәгънәви хиҗаб белән әмер итмештер. Ягъни гыйффәтлек саклау белән әмер итмештер. Бу хакта ирләр вә хатыннар тигез булып, һәрберсенә бу әмер тигездер:

«قُل لِّلْمُؤْمِنِينَ يَغُضُّوا مِنْ أَبْصَارِهِمْ وَيَحْفَظُوا فُرُوجَهُمْ ذَلِكَ أَزْكَى لَهُمْ إِنَّ اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا يَصْنَعُونَ. وَقُل لِّلْمُؤْمِنَاتِ يَغْضُضْنَ مِنْ أَبْصَارِهِنَّ وَيَحْفَظْنَ فُرُوجَهُنَّ»[1]

«Нур» сүрәсе, 30-31 аятьләр.

---

1 «Әйт син мөэминнәргә күзләрен түбән салсыннар, гыйффәтләрен сакласыннар. Мөэминәләргә дә әйт күзләрен түбән салсыннар, гыйффәтләрен сакласыннар» мәгънәсендә – авт.



www.darul-kutub.com

Исламият кебек изге, гадел бер дин, хатыннарның битләренә пәрдә каплау вә аларны дүрт дивар арасына бикләп асрау кебек рәхимсезлек эшләми.

Исламият кебек аңлаешлы сүзләр белән күтәрә алмаслык бер эшне кабул итмәгән бер диндә тормышта кулланып булмый торган бер хөкемнең булуы акылга сыймыйдыр. Исламият кебек гомуми һәм Кыямәт көненә кадәр булачак бер диндә, әлбәттә, мондый хәят белән туры килми торган хөкемнәр булмас һәм юк та. Мөэминнәр аналары файда өчен хиҗаб астына алынган икән, аларга кыяс [чагыштыру] ясап, кыямәт көненә кадәр булачак хатын-кызларга хиҗаб тагу катгый рәвештә туры килә торган эш түгелдер. Мөэминнәр аналары чикләнелгән кешеләр булып, гомерләре дә ярты гасырга кадәр чикләнелгән бер заман иде. Ярым гасыр кадәр бер заманда махсус һәм чикле кешеләрнең тормышы белән оеша алган бер хөкемне меңнәрчә, Аллаһы белсен, миллионнарча еллар буена миллиардларча халыкның тормышына оешыр дип әйтү туры килмәс. Хиҗаб рәсүлуллаһ хатыннары өчен горурлык булган бер аермалык иде. Алар аңардан разый иделәр. Аларга ул вакыт хиҗаб киюдә кыенлык, уңайсызлык юк иде. Бөтен мөселман хатыннарына исә бу бер бәла, җәфа, зур уңайсызлыктыр.

Кыскасы, хиҗаб – Ислам шәригатендә юк. Гасыр сәгадәттәме, сәләф салихин гасырындамы булсын, хатыннар битләренә пәрдә каплап, нәмәхрамнәрдән качып йөрмиләр иде. Алар мәчетләргә килеп, ирләр белән биш вакыт намаз укыйлар, гает вә җомгаларга барып хөтбә-вәгазь тыңлыйлар, ирләр белән бергә Бәйтуллаһны тәваф кылалар, сугышларда катнашып, анда дәвалап йөриләр, базарларга чыгып кирәк-яракларын алалар, алыш-биреш итәләр, җыелышларга ба-

www.darul-kutub.com

рып, үз хокукларын яклыйлар, хөтбә сөйлиләр иде. Ошбу вакытларда, табигый, аларның йөзләре ачык була, пәрдә белән капланган булмый иде. Шуның белән бергә ул вакытларда хатын-кызлар үрнәк булырлык гыйффәт һәм фазыйләт ияләре иде. Чөнки ул вакытларда ире дә, хатыны да, динне заһири гадәтләрдән генә гыйбарәт дип белмиләр иде. «Күзне түбән төшерү зинадан саклый», – дигән сүзне һәр ике як күз алдында тота иде. Моның өчен фетнә куркынычы да, бозыклык куркынычы да юк иде.

Пәйгамбәр булган заман азагына якынлашып, Ислам әһеленең калебләрендә диннең тәэсире кими төшкәч, башка кавемнәрнең дәүләтләрен Ислам дәүләтенә кушу сәбәпле, гарәпләр күрше кавемнәргә катнашып, аларның әхлак вә гадәтләрен ала башлагач, Ислам дине жиңү соңында гарәпләрдә, әүвәлге фәкыйрьлек урынына байлык, куанычлык хөкем сөреп, зәвык һәм сафага бирелә башлагач, әмирләр сарайлары алтын-көмеш астында калып, никахлы хатыннар өстенә дистәләп җария хатыннарга хуҗа булгач, кул асларындагы хатыннарның башкаларга күренүләре вә катнашулары, алар белән сөйләшүләре ошбу үзирекле әмирләрнең күңелләрен кытыклый башлады. Хатын-кыз турында начар уйлый вә аларга күзәтчеләр куя башлады. Аларның көнчелекләре, хайвани шәһвәтләре хатын-кызларын читләргә күрсәтмәскә, катнаштырмаска, аларны читлектәге кош кебек ябып асрарга буйсындыра башлады. Ул вакыттагы күрше милләтләрендәге югары катлам ияләрендә киң таралган бу гадәт, боларның күңелләренә ятты. Аларга ияреп, хатыннарын әкренләп өйдә бикләп тота, табигать белән аларның арасын аера башладылар. Икенче гасыр голәмәләреннән мәнфәгать һәм файда түрәләр файдасы белән бәйле булганлыктан, бәгъзе

фәкыйһләр чыгып, бу эшкә дини аң бирделәр: «Заман бозылды, хатыннарны ачык йөртүдә фетнә куркынычы бар», – дигән сүзләр табып, хатыннарга ачык йөрүнең дөрес түгеллегенә шәргый фәтваләр чыгардылар. «Әгәр рәсүлуллаһ (саләллаһу галәйһи вәссәлам) белсә иде, тыелган эшне бозган хатыннар ни эшләгәнен? Һичшиксез, аларны Ибне Исраил хатыннары кебек тыяр иде»[1] кебек сүзләр аларга көч-куәт бирде.

Хәлбуки, фәсад, фетнә хатыннардан бигрәк, ирләрдән килгәнлеген оныттылар. Хәтта ир ни эшләсә дә ярый, «түбән карау» – хатыннарга гына тиеш, ә ирләргә бу хакта һичбер тәклиф юк шикелле булып кала. Зәгыйфь һәм мескен хатыннарга ирләренең золымыннан шикаять итеп, шагыйрьнең түбәндәге шигырен кабатларга гына калды:

وَ حَمَّلْتَنِي ذَنْبَ امْرِئ وَ تَرَكْتَهُ كَذِي العُرِّ يُكْوَى غَيْرُهُ وَ هُوَ رَاتِعُ

Нәтиҗәдә

«النَّاسُ عَلَى دِينِ مُلُوكِهِم»[2]

– дигән сүзгә таянып, башка халык та боларга иярде.

Шулай итеп, югары вә урта катлам халыкларында хиҗаб мәйдан алып, бер гыйффәт гәләмәтләреннән һәм горурланырлык нәрсәләрдән булып китте. Хиҗабның иң киң таралу чоры Габбасилар хәлифәте заманының урталарында булды. Бу вакытларда хатын иренең кулында бер уенчык шикелле булып калды. Аңа аслән кыйммәт юк, ул бары тик ирнең шәһвәтен канәгатьләндерер өчен генә бар кылын-

1 Гайшә сүзе. Бохари, 1 т., 173 б. – авт.

2 «Кешеләр үзләренең патшалары динендә» – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

ган бер мәхлук итеп каралды. Хатын дүрт дивар арасында капланып, җарияләр һәм агалары арасында гына яши торган булды. Аңа матур табигать тыелды. Гүя табигать тә аңа нәмәхрам булды. Моның нәтиҗәсендә хатын-кызлар гыйлем вә мәгърифәттән өлешсез булып, вөҗуде зәгыйфь, рухы төшкән, баш миләре буш, акыл вә фикер даирәсе бик тар бер мәхлук булып калды. Милләтнең ярым әгъзасы булган «йомшак җенес» паралич зәхмәте белән сыналган булгач, калган ярымы да эш күрсәтә алмады, аксады. Ислам дәүләтенең, гомуми Ислам милләтләрнең караңгылык вә томаналык эчендә күмелеп калуына иң зур сәбәп, шөбһәсез, шушы тәрбияләрнең нәтиҗәсе булды.

Исламияттә хиҗаб дигән нәрсә ошбу юл белән вөҗүдкә килеп, хәзерге көнгә кадәр дәвам итәдер. Югарыда әйтелгәнчә, моңа китап вә сөннәттән дәлил булмыйча, икенче вә өченче гасыр галимнәре тарафыннан фәсад заманы вә фетнә куркынычы сәбәпле вөҗүдкә килмештер. Хәлбуки, бу караш дөрес түгел. Чөнки ирләр белән күп вакыт аралаша торган вә алар белән бергә эшләп йөри торган авыл хатыннарында, пәрдә вә чапан астында йөри торган шәһәр хатыннарына караганда, гыйффәтлек артыграктыр.

Ярар, хиҗабны фарыз итеп тә карыйк. Ләкин моңа каршы хиҗабның үзендә әллә никадәр иҗтимагый мөфсидәләр дә бардыр. Аңардан  көтелгән файдалар, чагыштырмача юк дәрәҗәсендә булып калалар. Бу урында хиҗабның зарарларын сөйләү вазыйфабыздан булмаганга, аның дини ягын вә тарихын сөйләү белән чикләнеп калыйк.

Исламият хатыннарның ирләр белән катнашуын тыймаса да, аларга ирләр белән сөйләшергә, бер-берсе белән катнашып йөрергә хөррият бирсә дә, чит ир белән чит хатынның

берүзләре калуларын тыядыр. Бу эш хатынга тыелган кебек булса, шөбһәсез, иргә дә тыелгандыр. Шулай ук хатынга мәхрамыннан [туган кардәшеннән] башка ялгызы гына озак сәфәргә чыгу да тыелган. Бу хакта

«لَا يَحِلُّ لِامْرَأَةٍ تُؤْمِنَ بِاللهِ و اليَوْمِ الْآخِرِ أنْ تُسافِرَ مَسِيرَةَ يَوْمٍ وَ لَيْلَةٍ لَيْسَ مَعَهَا حُرْمَةٍ» , «لَا تُسَافِرُ المرْأةُ إلَّا مَعَ ذِي مَحْرَمٍ وَ لَا يَدْخُلُ عَلَيْهَا رَجُلٌ إلَّا وَ مَعَهَا مَحْرَمٍ» , «لَا تُسَافِرُ امْرَأةٌ مَيْسَرَةَ يَوْمَيْنِ لَيْسَ مَعَهَا زَوْجهَا أوْ ذُو مَحْرَمٍ»[1]

кебек «Ике сахих» хәдис китабында һәм башка китаплардагы сахих хәдисләрдә риваять ителә. Ләкин бу тыю – бозыклык юлын бикләү өчендер, фәкыйһлар әйтмешли: «Сәддәнел-л-иззәрига»дыр. Хәрам булган нәрсәләрне, аларга илтүче юлларны тыю зарурат, хәтта хәҗәт өчен дә хәрам дәрәҗәсендә буладыр. Шуңа күрә зарурат яки хәҗәт төшкән вакытта ялгыз калуны шәригать тыймыйдыр. Фәкыйһлар, үзләре дә моны аңлатып китәләр. Ире яки нәмәхрам кардәше белән сәфәр итү мөмкин булмаганда, хатын ялгызы гына сәфәр итүгә мәҗбүр булганда, шәригать аңа юлын кисми, рөхсәт бирәдер.

«وَمَا جَعَلَ عَلَيْكُمْ فِي الدِّينِ مِنْ حَرَجٍ»[2],
«يُرِيدُ اللّهُ بِكُمُ الْيُسْرَ وَلاَ يُرِيدُ بِكُمُ الْعُسْرَ»[3].

---

1 “Хатын-кыз ике көнлек юлга ире яки мәхрам кардәшеннән башка сәфәр кылмасын” Бохари, 3 т., 19 б. – авт.

2 «Аллаһы сезнең өчен диндә авырлык кылмады.» – мәгънәсендә. – тәрҗ.

3 «Аллаһы сезгә җиңеллек тели, авырлык түгел.» – мәгънәсендә. – тәрҗ.



www.darulkutub.com

# Алтынчы ел

## *Мөхәммәд бине Мәсләмә сәриясе*

Ошбу ел мөхәррәм аенда рәсүлуллаһ «Зарийя»[1] исемендәге җирдә тора торган Бәнү Бәкер кабиләсеннән бер кавеменә һөҗүм итәр өчен Мөхәммәд бине Мәсләмә җитәкчелегендә утыз кешедән торган атлы гаскәр җибәрде. Мөхәммәд бине Мәсләмә боларга барып кинәттән һөҗүм итте. Дошманның ун кешесе үтерелеп, калганнары качтылар. Сәрия болардан куй вә дөяләрдән гыйбарәт ганимәт алып кайтып китте. Алар юлда Ибне Хәнифә башлыкларыннан Сүмәмә бине Үсәлне тотып, әсирлеккә алды. Мәдинәгә алып кайткач, Сүмәмәне рәсүлуллаһ өч көнгә кадәр Исламга дәгъвәт итсә дә, ул кабул итмәде. Соңра моны, һичбер зарар тидермичә азат кылды. Рәсүлуллаһтан бу кадәр зур нигъмәтне күргәч, Сүмәмәнең күңеле нечкәреп, Исламга мәхәббәт багълады һәм аңа килеп иман китерде. Моңа рәсүлуллаһ бик шатланды. Чөнки Сүмәмә югарыда әйтелгәнчә, Ибне Хәнифәнең башлыкларыннан иде. Шуңа да, бик күп кеше аңа ияреп Исламга киләчәк иде.

Сүмәмә Ватанына кайтышлый, гомрә хаҗы өчен Мәккәгә керде вә анда Мәккә халкына үзенең мөселман булганлыгын белдерде. Мәккә халкы аны никадәр газапларга теләсәләр дә, Сүмәмәнең җиреннән аларга азык китерелүне хәтерләренә төшереп, ул эштән ваз кичтеләр. Сүмәмә Ватанына кайткач, кавемен Корәеш гарәпләренә азык җибәрүдән тыйды. Шуның сәбәпле, Корәешләр бик авыр хәлдә калды. Чөнки аларга иң күп азык Ямәмәдән килә иде. Ниһаять, алар рәсүлуллаһка хат язып, Сүмәмәгә азык җибәртергә әмер итүен үтенделәр.

Шәфкать вә мәрхәмәтнең иң югары дәрәҗәсендә

1 Нәҗддәге бер авыл. Мәккә белән Басра юлында урнашкан – авт.



www.darul-kutub.com

булган рәсүлуллаһ Мәккә мөшрикләренең үтенечен кабул итте. Сүмәмәгә хат язып, кавемен Мәккәгә азык җибәрүдән тыймаска кушты. Берникадәр вакыт элек кенә Мәдинәне җир белән тигезләү нияте белән килеп, Мәдинәне камап тору сәбәпле, мөселманнарны бер хөрмәгә мохтаҗ булыр дәрәҗәсендә ачлыкта калдырган бу кавемгә рәсүлуллаһның ошбу мөгамәләсен күреп хәйран калмый мөмкин түгел.

## *Бәни Лихъян газвәсе*

Ошбу ел рабигыль-әүвәл башында рәсүлуллаһ Раҗигъ әсхәбләрен хыянәт итеп үтергән Бәни Лихъян кавеменә җәза бирер өчен ике йөзгә кадәр гаскәр белән Мәдинәдән чыкты. Гаскәрдән егермесе атлы иде. Мәдинәдә Ибне Умм Мәктум калды. Рәсүлуллаһ кайда барачагын кешеләргә белдермәс өчен туры юлдан бармыйча, Шам тарафына юнәлде. Соңра сул тарафка борылып, Мәккә юлына төште. Ислам гаскәре мөшрикләрнең җирләренә якынлашканда, Бәни Лихьян кешеләре боларны күреп, тауларга качып беттеләр. Рәсүлуллаһ монда ике көн калып, төрле тарафка сәрияләр җибәреп караса да, алар һичкемне очрата алмадылар.

Рәсүлуллаһ Мәккә мөшрикләренә үзенең көчен күрсәтер өчен Гасафанга[1] беркадәр гаскәр җибәрде. Алар «Куррагу Гамим»[2] исемендәге бер тауга барып, мөшрикләрнең күзләренә чалынды. Соңра сугышмыйча, Мәдинәгә кайтып киттеләр. Бу газвәгә килгәндә, юлда Ислам гаскәренең «Биэру Мәгунә вә Раҗигъ» шәһидләренә дога кылганнары риваять иteләдер.

1 Мәккәдән Мәдинәгә таба ике тукталыш ераклыгында урнашкан бер урындыр – авт.

2 Гасафәннең көньягында, Мәккәдән сигез мил ераклыгындагы бер таудыр – авт.

## *Габә газвәсе*

Мәдинәнең төньяк тарафында «Габә»[1] исемендә бер агачлык җирдә рәсүлуллаһның утлап йөри торган егерме дөясе бар иде. Бер көн Гүяйнә бине Хисн кырык атлы гаскәр белән килеп, көтүчене үтереп, дөяләрен әйдәп алып китте. Әнсарилардан Сәләмә бине әл-Әквагъ исемендә берсе, моны ишетеп хәбәр биргәч, рәсүлуллаһ боларның артыннан чыгарга әзерләнде. Гаскәр барып җиткәнче дошманны күзәтеп торыр өчен Сәләмә бине әл-Әквагъне җибәрде. Ул бик оста ук атучы һәм әйбәт йөгерүче иде. Сәләмә дошман артыннан куып җитеп, аларга ук ата башлады. Дошман аны куа башласа, я агач артына яшеренеп, я тау башына менеп, таш вә ук ата иде.

Ислам гаскәре артларыннан килеп җитүдән куркып, мөшрикләр үзләрен җиңеләйтү өчен бик күп сөңге вә киемнәрен ташлап калдырдылар. Ниһаять, Ислам гаскәре боларның артларыннан куып җитеп, ике арада атышулар булды. Мөселманнардан берәү вә мөшрикләрдән икәү үтерелде. Шулай итеп, дөяләрнең күбесен коткаруга ирештеләр.

Сугышта иң зур батырлык күрсәткән атлы кешеләрдән әл-Микъдәд бине әл-Әсвәд, җәяүлеләрдән Сәләмә бине Әквагъ иде. Байрак Микъдәд кулында иде. Мәдинәдә Ибн Умм Мәктум калган иде. Гаскәр биш көн йөреп, Мәдинәгә кайтып киттеләр. Бу газвә «Зү Карәд» исемендәге су янында булганлыктан, «Зү Карәд» газвәсе дип тә йөртелә.

1 Сәлгъ белән Габә арасы сигез мильлек арадыр – авт.

## *Гукәшә сәриясе*

Мөселманнарга һәрвакыт зарар тидереп торган Ибне Әсәд кабиләсенә җәза бирү өчен, рәсүлуллаһ рабигыль-әүвәл аенда Гукәшә бине Мухсин җитәкчелегендә кырык кешедән гыйбарәт бер сәрия җибәрде. Мәзкүр сәрия аларның тора торган «әл-Гамр» исемле су буена килеп җиткәндә, дошман хәбәрне ишетеп качып беткән иде. Сәрия, сугышмыйча, ике йөз дөя ганимәт алып, Мәдинәгә кайтты.

## *Мөхәммәд бине Мәсләмә сәриясе*

«Зүл-Касса»[1] исемендәге җирдә тора торган Бәни Сәгъләбә гарәпләренең Мәдинә янында йөргән хайваннарга һөҗүм итәчәкләре ишетелде. Шуңа Рәсүлуллаһ аларга һөҗүм итү өчен рабигыль-әүвәл аенда Мөхәммәд бине Мәсләмә кул астында ун атлы кеше җибәрде. Ләкин дошман яшеренеп торып, йоклаган вакытта аларга һөҗүм итте һәм аларны шәһид итте. Башлыклары Мөхәммәд бине Мәсләмә җәрәхәтләнгән хәлдә ялгызы Мәдинәгә кайта алды.

## *Әбү Губәйдә сәриясе*

Мөхәммәд бине Мәсләмә кайтып, вакыйганы сөйләгәч, рәсүлуллаһ болардан үч алу өчен Әбү Губәйдә бине Җәррах кул астында кырык кеше җибәрде. Сәрия Сәгъләбә җиренә җиткәндә дошманнан берәү дә калмаган иде. Шуның өчен сугыш булмады. Алар беркадәр куй һәм дөяләр ганимәт итеп, Мәдинәгә кайттылар.

1 Мәдинәгә 24 миль ераклыкта урнашкан бер урындыр – авт.

## *Зәйд сәриясе*

Хандак вакыйгасында мөшрикләргә кушылган Бәни Сүләйм гарәпләрен җәза кылыр өчен рабиг әс-сани аенда рәсүлуллаһ Зәйд бине Харисә кул астында бер сәрия җибәрде. Юлда әсир төшкән Хәлимә исемендәге бер хатынның өйрәтүе белән, сәрия дошман җиренә җитте. Дошман хәбәрне ишеткәнлектән качып беткән иде. Шунлыктан, сугыш булмады. Ислам гаскәре дөя вә куй кебек ганимәтләр һәм беркадәр әсирләр алып кайтып китте. Рәсүлуллаһ сәриягә файдасы тигән Хәлимәне ире белән бергә азат итте.

## *Зәйд сәриясе*

Ошбу ел җөмадиәл-әүвәл аенда рәсүлуллаһ Шамнан Мәккәгә кайтып килә торган Корәеш кәрваны хакында ишетеп, Зәйд бине Харисә кул астында йөз җитмеш кешедән торган гаскәр җибәрде. Шул сәрия кәрванны бөтен кешеләре вә маллары белән әсир итеп, Мәдинәгә китерде. Болар арасында кәрванның башлыгы вә рәсүлуллаһның кызы Зәйнәбнең ире Әбү әл-Гас та бар иде. Зәйнәб Мәдинәгә һиҗрәт иткәндә Әбү әл-Гас, мөшрик булганлыктан, Мәккәдә калган иде. Әбү әл-Гас әсир буларак Мәдинәгә китерелгәч, хатыны Зәйнәбнең яклавы астына керде вә аның рәсүлуллаһтан кәрванны кайтарып җибәрүен соравын үтенде. Рәсүлуллаһ мәсьәләне сәхабәләргә сөйләгәч, алар  берсүзсез ризалык бирделәр.

Әбү әл-Гас Мәккәгә кайтып, кәрвандагы малларны хуҗаларына тапшыргач, Мәдинәгә килеп, Исламны кабул итте. Рәсүлуллаһ аңа әүвәлге никахы белән Зәйнәбне бирде.

www.darul-kutub.com

## *Зәйд сәриясе*

Мөхәммәд бине Мәсләмәнең иптәшләрен шәһид иткән Бәни Сәгъләбә гарәпләре белән сугышу өчен рәсүлуллаһ җөмадиәл-ахир аенда Тариф[1] ягына, Зәйд бине Харисә кул астында 15 кешедән гыйбарәт бер сәрия җибәрде. Дошман аларны күргәч, артларында зур гаскәр бардыр дип, качып бетте. Зәйд егерме дөя ганимәт алып, Мәдинәгә кайтты.

## *Зәйд сәриясе*

Мөселманнарга һәрвакыт зарарлары тия торган «Вәди әл-Кура»[2] да тора торган Бәни Фәззәра гарәпләрен җәза кылу өчен рәсүлуллаһ рәҗәб аенда Зәйд бине Харисә җитәкчелегендә бер сәрия җибәрде.

Ошбу сәрия Вәди әл-Курага җитеп, аларга һөҗүм итте, һәр ике тарафтан берәр кеше үтерелде. Башлыкларыннан берсенең кызын әсир алып, сәрия Мәдинәгә кайтып китте.

## *Габдрахман бине Гауф сәриясе*

Шәгъбан аенда рәсүлуллаһ Габдрахман бине Гауф җитәкчелегендә җиде йөз сәхабәне «Думәтүл Җәндәл» дигән җирдә яшәгән Кәлб кабиләсенә каршы сугышка җибәрде. Алар Думәтүл Җәндәлгә баргач, өч көн буена дошманны Исламга дәгъвәт иттеләр. Дүртенче көндә башлыклары әл-Әсбагъ бине Гамр белән берничә кеше Исламны кабул итеп, башкалары салым бирергә разый булганлыктан, сугышмый-

1 Мәдинәгә 36 мил ераклыгында булып, Мәдинә – Куфа юлында урнашкандыр – авт.

2 Шам ягындагы Мәдинәгә якын бер авылдыр – авт.

ча кайтып киттеләр. Габдрахман рәсүлуллаһның әмере илә әл-Әсбагъның кызы Тумазыйр белән никахланды.

## *Гали сәриясе*

«Фәдәк» исемендәге җирдә тора торган Бәни Сәгъд кабиләсеннән бер кавемнең Ислам әһеле белән сугышыр өчен Хайбәр яһүдләренә ярдәм итү нияте илә гаскәр җыюлары рәсүлуллаһка ишетелгәч, аларга җәза бирү өчен Гали бине Әбү Талиб кул астында йөз кешелек бер сәрия җибәрелде. Сәрия юлда, Ибне Сәгъд тарафыннан солых төзү өчен Хайбәргә җибәрелгән бер кешене тотып, аларның торган җирләрен өйрәнде. Сәрия шунда барганда тегеләр качып беткәннәр иде, сугыш булмады. Биш йөз дөя вә ике мең куй ганимәт алып кайтып киттеләр. Сәриянең чыгуы шәгъбан аенда иде.

## *Әбү Рафигъның үтерелүе*

Мәдинә тирәсеннән сөрелеп, Хайбәргә урнашкан Бәни Назыйр башлыклары арасында Әбү Рафигъның (Сәлләм бине Әбү Хукайк) барлыгы югарыда язылган иде. Бу зат бик бай булып, яһүдләр арасында сүзе үтүчән вә абруйлы иде. Ул Хүяй бине Әхтаб кебек Хандак сугышында мөселманнарга каршы күп кешеләр котыртып чыгарган һәм хәзер дә Хайбәр яһүдләрен алардан үч алуга котыртуын дәвам итә иде. Әбү Рафигъ бу эшен дәвам итсә, Хайбәр яһүдләре белән мөселманнар арасында сугыш булып, бик күп кан түгеләчәк иде. Шуның өчен Хазраҗ кабиләсеннән биш кеше рәсүлуллаһка килеп: «Безнең кардәшләребез әүсләр Кәгъб бине әл-Әшрәфне үтереп, әҗер вә савапка

ирештеләр, инде безгә бу фетнәчене үтерергә рөхсәт бир», – диделәр. Рәсүлуллаһ ике яман эшнең җиңелен сайлап, аларга бу эшкә рөхсәт бирде. Боларның башлыклары Габдулла бине Гатик иде. Алар Хайбәргә барып, төн уртасында хәйлә белән кальга эченә кереп, Әбү Рафигъны үтереп, Мәдинәгә кайттылар. Бу вакыйга рамазан аенда булды.

## *Габдулла бине Равәхә сәриясе*

Әбү Рафигъ үтерелгәч, аның урынына рәис булып калган Үсәйр бине Ризам үзенең кавемен рәсүлуллаһка каршы котырта, аларга: «Мин, Мөхәммәдкә һичкем эшләмәгән эшне эшләячәкмен, Гатафан кабиләсенә барып, аларны Мөхәммәд белән сугышырга чакырачакмын», – ди һәм шул юнәлештә эш алып бара башлады. Рәсүлуллаһка бу хәбәр ишетелгәч, Габдулла бине Равәхә җитәкчелегендә утыз кешедән гыйбарәт бер сәрия җыеп, аңа каршы җибәрде. Рәсүлуллаһ Габдулла бине Равәхәгә мөмкин кадәр аны Исламга кертергә тырышырга кушты. Габдулла Үсәйр бине Ризам янына баргач, аны рәсүлуллаһка барырга һәм аңа бирелергә өндәде. Рәсүлуллаһка буйсынган очракта, ул аны Хайбәргә вәли итеп куячагын белдерде. Үсәйр Габдулланың сүзен муафыйк күргәндәй, утыз кеше белән Мәдинәгә юнәлде. Алардан һәрберсе мөселманнарның атларына менеп атланган иделәр. Үсәйр үзе сәрия башлыгы Габдулланың атына атланган иде. Юлда ул Габдуллага хыянәт итеп, аны үтерергә теләде. Габдулла, эшне сизеп, аның үзен үтерде. Калган хыянәтчеләрне дә үтереп бетерделәр.

www.darul-kutub.com

## *Гамр бине Үмәйяне Әбү Суфьянны үтерергә җибәрү*

Ошбу ел Әбү Сафүән бине Хәрб рәсүлуллаһны үтертү өчен Мәдинәгә бер кеше җибәргән иде. Шул кеше Мәдинәгә барып Ибне Габдүл Әшһәл мәчетендә рәсүлуллаһны очратты. Рәсүлуллаһ моны күргәч: «Бу кеше начар ният белән килгән, ләкин ул аңа ирешәчәк түгел», – диде. Аның рәсүлуллаһка якынлашып баруын күреп, Үсәйд бине Хузайр каты итеп аның итәгеннән тартты. Шул вакыт аның кием астында яшерелгән хәнҗәре төшеп китте. Хыянәтче тотылып, аннан сорау алына башлады. Ләкин аның кылган эшенә үкенүе аңлашылганнан соң, рәсүлуллаһ аны азат итте. Моннан соң ул: «Әй, Мөхәммәд! Мин һичкемнән курыкмый торган идем, сине күргәч курыктым, акылым башымнан китте. Син минем ни өчен килгәнемне белдең, шунлыктан сине үтерү мөмкин булмаячагын, синең хак юлда булганлыгыңны, Әбү Сафүән вә кавеменең батыл юлда булганлыкларын белдем һәм бу эшнең нәтиҗәсенә канәгать булдым», – диде һәм Ислам динен кабул итте.

Шуннан соң рәсүлуллаһ үч алу өчен Әбү Сафүәнны үтерергә Гамр бине Үмәйя әз-Замарине җибәрде. Гамр гаять йөрәкле, хәйлә белән үтерергә оста бер кеше иде. Рәсүлуллаһ моңа бер иптәш тә бирде. Болар Мәккәгә кич белән барып керделәр. Әмма кушкан эшләрен үтәү урынына элек Кәгъбәтуллаһны тәваф кылдылар. Мәккәлеләрдән берәү боларны күреп, начар ният белән килгәннәрен сизде. Моны белгәч, кушкан эшне кылу мөмкин булмаячагын аңлап, алар Мәккәдән ашыгып киттеләр. Мәккә мөшрикләре артларыннан куып чыксалар да, аларны тота алмадылар.

www.darul-kutub.com

## *Гукәл вә Гурайнә вакыйгасы*

Ошбу ел шәүвәл аенда Гукәл вә Гурайнә гарәпләреннән бер кавем, Ислам динен кабул иткән булып, Мәдинәгә килеп урнашты. Ләкин алар сахрада торырга ияләшкәннән, Мәдинә һавасы килешмичә авыруга сабыштылар. Рәсүлуллаһ боларга, үзенең дөяләре йөри торган җиргә барып, сөт вә бәвелләре белән дәваланырга әмер итте. Алар беркадәр торып, дәваланып шифа тапкач, көтүченең аяк-кулларын кисеп, күзләрен чыгарып, җәзалап үтерделәр. Соңыннан көтүне дә куып алып киттеләр. Бу хәбәр ишетелгәч, рәсүлуллаһ алар артыннан Күрз бине Җәбир әл-Фәһри кул астында егерме атлы гаскәр җибәрде. Ошбу хыянәтчеләр сәрия тарафыннан Мәдинәгә китерелгәч, рәсүлуллаһ аларны көтүче ничек үтерелгән булса, шулай ук җәзәлап үтертте.

## *Хүдәйбия вакыйгасы*

Рәсүлуллаһ бер көн төшендә сәхабәләр белән гаять тыныч бер хәлдә Мәккәгә кереп, анда хаҗ гамәлләрен үтәгәнлеген күрде. Шул сәбәптән берничә елдан бирле Хәрам мәчетен зиярат кылудан мәхрүм булган рәсүлуллаһ Мәккәгә барырга күңеле кузгалып, гомрә хаҗына әзерләнергә кушты. Сәхабәләр төшнең дөреслеге шушы елда ук тормышка ашу өмете белән бик шатланып, юлга әзерләнә башлады. Мөселманнар алар белән сугыш хәлендә булган Корәеш гарәпләре аларны Мәккәгә кертмәүләреннән куркып, үзләренең саннарын күбәйтү нияте белән сахра гарәпләрен (Җүһәйнә, Мүзәйнә, Гыйфар, Әсләм кебек) алар белән бергә чыгарга кызыктырсалар да, алардан бик азы гына риза бул-

дылар. Күбесе мөселманнарның мөшрикләрдән җиңелеп, үтерелеп бетәчәкләрен фарыз кылып, төрле сәбәпләр белән юлга чыкмады.

## *Юлга чыгу*

Һиҗрәтнең алтынчы елында, зил-кагъдә аенда рәсүлуллаһ бер мең дә дүрт йөз сәхабә белән Мәккәгә юнәлде. Болар арасында мөэминнәрнең аналарыннан Үмм Сәләмә вә берничә башка хатын бар иде. Мәдинәдә Ибн Умм Мәктум калды.

Аларның максатлары сугышсыз гына гомрә кылу булганлыктан, кылычтан башка корал алмадылар. Үзләре белән җитмеш дөя корбанлык алып киттеләр. Зүл-хуләйфәгә[1] җиткәч ихрам багълап, корбанлыкларын ишгарь вә тәкълид иттеләр[2].

## *Мөшрикләр турында мәгълүмат алу*

Мөшрикләрдән хәбәр алу өчен, рәсүлуллаһ алдан бер җәсусны җибәргән иде. Кәрван Гусфәнгә якынлашып килгәндә, ошбу кеше кайтып, Корәеш гарәпләренең рәсүлуллаһның чыгуыннан хәбәр алганлыкларын, аңа Мәккәгә керергә юл бирмәскә карар кылуларын, саклану максаты белән гаскәр әзерләп, Халид бине әл-Вәлид кул астында ике йөз атлы сугышчылардан гыйбарәт бер фирканы рәсүлуллаһка каршы Күрагу әл-Гамимгә чыгарганлыкларын сөйләде.

Рәсүлуллаһ бу хәбәрне ишеткәч, сәхабәләр белән

1 Мәдинәдән алты миль ераклыктагы урын – авт.

2 Ишгарь – дөянең үркәчен җәрәхәтләү; Тәкълид – муенына берәр нәрсә тагу – авт.

киңәшләште. Шул киңәш мәҗлесе нәтиҗәсендә, мәҗбүрият булганда сугыштан тартынмаска карар биреп, юлларын дәвам иттеләр. Күрагу әл-Гамимгә җиткәч, Халид бине әл-Вәлиднең намаз вакытында килеп һөҗүм итү куркынычы булганлыктан, икендене хәвеф намазы итеп укыдылар. Хәдис китапларында «Саләтү Гусфән» дип билгеле булган намаз ошбу намаз булса кирәк[1]. Бу беренче укылган хәвеф намазы иде[2]. Шушы вакытта хәвеф намазы хакында Коръән аяте иңдерелде («Ниса» сүрәсе, 102-103 аятьләр).

## *Худәйбиягә бару*

Рәсүлуллаһның бөтен максаты – Бәйтуллаһны тәваф итү булганлыктан, мөмкин кадәр сугыштан саклану да иде. Туры юл белән киткән хәлдә, Халиднең гаскәре белән бәрелешеп, кан түгеләчәге ихтимал булганлыктан, Мәккәнең түбән ягыннан Худәйбиягә алып чыгачак начар бер юлдан киттеләр. Гаскәр «Сәнийятү әл-Мурар» дигән җиргә җиткәндә рәсүлуллаһның дөясе чүкте, сәхабәләр никадәр кусалар да тормады. Шуннан соң «Касвә чыгымчылады, Касвә чыгымчылады!» – диешә башладылар. Моңа каршы рәсүлуллаһ: «Касвә чыгымчыламады. Чыгымчылау аның гадәте түгел. Аны филне туктаткандай Аллаһы туктатты», – диде[3]. Дөянең чүгүе, Мәккәдә сугыш булып, Бәйтуллаһның хөрмәтен җибәрү тиеш түгел икәнлегенә бер ишарә булган-

1 “Хәләбия”, 3 т., 12 б. – авт.

2 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 368 б. Сира галимнәренең күпчелек фикере белән хәвеф намазы 4 елда “Зәтү әр-Рикагъ” газвәсеннән башлап укылды дисәләр дә, Ибнү Каййим хәзрәтләренең ышандыруы белән бу фикер дөрес түгелдер. “Зәтү әр-Рикагъ” газвәсе Хайбәр сугышыннан соң булды. Имам Бохари да шул фикердә. Кара: “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 268 б. – авт.

3 Касвә – рәсүлуллаһның дөясенең исемедер. Рәсүлуллаһның җавабы "Әсхабү Фил" вакыйгасына ишарәдер - авт.



www.darul-kutub.com

лыктан, рәсүлуллаһ Корәеш гарәпләре тарафыннан нинди генә шартлар күрсәтсәләр дә, Бәйтуллаһны олылап аны кабул итәчәген белдерде. Расулүллаһның кууы белән дөя кузгалып китте. Гаскәр, Худәйбиягә килеп төшеп, Мәккәдән ерак бер тарафка урнаштылар. Халид бине әл-Вәлид боларның Худәйбиягә килеп төшүләрен соңыннан гына сизде.

## *Мәккәлеләр Рәсүлуллаһка кеше җибәрәләр*

Хөрмәтле хаҗилар Худәйбиядә урнашкач, Бүдәйл бине Варка килеп, рәсүлуллаһтан ни өчен Мәккәгә килгәнлеген сорады. Рәсүлуллаһ аңа, сугыш өчен килмичә, фәкать гомрә кылыр өчен генә килгәнлеген әйткәч, Бүдәйл кайтып Корәешкә мәсьәләне аңлатты. Әмма Бүдәйл рәсүлуллаһ яклы Хузәга гарәпләреннән булганлыктан, аның сүзенә колак салмадылар, һаман да мөселманнардан шикләнүдә калдылар. Соңра, эшнең асылын аңлап кайту өчен, Әхәбиш башлыгы булган Хуләйс бине Галкамәне җибәрделәр. Аның килүен күргәч, рәсүлуллаһ сәхабәләргә: «Бу адәм корбанлыкларны олылый торган кавемнән, моның алдына дөяләрегезне җибәрегез!» – диде. Сәхабәләр шунда ук моның алдына дөяләрен җибәреп, тәлбия әйтә башладылар. Хуләйс моны күрү белән кайтып китте һәм Корәеш гарәпләренә: «Болар фәкать гомрә өчен килгәннәр, Ләхм, Жүзәм, Химяр кабиләләре Бәйтуллаһны зиярат итеп торганлыклары хәлдә, Габделмоталлибның улын (Мөхәммәд галәйһиссәламне) хаждан тыю дөрес түгел, аларга Мәккәгә керергә рөхсәт бирергә кирәк», – диде. Корәеш гарәпләре аңа: «Син хәйлә белми торган бер гарәп икәнсең», – дип аны туктаттылар.

Шуннан соң Сәкыйф гарәпләренең башлыкларын-



www.darul-kutub.com

нан Гурвә бине Мәсгудне җибәрделәр. Гурвә рәсүлуллаһ хозурына барып, беркадәр сөйләшкәннән соң, аның гомрә өчен генә килгәнлегенә канәгать булды. Шул вакыт арасында сәхабәләр тарафыннан рәсүлуллаһка күрсәтелгән хөрмәт вә зурлауларны күреп, Гурвә хәйран калды. Корәешкә кайткач: «Мин Кисра, Кайсар, Нәҗәшиләр хозурында булдым. Мөхәммәднең иптәшләре тарафыннан аңа күрсәтелгән хөрмәт вә игътибарны боларның һичберсендә дә күрмәдем. Мөхәммәднең иптәшләре аны җаннарыннан артык күрәләр. Аны һичбер вакыт ташлап качу ихтималлары юк. Сез Мөхәммәднең таләбен кабул итегез, аның белән сугыш була калса, сезнең аларны җиңүегез бик шөбһәле», – мәгънәсендә сүзләр сөйләде.

Рәсүлуллаһ вә сәхабәләргә ачудан күзләрен кан баскан Мәккә мөшрикләре аның нәсыйхәтен кабул итмәделәр, Мәккәгә кертүгә катгый разый булмаганлыкларын белдерделәр. Моннан соң Микраз бине Хәфс исемендәге берәү рәсүлуллаһка янә барып кайтса да, теләгән нәтиҗә булмады.

## *Госманны Мәккәгә җибәрү*

Рәсүлуллаһның Мәккәгә килүдән максаты фәкать гомрә хаҗы булып, сугышу күңелендә булмаганлыктан, ул мөшрикләргә шуны рәсми рәвештә белдерү өчен Госман бине Гаффәнне җибәрде[1]. Аның белән бергә сәхабәләрдән унлап кеше рәсүлуллаһның рөхсәте белән Мәккәдәге

1 Рәсүлуллаһ әүвәл Гомәр бине Хаттабны җибәрмәкче булса да, ул Мәккәдә аны яклаучы якыннары, туганнары булмавын гозер күрсәтеп кабул итмәде. Госман бине Гаффәнне җибәрергә киңәш бирде. Госман Ибне Үмәйядән булып, аның Мәккәдә якларлык якыннары бар иде – авт.

якыннарын зиярат итү өчен киттеләр. Рәсүлуллаһ Госманга Мәккәдә калган зәгыйфь мөселманнарны күреп, якын вакытта Мәккәне мөселманнар кулга төшерәчәген белдерергә кушты. Госман Мәккәдә Әбән бине Сәгыйд әл-Үмәви кулы астында мөшрикләргә рәсүлуллаһның сүзен ирештерсә дә, һаман да башка нәтиҗә кабул итмәделәр. Киресенчә, аны вә иптәшләрен әсирлеккә алдылар. Шул сәбәпле, сәхабәләр арасында Госманның үтерелү хәбәре таралып, рәсүлуллаһ мәккәлеләр белән сугышка әзерләнә башлады.

## *Ризван бәйгате*

Шулай итеп, сәхабәләр Худәйбиядә бер агач күләгәсендә рәсүлуллаһ белән бергә үләргә, аңардан бер карыш качмаска берәм-берәм килеп рәсүлуллаһка бәйгать бирделәр. Иң әүвәл бәйгать иткән кеше Әбү Синән әл-Әсәди иде. Әбү Синән бәйгатьне бик гүзәл рәвештә әйткәнлектән, башка сәхабәләр бәйгать биргәндә: «Сиңа бәйгать биргән нәрсәләргә бәйгать бирәбез», – диләр иде. Рәсүлуллаһның бер кулын икенче кулына куеп: «Бу – Госман өчен булсын», – дип бәйгать кабул итүе риваять ителәдер. «Ризван бәйгате» исеме белән билгеле булган бәйгать ошбу вакыйгадан гыйбарәттер[1].

Бу арада мөшрикләрдән бер кадәресе белән сәхабәләр арасында бәрелешү булып, мөшрикләрдән унике кеше әсиргә дә алынды.

1 Бу бәйгатькә “Ризван бәйгате”, агачка да “Ризван агачы” диюләре “لَقَدْ رَضِيَ اللَّهُ عَنِ الْمُؤْمِنِينَ إِذْ يُبَايِعُونَكَ تَحْتَ الشَّجَرَةِ”[“Сугыштан кайтмыйча, үлгәнче мөшрикләр белән сугышырга дип, агач төбендә сиңа бәйгать бирүче сәхабәләрдән Аллаһы, шиксез, разый булды.”] “Фәтх” сүрәсендәге 18 аять иңгән өчендер. Гомәр бине Хаттаб заманында бу агачтан тәбәррүк кыла башлаганлыктан, ул аны кистереп ташлатты – авт.



www.darul-kutub.com

## *Мәккәлеләр Рәсүлуллаһка хаҗ кылырга рөхсәт бирәләр*

Бәйгать хәбәре Мәккә мөшрикләренә ишетелгәч, алар куркып, рәсүлуллаһ белән солых төзү фикеренә килделәр. Моның өчен мәшһүр хатибларыннан Суһәйл бине Гамрне вәкил итеп җибәрделәр. Суһәйл рәсүлуллаһ янына баргач, әсирләрне җибәрүен таләп итте. Рәсүлуллаһ боларны җибәрү Госман һәм аның иптәшләрен җибәрүгә бәйле икәнлекне әйткәч, мөшрикләр аларны җибәрделәр.

Суһәйл тарафыннан рәсүлуллаһка тәкъдим ителгән шартлар дүрт кисәктән гыйбарәт иде: 1) Бәйтуллаһны тәваф итү икенче елга кичектереләчәк. Киләсе елга мөселманнарның Мәккәгә килеп өч көн торырга хаклары булып, шул вакытта халык Мәккәдән чыгып торачак. 2) Мөшрикләрдән Исламиятне кабул итеп, Мәдинәгә барган кешеләр кирәк булганда кайтарылачаклар. Мәккәгә киткән кешеләрне кайтару мәҗбүр ителмәячәк. 3) Корәеш белән мөселманнар арасында ун елга сугыш туктатылачак. 4) Гарәпләрдән үзе теләгән кабилә рәсүлуллаһ гәһеденә, теләгән кабилә Корәеш гәһеденә керәчәкләр[1].

Шул солыхтан өченче маддә мөселманнар кабул итү өчен иң җиңеле һәм иң кирәклесе иде. Чөнки рәсүлуллаһ һәм Корәешләр арасында солых булганда, мөшрикләр белән мөселманнар аралашсалар, Исламның гаять тиз арада таралуында шик юк иде. Хакыйкатьтә, бу вакытка кадәр мөшрикләр белән сугыш мәҗбүри булып, фәкать үзләрен яклау өчен иде. Рәсүлуллаһ һәрвакыт башкалар белән тыныч торуны сөя, алар белән һәрвакыт солых төзүгә әзер иде. Шуның өчен дә

1 Худәйбия килешүеннән соң, Бәнү Бәкер гарәпләре Көрәеш гаһеденә, ә Хузага гарәпләре Рәсүлуллаһ гаһеденә һәм аның яклавына керделәр – авт.

Мәдинәгә килү белән Мәдинә янында булган китап әһелләре белән солых төзеде. Мөмкин булган гарәп кабиләләре белән дә солых төзеде. Әгәр Мәккә мөшрикләре сәхабәләргә иза һәм җәфа кылмасалар, аларны диннәреннән кайтару өчен газапламасалар, рәсүлуллаһка начарлык эшләп тормасалар, аны үз хөрриятендә калдырсалар, рәсүлуллаһ Мәдинәгә күчеп, алар белән сугыш хәлендә булмас та иде. Исламиятнең матлуб дәрәҗәдә таралуына иң беренче чара мөшрикләр белән сугыш мөгамәләсен бетерү булачак иде. Солых маддәләре эчендә мөселманнар мәнфәгатенә каршы һәм алар өчен кабул итү авыр булачак беренче вә икенче маддәләр булса да, өченче маддәнең әһәмиятенә караганда рәсүлуллаһ, Сүһәйл тәкъдим иткән солыхны кабул итү яклы булды. Сәхабәләр башта моңа бик каршы килделәр. Рәсүлуллаһның бу эшенә аслән разый булмадылар. Кәефләре кырылды, күңелләре төште. Хәтта Гомәр кебек бөек бер сәхабә дә рәсүлуллаһ белән бу мәсьәләдә байтак килешмичә йөрде.

Рәсүлуллаһ солыхның беренче шарты турында: «Мин төшемдә күргән сөенечне бу елда булачак димәдем. Киләчәк елда Бәйтуллаһны тәваф итү – шул шатлыкка ирешүдер». Икенче маддәгә килгәндә: «Исламияттән чыгып Мәккәгә киткән кешеләргә безнең ихтыяҗыбыз юк. Исламиятне кабул итеп, Мәдинәгә килгән кешеләрнең яңадан Мәккәгә кайтаруларында да зарар юк, аларга бервакыт иркенлек киләчәк», – дип сәхабәләрне канәгатьләндерергә тырышса да, сүзе күп тәэсир итмәде. Рәсүлуллаһ аларның кәефләре кырылуларына карамастан әүвәлге фикерендә калып, солыхнамәне яздырды. Язучы Гали бине Әбү Талиб иде. Һәр ике тараftан шаһитлар билгеләнелде. Рәсүлуллаһ тарафыннан булган шаһитлар арасында Әбү Бәкер, Гомәр, Габдрахман бине Гауф

www.darul-kutub.com

бар иде[1]. Мөшрикләр тарафыннан шаһитлар Микраз бине Хафс белән Хувайтиб бине Габдүл Гоззә иде. Солыхнамә ике нөсхә булып, берсе Суһәйл бине Гамрдә калды.

Рәсүлуллаһ солыхнамәне: «Бисмилләһир рахманир рахим», – дип башлап язарга теләсә дә, Суһәйл: «Мин мондый нәрсәне белмим, үзебез белгән «Бисмикәллаһүммә»[2], – дип яз диде. Нәтиҗәдә рәсүлуллаһ, Суһәйл теләгәнчә: «Бисмикәллаһүммә», – дип яздырды. Соңра рәсүлуллаһ: «Бу солых Аллаһының рәсүле Мөхәммәд белән Суһәйл бине Гамр арасында», – дип яздырта башлаган иде, Суһәйл моңа каршы: «Әй, Мөхәммәд, синең рәсүл икәнлегеңне белсәк, Мәккәгә керүдән тыймас идек вә синең белән сугышмас та идек. Шуның өчен «Мөхәммәд рәсүлуллаһ» урынына «Мөхәммәд бине Габдулла» дип яздыр», – диде. Рәсүлуллаһ Галигә рәсүлуллаһ сүзен бозып, аның урынына Габдулла дип язарга кушса да, Гали «рәсүлуллаһ» сүзен бозарга разый булмады.

Шуннан соң рәсүлуллаһ үз кулы белән сызды. Сәхабәләрнең мөшрикләргә бик каты ачулары кабарып, сугышка бер ишарәт кенә көтеп торулары, сугыш булган очракта үзләренең җиңүләре бик ихтимал булган хәлдә, рәсүлуллаһның боларның фикерләренә аслән әһәмият итмичә, бу кадәр авыр шартлар белән солых төзүе, бу солыхтан Исламга гаять файдалы нәтиҗәләр туачагын өметләндерә иде. Чыннан да, эш рәсүлуллаһ уйлаганча булды. Худәйбиядә төзелгән солыхтан соң Ислам әһеле мөшрикләр белән аралаша башладылар. Ислам белән башка гарәпләр арасында булган пәрдә күтәрелде. Исламның илаһи дин икәнлегенә ышанучылар күбәеп, мөселманнарның саны шактый артып китте[3].

1 “Ибнү әл-Әсир”, 2 т., 77 б. – авт.

2 “Синең исемең белән, әй Аллаһы” – тәрҗ.

3 Сира әһелләре сүзенә күрә: солых төзегәннән Мәккәне кулга төшергәнчегә кадәр Исламиятне кабул итүчеләрнең саны, бу вакытка кадәр кергәннәрдән күп булмыштыр – авт.

## *Әбү Җәндәл*

Суһәйл бине Гамрнең улы Әбү Җәндәл Исламны кабул иткән булса да, атасы аны бикләп тотып, Мәдинәгә күчүдән тыеп тора иде. Солыхнамә язылган чакта ул ничектер котылып, рәсүлуллаһ янына килде. Суһәйл аны күргәч: «Мөхәммәд, синнән иң беренче башлап аны кайтарып бирүеңне таләп итәм», – диде. Рәсүлуллаһ моңа солыхнамәнең язылып бетмәвен сылтау итеп, аны кайтарып бирмәскә булса да, Суһәйл: «Алайса һичшиксез, синең белән солых итәчәк түгелмен», – диде. Шунлыктан рәсүлуллаһ аны кайтарып бирергә разый булды. Моны күргәч, Әбү Җәндәл сәхабәләргә карап: «Әй, җәмәгать! Ни өчен мине мөшрикләргә бирәсез, минем алар кулында никадәр газаб чиккәнемне белмисезме?» – диде. Рәсүлуллаһның бу мөгамәләсе өчен сәхабәләрнең кәефләре бик нык кырылды[1].

## *Ихрамнан чыгу*

Солых төзү тәмам булгач рәсүлуллаһ сәхабәләргә ихрамнан чыгарга (корбаннарын чалып, чәчләрен алырга) кушса да, солыхның авыр шартларыннан тәэсирләнгән сәхабәләр аңа буйсынуны гаепле күрделәр. Моны күргәч, рәсүлуллаһ кайгылы хәлдә Үмм Сәләмә янына барып, сәхабәләрнең аның сүзен тыңламауларыннан шикаять итте.

1 Гомәрнең: “Ошбу көнгә кадәр миңа аслән шик вә шөбһә төшкәне юк иде. Ошбу вакыт Рәсүлуллаһка барып: “Син хак пәйгамбәр түгелсеңме? Без хак диндә булып, дошманыбыз батыл диндә түгелме? Шулай булгач, ни өчен мондый яман эш эшлибез? Әле аңа мәҗбүрият төшкән юк бит. Син безгә Бәйтуллаһны барып тәваф кылачакбыз дип сөйләмәдеңме?” – диде. Рәсүлуллаһ моңа каршы: “Әйе, мин хак пәйгамбәрмен, без хак диндәбез. Тәваф итәчәгебезне дә сөйләдем, фәкать бу ел димәдем, киләчәк ел таваф итәчәксез”, – диде. Соңра Әбү Бәкергә барып ошбу мәгънәдә сүзләр сөйләдем. Ул да Рәсүлуллаһ әйткәнчә җавап бирде. Соңыннан ошбу эшемә кәфәрат булсын өчен күп гәмәлләр кылдым” – дигәне риваять иteләдер.

Моңа каршы Үмм Сәләмә: «Әй, рәсүлуллаһ, син авыр шартлар белән солых төзедең, моның өчен сәхабәләр гаять кайгыралар, алар гозерледер. Син бер сүз сөйләмәстән ихрамнан чык, моны күреп, алар да синә иярерләр», – диде. Шулай итеп, рәсүлуллаһ корбанын чалып, чәчен алдырып, ихрамнан чыкты. Моны күргәч, сәхабәләр дә озак уйлап тормыйча ихрамнан чыктылар.

## *Худәйбия мөнәсәбәте белән сүрә иңү*

Мәккәдән кайтканда, рәсүлуллаһка «Фәтх» [Җиңү] сүрәсе иңеп, Худәйбия солыхыннан тәэсир булган сәхабәләрнең күңелләрен шатландырды. Алар Худәйбия килешүенең Исламият өчен бик файдалы булачагына, моның хакыйкатьтә фәтех икәнлегенә канәгать булдылар. Солых хакында рәсүлуллаһның фикере туры килеп, үзләренең хаталануын аңладылар. Рәсүлуллаһка каршы кылган кайбер килешсез мөгамәләренә үкенеп истигъфар кылдылар.

## *Үмм Күлсүм бинте Гукбә*

Рәсүлуллаһ вә сәхабәләр Мәдинәгә кайткач, Гукбә бине Мугайтның кызы Үмм Көлсем Исламиятне кабул итеп, Мәдинәгә килде. Аның якыннары артыннан барып, солых буенча Үмм Көлсемне аларга кайтарып бирүне таләп итсәләр дә, рәсүлуллаһ солыхның хатын-кызларны үз эченә алмаганлыгын бәян итеп, аларга тапшырмады.

Ошбу мөнәсәбәт белән «Мүмтәхинә» сүрәсендәге 10-11 аятьләр иңеп, күчеп килгән хатыннарны имтихан кылырга, иман китергәнлекләре исбат ителсә, күчүләре башка дөньяви максатлар өчен булмыйча, бары тик Аллаһы риза-

лыгы өчен икәнлеге ачыкланса, Мәккәгә кире кайтармаска, мөшрик ирләреннән аерып, аларның биргән мәһерләрен кайтарып бирергә кушты. Шушы күчеп килгән хатыннарның башка ирләргә кияүгә чыгарга хаклары барлыгы бәян ителде. Моннан соң сәхабәләргә мөшрик хатыннарын никахларында тотмаска, аларны аерып җибәрергә кушылды. Шуңа нигезләнеп сәхабәләр мөшрик хатыннарын талак кылдылар[1].

## *Әбү Бәсыйр*

Худәйбия солыхыннан соң бераз вакытлар үткәч, Әбү Бәсыйр исемле берсе Исламиятне кабул итеп, Мәдинәгә килсә дә, рәсүлуллаһ аны кабул итмәгәнлектән, Шам юлында бер җиргә барып урнашты. Югарыда зекер ителгән Әбү Җәндәл дә мөшрикләрдән котылып, Әбү Бәсыйр янына барды. Сахра гарәпләреннән дә бик күп кеше болар янына җыелып, Шам юлыннан үткән мөшрикләр кәрваннарына һөҗүм итә башладылар. Аларның талауларыннан туйган мөшрикләр, рәсүлуллаһка илче җибәреп, ясаган солыхның икенче маддәсен бозуын үтенделәр. Шулай итеп, солыхның икенче маддәсе бетерелеп, Ислам кабул итеп Мәккәдән Мәдинәгә килгән кешеләр кайтарылмас булдылар.

Худәйбия солыхына бәйле булган «Бәкара» сүрәсендәге 190-203 аятьләр иңеп, Хәрам айларында сугышу, хаҗ, гомрә, ихсар[2] хөкемнәрен бәян итте.

1 Шул вакыт Гомәр бине әл-Хаттаб Мәккәдә мөшрик булган ике хатынын талак кылды. Шул хатыннарның берсенә Сафвән бине Үмәйя, берсенә Мугавия никахланды. – авт.

2 Хаҗ кылуны туктаткан каршылыклар – тәрҗ.

## *Патшаларга илчеләр җибәрү*

Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлеге гарәп кавеменә генә махсус булмыйча, бөтен халыкка да кагыладыр. Коръәни Кәримдәге

«قُلْ يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنِّي رَسُولُ اللَّهِ إِلَيْكُمْ جَمِيعًا»[1],
«وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا كَافَّةً لِّلنَّاسِ بَشِيرًا وَنَذِيرًا»[2],
«وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا رَحْمَةً لِّلْعَالَمِينَ»[3]

аятьләре моны ачык күрсәтәдер. Әмма Худәйбия солыхына кадәр рәсүлуллаһ, Корәеш гарәпләре белән сугыш хәлендә булып, алар белән мәшгуль булганлыктан, Исламны чит халыкка ирештерә алмый тора иде. Ул бу вакытка кадәр бары тик гарәп халкын вә якын-тирәдәге китап әһелләрен генә дингә дәгъвәт итә алды.

Худәйбия солыхы төзелгәннән соң Корәеш мөшрикләреннән һәм болар сәбәпле башка бик күп гарәп кабиләләреннән куркыныч беткәч, рәсүлуллаһның иң беренче эше якын тирәдәге хөкүмәт вә әмирлекләргә илчеләр җибәреп, аларны дингә өндәү булды. Күрше мәмләкәтләргә дингә дәгъвәт итеп илчеләр җибәрү алтынчы ел ахырларында яки җиденче елның мөхәррәм аеннан башлап, рәсүлуллаһның вафатына кадәр дәвам итте.

www.darul-kutub.com

1 «Әйт: «Әй, кешеләр! Тәхкыйк, мин барчагызга – бөтен дөнья кешеләренә Аллаһыдан җибәрелгән рәсүлдер» – мәгънәсендә. «әл-Әгъраф»/158. – тәрҗ.

2 «Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, Без сине барча дөнья кешеләренә шатландыручы (җәннәт белән) һәм куркытучы (җәһәннәм белән) итеп җибәрдек» – мәгънәсендә. «Сәбә»/28. – тәрҗ.

3 «Әй, Мөхәммәд галәйһиссәлам, Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен җибәрдек» - мәгънәсендә. «әл-Әнбия»/107. – тәрҗ.

## *Мөһер ясату*

Рәсүлуллаһ бу вакытка кадәр язган мәктүбләрендә мөһер кулланмый торган иде. Патшаларны дәгъвәт итү мәсьәләсен сәхабәләргә сөйләгәч, алар патшаларга җибәреләчәк мәктүбләрнең мөһерле булуы тиешлеген әйткәннән соң, көмештән бер йөзек койдырып, кашына өч юл итеп «Мөхәммәд рәсүлуллаһ» дип яздырды[1]. Бу сүзләрдән «Аллаһы» сүзе өстә, «рәсүл» сүзе уртада, «Мөхәммәд» сүзе аста иде.

Худәйбия солыхыннан соң рәсүлуллаһ төрле җиргә алты илче җибәрде. Рум императоры кайсар Һираклийга Дихъятүл Кәльбине, Иран кисрасы Пәрвизгә Габдулла бине Хузәфәтү әс-Сәһмине, Хәбәшә нәҗәшиенә Гамр бине Умәйя әз-Замрине, Мисыр мукаукисы Җәриж бине Минәга Хатиб бине Әбү Бәлтәганы, Гассән хөкемдаре Җәбәлә бине әл-Әйһәмгә Шүҗәгъ бине Вәһбне[2], Ямәмә әмире Һәүзә бине Галигә Сәлид бине Гамр әл-Гамирине җибәрде. Ошбу кешеләрнең һәркайсына мәктүбләр язып, барысына да бер көндә җибәрелүен риваять итәләр. Моннан башка Гумән әмирләре Җәйфар һәм Габдкә Гамр бине әл-Гасны, Бәхрайн вәлие әл-Мүнзир бине Сәвига әл-Галә бине әл-Хазрамины[3], Харис бине Габдү Күләл әл-Хумәйригә Мүһәҗир бине Үмәйя әл-Мәхзумине, Зүл Күләгъ әл-Хумәйри белән Зү Гамр әл-Хумәйригә Җәрир бине Габдулла әл-Бәҗәлине[4] җибәрде.

---

1 Бу мөһер, рәсүлулаһтан соң Әбү Бәкер, Гомәр, Госман тарафыннан да кулланылды. Госман чорында исә, Госманның кулыннан "Әрис" исемле коега төшеп югалды. Мөслими, 2 т., 214 б. – авт.

2 Ибн Һишам, 2 т., 393 б. – авт.

3 Гамр бине әл-Гасның баруы 8 елның зөлкагъдә аенда, әл-Галә бине әл-Хазраминың җибәрелүе 8 елны Җәгъранәдән кайтыр алдыннан иде. "Зәдүл-мәгад", 1 т., 31 б. – авт.

4 Болар Исламны кабул иттеләр. Җәрир рәсүлуллаһ вафат булганда, һаман да алар янында иде. "Зәдүл-мәгад", 1 т., 31 б. – авт.

Мүсәйләмә әл-Кәззәбкә ике мәртәбә хат җибәрде. Берсе Гамр бине Үмәйя әз-Замри, икенчесе әс-Сәим бине әл-Гавәм аркылы. Хумәйриләрдән Габду Күләл балалары Харис, Мәсрух, Нәгыймгә Гыяш бине Рабига әл-Мәхзумине җибәрде[1].

## *Кайсарга мәктүб*

Шәркый Рум императоры кайсар Һираклий бу вакытларда Кудуста иде. Иранлылар белән булган сугышта румлылар җиңгәч, кайсар Сүрия өлкәсен төзекләндерү өчен һәм шөкер йөзеннән Кудус-шәрифне зиярат өчен Кудуска килгән иде. Дихъя мәктүбне Кайсарга Кудуста тапшырды. Мәктүбнең эчтәлеге шуннан гыйбарәттер: «Аллаһының колы вә рәсүле Мөхәммәдтән Рум кавеменең иң олугы Һираклийга. Тугры юлга ияргәннәргә сәлам булсын. Мин сине Исламга дәгъвәт итәм. Исламга килсәң, сәламәт булырсың, Аллаһы сиңа әҗереңне ике өлеш кылыр (берсе – хәзрәти Гыйса галәйһиссәламгә, икенчесе – Мөхәммәд галәйһиссәламгә иман китергән өчен). Әгәр кабул итмәсәң, бөтен кавемеңнең гөнаһы сиңа төшәчәк. Әй, китап әһеле, сезнең белән безнең арада уртак булган, ифрат һәм тәфриттан пакь бер сүзгә килегез: Аллаһыдан башка һичкемгә гыйбадәт итмик, Аңарга һичкемне тиңдәш кылмыйк. Әгәр китап әһеле моңа каршы килсә, әйтегез: «Без мөселманбыз, моңа шаһит булыгыз, – дип»[2]. Кайсар мәктүбне укыгач, ул вакытларда сәүдә өчен Шам тарафына барган Әбү Сафүән вә иптәшләрен чакыртып, рәсүлуллаһ хакында Әбү Сафүәннан сорашты. Әбү

1 “Зәдүл-мәгад”, 1 т., 31 б. Харис бине Габду Күләлгә ике мәртәбә җибәргән буладыр. Бер үзенә генә, икенчесе бер туганнары белән бергә – авт.

2 Гарәпчә мәктүб сүрәте: “بسم الله الرحمن الرحيم
من محمد عبد الله ورسوله الى هرقل عظيم الروم.
سلام على من اتبع الهدى، أسلم تسلم، أسلم يؤتك الله أجرك مرتين، فإن توليت فان عليك إثم الأريسيين ،يا أهل الكتاب تعالوا الى كلمة سواء بيننا وبينكم ألا نعبد الا الله ولا نشرك به شيئاً ولا يتخذ بعضنا بعضاً أرباباً من دون الله فان تولوا فقولوا اشهدوا بأنا مسلمو” – авт.

Сафүән ул вакытларда мөшрик булса да, рәсүлуллаһ хакында дөресен җавап бирде. Әбү Сафүән белән Кайсар арасында сөйләшкән сүзләр Бохарида зекер ителгән[1]:

– Сезнең арагызда Мөхәммәд нәсебе белән нинди кеше?

– Асыл нәсебле.

– Аңардан элек арагызда дәгъвәт иткән пәйгамбәр булдымы?

– Юк.

– Аның ата-бабаларыннан патша булган кеше бармы?

– Юк.

– Аңа ияргән халык югары катламга яисә түбән катламга карыймы?

– Түбән катламга.

– Аңа ияргән кешеләр артамы, кимиме?

– Арта.

– Аның диненә кергәннәрдән кире кайтучылар бармы?

– Юк.

– Пәйгамбәр булганчы, аның ялган сөйләгәнлеген ишеткәнегез булдымы?

– Юк.

– Гаһеден бозганы бармы?

– Юк, хәзер аның белән безнең арада гаһед бар, бозармы-юкмы, белмим.

– Аның белән сугышканыгыз бармы?

– Бар.

– Кайсыгыз җиңде?

– Кайсы вакытта ул, кайсы вакытта без.

---

1 Бохари, 1 т., 908 б. – авт.

– Сезгә нәрсәләр йөкли?

– Бары тик Аллаһыга гыйбадәт итегез, Аңа гыйбадәттә һичкемне тиңдәш кылмагыз, ата-бабаларыгызның динен ташлагыз, ди. Намаз укырга, сәдака бирергә, гыйффәтле булырга, туганлык хакын сакларга куша.

## *Кисрага мәктүб*

Ул вакытта Иран дәүләтенең башкаласы Мәдәин шәһәре иде. Габдулла бине Хүзәфа Мәдәингә барып, кисра Пәрвизгә мәктүбне тапшырды. Мәктүбнең эчтәлегендә: «Аллаһының рәсүле Мөхәммәдтән Иранның бөеклесе кисрага. Туры юлга кереп, Аллаһыга вә рәсүленә иман иткән, Аллаһыдан башка хакыйкый мәгъбуд юк, Аның тиңдәше юк. Мөхәммәд Аллаһының колы вә рәсүле дип шәһадәт биргән кешеләргә сәлам булсын. Мин сине Исламга дәгъвәт итәм. Чөнки мин – Аллаһы тарафыннан бөтен дөнья халкына җибәрелгән рәсүлмен. Мин халыкны вәгазьлим. Карышкан кешеләргә газабның булуы белән куркытам. Исламга килсәң, сәламәт булырсын. Әгәр карышсаң, бөтен мәҗүсиләрнең гөнаһлары сиңа төшәчәк.»[1]

Кисра, мәктүбне укыгач, тәкәбберлек вә горурлыгыннан бик каты ачуланып, мәктүбне ерткалап ташлады. Илчегә дә: «Әгәр миннән элек илчеләрне үтерү гадәте булса, сине үтерер идем», – диде.

Рәсүлуллаһ кисраның шул мөгамәләсен ишеткәч: «Аллаһы аның милкен таркатып бетерсен», – дип дога кыл-

1 Гарәпчәсе: "بسم الله الرحمن الرحيم. من محمد رسول الله الى كسرى عظيم فارس، سلام على من اتبع الهدى، وآمن بالله ورسوله، وشهد أن لا إله الا الله وحده لا شريك له، وأن محمداً عبده ورسوله، وأدعوك بدعاية الله، فاني أنا رسول الله الى الناس كافة، لينذر من كان حياً ويحق القول على الكافرين، فأسلم تسلم، فان أبيت فان إثم المجوس عليك." – авт.

ды. Шуннан озак вакыт үтмәде, Иран дәүләте мөселманнар тарафыннан алынды. Кисра моның белән генә калмыйча, Хәбәшә башлыгы Бәзәнгә рәсүлуллаһны тотып җибәрергә кушып мәктүб язды.

Гарәп тарихчыларының сүзенә караганда, Бәзән рәсүлуллаһка ике кеше җибәреп, шулар белән кисрага барырга әмер итә, итәгать итмәсә, үтерергә куша. Шул илчеләргә рәсүлуллаһ кисраның инде үтерелүен хәбәр итә. Илчеләр Исламиятне кабул иткәннәр. Соңра вакыйганы кайтып Бәзәнгә сөйләгәч, хәбәрнең дөреслеген белгәч, Бәзән дә Исламияткә килә.

## *Нәҗәшигә мәктүб*

Нәҗәшигә җибәрелгән Гамр бине Үмәйягә ике боерык тапшырылды. Берсе мәктүбне тапшыру, икенчесе Әбү Сафүән бине Хәрб кызы Үмм Хәбибә белән никахлану турысында нәҗәшидән арадашлык итү вә Хәбәшә мөһаҗирләрен Мәдинәгә озатуны үтенү иде.

Гамр Хәбәшәгә барып нәҗәшигә мәктүбне тапшырды. Мәктүбдә ошбу сүзләр язылган иде: «Аллаһының рәсүле Мөхәммәдтән Хәбәшәнең бөеге Нәҗәшигә. Мин шул Аллаһыга мактау әйтәм ки, Аннан башка мәгъбуд юктыр. Ул – Мәлик, Куддус, Сәләм, Муэмин, Муһәймин. Шәһадәт итәм ки, Гыйсә Мәрьям улы Аллаһының рухы вә кәлимәсе. Аллаһы Тәгалә аны таййб, гафиф һәм бутүлә (дөньядан киселгән) белән Мәрьямгә бирде. Мәрьям аның белән йөкле булды. Аллаһы адәмне яраткан кебек Гыйсәне дә рух вә өрүдән мәхлүк кылды. Мин сине тиңдәше булмаган бер Аллаһыга итагать итүгә, бу хакта миңа ияргергә вә миңа килгән нәрсәгә иман итәргә дәгъвәт итәм. Мин

www.darul-kutub.com

Аллаһының рәсүлемен. Сине вә халкыңны Аллаһы Тәгаләгә дәгъвәт итәм. Мин сезгә җиткердем вә нәсыйхәт кылдым. Нәсыйхәтемне кабул итегез. Һәм һидаяттә булганнарга сәлам.»[1]

## *Үмм Хәбибәне хатынлыкка алу*

Нәҗәши рәсүлуллаһның хаты буенча вәкаләте белән Умму Хәбибәне никахландырды. Умму Хәбибә ире Гобәйдулла бине Җәһш белән Мәккәдән Хәбәшәгә күчеп килгән иде. Гобәйдулла Хәбәшәдә насарияткә күчеп вафат булып, Үмм Хәбибә тол калган иде. Аллаһы һәм рәсүленең ризалыгы өчен Ватанын ташлап чит җирләргә күчеп киткән, иренең вафаты белән күңеле сынган, шәрәфле бер хатынның күңелен табуга моннан да артык юл булырмы? Нәҗәши сәхабәләрне көймәләргә утыртып җибәргән иде.

Сира галимнәренең күпчелеге Вакиди һәм Ибнү Исхакларга ияреп, нәҗәшинең Исламга килүен сөйлиләр. Алар нәҗәшинең рәсүлуллаһ мәктүбенә җавап язуын һәм мәктүбнең сурәтен дә тәкъдим итәләр. Рәсүлуллаһның сәхабәләргә Асхамә исемле бер нәҗәшинең вафаты хакында сөйләве һәм аңа җеназа намазы укуы турында «Бохари»да риваять ителә[2]. Гомәр һәм Үмәйя илче булып барган нәҗәшинең Исламга килүе хәбәренең төп чыганагы шушы Бохари хәдисе булса кирәк. Ләкин «Са-

---

1 ‟بسم الله الرحمن الرحيم. من محمد رسول الله إلى النجاشي عظيم الحبشة، سلام على من اتبع الهدى، أما بعد: فإني أحمد إليك الله الذي لا إله إلا هو الملك القدوس السلام المؤمن المهيمن، وأشهد أن عيسي بن مريم روح الله وكلمته ألقاها إلى مريم البتول الطيبة الحصينة، فحملت بعيسي من روحه ونفخه، كما خلق آدم بيده، وإني أدعو إلى الله وحده لا شريك له، والموالاة على طاعته، وأن تتبعني، وتؤمن بالذي جاءني، فإني رسول الله صلى الله عليه وسلم، وإني أدعوك وجنودك إلى الله عز وجل، وقد بلغت ونصحت، فاقبل نصيحتى، والسلام على من اتبع الهدى).

2 Бохари, 2 т., 86 б, 88-89 бб. Хәдис Әду Һурайра белән Җәбирдән риваять ителә. “Асхәмә” гыйбарәсе Җәбир хәдисендә әйтелә – авт.



www.darul-kutub.com

хих Мөслими»[1]дә Әнәс риваятенә күрә, рәсүлуллаһ язган нәҗәши Исламга килмидер. Ибнү Кайим хәзрәтләре дә Мөслими сүзен җөпләп, рәсүлуллаһ мәктүб язган нәҗәши Исламга килмәде, рәсүлуллаһка иман итеп сәхабәләрне кул астына алган, рәсүлуллаһ аңа җеназа намазы укыган нәҗәши башка иде ди[2]. Ибнү Хәрам хәзрәтләре дә шул фикердәдер. Чыннан да шулай булырга кирәк. Чөнки нәҗәшинең рәсми рәвештә Исламга килеп, рәсүлуллаһка мәктүб язуы гаять еракtыр. Әгәр бу эш булса, Хәбәшә белән Мәдинә арасында мөнәсәбәт башка төрле булыр иде. Хәбәшәгә динне өйрәтер һәм тарату өчен рәсүлуллаһ тарафыннан кешеләр җибәрелер иде. Хәбәшәдә шул вакыт Ислам күпмедер таралган булыр иде. Хәлбуки, Хәбәшә мөһаҗирләре кайтканнан соң, анда Ислам әсәре калмаганлыгы тарихта мәгълүм нәрсәдер. Сира галимнәре, рәсүлуллаһның Исламны кабул иткән әмирләргә дин өйрәтү өчен кешеләр җибәргәнен зекер иткән хәлдә, бу хосуста берни дә сөйләмиләр. Әгәр Хәбәшә хөкемдары рәсми рәвештә Исламга килгән булса, моның турыда берәр сүз булыр иде. Ул вакытта Хәбәшә мөһаҗирләре дә кайтып китмәсләр яки алар арасында яңадан баручылары да булыр иде. Алар анда торырга иялә шкәннәр иде бит.

Гамр бине Үмәйя илче булып барган нәҗәшинең сәхабәләрне көймәләрдә озатуы, Умму Хәбибәне рәсүлуллаһка алып бирүе, аның мөселман булганлыгына дәлил түгелдер. Чөнки аның мөселман булмый торып ук шундый яхшы мөгамәлә кылуы мөмкин. Кайсар, мукаукыйслар да

1 Әнәстән риваять ителә: “Пәйгамбәребез (Аллаһының салаваты һәм сәламе булсын) кисрага, кайсар белән нәҗәшига һәм башка бөекләргә Аллаһы юлына дәгъвәт итеп мәктүбләр язды. Әмма бу нәҗәши пәйгамбәребез (Аллаһының салаваты һәм сәламе булсын) җеназа намазы укыганы түгелдер” – мәгънәсендә. Мөслими, 2 т., 81 б. – авт.

2 “Зәдүл-мәгад”, 1 т., 30 б.; 2 т., 56 б. – авт.

илчеләрне ихтирам итеп, бүләкләр белән кайтарганнар иде. Шуның кебек бу да рәсүлуллаһка яхшылык кылгандыр. Гарәбстанда баш калкытып килгән яшь хөкүмәтнең әллә нинди бәлаләр чыгару ихтималы аларның күңелләренә шик салмый калмагандыр.

Кыскасы, сира галимнәренең күпчелеге, рәсүлуллаһ мәктүб язган нәҗәшинең Исламга килүе хакындагы риваятьләре «Зәдүл-мәгад» сахибе әйткәнчә, шөбһәле фикерләр. Рәсүлуллаһ «изге кеше» дип атаган һәм җеназа намазы укыган нәҗәши башкасыдыр. Ул пәйгамбәрлекнең бишенче елында һиҗрәт иткән сәхабәләрне кулы астына алган һәм аларга яхшы мөгамәлә күрсәткән нәҗәшидер. Аның рәсми рәвештә Исламга килүе мәгълүм түгелдер. Рәсүлуллаһ аның мөселман булуын вәхи аркылы гына белмештер. Бу хәлдә җеназа намазы укуы да Ибнү Исхак әйткәнчә тугызынчы елда булмыйча, Хайбәр елына кадәр буладыр.

## *Мукаукиска мәктүб*

Бу вакытларда Мисыр мәмләкәте көнчыгыш Рум империясенә кереп, мукаукис Рум императорлары тарафыннан куела иде. Мукаукис Искәндәрия шәһәрендә тора иде. Илче Хатыйб Искәндәриягә барып, мәктүбне мукаукиска тапшырды. Мәктүбнең мәгънәсе шушыдыр: «Аллаһының колы һәм рәсүле Мөхәммәдтән кыйбт кавеменең бөеклесе мукаукыйска. Тугры юлга ияргәннәргә сәлам булсын. Мин сине Исламияткә дәгъвәт итәм. Исламияткә килсәң, сәламәт булырсың. Аллаһы сиңа әҗереңне ике өлеш кылыр. Әгәр каршы килсәң, кыйбт халкының гөнаһысы сиңа төшәр. Әй, китап әһеле, сезнең белән безнең арада уртак булган, ифрат һәм тәфрыйттан

пакь булган бер сүзгә килегез: Аллаһыдан башка һичкемгә гыйбадәт итмик, Аңарга һичкемне тиңдәш кылмыйк. Аллаһыдан башка бер-беребезне «рабб» итеп алмыйк. Әгәр китап әһеле моңардан баш тартса, Ислам әһеле әйт: «Без мөселманбыз, моңа шаһит булыгыз, – дип».

Мукаукис Исламны кабул итмәсә дә, илчене бик ихтирам итте вә аның белән Рәсүлуллаһка җавап язды һәм ике гүзәл җәрия, бер качыр вә башка бүләкләр биреп озатты[1]. Мукаукис тарафыннан язылган мәктүбнең мәгънәсе: «Мөхәммәд бине Габдуллага кыйбт кавеменең бөеге мукаукистан. Мәктүбеңне укыдым. Ни сөйләгәнеңне вә нинди нәрсәгә дәгъвәт иткәнеңне аңладым. Мин тагы бер пәйгамбәр киләчәген белә идем. Ләкин аның Шамнан чыгачагын уйлый идем. Синең илчеңне ихтирам иттем һәм сиңа кыйбт халкы арасында зур урын тоткан ике җәрия вә кимнәр бирдем. Сиңа менеп йөрер өчен бер качыр да тәкъдим итәм. Вәссәлам».[2] Рәсүлуллаһ мукаукисның җавабы килгәч: «Ул кулыннан мөлке китүдән куркып, Исламны кабул итмәде, ләкин мүлке фанидыр», – диде. Чыннан да, озак вакыт үтмәде, Мисыр мәмләкәте мөселманнар тарафыннан алынды.

## *Гассан әмиренә мәктүб*

Гассан әмире ул вакытта Димәшкъта, үзенең резиденциясендә тора иде. Илче Шуҗәгъ бине Вәһб мәктүбне шунда тапшырды. Мәктүбдә бер Аллаһыга

---

1 Җәрияләрнен берсе Мария, берсе Сирин иде. Рәсүлуллаһ Марияне үзенә алды һәм ул хатыннан Ибраһим исемле малае туды. Сиринне Хәссән бине Сәбиткә бүләк итте. Рәсүлуллаһтан соң хәзрәти Гали атланып йөргән һәм “Дүл-дүл” дип танылган качыр шушыдыр – авт.

2 “(?) بسم الله الرحمن الرحيم.
لمحمد بن عبد الله من مقوقس عظيم القبط ، أما بعد ، فقد قرأت كتابك وفهمت ما ذكرته وما تدعو إليه ، وقد علمت أن نبيًا بقى وقد كنت أظن أن يخرج بالشام، وقد أكرمت رسولك ، وبعثت إليك بجاريتين لهما مكان من القبط عظيم ، وبكسوة ، وأهديت إليك بغلة لتركبها .. والسلام”

гына иман китерергә дәгъвәт ителгән иде. Кабул итмәгән тәкъдирдә, мөлкенең кулыннан китүе белән кисәтелгән иде. Ул мәктүбне укыгач, ачуы килеп хатны җиргә ташлады һәм Мәдинәгә һөҗүм итү белән янады. Ләкин Һираклий моңа рөхсәт бирмәгәнлектән, илчегә яхшылык кылып, бүләкләр белән озатты. Рәсүлуллаһ илчедән моның шундый мөгамәләсен ишеткәч: «Мүлке бетсен», – дип дога кылганы риваять ителәдер.

Күпчелек сира галимнәре рәсүлуллаһның Шуҗәгъ бине Вәһбне әл-Харис бине Әбү Шәмр әл-Гассанигә җибәрүен сөйлиләр. Ибн Һишам исә, моны Җәбәлә бине әл-Әйһәм, ди. «Зәдүл-мәгад» сахибе Шуҗәгъның Җәбәләгә җибәрелү ихтималы ышанычлырак дип саный. Шуҗәгъның Җәбәләгә җибәрелүен Вакиди белән Ибн Исхак та зекер итә. Ләкин аның Җәбәлә бине әл-Әйһәм һәм әл-Мунзир бине әл-Харис бине Әбү Шәмрларга җибәрелүе хакында да риваятьләр бар. Җәбәләгә җибәрелүе Вакидидан, әл-Мунзирга җибәрелүе Ибн Исхактан риваять ителә. Кайберәүләр моның Харис бине Әбү Шәмр белән бергә Җәбәләгә дә җибәрелүен сөйлиләр. «Камус әл-Әгъләм» сәхибы да шуны әйтә (4 т., 2843 б.).

Безнеңчә, Ибне Һишам сүзе дөрес булып, башка сира галимнәренең сүзе шикле булса кирәк. Шулай итеп, югарыда әйтелгәнчә, әл-Харис бине Әбү Шәмр бу вакытларда исән түгел иде. Гарәп тарихчылары аны «Мүнәзира», «Мүлүке-л-Киндә» һәм «Әййәмү гарәб» хакында сүз сөйләгәндә кабатлап зекер итәләр. Алар аны Мүнәзирадән (Хира хөкемдарлары) әл-Мунзир бине Мәүссәмәгә гасырдаш булып, аның белән сугышларда булуын бәян итәләр. Хәлбуки, әл-Мунзир бине Мәүссәмә кисралардан Әнуширван белән гасырдаш иде. Ул аның заманында милади буенча 563 елда вафат булды.

www.darul-kutub.com

Мәшһүр «Гайнү Әбәгъ» вакыйгасы мәзкүр әл-Мүнзир белән әл-Харис бине Әбү Шәмр арасында иде. Бу вакытта алар икесе дә карт кешеләр иде инде. Харисның бу сугышта ике улы үтерелгәнлеге дә риваять ителә. Шулай булгач, аның 628 елда, ягъни хөкемдарларга мәктүбләр язылган елга кадәр сәламәт булуы мөмкин түгелдер. Аның соңында гарәп тарихчылары Харис бине Әбү Шәмрнең Сәмуәл бине Гадия, Имру әл-Кайс, Галкамә әл-Фәхл вә Гамр бине Күлсүм белән булган вакыйгаларын зекер итәләр. Хәлбуки, Имре-л-Кайс 560 елда, Сәмуәл 560 елда, Галкамә 561 елда, Гамр бине Көлсем 600 елда вафат булдылар. Димәк, гарәб тарихчылары сүзләренә караганда, Харис бине Әбү Шәмрнең Мүкәтәбә елына кадәр сәламәт булуы мөмкин түгелдер. Гарәп тарихчылары моннан башка Харис бине Әбү Шәмр исемендәге хөкемдарны зекер итмиләр. Мәзкүр Харисның атасы Җәбәлә исемле булып, Әбү Шәмр атасының кушаматыдыр.

Гассанлылардан Харис бине Җәбәлә исемле ике хөкемдар булса да, берсе аның күп еллар алдан яшәгән. Соңгысы Харис бине Җәбәләне исә Ибне-л-Әсир «әл-Кәмил»ендә (2 т., 193 б.), Хәмзә әл-Исфаһани «Тарихү сәне-л-мүлүк» исемле китабында (моны остаз Ризаэтдин хәзрәт китапханәсендә язма нөсхәдә күрдек) Харис бине Әбү Шәмр дип аңлаталар. Мәшһүр тарихчы Георгий Зидан хәзрәтләре «Әл-гарәб кабле-л-Ислам» китабында гассанлылар хакында күп мәгълүмат биргән. Ул язган сүзләрендә гарәп тарихчыларының фикеренә генә таянмый, моны көнбатыш галимнәре сүзләре белән дә чагыштырып карый. Юнан [грек] чыганакларыннан алып, әл-Харис бине Әбү Шәмр хакында байтак сүз яза. Аның Рум патшаларының дәгъвәте белән 560 елны Канстантыниягә [Константинополь] барганын һәм 569

елда вафат булганын сөйли. Югарыда зекер иткәнчә, гарәб тарихчыларының бәянына күрә дә, ул шул вакытларда вафат булганга охшый.

Шулай ук әл-Мүнзир бине әл-Харис бине Әбү Шәмрга мәктүб җибәрелү риваяте да дөрес булмаса кирәк. Чөнки гарәп тарихчылары каршында Харисның хөкемдарлык кылган әл-Мүнзир исемле улы юктыр. Харисның улы Җәбәләнең әл-Мүнзир исемле улы булса да, ул хөкем сөрмәгән. Юнан тарихында әл-Мүнзир бине әл-Харис бине Әбү Шәмр исемендә берәр хөкемдар булса да, ул 582 елда вафат булган. Шулай булгач, әл-Мүнзиргә мәктүб җибәрелү риваяте бөтенләй хата яки әл-Мүнзир бине әл-Харис гассанлылардан берәр вәли булып, рәсүлуллаһ аңа да Шуҗәгъ бине Вәһбне җибәргән буладыр. Мәсәлән, Йәмәндәге кечерәк түрәләргә дә мәктүбләр җибәрелгән иде.

Без Ибн Һишам сүзен өстенрәк күреп, Шуҗәгъ бине Вәһбнең Җәбәлә бине әл-Әйһәмгә җибәрелү риваятен дөресрәк дибез. Георгий Зидан югарыда зекер ителгән «Нүлдеки»дән алып, аның 613 елдан 636 елга кадәр хөкем сөргәнлеген күрсәтә. Икенче бер урында юнән чыганакларыннан алып булса кирәк, Җәбәлә бине әл-Әйһәмнең соңгы Рум-Иран сугышында Һираклийга зур хезмәт кылганлыгын сөйли. Бу сүзләрдә безнең фикеребезгә куәт бирәдер.

## *Бәхрайн вәлисенә мәктүб*

Бәхрайн вәлисе әл-Мүнзир бине Сәви, рәсүлуллаһның мәктүбен алгач, озак уйламыйча Исламны кабул итте. Кавеменә Исламны кабул итәргә тәкъдим иткәч, китап әһелләреннән вә мәҗүсиләрдән башкалары риза булды.

Әл-Мүнзирнең Исламны кабул итмәгән китап әһелләре вә мәҗүсиләр хакында рәсүлуллаһның фикерен сорап, ошбу мәгънәдә мәктүб язганлыгы риваять ителәдер[1]: «Әй, рәсүлуллаһ, синең мәктүбеңне Бәхрайн халкына укыдым, алардан Исламиятне яраткан вә яратмаганнары булды. Яратканнары кабул иттеләр. Минем җиремдә яһүдләр вә мәҗүсиләр бар. Алар хакында ни эшләргә кушасың?»
Аңа каршы рәсүлуллаһтан әл-Мүнзиргә шөкер кылып, вәгазь вә нәсыйхәт кылып, яһүд вә мәҗүсиләрдән җизья [салым] алырга кушып, үзен әүвәлге урында калдырганлыгын, юлын үзгәртмәсә төшермәячәген бәян итеп мәктүб язганлыгын сира галимнәре риваять итәләрдер[2]. Шуннан соң Бәхрайн җирлегендә булган мәҗүси вә яһүдләрдән һәр балигъ кешегә бер динар (алтын) җизья салынды[3].

## *Оман әмирләренә мәктүб*

Оман әмирләре Җәйфәр һәм Габдкә язылган мәктүбнең эчтәлеге шуннан гыйбарәттер[4]: «Аллаһының колы вә рәсүле булган Мөхәммәдтән әл-Җүләнди угыллары Җәйфар белән Габдкә туры юлга ияргәннәргә сәлам булсын. Мин сезне Исламияткә дәгъвәт итәм. Исламиятне кабул

1 Мәктүбнең гарәпчәсе: “أما بعد. يا رسول الله فإني قرأت كتابك على أهل البحرين. فمنهم من أحب الإسلام و أعجبه و دخل فيه و منهم من كرهه و بأرضي مجوس و يهود فأحدث إليَّ في ذلك أمرك” – авт.

2 Мәктүбнең гарәпчәсе: "بسم الله الرحمن الرحيم"
“من محمد رسول الله الى المنذر بن ساوي،
سلام عليك فاني أحمد اليك الله الذي لا إله الا هو وأن محمداً عبده ورسوله، أما بعد، فاني أذكرك الله عز وجل، فانه من ينصح فانما ينصح لنفسه، وإنه من يطع رسلي ويتبع أمرهم فقد أطاعني، ومن نصح لهم فقد نصح لي، وإن رسلي قد أثنوا عليك خيراً، واني قد شفعتك في قومك، فاترك للمسلمين ما أسلموا عليه، وعفوت عن أهل الذنوب، فاقبل منهم، وإنك مهما تصلح فلم نعزلك عن عملك. ومن أقام على يهوديته أو مجوسيته فعليه الجزية” – авт.

3 Ибнү әл-Әсир, 2 т., 82 б. – авт.

4 Мәктүбнең гарәпчәсе: “بسم الله الرحمن الرحيم من محمد رسول الله إلى جيفر وعبد ابني الجلندي السلام على من اتبع الهدى أما بعد فإنني ادعوكما بدعاية الإسلام اسلما تسلما فاني رسول الله إلى الناس كافة لأنذر من كان حيا ويحق القول على الكافرين وأنكما ان أقررتما بالإسلام وليتكما وان أبيتما ان تقرا بالإسلام فان ملكما زائل عنكما وخيلي تطأ ساحتكما وتظهر نبوتي على ملككما” – авт.



www.darul-kutub.com

итсәгез, үзегезне саклаган булырсыз. Мин дөньяда булган кешеләрне вәгазь кылыр өчен, инкарь кылучыларны газап белән куркыту өчен Аллаһы тарафыннан җибәрелгән бөтен кешелек дөньясына рәсүлмен.

Әгәр сез Исламны кабул итсәгез, сезне үз урыныгызда калдырачакмын. Әгәр кабул итмәсәгез, сезнең мөлкегез озак булмаячак. Минем гаскәрем, сезнең җирегезне таптап, минем пәйгамбәрлегемне сезгә изһар итәчәк».

Болар башта Исламиятне кабул итмәскә тырышсалар да, илче Гамр бине әл-Гас тарафыннан төрле дәлилләр белән Мөхәммәднең Аллаһы тарафыннан җибәрелмеш пәйгамбәр икәнлеген, Исламиятнең аермалыкларын, өстенлекләрен бәян иткәннән соң алар Исламиятне кабул иттеләр. Гамр бине әл-Гас рәсүлуллаһның вафатына кадәр болар арасында яшәде.

## *Йәмәмә әмиренә мәктүб*

Йәмәмә әмире Һәүзә бине Галигә язылган мәктүбтә, Исламны кабул иткән дәвердә аны үз урынында калдыру вәгъдә ителә. Кабул итмәгән очракта, мөлке бетүе һәм Ислам гаскәре тарафыннан кулга алыну турында кисәтелә. Һәүзә хатны китерүче Сүләйт бине Гамрны ихтирам итеп, аңа бүләкләр биреп озатты. Рәсүлуллаһка каршы мәктүб дә язды. Фәкать җавапта рәсүлуллаһка иярмәвен мөлектә бергә булуына бәйләде. Рәсүлуллаһ моның хатын укыгач: «Бер бармак кадәр җир сораса да бирмәс идем. Үзе дә һәлак булачак, мөлке дә бетәчәк», – диде. Һәүзә рәсүлуллаһ Мәккәне үз кулына алып кайтканда вафат булды. Күп вакыт үтмәстән Йәмәмә вилаяте мөселманнар кулына күчте.



www.darul-kutub.com

Югарыда күрсәтелгән кешеләрдән башка да сира галимнәре рәсүлуллаһның Басра әмиренә хат язып, Харис бине Гумәйр әл-Әзди аркылы җибәргәнен сөйлиләр. Ләкин аның исемен зекер итмиләр. Илче Муэтәгә җиткәч, Шурәхбил бине Гамр әл-Гассани тарафыннан үтерелде диләр. Зекер ителәчәк «Муэтә» сугышын сәбәп итеп, шушы вакыйганы сөйлиләр. Безнеңчә бу әмир Җәбәлә бине әл-Әйһәм яки аның тарафыннан билгеләнгән берәр вәли булса кирәк.

Рәсүлуллаһның әбисе, Гайшәнең әнисе Умму Румән шушы елда вафат булды.

# Җиденче ел

## *Хайбәр газвәсе*

Худәйбия килешүе төзелеп, мөшрикләр тарафыннан куркынычлар беткәч, рәсүлуллаһ мөселманнарның иң зур вә иң куәтле дошманнары булып, һәрвакыт аларга мәшәкатьләр чыгарып торган Хайбәр яһүдләренә җәза бирү өчен гаскәр әзерләде. Худәйбиядән кайтканда аңа Аллаһы Тәгалә «Фәтх» сүрәсен иңдереп, Худәйбия солыхы рәсүлуллаһ вә мөселманнарга бик файдалы бер килешү икәнлеген бәян иткән вә Хайбәрнең яулап алыначагы турында мөселманнарга шатлык хәбәре биргән иде. Нәтиҗәдә, рәсүлуллаһ җиденче елның мөхәррәм аенда бер мең дә дүрт йөзгә (алар эчендә ике йөз атлылар иде) кадәр гаскәр белән Хайбәргә юнәлде. Болар эчендә Худәйбия вакыйгасында катнашкан сахра гарәпләре дә бар иде. Сахра гарәпләреннән бик күбесе бу

сугышка чыгарга теләсәләр дә, максатлары фәкать ганимәт малы алу булганлыктан, рәсүлуллаһ аларга: «Теләсәгез чыгыгыз, ләкин сезгә ганимәт малы бирелмәячәк», – дигәч, алар чыкмадылар. Сугышка рәсүлуллаһның хатыны Үмм Сәләмә белән берничә сәхабия дә чыкканнар иде. Мәдинәдә Сибәгъ бине Гурфәтә  әл-Гифәри калды.

Юлда барганда рәсүлуллаһнын Гамир бине Әквәгъка шигырь сөйләргә кушуы, Гамирнең дә рәсүлуллаһ кушуы буенча гүзәл тавыш белән көйләп баруы риваять ителәдер.

Гаскәр таңга каршы Гатафан белән Хайбәр арасында «Раҗигъ» исемендәге бер җиргә урнашты. Бу җирне сайлау Гатафан кабиләсенең яһүдләргә ярдәмен кисү өчен иде. Иртә белән коралларын күтәреп эшкә чыкканда Хайбәр халкы рәсүлуллаһның гаскәрен күреп шашып калды һәм кальгаларына кереп бикләнде.

Хайбәр аерым-аерым Нәта, әш-Шикъ, әл-Кәсибә дигән өч тороктан гыйбарәт булып, боларның әүвәлгесе – өч (Хисну Нәгыйм, Хисну Сәгъб, Хисну Кыйлля), икенчесе – ике (Хисну Убә, Хисну Бәри), өченчесе – өч (Хисну Камус, Хисну әл-Ватих, Хисну әс-Суләлим) кальгаларыннан гыйбарәт иде. Рәсүлуллаһ башлап әүвәлге кальгаларны камап алырга карар биреп, аларның кояш чыга торган тарафына, ук барып җитә алмаслык урынга гаскәрен урнаштырды. Дошманны бирелүгә мәҗбүр итү нияте белән, хөрмә агачларын кисәргә әмер итте. 400 хөрмә агачы киселеп, аңардан һичбер файда булмагач, кисүдән тукталып, Хисну Нәгыймгә ук ата башладылар. Ошбу кальганы алты көн камап торган хәлдә һичбер нәтиҗә чыкмады. Бу вакыт рәсүлуллаһ байракны чират буенча һәр көнне сәхабәләрдән берсенә бирә иде. Кич белән гаскәрне каравыллау өчен сакчылар да куя иде.

Алтынчы көннең кичендә нәүбәтче Гомәр бине әл-Хаттаб кальгадан чыккан бер яһүдине тотып рәсүлуллаһ хозурына китерде. Яһүди рәсүлуллаһ аңа иминлек бирсә, кайбер серләрне сөйләячәген белдерде. Рәсүлуллаһ моңа иминлек бирде. Шуннан соң яһүди: «Кальгадагы халык бик нык арыды, бала-чагаларын Хисну әш-Шикъка күчерделәр, иртәгә сезнең белән сугышка чыгачаклар. Әгәр шул кальганы ала алсагыз, анда тимер кием, кылыч һәм диварны тишә һәм таш ата торган кораллар булган бер урынны күрсәтәчәкмен. Аларны кулга төшерсәгез, башка кальгаларны алу сезгә кулай булачак», – диде. Шул кичне рәсүлуллаһ: «Иртәгә байракны Аллаһы вә рәсүле аны сөя, ул да Аллаһыны вә рәсүлен сөя торган кешегә бирәчәкмен», – диде. Сәхабәләрнең һәркайсы байракның үзенә бирелүен өмет итеп йокларга ятты. Хәтта Гомәр бине әл-Хаттабның: «Бу көнге кебек вазыйфаны теләгәнем юк иде», – дигән сүзе риваять ителәдер.

Иртә белән рәсүлуллаһ Гали бине Әбү Талибны чакырып, байракны аңа бирде.

## *Мубәразә*

Гаскәр кальгага якынлаша башлады. Бу вакыт дошман да сугышка әзерләнеп тора иде. Ике тараф гаскәре берберсенә каршы сафка баскач, яһүдләрдән берсе мәйданга чыгып, мубәразә таләп итте. Гали бине Әбү Талиб чыгып, аны үтерде. Соңра дошманның иң баһадирларыннан булган Мәрхәб чыгып, аның белән сугышуны таләп иткәч, Мөхәммәд бине Мәсләмә рәсүлуллаһтан рөхсәт алып, аңа каршы чыкты вә беркадәр алышканнан соң аны үтерде. Шуннан соң Мәрхәбнең бертуган кардәше Ясир чыкты. Моны

www.darulkutub.com

Зубәйр бине әл-Гаввәм үтерде. Моннан соң Ислам гаскәре бик каты һөҗүм итеп, кальгага керде. Дошман моңа якын булган «Хисну Сәгъб»кә качты. Сәгъбтә дошман нык каршылыклар күрсәтеп, Ислам гаскәрен җиңүгә якынлашсалар да, ахырда Хуббәб бине Мүнзир һәм башка берничә кешенең гайрәте белән бу ныгытманы да кулга алуга ирештеләр. Бу ике кальгада Ислам гаскәре бик күп азык ганимәт алды.

Ошбу кальгалар алынгач, яһүдләр Кыйлләгә кереп бикләнде. Ул да камап алынды, ләкин бик нык булып, дошман да зур гайрәт күрсәткәнлектән, өч көн дәвам иткән камап тору бер нәтиҗә дә бирмәде. Ниһаять, дүртенче көнне әсир төшкән бер яһүднең өйрәтүе буенча, кальгага керә торган суны туктатып, дошманны аннан чыгарга мәҗбүр иттеләр. Кальгадан чыгып дошман озак сугыша алмады, җиңелеп, әш-Шикъка качып бикләнде. Ислам гаскәре аларны куып, Убә кальгасын камап алды. Ләкин ничә көннәрдән бирле сугышкан вә камалу астында калган дошман никадәр каршы торырга тырышса да, җиңелеп, әл-Бәри кальгасына качты. Үбәне алуда иң зур батырлык күрсәткән кеше – Әбү Дүҗәнә әл-Әнсари иде. Әл-Бәридә дошман нык каршы торганлыктан, таш ата торган корал кулланырга туры килде. Дошман гаскәре мөселманнарга каршы тора алмаганлыктан, әл-Кәсибә кальгасына качарга мәҗбүр булды. Әл-Кәсибәдә иң элек әл-Камус камап алынды. Ул Хайбәр кальгаларыннан иң зурысы вә иң ныгытылганы иде. Шуның өчен дә Ислам гаскәре аны яулап алуда гаять зур мәшәкатьләр чикте. Ниһаять, егерме көн дәвам иткән камау соңында Гали бине Әбү Талиб җитәкчелегендә җиңүгә ирештеләр. Зекер ителгән кальгада Хүяй бине Әхтабның кызы Сафия әсир алынды.

Моннан соң калган ике әл-Вәтих һәм әс-Сүләлим

кальгаларында дошман артык каршы тормады, солых килешүе сорарга мәҗбүр булды. Ошбу кальгада 100 тимер кием, 400 кылыч, 100 сөңге, 500 җәя ганимәт алынды.

## *Солых*

Солых буенча Хайбәр яһүдләре, өсләрендәге киемнәреннән башка һичнәрсә алмыйча, хатын вә балалары белән Хайбәрне ташлап китәргә булдылар. Ләкин соңыннан, яһүдләрнең үтенүе буенча, Хайбәрдә җыелган уңышның яртысын биреп тору шарты белән рәсүлуллаһ аларны Хайбәрдә калдырды. Әмма теләгән вакытта аларны чыгарырга ихтыярлы иде.

Солых төзегәндә рәсүлуллаһ яһүдләргә Хайбәрдәге малларны яшермәскә шарт иткән, яшергән кешене үтертәчәген әйткән иде. Рәсүлуллаһ Кинәнә бине әр-Рабигъны Хүяй бине Әхтабдан калган гаять кыйммәтле зиннәтләрне яшереп тотканга үтертте. Хайбәр сугышында Ислам гаскәреннән шәһид булган кешеләр унбиш булып, дошманнан туксан өч кеше үтерелде.

## *Сафиягә өйләнү*

Әсир алынган Сафия бинте Хүяй Исламны кабул иткәнлектән, рәсүлуллаһ аны үзенә никахлады. Атасы, ире вә башка бик күп якыннары үтерелеп, күңеле сынык булган бер хатынның хәтерен табу вә күңелен шатландыру өчен моннан да яхшы ысул юк иде.

www.darul-kutub.com

## *Рәсүлуллаһка агулы ит тәкъдим итү*

Хайбәр фәтех ителеп солых төзелгәч, Сәллам бине Мүшкәм хатыны Зәйнәб бинте әл-Харис куй ите пешереп, рәсүлуллаһ вә сәхабәләргә тәкъдим итте. Рәсүлуллаһ итне авызына алу белән агуланганлыгын сизеп, итне кире төкерде. Сәхабәләрдән Бәшәр бине әл-Бәрра агуланып вафат булды. Яһүдия чакырылып, кылган эшенең сәбәбе соралды. Моңа каршы ул: «Әгәр пәйгамбәр булса, аңа зарар итмәс, әгәр ялганчы булса, аңардан котылырбыз дип эшләдем бу эшне», – диде. Рәсүлуллаһ моны башта гафу итсә дә, Бәшәр бине әл-Бәрра вафат булганлыктан, касас белән үтертте. Ошбу агу рәсүлуллаһка тәэсир итеп, аңардан һәрвакыт зарланганлыгы, хәтта үлем алдыннан чирләгән вакытында да шуны исенә төшереп, авыруын шуннан күргәнлеге риваять ителәдер.

## *Хәбәшәдән мөһаҗирләрнең кайтуы*

Рәсүлуллаһ Хайбәрне җиңгән вакытларда Хәбәшәдәге мөһаҗирләрнең ахыргылары булган Җәгъфар бине Әбү Талиб, Әбү Муса әл-Әшгари вә иптәшләре кайтып җиттеләр. Рәсүлуллаһ вә сәхабәләр аларны күреп бик шатландылар. Рәсүлуллаһ Җәгъфарның маңгаеннан үбеп: «Белмим, нәрсә өчен шатланыйм, Хайбәрне алу беләнме, әллә Җәгъфарның кайтуы беләнме», – дигәне риваять ителәдер.

Бу вакытларда Исламны кабул иткән Әүс кавеме рәисләре Гамир бине әт-Туфәйл белән бергә Мәдинәгә һиҗрәт итеп килде. Рәсүлуллаһның Хайбәрдә икәнлеген белгәч, бер сәгать тормыйча аңа ярдәм итәргә Хайбәргә киттеләр. Ләкин болар Хайбәргә җиткәндә, Хайбәр алын-

ган иде инде. Ошбу килгән кешеләр арасында мәшһүр Әбү Һурәйра дә бар иде.

Хайбәр ганимәтеннән рәсүлуллаһ Хәбәшә мөһаҗирләренә һәм Әүс әһленә дә өлеш чыгарды. Хайбәр ганимәтләре икегә бүленеп, бер өлеше рәсүлуллаһның үзенә булды. Бу өлештән рәсүлуллаһ үзенең хатыннарына, якыннарына (Габделмоталлиб вә Һашим балаларына) һәм башка ихтыяҗы булган кешеләргә өлеш чыгарды. Калган өлеш атлыга өч, җәяүлегә бер өлеш итеп сугышчыларга бүлеп бирелде.

## *Фәдәкнең алынуы*

Хайбәрне алгач, рәсүлуллаһ Хайбәргә якын булган Фәдәк яһүдләренә Мүхәйяса бине Мәсгудне җибәреп, аларның бирелүләрен таләп итте. Карышкан очракта аларны Хайбәр яһүдләре язмышы көткәнлектән, ярты җирләрен биреп, рәсүлуллаһ белән солых төзеделәр[1]. Фәдәк җирен рәсүлуллаһ сәхабәләргә бүлеп бирмәде. Чөнки бу җир атлар вә дөяләр кулланып, мәшәкать белән алынмыйча, җиңеллек белән кулга төшерелде. Бу җирдән керемне рәсүлуллаһ үзе вә өй әһелләре, юлчылар һәм мохтаҗлар файдасына вә гомумән мәмләкәт ихтыяҗларына сарыф итә иде.

## *Вәди әл-Кураның алынуы*

Хайбәр вә Фәдәкне алып Мәдинәгә кайтышлый, рәсүлуллаһ Вәди әл-Кураны алыр өчен шул авылга килде. Вәди әл-Кура яһүдләре, алдан әзерләнмәгән булсалар

1 Фәдәк халкы хәзрәти Гомәр заманына кадәр җирләрендә калдылар. Аның хәлифлек иткән чорда, яһүдләрне Хиҗаздан сөрүгә карар бирелгәч, боларның җирләрен гадел кешеләрдән кыйммәтен хисаплатып, акчасын бирде. Соңра болар Шам тарафына җибәрелделәр. Ибн әл-Әсир, 2 т., 85 б. – авт.

да, рәсүлуллаһның гаскәрен ук белән атып каршы алдылар. Рәсүлуллаһ гаскәрен сафка тезеп, әләмне Сәгъд бине Губәдәгә бирде. Сугышка керешкәнче, боларны Исламга дәгъвәт итсә дә, кабул итмәделәр. Киресенчә, каршы торырга карар бирделәр.

Сугыш мүбәразә белән башланып, кичкә кадәр дәвам итте. Сугыш барышында мөселманнардан берәү, яһүдләрдән унөч кеше үтерелде. Бу кадәр гаскәргә каршы торып файда чыкмаячагын аңлаган яһүдләр иртә белән рәсүлуллаһка бирелергә мәҗбүр булдылар. Рәсүлуллаһ Вәди әл-Курада дүрт көн калып, алынган ганимәтләрне гаскәргә бүлеп бирде. Соңра Хайбәр яһүдләренә куйган шартлар бәрабәренә алар белән солых төзеп, Мәдинәгә кайтты. Рәсүлуллаһ заманында Хайбәр вә Вәди әл-Курадагы уңышларның бәясен билгеләү өчен Габдулла бине Равәхә, ул «Муэтә»дә шәһид булгач, аның урынына Җәббәр бине Сахр бине Үмәйя бара иде.

## *Тәймә солыхы*

Хайбәр вә Вәди әл-Кура яһүдләренең хәбәре Тәймә яһүдләренә ирешкәч, рәсүлуллаһка илче җибәреп, һәр елны билгеләнгән микъдарда җизья биреп тору шарты белән солых төзеделәр.

## *Халид бине әл-Вәлиднең вә аның иптәшләренең Исламга килүләре*

Ислам гаскәре Хайбәр сугышыннан кайткач, Мәккә мөшрикләреннән Халид бине әл-Вәлид, Гамр бине әл-Гас вә Госман бине Әбү Талхә Мәдинәгә килеп Исламны кабул иттеләр[1].

1 Ибнү әл-Әсир болар 8 елда Исламга килделәр ди – авт.

Рәсүлуллаһ вә сәхабәләр аларның Исламиятне кабул итүләренә бик шатландылар. Чөнки алар өчесе дә Мәккәнең бөекләреннән вә шәрифлеләреннән иделәр. Халид бине әл-Вәлид бер баһадир вә җитәкче булып, Гамр бине әл-Гас та алдынгы кеше иде. Мондый кешеләрнең мөшрикләрдән аерылулары мөшрикләр өчен зур югалту булды. Моннан соң мөшрикләрнең куәте кимеде. Ислам әһелләренең куәте артты вә рухлары күтәрелде. Халид бине әл-Вәлид рәсүлуллаһка: «Әй, рәсүлуллаһ, сиңа каршы бик күп сугышларда булдым, моны гафу ит, Аллаһыдан миңа гафу сора», – диде. Моңа каршы рәсүлуллаһ:

«الإِسْلَام يَجُبُّ مَا قَبْلَهُ»[1]

–дип җавап бирде. Рәсүлуллаһ Халид бине әл-Вәлид вә Гамр бине әл-Гасны бик күп сугыш сәфәрләренә башлык итеп җибәрде.

## *Әбү Бәкер сәриясе*

Нәҗед тарафында Ибне Фәзәра гарәбләренә Әбү Бәкер әс-Сиддыйк кул астында бер сәрия күндерелгән иде (шәгъбан аенда). Сәрия мәзкүр кавем белән сугыш кылып җиңде вә беркадәр ганимәт вә әсирләр алып, Мәдинәгә кайтты. Сәрия гаскәрләреннән Сәләмә бине әл-Әквәгъка бик матур бер кыз эләккән иде. Рәсүлуллаһның соравы буенча Сәләмә ул кызны аңа бүләк итте. Соңра рәсүлуллаһ ул кызны Мәккәгә җибәреп, андагы әсирләргә алмаштырды.

1 «Ислам әүвәлге гөнаһларны гафу итә» – дигән мәгънәдәдер – авт.

## *Гомәр сәриясе*

Шул ук шәгъбан аенда «Түрабә»[1] исемендәге җирдә Сәкинү Һәвәзин гарәпләренә Гомәр бине әл-Хаттаб җитәкчелегендә утыз кешедән гыйбарәт бер сәрия җибәрде. Ләкин алар сәриянең килүен алдан ук белеп, качып беттеләр. Гомәр бине әл-Хаттаб сугышмыйча, беркадәр ганимәт алып, Мәдинәгә кайтып китте.

## *Бәшир бине Сәгъд сәриясе*

Шул ук шәгъбан аенда Рәсүлуллаһ Фәдәк тирәсендәге Ибне Мурра гарәпләренә Бәшир бине Сәгъд кул астында утыз кешедән гыйбарәт бер сәрия җибәрде. Сәрия дошман җиренә җиткәндә, анда һичкем булмаганлыктан, малларын куып алып китәләр. Ләкин дошман эшне сизеп, артларыннан куа чыкты. Ике арадагы каты сугышта сәхабәләр җиңелеп, бөтенесе шәһид булдылар. Бары тик сәрия башлыгы җәрәхәтләнгән хәлдә, үзе генә Мәдинәгә кайта алды.

## *Галиб бине Габдулла сәриясе*

Җиденче ел рамазан аенда Рәсүлуллаһ Галиб бине Габдулла әл-Ләйси җитәкчелегендә йөз утыз сәхабәдән торган бер сәрия җыеп, Мәйфәга халкына җибәрде. Ошбу кавем белән булган канлы сугышта сәрия җиңеп, ганимәт вә әсирләр алып, Мәдинәгә кайтты. Үсәмә бине Зәйд, дошман гаскәреннән берсен куып артыннан җиткәч, дошман шәһадәт кәлимәсен әйткән иде. Үсәмә моңа карамыйча аны үтерде. Сәрия Мәдинәгә кайтып Үсәмәнең хәбәре рәсүлуллаһка

1 Мәдинәнең көньягында ике көнлек ераклыкта урнашкан бер вәдидер. – авт.

ишетелгәч, моны бик каты орышты. Үсәмә: «Әй, рәсүлуллаһ, ул бит үлемнән куркып кына шәһадәт кәлимәсен әйтте», – дисә дә, рәсүлуллаһ: «Син аның калебен ярып карамадың бит», – диде. Усәмәнең шушы мөселманны үтерүе хата булганлыктан, рәсүлуллаһ аңа бер колын азат итәргә әмер итте. «Ән-Ниса» сүрәсенең 94 аяте шушы хакта иңдерелгән, диләр.

## *Бәшир бине Сәгъд сәриясе*

Ошбу елның шәүвәл аенда рәсүлуллаһка Гуяйнә бине Хисннның Гатафан кабиләсеннән «Ямн» вә «Җүббәр»[1]дә тора торган бер җәмәгатьне мөселманнар белән сугыш өчен җыюы ишетелде. Аларга каршы рәсүлуллаһ Бәшир бине Сәгъд кул астында өч йөзгә кадәр сәхабә җибәрде. Алар дошман җиренә җитеп, малларын тартып алдылар. Дошман сәриянең килүен ишетеп качты. Юлда Гуяйнәнең бер шымчысын тотып үтерделәр. Соңра Гуяйнә гаскәренең бер өлешенә очрап сугыштылар, дошманны җиңделәр вә ике әсир алып Мәдинәгә кайттылар. Ошбу әсирләр Мәдинәгә кайткач, Ислам динен кабул итте.

## *Зәтү әр-Рикәгъ газвәсе*

Нәҗед тарафында Сәкинү Ибне Мухәриб вә Бәну Сәгъләбә гарәпләренең рәсүлуллаһ белән сугышка әзерләнгәнлекләре ишетелде. Шуның өчен рәсүлуллаһ җиде йөзгә кадәр гаскәр белән боларга каршы сәфәр итте.

Мәдинәдә үз урынына Госман бине Гәффәнне калдырды. Рәсүлуллаһ килүен ишетеп, дошман тауларга качып

1 Су исемнәредер – авт.

бетте. Соңра Ислам гаскәре белән сугышка әзерләнеп каршы чыксалар да, сугыш булмады. Бу газвәдә дошманның килеп һөҗүм итү куркынычы булганлыктан, «Хавеф намазы»[1] укыганнары риваять ителәдер. Ошбу газвә сугыш булган урынга нисбәт итеп «Зәтү әр-Рикагъ» диелер яки анда булган сәхабәләр аякларына чүпрәк бәйләгәннәреннән «Зәтү әр-Рикагъ» исеме белән аталадыр.

## *Гомрә казасы*

Худәйбия солыхына бер ел тулгач, рәсүлуллаһ вә сәхабәләр үткән елгы гомрә хаҗларын каза кылу өчен Мәккәгә юнәлделәр. Бу сәфәрдә үткән ел гомрәдә катнашмаган кешеләр дә бар иде. Рәсүлуллаһ урынына Мәдинәдә Әбү Зәрр әл-Гыйффәри калды. Үзләре белән алтмыш корбанлык дөя алып киттеләр. Бу юлы рәсүлуллаһ мөшрикләрнең хыянәтләреннән куркып, саклык өчен кылычлардан башка коралларны да алды. Ихрамны Мәдинә мәчетендә багъладылар. Атлы гаскәрне алга куеп, Мәккәгә юнәлделәр.

1 Сира галимнәренең күпчелеге бу газвәнең дүртенче елда булганлыгын сөйлиләр. “Зәдүл-мәгад” сахибе исә, Хайбәрдән соң җиденче елда булды, ди. Имам Бохари да шушы фикердәдер. Фәкать җөмһүр сүзе туры булмаска кирәк. Чөнки ике сахих китабында килгәнчә, Ислам гаскәре хавеф намазы укылды диелә. Хәлбуки, бишенче елда Хандак газвәсендә нинди мөшкел хәлдә булып та, хавеф намазы укымадылар. Бер көн икенде намазын кояш баегач укыдылар. Башка бер көн иртә намазыннан башка бөтен намазны кич белән укыдылар. Әгәр әр-Рикагъ газвәсе дүртенче елда булган булса, Хандак сугышында хавеф намазы укылган булыр иде. Димәк, Хандак сугышына кадәр хавеф намазы мәшругъ түгел иде булып чыга. Шуңа күрә Зәтү әр-Ридагъ газвәсе дә дүртенче ел булмаган буладыр. Хандак сугышында “мусәяфә” хәле иде, шунлыктан, хавеф намазы укылмады дип котылу да мөмкин түгел. Чөнки Хандак авызында торып, ярты гаскәр белән мөшрикләргә каршы тору мөмкин иде.

Аның соңында Зәтү әр-Рикагъ газвәсендә Әбү Һурайра һәм Әбү Муса әл-Әшгарилар бар иде. Боларның үзләреннән шул сугышта булулары риваять ителә. Хәлбуки, Әбү Муса әл-Әшгари дүртенче елны Хәбәшәдә иде әле. Ул Хайәр яулап алынып беткәндә Җәгъфар бине Әбү Талиб белән кайтты. Әбү Һурайра да Хайбәр алынып торганда гына үзенең кавеме белән рәсүлуллаһка килде. Шулай булгач, бу газвәнең дүртенче елда булуы шикледер. “Зәдүл-мәгад” сахибе югарыдагы дәлилләргә таянып, бу газвәне Хайбәрдән соң булды, ди. Без дә моның куәтле дәлилләренә ияреп, җиденче елга куйдык. Беренче мәртәбә буларак хавеф намазының укылуы, безнеңчә, Худәйбиягә килгәндә Күрәгу әл-Гамим белән Гусфән арасында булмыштыр. Худәйбия килешүен кара – авт.

Марру әз-Заһранга җиткәндә, Корәеш гарәпләреннән бер җәмәгать мөселманнарның әзерлек белән килүен күреп нык курыктылар вә Корәеш гарәпләренә кайтып мәсьәләне сөйләделәр. Моны ишеткәч, Корәеш мөшрикләре эшнең асылын аңлап килү өчен рәсүлуллаһка Мүкраз бине Хафс белән берничә кеше җибәрделәр. Болар рәсүлуллаһның Худәйбия солыхына хилаф буларак корал белән килүенең сәбәбен сорадылар. Рәсүлуллаһ моңа каршы коралны бары саклык өчен алып килгәнлеген, харамга кылычтан башка корал белән кермәячәген анлатты. Харамга якын «Бәтну Нәҗих» дигән җиргә җиткәч, рәсүлуллаһ, кылычтан башка коралларын калдырып, аларны саклау өчен ике йөзгә кадәр гаскәр билгеләде. Соңра дөясенә атланып, сәхабәләр белән гадәттән тыш тантаналы бер төстә Мәккәгә юнәлде. Рәсүлуллаһның дөясен мәшһүр шагыйрь Габдулла бине Равәхә җитәкләгән иде. Ул дөяне җитәкләгән хәлдә: «Аллаһыдан башка мәгъбуд юктыр. Ул үзененең вәгъдәсендә торып рәсүленә ярдәм бирде, мөселманнарны гыйззәтле вә өстен кылды. Мөшрикләрне җиңелдертте», – дигән мәгънәдә сүзләр кабатлады[1].

Ислам әһеле Мәккәгә кергәндә мөшрикләрнең бөекләре, боларның Бәйтуллаһны тәваф итүләрен күрәселәре килмичә, Мәккәне ташлап чыктылар. Рәсүлуллаһ «Хәҗәрү Әсвәд»кә таягы белән кагылды. Мөшрикләргә куәт вә батырлыкларын күрсәтер өчен сәхабәләргә Бәйтуллаһны өч мәртәбә тиз генә тәваф итәргә әмер итте. Чөнки Мәккә

---

1 Габдулла бине Равәхәның Мәккәгә кергәндә түбәндәге бәетләрне иншад иткәне риваять ителәдер:

خَلُّوا بَنِي الكُفَّارِ عَنْ سَبِيلِهِ
خَلُّوا فَكُلُّ الخَيْرِ فِي رَسُلِهِ
يَا رَبُّ إِنِّ مَؤْمِنٌ بِقِيلِهِ
أَعْرِفُ حَقَّ اللهِ فِي قَبُولِهِ
نَحْنُ قَتَلْنَاكُمْ عَلَى تَأْوِيلِهِ
كَمَا قَتَلْنَاكُمْ عَلَى تَنْزِيلِهِ
ضَرْبًا يُزِيلُ الْهَامَ عَنْ مَقِيلِهِ
وَ يُذْهِلُ الخَلِيلَ عَنْ خَلِيلِهِ



www.darul-kutub.com

мөшрикләре сәхабәләрне Мәдинәнең начар һавасы белән зәгыйфьләнгәннәр, дип сөйлиләр иде.

Шуның өчен дә тәваф вакытында иңбашларын вә уң беләкләрен ачып йөрделәр. Сәхабәләр гомрәдән бушангач, коралларны саклар өчен калган затлар килеп тәваф кылдылар. Алар урынына башкалары барып тордылар. Шулай итеп, мөселманнар өч көн Мәккәдә торып, гаять рәхәт вә тынычлык белән гомрә гамәлләрен үтәделәр. Дүртенче көн Сүһәйл бине Гамр һәм Хувәйтиб бине Габдел Гоззә килеп, рәсүлуллаһтан шарт буенча Мәккәдән чыгуын үтенделәр. Бу вакытта рәсүлуллаһ әнсарилар белән сөйләшеп утыра иде. Сәгъд бине Губәдә торып: «Бу синең җиреңмени? Безне чыгарырга ни хакың бар? Без чыкмаячакбыз», – диде. Рәсүлуллаһ боларга мөрәҗәгать итеп: «Мин Мәккәдә бер хатынга өйләндем. Шуның туен ясаганчы торсак булмасмы? Мәҗлес ясап, бергә ашап эчәр идек», – диде. Ләкин болар һаман рәсүлуллаһны чыгарга кыстаганга, мөселманнар карышмыйча, Мәккәдән чыгып киттеләр. Бу гомрәне «Гумратү әл-Худәйбия» вә «Гумратү әл-Кадия» дип тә йөртәләр.

## *Мәймүнәгә өйләнү*

Рәсүлуллаһ Мәккәгә кермәс борын, Җәгъфар бине Әбү Талибне җибәреп, Мәймүнә бинте әл-Харис әл-Һиләлияне үзенә сорады. Мәймүнә эшен Габбас бине Габделмоталлабка тапшырганлыктан, аны рәсүлуллаһка Габбас никахландырды. Рәсүлуллаһ моның куенына Мәдинәгә кайтышлый «Сәриф»тә керде. Бу – рәсүлуллаһның иң соңгы хатыныдыр. Мәймүнә әүвәл Хәмзә никахында иде.

# <u>Сигезенче ел</u>

## *Галиб бине Габдулла сәриясе*

Сигезенче елның сәфәр аенда рәсүлуллаһ, «Кудәйд»[1] исемле урында яшәгән, Ибне әл-Муләввәх гарәпләренә бер сәрия җибәрде. Сәрия башлыгы Галиб бине Габдулла әл-Ләйси иде. Сәрия юлда барганда мөселманнарга гаять дошман булган Харис бине Малик әл-Ләйсине әсир алды. Болар шул кавемнең җиренә җиткәч, аларның йоклаганлыкларыннан файдаланып, малларын алып китсәләр дә, тегеләр сизенеп, бик күп гаскәр белән куа чыктылар. Ләкин кинәттән яңгыр явып, дошман белән Ислам гаскәре арасында булган чокыр ташып, су белән капланды. Шуның өчен сәрия ганимәт малларны югалтмыйча, Мәдинәгә кайтты.

## *Галиб бине Габдулла сәриясе*

Ибне Мурра гарәпләренә жибәрелмеш Башир бине Сәгъд сәриясенең җиңелеп, шәһид булулары югарыда язылган иде инде. Галиб бине Габдулла Ибне Муләввәх гарәпләрен жиңеп кайткач, рәсүлуллаһ аның кул астында, Ибне Мурра гарәпләренә җәза бирер өчен, ике йөз гаскәридән гыйбарәт бер сәрия җибәрде. Сәрия боларның җирләренә барып, бик каты сугышып, аларны җиңде вә бик күп ганимәт вә әсирләр алып, Мәдинәгә кайтты. Ганимәт бүленгәндә сугышчыларның һәрберсенә унар дөя тиде.

1 Гасафәнгә якын бер урын исемедер – авт.

## *Кәгъб бине Гамир сәриясе*

Шам тарафындагы «Зәтү Әтлах» дигән җиргә Кәгъб бине Гумәйр әл-Гыйфари җитәкчелегендә бер сәрия җибәрелсә дә, дошман белән булган сугышта сәриянең саны аз, ә дошманның саны күп булганлыктан җиңелеп, бөтенесе шәһид булдылар. Бары тик башлыклары Кәгъб кенә исән калды. Рәсүлуллаһ вә сәхабәләр бу вакыйгага бик кайгырдылар.

## *Муэтә сәриясе*

Басра әмиренә җибәрелгән илче Харис бине Гамир әл-Әздинең Шурахбил бине Гамр әл-Гассани тарафыннан Муэтәдә үтерелгәнен югарыда язган идек. Бу хәбәр рәсүлуллаһка ишетелгәч, ул бик каты кайгырды. Болардан үч алу өчен өч меңнән гыйбарәт бер сәрия җыеп, Зәйд бине Харисәне гаскәр башлыгы итеп билгеләде. Зәйд шәһид булса, Җәгъфәр бине Әбү Талибның, ул да шәһид булса, Габдулла бине Равәхәнең башлык булачагын әйтте. Ерак җиргә куәтле дошман белән сугышка китәчәк сугышчыларны рәсүлуллаһ үзе озата чыкты вә аларга: «Аллаһының ярдәменә таянып, Шамда булган дошманнарыгыз белән сугышыгыз, әмма гыйбадәт белән мәшгуль булган кешеләргә тимәгез, хатын вә балаларны, карт-корыларны үтермәгез, агачларны кисмәгез, биналарны җимермәгез!» – дип нәсыйхәт бирде.

Гаскәр Шам җиреннән Мәганга җиткәндә румлылар вә аларга буйсынган Ләхм, Җүзәм, Бәһра, Бәли вә Бәлкыйн гарәпләре җыелып, куәтле бер гаскәр туплаганнарын ишеттеләр. Шуңа күрә сәхабәләр рәсүлуллаһка илче

җибәреп, ярдәм сорарга теләсәләр дә, Габдулла бине Равәхә моңа каршы төште. Аның сүзләре белән тәэсирләнгән гаскәр ярдәм сораудан ваз кичеп, алга таба хәрәкәт итте. Румлылар Бәлкәдә Мәшәриф авылына урнашканнар иде. Ислам гаскәре Муэтә авылында урнашты. Ике гаскәр арасында каты сугыш башланып, сәрия башлыгы Зәйд бине Харисә шәһид булды. Шуннан соң, җитәкчелек Җәгъфәр бине Әбү Талибка бирелде. Ул да шәһид булды. Моннан соң командир булган Габдулла бине Равәхә дә шәһид булды. Башлыксыз калган Ислам гаскәреннән кайберләре качарга әзерләнеп, гаскәр бозылырга торганда, Сәбит бине Әркам тәэсирле нотык сөйләп, гаскәрне чыдамлыкка чакырды һәм гаскәр эчендә булган Халид бине әл-Вәлидне гаскәр башлыгы итеп сайларга тәкъдим итте. Шулай эшләделәр дә. Ул көн сугыш кичкә кадәр дәвам итте. Икенче көн иртә белән Халид гаскәрнең тәртибен үзгәртте: алдагы гаскәрне артка, уңдагы гаскәрне сулга күчерде. Ошбу көн румлылар каты һөҗүм итеп, Ислам гаскәрен тар-мар итү ниятендә булсалар да, каршыларында башка гаскәр күреп, Ислам гаскәренә ярдәм килгән дип фараз кылып, куркуларыннан кире чигенделәр. Боларның артларыннан куу гаскәрне куркыныч астына салу булганлыктан, Халид бине әл-Вәлид дошман артыннан бармады. Киресенчә, сәламәт хәлдә Мәдинәгә кайтып китәргә карар бирде. Чыннан да, Халиднең фикере дөрес, аларның исән-сау көенчә Мәдинәгә кайтулары максатка ирешү булып саналачак иде. Чөнки Рум гаскәре аларга караганда бик күп мәртәбә артык булып, алар белән сугышны дәвам иткәндә, мөселманнарның җиңелүләре бик мөмкин иде. Халид бине әл-Вәлиднең хәрби осталыгы белән Ислам гаскәре җиңелүдән котылды. Рум гаскәре дә Ислам гаскәре артыннан сахрага

кереп киткән очракта, үзләре өчен зур һәлакәт булачагыннан, мөселманнар артыннан бармады. Нәтиҗәдә, һәр ике тараф бер-береннән чигенүне өстен күрделәр. Сәрия Мәдинәгә кайткач, каршы алырга чыккан сәхабәләрдән бәгъзеләре аларны җиңелү белән гарьләндерсәләр дә, рәсүлуллаһ: «Юк, алар җиңелмәделәр, киресенчә, җиңделәр» , – диде.

## *Сугыштан файда*

Сәрия башлыкларының шәһид булуларын шул ук көндә рәсүлуллаһның сәхабәләргә хәбәр бирүе, алар үлгәч җитәкчелекне Аллаһы кылычларыннан берсе алды (Халид бине әл-Вәлидне истә тотып) диюе ике сахих китабында риваять ителәдер.

Бу сәрия ул кадәр файда итмәсә дә, сәхабәләрнең иң бөекләреннән өч кеше шәһид китсә дә, моның әһәмияте бик зур булды. Чөнки Ислам дәүләтенең шулкадәр ерак җиргә өч мең кешедән гыйбарәт гаскәр җибәрүе, аның куәт һәм көч җыеп килгәнлеген, башка дәүләтләр арасында аның әһәмияткә алырлык бер дәүләт булып үсә баруын күрсәтәдер. Шәхсән рәсүлуллаһның боларны җибәрүе дә аларның җиңүләрен өмет итеп түгел, бәлки аларны имтихан өчен вә чит мәмләкәтләр белән сугышуга чыныктыру өчендер. Киләчәктә зекер ителәчәк Тәбүк газвәсе дә шул ук максатка нигезләнеп, бер маневрдан гыйбарәт иде. Сәриянең чыгуы җөмадиәл-әүвәл аенда булды.

Рәсүлуллаһ гаскәр башлыкларының шәһид булуларын хәбәр иткәч, Җәгъфәрнең гаиләсе жаһилият гадәте буенча каты тавышланып елашты. Рәсүлуллаһ аларны елаудан тыйды. Болар һаман да елаудан туктамагач, рәсүлуллаһның

Галигә: «Туктамасалар, авызларына туфрак сип», – диюе риваять ителәдер.

## *Зәтү Сәләсил сәриясе*

Ошбу елның җөмадиәл-ахир аенда рәсүлуллаһка «Зәтү Сәләсил» дигән җирдә Сәкинү Кузага гарәпләренең Мәдинәгә һөҗүм итәргә әзерләнгәннәре ишетелде. Шуңа да рәсүлуллаһ Гамр бине әл-Гас житәкчелегендә өч йөз кешедән гыйбарәт бер сәрия күндерде. Дошман җиренә җиткәч, Гамр бине әл-Гас дошманның күплегеннән хәбәр алып, Рафигъ бине Кәгъбне җибәреп, рәсүлуллаһтан ярдәм сорады. Нәтиҗәдә рәсүлуллаһ Әбү Губәйдә бине әл-Җәррах кул астында тагы ике йөз кешелек гаскәр җибәрде. Болар арасында мәшһүр сәхабәләрдән Әбү Бәкер белән Гомәр дә бар иде. Әбү Губәйдә гаскәре Гамр бине әл-Гас гаскәренә барып кушылгач, Әбү Губәйдә намазда имам булып басмакчы булды. Әмма Гамр бине әл-Гас: «Рәсүлуллаһ сине бары тик ярдәмче итеп җибәрде, гаскәрнең әмире мин» – дип, үзе имам булып торды. Әбү Губәйдә моңа каршы килмәде. Ярдәм килү белән Гамр бине әл-Гас гаскәргә хәрәкәт итәргә әмер биреп дошманга каршы юнәлделәр. Ике арада булган сугышта Ислам гаскәре җиңеп, күп ганимәтләр алуга ирештеләр.

Гаскәр Мәдинәгә кайтканда суык бер кичтә гаскәрнең әмире Гамр бине әл-Гаска җөнеблек иреште. Госел коенганда зарар киләчәгеннән куркып, тәяммум белән генә гаскәргә намазда имам булып торды. Мәдинәгә кайткач, сәхабәләр Гамр бине әл-Гасның шул эшеннән рәсүлуллаһка шикаять иттеләр. Рәсүлуллаһ Гамрны чакырып, җөнеб хәлдә намаз укуының сәбәбен сорады. Гамр бине әл-Гас: «Госелләнсәм,

www.darul-kutub.com

зарар итәрмен дип курыктым. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә: «Үз кулларыгыз белән үзегезне һәлакәткә дучар итмәгез, – диде», – дип җавап бирде. Моны ишеткәч, рәсүлуллаһ көлеп җибәрде, Гамрга һичбер сүз әйтмәде[1].

## *Хабат сәриясе*

Рәҗәб аенда рәсүлуллаһ Әбү Губәйдә бине әл-Җәррах кул астында өч йөздән гыйбарәт бер сәрия җыеп, Кызыл диңгез буенда яши торган Җүһәйнә гарәпләре белән сугышырга җибәрде. Бу вакытларда Мәдинәдә ачлык булганлыктан, гаскәрдә бер микъдар хөрмәдән башка азык юк иде. Гаскәр дошман җиренә барып унбиш көн эзләсә дә, дошманны очрата алмады. Гаскәр бу сәфәрдә бик нык ачлыкта калып, агач яфракларын ашау дәрәҗәсенә җитте. Ошбу сәриягә «Хабат сәриясе» дип исем бирелү шуның өчендер. Сәрия сугышмыйча Мәдинәгә кайтты.

## *Мәккәне фәтех кылу*

Худәйбия солыхыннан соң Ибне Бәкр кабиләсенең Корәеш химаясе астына, Ибне Хузәга гарәпләренең рәсүлуллаһ химаясе астына кергәннәре югарыда язылган иде инде. Җаһилият гасырында бу ике кабилә арасында дошманлык булып, һәрвакыт берсе икенчесе белән сугышып торалар иде. Рәсүлуллаһка пәйгамбәрлек килеп, гарәпләрне сыннарга гыйбадәт кылудан тыя, тәүхидкә чакыра башлагач, мөшрикләр үзара дошманлыкларын онытып, рәсүлуллаһка бердәм каршы чыктылар.

Корәеш мөшрикләре белән Ислам әһеле арасын-

1 “Зәдүл-мәгад”, 1 т., 417 б. – авт.



www.darul-kutub.com

да солых төзелгәннән соң, Ибне Бәкер гарәпләре бер форсат китереп, Хузәга гарәпләренә кинәттән һөҗүм итеп, берничә кешене үтерделәр. Корәеш мөшрикләре дә боларга яшерен сурәттә корал вә кешеләр белән ярдәм иттеләр. Корәеш гарәпләренең бу эшләре Худәйбия солыхын аяк астына салып таптау иде. Ошбу вакыйгадан соң Хузәга гарәпләре Корәеш мөшрикләренең хыянәтеннән шикаять итү һәм Ибне Бәкер һөҗүменнән ярдәм сорау өчен Гамр бине Сәлим рәислеге астында бер төркем илче җибәрделәр. Ошбу илчеләр Мәдинәгә барып, рәсүлуллаһка вакыйганы сөйләде вә ярдәм сорады. Рәсүлуллаһ, аларның сүзләреннән тәэсирләнеп, аларга ярдәм итәргә вәгъдә бирде.

## *Әбү Сафүәннең Мәдинәгә баруы*

Корәеш мөшрикләре җинаятьләренең нәтиҗәсе начар булачагын аңлап, эшне төзәтү вә солыхны яңарту өчен Әбү Сафүәнне Мәдинәгә җибәрделәр. Әбү Сафүән Мәдинәгә барып, кызы, мөэминнәрнең анасы Үмм Хәбибә өенә төште. Әбү Сафүән Үмм Хәбибә өендә рәсүлуллаһ утыра торган паласка утырырга теләгәндә, Үмм Хәбибә паласны тартып алды. Моны күреп Әбү Сафүән: «Кызым, паласны миннән җәлләпме, әллә мине паластан җәлләпме тартып алдың?» – диде. Үмм Хәбибә аңа: «Син нәҗес мөшриксең, сиңа рәсүлуллаһ утыра торган паласка утыру дөрес түгел», – диде. Моңа каршы Әбү Сафүән: «Кызым, миннән соң бозылгансың икән», – диде.

Моннан соң Әбү Сафүән рәсүлуллаһка барып, солыхны яңарту турында сүз башласа да, аңардан бер җылы сүз ишетмәде. Эшнең рәсүлуллаһка сизелгәнен аңлап, бөек мөһаҗирләр Әбү Бәкер, Гомәр, Гали соңра Фатыймадан

рәсүлуллаһ белән килешү хакында ярдәм итүләрен үтенсә дә, һичберсеннән теләгән җавап ала алмады. Ниһаять, кайгылы бер хәлдә Мәккәгә кайтырга мәҗбүр булды.

## *Мәккәне алу өчен әзерләнү*

Рәсүлуллаһ Корәеш мөшрикләре белән никадәр тыныч тору вә солыхны дәвам иттерү тарафында булса да, мөшрикләрнең ошбу мөгамәләләре Ислам әһеленең шәраф вә абруена орыну һәм аларга уенчык итеп карау булганлыктан, аларның үзләре кебек эшкә әзерләнергә карар бирде. Бигрәк тә Худәйбия солыхыннан соң мөселманнарның саны күбәеп, куәте вә көче арткан иде, мөшрикләр исә болар белән чагыштырганда загыйфь булганга, мөселманнарга каршы тора алмаулары аңлашыла иде.

Мөшрикләрнең солыхны бозулары, кан түкмичә генә Мәккәне җиңүгә, Бәйтуллаһны сыннардан арындырып, Исламиятне бөтен Гарәп ярымутравына таратуга бер форсат иде. Шуның өчен рәсүлуллаһ шул форсатны уңай күреп, Мәккәне фәтех кылу өчен гаскәр әзерли башлады. Мәдинә тирәсендә булган мөселман сахра гарәпләренә дә әзерләнергә кушты. Гаскәрнең кайда сәфәр итәчәкләрен халыкка мөмкин кадәр белдермәскә кушты. Чөнки рәсүлуллаһның максаты Мәккәне кан түкмичә алу иде. Моның өчен хәбәрнең Мәккә мөшрикләренә ирешмәве шарт иде.

## *Хатыйбның хаты*

Сәхабәләрдән Хатыйб бине Әбү Бәлтәга исемле берсе Корәеш мөшрикләренә бер яхшылык кылу нияте белән, рәсүлуллаһның Мәккәне алуга әзерләнгәнлеген, тиз арада

көчле гаскәр белән Мәккәгә сәфәр итәчәген белдереп хат язып, бер хатын аркылы Мәккәгә җибәрде. Ошбу хатын, эзләгән очракта табылуыннан куркып, хатны толым астына яшерде. Рәсүлуллаһ Аллаһы тарафыннан вәхи белән мәсьәләдән хәбәрдар булып, Гали бине Әбү Талиб белән Зүбәйр бине әл-Гаввәмне хатын артыннан җибәрде. Болар хатынның артыннан куып җитеп, хатны эзләсәләр дә, таба алмадылар. Ниһаять, бирмәсә, чишендереп карау белән куркыткач, хатын толымын сүтеп хатны бирде.

Рәсүлуллаһ Хатыйбны чакырып хат язуының сәбәбен сорады. Моңа Хатыйб болай дип җавап бирде: «Әй, рәсүлуллаһ, минем гозерем бар, минем Корәеш эчендә хатыным, балаларым вә якыннарым бар. Хәлбуки, үзем Корәеш кабиләсеннән булмаганлыктан, аларны якларлык кешеләрем юк. Синең сәхабәләрең Корәештән булганлыктан, аларны химая итәчәк кешеләр бар. Мин аларга шул яхшылыгымны игътибарга алып, хатын вә балаларымны якласыннар дип хат яздым», – диде. Хатыйбның сүзе дөрес, чыннан да гозерле булганлыктан, рәсүлуллаһ моңа җәза бирмәде[1].

Шулай итеп, рәсүлуллаһ ун меңнән артык гаскәр әзерләп, Мәккәне алыр өчен юлга чыкты. Мәдинәдә үз урынына Әбү Раһм бине Хусайн әл-Гыйфарине калдырды. Гаскәрнең Мәдинәдән чыгуы рамазан аеның 10 көнендә иде. Гаскәр Әбвәгә җиткәндә рәсүлуллаһның әтисе белән бертуган абыйсының уллары Әбү Сафүән бине әл-Харис белән Габдулла бине Әбү Үмәйя очрадылар. Алар мөшрикләрнең олугларыннан булып, Мәккәдә рәсүлуллаһка күп кыенлык вә җәфа кылганнар иде. Болар рәсүлуллаһ хозурына килеп, Исламиятне кабул иттеләр. Хаталарын танып рәсүлуллаһка:

1 “Мүмтәхәнә” сүрәсенең башы, шушы мөнәсәбәт белән иңдерелде диләр – авт.

«تَاللهِ لَقَدْ ءَاثَرَكَ اللهُ عَلَيْنَا وَ إِنْ كُنَّا لَخَاطِئِينَ»

– диделәр[1].

Рәсүлуллаһнын аларга мәрхәмәте килеп, җәза бирмәде. Киресенчә,

«لَا تَثْرِيبَ عَلَيْكُمْ اليَوْمَ يَغْفِرُ اللهُ لَكُمْ وَ هُوَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ»

– дип җавап кайтарып, күңелләрен тынычландырды[2].

Гаскәр Җухфәгә җиткәндә, гаиләсе белән Мәдинәгә һиҗрәт итеп килә торган Габбас бине Габделмоталлиб очрады. Габбас күптән Исламиятне кабул иткән булса да, моңарча һиҗрәт итә алмый тора иде. Рәсүлуллаһ вә сәхабәләр аның һиҗрәт итеп килүенә бик нык куандылар. Габбасның гаиләсен Мәдинәгә җибәреп, үзен Мәккәгә алып киттеләр.

Гаскәр Күдәйдкә җиткәндә, сәхабәләргә руза тоту авыр килгәнлектән, рәсүлуллаһ ифтар итәргә кушты. Боларга үрнәк булып иң элек үзе ифтар кылды.

## ***Мәккәлеләрнең куркуы***

Бу вакытларда Мәккә мөшрикләре Ислам гаскәренең чыгуыннан хәбәрдар булмасалар да, һәр көн курку эчендә торалар иде. Чөнки солых яңарту өчен барган Әбү Сафүәнгә рәсүлуллаһның ачык йөз күрсәтмәвеннән аның үзләрен җәза

---

1 Йосыф пәйгамбәрнең кардәшләре тарафыннан аңа гозер белән гафу үтенеп әйтелгән сүз булып, Коръәни Кәримдә язылгандыр. Әбү Сафүәнгә шушы сүзләр белән гафу үтенергә кушучы Гали бине Әбү Талиб иде. Мәгънәсе: «Аллаһы белән ант итәбез, Аллаһы сине бездән өстен итте. Без хата кылганбыз»[Йосыф/91] – авт.

2 Йосыф пәйгамбәрнең кардәшләренең гафу үтенүләренә каршы әйтелгән сүзе. Мәгънәсе: «Бу көн сезне җәза кылу юктыр. Аллаһы сезне гафу кылсын. Ул рәхимле вә шәфкатьледер.»

итү ниятендә булганын чамалыйлар иде. Шуның өчен дә Әбү Сафүән Мәккә тирәсенә чыгып күзәтеп йөри иде.

Ислам гаскәре Мәрру әз-Заһранга җитеп ял итәргә туктагач, рәсүлуллаһ һәркемгә ут ягарга әмер бирде. Шуннан соң ун мең җирдә ут ягылып, төтене барча әтрафны каплады. Шул вакытларда гаскәрнең хәбәрен аңлау өчен Әбү Сафүән, Хәким бине Хизәм һәм Бүдәйл бине Вәрка белән Мәрру әз-Заһранга якын килгән иде. Гарәфә утына охшашлы ут ягылганын күргәч, Рәсүлуллаһның гаскәре нинди булуын аңладылар.

Гаскәр Мәрру әз-Заһранда ял иткән арада, Габбас бине Габделмоталлиб Мәккә мөшрикләреннән берсен күреп, Мәккәнең һичшиксез Ислам гаскәре тарафыннан алыначагын, бу кадәр гаскәргә каршы тору кан түгүдән башка һичбер нәтиҗәгә китермәячәген, әгәр Мәккәгә кереп корал кулланмыйча гына мөселманнарга бирелсәләр, мал вә җаннарын коткарачакларын сөйләү вә аларга кардәшләрчә нәсыйхәт бирмәк өчен, рәсүлуллаһның качырына атланып, Мәккәгә таба юнәлде. Габбас караңгыда Әбү Сафүән вә иптәшләренең (Бүдәйл вә Хәким) тавышларыннан таныды һәм алар янына барып мәсьәләне аңлатты, рәсүлуллаһка буйсынырга өндәде, каршы торып һичбер файда чыкмаячагын сөйләде. Болар, бик теләп булмаса да, Габбасның тәкъдимен кабул иттеләр. Бүдәйл белән Хәким Мәккәгә кайтып киттеләр. Әбү Сафүән исә, Габбасның качырына атланып, Габбас белән бергә рәсүлуллаһ хозурына киттеләр. Габбас рәсүлуллаһ качырында булганлыктан, һәр ут яныннан үткән саен: «Рәсүлуллаһ качырында әтисенең бертуган кардәше килә»дән башка сүз әйтмиләр, артындагы кешенең кем икәнлеген артык тикшермиләр иде.

Гомәр бине әл-Хаттаб яныннан үткәндә, Әбү Сафүәнны танып калып: «Ә, Аллаһының дошманы Әбү Сафүән икән! Әлхәмдулилләһ, безнең кулга төште», – диде. Соңра болардан элек барып җитү нияте белән рәсүлуллаһка йөгерде. Габбас та, Гомәр алардан элек барып җитмәсен өчен, качырны куып, Гомәрдән элек барып җитте һәм Әбү Сафүәнне үзенең яклавы астына алуын сөйләде. Ул арада Гомәр килеп җитеп, Әбү Сафүәнне үтертү хакында сөйләсә дә, рәсүлуллаһ аны үтертмәде. Рәсүлуллаһ Габбаска Әбү Сафүәнне янында кундырып, иртә белән үзе янына китерергә кушты. Рәсүлуллаһның әмере буенча Габбас иртән Әбү Сафүәнны алып барды. Рәсүлуллаһ аны күргәч: «Әй, Әбү Сафүән, сиңа Аллаһыдан башка мәгъбүд юклыгын белергә вакыт җитмәдеме инде?» – диде. Моңа каршы Әбү Сафүән: «Атам вә анам сиңа фида булсын, әгәр Аллаһыдан башка илаһ булса, моңарчы ул безгә файда иткән булыр иде инде», – диде. Соңра рәсүлуллаһ: «Сиңа минем Аллаһының рәсүле икәнлегемне белергә вакыт җитмәдеме инде?» – диде. Моңа каршы Әбү Сафүән: «Әмма бу турыда күңелдә әзрәк төер бар әле», – диде. Озак вакыт үтмәстән, ул Ислам динен кабул итте.

Мәрру Зәһранда беркадәр ял иткәч, рәсүлуллаһ гаскәргә кузгалырга әмер бирде. Гаскәрне тәртип белән сафлады. Һәр кабиләгә махсус әләм тоттырды. Габбас бине Габделмоталлибкә дә гаскәр үтәчәк тар бер җиргә Әбү Сафүәнне алып барып гаскәрне күрсәтергә кушты. Гаскәр бик тантаналы рәвештә Әбү Сафүән алдыннан үтте. Габбас та Әбү Сафүәнгә гаскәр төркемнәренең нинди кабиләдән икәнлекләрен берәм-берәм бәян итә иде. Иң ахыргы вә иң мөкәммәл үтүчеләр мөһаҗирләр белән әнсарилар иде. Әнсариларның әләме Сәгъд бине Гүбәдәдә, мөһаҗирләрнеке Зүбәйр бине әл-Гаввәмдә иде.

Рәсүлуллаһ үзе шул иң ахырдагы мөһаҗирләр төркемендә иде. Әбү Сафүәннең игътибарын җәлеп иткән вә аңа дәһшәт биргән төркемнәр дә әнсарилар белән мөһаҗирләрнеке иде. Чөнки алар мөкәммәл рәвештә коралланган булып, тимер киемнәрдән күзләре генә күренә иде.

Әнсарилар төркеме Әбү Сафүән яныннан үткән чакта әләм сахибе Сәгъд бине Губәдә аңа: «Бу көн сугыш көне, бу көн Кәгъбә хәләл кылына торган көн», – диде. Әбү Сафүән мөһаҗирләр төркеме яныннан үткәндә рәсүлуллаһка Сәгъднең сүзен җиткерде. Моңа каршы Рәсүлуллаһ: «Юк, бу көн Кәгъбә хөрмәт ителәчәк көн», – диде. Сәгъднең ошбу сүзе өчен, рәсүлуллаһ әләмне аңардан алып, улы Кайс бине Сәгъдкә бирүе риваять ителәдер.

Әбү Сафүән, Ислам гаскәренең куәте дәрәҗәсен аңлагач, тиз арада Мәккәгә кайтып, Корәешләрне рәсүлуллаһка итагать итүгә өндәде. Каршы тору белән файда итмәячәкләрен аларга аңлатты. Ошбу вакыт Әбү Сафүәннең хатыны Һинд бинте Гутбәнең аның сакалына ябышып: «Әй, Корәеш халкы, ошбу сатлыкҗан булган ахмак картны дөньяда яшәтмәгез!» – диюе риваять ителәдер.

## *Гаскәрнең Мәккәгә керүе*

Гаскәр Мәккәгә берничә яктан керсә дә, иң күп гаскәр рәсүлуллаһ җитәкчелегендә Мәккәнең өске ягыннан, Халид бине әл-Вәлид кул астындагылар түбән тарафыннан керде. Халид бине әл-Вәлид гаскәре мөшрикләрнең бер өлешенең каршы килүләре сәбәпле, корал кулланырга мәҗбүр булды. Шул сугышта мөшрикләрдән 13 кеше, мөселманнардан 2 кеше үтерелде. Рәсүлуллаһ исә Мәккәгә бөтенләй каршы-



www.darul-kutub.com

лык күрмичә барып керде. Хәҗҗүн дигән урында үзенә чатыр кордырып, байрагын шунда кадатты. Бәйтуллаһка, Әбү Сафүән йортына яки үз йортларына кереп бикләнгән кешеләрнең имин булачакларын игълан итте. Шуннан соң каршы килмәгән мөшрикләр йортларына яки Әбү Сафүән йортына яки Хәрам мәчетенә кереп качтылар. Ислам гаскәренең Мәккәгә керүе сигезенче елда, рамазан аеның 20се, җомга көне иде.

Рәсүлуллаһ чатырында беркадәр ял иткәч, мөһаҗир вә әнсарилар белән Бәйтуллаһны барып тәваф кылды. Хәҗәрү Әсвәдне кулындагы җәясе белән истиләм итте. Тәвафны дөягә атланып кылды. Ул вакыт Бәйтуллаһ тирәсендә өч йөз алтмыш сын бар иде. Рәсүлуллаһ тәваф кылганда: «Хаклык килде, батыл китте. Батыл бернәрсә дә тудырмады һәм кире дә кайтмас» ,– дип кулындагы җәясе белән потларга төртеп китә иде. Соңра мөәзин Билал белән Бәйтуллаһка керде. Андагы сурәтләрнең барын да чыгартты. Алар эчендә Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәрнең сурәтләре дә бар иде. Бәйтуллаһның эче сурәтләрдән арындырылгач, рәсүлуллаһ Аллаһы Тәгаләгә мондый бөек нигъмәте өчен шөкер йөзеннән намаз укыды, Бәйтуллаһ эчендә йөреп тәкъбирләр әйтте.

Рәсүлуллаһ Бәйтуллаһтан чыкканда халык ишек төбенә җыелып көтеп тора иде. Үзенә дә, сәхабәләргә дә зур җәбер вә золымнары тигән Мәккә халкын ни рәвешчә мөгамәлә итүе хакында һәркем үзенчә төшенер һәм хөкем кылыр иде. Аллаһы вә рәсүленең ризалыгы өчен мал вә милекләреннән аерылып, газиз Ватаннарын ташлап киткән мөһаҗирләр белән рәсүлуллаһка вә сәхабәләргә ярдәм иткән әнсарилар, Мәккәне фәтех кылып, аны сыннардан һәм потлардан тазартылуына, Аллаһының боларга кылган вәгъдәсенең үтәленүенә ничек

шөкер итәргә белмичә, бөтен вөҗүдләре белән шатланып торган бер заманда, Аллаһының рәсүленә вә аңа ияргән кешеләргә төрле кабахәтлекләрне кылудан тартынмаган Мәккә әһелләре, җинаятьләренең нәтиҗәсе ни булачагын белмичә, куркуларыннан бөтен әгъзалары тетри иде.

Әгәр Рәсүлуллаһ урынында Әбү Сафүән, сәхабәләр урынында Мәккә мөшрикләре булсалар, һичкемне калдырмастан кылычтан кичергән булырлар иде. Фәкать күркәм әхлакның, шәфкать вә мәрхәмәтнең иң югары дәрәҗәсендә булган Мөхәммәд галәйһиссәлам аларның явызлыгына каршы явызлык кылмады. Киресенчә, аларга кардәшнең кардәшенә кылган мөгамәлә кебек мөгамәлә кылды. Боларның бөтенесен гафу итте. Бәйтуллаһтан чыгуы белән: «Барыгыз, сез азатсыз», – диде. Куркудан бөтен гәүдәләре калтырап торган Мәккә әһеле моны күреп, шатлыкларыннан ни эшләргә белмәделәр. Рәсүлуллаһка күп тәшәккүр кылдылар.

Моннан соң рәсүлуллаһ халыкка хотбә сөйләп, күп хөкемнәрне бәян итте. Мәзкүр хотбә эчендә шундый сүзләр бардыр: «Әй, Корәеш, Аллаһы сездән җаһилияттәге буш һәм файдасыз нәрсәләргә алданып йөрүне юк итте. Ата-баба белән тәкәбберләнүне бетерде. Сез барыгыз да адәм балалары. Адәм туфрактан яратылды. Шуңа күрә бөтенегез дә бертигез. Бер-берегездән артыклыгыгыз фәкать изге гәмәл белән булачак», – диде.

«يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَى وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ»[1]

әл-Хуҗрәт/13.

1 «Әй, кешеләр, Без сезләрне ир вә хатын итеп яраттык вә сездән тармаклар вә кабиләләр кылдык, бер-берегезне танымаклыгыгыз өчен, тәхкыйк, сезнең Аллаһ хозурында хөрмәтлерәгегез - тәкъва булган кешеләрдер. Аллаһы - белүче вә һәр эшегездән хәбәрдар» – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

## *Кәгъбә ачкычы*

Ошбу вакыт Гали бине Әбү Талиб рәсүлуллаһтан «хиҗәбәт» вазыйфасын үзенә бирүен үтенгән иде. Әмма рәсүлуллаһ кабул итмәде. Госман бине Әбү Талхәне чакыртып, кулына Кәгъбәнең ачкычын тоттырып: «Мә ачкычыңны, мәңге сездә булсын, бу көн – вафа көне», – диде. Бу вакытка кадәр Кәгъбәнең хиҗәбәте (хезмәте) Габдү әд-Дар балаларында иде. Моннан соң да аларда калды.

«Сикаят» [хаҗиларны су белән тәэмин итү] исә Ибне Һашим кабиләсеннән Габбаста иде. Гали бу ике вазыйфаның икесен дә үзләрендә булдырасы килгән иде.

## *Мәккәлеләр бәйгате*

Моннан соң Мәккә халкы рәсүлуллаһ хозурына килеп, берәм-берәм бәйгать бирә вә Исламиятне кабул итә башладылар. Әбү Бәкернең атасы Әбү Кухәфә белән Әбү Сафүәннең улы Мугавия дә ошбу вакытта Исламга килделәр. Әбү Бәкер картлыктан чәч вә сакаллары агарып, ай кебек булган вә сукырайган атасын рәсүлуллаһ хозурына китергәч, рәсүлуллаһның мәрхәмәте килеп: «Әй, Әбү Бәкер, картны мәшәкатьләгәнсең, мин аңа үзем барган булыр идем», – дигәне риваять ителәдер.

Бәйгать өчен килгән бер кешенең куркудан артык тетрәгәнен күреп, рәсүлуллаһның: «Курыкма, тыныч бул! Мин падишаһ түгелмен, каклаган ит ашый торган бер Корәеш хатынының углымын»,[1] – дип мәзкүр кешене тынычландыруы риваять ителәдер.

---

1 ‘‘هوِّن عليك فأني لست بملك إنما أنا ابن امرأة من قريش كانت تأكل القديد’’ – авт.

Ирләр бәйгатьтән бушангач, хатыннар килеп бәйгать бирә башладылар. Алар Аллаһыга һич беркемне ширек кылмаска, зина кылмаска, урламаска, балаларын үтермәскә, нахак вә боһтан кылмаска бәйгать бирделәр. Мәзкүр хатыннар арасында Үмм Һәни бинте Әбү Талиб, мәшһүр Һинд бинте Гутбә, Гыйкримә хатыны Үмм Хәким бинте әл-Харис, Сафвән бине Үмәйя хатыны вә Халиднең кардәше Фәхитә, Гамр бине әл-Гасның хатыны Райта бинте әл-Хәҗҗәҗ бар иде.

## *Нотык*

Фәтех көненең иртәсендә рәсүлуллаһның халыкка ошбу сүзләр сөйләве билгеледер: «Әй, җәмәгать, Аллаһы Мәккәне, күк вә җирне яраткан көннән бирле игътибары белән хәрам кылды. Аның хөрмәте – Аллаһы хәрам кылганлыктандыр. Аллаһы вә ахыйрәт көненә иман иткән кешегә анда кан агызу вә андагы агачларны кисү хәләл түгелдер. Минем Мәккәне алуым Аллаһының рөхсәте беләндер. Миңа карап һичкем аны басып алмасын. Миңа да ул бик аз вакыт гына хәләл булды. Инде әүвәлге хөрмәтенә кайтты. Ишеткән кешеләр моны ишетмәгәннәргә ирештерсеннәр».

Мәккә фәтех кылынгач рәсүлуллаһның Үмм Һәни өенә кереп сигез рәкәгать намаз укуы риваять ителәдер. Ошбу намаз Аллаһыга шөкер йөзеннән укылган намаз иде.

Мәккә фәтех ителү белән ширек һәм сыннарга табыну бетерелде. Бәйтуллаһ эчендә вә тирәсендә булган бөтен сыннар вә потлар кырылды. Мәккә халкының шәфәгать сорарга һәм арадашчы итеп куелган Лат, Гоззә, Һүбәл кебек бөек сыннары ватылды, җимерелде. Гыйбадәт бары тик Аллаһыга булып калды. Мәккәнең бөтен урамнарында



www.darul-kutub.com

«Аллаһу әкбәр», «Аллаһу әкбәр» дигән сүзләр яңгырады. Бәйтулланың үзендә азан укылды. Худәйбия килешүендә әйтелгән фәтех сөенече чынга ашты.

«وَ سَيَعْلَمُ الَّذِينَ ظَلَمُوا أَيَّ مُنْقَلَبٍ يَنْقَلِبُونَ»[1]

аятенең мәгънәсе тугры килде.

## *Гафу ителгән һәм гафу ителмәгән кешеләр*

Рәсүлуллаһ Мәккә әһелен гафу иткән вакытта, кабахәтлекләре зур булган кемсәләр булып, аларны кайда күрсәләр, шунда үтерергә әмер иткән иде. Аларны кайберләре үтерелсә дә, бәгъзеләре соңыннан гафу ителде.

1) Гыйкримә бине Әбү Җәһел – бу кеше, атасы кебек, рәсүлуллаһка бик күп җәбер вә золым итә иде. Мәккә фәтех ителгәндә, үтерелүдән куркып, Йәмән тарафына качкан иде. Соңра хатыны, моның өчен рәсүлуллаһтан иминлек алып, артыннан барып ирен алып кайтты. Шуннан соң Гыйкримә рәсүлуллаһ хозурында Исламиятне кабул итүе белән мүшәрраф булды. Гыйкримә Ислам дәүләте башка илләрне фәтех кылганда, зур батырлыклар һәм шөһрәт казанган кешеләрдән булды.

2) Сафвән бине Үмәйя – бу да Гыйкримә кебек рәсүлуллаһның иң зур дошманнарыннан иде. Ислам әһеле тарафыннан Мәккә алынгач, Җиддәгә качса да, Гумәйр бине Вәһб әл-Җумәхи, моның өчен рәсүлуллаһтан иминлек алып, артыннан эзләп Мәккәгә алып кайтты. Сафвән рәсүлуллаһ хозурына килгәч, башта Исламны кабул итмәде. Аңардан

1 «Кемнәр золымлык кыла, алар тиздән беләчәкләр, кая кире әйләнеп кайтачакларын. » әш-Шугара/227. – тәрҗ.

ике айга кичектерү таләп итте. Рәсүлуллаһ аңа: «Ике ай гына түгел, дүрт айга кичектерүне бирәм», – диде. Сафвән Таиф газвәсеннән соң Исламны кабул итү белән шәрафәткә иреште.

3) Габдулла бине Сәгъд бине Әбү Сарх – бу, уллары мөселман булып, рәсүлуллаһка Коръән аятьләрен да язган иде. Соңра мөртәт булып Мәккәгә кайтты һәм анда рәсүлуллаһ өстеннән ялган сүзләр сөйләде. Мәккә мөшрикләренә: «Сезнең динегез Мөхәммәднең диненнән артык, үз динегездән аерыла күрмәгез!» – дия иде. Мәккә фәтех ителгәч, сөт кардәше Госман бине Гаффәнгә килеп яклавын сорады. Госман Мәккәдә тынычлык булганчы, аны үзендә яшереп торып, соңыннан Рәсүлуллаһ хозурына китереп, аңа иминлек сорады. Рәсүлуллаһ моның үтенечен кабул итмәү тарафында булса да, Госманның үтенече сәбәпле, иминлек бирде. Габдулла да Исламиятне кабул итте.

4, 5, 6) Габд бине Хатл – бу да әүвәл мөселман булса да, соңра мөртәт булып Мәккәгә кайткан иде. Аның рәсүлуллаһны мыскыл итеп җырлый торган ике җәриясе бар иде. Шул хатыннарның берсе Мәккә алынган көндә Габд бине Хатл белән бергә үтерелде. Икенчесе Мәккә алынган көннәрдә качып торып, соңыннан килеп Исламны кабул итүе өчен гафу ителде.

7) әл-Хувәйрис бине Нәкыйд – бу да рәсүлуллаһның зур дошманнарыннан булып, аны мыскыл итә вә аңа төрлечә яла яга иде. Мәккә алынганда Гали тарафыннан үтерелде.

8) Микъяс бине Субәбә – Мәдинәдә бер әнсарины үтереп, мөртәт булып Мәккәгә кайткан иде. Ул да үтерелде.

9) Габдулла бине әз-Зибәгъра – ул да рәсүлуллаһка күп җәберләр китергән кешеләрдән булып, аны һәрвакыт мыскыл итә иде. Мәккә фәтех кылынган көннәрдә качып то-

рып, соңра рәсүлуллаһка килеп шигырь сөйләп гафу сорады. Шунлыктан гафу ителде.

10) Вәхши – бу Хәмзә бине Габделмоталлибне шәһид иткән кешедер. Мәккә алынган көндә Таифкә качты. Соңра Таиф әһеле белән рәсүлуллаһ хозурына килеп, Ислам динен кабул итте. Моның җинаяте зур булса да, рәсүлуллаһ аны гафу итте. Бары тик үзенең күзенә күренмәвен шарт кылды.

11) Һинд бинте Гутбә – ул да рәсүлуллаһка бик каты дошман булып, аңа күп изалар кылган иде. Һинд Ухуд сугышында, Хәмзәне үтерттереп, аның йөрәген чәйнәгән иде. Мәккә фәтех ителгәч, Корәеш хатыннары белән рәсүлуллаһка килеп, Исламны кабул итте вә гафу үтенде. Рәсүлуллаһ аны гафу итте. Исламияткә килгәч, әүвәлге эшләренә үкенеп, күп яхшылыклар кылганлыгы риваять ителәдер. Һинд җаһили хатыннарның мәшһүрләреннән вә иң беренчеләреннән иде.

12) Сәрра – бу Гамр бине Габделмоталлибнең җәриясе булып, рәсүлуллаһны мыскыл итә иде. Әүвәл Исламияткә килгән булса да, мөртәт булып, яңадан Мәккәгә кайткан иде. Мәккә алынган көндә Гали бине Әбү Талиб тарафыннан кылычтан кичерелде.

## *Лат, Гоззә, Мәнәтләрне җимертү*

Рәсүлуллаһ Мәккәдә тәмам көч вә бөеклек белән унтугыз көн торды. Бу вакытта намазны кыскартып укыды. Рәсүлуллаһ Мәккәдә вакытында, Халид бине әл-Вәлид җитәкчелегендә утыз атлы кеше җибәреп, Гүззә сынын ваттырды.

Гамр бине әл-Гасне «Сувәгъ»не җимерергә җибәрде. Гамр бине әл-Гас сын янына баргач, сынның хезмәтчесе кар-

www.darul-kutub.com

шы чыгып: «Монда ни эшләп йөрисең?» – дип сорады. Гамр: «Рәсүлуллаһ мине Сувәгъны җимерергә җибәрде. Шуның өчен килдем», – диде. Хезмәтче моңа: «Бушка йөрмә, булдыра алмассың», – диде. Гамр моңа: «Әле һаман да шул батыл игътикадыңда дәвам итәсеңме? Аның күрми, ишетми торган бер таш икәнен белмисеңме?» – диде дә, иптәшләре белән шул сынны җимереп бетерде. Хезмәтче шаккатып карап торды. Соңра ул Исламга килде. Мәнәтне җимерү өчен егерме атлы кеше белән Сәгъд бине Зәйд әл-Әшһәли җибәрелде. Алар да потны җимереп кайттылар. Рәсүлуллаһ бу вакытта мәккәлеләрнең өйләрендә булган вак сыннарны ватып бетертте. «Аллаһыга вә ахирәт көненә иман китергән кеше өендә сын калдырмасын», – дип, Мәккә урамнарында каты тавыш белән әйттереп йөртте.

## *Мәккәгә вәли билгеләү*

Рәсүлуллаһ Мәккәдән киткәндә вәли итеп Гутәб бине Үсәйдне калдырды. Моңа көндәлек бер дирһәм хезмәт хакы билгеләде. Гутәб бине Үсәйднең бу хакның зурлыгыннан:

«لَا أَشْبَعَ اللهُ بَطْنًا جَاعَ عَلَى دِرْهَمٍ كُلَّ يَوْمٍ »

– дигәне риваять иteләдер.

Бу вакытка кадәр һиҗрәт тиешле булып, бик күп аятьләрдә мөселманнарны шуңа өнди, һиҗрәт иткән кешеләргә зур әҗер вә саваплар вәгъдә кылына иде. Моның хикмәте дә бик мәгълүм, бөтен мөселманнарны бергә җыю иде. Мәккә алыну белән моңа хәҗәт калмады. Шуңа күрә һиҗрәтнең мәшругыяте бетте.

## *Халид сәриясе*

Рәсүлуллаһ Мәккәдә вакыт Ибне Җүзәймә гарәпләрен Исламга дәгъвәт итү өчен Халид бине әл-Вәлид кул астында өч йөз илле кешедән гыйбарәт бер сәрия күндерде. Сәриядәге кешеләрнең күбрәге мөһаҗир вә әнсарилар булып, бер кадәресе Мәдинәдән килгән сахра гарәпләре иде. Халид бине әл-Вәлидкә аларны бары Исламияткә дәгъвәт итәргә кушылган, алар белән сугышырга әмер бирелмәгән иде. Ошбу кабилә җаһилият гасырында гаять явыз гарәпләрдән булып, Габдү әр-Рахман бине Гауфнең атасын, Халид бине әл-Вәлиднең әтисе белән бертуган Фәкә вә аның бертуганын вә ошбу сәриядә булган Ибне Сүләйм кабиләсеннән берничә кешене үтергәннәр иде. Шунлыктан алар Халиднең сәриясе турында хәбәр алгач, безне кылычтан кичерергә киләләр дип, коралланганнар иде. Болар Халидкә үзләренең Исламны кабул итеп, Ислам диненең хөкемнәрен үтәүләрен бәян итсәләр дә, коралланганнарын күреп, Халид шөбһәгә төште. Коралларын ташлатып, барысын да әсир алып, гаскәргә бүлеп бирде. Иртәгесе көнне Халид гаскәргә әсирләрен үтерергә әмер итсә дә, Ибне Сүләйм гарәпләреннән башкасы аларны үтермәделәр, киресенчә, әсирләрен азат иттеләр. Халиднең ошбу мөгамәләсенә бөек сәхабәләрнең кайберләре каты нәфрәтләрен күрсәттеләр. Сәрия Мәккәгә кайткач, рәсүлуллаһ Халиднең шул мөгамәләсе өчен, аны орышты. Соңра Гали бине Әбү Талибны җибәреп, үтерелгән кешеләрнең йолымнарын түләтте.

www.darul-kutub.com

## *Хүнәйн газвәсе*

Рәсүлуллаһ тарафыннан Мәккә фәтех ителеп, сыннарның бетерелүе, Корәеш мөшрикләре вә Мәккә тирәсендә булган башка гарәпләрнең рәсүлуллаһка баш иеп, Исламиятне кабул итүләре Һәвәзин вә Сәкыйф гарәпләренә ишетелгәч, алар да тиз арада Ислам гаскәренең алар җирләренә килеп җитәчәкләренә төшенеп, башлыклары бер җиргә җыелып, бу мәсьәлә турыда киңәшләшә башладылар.

Һәвәзин[1] вә сәкыйфлеләр[2] гарәпләрнең иң куәтле кабиләләре иде. Шуңа алар үзләренең куәтләренә таянып, рәсүлуллаһ белән сугыш кылырга, Ислам гаскәре һөҗүм итмәстән элек, аларга каршы чыгып һөҗүм итәргә карар бирделәр. Һәвәзин белән Сәкыйф вә тирә-як гарәпләрен Ислам гаскәренә каршы чакырып, куәтле бер гаскәр туплый алды. Ошбу кабиләләр арасында рәсүлуллаһның сөт анасының кавеме Ибне Сәгъд дә бар иде. Гаскәргә башлык итеп Малик бине Гауф ән-Насри билгеләнде. Бу зат никадәр батыр вә хәрби яктан оста булса да, яшь булганлыктан, тәҗрибәсе камил түгел иде. Малик гаскәрнең сугыш мәйданыннан качмауларына сәбәп булыр дип, гаскәргә үзләре белән хатыннарын, балаларын вә малларын алып чыгарга әмер бирде. Мөшрик гаскәре эчендә акыл вә фикере белән танылган Дүрәйд бине әс-Сыйммә бар иде. Бу зат мөшрикләрнең иң бөек атлы сугышчысы булып, күп сугышларда катнашып, шөһрәт казанган булса да, хәзерге көндә гаять карт вә сукыр булганлыктан, шул бер сыйфаты белән генә чыккан иде. Аны сугышка алып чыгулары да бары тик фикереннән файдалану

1 Мәккә белән Таиф арасында “Хунәйн” вә “Әутас” исемендәге җирләдә яшәүче гарәпләр – авт.

2 Таиф гарәпләре – авт.

вә аның белән киңәшләшү өчен иде. Дүрәйд гаскәр эчендә хатыннар, балалар вә маллары да барлыгын белгәч, Малик бине Гауфне чакыртып, боларның алып чыгуының сәбәбен сорады. Малик аңа сугыш майданыннан качмасыннар өчен алып чыктым дисә дә, Дүрәйд моның фикерен хата кылды: «Хатын вә балаларның булуы җиңелгән кешене качудан тота алмый», – дип аларны кире кайтарып җибәрергә киңәш бирде. Әмма Малик: «Син үзең дә, гакылың да картайган», – дип аның фикерен кабул итмәде.

## *Ислам гаскәренең чыгуы*

Рәсүлуллаһка Һәвәзин вә Сәкыйф гарәпләренең әзерләнеп сугышка чыгулары ишетелгәч, унике мең гаскәр белән аларга каршы китте. Ошбу гаскәрнең ун меңе Мәдинәдән Мәккәне алу өчен килгән гаскәр булып, калган ике меңе яңа гына Исламга килгән Мәккә халкы иде. Боларның калебләренә иман нуры әле яхшылап урнашмаганнан ихлас сугышмаячаклары, ә киресенчә, Ислам гаскәренә мәшәкатьләр чыгарачаклары табигый иде. Гаскәр эчендә мөшрикләрнең дә булуы мәсьәләне тагы да авырлаштырачак иде[1].

Гаскәр Хунәйнгә якынлашкач, рәсүлуллаһ гаскәрне сафка тезеп, мөһаҗирләрнең байрагын Гали бине Әбү Талибка, Әус әләмен Үсәйд бине Хузәйргә, Хазраҗ әләмен Хәббәб бине әл-Мунзиргә бирде. Моннан башка төрле кабилә башлыкларына да байраклар бирде. Үзе ике кат тимер кием киде.

1 “Сира хәләбия” буенча, бу сугышта Ислам гаскәре эчендә сиксән мөшрик булып, алар арасында Сафвән бине Үмәйя вә Сүһәйл бине Гамр да бар иде. – авт.

## *Ислам гаскәренең бозылуы*

Гаскәр хәрәкәт итеп, алгы сафлар Хүнәйнгә җиткәндә, тар бер җирдә посып торган мөшрик гаскәре кинәттән чыгып, каты сурәттә ук ата башлады. Һич уйламаганда мондый һөҗүмне күреп, Ислам гаскәре кире борылып кача башлады. Арттан килә торган гаскәр дә моны күреп курка калды. Ислам гаскәре бозылып, мөшрикләр боларның артларыннан куып киттеләр. Сугыш майданында рәсүлуллаһ янында мөһаҗир вә әнсарилардан беркадәр гаскәр генә торып калды. Болар эчендә Әбү Бәкер, Гомәр, Гали, Габбас, Фазыл бине Габбас, Әбү Сафүән бине әл-Харис, Рабига бине әл-Харис, Әймән бине Үмм Әймән, Үсәмә бине Зәйд бар иде. Сугыш мәйданында калган Габбас рәсүлуллаһ качырының тезгенен, Әбү Сафүән бине әл-Харис иярен тотып, аны саклыйлар иде. Рәсүлуллаһ качып барган гаскәргә кычкырып аны кайтарырга тырышса да, куркуларыннан аны ишетмәделәр. Гаскәрнең бозылуына күптән түгел генә Исламияткә кергән Мәккә халкыннан күбесе шатлык күрсәтсәләр дә, Гыйкримә бине Әбү Җәһел кебек хакыйкый борчылган кешеләр дә бар иде. Сафвән бине Үмәйя мөшрик булган хәлдә вакыйгадан бик нык тәэсирләнде. Әбү Сафүән исә беркадәр шатланганлыгын аңлатты. Рәсүлуллаһ сугыш майданында: «Мин Аллаһының рәсүле, мин ялганламыйм, мин Габделмоталлиб улы», – дип тора иде.

Болай гына гаскәрне җыеп булмагач, рәсүлуллаһ Габбас бине Габделмоталлибка мөһаҗир вә әнсариларга кычкырырга кушты. Габбас гаять каты тавышлы булып, үз тавышын ерак араларга ирештерә ала иде. Шулай ул каты тавышы белән: «Әй, әнсари җәмәгате! Әй, әр-Ризван бәйгате әһеле!» – дип кычкыра башлады. Качып бара торган сәхабәләр Габбасның

тавышын ишетеп, әсәрләнеп, тавышка таба кире йөгерә башладылар. Качып баручы гаскәрнең күплегеннән вә тәртипсез качуыннан дөя өстендә бару мөмкин булмаганлыктан, бик күбесе, дөяләрен ташлап, коралларын күтәреп җәяү йөгерделәр.

Ислам гаскәре тиз ара эчендә рәсүлуллаһ янына җыелып, тәртипле сурәттә сафланып бар куәт белән мөшрик гаскәренә һөҗүм ясады. Мөшрик гаскәре озак каршы тора алмыйча, җиңелеп кача башлады. Ислам гаскәре боларның артларыннан куып, бик күп малларын ганимәт алдылар. Хатын вә балаларын, хәтта гаскәрдән дә атлы әсирләр алдылар.

Сугышның башы мөселманнар өчен күңелсез булса да, Аллаһының ярдәме вә фазылы, мөһаҗирләр вә әнсариларның гайрәт вә чыдамлыгы аркасында сугышның ахыры алар файдасына булды.

Бик күп сугышларда үзләреннән әллә ничә кат артык мөшрик гаскәрләрен җиңеп килгән Ислам гаскәренең бу сугышта бозылуының төп сәбәбе - гаскәрнең төрле халыктан җыелган булуы. Югарыда зекер ителгәнчә, бу гаскәр эчендә сахра гарәпләре, яңа гына Исламга килгән Мәккә халкы вә мөшрикләр дә бар иде. Боларның сугышка барулары Аллаһы ризалыгы өчен булмыйча, бары тик халыктан калмау яки ганимәт алу өчен генә иде. Шуңа күрә мөшрикләрдән кинәт бер һөҗүм күрү белән, кача башладылар. Бу вакытка кадәр бик күп сугышларда катнашып тотрыклык вә гайрәттән аерылмаган, Аллаһы юлында мал вә җаннарын корбан итеп килгән мөһаҗирләр вә әнсариларның да күңелләренә курку салды. Әгәр гаскәр әнсарилар вә мөһаҗирләрдән генә гыйбарәт булса, мондый вакыйга булмас та иде. Шәхсән дошманга каршылык күрсәтеп җиңүгә ирешкән кешеләр дә әнсари вә мөһаҗирләр иде.



www.darulkutub.com

## *Әбү Гамир сәриясе*

Мөшрикләр җиңелгәч, бер фиркасы Әутаска, берсе Нәхләгә, берсе Таифка качтылар. Әутаска качкан мөшрикләр артыннан беркадәр гаскәр белән Әбү Гамир әл-Әшгари җибәрелде. Мөшрикләр аларга беркадәр каршы торып маташсалар да, соңыннан җиңелделәр. Сугышта Әбү Гамир шәһид булганлыктан, урынына Әбү Муса әл-Әшгари калып җитәкчелекне үзенә алды. Гаскәр, байтак ганимәт вә әсирләр алып, Рәсүлуллаһ янына кайтты.

Бөтен әсирләр вә ганимәтләр җыелып «Җәгърана» исемендәге җиргә урнаштырылды. Ганимәт 24.000 дөя, 40.000нән артык куй, 4000 укыя[1] көмеш вә бик күп әсирләрдән гыйбарәт иде. Хунәйн газвәсендә Әймән бине Үмм Әймән вә Зәйд бине Зәмга шәһид булдылар.

## *Таиф газвәсе*

Хунәйндә җиңелгән мөшрикләрдән бер фирка (Сәкыйф белән Һәвәзиннән кайберләре) җитәкчеләре Малик бине Гауф белән Таифка качканнар иде. Алар, үзләренә бер елга җитәрлек азык әзерләп, Таиф ныгытмасында бикләнделәр.

Рәсүлуллаһ аларның артларыннан куа килде. Юлда Мәлик бине Гауфнең кальгасына җитеп, аны җимереп киттеләр. Сәкыйф халкыннан берсенең бакчасыннан үткәндә, бакча иясенең итәгать итүе таләп ителгән иде. Бу кабул итмәгәнлектән, бакчасы яндырылды.

Гаскәр Таиф ныгытмасына якын бер җиргә урнаш-

1 Укыя – 1/12 ратль(кадак). – авт.



www.darul-kutub.com

ты. Мөшрикләр гаскәрне ук атып каршы алдылар. Бу атышуларда Ислам гаскәреннән унике кеше шәһид булды, күп кеше җәрәхәтләнде. Җәрәхәтләнгән кешеләр эчендә Халид бине әл-Вәлид, Габдулла бине Әбү Бәкер вә Әбү Сафүән бине Хәрб дә бар иде. Шәһидләр эчендә Габдулла бине Әбү Үмәйя бар иде. Камап алу унсигез көн дәвам иткән хәлдә, һичбер нәтиҗә булмады. Чөнки Таиф кальгасе гаять нык булып, мөшрикләрдә азык күп иде. Камап алу көннәрендә Халид бине Вәлид мүбәразәгә кеше таләп итсә дә, чыгучы булмады.

Мөшрикләрнең бирелмәүләрен күргәч, рәсүлуллаһ диварны тишә торган һәм таш ата торган кораллар кулланды. Таиф тирәсендә булган хөрмә агачларын кистерде. Әмма мөшрикләр кальгадан чыкмадылар, каршы торуларында һаман дәвам иттеләр. Моннан соң рәсүлуллаһ кальгадан чыгып итәгать иткән колларның азат ителәчәкләрен игълан итте. Нәтиҗәдә унбишләп кол кальгадан чыгып итәгать иттеләр. Камап алу озак вакыт дәвам итәчәктән, рәсүлуллаһ Таифне ташлап китү фикеренә килде. Бу хосуста Нәүфәл бине Мугавия әд-Дәйли белән киңәшләште. Нәүфәл дә китү тарафын куәтләде. Шуңа күрә рәсүлуллаһ гаскәргә Таифтан китүгә әмер бирде. Гаскәр башта Таифны алмый китүгә разый булмаса да, рәсүлуллаһ алар үзләре килеп бирелерләр дип, аларны канәгатьләндерде. Гаскәрдән бәгъзеләре рәсүлуллаһтан Таиф халкына бәддога кылуын үтенсәләр дә, рәсүлуллаһ, киресенчә, аларга хәер-дога кылып, Аллаһыдан Исламга килүләрен сорады.

www.darul-kutub.com

## *Һәвәзин вәкилләре*

Таифтан рәсүлуллаһ туры Җигъранәгә кайтты. Анда Хунәйндә алынган ганимәтләр калдырылган иде. Ганимәт вә әсирләрнең хисабы алынды. Шул вакытта Һәвәзин гарәпләреннән Зүһәйр бине Сард рәислегендә ундүрт кешелек илчелек үз кавемнәренең Исламга килгәнлекләрен бәян итеп, рәсүлуллаһтан малларын, хатын вә балаларын кайтарып бирүен үтенделәр. Әсирләр эчендә рәсүлуллаһның сөт туганнары да булып, илчеләр рәсүлуллаһның шәфкатен китерү өчен: «Әй, рәсүлуллаһ, әсирләрең эчендә сөт туган абыйларың, апаларың, сине тәрбия иткән кешеләр бар. Әгәр синең урыныңда ән-Нугъмән бине Мүнзир, яки әл-Харис бине Әбү Шәмр булса, шөбһәсез, әсирләрне азат итәрләр иде. Фәкать синдә безнең өметебез тагы да зуррак», – дигән сүзләр сөйләделәр. Рәсүлуллаһ боларга: «Мин бөтенесен кайтарып бирүгә ышандыра алмыйм, сезгә хатын вә балаларыгыз кадерлерәкме, әллә малларыгызмы? Шулардан берсенең кайтарылуында тырышырмын», – диде. Болар, табигый, хатын вә балаларын ихтыяр иттеләр. Соңра рәсүлуллаһ аларга: «Намаздан соң халыкка үзегезнең Исламга килгәнегезне, аларга дин кардәше икәнлегезне сөйләгез һәм әсирләрегезне кайтарып бирүләрен үтенегез. Шул вакыт мин дә сезгә ярдәм итәрмен», – диде. Намаздан соң болар рәсүлуллаһ әйткәнчә сәхабәләрдән хатын вә балаларын кайтарып бирүләрен үтенделәр. Рәсүлуллаһ та сүзгә керешеп, үзенең әсирләрне кайтарып бирү фикерендә булуын сөйләде. Халыкны да шул эшкә өндәде.

Мөһаҗирләр белән әнсарилар рәсүлуллаһ хәтере өчен үз өлешләреннән ваз кичәчәкләрен сөйләделәр. Әкърагъ

www.darulkutub.com

бине Хәбис, Гуяйнә бине Хисн, Габбас бине Мәрдәс кебек кайбер кабилә рәисләре башта разый булмасалар да, рәсүлуллаһ боларга икенче ганимәттән түләргә сүз биргәч, разый булдылар.

Рәсүлуллаһ бу илчеләргә, әгәр аларның рәисләре Малик бине Гауф килеп тапшырылса, хатын вә балаларын саклаячагын, моның өстенә йөз дөягә хуҗа булачагын сөйләгән иде. Малик моны ишеткәч, Таиф кальгасыннан яшеренеп чыгып, рәсүлуллаһка килде вә Исламиятне кабул итү белән шәрафәткә иреште. Вәгъдәсенә күрә, рәсүлуллаһ моңа гаилә әһелләрен кайтарып бирде, моның өстенә йөз дөя дә тапшырды. Һәвәзин гарәпләреннән Исламиятне кабул иткәннәргә аны рәис итеп куйды.

## *Хунәйн ганимәтләрен бүлү*

Моннан соң Хунәйн ганимәтләре өләшенә башлады. Иң әүвәл, колларыннан рәислек китүе сәбәпле күңелләре сынык булган, Исламиятне кабул итсәләр дә, һаман да калебләре икеләнеп яки шөбһәләнеп торган Корәеш башлыкларының вә кабилә рәисләренең күңелләрен табып, аларга Исламиятне сөйдерү максаты белән бик күп ганимәтләр бирелде. Шул җөмләдән Әбү Сафүән бине Хәрб вә уллары Язид белән Мугавиягә һәркайсына йөзәр дөя вә кырыгар укыя көмеш бирелде. Хәким бине Хизамга йөз дөя бирелде. Хәким тагы йөзне сорагач, рәсүлуллаһ тагы бирде. Сүһәйл бине Гамр, Хүвәйтиб бине Габдүл Гоззә, Гүяйнә бине Хисн, Әкърагъ бине Хәбис, Сафвән бине Үмәйя, Харис бине Һишам, Габбас бине Мирдәс вә моннан башка бик күп гарәп рәисләренә дәрәҗәләренә күрә йөз, илле, кырык дөядән бүленеп бирел-

www.darul-kutub.com

де. Мондый затларга шәргый телдә «Мүәлләфәтү кулүб» диелер. Исламияткә кергән кемсәләргә мал биреп хәтерләрен табу вә аларны Исламга авыштыру, тарту – Исламиятнең иң югары сәясәтләреннәндер. Чыннан да, бу сәясәтнең файдасы шунда ук күренде. Шушы гарәп рәисләре рәсүлуллаһның бу мөгамәләсеннән бик нык разый булып калдылар. Аңа никадәр шөкер итәргә белмәделәр. Күңелләре рәсүлуллаһка вә Исламияткә тартылды. Элек боларның иң зур дошманнарыннан булган хәзрәти пәйгамбәр иң сөекле кешеләреннән булып китте.

Ошбу мүәләфәтү кулүбкү бирелгән маллар нигездә ганимәттән түгел иде. Бәлки рәсүлуллаһ вә хөкүмәт эшләре өчен сарыф ителә торган «биштән бер» яки рәсүлуллаһның үзенә хас булган «биштән бернең биштән бере» иде. Шуның өчен дә рәсүлуллаһ бу хакта сугышчыларның фикерен сорамады. Моның белән, Аллаһы вә рәсүле хакынча тәкъдир итә алмаган кайбер сахра гарәпләре, мүәлләфәтү кулүбкә малның бик мул бирелүен күргәч, өлештән коры калуларыннан куркып, рәсүлуллаһны бер агачка кысрыклап китерделәр. Рәсүлуллаһның киеме агач ботагына эләгеп калды. Шулвакыт рәсүлуллаһ боларның мәзкүр мөгамәләләреннән тәэсирле булып: «Әй, җәмәгать! Ашыкмагыз, бирегез киememне. Минем кулымда Тиһамә агачы санында мал булса да, үземә калдырмыйча сезгә бүлеп бирер идем», – диде. Соңра дөясеннән бер йон йолкып алып: «Миңа ганимәтнең биштән береннән башка ошбу кадәр нәрсә дә тими. Ул биштән бер өлеш тә ахырда сезнең үзегезгә кайта вә сезнең ихтыяҗларыгызга сарыф кылына», – диде. Кайбер кешеләр мәзкүр эшне күргәч Рәсүлуллаһка: «Гаделлек белән бүлмәдең, гаделлек кыл», кайберләре: «Бу эштә Аллаһы ризалыгы таләп кылынмады», –

диештеләр. Әмма рәсүлуллаһ аларга йомшаклыктан башка мөгамәлә кылмады. Сәхабәләрдән бәгъзеләре боларны үтерергә киңәш итсәләр дә, аларны гафу итте.

## *Өлешсез калганга әнсариларнын кәефләре кырыла*

Ганимәт бүленгәч, җәяүлегә дүрт дөя вә кырык куй, атлыга моның өч мәртәбә күбрәге тиде. Ошбу ганимәттән мөһаҗирләр вә әнсарилардан берсенә дә өлеш бирелмәгән иде. Моның өчен боларның, хосусан әнсариларнын, беркадәр хәтерләре калды: «Рәсүлуллаһ үз кавеменә күп ганимәт бирде, безгә һичбер өлеш чыгармады, хәлбуки без аңа иң авыр хәлендә ярдәм иттек, аны вә күчеп килгән сәхабәләрне шәһәребезгә кабул иттек, мал вә җаннарыбызны аны яклау юлында корбан иттек. Бәдр, Ухуд, Хандак кебек иң мөшкел вакыйгаларда, сугыш мәйданында торып калдык. Шулай булгач, ни өчен ганимәт малыннан безне коры калдыра?» – диештеләр. Хәсән бине Сәбит тә, әнсариларның бу хәлгә кәефләре кырылганлыгын бәян итеп, бер касыйдә чыгарды. Касыйдәнең ошбу битләре бардыр:

دَعْ عَنْكَ شَعْثَاءَ إِذْ كَانَتْ مَوَدَّتُهَا نَزْرًا وَ شَرُّ وِصَالِ الْوَاصِلِ النَّزْرُ [1]
وَ أْتِ الرَّسُولَ فَقُلْ يَا خَيرُ مُؤْتَمَنٍ لِـمُؤْمِنِينَ, إِذَا مَا عُـدِّدَ الْبَشَرُ [2]
عَـلَامَ تُدْعَى سُلَيمٌ وَ هِيَ نَازِحَةٌ أَمَـامَ قَوْمٍ هُمْ آوَوْا وَ هُمْ نَصَرُوا [3]
سَمَّـاهُمُ اللهُ أَنْصـارًا لِنَصْـــرِهِ دِينَ الْهُدى و عَوَانُ الْحَرْبِ تستَعِرُ [4]

---

1 Ташла ул башы тузган кызны, ул бик аз сөя иде. Мәсьәләнең мөшкеллеге дә шунда иде – авт.

2 Бар рәсүлгә дә әйт аңа: «Әй, мөэминнәр өчен иң әманиятле кеше! – авт.

3 Ни өчен ерак булган Сүләйм өлешкә кертелә дә, сиңа ярдәм биргән вә сине йортларына төшергән кавем калдырыла. – авт.

4 Аллаһы аларны «әнсари» дип атады, дин өчен сугыш кызган чакта дингә ярдәм иткәннәре өчен – авт.

www.darul-kutub.com

وَ جَاهَدُوا فِي سَبِيلِ اللهِ وَ اعْتَرَفُوا     لِلنَّائِبَاتِ فَمَا خَامُوا و مَا ضَجِرُوا [1]
وَ النَّــاسُ أَلْبٌ عَلَينا ثُمَّ لَيسَ لَنَا     إِلَّا السُّيُوفُ وَ أَطْرَافُ الْقَنَا وَزَرُ [2]
نُجَــادِلُ النَّاسَ لَا نُبقِي عَلَى أَحَدٍ     وَ لَا نُضَيِّعُ مَــا تُوحِي بِهِ السُّوَرُ [3]
و كَــم رَدَدْنا بِبَدْرٍ دُونَ مَا طَلَبُوا     أَهْلَ النِّــفَاقِ وَ فِينَا أَنْزَلَ الظَّفَرُ [4]
وَ نَحْنُ جُنْدُكَ يَوْمَ النَّعْفِ مِنْ أُحُدٍ     إِذْ حَزَّبَتْ بَطَرًا أَشْيَاعَهَا مُـضَرُ [5]
فَمَــا وَنَيْنَا, وَ مَا خِمْنَا وَ مَا خَبَرُوا     مِنَّــا عِثَارًا وَ جُلُّ الْقَوْمِ قَدْ عَثَرُوا [6]

## *Рәсүлуллаһның әнсариларга нотыгы*

Сәгъд бине Губәдә рәсүлуллаһ хозурына килеп, бу турыда әнсариларның хәтерләре калганлыгын сөйләде. Шуның өчен Рәсүлуллаһ әнсариларны үзенә җыеп, ошбу мәгънәдә сүз сөйләде: «Әй, әнсари җәмәгате, сезнең хакта шундый вә шундый сүзләр ишеттем. Сез мин килгәнче адашуда түгел идегезме? Аллаһы сезне минем сәбәпле тугры юлга күндерде, сез фәкыйрь түгел идегезме? Минем сәбәпле Аллаһы сезне бай кылды. Бер-берегезгә дошман түгел идегезме? Аллаһы минем белән сезне бер-берегезгә дус вә кардәш ясады. Корәеш гарәпләре яңа гына көфердән чыккан вә өсләренә мусыйбәтләр килгән кешеләрдер. Мин мал биреп, аларның күңелләрен тапмакчы булдым. Әй,

www.darul-kutub.com

1 Алар Аллаһы юлында җиһад кылдылар, мусыйбәтләргә сабыр иттеләр, курыкмадылар, ялыкмадылар – авт.

2 Хәлбуки, бөтен халык безгә каршы чыктылар. Бездә исә кылыч вә сөңгеләрдән башка сыенасы нәрсә юк – авт.

3 Халык (дошман) белән сугышабыз, һичкемне җәлләмибез. Шуның белән бергә вәхи кылынган сүрәләрне дә игътибарсыз калдырмыйбыз – авт.

4 Бәдер сугышында монафикларның (мөшрикләр) максатларына ирештермичә никадәр кайтардык. Бәдердәге җиңү дә безнең аркада гына булды – авт.

5 Ухуд сугышында, зарар кылучы гарәпләр тәкәбберлек вә горурлык белән партияләрен җыйган чакта гаскәрең без идек бит – авт.

6 Без кимчелек күрсәтмәдек, куркып артка чигенмәдек, бездән абыну-сөренүне белмәделәр. Хәлбуки, күп халык бу вакыт абындылар – авт.

әнсари җәмәгате, халыкның күңелен табу өчен бирелгән аз гына дөнья малы өчен кәефегез кырылдымы? Хәлбуки, сезне нык вә сәбит иманыгызга ышанып өлештән калдырган идем. Әй, әнсарилар, халык дөяләр вә куйлар белән кайтып киткәндә, сез рәсүлуллаһ белән бергә кайтып китүгә разый түгелсезме? Ант итеп әйтәм ки, әгәр һиҗрәт булмаган булса, әнсаридан бер кеше булыр идем, әгәр бөтен халык бер юлга кереп, әнсарилар икенче юлга керсәләр, әнсарилар юлына керер идем. Әй, Раббым! Әнсариларга вә аларның балаларына рәхмәт кыл».

Ошбу сүзләрне ишеткәч, күңелләре иман белән тулы әнсарилар, сөйләгән сүзләренә бик каты борчылдылар вә тәэсирләнделәр, балалар кебек еладылар. «Безнең өлешкә рәсүлуллаһ төшүенә разыйбыз», – диешеп таралдылар.

## *Җигъранә гомрәсе*

Рәсүлуллаһ Җигъранәдә унөч көн калып, ганимәтләрне бүлеп вә мүәлләфәтү кулүбкә күп маллар биргәннән соң, гомрә өчен Мәккәгә барды. Ихрамны Җигъранәдә баглады. Мәккәгә кич кереп гомрә кылды вә шул кичтә үк Җигъранәгә кайтты. Мәккәдә вәли итеп әүвәл билгеләнгән Гутәб бине Үсәйдне калдырды. Халыкка Коръәнне вә динне өйрәтер өчен Мугәз бине Җәбәлне калдырды. Соңра сәхабәләр белән Мәдинәгә юнәлде. Мәдинәгә керүләре зил-кагъдә аеның 25ендә иде.

## *Әш-Шәймә*

Рәсүлуллаһ Җигъранәдә вакытта сөт кардәше әш-Шәймә бинте әл-Харис бине Габдүл Гоззә килгән иде. Рәсүлуллаһ моны ихтирам итеп, киемен җәеп утыртты. Әгәр

үз янында калса, хөрмәт вә игътибарда булачагын сөйләде. Ләкин әш-Шәймәнең иленә кайтасы килде. Шул вакытта рәсүлуллаһның моңа күп бүләкләр бирүе риваять ителәдер.

## *Кәгъб бине Зүһәйр*

Мәшһүр шагыйрь Кәгъб бине Зүһәйрнең кардәше Бүҗәйр рәсүлуллаһ хозурына барып Исламиятне кабул иткән иде. Кәгъб моны ишеткәч, Бүҗәйргә багышлап

«أَلَا أَبْلِغَا عَنِّي بُجَيْرًا رِسَالَةً»

мисрагы[1] белән башланган касыйдәсен сөйләгән иде. Шушы касыйдәдә Бүҗәйрне хак диннән чыгуы белән орышкан, вә рәсүлуллаһның пәйгамбәрлегенә каршы сүзләр бар иде. Рәсүлуллаһ Кәгъбнең ошбу шигырьләрен ишеткәч, аның канын хәләл кылган иде. Бүҗәйр рәсүлуллаһның каннарын хәләл кылган кайбер кешеләрне гафу иткәнлеген белгәч, кардәше Кәгъбкә хат язып, рәсүлуллаһка килеп тапшырылырга өндәде, вә шул вакытта гына җанын коткара алачагын сөйләде.

Бүҗәйраның хат язуы рәсүлуллаһ Таифны камап кайтканнан соң иде. Кәгъб хатны алгач, бераз уйланып торса да, башка чара таба алмаганлыктан, рәсүлуллаһка барып бирелергә вә аннан гафу сорарга булды. Шуңа күрә Мәдинәгә килеп, бер танышының өенә төште. Соңра мәчеткә барды. Халык иртә намазыннан бушагач, Кәгъб рәсүлуллаһтан үзенә иминлек сорады. Мөһаҗирләр аның хакында йомшак мөгамәләдә булып, әнсарилар катылык күрсәттеләр. Ахырда рәсүлуллаһ моның үтенечен кабул итте. Моннан соң Кәгъб

1 Шигырь кисәге – тәрҗ.

рәсүлуллаһны вә мөһаҗирләрне мактап «بَانَتْ سُعأدُ» исемле мәгъруф озын касыйдәсен чыгарды. Касыйдә эчендә ошбу бәетләр бар иде:

بَانَتْ سُعَادُ فَقَلْبِي الْيَوْمَ مَتْبُولُ    مُتَيَّمٌ إِثْرَهَا لَمْ يُفْدَ مَكْبُولُ [1]
وَقَالَ كُلُّ خَلِيلٍ كُنْتُ آمُلُهُ    لَا أُلْفِيَنَّكَ إِنِّي عَنْكَ مَشْغُولُ [2]
فَقُلْتُ خَلُّوا سَبِيلِي لَا أَبَا لَكُمُ    فَكُلُّ مَا قَدَّرَ الرَّحْمَنُ مَفْعُولُ [3]
كُلُ ابنِ أُنْثَى وَإِنْ طَالَتْ سَلامَتُهُ    يَوماً عَلَى آلَةٍ حَدْبَاءَ مَحْمُولُ [4]
إِنَّ الرَّسُولَ لَنُورٌ يُستَضَاءُ بِهِ    مُهَنَّدٌ مِن سُيوفِ اللَّهِ مَسْلُولُ [5]
شُمُّ الْعَرَانِينِ أَبْطَالٌ لَبُوسُهُمُ    مِن نَسْجِ داوُدَ في الْهَيْجَا سَرابِيلُ [6]
لا يَقَعُ الطَّعْنُ إِلَّا فِي نُحُورِهِمُ    مَا إِنْ لَهُم عَنْ حِياضِ الْمَوتِ تَهلِيلُ [7]

Шушы касыйдәне чыгаргач, рәсүлуллаһның Кәгъб бине Зүһәйрне хөрмәт итеп, өстендәге «Бүрдә» киемен кидергәнлеге риваять иteләдер[8].

---

1 Сүгад бездән аерылды, ерак китте. Шунлыктан күңелем яраланды, төшке вә богаулыдыр – авт.

2 Өмет баглап йөргән дусларым миңа: «Сине алдап торуда мәгънә юк, без сиңа файда итә алмыйбыз, мәшгульбез» – диделәр – авт.

3 Мин аларга: «Аллаһы язган нәрсә булмый калмас. Мине үз юлыма ташлагыз» – дидем – авт.

4 Һәр инсан никадәр гомер сөрсә дә, бер көн табутка күтәреләчәктер – авт.

5 Рәсүл – яктыртучы бер нурдыр, мөшрикләр зарарына суырылмыш Аллаһның кылычларыннан бер кылычтыр – авт.

6 Алар (мөһаҗирләр) күтәренке борынлылар (бөек кешеләр димәктер), баһадирлар. Сугыш вакытында кигән киемнәре Дәуд тукыган тимер киемнәрдер. (Гарәпләр яхшы, нык тимер киемнәрне «Дәуд тукыган», «Дәуд эше» дип әйтәләр иде, Дәуд пәйгамбәр күздә тотып) – авт.

7 Сөңге аларның күкрәк авызларына гына житә (сугышта качмыйлар, һәрвакыт дошманга күкрәк биреп торалар дигән мәгънәдә), үлемнән качу аларның гадәте түгел – авт.

8 Мәзкүр бүрдәне Мугавия, Кәгъб бине Зүһәйр варисларыннан егерме мең дирһамга сатып алды. Халифәдән халифәгә күчеп килгән бүрдә, шушыдыр. Ибнү әл-Әсир, 2 т., 105 б. – авт.

www.darul-kutub.com

## *Галкамә сәриясе*

Рәсүлуллаһка хәбәшәләрдән бер кавемнең Җиддәгә һөҗүм итәргә әзерләнгәнлекләре ишетелгән иде. Шунлыктан 300 гаскәр белән Галкамә бине Мүҗәззизне җибәрде. Сәрия дошманга барып җитеп, сугышка әзерләнгәч, дошман качты. Нәтиҗәдә сугыш булмады. Гаскәр кайтканда Галкамә яшь җилкенчәкләрне Габдулла бине Хүзәфә җитәкчелегендә алдан җибәрде. Габдулла уенчак кеше иде. Юлда учак яктыртты да, гаскәргә шунда төшәргә кушты. Гаскәр аптырап калды. Кайберләре чынлап ук төшәргә ният иттеләр. Ләкин Габдулла үзенең шаярып кыланганын бәян итте. Мәдинәгә кайтып, мәсьәлә рәсүлуллаһка сөйләнгәч, «Гөнаһны, аны эшләүче артыннан кылуда буйсыну юктыр», – диде.

# Тугызынчы ел

## *Гуяйнә сәриясе*

Тугызынчы елның мөхәррәм аенда рәсүлуллаһ Гуяйнә бине Хисн җитәкчелегендә Ибне Тәмим кабиләсенә илле атлы гаскәр җибәрде. Моңа сәбәп булып рәсүлуллаһның Бишер бине Әбү Сафүән исемендәге берәүне Ибне Кәгъб гарәпләренең зәкәтләрен алу өчен җибәргән булуы. Ибне Кәгъб гарәпләре әүвәлдән Исламны кабул иткәннәр иде. Бәшир килгәч, зәкәт бирергә булсалар да, боларның күршеләре булган Ибне Тәмим кабиләсе зәкәт бирүдән тыйдылар. Бишер кайтып вакыйганы сөйләгәч, рәсүлуллаһ аларны җәза кылыр өчен, мәзкүр сәрияне җибәрде. Сәрия

Ибне Тәмим җиренә барып һөҗүм итте һәм әсирләр вә атлы ганимәт алып, Мәдинәгә кайтты. Әсирләр гаскәргә бүленеп бирелмәде. Кавемнәре килеп сорасалар, кайтарып бирү нияте белән Рамлә бинте әл-Харис йортында сакланды.

Мәзкүр вакыйгадан соң рәсүлуллаһтан үтенеп әсирләрне алып кайту өчен Ибне Тәмимнең бөекләреннән гыйбарәт бер илче җәмәгате Мәдинәгә килде. Болар эчендә Гутарид бине Хәҗип, Зәбрикан бине Бәдер, Кайс бине Гасыйм һәм Әкърагъ бине Хәбис бар иде. Алар Мәдинәгә килеп хатын вә балаларын күргәч бик тәэсирләнделәр. Сабырсызлыктан рәсүлуллаһның өенә барып каты тавыш белән: «Әй, Мөхәммәд, безнең яныбызга чык! Синең белән монәзарә өчен хатиб вә шагыйрьләребезне алып килдек», – дип кычкырдылар.

Бу вакыт намаз вакыты булып, Билал азан әйтүдә, рәсүлуллаһ та намазга әзерләнә иде. Аларның каты тавышларына рәсүлуллаһ борчылды, өеннән чыгып: «Мин сүз көрәштерү вә шигырь сөйләү өчен җибәрелмәдем», – диде дә кереп китте. «Хуҗүрат» сүрәсендәге 4-5 аятьләр ошбу кешеләр хакында иңдерелде диләр.

Намаздан соң болар мәчеткә кереп рәсүлуллаһ белән тартыша башладылар. Иң әүвәл мәшһүр хатиблары Гутарид бине Хәҗип торып, мактанып озын бер хотбә сөйләде. Моңа каршы рәсүлуллаһның хатибы Сәбит бине Кайс бине Шәммәс җавап бирде. Соңра Зәбрикан:

«نَحْنُ الْكِرَامُ فَلَا حَيٌّ يُعَادِلُنَا, مِنَّا الْمُلُوكُ و فِينَا الْبِيَعُ»

бәете белән башланган мәшһүр касыйдә фәхриясен сөйләде. Моңа каршы рәсүлуллаһның шагыйре Хәссән бине Сәбит торып:

«إِنَّ الذَّوَائِبَ مِنْ فِهْرٍ وَ إِخْوَتَهُمْ , قَدْ بَيَّنُوا سُنَّةً لِلنَّاسِ تُتَّبَعُ»

бәете белән башланган касыйдәсен сөйләде. Моннан соң бу илчеләр тегеләрнең өстенлекләрен аңлап җиңелделәр һәм рәсүлуллаһ хозурында Исламны кабул иттеләр. Моннан соң рәсүлуллаһ боларга хатын вә балаларын кайтарып бирде вә һәркайсына бүләк өләште.

## *Халид сәриясе*

Вәлид бине Гукбә исемендә бер сәхабә Ибне Мөстәгълик гарәпләреннән зәкәт алу өчен җибәрелгән иде. Вәлиднең килүен ишетү белән мәзкүр гарәпләр аны каршылар өчен коралланып каршы чыктылар. Вәлид моны күргәч, боларны Исламияттән чыккан дип уйлап, борылып кайтып китте. Вакыйганы рәсүлуллаһка сөйләде. Рәсүлуллаһ эшне аңлагач, беркадәр гаскәр белән Халид бине әл-Вәлидне җибәрде. Сәрия аларның җиренә җиткәндә мөәзин иртәнге намазга азан әйтә иде. Халид Вәлид бине Гукбәнең эше хата икәнлеген аңлагач, сугыш башламыйча Мәдинәгә кайтты. Моннан соң рәсүлуллаһ алардан зәкәт алу өчен икенче бер кешене җибәрде.

## *Гали сәриясе*

Ошбу ел, рабигыль-ахир аенда Гали бине Әбү Талиб җитәкчелегендә йөз илле әнсаридан гыйбарәт бер сәрия әзерләп, Тай кабиләсенең Фүлс исемле сынын җимерү өчен җибәрде. Сын сәрия тарафыннан җимерелде. Тай кабиләсе сәриягә каршы торганлыктан, малларына һөҗүм ителеп, атлы ганимәт вә бераз әсир алынды. Мәзкүр әсирләр эчендә

мәшһүр Хәтим кызы Сәффәнә дә бар иде. Сәффәнә Мәдинәгә килгәч, үзенең Хәтим кызы икәнлеген Рәсүлуллаһка сөйләп, азат итүен үтенде. Рәсүлуллаһ моны җәлләп азат итте.

## *Гадинең килүе*

Рәсүлуллаһның Сәффәнәгә кылган ошбу яхшылыгы кардәше Гади бине Хәтимнең Исламны кабул итүенә сәбәп булды. Гади, Гали бине Әбү Талиб сәриясе килгәч, Шам тарафына качкан иде. Сәффәнә рәсүлуллаһның яхшы мөгамәләсен күргәч, кардәше Гадигә хәбәр җибәреп, Исламиятне кабул итәргә вә рәсүлуллаһка килеп итәгать итәргә өндәде. Моның нәтиҗәсендә Гади Мәдинәгә килде. Рәсүлуллаһны күреп үзенең кем икәнлеген сөйләде. Рәсүлуллаһ моны кунак итү өчен үзенең өенә алып китте.

Юлда рәсүлуллаһны бер карчык туктатып, үзенең хаҗәтләре хакында озак вакыт сөйләшеп торды. Гади моны күреп, рәсүлуллаһның шундый шәфкатьле булуына хәйран калды һәм эченнән: «Бу кеше падишаһ булырга охшамый», – дип уйлады. Өйгә кергәч, рәсүлуллаһ аңа утырырга мендәр тәкъдим итте, үзе исә коры җиргә утырды. Бу да Гадигә яхшы тәэсир бирде. Шуннан соң рәсүлуллаһ моны Исламга дәгъвәт итә башлады вә аңа: «Әй, Гади, син ихтимал безнең фәкыйрьлектә вә мохтаҗлыкта булуыбызны күреп, динебезне кабул итми торгансыңдыр. Ихтимал, безнең дошманнарыбызның күплеге сине динебезгә керүдән тыя торгандыр. Ихтимал, патшалык безнең кулда булмау сәбәпле, динебездән кача торгансыңдыр. Мин ант итеп әйтәм ки, мөселманнарда бервакыт мал шул кадәр күбәячәк, хәтта аны алучы да булмаячак. Шул кадәр тынычлык вә иминлек

хөкем сөрәчәк ки, хатын кеше ялгыз хәлдә, һичкемнән курыкмыйча, Кадисиядән Бәйтуллаһка барып кайтачак. Озак үтмәстән, Бәбил сарайларының алынганын күрерсең», – диде. Моннан соң Гади Исламны кабул итте вә рәсүлуллаһ әйткән нәрсәләрнең барысын да күрде. Гади әүвәл насара динендә иде.

## *Тәбүк газвәсе*

Румлыларның Ислам әһеле белән сугышыр өчен гаскәр әзерләгәннәре рәсүлуллаһка ишетелде. Шунлыктан рәсүлуллаһ сәхабәләргә Румлылар белән сугышу өчен Шам тарафына сәфәр итәчәген сөйләде. Башка сугышларда рәсүлуллаһ халыкка таралмасын өчен кайда чыгачагын ачык әйтми иде. Бу сәфәрдә исә барачак җир озак булып, яхшы әзерләнү тиеш булганлыктан, кайда чыгачагын ачык сөйләде. Бу вакытка кадәр Исламиятне кабул иткән бөтен сахра гарәпләрен вә Мәккә халкын да сугышка чыгарга әмер итте.

Бу сугышка чыгу халыкка бик авыр килде. Чөнки аларның сугыш итәчәк дошманнары ул гасырның иң куәтле дәүләтләреннән булган шәркый Рум императорлыгы булып, барачак җирләре дә бик озак иде. Мәдинә вә тирә якларында бу вакытта ачлык булып, халык бик уңайсыз хәлдә иде. Көннәрнең бик эссе булуы уңайсызлыкны тагы да арттыра иде. Аның өстенә бу вакыт җимешләрнең өлгергән вакытына туры килеп, бакча ияләре үзләренең бакчаларында яңа җимешләр ашап, күләгәдә рәхәтләнеп ятасылары килә иде.

## *Иганә итү*

Гаскәр әзерлеге өчен рәсүлуллаһ мөселманнарны ярдәм итүгә өндәде, бу турыда хотбәләр сөйләде һәм вәгазь-нәсыйхәтләр кылды. Һәркем кулыннан килгән кадәр ярдәм итә, ярдәм кылырга мөмкинчелекләре булмаган кешеләр әҗер вә саваптан мәхрүм калуларына бик нык кайгыра иделәр. Мәдинәнең зур бае Госман бине Гаффән бөтен барлыгы белән өч йөз дөя, илле ат вә мең динар бирде. Моңа рәсүлуллаһның гаять шатланып, кул күтәреп озын дога кылуы риваять ителәдер. Әбү Бәкер әс-Сиддыйк үзендә булган бөтен дүрт мең дирһәмен китереп бирде. Гомәр бине әл-Хаттаб ярым малын бирде. Гасыйм бине Гади җитмеш дөя йөге хөрмә бирде. Талхә бине Губәйдулла, Габбас бине Габделмоталлиб вә Габдрахман бине Гауф тә күп микъдарда иганә бирделәр. Хатын-кызлар да кулларыннан килгән кадәр ярдәм иттеләр: алка, йөзек, муенса, беләзек, аяк беләзеге кебек зиннәтләрен кызганмастан рәсүлуллаһка китереп тапшыралар иде. Һәркем сәфәр әзерлеген күрә, Аллаһы вә рәсүленең ризалыгы өчен корбан булырга әзер иде. Сугышка атланып чыгарга ат вә дөяләре булмаган фәкыйрьләргә иганә малыннан ат вә дөяләр бирелә, иганә бетеп, бирергә бернәрсә дә табылмыйча кире кайтарылган кешеләр сугышка чыга алмаудан куркып, балалар кебек елыйлар иде. «Тәүбә» сүрәсендәге 92 аять шушындый фәкыйрьләр хакындадыр.

## *Монафикълар*

Башка вакытлардагы кебек бу вакытта да монафикълар форсаттан файдаланып, мөселманнарга төрле коткы бирүдә иде: «Мөхәммәд Шам кадәр озак җиргә барып, Ибне

әл-Әсфәр (Румлылар) белән сугышмакчы була, алар белән сугышуны уенчык дип белә торгандыр. Аларны гарәпләр белән чагыштырырга ярамый. Озак үтмәс, иптәшләре белән бергә арканнарга бәйләнеп әсир алынырлар», – дигән сүзләр сөйлиләр иде. Әз-мәз ярдәм иткән фәкыйрьләрдән көлеп: «Боларга ни калган инде, үзләренә юкны китереп биргән булалар, рия икәнлеге күренеп тора », – кебек сүзләр сөйлиләр иде. «Тәүбә» сүрәсендәге 79 аять иганә биргән фәкыйрьләрдән көлгән монафикълар хакында иңдерелде.

Монафикъларның халыкка коткы бирүләре рәсүлуллаһка ишетелгәч, мәсьәләне белер өчен Гаммәр бине Ясирне җибәрде. Алар Гаммәргә: «Юк, без мондый сүзләрне уен-көлке итеп кенә сөйләдек, коткы салу нияте белән түгел», – дип җавап бирделәр. «Тәүбә» сүрәсендәге 65 аять ошбу хакта иңде.

## *Гозер күрсәтеп сәфәрдән калучылар*

Җәддә бине Кайс исемендә берсе рәсүлуллаһтан сәфәргә чыкмаска рөхсәт сорады вә гозерен күрсәтте: «Әй, Мөхәммәд, минем хатын-кызларны яраткан бер кеше икәнлегем бөтен кавемемә билгеле. Мин Шамга барсам, Ибне әл-Әсфәр кызлары мине фетнәгә төшерерләр дип куркам, мин аларны күрсәм түзә алмам, миңа бармыйча калырга рөхсәт бир», – диде. Мондый кешедән, табигый, хәер чыкмаячагын күреп, рәсүлуллаһ рөхсәт бирде. Тәүбә сүрәсендәге 49 аять ошбу кеше хакындадыр.

Сахра гарәпләреннән сиксәнләп кеше гозерләре булмаган хәлдә, төрле сәбәпләр күрсәтеп, рәсүлуллаһтан калырга рөхсәт алдылар. Тәүбә сүрәсендәге 90 аять шушы гарәпләр хакындадыр.

Габдулла бине Үбәй һәм башка бик күп монафикъ-



www.darul-kutub.com

лар да төрле гозерләр күрсәтеп Мәдинәдә калдылар. Моннан башка Исламда шикле булмаган Әбү Хәйсәмә, Кәгъб бине Малик, Һиләл бине Үмәйя, Мүрара бине әр-Рабигълар да сәфәргә чыгуга авырсынып яки арттан барып куып җитәрмен әле дигән уй белән чыкмый калганнар иде.

## *Мәдинәдән хәрәкәт*

Әзерлек тәмам булгач, рәсүлуллаһ Мәдинәдә үзе урынына Мөхәммәд бине Мәсләмә әл-Әнсарины[1], гаиләсе янында Гали бине Әбү Талибны калдырып, утыз мең гаскәр белән сәфәр итте. Мәзкүр гаскәр эчендә ун мең кадәресе атлы гаскәр иде. Иң зур байрак Әбү Бәкергә, мөһаҗирләрнең әләме Зүбәйр бине әл-Гаввәмгә, Әусныкы Үсәйд бине Хузәйргә, Хазраҗ әләме Хәббәб бине әл-Мүнзиргә вә башка кабилә башлыкларына да әләмнәр бирелде. Гали Мәдинәдә калгач, монафикълар: «Мөхәммәд моны авырлыгы өчен алып чыкмады», – дип мыскыллаганнан соң, ул рәсүлуллаһның артыннан чыкты. Ләкин рәсүлуллаһ аңа: «Мин сине гаиләмне карар өчен калдырдым. Аларның сүзләренә әһәмият бирмә. Син миңа Мусага Һарун ничек якын вә кадерле булса, шулай якынсың. Ләкин шул аерма бар ки, миннән соң пәйгамбәр килмәячәк», – дип тынычландырып кайтарып җибәрде.

Гаскәр Хиҗргә җиткәндә рәсүлуллаһ, Сәмуд кавеменең кыйссаларын хәтерләренә төшереп, алардан гыйбрәт алырга, һәрвакыт Аллаһының бөеклегән күз алларында тотып, кайгы вә тәэсир белән үтәргә кушты. Шул юл белән гаскәр Шамның читенә җитеп «Тәбүк» дигән урынга төште. Ул вакытларда Тәбүктә йортлар әсәре юк иде. Рәсүлуллаһ Мугаз бине Җәбәлгә: «Әй, Мугаз,

1 Ибн Һишам моның урынына Сибагъ бине Гуруфутаны зекер итә – авт.

исән булсаң, бу җирләрне бакчалар белән тулы күрерсең», – диде. Чыннан да, рәсүлуллаһның сүзе туры килде. Тәбүк җирлеге, мөселманнар тарафыннан алынып, төзелгән биналар һәм бакчалар белән тулды. Гаскәрнең Мәдинәдән чыгуы рәҗәб аенда иде.

## *Әбү Хайсәмә*

Гаскәр Мәдинәдән сәфәр иткәч, югарыда зекер ителгән Әбү Хайсәмә гаять эссе бер көн бакчасына кайтып керде. Ике хатыны икесе дә моның өчен чатырларын җыештырып, салкынайтып куйганнар, яңа җимешләр вә салкын сулар әзерләгәннәр, бизәнеп-төзәнеп аны каршы алганнар иде. Моны күрү белән Әбү Хайсәмәнең хәтеренә рәсүлуллаһ килеп төште. Бик каты борчылып: «Рәсүлуллаһ мондый эссе көннәрдә мәшәкать эчендә була торып, минем күләгә астында матур хатыннар кочагында, татлы җимешләр ашап ятуым дөрес түгел», – диде һәм чатырларына керүдән ваз кичеп, шул сәгатьтә ук юл әзерлеген күреп, гаскәр артыннан сәфәр итте. Әбү Хайсәмә гаскәр артыннан килеп җиткәндә, гаскәр Тәбүктә урнашкан иде. Ерактан бер кеше килгәнен күргән сәхабәләр рәсүлуллаһка: «Ерактан бер кара күренә, кем булыр икән?» – диешкәндә, ул: «Әбү Хайсәмә булса ярар иде», – дигән иде. Әлеге ерактан күренгән кара Әбү Хайсәмә булып чыккач, рәсүлуллаһ бик нык шатланды.

## *Әйлә халкы вә башкалар белән солыхнамә ясау*

Гаскәр Тәбүктә егерме көн кадәр торды. Шул вакытта ул тирәдә булган кайбер халык килеп, рәсүлуллаһ белән солыхнамә ясадылар. Әйлә башлыгы Юхнә ошбу вакыт рәсүлуллаһка килеп, елына 300 динар биреп тору шарты

www.darul-kutub.com

белән солыхнамә ясады. Моннан башка Әзрух вә Җәрба әһелләре дә елына 100 динар биреп тору шарты белән солых ясадылар. Минә[1] халкына җимешләренең өчтән берен биреп бару шарты белән солых ясалды.

Әйлә башлыгына бирелгән солыхнамәнең мәгънәсе шушыннан гыйбарәттер: «Бу, Аллаһы вә рәсүле Мөхәммәдтән Әйлә сахибы Юхнә бине Руэбә вә Әйлә халкына; җирдә вә диңгездә булганнарына килешү төзелгән солыхнамәдер. Алар һәм алар белән булган Шам әһеле, Йәмән әһеле вә диңгез әһеле Аллаһы вә рәсүле Мөхәммәднең җаваплылыгындадыр. Болардан берәр кеше килешүгә каршы хәрәкәттә булса, аның малы аны коткармаячактыр. Малын кем алса да хәләлдер. Солых буенча, хәрәкәт иткән кеше кая гына барса да, кирәк диңгездә, кирәк җирдә булсын, аның юлына каршы чыгу тыеладыр».

## *Үкәйдиргә сәрия җибәрү*

Рәсүлуллаһ Тәбүктә булган вакытта Думәтүл Җәндәл әмире Үкәйдир бине Габдүл Маликка Халид бине әл-Вәлид житәкчелегендә дүрт йөз егерме атлы гаскәрдән гыйбарәт бер сәрия җибәрде. Бу вакыт Үкәйдир ау белән мәшгуль иде. Халид Үкәйдирне тотып алып, рәсүлуллаһ хозурына китерде. Үкәйдир рәсүлуллаһ тарафыннан Исламга дәгъвәт ителсә дә, кабул итмәгәч, билгеле бер микъдар йолым биреп тору шарты белән арада солых ясалды.

## *Мәдинәгә кайту хакында киңәшләшү*

Рәсүлуллаһ Тәбүктә егерме көн торгач, алга хәрәкәт итү турында сәхабәләр белән киңәшләште. Сәхабәләр исә

1 Әйләгә якын, Мисыр чигенә таба бер шәһәрдер – авт.

ары баруны дөрес күрмәделәр: «Хәзер без Тәбүк кадәр җиргә килеп җиткәнебез хәлдә дошманнан бер әсәр күрмәдек. Димәк, алар без килүдән курыктылар. Хәзергә без шуның белән канәгатьләник. Без Шамга кадәр барсак, беркадәр мәшәкатькә очрарбыз, чөнки анда дошманыбыз күп, Ислам әһеленнән әсәр юк. Бу ел Мәдинәгә кайтыйк, киләчәктә үзебез карарбыз», – диделәр. Моның өстенә Шамда чума барлыгы да ишетелгән иде. Шунлыктан, рәсүлуллаһ боларның фикеренә ияреп, Мәдинәгә кайтырга карар бирде.

Асылда, Тәбүк газвәсенә чыгуда төп максат Ислам әһелен имтихан итү иде. Аларның иманнарының дәрәҗәләрен, диннәренең никадәр нык булуларын сынау өчен иң беренче ысул мондый ачлык вакытында, иң эссе көннәрдә, куәтле дошман белән сугышу өчен ерак җиргә чыгу иде. Шуның өчен дә рәсүлуллаһ бәгъзе бер сәбәп белән гаскәрдән артка калган кешеләрне көтеп тормый: «Әгәр аңардан хәер чыгарлык булса, килеп җитәр әле», – дип юлын дәвам итә иде.

## *Әбү Зәр*

Тукталышларның берсендә, сәхабәләрдән Әбү Зәр дөясен югалтып артта калган иде. Моны күреп сәхабәләр: «Әй, рәсүлуллаһ, Әбү Зәр калды бит!» – диешә башладылар. Шул вакыт рәсүлуллаһ: «Калсын, әгәр дә аңардан хәер чыга торган булса, килеп җитәр әле», – диде. Чыннан да, Әбү Зәр дөясен таба алмагач, гаскәрдән аерылып калудан куркып, әйберләрен аркасына күтәреп гаскәр артыннан китте. Гаскәр туктап ял иткән вакытта Әбү Зәр күренде. Моны күргәч, сәхабәләр шатлыктан түбәләре күккә тиярлек булып, рәсүлуллаһка аның килеп җиткәнен сөйләделәр. Шул вакыт рәсүлуллаһ:

www.darul-kutub.com

«رَحِمَ اللهُ أَبَا ذَرٍّ يَمْشِي وَحْدَهُ وَ يَمُوتُ وَحْدَهُ و يُبْعَثُ وَحْدَهُ»[1] – диде.

Чыннан да, бу сәфәр шул максатка артыгы белән хезмәт итте. Сәхабәләрнең Аллаһы сүзен күтәрү юлында никадәр мәшәкатьләр көтүләре, Аллаһы юлында мал вә җан корбан итүне иң зур бурыч санаганлыклары мәйданга чыкты. Бу вакытка кадәр монафикъларның төрле кинаяләрдән аңлашылып килгән хакыйкый хәлләре моннан соң бик ачык мәгълүм булды. Аларның мөселманнарны фетнәләүдән башка эшкә ярамаганлыклары, алардан мөмкин кадәрераграк читләшү тиешлеге ачык булды. Шул вакыйга мөнәсәбәте илә «Тәүбә» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә монафикълар хакында игътибар ителәчәк дәресләр бирде. Рәсүлуллаһка итәгать итүдә битараф булган, сугышка чыгуга җиңел караган кешеләргә шелтә яудырды. Моннан соң андый эшне кылмаска катгый сурәттә әмер ителде.

## *Монафикъларның явыз нияте*

Тәбүктән кайтканда рәсүлуллаһ гаскәрне икенче юлдан җибәреп, үзенә начар бер юлдан үтәргә туры килде. Моны монафикълардан берничәсе сизеп калып, рәсүлуллаһ үтәчәк җиргә барып тордылар. Аларның максатлары аның дөясен өркетеп, аны ектыру иде. Ләкин рәсүлуллаһ эшне сизеп, саклык чараларын күрде. Гаммәр бине Ясиргә дөянең тезгенен тоттырды, Хузәйфәгә дөянең артыннан барырга

www.darul-kutub.com

1 «Аллаһы Әбү Зәргә рәхмәт итсен. Ул ялгыз йөри, ялгыз хәлдә үләчәк, ялгыз хәлдә кубарылачак» – мәгънәсендә сүзләр әйтте. Хәзрәти Госман тарафыннан Әбү Зәр Рабзага җибәрелмеш иде. Үлем вакытында янында бары тик хатыны белән хезмәтчесе генә бар иде. Алар аны кәфенләгәч, күмә алмыйча, юлдан узган мөсафирларны көтеп тордылар. Шул вакыт Ибн Мәсгудләр туры килделәр. Ибн Мәсгуд моны күргәч елап җибәреп: «Рәсүлуллаһ дөрес әйтте: «Үзең генә йөрдең, ялгыз хәлдә үлдең, үзең генә кубарылачаксың», – диде. Ибн әл-Әсир, 2 т., 107 б. – авт.

кушты. Шуның өчен монафикълар максатларына ирешми калды. Алар рәсүлуллаһның артыннан килеп җитсәләр дә, Хузәйфә кулындагы таягы белән дөяләрнең башына сугып, алга җибәрмәде. Монафикълар эшнең сизелгәнлеген белеп, шыпырт кына тайдылар.

Гаскәр Мәдинәгә якынлашкач, Мәдинә халкы боларны каршы алыр өчен «Сәниятүл Видагъ»[1]ка чыктылар. Хатын-кыз вә бала-чагалар түбәндәге бәетләрне тәкрарлыйлар иде[2]:

طَلَعَ البدرُ عَلَينَا    مِنْ ثَنِيَّةِ الْوِدَاع
وَجَبَ الشُّكرُ عَلَيْنَا    مَا دَعَا للهِ دَاع

## *Зыйрар мәчетен җимертү*

Рәсүлуллаһ Мәдинәгә җитәргә бер сәгатьлек юл калгач, берничә сәхабәләрне җибәреп, «Зыйрар» мәчетен җимертте. Ошбу мәчетне Куба монафикъларыннан бер җәмәгать бина итеп, рәсүлуллаһ Тәбүк сәфәренә чыгар алдыннан аңа килеп: «Әй, рәсүлуллаһ, без карт-коры, зәгыйфь-зугафәгә җиңеллек ясар өчен, бер мәчет бина иттек. Синнән ошбу мәчеттә башлап намаз укып бирүеңне үтенәбез», – дигәннәр иде.

Рәсүлуллаһ сәфәргә әзерлек белән мәшгуль булганлыктан, боларның үтенечләрен Тәбүктән кайтканга кадәр кичектергән иде. Әмма аларның максатлары мәхәллә аерып, Ислам әһеле арасын бозу булганлыгы рәсүлуллаһка мәгълүм булганлыктан, Тәбүктән кайтышлый бу мәчетне җимертте. «Тәүбә» сүрәсенең 107-110 аятьләре ошбу хакта иңдерелде.

Гаскәрнең Мәдинәгә кайтып керүе рамазан аенда иде.

1 Бохари, 6 т., 9 б. – авт.

2 “Зәдүл-мәгад”, 2 т., 10 б. Мәгънәсе: “Сәниятүл Видагъ тарафыннан безгә ай туды. Моның өчен, даимән, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итүебез тиештер” – авт.

## *Аклану*

Рәсүлуллаһ Мәдинәгә кайткач, сугышка чыкмый калган кешеләр, берәм-берәм килеп, төрле сәбәпләр күрсәтеп, аклана башладылар. Рәсүлуллаһ аларның ачык хәлләренә карап, гозерләрен кабул итте. Яшерен булганнарын исә Аллаһыга тапшырды.

Шул вакыт гозерсез калган өч кеше килде. Ләкин болар, башкалар кебек ялган гозерләр күрсәтмичә, эшнең турысын сөйләделәр. Моның нәтиҗәсендә рәсүлуллаһ, Аллаһы тарафыннан боларның тәүбәләре кабул ителгәнчә, халыкны алар белән аралашу вә сөйләшүдән тыйды. Шуның өчен халык алар белән сөйләшмәс булды. Һиләл белән Мурара халыкның мондый мөгамәләсен күргәч, кайгы вә хәсрәтләреннән өйләреннән чыкмас булдылар. Мәчеткә җәмәгать намазына барудан да туктадылар. Кәгъб боларга караганда яшь һәм кыю булганлыктан, эштән калмады, мәчеткә барудан да туктамады. Халыкның сөйләшмәвенә карамыйча, әрсезләнеп алар арасында йөри иде. Бу вакыйгага кырык көн үткәндә, рәсүлуллаһ боларга хатыннарыннан аерым торырга кушты. Ниһаять, илле көн кичеп, күз аллары караңгыланып, киң дөнья тар күренеп йөргән чакта, Аллаһы аларның тәүбәләрен кабул итте. Ошбу вакыт алар үзләрен гафу иткән Аллаһыга шөкер йөзеннән бөтен малларын сәдака кылмакчы булдылар. Әмма рәсүлуллаһ бөтен малларын биреп бетермәскә, үзләренә дә беркадәр калдырырга кушты.

Тәбүк сәфәрендә күп вакыт рәсүлуллаһның өйлә белән икенде намазын, ахшам белән ястү намазын бер вакытта җыеп укыганлыгы риваять ителәдер[1]. Тәбүктә торган

www.darulkutub.com

1 Әт-Тирмизи, 1 т., 75 б. – авт.

егерме көн дәверендә намазны юлдагы кебек кыскартып укыдылар. Тәбүк сәфәрендә сәхабәләр рузаларын тотмаганлыклары риваять ителәдер.

Ошбу елның зил-кагъдә ахырларында рәсүлуллаһ Ислам әһеле белән хаҗ кылу өчен әмир итеп Әбү Бәкер әс-Сиддыйкны җибәрде. Мәдинәдән Әбү Бәкер белән өч йөзгә кадәр хаҗи чыкты. Рәсүлуллаһ үз тарафыннан егерме дөя корбанлык, Әбү Бәкер биш дөя корбанлык бирделәр.

## *«Тәүбә» («Бәраә») сүрәсе*

Мәккәи Мөкәррәмә бер елдан бирле рәсүлуллаһ кулында булса да, Бәйтуллаһны зиярат итүдән мөшрикләрне тыймаган иделәр. Алар элекеге кебек Бәйтуллаһны зиярат итәләр вә үз гадәтләренчә хаҗ кылалар иде. Җаһилият заманында гарәпләрдә Кәгъбатуллаһны ялангач хәлдә тәваф итү гадәте дә бар иде. Хаҗилар Мәккәгә сәфәр иткәч, Ислам әһеле белән мөшрикләр арасындагы килешүнең бозылуына вә Тәбүк вакыйгасына кагылышлы «Бәраә» сүрәсе инде. Мәзкүр сүрә, мөселманнарга һәм Исламга иң зур дошманнар булып, һичбер сәбәпсез боларга төрле җәфа вә мыскыл кылган, рәсүлуллаһның вә сәхабәләрнең Ватаннарын ташлап, Мәдинәгә күчүләренә сәбәп булган, биргән гаһедләрендә тормыйча, форсат килгәндә һич чирканмыйча золым вә хыянәт иткән мөшрикләр белән араны өзүдән гыйбарәт булып, дүрт айга кадәр форсат бирелеп, моннан соң бөтенләй өзелү турында бәян ителгән иде. Мөселманнар белән булган килешүне үтәгән кайбер кабиләләр моннан истиснә кылынып, килешү вакыты тул-

ганчы аларга яхшы мөнәсәбәттә булырга әмер ителгән иде[1]. Рәсүлуллаһ Мәдинәгә һиҗрәт итү белән мөселманнар белән мөшрикләр арасында мөнәсәбәт өзелеп, болар бер-беренә каршы сугышучы ике милләт булып саналалар иде. Сугышучы дәүләтләрнең бер-беренең көчләрен бетерүгә, мадди вә мәгънәви куәтләрен киметүгә авышачаклары табигыйдыр. Шуңа да мөшрикләр белән Ислам әһеле һәрвакыт бер-берсенә аяк чалырга тырышалар, бер-берсенең малларын кулга төшерергә, форсат табылганда берсе икенчесенә һөҗүм итәргә дә тартынып тормыйлар иде. Бәдер, Ухуд вә Хандак шул каршылыкның нәтиҗәсе иде.

«Бәраә» сүрәсе иңгәч, рәсүлуллаһ Әбү Бәкер артыннан Гали бине Әбү Талибны җибәреп, корбан көнендә халыкка ошбу сүрәнең башыннан кырыклап аять укырга кушты. Моннан соң мөшрикләргә Кәгъбатуллаһны тәваф итәргә юл бирелмәячәген, җаһилияттәге кебек ялангач тәваф итү тыелган икәнлеген халыкка игълан итәргә боерды. Гали юлда Әбү Бәкернең артыннан куып җитеп, Мәккәгә аның белән керде һәм корбан көнендә үзенә кушылган эшне кешеләргә сөйләде. Моннан элек рәсүлуллаһ тарафыннан җибәрелгән Әбү Һурайра вә берничә сәхабә дә Гали белән бергә бу турыда игълан кылып йөрделәр.

## *Ислам дине көч белән таралдымы?*

Исламият йөзенә кара тап төшерергә тырышкан кешеләр мондый вакыйгаларны, Ислам диненең инану вә аңлату белән таралмаганлыгына, киресенчә, корал куәте белән таралуына

---

1 Худәйбия килешүе буенча Көрәеш мөшрикләренең гаһеденә кереп тә Хузәга гарәпләренә хыянәт итеп, килешүне бозган Ибне әд-Дил (Ибне Бәкер батыннарыннан берсе) гарәпләреннән башка Ибне Бәкер гарәпләре ошбу истиснәгә кертелделәр – авт.



www.darul-kutub.com

дәлил итеп тоталар. Алар Мөхәммәд галәйһиссәлам гарәпләрне Ислам диненә канәгатьләндерү юлы белән кертә алмады, бәлки көч-куәт белән кертте, диләр. Безнең бик күп мөфәссирләребез дә, сугышка өнди торган аятьләрне тәфсир кылганда, үзләрен сугыш мәйданында дип уйлапмы, «аять-кылычлар»ны селтәп җибәреп, Исламияттә көчләү юклыгын кычкырып торган мүхкәм [ачык, төгәл] аятьләрне кырып-себереп түгәләр. Һәм бу эшләре белән каршы булганнарга сөйләргә зур мәйдан ачалар. Ләкин Ислам мондый ялган, гаептән пакь булып, дәлил вә бурһан белән таралганлыгы күз алдындадыр.

Мәккәдә булган вакытта рәсүлуллаһ Мәккә мөшрикләре тарафыннан төрле җәфа, мыскыл күреп торган вакытларында куәт булмаган чакта, Ислам дәлил белән таралмый нәрсә белән таралган иде? Мәккәдә шул кадәр кысынкылык астында торып, Мөхәммәд галәйһиссәлам һичбер пәйгамбәр җыя алмаган кадәр иярүчеләр җыйган иде. Мәккәдә генә аңа ияргән кешеләрнең саны (Гакабә бәйгатендә катнашканнар моннан искәрмә) ике йөздән ким түгел иде. Алар Исламиятне кылыч тәэсире белән кабул иткәннәр идеме? Мәзлүм вә җиңелгән Мөхәммәд галәйһиссәламгә иярүгә боларга нинди мәҗбүрият бар иде? Ясриб гарәпләренең Мәккәгә килеп, караңгы төн урталарында халыктан яшеренеп, Мөхәммәд галәйһиссәламгә бәйгать бирүләренә корал хөкем сөрәме? Бөтен Хиҗаз мөшрикләре рәсүлуллаһның иң бөек дошманнары булып, аны дөньядан югалтырга әзер торган бер вакытта, аңа иярергә нинди мәҗбүрият бар иде? Юк! Монда Мөхәммәд галәйһиссәлам тарафыннан куркыныч та юк, баш өстендә кылыч та күтәрелеп тормый, башка мәҗбүрият тә юк иде. Болар Исламиятнең илаһи дин икәнлегенә иман китергәннән, аның бөеклегенә канәгатьләнгәннән, аңа

www.darul-kutub.com

ияргәннән иде. Менә шул кадәрлесе  Ислам дине дәлил вә бурһан белән таралуына дәлил буладыр:

«أَفَأَنتَ تُكْرِهُ النَّاسَ حَتَّى يَكُونُواْ مُؤْمِنِينَ»[1]

«وَقُلِ الْحَقُّ مِن رَّبِّكُمْ فَمَن شَاء فَلْيُؤْمِن وَمَن شَاء فَلْيَكْفُرْ»[2]

«لاَ إِكْرَاهَ فِي الدِّينِ قَد تَّبَيَّنَ الرُّشْدُ مِنَ الْغَيِّ»[3]

Шушы аятьләр белән дингә көчләү юклыгын ачык аңлатып торган бер диндә, нинди җәберләүче көч кулланылсын? Ошбу аятьләр белән эш итергә әмер ителгән шәригать сахибе, дингә кертү өчен җәберләү куәтен кулланырмы? Әлбәттә, кулланмас.  Ул,

«اُدْعُ إِلِى سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ وَجَادِلْهُم بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ»[4]

әмере буенча, йомшаклык вә канәгатьләндерү юлы белән дингә дәгъвәт итте.

Югарыдагы «Ислам динендә көчләү юк» аяте, Ибне Нәзыйр газвәсе мөнәсәбәте илә иңдерелгән иде.

Җаһилият гасырында Ясриб гарәпләрендә хатын бала китерми торса, баласын «яһүди» кылу белән нәзер әйтү гадәте бар иде. Ул хатын бала тапса, нәзер буенча шул баланы Мәдинә тирәсендәге яһүдләргә илтеп тапшыра иде. Ибне Нәзыйр яһүдләре рәсүлуллаһ тарафыннан сөрелергә

1 «Йунус» сүрәсе, 99 аять: «Әллә син, Мөхәммәд галәйһиссәлам, барча кешеләрне ышандыру өчен, аларны көчләр иденме?» – тәрҗ.

2 «Кәһеф» сүрәсе, 29 аять:

«Янә әйт: «Әй, кешеләр! Ошбу Коръән – Раббыгыздан килгән хак сүзләрдер, теләгән кеше кабул итсен(иман китерсен), вә теләгән кеше инкар итсен (көферлек кылсын)!» – тәрҗ.

3 Бәкара сүрәсе, 256 аять:

«Ислам динендә көчләү юк, батыл диннән Аллаһы төзегән хак дин ачык аерылды». – тәрҗ.

4 Нәхел сүрәсе, 125 аять:

«Раббыңның юлына хикмәт белән һәм яхшы вәгазьләр белән кешеләрне чакыр һәм кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен иң күркәм юл белән тартыш!» – тәрҗ.

www.darul-kutub.com

булгач, яһүдләрдә шундый балалары булган кешеләр аларны алып калып үз диннәренә кертмәкче булдылар вә бу хосуста рәсүлуллаһтан рөхсәт сорадылар. Шул вакыт «Диндә көчләү юк» аяте иңде. Бу вакыт һиҗрәтнең 4 елы, Исламиятнең яхшы гына куәт тапкан вакыты иде. Димәк, Мәккәдәге кебек үк Мәдинәдә дә, Исламның куәт вә шәүкәткә юл тоткан вакытында да дингә көчләү булмаган. Әгәр Исламияттә дингә көчләү булса, Мәккә алыну көнендә дә булган булыр иде. Ул вакыт рәсүлуллаһ теләгәнен эшли ала иде. Хәлбуки, ул шул вакытта да дәгъвәт белән генә чикләнеп, һичкемне дингә көчләмәде. Хунәйн сугышында рәсүлуллаһ гаскәрендә йөзләп мөшрикнең булуы моны ачык күрсәтәдер.

Дөрес, рәсүлуллаһ кылыч кулланды, мөшрикләр белән бик күп сугышларда катнашты. Ләкин бу, дингә көчләү өчен булмыйча, саклану өчен мәҗбүри буларак кына иде;

«وَقَاتِلُواْ فِي سَبِيلِ اللّهِ الَّذِينَ يُقَاتِلُونَكُمْ وَلاَ تَعْتَدُواْ إِنَّ اللّهَ لاَ يُحِبِّ الْمُعْتَدِينَ»[1] , «وَقَاتِلُوهُمْ حَتَّى لاَ تَكُونَ فِتْنَةٌ وَيَكُونَ الدِّينُ لِلّهِ فَإِنِ انتَهَواْ فَلاَ عُدْوَانَ إِلاَّ عَلَى الظَّالِمِينَ»[2].

Сугыш коралы, Мәдинәгә һиҗрәттән соң гына кулланылды. Бу да табигый бер эш иде. Бөтен мөшрикләр рәсүлуллаһка һәм мөселманнарга каршы чыккан вакытта, аларның каршы тормаулары мәгъкульмы? Әгәр мөшрикләр рәсүлуллаһка хөррият биргән булсалар, сәхабәләрне дә Ислам диненнән чыгарырга тырышмасалар, иске диннәренә

1 Әл-Бәкара/190: «Аллаһы юлында сугышыгыз, сезгә каршы сугыш башлаган кәферләр белән! Ләкин чиктән үтмәгез (ягъни үзегез сугыш башламагыз, сугыш башламау килешүен бозмагыз, сугышка катнашмаган кешене үтермәгез һәм әсирләрне җәберләмәгез) Аллаһ, әлбәттә, чиктән үтүчеләрне сөйми» – тәрҗ.

2 Әл-Бәкара/193: «Кәферләрне һәм мөшрикләрне үтерегез, фетнә беткәнгә чаклы һәм Аллаһы дине – Ислам булганчыга чаклы. Әгәр кәферлекне ташлап, Исламга керсәләр, аларга дошманлык күрсәтү юк» – тәрҗ.

www.darul-kutub.com

кайтарырга көчләмәсәләр, алар белән сугыш асылда ук ихтыяр ителмәс иде. Ухуд, Хандак вакыйгаларын вә бер тарафтан Худәйбия вакыйгасын хәтергә алып читтән хөкем ителсә, рәсүлуллаһның һәрвакыт солых тарафдары булганлыгы, Исламиятнең таралуы бары тик иркенлектә дәгъвәт итүгә туктап торганлыгын игътикад иткәнлеге көн кебек ачык булыр. Худәйбия килешүе Мәккә мөшрикләре тарафыннан аяк астына салып тапталгач, рәсүлуллаһ намус вә әһәмиятен саклау өчен Мәккәне алырга мәҗбүр булды. Бу хосуста кем һөҗүм итүче вә кем саклanучы иде?

Мәккә алыну белән мөселманнар белән Корәеш гарәпләре арасында булган сугыш хәле туктаган булса да, мөшрикләр һаман да дошман булып саналалар, ике сугышучы дәүләт арасындагы сугыш кагыйдәләре буенча, болар бер-беренә һәрвакыт һөҗүм итергә ихтыярлылар, бу эш һичкем каршында золымлык саналмый иде. Ләкин бу вакытларда Исламиятнең шөһрәте арткач, мөшрикләр әллә нинди руханилар куәтенә, күзгә күренмәгән көчләргә таянуларын, Һүбәл, Гоззә, Мәнатлары җимерелгәч, алар ошбу сыннарның батыйл булганлыкларын, файда вә зарар кыла алмаганлыкларын белделәр. Хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәламнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан халыкны һидаяткә бастыру өчен җибәрелгән бер рәсүл икәнлегенә канәгать булдылар. Бик күбесе Мәдинәгә илчеләр җибәреп, әүвәлге батыйл тормышларыннан ваз кичкәннәрен, рәсүлуллаһка баш игәнлекләрен белдерделәр. Калганнары да бүген яки иртәгә рәсүлуллаһка тапшырылу ниятендә иделәр. Шунлыктан рәсүлуллаһ, сугыштан тукталыбрак тора иде. Менә шул вакыт Аллаһы Тәгалә «Бәраә» сүрәсендә Ислам әһеле белән мөшрикләр арасында мөнәсәбәтнең әүвәлдәгечә кисек икәнлеген, бо-

лар һаман дошман милләтләр икәнлеген аңлатып бирде. Мөшрикләр рәсүлуллаһка тизрәк килеп бирелсеннәр өчен, боларга дүрт ай вакыт билгеләнде. Моннан соң Ислам динен кабул итү ниятендә булган мөшрикләр Мәдинәгә илчеләр җибәреп, рәсүлуллаһка буйсынуны белдерделәр.

## *Зәкәт җыю*

Ошбу елны вә унынчы елны рәсүлуллаһ, Ислам кабул иткән төрле гарәп кабиләләреннән зәкәтләрен алу өчен берничә кеше җибәрде. Аларга «Мусаддикун», «Гуммәлү зәкәт» диелер. Гуяйнә бине Хисннны Ибне Тәмим гарәпләренә, Язид бине Хусайнны Әсләм вә Гифар кабиләләренә, Гамр бине әл-Гасны Ибне Фәззәра гарәпләренә, Бишр бине Сафүәнны Ибне Кәгъб гарәпләренә, Габбәд бине Бәширне Сүләйм вә Мүзәйнә гарәпләренә, Рафигъ бине Мүкәисне Җүһәйнә гарәпләренә, Зыйхак бине Сафүәнны Ибне Киләб гарәпләренә, Гади бине Хәтимне Тай вә Әсәд кабиләләренә, Зибрикан бине Бәдер белән Кайс бине Гасыймны Ибне Сәгъд гарәпләренә, әл-Галәү бине әл-Хазрамины Бәхрайнгә, Гали бине Әбү Талибны Нәҗранга, Сәһл бине Мүнҗәбне, Сафвән бине Сафвәнне, Сүбра бине Гамрны, Вәкигъ бине Мәликне, Мәлик бине Нүвәйраны Ибне Тәмим батыннарына, Фәрва бине Мүсәйкне Мурад гарәпләренә җибәрде. Ошбу кешеләрнең бәгъзеләре Рәсүлуллаһ вафат булганчы шул урыннарында калдылар. Кайберләре исә, вакытлыча гына җибәрелгәнгә, вазыйфаларын үтәгәч кайттылар. Мөһаҗир бине Әбү Үмәйя Кинд вә Садәф кабиләләренең зәкәтләрен алу өчен билгеләнелгән булса да, рәсүлуллаһ вафат булгач бара алмады. Зәкәт җыючылар алынган зәкәт малларын

шул җирнең фәкыйрьләренә тараталар, артып калса гына Мәдинәгә озаталар иде.

Рәсүлуллаһның кызы вә Госман бине Гаффәннең хатыны Үмм Гөлсем ошбу ел вафат булды.

Монафикъларның башлыгы Габдулла бине Үбәй дә ошбу ел вафат булды. Аның улы Габдулла бөек сәхабәләрдән иде. Атасы вафат булгач, рәсүлуллаһка килеп, атасын гафу итүен, кылган начарлыкларын кичерүен үтенде. Атасын кәфенләр өчен рәсүлуллаһның өстендәге күлмәген сорады. Рәсүлуллаһ моның үтенечен кабул итеп, күлмәген бирде һәм аңа җеназа намазын укыды. Кабер өстендә торып, аңа гафу сорады. Моннан соң Аллаһы Тәгалә «Тәүбә» сүрәсендәге

«وَلاَ تُصَلِّ عَلَى أَحَدٍ مِّنْهُم مَّاتَ أَبَدًا وَلاَ تَقُمْ عَلَىَ قَبْرِهِ»[1]

аяте белән монафикъларга җеназа укуны һәм каберләрендә торуны тыйды.

## Унынчы ел

### *Халид сәриясе*

Ошбу елның рабигыль-ахыйр аенда рәсүлуллаһ Йәмәндәге Ибне Харис бине әл-Кәгъб гарәпләрен Исламга дәгъвәт итү өчен Халид бине әл-Вәлид кул астында бер сәрия җибәрде. Мәзкүр гарәпләр Халидкә каршы килмичә, Исламны кабул иттеләр. Халид рәсүлуллаһка боларның Исламга килгәнлекләрен бәян итеп хат җибәрде. Җавап килгәнче, бо-

1 «Әгәр алардан берсе үлсә, мәңге җеназа намазын укыма һәм каберенә дә барып басма» Тәүбә/84. – тәрҗ.

лар янында калып, Ислам хөкемнәрен өйрәтте. Рәсүлуллаһ моңа каршы язган җавабында Мәдинәгә кайтуын вә мәзкүр гарәпләрдән вәкилләр алып килүен таләп итте. Моның нәтиҗәсендә Халид белән шушы кавемнең башлыкларыннан гыйбарәт булган илчеләр төркеме килде. Рәсүлуллаһ боларга рәисләре Кайс бине Хусаинны әмир итеп билгеләде.

## *Гали сәриясе*

Рамазан аенда рәсүлуллаһ Йәмәндәге Ибне Мәзхиҗ гарәпләрен Исламияткә дәгъвәт итү өчен Гали бине Әбү Талиб кул астында бер сәрия җибәрде. Боларга шушы гарәпләрдән каршылык булмаса, сугыш кылмаска кушты. Сәрия аларның җиренә килгәндә, болар ук атып каршы алдылар. Шуның өчен Гали алар белән сугышырга мәҗбүр булды вә аларны җиңде.

Соңра боларны Исламияткә дәгъвәт итте. Нәтиҗәдә болар аны кабул иттеләр һәм зәкәт бирергә разый булдылар. Гали бине Әбү Талиб Йәмәннән кайтканда, рәсүлуллаһ Мәккәдә Хәҗҗәтү әл-Вәдәгъда иде. Гали рәсүлуллаһ белән бергә хаҗ кылды.

## *Әл-Вәдәгъ хаҗы*

Электән, Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәр заманыннан бирле гарәпләр карашында Кәгъбә изге вә мөхтәрәм урын дип санала иде. Аларга бабалары Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәрнең Кәгъбәне тәваф итүләре, анда гыйбадәт кылулары буыннан буынга күчеп килгәнгә, үзләре бабаларының юлыннан бөтенләй адашкан булсалар да, аларның динендәбез дип йөргәнгә, аны һәрвакыт зиярат

www.darul-kutub.com

вә тәваф итәләр иде. Мәккәдә торучы бер җирдән сәфәрдән кайтса, иң беренче эше Кәгъбәне тәваф итү була иде. Шулай ук читтән килгән кешеләр дә аны тәваф итмичә китмиләр иде. Кәгъбә гарәпләр күзендә шул кадәр изге иде ки, хәтта атасын яки якынын үтергән кешене эзләп йөреп, аны шунда тапса, Кәгъбәнең хөрмәте өчен аны үтерми иде. Гарәпләр каршында Кәгъбә мөхтәрәм булганга күрә, аны химая итүче Корәеш гарәпләре дә башка гарәпләргә караганда аерылып тора иделәр. Шуның өчен дә алар башка кабиләләр сәфәр итә алмый торган вакытларда да сәфәрдә тыныч, рәхәт йөриләр, Йәмән вә Шам кебек ерак җирләргә кадәр сәүдә белән чыгалар иде. Кәгъбә бөтен гарәпләр өчен уртак бер гыйбадәтханә хисап ителгәнгә, Корәеш гарәпләре башка гарәпләрне Кәгъбәне зиярат итүдән тыймыйлар иде, киресенчә, аларны үзләренең кунагы дип исәплиләр, аларны хөрмәтлиләр, фәкыйрьләрен ашаталар һәм эчертәләр иде. Моның белән бергә Корәешләр башка гарәпләр каршында әһәмиятләрен, дәрәҗәләрен арттыралар иде. Шунлыктан Кәгъбә гарәпләрнең сәяси берләшүенә, тел берлеге мәсьәләсенә иң зур сәбәпче булды. Мәшһүр «Фил» вакыйгасыннан соң гарәпләрнең күзендә Кәгъбәнең дәрәҗәсе тагын да арткан, Корәеш гарәпләренең абруе тагын да күтәрелгән иде.

Шулай электән үк мөкаддәс саналып килгән Кәгъбәне зиярат итү, анда барып гомрә, хаҗ кебек махсус гыйбадәтләр кылу, аңа якын вә ерак бөтен гарәпләрнең иң зур теләкләре булганлыктан, гарәпләр каршында мөхтәрәм вә солых айлары булып саналган «Хәрам айларда» аңа киләләр, хаҗ вә гомрә кылалар иде. Ләкин алар Ибраһим вә Исмәгыйль юлыннан тайпылганлыктан, хаҗ вә гомрәләре чын гыйбадәтлектән чыгып, ширек белән катышкан, Кәгъбәне бер мәгъбүд урынына тотып, аңа гыйбадәт кылу вә аңардан ярдәм сораудан гыйбарәт

булып калган иде. Кәгъбәне ялангач тәваф итүләр, тәваф кылганда кул чабу, акыру, бакыру вә сызгыру кебек гыйбадәт рухына каршы булган гамәлләр белән катнашып беткән иде.

Хәзрәти Мөхәммәд галәйһиссәлам дәгъвәт иткән дин – шул ук Ибраһим вә башка пәйгамбәрләр дәгъвәт иткән дин булып, алдагы буыннарыннан Ибраһим вә Исмәгыйль тарафыннан дөрес гыйбадәт өчен салынган бер урынны һәрбер дин иясенә олылау вә изгеләштерү тиеш булганлыктан, Коръәни Кәрим һәрвакыт аны зекер итә, хөрмәт вә ихтирам кыла, Ибраһим вә Исмәгыйль галәйһиссәламнәрнең аны ничек бина итүләрен вә анда ничек гыйбадәт кылуларын искә төшерә. Шуның белән бергә мөшрик гарәпләрнең Ибраһим галәйһиссәлам динендә булуны сөйләүләре коры сүз генә булып, аның юлыннан бөтенләй адашканлыкларын, ике араны чагыштырганда җир белән күк арасындагы аерма булуын, Ибраһимга вә ул бина кылган Кәгъбәгә иң якын кешеләр рәсүл вә аңа ияргән кешеләр икәнлеген сөйли һәм гарәпләрнең тоткан юлын хата дип таба вә аларны рәсүлуллаһка иярүне тиеш итә иде.

Аллаһы Тәгалә Кәгъбәне һәрвакыт «Үз өем» дип атамыштыр. Шунлыктан Исламиятькә килгән гарәпләр дә Кәгъбәнең изгелеге әүвәлгечә, бәлки аннан да артык күреп, Ислам әһелен аны һаман да тәваф вә зиярат итәләр иде. Исламият, табигый ки, Кәгъбәдәге гыйбадәтне җаһилият гамәлләреннән арындырып, дөрес гыйбадәт шәкеленә куйды. Алтынчы елдагы Худәйбия гомрәсе мөнәсәбәте илә, хаж вә гомрә хөкемнәре бәян ителде. 9 ел ахырларында исә,

«وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً»[1]

---

1 «Кешеләргә Аллаһs каршында, Кәгъбәгә хаж кылу тиешледер, әгәр дә аларның бу юлны үтәргә мөмкинчелекләре булса» Әл Гыймран/97. – тәрж.

аяте белән көче җиткән һәр мөселманга Кәгъбәне хаҗ кылу фарыз кылынды.

## *Сәфәр*

Тугызынчы елны хаҗ фарыз булганлыктан, рәсүлуллаһ Мәккәгә хаҗның әмире итеп Әбү Бәкер әс-Сиддыйкны җибәргән иде. Унынчы елны исә хаҗ кылуга үзе әзерләнде. Мәдинә тирәсендәге сахра гарәпләренә дә сәфәргә әзерләнергә кушты. Бик күп кеше хаҗга әзерләнеп, Мәдинәгә килделәр. Рәсүлуллаһ аларга җомга намазында, хотбәдә хаҗның гамәлләрен өйрәтте. Зил-кагъдәнең 25ендә, шимбә көнне өйлә намазыннан соң Мәдинәдән чыктылар. Мәдинәдә рәсүлуллаһ урынына Әбү Дүҗәнә әл-Әнсари калды. Рәсүлуллаһ хатыннарының бөтенесе дә бу сәфәргә әзер иделәр. Юлда барганда кабиләләр рәсүлуллаһны көтеп торып, аңа кушылалар иде. Рәсүлуллаһ белән Мәккәгә барып кергән хаҗиларның саны туксан меңгә җиткәнлеге риваять ителәдер. Рәсүлуллаһ үзе белән корбанлыкка йөз дөя куып китерде.

Хаҗилар икенде вакытларында Зүл-Хуләйфәгә җитеп, ял итәргә туктадылар. Зүл-Хуләйфәдә икенче көнне өйлә намазын укыганнан соң, ихрам багълап, Мәккәгә юнәлделәр[1]. Зүл-Хуләйфәдә бөтен намазларын кыскартып укыдылар. Зөлхиҗҗә аеның 3се көнне, шимбә, «Зи-Тувә» исемендәге җиргә төшеп кундылар. Мәзкүр җирдә иртә намазын укып, зөлхиҗҗәнең дүртенче көнендә, якшәмбе көнне, зуха вакытында (кояш күтәрелгән вакытларда) Мәккәгә керделәр.

1 “Зәдүл-мәгад”, 1 т., 202 б. – авт.

## *Тәваф*

Рәсүлуллаһ Мәккәгә кергәч, Бәйтуллаһны җиде мәртәбә җәяү тәваф итте. Әүвәлге мәртәбәсендә «Хәҗәрү әсвәдкә» мөбарәк куллары белән кагыла, калганнарында таягы белән генә кагыла вә таягын үбә иде. Тәвафтан соң «Мәкам» артында ике рәкәгать намаз кылды. «Сафа» белән «Мәрвә» арасын җиде мәртәбә чабып үтте. Сафа белән Мәрвәгә менгән саен, Бәйтуллаһка борылып тәкбир әйтә вә:

«لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ, لَهُ الْمُلْكُ و لَهُ الْحَمْدُ وَ هُوَ عَلَى كُلِّ شَيءٍ قَدِيرٌ.»[1]

– дия иде.

## *Хаҗны гомрәгә әйләндерү*

Рәсүлуллаһ Сәрәфкә җиткәч сәхабәләргә: «Корбанлык алып килмәгән кешеләргә хаҗ өчен баглаган ихрамнарын гомрәгә әйләндереп, гомрәдән бушангач, тәрвия көненә кадәр ихрамнан чишелеп торырга ихтыяр», – дигән иде. Мәккәгә кергәч, корбанлыклары булмаган кешеләргә хаҗны гомрәгә әйләндереп, гомрә кылганнан соң ихрамнан чишелеп торырга катгый әмер кылды. Шуннан соң сәхабәләр, гомрә кылып, ихрамнан чыктылар. Үзләре белән корбанлык алып килгән рәсүлуллаһ вә берничә кеше генә ихрамда калды. Сүрака бине Малик: «Әй, рәсүлуллаһ, бу хөкем бу елга гына хасмы? Әллә кыяматкәчә шулаймы?» – дип сорагач, рәсүлуллаһ: «Кыяматкә хәтле шулай булыр», – дип җавап бирде.

1 «Ул бер генә, Аңа тиңдәш зат юк. Бөтен мөлек һәм мактау Аңа гына һәм Ул бөтен нәрсәгә кодрәтле. Аллаhslan кала башка илаһ юктыр. Ул вәгъдәсендә торды, Үзенең колына ярдәм итте, мөшрикләрнең, кәферләрнең гаскәрләрен җиңде» – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

# *Минада куну*

Рәсүлуллаһ Мәккәнең эченә төшмичә, чит тарафына төшкән иде. Тәрвия коненә кадәр (якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе көннәр) намазны шул төшкән җирендә укыды. Зөлхиҗҗәнең сигезенче көнендә, якшәмбе ихрамнан чишелгән сәхабәләр хаҗ өчен ихрам багладылар. Шул көн зуха вакытында рәсүлуллаһ белән Минага юнәлделәр вә шунда кундылар. Җомга көн, кояш чыккач, Гарәфәткә юнәлделәр. Юлда барганда сәхабәләрдән кайсысы тәкъбир әйтә, кайсы тәлбия әйтә иде. Рәсүлуллаһ моны инкарь итми иде. Гарәфәтнең көнчыгыш ягында «Нәмирә» дигән җирдә рәсүлуллаһка чатыр төзелгән иде, шунда килеп төште. Төш авышкач, дөясе Касвага атланып, «Гуранә» дигән җиргә барып туктады. Вә шул җирдә озын хотбә сөйләп, Ислам кагыйдәләрен бәян кылды. Ширек вә потларга гыйбадәт итүне, җаһилият гамәлләрен бетерде.

Рәсүлуллаһ җаһилият гасырында була торган кан дәгъваларыннан, риба мөгамәләсеннән катгый тыйды. Хатыннарга гүзәл мәгамәлә итәргә, аларга җәбер кылмаска кушты. Ирләрнең хатыннар өстендә булган хакларын, хатыннарның ирләр өстендә булган хакларын бәян итте. Ирләрнең хатыннарга рәислек хакы булганлыктан, хатыннар мөнәсәбәтсез эшләрдә булсалар, аларны әдәпкә кайтарырга хаклары барлыгын сөйләде. Халыкка Аллаһы китабына тотынырга кушты. Аңа тотынсалар, адашмаячакларын сөйләде. Сөйләгән сүзләрен шунда булмаган кешеләргә ирештерергә кушты. Сүзенең ахырында халыкка карап: «Мин сезгә ирештердемме? Үземә Аллаһы тарафыннан йөкләнгән вазыйфамны үтәдемме, нәсыйхәт кылдыммы?» – диде. Халык беравыздан: «Кылдың, кылдың», – диделәр.

www.darulkutub.com

Хотбә тәмам булгач, Билалга азан әйтергә кушты. Азан вә камәт әйтелгәч, ике рәкәгать өйлә намазын укыды. Кыйраәтне яшерен кылды. Өйлә тәмам булгач, яңадан камәт әйтелеп, ике рәкәгать икенде намазын укыды. Бу вакыт Мәккә әһелләре дә шунда иделәр, алар да башка хаҗилар кебек өйлә белән икенде намазларын җыеп һәм кыскартып укыдылар. Рәсүлуллаһ аларга намазларын тәмам итәргә кушмады[1].

Моннан соң рәсүлуллаһ дөясенә атланып бераз барды да тау итәгендә туктады. Дөя өстендә хәлендә кыйблага каршы торып, кояш баеганчы дога кылды. Шул вакыт тукталган урын гына тукталыш урыны булмыйча, Гарәфәнең бөтенесе тукталыш урыны икәнлеген, Гарәфә көн иртә намазыннан элек килеп җиткән кеше хаҗга ирешкәнлеген сөйләде.

«الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي
وَرَضِيتُ لَكُمُ الْإِسْلَامَ دِينًا»[2]

аяте ошбу вакытта иңдерелде.

Ошбу вакыт халык рәсүлуллаһның руза булуы-булмавы хакында шикләнәләр иде. Габбас хатыны Үмм әл-Фазыл сынау өчен аңа бер савыт сөт җибәрде. Рәсүлуллаһ дөя өстендә сөтне эчте. Кояш баегач, Гарәфәдән Мүздәлифәгә төште. Артына Үсәмә бине Зәидне атландырган иде. Юлда һаман тәлбия әйтә килде. Мүздәлифәгә төшкәч, яңадан тәһарәт алды һәм Билалга азан әйтергә кушты. Камәт

1 “Намазыгызны тәмамлагыз! Чынлыкта исә мин сәфәрдәмен” хәдисе Мәккә алынган көндә, Мәккә эчендә әйтелгән сүздер. “Зәдүл-мәгад”, 1 т., 229 б. Ибнү Кайим хәзрәтләре, бу вакыйганы кыскартып, уку сәфәренең билгеле бер дәвер вә билгеле бер көннәр белән чикләнелмәгәнлегенә, мосафирга җомга урынына өйлә укырга тиешлегенә бер дәлил итеп тоту, рәсүлуллаһның сөннәте шулай булганын бәян итәдер. 1 т., 229 б. – авт.

2 «Бүген сезнең өчен динегезне камил кылдым һәм нигъмәтемне сезгә тәмамладым, һәм сезгә дин итеп Исламны разый кылдым» Мәидә/3. – тәрҗ.



www.darulkutub.com

әйтелгәч, ахшам намазы укылды. Беркадәр торганнан соң азансыз, камәт белән генә ясту намазы укылды.

Мүздәлифәдә кунып, зөлхиҗҗәнең унынчы көнендә, таң аткач, иртә намазын укыды да, дөясенә атланып, «Мәшгару хәрам»[1]гача барды. Анда туктап торды. Туктап торган вакытында кыйблага каршы торып дога кылды, тәкбир вә тәһлил әйтте. Соңра Минага юнәлде. Бу вакыт артына Фазыл бине Габбасны атландырган иде. Юлда аңардан җиде таш алдырды. Ошбу вакыт Хасгам кабиләсеннән бер хатын рәсүлуллаһны туктатып: «Я, Рәсүлуллаһ, минем атам ярдәмгә мохтаҗ карт, аның атка атланырга көче юк, аның өчен хаҗ кылсам ярыймы?» – диде. Рәсүлуллаһ моңа: «Ярый, кыл», – диде. Шул вакыт Фазыл белән мәзкүр хатын бер-берсенә карашып торалар иде. Рәсүлуллаһ моны күреп, Фазылның битен кулы белән каплап, башын читкә борды. Икенче бер кеше карт анасы өчен хаҗ кылу хакында сораган иде. Аңа да: «Анаңның бурычын үтәү ярый бит, шуның кебек аның өчен хаҗ кылу да ярый», – диде. «Вәди мүхәссир»[2]гә килеп җиткәч, беркадәр дөясен караштыргалап алды. Шулай итеп, Минага килеп җитте.

## *Минадагы хотбә*

Минада «Җәмратү әл-гакабә»гә каршы торып, дөя өстендә җиде таш атты. Һәр ташны тәкбир белән атар иде. Соңра Минада хотбә укып, халыкка хаҗның гамәлләрен өйрәтте. Мәккәнең башка шәһәрләргә караганда артыклыгын, корбан көннең бөеклеген сөйләде. Үзенең бу елдан соң хаҗ кыла алмау ихтималын сөйләп, халык белән саубуллаш-

1 Мүздәлифәдә бер урындыр – авт.

2 Мина белән Мүздәлифә арасындагы бер вәдидер – авт.

ты. Үзеннән соң бердәмлек белән торырга, ихтилаф кылышмаска кушты. Сөйләгән сүзләрен шунда булмаган кешеләргә ирештерергә кушты. Бу хаҗның «әл-Вәдәгъ хажы» дип аталуы да рәсүлуллаһның халык белән саубуллашуыннандыр.

Ошбу вакыт халык рәсүлуллаһка хаҗ гамәлләрендәге кайбер кимчелекләрен сөйлиләр, рәсүлуллаһ аларга: «Кайгырырлык түгел, эшлә», – дип җавап бирә иде. Моннан соң рәсүлуллаһ Мәнхәргә барып, үз кулы белән алтмыш өч дөя чалды. Калган 37сен Гали бине Әбү Талибкә чалырга кушты. Корбан итен үзе дә ашады. Тиреләрен сәдака итеп таратты. Корбаннар чалынып беткәч, Мүгаммәр бине Габдулланы чакырып чәчен алдырды вә ихрамнан чыкты. Бу вакытта сәхабәләрдән кайберләре рәсүлуллаһның чәч бөртекләрен алганнары ике сахих хәдисләр җыентыгында риваять ителәдер.

Шуннан соң рәсүлуллаһ дөягә атланып Мәккәгә килде һәм Бәйтуллаһны тәваф итте. Мәзкүр тәвафка «Тәвафу зиярат», «Тәвафу садр», «Тәвафу ифаза» диелер. Ошбу вакыт аяк өстендә Зәм-зәмнән су эчте. Соңра яңадан Минага килеп өйлә намазын укыды. Минада тәшрикъ көннәренең һәркайсында беренче Җәмрадә, уртанчы Җәмрадә, вә өченче Җәмрадә (Җәмратү әл-Гакабә) җидешәр таш атар иде. Таш атып беткәч, кыйблага каршы торып, озын дога кыла иде. Югарыда зекер ителмеш хотбәләрдән башка Рәсүлуллаһ тәшрикъ көннәренең икенче көнендә бер хотбә сөйләде. Шулвакыт «Наср» сүрәсе иңде[1].

Минада шимбә, якшәмбе, дүшәмбе көннәр калып, сишәмбе көн Мухассабка[2] барды. Анда өйлә, икенде, ахшам

1 "Зәдүл-мәгад", 1 т., 245 б. әл-Видагъ хажы хакында язганыбыз Зәдүл-мәгаддан алынды – авт.

2 Мәккә белән Мина арасында бер урын булып, Мәккәгә якынрактыр. Тагы "Батхау Мәккә" дип тә танылган. Хәҗҗүнгә барып чикләнәдер – авт.

вә ястү намазларын укып азрак ятып алды. Аннан соң Мәккәгә килде. Төнлә Бәйтуллаһны тәваф итте. Моңа «әл-Видагъ тәвафы» диләр. Иртә намазын Мәккәдә укып, зөлхиҗҗәнең ундүртенче чәршәмбе көнне Мәдинәгә юнәлделәр.

Ошбу хаҗ, рәсүлуллаһның иң беренче хаҗы булып, моннан элек кылмаган иде. Гомрәләре исә дүрттер: Худәйбия гомрәсе, Каза гомрәсе, Җигъранә гомрәсе, ошбу хаҗ белән кылынган гомрә. Әл-Видагъ хаҗының Ифрад, Тәмәттугъ, Кыйранлыгы хакында галимнәр арасында каршылыклы фикерләр булса да, Кыйраны өстенрәктер.

## *Вәкилләр килү*

Мәккә фәтех ителеп, Корәеш гарәпләре Исламияткә кергәч, икенче тарафтан Ислам гаскәре «Тәбүк» дигән җиргә кадәр барып, Рум дәүләте белән хисаплашырлык булып килгәнен исбат иткәч, гарәп кабиләләре Мәдинәгә вәкилләр җибәреп, рәсүлуллаһка тапшырыла вә Исламиятне кабул итә башладылар. Илче төркемнәренең килүе тугызынчы елдан башлап рәсүлуллаһның вафатына кадәр дәвам итте. Шуңа күрә тугызынчы елга «Илчеләр елы» диелер. Без бөтен илче төркемнәрне бергә җыеп, унынчы ел вакыйгаларына яздык.

Рәсүлуллаһ Таифны алганнан соң кайтып барганда Сәкыйф башлыкларыннан Гарвә бине Мәсгуднең күңеле Исламияткә тартылып, рәсүлуллаһ артыннан барып, Исламны кабул иткән иде. Гарвә үзенең Таиф халкы арасындагы абруйлы һәм сүзе үтемлелегенә ышанып, аларны Исламияткә чакыру өчен рөхсәт алды. Ләкин күзләре тәгассуб пәрдәләре белән капланган Сәкыйф әһеле, Гарвәнең Исламга килеп, боларны хак дингә дәгъвәт итүен

күргәч, аны үтерде. Шулай да болар рәсүлуллаһтан имин түгелләр иде. Исламиятнең көннән көн алга китүе, Гарәп ярымутравында булган гарәпләрнең төркем-төркем Исламны кабул итүләре, башка кайбер кавемнәрнең дә җизьяләр биреп, рәсүлуллаһның яклавына керүгә мәҗбүр булулары боларның куркуларын арттыра, аларны көннән-көн йомшарта бара иде. Бигрәк тә Хунәйн газвәсеннән соң Исламны кабул иткән Малик бине Гауфның үзенә ияргән кешеләр белән боларны һәрвакыт тынычсызлап торулары, рәсүлуллаһтан дәгъвәт өчен рөхсәт алган бер шәрифнең (Гарвә) болар тарафыннан үтерелүе, боларны һәрвакыт төшенкелектә тота иде. Шунлыктан Гарвәнең үтерелүеннән бер айдан соң, Таифның игътибарлы кешеләре җыелып, бу хакта киңәшләштеләр. Киңәшләшү нәтиҗәсендә, рәисләре Кинәнә бине Габдү Йәлил җитәкчелегендә биш-алты кешелек илче төркем җибәреп, рәсүлуллаһ белән сөйләшергә карар бирделәр. Боларның Мәдинәгә барулары рәсүлуллаһ Тәбүктән кайткан вакытка туры килде.

Рәсүлуллаһ боларны Коръән ишетсеннәр вә сәхабәләрнең намаз укуларын күрсеннәр өчен мәчет янындагы бер чатырга урнаштырды. Болар берничә көн рәсүлуллаһ белән сөйләшкәннән соң Исламиятне кабул иттеләр. Рәсүлуллаһ боларга үз араларыннан Коръәнне иң күп белгән Госман бине Әбү әл-Гасны баш итеп куйды.

Мәзкүр илче төркеменә рәсүлуллаһ Таиф халкын Исламга чакырырга кушкан иде. Болар тегеләрнең буйсынмауларыннан куркып, башта Исламда икәнлекләрен әйтмәделәр. Киресенчә, «Мөхәммәдне җиңел шартларга күндерергә мөмкин түгел, аның куәт вә көче арткан, бөтен халык аңа тапшырылып тору өстендәдер. Безгә зина, хәмер вә риба-

ны ташлау, Ләтне җимерү кебек шартлар куйды. Шунлыктан кабул итмәдек, сезнең үзегезгә тапшырдык», – диделәр. Сәкыйф халкы башта бу шартларны кабул итергә разый булмасалар да, ахырда ризалык күрсәттеләр. Болар Исламга килгәч, рәсүлуллаһ Әбү Сафүән бине Хәрб белән Мугыйра бине Шәгъбәне җибәреп, Сәкыйф поты булган «Лат»не җимертте.

## *Габдүл Кайс илчеләре*

Бер көнне рәсүлуллаһ сәхабәләр белән мәҗлестә утырганда, Габдүл Кайс илчеләре килеп, рәсүлуллаһка сәлам бирделәр. Шул ук мәҗлестә рәсүлуллаһ аларның киләчәкләреннән хәбәр биргән вә аларны хәерле сүзләр белән сөйләгән иде. Рәсүлуллаһ һәм сәхабәләре боларны гаять шатлык белән каршы алдылар.

Габдүл Кайс, Ватаннарының Мәдинәгә ерак булуын, килгәндә күп мәшәкатьләр чиккәнлекләрен, юл дошманнардан куркынычлы булып, Харам айларыннан башкаларында Мәдинәгә килү мөмкин булмаячагын сөйләп, үзләренә нәрсәләр эшләү тиешлеген ачык бәян итүен үтенде. Моннан соң рәсүлуллаһ боларга иман, намаз уку, зәкәт бирү, Рамазан рузасын тотуны әмер итте. Ганимәттән биштән берен бирергә кушты. Иманның «Лә иләһә иллә Аллаһы, Мөхәммәд рәсүлуллаһ» дигән шәһадәттән гыйбарәт икәнлеген сөйләде. Дәббә, хәнтәм, нәкыйрь, мүзәффәттә ширбәт ясап эчүдән тыйды[1]. Илчеләр эчендә Габдулла бине Гауф әл-Әшах исемендә берәү бар иде. Бу кеше боларның иң кечкенәләре

1 Дәббә – эчен алып ташлап, савыт урынына йөртелгән кабактыр;
Хәнтәм – махсус май белән майлана торган чүлмәк;
Нәкыйрь – хөрмә агачының төбеннән ясалган савыт;
Мүзәффәт – сумала белән буялган махсус савыт – авт.

һәм иң ямьсезе иде. Рәсүлуллаһ: «Синең ике гүзәл табигатең бар: килешү һәм җитди күренеш», - дип моның күңелен тапты. Шушы кеше рәсүлуллаһтан: «Әй, рәсүлуллаһ, безгә аз гына булса да хәмер эчәргә рөхсәт бир. Безнең җиребезнең һавасы начар. Хәмер эчмәсәк, корсакларыбыз күбенеп, авыраячакбыз», – диде. Рәсүлуллаһ моңа: «Юк, азга рөхсәт бирсәм, күбен эчәчәксез. Соңыннан бер-берегезгә һөҗүм итеп, үтерешәчәксез», – диде.

Рәсүлуллаһның боларның мәзкүр савытлардан эчүдән тыюы, боларның хәрам икәнлегеннән булмыйча, саклану чарасы буларак иде. Саклану чарасы, хәрам нәрсәләрдә төп сәбәпнең булуы белән хәрамлык булыр. Шуның өчен дә рәсүлуллаһ халык хәмер эчүдән тыелып, хәвеф юкка чыккач, мәзкүр савытларны кулланырга рөхсәт бирде. Рәсүлуллаһның башта каберләрне зиярат итүдән тыюы да шуның кебек сәбәптән иде. Соңында халыкның калбендә тәүхид ныгып, ширек вә потларга гыйбадәт итү бетерелгәч, сәхабәләр кабердән ярдәм сорау һәм аларны арадашчы итү куркынычы беткәч, рөхсәт бирде. Габдүл Кайс илчеләренең килүе тугызынчы елда иде.

## *Бәни Хәнифә делегациясе*

Рәсүлуллаһка килгән илчеләрдән берсе Ибне Хәнифә илчеләре булып, шуның эчендә мәшһүр Мүсәйләмә дә бар иде. Ул: «Әгәр Мөхәммәд үзеннән соң урынына мине калдырса, аңа иярәчәкмен», – дип сөйләнә иде. Моннан элек рәсүлуллаһ бер төш күреп, өммәтеннән ике ялган пәйгамбәрлек дәгъва итүче чыгуы турында белдерелгән иде. Рәсүлуллаһ, шул вәкилләр арасында Мүсәйләмәне күргәч, аның шул ике ялганчы пәйгамбәрнең берсе булганлыгын фараз итте.

## *Мүсәйләмә әл-Кәззәб*

Ибне Хәнифә вәкилләре Исламиятне кабул итеп, ватаннарына кайтып китсәләр дә, беркадәр вакыттан соң Мусәйләмә пәйгамбәрлекне дәгъва кыла башлады. Шуның белән бергә ул рәсүлуллаһның пәйгамбәр булуын да таный иде. Ул кавеменнән намаз укуны бетертте, хәмер вә зинаны хәләл кылды. Ибне Хәнифә гарәпләре моңа ияреп, мөртәт булдылар. Мүсәйләмә рәсүлуллаһка ошбу рәвештә хат язды: «Аллаһының рәсүле Мүсәйләмәдән Аллаһының рәсүле Мөхәммәдкә. Мин сиңа пәйгамбәрлектә тиңдәш булдым. Мөлкәтеңнең яртысы безгә, яртысы Корәешкә булачак, фәкать Корәешләр гадел халык түгелләр».

Рәсүлуллаһның моңа каршы ошбу хатны язганлыгы риваять ителәдер: «Аллаһының рәсүле Мөхәммәдтән ялганчы Мүсәйләмәгә. Туры юлга ияргәннәргә сәлам булсын. Җир Аллаһынықы булып, теләгән колына бирәчәк. Фәкать эшнең соңы тәкъва кешеләрнең файдасынадыр».

Рәсүлуллаһ Мүсәйләмәнең илчеләреннән аның хакында нинди фикердә икәнлекләрен сорагач, болар Мусәйләмәнең пәйгамбәрлегеннән канәгать булуларын сөйләделәр. Моңа каршы рәсүлуллаһ: «Әгәр илчене үтермәү гадәте булмаса иде, сезне үтерер идем», – диде. Илчеләр нинди фикердә булсалар да, рәсүлуллаһ аларга тими торган иде. Мүсәйләмәнең мәктүб язуы унынчы елда иде.

Рәсүлуллаһ Мүсәйләмә белән сугышыр өчен Фурат бине Хәйән әл-Гыйҗли аркылы Сүмәмә бине Үсәлгә хат язса да, аның кулында җитәрлек көч булмаганлыктан, ул каршы тора алмады. Киресенчә, Бәхрайнгә әл-Галәү әл-Хазрами янына китте. Мүсәйләмәнең үтерелүе Әбү Бәкер заманында

Гыйкримә вә Халид гаскәре тарафыннан булмыштыр. Аны мәшһүр Вәхши үтерде.

## *Нәҗран илчеләре*

Илчеләр төркемнәреннән берсе Нәҗран насараларыннан иде. Алар алтмыш атлы кешедән гыйбарәт булып, араларында башлыклардан бик күпләре бар иде. Аларның өсләрендә гаять матур ефәк киемнәр, бармакларында алтын йөзекләр иде. Болар рәсүлуллаһка бүләк итеп төрле келәмнәр алып килгәннәр иде. Рәсүлуллаһ шул келәмнәрнең сурәтлеләрен кире кайтарып бирде, сурәтсезләрен кабул итте. Алар Мәдинәгә килгәч, рәсүлуллаһ белән сөйләшер өчен мәчеткә керделәр, гыйбадәт вакытлары җиткәч, мәчеттә үзләренчә гыйбадәт кылдылар. Сәхабәләрдән кайберләре боларның мәчеттә гыйбадәт кылуларына эчләре пошып, тыймакчы булсалар да, рәсүлуллаһ юл бирмәде. Моннан соң рәсүлуллаһ аларны Исламияткә дәгъвәт итте. Арада озын сөйләшү булып, рәсүлуллаһ аларның Гайса галәйһиссәлам хакында булган игътикадларын юкка чыгарды. «Әл Гыймран» сүрәсенең башыннан сиксәнләп аять ошбу Нәҗран насаралары хакында иңде. Ахырда рәсүлуллаһ боларны шушы сүрәдәге

«فَمَنْ حَآجَّكَ فِيهِ مِن بَعْدِ مَا جَاءَكَ مِنَ الْعِلْمِ فَقُلْ تَعَالَوْاْ نَدْعُ أَبْنَاءَنَا وَأَبْنَاءَكُمْ...»[1]

аяте буенча ләгънәт кылышуга дәгъвәт итте. Ләкин алар бу

1 «Әл Гимран»/61 аять: «Ачык дәлилләр килгәннән соң, берәү Гыйса хакында синең белән бәхәсләшсә, син аларга әйт: «Без үзебез, балаларыбыз һәм хатыннарыбыз һәм сез үзегез, балаларыгыз һәм хатыннарыгыз бер урынга җыелыйк, аннары Гайса хакында кем ялган сөйләсә, аңа Аллаһының ләгънәте булсын, дип Аллаһыдан сорап, бер-беребезгә дога кылышырбыз» – тәрҗ.



www.darul-kutub.com

эшкә батырчылык итә алмадылар, тартындылар. Исламиятне кабул итмәүләре дә рәсүлуллаһның расүллегенә канәгать итмәгәнлектән булмыйча,  Рум императорлары тарафыннан килә торган файдаларның китүеннән куркып иде. Моннан соң болар һәр ел ике мең кием биреп тору шарты белән солых төзеделәр. Җизья алыр өчен рәсүлуллаһтан гаять ышанычлы булган бер кешене җибәрүен үтенделәр. Рәсүлуллаһ аларга Әбү Губәйдә бине әл-Җәррахны җибәрде. Нәҗран илчеләренең килүе унынчы елда иде.

## *Түҗиб вәкиллеге*

Түҗиб гарәпләре (Киндә гарәпләреннән бер кабилә) Исламны кабул итеп, Мәдинәгә 13 кешедән гыйбарәт илчеләр җибәрделәр. Алар үзләре белән зәкәт малларын да алып килгәннәр иде. Рәсүлуллаһ боларның килүләренә бик шатланды. Үзләрен хөрмәтләде вә сәхабәләргә дә аларны хөрмәтләргә кушты. Алып килгән зәкәт малларын, кире алып кайтып, үз фәкыйрьләренә өләшергә кушты. Алар Мәдинәдә булган вакытларында Коръән уку, рәсүлуллаһтан дин вә шәригать өйрәнү белән мәшгуль булдылар. Шунлыктан рәсүлуллаһ боларны гаять яратты. Үзләренә күп бүләкләр биреп озатты. Ошбу кавем рәсүлуллаһ белән унынчы елны саубуллашу хаҗында очрашты.

## *Ибне Сәгъд вәкилләре*

Ибне Сәгъд бине Һүзәйм гарәпләре (Кузага кабиләләреннән) Исламны кабул итеп, араларыннан берничә кешене сайлап, рәсүлуллаһка бәйгать итү өчен җибәрделәр. Алар рәсүлуллаһ белән күрешү өчен мәчеткә

килгәндә, рәсүлуллаһ вә сәхабәләр җеназа укып торалар иде. Болар мәчетнең бер тарафында җеназа укылып бетүен көтеп тордылар. Рәсүлуллаһ намаздан соң аларны чакырып, нинди кабиләдән икәнлекләрен, моңарчы Исламиятне кабул итү-итмәүләрен сорады. Алар: «Кабул иттек», – дип җавап бирделәр. Моннан соң рәсүлуллаһ: «Алай булгач кардәшегезгә җеназа намазын уку кирәк иде», – диде. Болар: «Сиңа бәйгать бирмәстән элек намаз уку дөрес булмас дип уйладык», – диделәр. Моңа каршы рәсүлуллаһ: «Мөселман булыр өчен Исламиятне махсус урында, махсус кеше кулыннан кабул итү шарт түгел, кайда кабул итсәң дә, мөселман буласың», – диде. Болар Мәдинәдә берничә көн калып, Ислам хөкемнәрен өйрәнгәннән соң, ватаннарына кайтып киттеләр.

## *Тай илчеләре*

Рәсүлуллаһка килгән илчелекләрдән берсе Тай гарәпләреннән иде. Алар эчендә башлыклары Зәйдү әл-Хайл бар иде. Рәсүлуллаһ моның яхшы сыйфатларына сокланып: «Бу вакытка кадәр миңа килгән кешеләр эчендә иң артыгын таптым», – дию вә ул кешегә «Зәйдү әл-Хайр» дип исем бирүе риваять ителәдер.

## *Фәзәра илчеләре*

Фәзәра гарәпләре (Гатафан кабиләсеннән) Исламиятне кабул итеп, араларыннан берничә кешене илче итеп рәсүлуллаһка җибәрделәр. Боларның килүе рәсүлуллаһның Тәбүк сугышыннан кайтуына туры килде. Бу вакыт аларда, бер дә яңгыр булмаганлыктан, каты ачлык хөкем сөрә, ачлыктан маллары кырылып ята иде. Болар рәсүлуллаһка бәйгать

биргәннән соң, Аллаһыдан яңгыр соравын үтенделәр. Моннан соң рәсүлуллаһның минбарга чыгып, озын дога кылып, яңгыр соравы риваять ителәдер.

## *Ибне Әсәд илчеләре*

Ибне Әсәд гарәбләре Исламиятне кабул итеп, рәсүлуллаһка бәйгать итү өчен ун кешедән гыйбарәт бер илчеләр төркеме җибәрделәр. Болар рәсүлуллаһтан җаһилият заманында кылына торган гыяфәт[1] вә күрәзәчелек кебек эшләрнең хөкемен сорадылар. Рәсүлуллаһ Исламияттә боларның тыелган икәнлеген сөйләде. Илчеләр Мәдинәдә берничә көн торып, шәригать хөкемнәрен өйрәнгәннән соң, бүләкләр алып кайтып киттеләр.

## *Ибне Мүхәриб илчеләре*

Ибне Мүхәриб гарәпләре дә Исламиятне кабул итеп, бәйгать өчен Мәдинәгә ун кешелек бер төркем илчеләр җибәрделәр. Бу гарәбләр элек рәсүлуллаһның иң зур дошманнарыннан иде. Рәсүлуллаһ Гукәз, Мәҗнә, Зүл Мәҗәз кебек ярминкәләрдә гарәп кабиләләреннән саклауларына алуны үтенеп йөргәндә, иң каты җавап бирүчеләрнең берсе ошбу кабилә гарәпләре иде. Ошбу төркем эчендә Гукәздә рәсүлуллаһка бик яман сүзләр сөйләгән һәм аны төрлечә изалаган берсе бар иде. Бу кеше рәсүлуллаһтан үткән кабахәтлекләрен гафу итүен, моның өчен Аллаһыдан гафу соравын үтенде. Рәсүлуллаһ аңа: «Ислам үткәндәге нәрсәләрне өзә», – дип җавап кайтарды.

1 Гыяфәт – кошлар очуыннан юрау. – тәрҗ.

## *Киндә илчеләре*

Киндә илчеләре алтмыш атлы кешедән гыйбарәт булып, араларында иң бөек рәисләре Әшгас бине Кайс бар иде. Алар рәсүлуллаһ хозурына кергәч, аны сынау өчен: «Әй, Мөхәммәд! Без бер нәрсә яшердек, пәйгамбәр булсаң шуны бел», – диделәр. Рәсүлуллаһ моңа каршы: «Мондый эшләр күрәзәчеләрдән соралыр. Мин күрәзәче түгелмен. Чөнки күрәзәчеләр җәһәннәмдә булачаклар. Аллаһы Тәгалә миңа бер китап бирде, минем пәйгамбәрлегемне раслар өчен шул җитә», – диде. Соңра аларга «әс-Саффәт» сүрәсен укыды. «Вә Раббүл мәшәрик» сүзенә җиткәч, тәэсирләнеп елады. Илчеләр елауның сәбәбен сорагач: «Мин ошбу китапны миңа биргән Аллаһыдан куркып елыйм. Аллаһы мине кылыч сыры кебек нечкә бер юлга күндерде. Әгәр аңардан адашсам, һәлак булачакмын», – диде. Моннан соң илчеләр Исламны кабул итү белән шәрафәткә ирештеләр.

## *Зыймәм бине Сәгъләбә*

Рәсүлуллаһ сәхабәләр белән мәчеттә утырган вакытта, сахра гарәпләреннән чәче тузган бер кеше килеп, дөясен мәчет йортына кертеп чүктерде. Соңра рәсүлуллаһны сорашып, каршысына барып: «Мин сиңа каты сораулар бирәчәкмен, кәефең китмәсен», – диде. Рәсүлуллаһ моңа теләгән нәрсәне сорарга кушты. Теге кеше: «Аллаһы хакына сорыйм, Аллаһымы сине бөтен халыкка пәйгамбәр итеп җибәрде? Бары тик бер Аллаһыга гыйбадәт итәргә, ата-бабаларыбыз гыйбадәт итеп килгән мәгъбудләрне ташларга Аллаһымы кушты? Тәүлектә биш тапкыр намаз укыр-

га, байларыбызга малларын фәкыйрьләргә бирергә, көче җиткәннәргә хаҗ кылырга, рамазан аенда руза тотарга Аллаһымы кушты?» – диде. Рәсүлуллаһ ошбу сорауларның һәркайсына: «Әйе, Аллаһы кушты», – дип торды. Бу гарәп рәсүлуллаһның шушы җавабын ишеткәч: «Әй, Мөхәммәд, мин Зыймәм бине Сәгъләбә, мин синең пәйгамбәрлегенә ышандым, син кушкан нәрсәләрнең барысын да арттырмый, киметми эшләячәкмен», – дип чыгып китте. Рәсүлуллаһ моның артыннан: «Әгәр бу кеше сүзендә торса, җәннәткә керәчәк», – дип калды. Зыймәм үз кавеменә кайтып Исламияткә дәгъвәт иткәч, бөтенесе кабул иттеләр. Зыймәм Ибне Сәгъд бине Бәкер кабиләсеннән иде.

## *Садә илчеләре*

Садә гарәпләреннән (Йәмәндә бер кабилә) унбиш кеше Мәдинәгә килеп Рәсүлуллаһка бәйгать бирделәр. Рәсүлуллаһ аларга кавемнәрен Исламияткә дәгъвәт итәргә кушты. Алар үз ватаннарына кайткач, араларында Исламият таралды. Әл-Вәдәгъ хаҗында алардан йөз кеше рәсүлуллаһ белән күрештеләр. Рәсүлуллаһ башта аларны Исламияткә дәгъвәт итү өчен Кайс бине Сәгъд җитәкчелегендә дүрт йөзләп сәхабә җибәрергә әзерләнгән булса да, анда Исламият тарала башлаганын ишетеп җибәрергә хәҗәте калмады. Садә вәкилләре килүе Мәккә алынып кайткач иде.

Румлылар тарафыннан Шам гарәпләренең бер төркеменә вәли итеп куелган Фәрва бине Гамр әл-Җүзәми Исламны кабул итеп, рәсүлуллаһка илче җибәреп, аңа бүләк буларак бер качыр тәкъдим иткән иде. Румлылар моны ишеткәч, Фәрваны кулга алып үтерделәр. Фәрва Мәганда тора иде.

## *Габәс илчеләре*

Рәсүлуллаһка килгән илчелекләрдән берсе – Ибне Габәстәндер. Рәсүлуллаһ аларны бик яхшы кабул итте. Болар алдында Халид бине Синән әл-Габәсине искә төшереп, аның нинди яхшы кеше булганлыгы хакында сүз сөйләде. Аңардан соң кеше калу-калмавы хакында илчеләрдән сорашты. Аның хакында рәсүлуллаһның: «Ул нәби иде, халкы аны зая итте, кадерен белмәде», – диюе риваять ителәдер[1].

## *Әздү илчеләре*

Әздү Шәнүә гарәбләреннән берничә кеше рәисләре Сурад бине Габдуллаһ кул астында рәсүлуллаһка килеп, Исламны кабул иттеләр. Рәсүлуллаһ боларга Сурадны әмир итеп билгеләде һәм аңа тирә-яктагы халыкны Исламияткә дәгъвәт итәргә кушты. Әздү Йәмән кабиләләреннән берсе иде.

## *Ганәс илчеләре*

Ганәс (Йәмәндәге Мәзхиж ыруыннан) гарәбләреннән мәшһүр Әсвәд әл-Ганәси килде. Ул Исламны кабул итеп, ватанына кайтты. Ләкин әл-Вәдәгъ хаҗыннан соң рәсүлуллаһның авыру хәбәрен ишеткәч, үзен пәйгамбәр дип игълан итте. Әсвәд фокус эшләренә оста булып, халыкка могҗиза дип төрле нәрсәләр күрсәтә иде. Тиз арада моңа Мәзхиж вә башка гарәпләрдән бик күп иярченнәр җыелды. Ул гаскәр җыеп Нәҗранга барды һәм рәсүлуллаһның андагы вәлиләре Гамр бине Хәзим белән Халид бине Сәгыйдләрне җинде. Соңра Сангагә барып, анда вәли булган Шәһр бине

1 "Зәдүл-мәгад", 2 т., 5 б. – авт.

Бәзәнне үтерде һәм хатыны Азәдне көчләп үзенә никахлады. Шулай итеп, тиз арада Әсвәд бөтен Йәмәнне үз кул астына алды. Рәсүлуллаһ вәлиләренең күбесе Гак вәлисе әт-Таһир бине Әбү Һәләдән ярдәм сорадылар. Рәсүлуллаһка Әсвәднең хәбәре ишетелгәч, аңа каршы торырга әмер итеп, Йәмәндәге вәлиләренә хат язды. Азәд Әсвәднең никахында булса да, көчләнеп кенә тора, эчтән аңардан үч алу ниятендә иде.

Рәсүлуллаһның кайбер вәлиләре, Азәд вә аның әтисе белән бертуган кардәшенең улы Фәйрүз әд-Дилмине өндәп, Әсвәдне хәйлә белән үтерергә килештеләр. Әсвәднең үтерелүе рәсүлуллаһның исән вакытында булса да, ошбу хәбәр килгәндә рәсүлуллаһ вафат булып, Әбү Бәкер хәлиф булган иде. Әсвәднең исеме Гәйһилә бине Кәгъб булып, Зуль Химар ләкабе белән йөртелә иде.

## *Бүҗәйлә илчеләре*

Бүҗәйлә (Йәмән кабиләләреннән) гарәпләреннән йөз илле кеше Җәрир бине Габдулла рәислегендә Мәдинәгә килеп, Исламиятне кабул иттеләр. Рәсүлуллаһ, болар килмәс борын, киләчәкләре хакында сөйләп, аларны хәер белән искә алды. Рәсүлуллаһ Җәриргә Бүҗәйлә вә Хасгәм кабиләләренең сыннары булган Зүл Хассанны җимерергә әмер итте. Җәрир шул йөз илле атлы гаскәре белән барып аны җимерде.

Моннан тыш рәсүлуллаһка килгән илчеләр арасында Мурад, Һәмәдән, Гузра, Бәли, Бәһра (Йәмәндәге бер кабилә), Хаулән, Зүбәйд, Гамид (Йәмәндәге кабилә), Нәхгъ (Йәмәндәге кабилә) вә башкалар бар иде.

Нәхгъ илчеләре иң соңгы илчеләрдән булып, унберенче елның мөхәррәм аенда килгәннәр иде. Алар ике йөз

кешедән гыйбарәт булып, рәисләре Зирара бине Гамр иде. Гассан гарәпләреннән дә өч кеше Мәдинәгә килеп, Исламиятне кабул иткәннәр иде.

Рәсүлуллаһ вәкилләрне хуш күреп кабул итә, аларга хөрмәт күрсәтә, дәрәҗәләренә күрә бүләкләр биреп озата иде. Баштарак кунаклар махсус кешеләрдә кунак булсалар да, соңыннан бик күбәя башлагач, Мугәз бине Гыйфра хатыны Рамлә бинте әл-Харисның ханәсе гомуми мөсафирханә итеп билгеләнде.

Рәсүлуллаһның Мария кыбтыядән туган улы Ибраһимның вафаты ошбу елда булды. Ул вафат булган көнне кояш тотылды. Халык моны Ибраһимның вафатына бәйләде. Рәсүлуллаһ, аларның ошбу батыл фикерләрен бетерү өчен, ай вә кояшның Аллаһының аятьләреннән булган бер галәмәт икәнлекләрен, аларның тотылулары берәүнең тууы яки вафаты сәбәпле булмаганлыгын бәян итте.

# Унберенче ел

## *Үсәмә бине Зәйд сәриясе*

Унберенче елның сәфәр ае ахырларында рәсүлуллаһ Зәйд бине Хәрисә һәм иптәшләрен шәһид иткән румлылар белән сугыш кылу өчен зур гаскәр әзерләде. Мәзкүр гаскәр эчендә бөек мөһаҗирләр вә әнсарилар, болар җөмләсеннән Әбү Бәкер, Гомәр, Әбү Губәйдә бар иде. Рәсүлуллаһ гаскәр башлыгы итеп Зәйд бине Хәрисәнең улы Үсәмә бине Зәйдне билгеләде. Үсәмә бу вакытта унҗиде яшьлек егет иде. Мондый яшь бер егетнең бөек сәхабәләргә баш булуын хуп күрмичә, кайбер халык яратмыйча сөйли башлады.



www.darul-kutub.com

Рәсүлуллаһка аларның сүзләре ишетелгәч, ачуланып халыкны җыйды һәм ошбу мәгънәдә сүзләр сөйләде: «Әй, халык, минем Үсәмәне гаскәр башлыгы итеп билгеләвемә бәгъзеләрегезнең разый булмаганыгыз аңлашыла. Сез моннан элек аның атасы Зәйд бине Хәрисәне дә башлык итеп билгеләвемә ризасызлык күрсәттегез. Ләкин Зәйд булсынмы, Үсәмә булсынмы, җитәкчелек итәргә иң лаеклы затлардыр. Алар миңа иң сөекле кемсәләрдер. Үсәмә сезнең иң яхшыларыгыздандыр, аны каты сүзләр белән рәнҗетмәгез», – диде. Фәкать бу вакыт рәсүлуллаһ хасталанып киткәнлектән, гаскәр аның сәламәтләнүен көтеп, сәфәргә чыкмады. Боларның сәфәре Әбү Бәкер хәлиф булганда кылынды.

## *Рәсүлуллаһның вафаты*

Исламият камил дәрәҗәгә ирешеп, Гарәбстанда булган бөтен гарәбләр Исламны кабул итү белән мушәррәф булгач, Аллаһы тарафыннан

«الْيَوْمَ أَكْمَلْتُ لَكُمْ دِينَكُمْ وَأَتْمَمْتُ عَلَيْكُمْ نِعْمَتِي وَرَضِيتُ لَكُمُ الْإِسْلَامَ دِينًا»[1]

аяте иңгәч, рәсүлуллаһ үзенең үлем вакыты якынлашуын сизгән вә әл-Видагъ хаҗында халык белән саубуллашкан иде. Сафәр аеның ахырларында бер төнне рәсүлуллаһ, азат итәсе Әбү Мүвәһибә белән Бәкыйгу Гаркадкә барып, үлекләргә истигъфар кылып кайткан иде. Шул төннең иртәсендә башы авырып хасталана башлады. Рәсүлуллаһның бу авыруы башлану Зәйнәб бинте Җәхш өендә иде. Авыруы җиңел чакла-

1 «Мәидә»/3: «Бүген динегезне камил кылдым, бирәсе нигъмәтләремне дә биреп тәмам кылдым һәм сезгә Ислам динен ихтыяр иттем» – тәрж.

www.darul-kutub.com

рында һәр хатынының чиратында өйләренә бара иде. Бер көн Мәймүнә өендә авыруы катылангач, хатыннарын чакырып, моннан соң Гайшә өендә булырга рөхсәт алды. Бу вакытларда рәсүлуллаһ мәчеткә йөрүен дәвам итә вә халыкка торып намаз укый иде.

## Әбү Бәкергә имтияз

Бер көн рәсүлуллаһ минбарда: «Аллаһы бер колын дөнья белән ахирәттән берсен сайларга ихтыярлы итте, кол ахирәтне ихтыяр итте», – дигән иде. Әбү Бәкер бу сүздән рәсүлуллаһның вафат булачагын аңлап: «Ата-аналарыбыз сиңа фида булсын», – дип елый башлады. Моны күреп Рәсүлуллаһ: «Мин Әбү Бәкер дуслыгы кебек бер дуслык күрмәдем. Мин иң күп аңа рәхмәтлемен. Әгәр дус сайларга булсам, аны сайлар идем. Фәкать Ислам туганлыгы җитәрлектер», – диде. Моннан соң мәчеттә Әбү Бәкер ишегеннән башка ишекләрне бикләргә кушты[1].

## Әбү Бәкернең имам торуы

Рабигыль-әүвәл аенда, пәнҗешәмбе көнне Рәсүлуллаһның авыруы көчәеп, ястү намазына чыга алмады[2]. Әбү Бәкер әс-Сиддыйкка халыкка имам булып намаз укырга кушты. Ошбу вакыттан алып рәсүлуллаһ вафат булганчы Әбү Бәкер имам булды. Рәсүлуллаһның Әбү Бәкерне имам итеп билгеләве аның үзеннән соң хәлиф булачагына бер ишарә кебек иде. Шуның өчен дә сәхабәләр Әбү Бәкергә

1 Сәхабәләрдән кайберләре үз өйләреннән туры мәчеткә чыгарга кечкенә ишекләр куйганнар иде. Ошбу көн Әбү Бәкер ишегеннән башкаларын, рәсүлуллаһ бикләргә кушты – авт.

2 Бохари, 1 т., 139 б. – авт.

бәйгать биргәндә: «Динебез өчен рәсүлуллаһ разый булган вә ихтыяр иткән кешене дөньябыз өчен ихтыяр итәбез», – димешләрдер. Рәсүлуллаһның үлем чире вакытында Әбү Бәкер имам булып 17 намаз кылуы риваять ителәдер[1].

## *Сәхабәләрдә борчылу*

Рәсүлуллаһның авыруы куәтләнеп намазга чыга алмагач, сәхабәләр бик каты кайгыра башладылар. Аны күрәселәре килеп, сабырсызлыктан мәчет тирәсенә килеп-китеп йөрделәр. Бигрәк тә әнсарилар рәсүлуллаһтан берәр сүз ишетәселәре килә, аның мөбарәк йөзен күрми калырбыз дип, бик борчылалар вә сабырсызланалар иде. Рәсүлуллаһның янында саклап торучы Габбас вә Гали рәсүлуллаһка халыкның дулкынлануы турында хәбәр бирделәр.

## *Намазга чыгу*

Бервакыт рәсүлуллаһ, үзендә беркадәр җиңеллек хис итеп, Габбас белән Галигә култыкланып өйлә намазына чыкты, халык намаз укый иде. Рәсүлуллаһның чыкканын сизеп, Әбү Бәкер артка китмәкче булса да, рәсүлуллаһ урыныннан кузгалмаска кушты. Рәсүлуллаһны Әбү Бәкернең янына утырттылар. Ошбу намазны Әбү Бәкер рәсүлуллаһка ияреп, халык Әбү Бәкергә ияреп укыдылар.[2]

## *Хотбә сөйләве*

Намаздан соң рәсүлуллаһ халыкка хотбә сөйләү өчен минбарга утырды. Иң башта Ухуд шәһидләренә озын итеп дога вә истигъфар кылды. Соңыннан ошбу мәгънәдә сүзләр

1 Ибнү әл-Әсир, 2 т., 122 б. – авт.

2 Бохари, 1 т., 139 б. Шушы намаз шимбә көненең өйләсе булса кирәк – авт.

сөйләде: «Әй, халык, сез минем вафат булуымнан куркасыз икән. Миннән элекке пәйгамбәрләр мәңге калмаган кебек, мин дә калмаячакмын, әлбәттә, бер үләчәкмен. Мин дә, сез дә барыбыз да Раббыбызга барачакбыз. Мин сезгә үземнән соң әүвәлге мөһаҗирләргә хөрмәт вә игътибар итәргә нәсыйхәт итәм. Мөһаҗирләргә үзара гүзәл мөгамәләдә булырга кушам. Мөһаҗирләр әнсариларга яхшы мөгамәлә итсеннәр. Аларга нәсыйхәтем шулдыр. Әнсарилар мөһаҗирләрне йортларына кабул иттеләр. Аларга малларын бүлеп бирделәр. Үзләренә юкны аларга бирергә тырыштылар. Әгәр берәрегез аларның өстеннән хөкем сөрәчәк булса, аларга шәфкать белән мөгамәлә итсен. Бәгъзе кимчелекләр булса, кичерсен! Әй, җәмәгать! Миндә хакы булган кеше сөйләсен. Берәүнең аркасына сукканмын икән, менә аркам, үч алсын. Берәүнең намусына орынганмын икән, менә намусым, үчен кайтарсын. Берәүнең малын алганмын икән, малымны алсын. Минем кәефем китәр, ачуым килер дип курыкмасын. Миндә андый табигать юктыр. Миңа иң сөекле кеше – миннән хакын таләп иткән, өстемдә хакын калдырмаган кешедер. Шулай ук өстендә хакым булган кеше дә бирсен. Дөньяда хур булырмын дип куркып, ахирәт хурлыгына дучар булмасын!». Ошбу вакыт бер кеше торып рәсүлуллаһтан өч дирһәм алачагы барлыгын сөйләгәне, рәсүлуллаһның да моны түләве риваять ителәдер.

## *Васыятьнамә*

Рәсүлуллаһ чирләгән вакытында янына җыелган сәхабәләргә: «Кая, каләм, кара китерегез. Сезгә бер васыятьнамә языйм. Миннән соң адашуга төшмәссез»,

– диде. Сәхабәләр арасында бу хакта ихтилаф булып, бәгъзеләре яздырыйк, бәгъзеләре исә: «Мондый вакытта Рәсүлуллаһны борчу дөрес түгел. Алдыбызда Аллаһының китабы бар бит, шул безгә җитәр», – диделәр. Шунлыктан рәсүлуллаһ васыятьнамә язмады.

## *Гали вә Габбас*

Бер көн Гали бине Әбү Талиб рәсүлуллаһ яныннан чыкты. Сәхабәләр моңардан рәсүлуллаһның хәлен сорадылар. Гали аларга: «Әлхәмдулилләһи, хәле яхшылана бара», – диде. Шул вакыт Габбас Галинең кулыннан тотып, үзенә генә: «Әй, Гали, мин рәсүлуллаһны терелер дип уйламыйм. Үлем алдыннан Габделмоталлиб балаларында заһир була торган галәмәтләрне аңарда күрдем. Әйдә рәсүлуллаһка кереп, үзеннән соң кемне хәлиф кылачагын сорыйк. Әгәр хәлифәлек безгә булса, бик яхшы, алдан белеп торган булырбыз. Әгәр башкага булса, безне аңа тәүсыя итүен үтенербез», – диде. Моңа каршы Гали: «Юк, мин һичничек сораячак түгелмен. Әгәр без сорап та, башкасына бирсә, безгә хәлифәлек җиңел булмас», – диде.

## *Вафат*

Рабигыл-әүвәл аеның 12сендә, дүшәмбе көн рәсүлуллаһ үзендә беркадәр җиңеллек хис итеп, иртә намазында булган сәхабәләрне карар өчен Гайшә бүлмәсеннән чыкты. Мәчет тулы намаз укучы сәхабәләрне күреп, шатланып елмайды. Халык рәсүлуллаһны күреп, шатлыкларыннан ни эшләргә белмәде. Әбү Бәкер рәсүлуллаһны намазга чыга дип уйлап, юл бирмәкче булса да, рәсүлуллаһ аңа намазын дәвам итүгә ишарә кылды.



www.darul-kutub.com

Соңра өенә кереп китте. Шул көн кояш күтәрелгәч, дөньядан кичте. Рәсүлуллаһның үләр алдыннан алдындагы савыттан су алып йөзен сыйпавы вә: «Әй, Раббым, миңа үлем исереклегендә ярдәм бир», – дигәне вә күзләрен йомып: «Рафикъ әгъләне ихтыяр итәм», – диюе Гайшәдән риваять ителәдер.

Рәсүлуллаһның вафаты һиҗрәттән 11 елда, рабигыльәүвәлнең уникенче дүшәмбе көнне иде (Милади белән 632 елның 7 июне туры киләдер). Бу вакыт яше 63 булып, чәч вә сакалында ак бөртекләр күренә башлаган иде.

Берничә сәгать элек кенә боларга елмаеп караган рәсүлуллаһның үлем хәбәрен ишетеп, сәхабәләр бөтенләй шашып калдылар. Хәтта аның вафатына ышанмаучылар да булды. Ошбу җөмләдән хәзрәти Гомәр бөтенләй аптырашта калып: «Монафикъларлардан бәгъзеләре рәсүлуллаһ вафат булды дип ялган сүзләр тараталар. Юк, ул вафат булмады. Муса бине Гыймран галәйһиссәлам кебек Раббысына китте. Күрермен, кайтып шул кешеләрнең кул-аякларын кисәр», – дип халык арасында сөйләп йөрде.

## *Әбү Бәкернең хотбәсе*

Бу вакытларда Әбү Бәкер Кубәдә, «Сунх» дигән мәхәлләдә торган хатынын зиярат итү өчен киткән иде. Рәсүлуллаһның вафат хәбәрен ишетеп Мәдинәгә кайткач, иң беренче Гайшә өенә керде. Рәсүлуллаһ бүлмәнең бер тарафына яткырылып, йөзе пәрдә белән капланган иде. Рәсүлуллаһның йөзен ачып үпте вә бик каты елады. Соңыннан мәчет тирәсенә җыелган халык янына чыгып, аларның шөбһәләрен тарату өчен ошбу сүзләрне сөйләде: «Мөхәммәдкә гыйбадәт итүчеләр булса, белсеннәр: Мөхәммәд үлде. Аллаһыга гыйбадәт итүчеләр белсеннәр:

Аллаһы исән, мәңгелектер!». Соңра

«إِنَّكَ مَيِّتٌ وَإِنَّهُم مَّيِّتُونَ»[1],

«وَمَا مُحَمَّدٌ إِلاَّ رَسُولٌ قَدْ خَلَتْ مِن قَبْلِهِ الرُّسُلُ أَفَإِن مَّاتَ أَوْ قُتِلَ انقَلَبْتُمْ عَلَى أَعْقَابِكُمْ وَمَن يَنقَلِبْ عَلَىَ عَقِبَيْهِ فَلَن يَضُرَّ اللّهَ شَيْئًا وَسَيَجْزِي اللّهُ الشَّاكِرِينَ»[2]

аятьләрен укыды. Әбү Бәкернең мәзкүр сүзләрен ишеткәч, халык аңына килеп, рәсүлуллаһның вафатына ышандылар. Шул вакыт Гомәр: «Бу аятьләрне гүя моңарчы ишетмәгәнмен. Яңа Әбү Бәкердән ишетәм», – дип аягына басып тора алмыйча җиргә егылды.

Рәсүлуллаһны юучы Гали бине Әбү Талиб булып, Габбас, Фазыл бине Габбас, Кусәм бине Габбас, Үсәмә бине Зәйд Рәсүлуллаһның азат ителәсе колы Шәкран ярдәм итәләр иде. Бәдер сәхабәләреннән Әүс бине Хаули Рәсүлуллаһ янына керергә бик үтенгәч, аны да керттеләр. Ләкин ул юуда катнашмады. Юылып кәфенләнгәч, халык берәм-берәм җеназа укыдылар. Ирләр укып бетергәч, хатыннар, аннары сабыйлар укыды[3]. Җеназа укылып беткәч, Гайшә хөҗрәсендә рухы чыккан урында ләхет казылып күмелде. Кабер-шәрифенә Гали, Фазыл бине Габбас, Кусәм бине Габбас, Шакран, Әүс бине Хаули иңдерделәр. Кабердән иң соңгы чыккан кеше Кусәм бине Габбас иде. Кабер җирдән бер карыш кадәр

---

1 «Син (Мөхәммәд галәйһиссәлам) дә, алар да үләчәкләр» әз-Зүмәр/30. – авт.

2 Мөхәммәд бары тик рәсүл генәдер. Аннан алдан бик күп рәсүлләр килеп киттеләр. Әгәр ул үлсә яки үтерелсә, әүвәлге хәлегезгәме кайтачаксыз?! Әүвәлге хәлгә кайткан кешеләр (ширеккә кайтканнар) Аллаһыга аслән зарар итмәячәкләр. Аллаһы Ислам нигъмәтенә шөкрана кылып, аңардан аерылган кешеләргә гүзәл җәзасын бирәчәктер» – авт.

3 Рәсүлуллаһның гомуми мәкъбәрадә күмелмичә, вафат булган урынында күмелүе, Әбү Бәкер әс-Сыйддыйктан: “مَاقُبِضَ النبيّ إلّا دُفِنَ حَيْثُ يُقْبَضُ”[Пәйгамбәрләр вафат булган урыннарында күмелә] хәдисе риваять ителгәнлеге өчендер. Кайберәүләр моны рәсүлуллаһның васыяте буенча диләр – авт.



www.darulkutub.com

күтәрелде. Билал кабернең өстенә су сипте. Рәсүлуллаһның күмелүе сишәмбе көн, төн уртасында иде. Рәсүлуллаһның болай озак күмелми торуы сәхабәләрнең җеназа намазын берәм-берәм укуларыннан килмештер. Рәсүлуллаһның кабер-шәрифе, хәзерге көндә «Рауда мутаһһәра» дип аталадыр.

Менә Гарәбстан сахрасында барлыкка килеп, ятим буларак үскән, кавеменең батыл игътикадлары, әхлак вә гадәтләре белән көрәшкән «Габделмотталибның малае», «Әбү Кәбшә улы» дип хурлап зекер ителгән Мөхәммәд галәйһиссәламнең тормыш тарихы шуннан гыйбарәттер. Ул егерме ел кылган мүбәразә нәтиҗәсендә кавеменең әхлак вә гадәтләрен үзгәртте. Ширек вә потларга табыну урынына бераллалык гакыйдәсен урнаштырды. Башта һичбер ярдәмчесе булмыйча, кавеменең һәртөрле җәбер вә золымнарына сабыр итеп, ахырда аларга өстен булып, әмер һәм тыю аның кулында булды. Аңа ияргән кешеләр миллионнар белән санала башлады. Ул шул егерме ел кадәр аз гына бер вакыт эчендә шулкадәр вәхши, әхлак вә гадәтләр буенча бик түбән, әхлак, мәдәният, игътикад ягыннан түбән бер кавемне, кирәк игътикад, кирәк әхлакта халыкка үрнәк булачак, башкаларга мәдәният чәчәчәк бер халык итеп тәрбияләде. Аның өммәте күркәм әхлак, фазыйләт вә камиллек үрнәге булды.

«كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ»[1] ,
«وَكَذَلِكَ جَعَلْنَاكُمْ أُمَّةً وَسَطًا لِّتَكُونُواْ شُهَدَاءَ عَلَى النَّاسِ»[2]

www.darul-kutub.com

1 «Кешелек өчен килгән өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, изге гамәлләргә өндәдегез, бозыклыктан тыйдыгыз» әл-Бәкара/143. – тәрҗ.

2 «Шулай ук без сезне урталыкта булган өммәт итеп кылдык, бу эшегез белән кешелеккә шаһит булуыгыз өчен» әл-Гыймран/110. – тәрҗ.

аять мәгънәсенә туры килделәр.

Рәсүлуллаһтан соң аңа варис булып, алар бөтен Җир шарына бераллалык гакыйдәсе, фазыйләт вә камиллек орлыклары чәчтеләр. Гаҗәп ки, шулкадәр аз бер вакытта шундый зур бер дөньяви үзгәреш булды. Моңа тарихта бер мисал бармы? Әлбәттә, юк. Бу зур эшләр, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән генә булды дими, ни дияргә кирәк?

# Эпилог

## *Рәсүлуллаһның сыйфаты*

Рәсүлуллаһ урта буйлы, түгәрәк ак вә нурлы йөзле, зур күзле, күзенең карасы чем-кара, агы бераз кызгылт, озын вә нечкә кашлы булып, ике каш арасы ачык, борыны озынчарак булып, уртасы аз гына күтәренке вә очтан бөгелә төшкән, зуррак авызлы, киң маңгайлы, куе керфекле, куе кара сакаллы, ак вә сирәгрәк тешле, киң күкрәкле, эре сөякле, беләкләре тулы, тәне йонлырак, тыгыз итле иде. Күренешкә гаять мәһабәт булып, беренче күрүгә үк дәһшәт бирә, очрашырга килгән кешегә үзен сөйдерә торган күренеш вә кыяфәттә иде.

Чәчен күбрәк колак йомшагын капларлык озынлыкта йөртә, аннан арта башласа, кыскарта яки толым итеп җибәрә иде. Ихрамнан чишелгән вакытларда гына такыр итеп алдырганлыгы риваять ителәдер. Гомеренең ахыргы вакытларында гына чәч вә сакалында ак бөртекләр күренә башлаган иде. Сакалын шул көенчә җибәрә, мыегын кисә иде. Йөреше гаять җитди, төз вә егетләрчә булып, бөгелепсыгылып, бөкрәеп йөрми, тирә-якка каранмый, алдына гына карап йөри иде.



www.darulkutub.com

Чисталыкка каты игътибар итә иде вә халыкны да аңа нык өнди иде. Тәһарәт алганда вә башка вакытларда гел мисвәк куллана иде. Халыкны да мисвәк кулланырга өнди иде. Чәчен майлый вә тарауны ярата иде. Хушбуйлана вә хушбуйны бик сөя иде. Хушбуйны күп кулланганы өчен, соң заманнарда чәче яхшы ук саргайган иде. Кич яткан чакта күзенә сөрмә тартып ята иде. Тырнакларын гел кисеп тора, озын йөртми иде. Халыкны пакь йөрергә, юынырга өнди, ким дигәндә атнасына бер мәртәбә коенырга куша иде.

## *Кием-салымы*

Кием-салым турысында бер дә тикшереп тормый, ни туры килсә, шуны кия иде. Күлмәкне, Йәмәндә эшләнгән «хибәра» дип аталган киемне бик яратып кия торган иде. Чалманы бүрек белән дә, бүрексез дә кия, чалмасыз гына бүрек тә кия иде. Күбрәк чалмасыннан җилкәсенә койрык төшерә, кайбер вакыт койрык төшермичә дә кия иде. Чалмасын иң астыннан уратып чала иде. Кара чалма кигәнлеге дә риваять ителәдер. Киемнең ак төстә булуын бигрәк ярата, халыкны да ак төстәге кием киюгә өнди, үлекләрне ак киемдә кәфенләргә куша иде. Кып-кызылны сөйми һәм кими иде. Киемнең киңлеген, тарлыгын игътибарга алмый, тегүчесен дә тикшерми иде.

Рум хөкүмәтендә тегелгән тар җиңле җүббә киюе вә Рум башлыклары тарафыннан бүләк кылынган ефәк белән әдепләнгән тун киюе риваять ителәдер. Читек тә, башмак та кия, фәкать читекне күбрәк сәфәрләрдә кия иде. Кашына «Мөхәммәд рәсүлуллаһ» дип язылган көмеш йөзеге дә бар иде.

## *Ашау-эчүе*

Ашау-эчүдә бер дә сайланып тормый, хәләлдән ни туры килсә, шуны ашый иде. Барны кире кайтармый, юкны таптырмый, мәҗлестә тәкъдим ителгән ашны яратса ашый, яратмаса ашамый, фәкать аны яманламый, гаепләми иде. Башкаларга табигатегезгә килешсә ашагыз, миңа карамагыз дия иде. Пешкән кабакны бик яратып ашый, хәлвә, бал, сөтне дә бик ярата иде. Күбрәк ризыгы су белән хөрмә була иде. Икешәр, өчәр ай рәттән өендә ут янмаган вакытлар булып, шул су, хөрмә, сөт белән канәгатьләнә иде. Ашны туярлык дәрәҗәдә ашамый торган иде. Ашны күбрәк җирдә, ягъни өстәлсез ашый иде.

## *Йокысы*

Йокысы аз булып, күбрәк кичнең өчтән бер өлешен йоклый иде. Түшәк вә мендәре тиредән булып, эче хөрмә мунчаласы белән тутырылган иде. Икегә бөкләп җәеп ята торган бер паласы бар иде. Бер көн шуны дүрткә бөкләп җәйгәннәр иде. Иртәсен: «Моннан соң алай дүрткә бөкләмәгез, мине гыйбадәттән калдырды», – дип, әүвәлгечә икегә генә бөкләргә кушуы риваять ителә. Күп вакыт түшәк вә мендәрләрне дә тикшереп тормый, камыш паласта, хәтта коры җирдә дә ята торган иде.

## *Мәҗлес, кешеләр белән аралашу*

Мәҗлестә гаять хуш, кешегә йөзе ачык, сүзе тәмле иде. Мәҗлестә юк-бар сүзләр сөйләми, килешсез эшләр эшләми, аның алдында кычкырышу вә низаглашулар булмый, килешсез кычкырып көленми, елмаю гына була иде.



www.darul-kutub.com

Ул сөйләгәндә башкалар сүз кушмый, башларына кош кунган төсле түбән салып, тыңлап утыралар иде. Сүзе гаять ачык вә салмак булып, сүзләрне санап бару мөмкин була иде. Кешеләр белән аралашуы гаять гүзәл, кешене ялыктырмый, өркетми, үзенә җәлеп кыла иде. Кешенең сүзен бүлми, утырдашы үзе торып китмичә тормый, күрешкән кеше кулын алмый торып, кулын алмый иде. Юк-бар сүз сөйләми, мактанмый, бер нәрсәне дә дәрәҗәсеннән артык мактамый, гайбәт сөйләми, һичнәрсәне яманламый, көлке нәрсәләрдән кычкырып көлмичә, елмая гына иде. Дөнья сүзе чыкканда халык белән дөнья сүзен сөйли, ахирәт сүзе сөйләгәндә, ахирәт сүзен сөйли иде. Чакырсалар кире какмый, бирелгән бүләкне, аз булса да кире кайтармый иде. Сәхабәләр белән гел аралаша, алар белән шаяра, уен-көлке сөйли, аларның балаларын уйната, итәгенә алып утырта, сөя иде. Авыруларның хәлен белергә бара, үзенә якын торган кешеләр, икенче милләттән булса да, кереп хәлләрен белеп чыга иде. Мәдинәдә үзенә хезмәт иткән бер яһүди егетенең хәлен белергә керүе Бохарида зекер ителәдер.

Кешегә үзе башлап сәлам бирергә тырыша, башлап кул суза иде. Килгән кунакны хөрмәт итә, күп вакыт аңа киемен җәя, үзе утыра торган палас вә мендәрен аңа тәкъдим итә иде.

Бирүне гаять ярата, халыкны өнди, алудан кире сөрә, «Бирүче кул алучы кулдан хәерлерәк», – дип әйтә иде. Сәдака бирүне бик сөя, сораган кешене буш кайтармый, үзенә калмаса да бирә, үзе мохтаҗ нәрсәне берәү килеп сораса да бирми калмый иде. Мохтаҗларның хаҗәтләрендә булышуны иң мөкаддәс бер эш саный, үзе үти алмаса, сәхабәләрдән үтенә, аларны өнди иде. Сәдаканы кабул итми, бүләкне кабул итә, ләкин артыгы белән кайтара иде. Башка милләттән булган

кешеләрнең, хәтта мөшрикләрнең бүләкләрен дә кабул итә, аларга бүләк бирә иде. Ләкин алар белән сугыш кылучы мөшрикнең бүләген кабул итми торган иде. Әйлә сахибе Юхнәнең бүләгенә каршы бер кием бүләк иткәнлеге риваять ителәдер. Нәҗәшигә бүләк җибәргәнлеген сөйлиләр. Худәйбия тынычлыгы вакытында Әбү Сафүән тарафыннан бирелгән бүләкне кабул итүе риваять ителәдер.

## *Шәфкать вә мәрхәмәте*

Рәсүлуллаһ бик шәфкатьле вә мәрхәмәтле булып халыкка гел яхшылыкны тели, хаҗәтләрен үтәргә чаралар эзли, аларның хәлләрен үзе тикшереп йөри иде. Халыкка җиңеллек кылырга, авыр нәрсәләр белән йончытмаска тырыша, шуның өчен дә халык ялыкмасын дип вәгазь- нәсыйхәтне бик еш кылмый, сирәгәйтә төшә иде. Намазда сабыйларның елауларын ишетсә, аналарының борчылуларыннан куркып, намазны кыскарта төшә иде. Сәхабәләрдән берәүнең имам булып торганда намазны бик озак укыганына шикаять ителгәнгә, кызып вә кызарып хотбә сөйләгәнлеге өчен шундый кешеләрне: «Халыкны өркетәсез», – дип орышканлыгы Бохари һәм башка хәдис җыентыкларында риваять ителәдер. Сәхабәләргә юк-бар нәрсәләрне күп сорамаска, бик төпченмәскә куша, һәм: «Авырлык кылмагыз, Аллаһы сезгә авырлык кылыр. Сездән элекке кавемнәр пәйгамбәрләреннән төрле нәрсәләр сорап, өсләренә авыр йөкләр йөкләделәр. Сез дә шулар кебек булмагыз», – дия иде. Әбү Муса әл-Әшгари вә Мугәз бине Җәбәләләрне Йәмәнгә җибәргәндәге васыятьләре һәркемгә мәгълүмдер. Әл-Видагъ хаҗында, хаҗ гамәлләренә бәйле кайбер кимчелекләрен сөйләүчеләргә гел «Зарар юк, зарар юк» дип җавап биргәне югарыда язылды.

www.darulkutub.com

Рәсүлуллаһның халыкка карата булган шәфкать вә мәрхәмәтен сөйләп сүз озайтасы юк. Коръәни Кәримнең:

«لَقَدْ جَاءَكُمْ رَسُولٌ مِّنْ أَنفُسِكُمْ عَزِيزٌ عَلَيْهِ مَا عَنِتُّمْ حَرِيصٌ عَلَيْكُم بِالْمُؤْمِنِينَ رَؤُوفٌ رَّحِيمٌ»[1]

кебек сүзләре моңа иң зур шаһиттыр.

## *Заһидлыгы*

Рәсүлуллаһ дөньяга күз салмый, дөнья малына бирелми, кулына мал төшсә, гел тарата, үзенә һәм гаиләсенә бик аз нәрсә генә алып кала иде. Дөньядан ни дәрәҗәдә ерак булуын белергә вафатыннан соң бер качыры вә коралларыннан башка һичбер нәрсә калмаганлыгын, тимер киеме бер яһүдидә закладта калганлыгын искә төшерү җитәдер. Хәлбуки, аның өлешенә тигән ганимәт маллар вә бүләкләр белән генә дә яхшы ук киң тормыш сөрергә, үзеннән соң байтак мал калдырып китәргә мөмкин иде[2]. Ләкин ул дөньяга бирелмәде, байлык җыймады, килгәнен гел таратып торды, баерга мөмкин булганда да, ул аңа кызыкмады. Гайшә әйтәдер: «Рәсүлуллаһ өч көн рәттән икмәккә туймады, үзеннән соң алтын, көмеш, куй, дөя булсын, бернәрсә дә калдырмады, ул вафат булганда минем өемдә ярым сагъ арпадан башка нәрсә юк иде». Ята

1 «Тәхкыйк, сезгә үз арагыздан пәйгамбәр килде, сезнең, гөнаһ эшләвегез аңа авырдыр, ул сезнең иманга килүегез өчен бик тырышучы, мөэминнәргә шәфкатьле вә рәхимледер» Тәүбә/128. – тәрҗ.

2 Ибне Назыйр яһүдләренең җире сугышчылар арасында бүленмичә, рәсүлуллаһка гына хас иде. Ул үзенең тормышында шул җирдән файда күрде. Үзеннән артканын хөкүмәт мәслихәтләренә тота вә фәкыйрьләргә бирә иде. Моннан башка аңа Фәдәк вә Хайбәрдән тигән өлешләре дә бар иде. “Бездән соң калган мал мирас ителми. Ул – сәдака” хәдисе буенча, бу җирләр рәсүлуллаһтан соң варисларына бүленеп бирелмәде. Бу хәдис Бохари һәм башкалар җыентыкларында риваять ителәдер – авт.

торган мендәр вә түшәкләренең хөрмә мунчаласы тутырган тире булуы да, әлбәттә, шул зaһидлыктан килмешдер.

Гайшә сөйләгәнчә: «Рәсүлуллаһ туярлык ашамый торган иде, булмаганлыктан һичкемгә зарланмый иде, ачлыктан төн буенча борчылып чыккан вакытлары була, шуның белән бергә көндезен руза тота иде, рәсүлуллаһның бу хәлен күреп, җәлләп елый торган идем һәм ник ул кадәр үзеңне газаплыйсың, туйганчы ашарлык нәрсә тотсаң булмасмы дия торган идем. Моңа каршы ул: «Әй, Гайшә, дөньяның миңа ни кирәге бар, минем пәйгамбәр кардәшләрем моннан артыгракка да сабыр иттеләр, шул сәбәпле Аллаһының хөрмәт вә ихтирамына лаек булдылар, мин әгәр дөньяда иркенлеккә бирелсәм дәрәҗәм алардан ким булыр дип куркам, хәлбуки миңа аларга ирешүдән вә алар белән бергә булудан да сөекле нәрсә юк», – дия иде»

Әл-Видагъ хаҗында йөз дөя корбанлык кылганы хәлдә, астындагы ияре тузып беткән бер ияр булуы, ияр өстенә салган нәрсәсе дүрт дирһәм кыйммәтендә тормаслык дәрәҗәдә булуы аның дөньядан ерак икәнлеген ачык күрсәтәдер.

Рәсүлуллаһның хатыннары үз тормышларыннан разый булмыйча, бервакыт аңардан иркенрәк, зуррак тормыш даулаганнар, башка башлыклар хатыннары кебек мул торырга, кием-салымда да алардан калышмаска теләгәннәр иде. Моңа каршы рәсүлуллаһ аларга бер ай якынлык кылмады, әгәр иске тормышларына разый булмасалар, аларны талак итәчәген белдерде вә ихтыярларына салды. Бу эшләр, әлбәттә, рәсүлуллаһның дөньяга бирелмәгәнлегеннән килә иде. Юкса аның хатыннарын бик мул тотарга кодрәте бар иде. Ләкин ул киң вә рәхәт тормышка бирелми, хатыннарын

да алай асрамый иде. Киресенчә, үзе вә хатыннары белән өммәтенең бик күпләренә үрнәк була, шушы фигыле белән аларга юаныч була, күңелләрен күрә иде.

Шуның белән бергә халыкны тырышлыкка һәм эшкә өнди, хәләл көч белән мал табарга димли, ялкаулыктан тыя, ялкаулыкның начар нәтиҗәләрен, фәкыйрьлекнең төрле бәлаләргә сәбәп булуын сөйли, моның белән бергә өммәтенең газиз вә куәтле бер милләт булуын тели иде.

Күп вакыт сәдака бирмәкче булган кешеләрнең үз гаиләләрен тәэмин итәрлек акчалары бармы-юкмы икәнен тикшерә, элек үз гаиләләренең ихтыяҗларын үтәргә, аннан соң башкаларга сәдака бирергә куша иде. Бөтен малларын сәдака кылырга булган кешеләргә барысын да биреп бетермәскә куша, бөтен малларын васыять итәргә тырышучыларга: «Юк, алай барысын да васыять итмә, өчтән берен васыять итсәң җитәр, ул да бик күп. Үзеңнән соң балаларың кешедән сорап йөрерлек хәлдә калмасын!» – дия иде.

Кыскасы, рәсүлуллаһның киң вә рәхәт тормыйча, кысынкы тормышны ихтыяр итүе юклыктан түгел, бәлки башка фәкыйрь вә мескеннәрнең күңелен юату өчен һәм дә дөньяга артык күз салмаганлыгыннан иде. Ул үзе өммәтенең бай булып, башкаларга яхшылык кылуларын, сорып йөрү ихтыяҗы тумавын тели, «Бирә торган кул ала торган кулдан хәерлерәк», дип бирергә вә бирү өчен мал табарга өнди иде.

## *Сабырлыгы, йомшаклыгы, гафу итүе*

Рәсүлуллаһ бөтен мактаулы әхлак вә югары фазыйләт белән сыйфатланмыш иде. Моңа

«وَإِنَّكَ لَعَلى خُلُقٍ عَظِيمٍ»[1]

дип, Коръән дә шәһадәт бирәдер. Ул үзе халыкны һәрвакыт яхшы әхлакка өнди вә:

«بُعِثْتُ لأُتَمِّمَ مَكارِمَ الْأَخْلَاقِ»[2]

– дип әйтә иде. Ул йомшак күңеллелек, сабырлык, гафу итүче, тыйнак, юмарт, гадел, сүзендә торучы, шәфкатьле, батыр, тәвәккәл кебек югары сыйфатларның иң югары дәрәҗәсендә иде.

Мәккәдә пәйгамбәр булганнан соң ул Корәеш гарәпләреннән никадәр җәбер вә золым күргән хәлдә бер дә сабырсызланмады, рухы төшмәде.

«فَاصْبِرْ كَمَا صَبَرَ أُوْلُوا الْعَزْمِ مِنَ الرُّسُلِ»[3],
«اصْبِرْ عَلَى مَا يَقُولُونَ وَاذْكُرْ عَبْدَنَا دَاوُودَ»[4],
«فَاصْبِرْ إِنَّ الْعَاقِبَةَ لِلْمُتَّقِينَ»[5]

кебек Аллаһының әмерләрендә итәгатьтә булып, юлында дәвам итте. Бөтен Мәккә һәм аның тирәсендәге гарәпләр

1 «Чынлыкта син бөек холык ияседер» Әл-Каләм/4. – тәрҗ.

2 «Күркәм әхлакны тәмамлау өчен җибәрелдем» – тәрҗ.

3 «Тотрыклылык сахибе булган рәсүлләр кебек сабыр ит» әл-Әхкаф/35. – авт.

4 «Мөшрикләрнең сүзләренә сабыр ит, Безнең колыбыз Дәуд(пәйгамбәр)не исеңә төшер.» Сад/17. – авт.

5 «Сабыр ит! Эшнең ахыры тәкъвалылар файдасына булачак» Һуд/49. – авт.



www.darul-kutub.com

нәфрәтендә булып, алардан өмет өзгәч тә, иң соңгы чара буларак керешкән эшендә нәтиҗәсез калгач та, Раббысына дога кылганда: «Әгәр миңа ачуың булмаса, бу авырлыкларга әһәмият бирмәячәкмен», – дигән сүздән башка сүз әйтмәде.

Сәхабәләр әллә ничә мәртәбә мөшрикләргә бәддога кылырга үтенсәләр дә, бәддога кылмады, киресенчә, хәердога кылды. Ухуд сугышында сәхабәләр, мөшрикләргә бәддога кылуын үтенгәч, ул: «Әй, Раббым, кавемемә мәгъфирәт кыл, чөнки алар белмиләр», – дип дога кылды. Таифка барышында дошманнарга бәддога кылырга үтенгәндә дә ул: «Әй, Раббым, Сәкыйф халкын тугры юлга күндер, миңа аларны мөселман итеп җибәр», – дип дога кылды.

Ул үзенә кагылышлы эшләрдә аслән үч алмый, һәрвакыт гафу итә, ялгыз Аллаһы өчен генә үч ала иде. Шуның өчен дә кеше танымый, яхшылыкның кадерен белми торган, пәйгамбәрлек дәрәҗәсенең кыйммәтен белмәгән каты бәгырьле сахра гарәпләре рәсүлуллаһны урынлы-урынсыз борчыйлар, кайбер вакыт аңардан берәр нәрсә сорап бирмәсә, аңа бәйләнәләр, киемнәреннән тарткалыйлар, ганимәт малын бүлгәндә: «Бу шундый өлеш ки, аңарда Аллаһы ризалыгы тәлап кылынмады!», «Гадел булмадың, гаделлек кыл!» кебек килешсез, мәгънәсез сүзләр әйтсәләр дә, рәсүлуллаһ моны да күтәрә иде. Янындагы сәхабәләр мондый кешеләрне үтерергә киңәш бирсәләр дә, ул һаман гафу кыла иде. Фәтхү Мәккә көнендә үзенә кылмаган кабахәтлекне калдырмаган Корәеш гарәпләренә ни эшләсә, шуңа кадир булганы хәлдә, аслән алардан үч алу юлына басмады.

Гайшә: «Рәсүлуллаһ кешедән күргән җәбер вә золымны икенче кешегә шикаять итмәде, кешедән үч алу өчен башкалардан ярдәм сорамады, сугышлардан башка вакытларда

кул күтәреп сукмады, хатыннарына булсын, хезмәтчеләренә булсын, кул тидермәде», – диядер.

«فَبِمَا رَحْمَةٍ مِّنَ اللّهِ لِنتَ لَهُمْ وَلَوْ كُنتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لاَنفَضُّواْ مِنْ حَوْلِكَ فَاعْفُ عَنْهُمْ وَاسْتَغْفِرْ لَهُمْ وَشَاوِرْهُمْ فِي الأَمْرِ»[1].

Бервакыт рәсүлуллаһта алачагы бар бер кеше аңа бик каты бәрелгәч, сәхабәләрдән кайберәүләре шул кешене җәза кылмакчы булганнар иде. Шул вакыт ул аларга: «Куегыз, хаклык сахибенә сөйләргә ирек бар», – диде. Шундый ук бер вакыйгада Гомәр бурычын таләп итәргә килгән кешене үтерергә уйлаган иде. Шул вакыт рәсүлуллаһ Гомәргә: «Син миңа бигрәк тә бурычымны түләргә, аңа исә сабыр итәргә кушарга тиеш идең», – диде. Бервакыт аңа көтәчәккә бер нәрсә саткан яһүди вакыт җитмәс борын акчасын сорарга килгән иде. Рәсүлуллаһ аңа: «Әле сөйләшкән вакыт җиткәне юк бит», – диде. Моңа каршы яһүди: «Сез, Габделмоталлиб балалары, түләргә каты кешеләрсез», – диде. Моны күреп сәхабәләр яһүдине үтерергә теләгәч, рәсүлуллаһ аларны тыйды һәм яһүдигә тагын да йомшаграк мөгамәлә күрсәтте. Моны күреп яһүдинең: «Синдә пәйгамбәр галәмәтләреннән бөтенесен күргән идем. Бары сабырлыгыңны сынап карыйсым килгән иде», – дип, Исламияткә керүе билгеледер.

## *Кече күңеллелеге*

Кече күңеллелеге хакында сөйләп торасы да юк.

1 «Аллаһның рәхмәте сәбәпле син аларга йомшак булдың. Әгәр каты бәгырьле, каты сүзле булсаң, сиңа җыелмаслар, тирәңнән таралырлар иде. Шулай булгач, син аларны гафу ит, алар өчен истигъфар кыл, халыкка кагылган эшләрдә алар белән киңәш.» Әәл Гыймран/159. – авт.



www.darulkutub.com

Аңарда аслән, тәкәбберлек, масаю дигән нәрсә юк, ул шулкадәр югары дәрәҗәле була торып,  бөтен кешедән дә түбәнчелекле. Фәкыйрьләр белән бергә утыра, мескеннәрнең барып хәлен белә, кол кеше чакырса да бара, чакыруны кире какмый иде. Карчыклар белән аларның хаҗәтләре хакында әллә никадәр сөйләшеп тора иде. Мәҗлестә нинди урын туры килсә, шунда утыра, халыкны урыннарыннан кузгатмый, сәхабәләренә аны каршылап тормаска куша иде. Дөя вә ишәкләргә атлана, артына кешеләр дә атландыра, сугышларда атланырга ат вә дөяләр җитмәгән чакта башка кешеләр кебек үк, чиратлап атланып бара иде. Бервакыт рәсүлуллаһ, сәхабәләрдән берничә кеше яныннан үткәндә, аны зурлап тордылар. Моңа кәефе китеп: «Сез алай бер-берегезне зурлар өчен тормагыз. Мин сезнең кебек бер кол бит, сезнең кебек ашыйм, эчәм, торам, утырам», – диде. Ул сәхабәләренә: «Мине башка кавемнәр пәйгамбәрләрен күтәргән шикелле күтәрмәгез, бине Габдулла вә рәсүлуллаһ диегез», – дия иде.

Әбү Һүрәйрә әйтәдер: «Бервакыт рәсүлуллаһ белән базарга чыгып аңа киемлек ала идек. Рәсүлуллаһ әйбергә акчаны бер микъдар артыграк бирде. Сатучы шатлыгыннан рәсүлуллаһның кулын үбә башлады. Моны күреп, рәсүлуллаһ кулын тартып алды да: «Ник алай минем кулымны үбәсең? Бу бит мәҗүсиләр эше. Алар падишаһларының кулын шулай үбәләр. Мин падишаһ түгелмен, сезнен кебек ук бер кешемен», – диде. Алган киемен күтәрмәкче булган идем, бирмәде: «Кеше үз нәрсәсен үзе күтәрсә яхшы.» – диде.

Әмерен үтәргә әзер булган хезмәтче вә коллары була торып, күп вакыт гаиләсенә булышлык итә, идән себерә, хайваннарына ашарга сала, сугара, куйларын савыша, үз киемнәрен үзе ямый, сынган, җимерелгән нәрсәләрне үзе

www.darul-kutub.com

төзәтә иде. Кунакны хуш күреп каршы ала, аларга ачык йөз күрсәтә, үзе хезмәт итә, кыстап ашата иде. Бервакыт кунакларга үзе хезмәт итә башлагач, сәхабәләреннән кайберләре: «Әй, рәсүлуллаһ, син утыр, без үзебез хезмәт итәрбез!» – димешләр иде. Моңа каршы рәсүлуллаһ: «Алар минем сәхабәләремә хөрмәт күрсәткәннәр, аларга хезмәт иткәннәр иде. Шуның өчен аларга үзем хезмәт итәсем килә», – диде.

Йөгереш, көрәш уеннарында үзе дә көрәшә вә йөгерешә иде. Ат вә дөя узышуларына катнашып, үзе дә дөясен ярышка җибәрә иде. Газбә исемендәге дөясе күп вакыт җиңүләргә ирешкәнлеге риваять ителә[1]. Фәтех Мәккә көнне Мәккәгә кергәндә түбәнчелек белән, тәкәбберләнмичә керде.

## *Юмартлыгы*

Юмартлыгының исә чиге юк иде. Пәйгамбәр булмас борын ук Хәдичәнең аңа: «Син рәхимлесең, һәлакәткә төшкән кешеләргә, ач вә мохтаҗларга ярдәм итәсен», – дию моны ачык күрсәтәдер.

Кулында мал булса, уйлап та тормыйча бирә иде. Әгәр мохтаҗ кешенең ихтыяҗын үтәү мөмкин булмаса, яхшы вә мөлаем сүзләр белән кайтара яки кулына мал кергәч бирергә вәгъдә кыла иде. Һәрвакыт бирә, әмма Рамазан аенда кулы бигрәк тә ачыла иде. Үлгән вакытында һичбер нәрсә калдырмавы, тимер киеме яһүдидә закладта калуы, әлбәттә, шул юмартлык нәтиҗәсе иде. Бервакыт аңа туксан мең дирһәмлек мал килгән иде. Шуны паласка салып, бер мәҗлестә өләшеп бетерде. Шулвакыт бер кеше килеп аңардан мал сорады. Рәсүлуллаһ моңа: «Хәзер миндә бернәрсә дә калмады. Син минем өстемә

1 Ибнү әл-Әсир Газбә урынына Касвәне зекер итә. Ат вә дөя ярышлары башлап һиҗрәттән алтынчы елда булды. "Әсәдү әл-Габә", 1 т., 23 б. – авт.

бурычка кер, кулыма мал төшкәч шул кешегә түләрмен», – диде. Моны күреп Гомәр: «Әй, рәсүлуллаһ, ник ул кадәр үзеңә авырлык йөклисең? Аллаһы сиңа көчең җитмәгән нәрсә белән боермады бит», – диде. Рәсүлуллаһ Гомәрнең ошбу сүзләрен яратмады. Шулвакыт бер әнсари: «Әй, рәсүлуллаһ, әйдә мал бирүеңне дәвам ит, курыкма, Аллаһы сине ач калдырмас!» – диде. Бу сүзләргә рәсүлуллаһ гаять шатланып, йөзе ачылып китте һәм: «Миңа шул әмер ителгән», – диде.

## *Батырлыгы*

Рәсүлуллаһның йөрәге, батырлыгы шул дәрәҗәдә иде ки, иң мөшкел вакытларда баһадирлык белән шөһрәт казанган кешеләр качкан чакта да ул качмый, урынында кала, урынын ташламый иде. Ухуд вә Һәвәзин сугышларында рәсүлуллаһның тотрыклыгы моңа иң зур дәлилдер. Ибн Гомәр: «Рәсүлуллаһтан батыр, юмарт, канәгать кеше күрмәдем», – дия иде. Гали: «Безнең мәркәзебез авырлаша башласа, рәсүлуллаһка сыена башлый идек, дошманга иң якын торган кеше ул була торган иде,» – ди.

Бер төн Мәдинә халкы куркыныч тавыш ишетеп, дошман һөҗүм итә дип уйлады. Халык коралланып тавышка каршы бара башлаганда, рәсүлуллаһ инде мәсьәләнең нидән гыйбарәт булганын аңлап, кайтып килә иде. Бу, әлбәттә, йөрәкле кешеләр генә булдыра ала торган эштер.

## *Тәвәккәллеге*

Рәсүлуллаһның тәвәккәллеге хакында да озак сөйләргә хаҗәт юктыр. Ул, әлбәттә, Аллаһыга һәркемнән артык тәвәккәл итә иде. Коръәни Кәримдә аңа һәрвакыт тәвәккәл

итәргә әмер бирелә, ул да Аллаһының ярдәменә таянып, эшен дәвам итә, шулай итеп аз гаскәр белән күп мөшрик гаскәрен җиңә иде. Әмма рәсүлуллаһның тәвәккәллеге без аңлаганча һичбер сәбәпкә таянмыйча, тәкъдиргә ышанып ятудан гына гыйбарәт түгел иде. Ул элек, эшнең хасил булуына ләзем гамәлләрен, сәбәпләрен кыла, шуның өстенә Аллаһыдан ярдәм сорый, Аңа ялына, ялвара иде. Рәсүлуллаһның Ухуд вә Хунәйн сугышларында икешәр кат тимер кием киюе шуны күрсәтәдер. Хәлбуки, Аллаһы Тәгалә аңа

«وَاللّٰهُ يَعْصِمُكَ مِنَ النَّاسِ»[1]

сүзе белән кешеләр зарарыннан иминлек биргән иде. Кыскасы, рәсүлуллаһ сәбәпләрдән тыш куәткә бары ачык сәбәпләр файда бирми торган яки ачык сәбәпләрне кылып бетергәннән соң гына сыена иде. Шуның өчен дә ул мөмкин булганда үзенә табиб чакырта, сәхабәләренә дә дәваланырга куша торган иде. Рәсүлуллаһның Бәдер һәм Ухуд сугышларында кылган гамәлләре аның тәвәккәллеген аңлатадыр.

Акылының бөеклеге, фикеренең турылыгы, әманәте, вәгъдәсендә торуы, сүздә тугрылыгы, ахирәт гамәленә вә гыйбадәтенә нык бирелүе хакында сөйләмибез дә инде.

Рәсүлуллаһның зекер иткән фитри вә кәсеп ителгән фазыйләтләр белән сыйфатлануы үзе бер могҗизадыр. Шәхсән аңа бик күп кешеләр фазыл вә камиллегенә хайран калудан, аңардагы бөек холыклар, югары табигать, һәр хосуста вә һәр эштә гадәттән тыш булуыннан аның Аллаһы тарафыннан җибәрелгән бер мөршид икәнлегенә дәлил буларак аңлаганлыкларыннан иманга килмешләрдер.

1 «Аллаһ сине кешеләрдән саклый» әл-Мәидә/67 – тәрж.

## *Балалары*

Рәсүлуллаһның өч ир вә дүрт кыз балалары булды. Ир балалары – Касыйм, Габдулла, Ибраһим. Кыз балалары – Зәйнәб, Рукайя, Үмм Көлсем, Фатыйма. Ибраһимнан башка балалары Хәдичә әл-Күбрадан туып, Ибраһим кыбтый Мәриядән туды.

Касыйм рәсүлуллаһның беренче баласы[1] булып, пәйгамбәрлектән алдан Мәккәдә дөньяга килде. Ике яшьтә вафат булды. Рәсүлуллаһ ошбу баласы аркасында Әбү Касыйм [Касыймның атасы] дип йөртелә иде.

Габдулла пәйгамбәрлек иңгәннән соң дөньяга килде. Хәдичәнең төпчек баласыдыр. Тайб вә Таһир кушаматлары белән йөртелә иде. Кайберәүләр Тайб белән Таһирны аерым санап, рәсүлуллаһның ир балаларын бишкә җиткерәләр. Ләкин дөресе, болар Габдулланың кушаматларыдыр[2]. Габдулла да сабый вакытында Мәккәдә вафат булды.

Ибраһим, һиҗрәтнең сигезенче елында Мәдинәдә дөньяга килеп, ике яшьтә вафат булды. Ибраһим туу турында сөенеч хәбәр китерүчегә рәсүлуллаһның бер кол бүләк итүе риваять ителәдер. Ибраһим бик матур булып, рәсүлуллаһ аны бик сөя иде. Вафатында кайгырып елавы вә: «Күңел кайгыра, күз яшьләнә, ләкин Аллаһы ризалыгына каршы сүз сөйләмибез. Әй, Ибраһим, без синең вафатыңа бик кайгырабыз», – дию Бохари җыентыгында зекер ителә.

Зәйнәб рәсүлуллаһның икенче баласы иде. Рәсүлуллаһ 30 яшендә вакытта дөньяга килде. Әнисе белән бертуган

1 “Әсәдү әл-Габә”, 4 т., 188 б. “Зәдүлмәгад”, 1 т., 25 б. – авт.

2 “Зәдүлмәгад”, 1 т., 25 б. – авт.

апасы Һәлә бинте Хувәйлиднең улы Әбү әл-Гас Лүкайт бине Рабигъ никахында иде. Һиҗрәтнең сигезенче елында Мәдинәдә вафат булды.

Рукайя рәсүлуллаһның өченче баласы булып, пәйгамбәрлеккә кадәр дөньяга килде. Әүвәл Әбү Ләһәбнең Гутбә исемле улына никахланса да, «Тәббәт» сүрәсе иңгәч, ата-анасы кушуы буенча Гутбә аны зөфәфтән элек талак кылды. Шуннан соң ул хәзрәти Госманга кияүгә чыкты. Беренче мәртәбә Хәбәшәгә һиҗрәт итүчеләр эчендә алар да бар иде. Вафаты һиҗрәтнен икенче елында, Бәдер сугышы вакытында иде. Шуның өчен рәсүлуллаһ аның җеназасында була алмады.

Үмм Көлсем рәсүлуллаһның дүртенче баласы булып, Гутәйбә бине Әбү Ләһәбкә кияүгә чыккан булса да, «Тәббәт» сүрәсе иңгәч, талак кылынды. Куенына кермәгән иде. Рукайянең вафатыннан соң, хәзрәти Госманга никахланды. Һиҗрәтнең тугызынчы елында вафат булды.

Фатыйма бишенче баласы булып, Мәккәдә дөньяга килде. Галигә кияүгә чыкты. Рәсүлуллаһ вафат булганнан соң алты ай үткәч, Мәдинәдә вафат булды. Рәсүлуллаһның нәселе ошбу Фатыймадан таралмыштыр.

## *Оныклары*

Рәсүлуллаһның оныклары ошбулардыр – Гали, Үмәмә, Габдулла, Хәсән, Хүсәйн, Зәйнәб, Үмм Күлсүм.

Гали белән Үмәмә – Зәйнәб балаларыдыр. Гали балигъ яшьтә вафат булды. Үмәмә Фатыймадан соң Гали бине Әбү Талибка, ул шәһид булгач, Мугыйра бине Нәүфәл бине әл-Хәрис бине Габделмоталлибка кияүгә чыкты. Мугыйра никахында ва-

фат булды. Аңардан Яхъя исемендә бер баласы булды.

Габдулла – Рукайя баласыдыр. Хәбәшәдә дөньяга килде. Һиҗрәтнең дүртенче елында, алты яшендә вафат булды.

Хәсән һиҗрәтнең өченче елында дөньяга килде. Галидән соң җиде айга кадәр хәлиф булып торды. Соңра хәлифлекне Мугавиягә тапшырды. Хатыны Җәгъдә бинте Әшгас бине Кайс тарафыннан агуланып үтерелде. Вафаты һиҗрәтнең кырык тугызынчы елында булып, яше 46 да иде. Васыяте буенча Мәдинәдә «Бәкыйгу Гаркад»кә күмелде.

Хүсәйн һиҗрәтнең дүртенче елында туды. Хәсәннән ике яшькә якын кечерәк иде. Һиҗрәтнең алтмыш беренче елында мәшһүр вакыйгада, Кәрбәләдә шәһид булды. Яше 55 тә иде.

Зәйнәб Габдулла бине Җәгъфәр бине Әбү Талиб никахында иде. Гали, Гаун әл-Әкбәр, Габбас, Мөхәммәд, Үмм Көлсем исемендә балалары туды. Ошбу Үмм Көлсем Кәрбәлә вакыйгасында Хүсәйн янында булып, Димәшкъка Язид янына китерелмеш иде. Үмм Көлсем әүвәл Гомәр бине Хаттаб никахында булып, аңардан Зәйд вә Рукайя исемендә балалары туды. Гомәрдән соң Гаун бине Җәгъфәр никахында булды.

## *Атасы белән бертуган абыйлары*

Рәсүлуллаһның ата ягыннан ир кардәшләре тугыздыр – Харис, Әбү Талиб, Зүбәйр, Гайдак, Габдүл Кәгъбә, Зыйрар, Әбү Ләһәб, Хәмзә, Габбас. Алардан Харис иң олысы, Габбас иң кечесе иде. Әбү Талиб, Әбү Ләһәб, Хәмзә вә Габбас Мөхәммәдкә пәйгамбәрлек килүенә ирешеп, соңгы икесе Исламиятне кабул итү белән мүшәррәф булдылар. Калганнары пәйгамбәрлеккә ирешмичә вафат булдылар.

Харисның Нәүфәл, Әбү Сафүән, Габдулла, Рабига, Үмәйя, Әрвә исемендәге балалары бар иде. Нәүфәл Бәдер сугышында әсир алынып, соңра Исламиятне кабул итте вә олугъ сәхабәләрдән булды. Әбү Сафүән башта рәсүлуллаһның зур дошманнарыннан булып, Мәккәне алырга барганда, Җүхфәдә рәсүлуллаһны күреп, Исламиятне кабул итте.

Габдулла да Исламиятне кабул итте. Элекке исеме Габдүшәмс булып, рәсүлуллаһ тарафыннан Габдуллага алыштырылды. Рәсүлуллаһ исән чагында Сафрадә вафат булды.

Әрвә Әбү Вәдәга әс-Сәһми белән никахта булып, аларның Муталлиб, Әбү Сафүән, Үмм Җәмил, Үмм Хәким, Рубга исемле балалары туды. Рабига да Исламиятне кабул итте. Егерме өченче елны Мәдинәдә вафат булды.

## *Әбү Талиб*

Әбү Талиб, Мөхәммәд галәйһиссәламнең бабасы Габделмоталлибтан соң рәсүлуллаһны тәрбия итте. Рәсүлуллаһны бик сөя, хәтта үз балаларыннан артык күрә иде. Аның пәйгамбәрлегенә ышанган хәлдә, шәһадәт кәлимәсен әйтмәде. Рәсүлуллаһны мөшрикләрдән яклауда гаять зур тырышлык күрсәтте, шул юлда мөшрикләрнең бойкотына да очрады. Һиҗрәткә кадәр өч ел элек, сиксән яшьтән узып вафат булды. Аның вафат елы «Кайгы елы» дип аталмыштыр. Аның балалары – Җәгъфәр, Гакыйль, Гали, Талиб, Үмм Һәни, Җумәнә.

Икенче мәртәбә Хәбәшәгә һиҗрәт итүчеләр арасында Җәгъфәр дә бар иде. Мүэтә сугышында шәһид булды. Га-

www.darulkutub.com

кыйль Бәдердә әсир алынып, соңра Исламиятне кабул итү белән мүшәррәф булды. Мугавия заманында вафат булды.

Гали – тугры халифләрдәндер.

Үмм Һәни Мәккә алынган елда Исламияткә килде, Һүбәйра бине Әбү Вәһб никахында иде.

Җүмәнә Сафүән бине әл-Харис бине Габделмоталлиб никахында иде.

Талиб Исламияткә килмичә вафат булды.

Әбү Ләһәбнең асылдагы исеме Габдүл Гуззәдер. Бәдер сугышыннан соң кайгыдан вафат булды. Гутбә, Мугаттиб, Гутәйбә исемендәге ир балалары, Дүрра исемендәге кыз баласы бар иде.

Гутбә белән Мугаттиб Мәккә алынган көндә Исламияткә килделәр. Рәсүлуллаһ аларның Исламияткә килүләренә бик нык шатланды.

Дүрра Исламиятне кабул итеп, Мәдинәгә һиҗрәт иткән иде. Харис бине Нәүфәл никахында булып, Вәлид вә Гукбә исемендәге балалары булды.

Хәмзә пәйгамбәрлекнең өченче елында Исламияткә килде. 59 яшендә Өхед сугышында шәһид булды. Рәсүлуллаһка сөт кардәшедер. Гутәйбә, Ягълә исемендәге уллары, Гомәра, Үмәмә, Фатыйма, Сәлмә исемендәге кызлары бар иде. Үмәмәне рәсүлуллаһ Сәлмә бине Әбү Сәлмәгә никахландырды.

Габбас Габделмоталлибның иң төпчек баласы иде. Бәдердә әсир алынып, Исламиятне кабул итте. Сигезенче елны гаиләсе белән Мәдинәгә һиҗрәт иткәндә, Әбвәдә рәсүлуллаһка очрады. Шул җирдән гаиләсен Мәдинәгә озатып, үзе рәсүлуллаһ гаскәренә кушылды. Утыз өченче елны 88 яшендә Мәдинәдә вафат булды. Фазыл, Габдулла, Гобәйдулла, Кусәм, Габдрахман, Мәгъбәд, Харис, Кусәйр,

Гаун, Тәммәм, Үмм Көлсем исемендәге балалары бар иде. Фазыл бөек сәхабәләрдән иде. Габдулла сәхабәләрнең галим вә факыйһларыннан иде. Алтмыш сигезенче елны 74 яшендә вафат булды. Гобәйдулла юмартлык белән шөһрәт тапмыш иде. Язид бине Мугавия заманында вафат булды. Кусәм Мугавия заманында Сәмәркандта шәһид булды. Габдрахман белән Мәгъбәд Африка илләрендә Ислам динен таратканда шәһид булдылар. Үмм Көлсем башта Хәсән бине Гали никахында, аннан соң Әбү Муса әл-Әшгари, аннан соң Гыймран бине Әбү Талхә никахында булды.

Зүбәйр «Хәрбү әл-Фүҗҗәр» вакыйгасында Ибне Һәшим башлыгы иде. «Хилфү әл-Фүзүл»дә дә катнашты. Габдулла исемендәге улы, Үмм Хәким вә Зубәга исемендәге кызы бар иде.

Габдүл Кәгъбә Мукаввәм дип шөһрәт казанды. Һинд исемле бер баласы бар иде.

Гайдәк Мусгаб исемендә булып, Гайдәк вә Хәҗл – кушаматларыдыр. Мүрра исемендә бер баласы бар иде.

## *Атасы белән бертуган апалары*

Рәсүлуллаһның ата ягыннан бертуган кыз кардәшләре алтыдыр – Сафийя, Гатикә, Бәрра, Әрвә, Умәймә, Үмм Хәким әл-Бәйза. Алардан Сафия Исламияткә килеп, Мәдинәгә һиҗрәт итте. Калганнары, ихтималы күбрәк, Исламиятне кабул итмәделәр[1].

Сафийя әүвәл Харис бине Хәрб бине Үмәйя, аның вафатыннан соң Гаввәм бине Хувәйлид никахында булды. Һиҗрәтнең егерменче елында 73 яшендә Мәдинәдә вафат булды. Балалары мәшһүр Зүбәйр бине Гаввәм, Сәиб вә

1 “Әсәдү әл-Габә”, 5 т., 492 б. – авт.

Габдүл Кәгъбәдер.

Гатикә, Әбү Үмәйя бине Мугыйра әл-Мәхзуми никахында иде. Зүһәйр вә Габдулла исемендә балалары булмыштыр. Габдулла әүвәл Рәсүлуллаһның иң зур дошманнарыннан булып, аны рәнҗетсә дә, Мәккә фәтех кылынган елда тәүбә вә истигъфар кылып, Исламияткә килде. Таифне камап торган вакытта вафат булды.

Бәрра әүвәл Габдүл Әсәд бине Һилал, аннан соң Әбү Раһм бине Габдүл Гоззә никахында булды. Балалары Габдулла бине Габдүл Әсәд вә Әбү Сүбра бине Әбү Раһмдер. Әбү Сәләмә мәшһүр сәхабәләрдән булып, рәсүлуллаһның хатыны Үмм Сәләмәнең әүвәлге ире иде. Әбү Сүбра да бөек сәхабәләрдән иде.

Әрвә Гумәйр бине Вәһб, соңра Кәлдә бине Габдү Мәннәф никахында булып, әүвәлгедән Туләйб, соңгысыннан Әрвә исемендәге балалары булды.

Умәймә Җәхш бине Ягъмур никахында иде. Габдулла, Гобәйдулла, Габд (Әбү Әхмәд), Зәйнәб, Үмм Хәбибә, Хәмнә исемендәге балалары булды. Габдулла Ухуд сугышында шәһид булды. Гобәйдулла Хәбәшәдә вафат итте. Рәсүлуллаһның хатыны Үмм Хәбибәнең әүвәлге иредер.

Әбү Әхмәд Исламияткә килгәч Мәдинәгә һиҗрәт кылды. Зәйнәб Рәсүлуллаһның хатыннарыннандыр. Хәмнә әүвәл Мусгаб бине Гумәйр, аннары Талхә бине Гобәйдуллага барды. Үмм Хәбибә Габдрахман бине Гауф никахында иде.
Үмм Хәким әл-Бәйза, Күрайз бине Рабига никахында иде. Әрвә вә Гумәйр исемендәге балалары туды. Әрвә Госман бине Гаффәннең анасыдыр. Гаффәннән соң Әбү Мугайт Гукбәгә кияүгә чыкты. Гумәйр Мәккә алынган вакытта Исламияткә килде.

## *Уммәһәтү әл-муэминин [рәсүлуллаһның хатыннары]*

Рәсүлуллаһның никахлап алган вә куенына кергән хатыннары унбердер: Хәдичә бинте Хувәйлид, Сәүдә бинте Зәмга, Гайшә бинте Әбү Бәкер әс-Сиддыйк, Хәфса бинте Гомәр бине әл-Хаттаб, Зәйнәб бинте Хузәймә, Үмм Сәләмә Һинд бинте Әбү Үмәйя, Зәйнәб бинте Җәхш, Җувәйра бинте әл-Харис, Үмм Хәбибә Рамлә бинте Әбү Сафүән, Сафийя бинте Хүяй бине Әхтаб, Мәймунә бинте әл-Харис.

Болардан бары тик Гайшә генә кызлата алынып, башкалары тол хәлләрендә алынмышлардыр.

Хәдичә Рәсүлуллаһның иң беренче хатыныдыр. Аңа кияүгә чыкканда кырык яшендә иде. Рәсүлуллаһ аның өстенә һичбер хатын алмады. Рәсүлуллаһның Ибраһимнан башка бөтен балалары Хәдичәдән туды. Хәдичә җаһилият гасырында акыллы, югары табигатьле, камиллек иясе бер хатын булып, «Таһира» кушаматы белән йөртелә иде. Исламиятне таратуда вә рәсүлуллаһны яклауда иң зур ярдәмче булганлыктан, мөселманнар тарафыннан «әл-Күбра» кушаматы бирелгән. Рәсүлуллаһ белән 25 ел гомер сөреп, 65 яшендә вафат булды. Мәккәдә Хәҗҗүндә күмелде. Рәсүлуллаһ аның вафатына бик кайгырды. Аны һәрвакыт исенә төшерә, сагынып сөйли иде, якыннарына кадер-хөрмәт күрсәтә иде. Хәдичәнең бертуганы Һәләнең килгәнен хәбәр иткәчтен, ни эшләргә белмичә: «Аллаһыүммә Һәлә», – дип урыныннан сикереп каршы алырга торганы риваять ителә. Куй бугазласа, өлешләр кисеп, Хәдичәнең дусларына җибәрә иде. Бер-бер җирдән бүләк килсә, аны фәлән хатынга илтегез, ул

Хәдичәнең дус хатыны дия иде.

Бервакыт рәсүлуллаһ Хәдичәне бик күп телгә алгач, Гайшә көнләшеп: «Нәрсә инде шул карчыкны авызыңнан куймыйсың, Аллаһы сиңа аңардан артыкларны бирде ич», – дип ычкындырган иде. Рәсүлуллаһ моны ишетеп, ачуыннан чәче үрә торды һәм ошбу мәгънәдә сүз сөйләде: «Юк, аннан артык хатын булмас. Ул халык ышанмаган вакытта миңа ышанды. Халык кәфер чакта, ул иман китерде. Халык төрле яктан миңа мәшәкатьләр китергәндә, ул миңа малы белән ярдәм итте. Башка хатыннарымнан бала насыйп булмаганда, аңардан балаларым булды». Моны ишеткәч Гайшә: «Моннан соң Хәдичәне начарлык белән зекер итмәскә булдым», – диде.

Хәдичә рәсүлуллаһтан элек Гатикъ бине Гаиз, аңардан элек Әбү Һәлә Һинд никахында иде. Әбү Һәләдән Һинд вә Һәлә исемендәге угыллары, Гатикътан Һинд исемендә кызы туды.

Сәүдә бинте Зәмга әүвәл Сәкран бине Гамр никахында булып, ире белән бергә Хәбәшәгә һиҗрәт итте. Хәбәшәдән Мәккәгә кайткач, ире вафат булып яклаучысыз калгач, рәсүлуллаһ үзенә никахлады. Хәдичәдән соң беренче хатыны ошбу Сәүдә иде. Сәүдә картайгач урынын Гайшәгә бирде. Хәзрәти Гомәр заманында вафат булды.

Гайшә алты-җиде яшендә рәсүлуллаһка никахланды. 9 яшендә рәсүлуллаһ куенына керде. 18 яшендә рәсүлуллаһтан калды. Һиҗрәтнең илле сигезенче елында, 66 яшендә вафат булды. Гайшә рәсүлуллаһ хатыннарыннан иң гыйлемлесе иде. Рәсүлуллаһтан соң бик күп хәдисләр риваять итмештер. Сәхабәләрнең бөекләре Гайшәгә мөрәҗәгать итәләр вә аңардан фәтва сорыйлар иде. Гайшә рәсүлуллаһның иң сөекле хатыны иде.

www.darul-kutub.com

Хәфса элек Хунәйс бине Хузәфә никахында иде. Ул Бәдердә шәһид булгач, һиҗрәтнең өченче елында рәсүлуллаһка никахланды. Кырык бишенче елда, 60 яшендә вафат булды.

Зәйнәб бинте Хузәймә рәсүлуллаһтан элек Габдулла бине Җәхш никахында иде[1]. Ул Өхед сугышында шәһид булгач, рәсүлуллаһ аңа никахланды. Фәкыйрьләргә гаять мәрхәмәтле булганлыктан «Мескеннәрнең анасы» дип йөртелә иде. Рәсүлуллаһ никахында ике-өч ай гына торып вафат булды[2].

Үмм Сәләмә әүвәл Әбү Сәләмә никахында иде. Ул дүртенче елда вафат булгач, Рәсүлуллаһка никахланды. Алтмыш өченче елда 84 яшендә вафат итте. Рәсүлуллаһ хатыннарыннан иң соң вафат булганы ошбу заттыр.

Зәйнәб бинте Җәхш әүвәл Зәйд бине Хәрисә никахында иде. Ире талак кылгач, Аллаһының боерыгы буенча рәсүлуллаһ аңа никахланды. Моның белән Зәйнәб горурлана торган иде. Зәйнәб юмарт, фәкыйрьләргә яхшы мөгамәлә күрсәтә иде. Егерменче елда 53 яшендә вафат итте. Рәсүлуллаһтан соң иң элек вафат булган хатыннарыннан ошбу Зәйнәбтер.

Җүәйрия бинте әл-Харис Мураисигъ газвәсендә әсиргә төшкән иде. Рәсүлуллаһ аны азат итеп, үзенә никахланды. Аның әүвәлге исеме Бәрра булып, рәсүлуллаһ аны Җүвәйриягә алыштырды. Илле алтынчы елда 65 яшендә вафат булды.

Үмм Хәбибә элек Губәйдулла бине Җәхш ника-

---

1 “Әсәдү әл-Габә”, 5 т., 466 б. Ибнү әл-Әсир “Әсәдү әл-Габә”дә моны Габдулла бине Җәхш никахында дигән хәлдә, “әл-Кәмил”ендә әт-Туфәйл бине әл-Харис никахында ди. “әл-Кәмил”, 2 т., 118 б. Ибн Һишам, Губәйдә бине әл-Харис никахында иде, ди. Ибн Һишам, 2 т., 427 б. – авт.

2 “Әсәдү әл-Габә”, 5 т., 466 б. – авт.

хында иде. Ул Хәбәшәдә насара диненә күчеп вафат булды. Җиденче елны рәсүлуллаһ Нәҗәши арадашлык итүе белән аны үзенә никахланды. Кырык дүртенче елны вафат булды.

Сафийя Хайбәр сугышында әсир алынып, рәсүлуллаһ тарафыннан азат ителде, вә рәсүлуллаһ аны хатынлыкка алды. Элек Сәлләм бине Мушкәм вә Кинәнә бине әр-Рабигъ никахларында булды. Илленче елны Мәдинәдә вафат булды.

Мәймунә рәсүлуллаһтан элек Әбү Раһм бине Габдүл Гozзә никахында иде. Җиденче елны Гумратү әл-Казада рәсүлуллаһка никахланды. Бу – рәсүлуллаһның иң соңгы никахланган хатыныдыр. Илле беренче елны вафат булды. Кабере Сәрифтәдер.

Болардан Хәдичә, Сәүдә, Гайшә, Хәфса, Умму Сәләмә, Үмм Хәбибә – Корәештән, Сафийя – яһүддән, башкалары гарәп кабиләләреннән иде. Моннан башка рәсүлуллаһның берничә хатынны никахлап, куенына кермәгәнлеге яки яучылаганның соңында кайбер сәбәпләрдән кире кайтарылганлыгы риваять ителәдер[1].

Рәсүлуллаһның бу кадәр хатын алуының сәбәпләре югарыда язылган иде. Ислам дошманнары аны шәһвәнияткә бирелгән дип гаепләп, пәйгамбәргә яла ягалар. Хәлбуки, моның бер ифтира икәнлеге көн кебек ачыктыр. Әгәр бу кадәр хатын алу шәһвәнияттән килсә, ни өчен Мәккәдә, яшь чагында карт Хәдичәгә канәгатьләнеп торды? Ул вакыт аңа әллә никадәр яшь матур кызлар алырга мөмкин иде бит. Гарәпләрдә күп хатын алу гади бер нәрсә иде. Кырык яшенә

1 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 29 б. Мәзкүр хатыннарның исемнәрендә гаять күп ихтилаф бардыр. Шуның өчен булса кирәк, “Зәдүл-Мәгад” сахибе боларны атамыйча китә. Ибнү әл-Әсир “әл-Кәмил”ендә боларның берничәсен зекер итеп, “кыйлә”[имеш]ләр белән тутырган хәлдә, “Әсәдү әл-Габә”дә бер-ике җирдә, боларны зекер итүдә файда юк дип, әйтә – авт.

кадәр бөтен Корәеш гарәпләре аны сөя вә ихтирам итәләр иде. Шуның өчен аңа теләгән кызны алырга мөмкин иде. Хәдичә дә аңа өстеннән көндәш алырга каршы килмәячәк иде. Чөнки гарәп хатынына көндәшле булу бик гади бер эш иде. Яшь вакытларында карт бер хатынга канәгатьләнгән кешене ничек шәһвәткә бирелгән дияргә тел барсын?

Рәсүлуллаһның калган ун хатынын алуы илле белән алтмыш арасында чагында булды. Бу да, әүвәл сөйләгәнчә, я ата-анасының күңелен табу яки аларны мөшрикләр фетнәләнүләреннән саклау яки кайбер җаһил гадәтләрне юкка чыгару кебек мәслихәтләргә нигезләнгән иде. Әгәр дә хатын күбәйтүгә шәһвәният сәбәп булса, ирдән калган хатыннарны, карчык-корчыкларны алмас, бәлки яшь кызларны алыр иде. Моңа һичбер тыю юк иде. Хәлбуки, аның кызлата алган хатыны Гайшә генәдер.

Рәсүлуллаһ хатыннарын һәрвакыт тигез күрә, тигез тота иде. Кием-салым, ашау-эчү, алар белән бергә булуда һәрвакыт гаделлек итә, берсен икенчесеннән артык күрми иде. Сәфәргә чыкса, хатыннары арасында шобага салдыра, кемгә чыкса, шуны алып бара иде. Хатыннарына мөмкин кадәр тигезлек кылырга тырыша, үз ихтыярында булмаган мәхәббәт хакында: «Әй, Раббым, үз ихтыярымда булган нәрсәләр хосусында тигезлек кылуым ошбудыр. Минем кулымда булмаган нәрсәләр хакында мине шелтәләмә!» – дия иде.

Һәркөн диярлек хатыннарының хәлләрен белеп чыга, аларның хаҗәтләре хакында сөйләшә иде. Икенде намазын укыганнан соң бөтен хатыннарына кереп хәлләрен белә торган булганлыгы риваять ителәдер.

Гайшә: «Рәсүлуллаһ, чират хосусында бер-беребезне артык күрми, беребезнең бүлмәсендә икенчесеннән артык

тормый, һәркөн диярлек барыбызның да хәлен белеп чыга, чират туры килгән хатынында куна иде», – диядер. Сәүдә бинте Зәмга, картайгач, чиратын Гайшәгә бүләк итеп бирмештер.

Хатыннарына мөгамәләсе гаять гүзәл, алар белән уен-көлке сөйли, әдәп вә тәрбиягә хилаф булмаган эшләрдә аларга рөхсәт бирә иде. Гайшә өенә гел әнсари кызлары килеп, сөйләшеп, уйнап-көлеп утырганлыклары риваять ителәдер. Гает көннәренең берсендә ике кыз Гайшә янына кереп, балалайка шикелле бер коралдан музыка уйнап, үзләренең милли көйләре булган мәшһүр «Бүгас» көенә җырлап утыралар. Шул вакыт рәсүлуллаһ кайтып керде дә, бер җиргә таянып ятты. Кызлар һаман җырларын дәвам иттеләр. Шул арада Әбү Бәкер дә кереп: «Рәсүлуллаһ хозурында шайтан уены уйнатасың!» – дип, Гайшәне орыша башлады. Моңа каршы рәсүлуллаһ: «Ник аларны тыясың? Бу бит бәйрәм көне», – дип, Әбү Бәкерне туктатуы ике сахих хәдисләр җыентыгында зекер ителәдер. Гает көннәрне хәбәшиләр мәчеттә кылыч уены уйный торганнар иде. Рәсүлуллаһ бүлмә ишеген ачып, Гайшә белән шул уеннарны тамаша кыла торган иде. Хатыннары белән парлап Мәдинә урамнарында йөргәнлеге, хатыннарын тезенә бастырып дөягә атландыруы[1], Гайшә белән ике мәртәбә сәфәрдә чыкканы риваять ителәдер[2]. Болар барысы да табигый, яхшы тормыш итү нәтиҗәседер.

Ул, үз хатыннары белән яхшы торган кебек, башкаларга да үз хатыннары белән яхшы торырга әмер итә һәм: «Сезнең иң яхшыгыз – хатынына яхшы булган кешедер. Мин сезнең арагызда хатынына иң яхшы кешемен», – дия иде. Хаста вакытында рәсүлуллаһның иң күп кабатлап әйткән сүзе хатыннарга гүзәл мөгамәлә итү хакында икәнлеген сира

1 Бохари, 4 т., 36 б. – авт.

2 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 39 б. – авт.

галимнәре риваять итәләрдер.

Хәфса бинте Гомәрне талак кылып та кире кайтаруы[1], Зәйнәб бинте Җәхшкә Сафияне яһүдия дип кимсеткәнлегә өчен ике айдан артык якынлык кылмаганлыгы[2], киң тормыш сораганнары өчен бөтен хатыннарына бергә бер ай якынлык кылмаганлыгы риваять ителәдер.

## *Кәнизәкләре*

Зекер ителгән хатыннардан башка рәсүлуллаһның дүрт җәриясе булганлыгын сира язучылар риваять итәләр. Болардан берсе – мәшһүр кыбтый Мәрия. Мәрия – хәзрәти Ибраһимның анасы булып, рәсүлуллаһка улының әниседер. Мисырдан килешли, юлда Хатиб кулында Исламиятне кабул итмеш иде.

Рәсүлуллаһ Мәрияне «Гавәли» тарафындагы үзенең йортына урнаштырып, һәрвакыт аны зиярат өчен бара иде. Ошбу урын «Ибраһимның кәнизәк анасы» дип билгеле иде. Мәрия Гомәр хәлифә булганда, уналтынчы елда вафат булды. Аңа җеназа намазын укучы Гомәр иде. Гомәрнең Мәрия җеназасына халыкны үзе җыеп йөргәне билгеледер.

Икенчесе Райхәнә исемендә булып, Ибне Курайза яһүдләреннән иде. Рәсүлуллаһтан элек вафат ителүе риваять ителәдер. Калган икесенең берсен Зәйнәб бинте Җәхш бүләк иткән иде, икенчесе – сугышларның берендә әсирлеккә алынган иде.

## *Вәлиләр*

Мәккә фәтех ителеп, Корәеш гарәбләре Исламияткә килгәч, Сәкыйф вә Һәвәзин гарәбләре дә җиңелеп, соңыннан

1 “Зәдүл-Мәгад”, 1 т., 26 б. – авт.

2 “Зәдүл-мәгад”, 1 т., 282 б. – авт.

бик күбесе Исламиятне кабул иткәч, Тәбүк сәфәре сәбәпле Исламиятнең дан вә шөһрәте Гәрабстан вә тирәсендәге бөтен халыкка җәелгәч, төрле гарәб кабиләләре, Мәдинәгә вәкиллекләр җибәреп, Исламиятне кабул иткәннәр иде вә шулай итеп Согуд Гарәб ярымутравындагы бөтенесе диярлек рәсүлуллаһның кул астына кермеш иде. Исламиятне кабул иткән гарәб кабиләләренә рәсүлуллаһ зәкәтләрен алу өчен кешеләр җибәрә, шәһәр вә авылларда тора торган мәдәниятлерәк гарәпләргә вәлиләр (губернаторлар) билгели иде. Сира галимнәре түбәндәге затларның төрле җирләргә, рәсүлуллаһ тарафыннан вәли итеп билгеләнүләрен зекер итәләр:

1. Гаттәб бине Әсид – Мәккә алынган көндә Исламияткә килде. Рәсүлуллаһ аны Хунәйн сугышына киткәндә Мәккә вә әтрафына вәли итеп калдырды. Бу вакытта яше унжиде белән егерме арасында гына иде. Сигезенче елда хаҗ әмире ошбу Гаттәб иде. Ул вафат булганчы шул вәлилек эшендә калды. Рәсүлуллаһның моңа көндәлек бер дирһәм акча түләү хакы билгеләве риваять ителәдер[1]. Вафаты хәзрәти Әбү Бәкер вафатына туры киләдер.

2. Госман бине Әбү әл-Гас әс-Сәкыйфи – Таиф вәкилләре белән Мәдинәгә барган вә шул вакыт Исламиятне кабул иткән иде. Рәсүлуллаһ аны Таифкә вәли итеп билгеләде. Рәсүлуллаһ вә Әбү Бәкер заманында шул вазыйфасында калып, Гомәрнең өченче ел хәлифлек чорында Бәхрәйн вә Гумән вәлилегенә күчерелде.

3. Малик бине Гауф ән-Насри – Һәвәзин сугышында мөшрик гаскәре башлыгы иде. Җугъранәгә килеп, Ислами-

1 Ибнү әл-Әсир "Әсәдү әл-Габә"сендә моның вазыйфасы көндәлек ике дирһәм булуын, яше дә 25ләрдә булуын сөйли – авт.

ятне кабул итте. Шул көн рәсүлуллаһ аны Таиф тирәсендәге сахра гарәпләренә башлык ясады. Малик Дәмәшкъ вә Кадсияне алганда катнашты.

4. Әл-Мүнзир бине Сәви – әүвәл Бәхрәйн әмире булып, Рәсүлуллаһ тарафыннан хат алгач, Исламиятне кабул итү белән мушәррәф булды. Рәсүлуллаһ тарафыннан шул урынында калдырылды. Мәдинәгә килеп, рәсүлуллаһны күрү бәхетенә ирешкәне риваять ителәдер[1]. Әл-Мүнзир рәсүлуллаһтан соң озак тормады, вафат булды.

5. Зияд бине Ләбид әл-Әнсари – Ясриб гарәбләреннән булып, Исламиятне кабул итеп, Мәккәгә һиҗрәт иткән иде. Соңыннан Мәдинәгә һиҗрәт кылды. Шунлыктан «мүһәҗири вә әнсари» дип тә йөртелә иде. Ул рәсүлуллаһ тарафыннан Хазрамәүткә вәли итеп билгеләнде. Мугавия заманында вафат булды.

6. Гамр бине Хәзм – рәсүлуллаһ тарафыннан Нәҗран (Бәну әл-Харис) гарәбләренә вәли итеп билгеләнде. Яше бу вакыт бары 17 дә иде. Илле беренче елда Мәдинәдә вафат итте[2].

7. Гамир бине Шәһр – Һәмәдән гарәбләреннән. Мәдинәгә барып, Исламиятне кабул итмеш иде. Рәсүлуллаһ тарафыннан Һәмәдән гарәбләренә вәли итеп билгеләнде. Ул Әсвәд әл-Гансигә нык каршы торган вәлиләрдәндер.

8. Шәһр бине Бәзән – мәшһүр Бәзән әл-Фәрисинең улыдыр. Әсвәд әл-Ганси тарафдарлары белән сугышта үтерелде. Хатыны Азәд Әсвәд тарафыннан көчләнеп никахландырылды.

---

1 “Әсәдү әл-Габә”, 5 т., 9 б. – авт.

2 Кайберәүләр Нәҗран вәлисе Әбү Суфьян бине Хәрб булуын сөйлиләр. “Зәдүл-Мәгад” сахибе дә шуны ихтияр иткән. Вәкъди моны инкар итә. Ул рәсүлуллаһ вафат булганда Әбү Сафүән Мәккәдә иде, ул вакытта Нәҗран вәлисе Гамр бине Хәзм иде, ди. – авт.

9. Әбү Муса әл-Әшгари Мәәрибкә вәли итеп билгеләнде. Рәсүлуллаһның моны вәли итеп җибәргәндә, халыкка җиңеллек кылырга, авыр нәрсә йөкләп, халыкны өркетмәскә кушуы Бохари вә башка хәдис җыентыкларында риваять ителә.

10. Халид бине Сәгид бине әл-Гас – беренче мөселманнардандыр. Рәсүлуллаһ тарафыннан Нәҗран белән Зәбид арасындагы җирләргә вәли итеп билгеләнде. Әбү Бәкер аны элекке урынында калдырырга теләсә дә, кабул итмәде.

11. Гукәшә бине Сәур – Сәкун вә Сәкәсик халкына вәли итеп билгеләнмеш иде[1].

12. Әт-Таһир бине Әбү Һәлә – Гаккә вә Әшгарийин гарәпләренә вәли итеп билгеләнде[2].

13. Язид бине Әбү Сафүән  Тәймәгә вәли итеп билгеләнде. Футухәт вакытында шөһрәт казанмыш затлардандыр.

14. Ягъләә бине Умәйя – анасы буенча Ягъләә бине Мүнәйя дип тә танылгандыр. Йәмәндә гаскәр башлыгы буларак билгеләнгән иде. Гомәр вә Госман заманнарында Санга вәлисе булып торды. Госман шәһид булгач, аңа ярдәм итү өчен Мәдинәгә кайтты. Бөек һәм абруйлы кеше иде. Җәмәл вакыйгасында Гайшәләр тарафында булды. Мал белән дә күп ярдәм итте. Соңрак Гали тарафында булып, Сыйффинда шәһид булды.

15. Бәзән бине Сәсән әл-Фәриси – әүвәл кисра тарафыннан Йәмәндә идарә итә иде. Соңра Исламиятне кабул

1 Хадрамаут янындагы шәһәрләр – авт.

2 Гаккә – кабилә исеме булып, шул ук исемдәге бер вилаяттә торалар иде. Гаккә Санга турысында, диңгез буена табадыр. Аңа якын вә каршы Дәһләк исемендәге бер кечкенә, эссе, пристаньлы шәһәр булып, Бәну Умәйя халифләре ышанычсыз кешеләрне шунда сөрәләр иде. Әшгарийүн – кабилә булып, Гаккә тауларында торалар иде. Мәшһүр Әбү Муса әл-Әшгари шушы кабиләдәндер. – авт.

итте. Йәмәндә Исламият тарала башлагач, рәсүлуллаһ моны бөтен Йәмән өлкәсенә вәли итеп билгеләде. Ул вафат булгач, югарыда зекер ителгән затлар билгеләнде.

16. Кайс бине Сәгъд бине Губәдә – Мәдинәдә полиция башлыгы кебек бер вазыйфада билгеләнгән иде. Ул шәриф, юмарт, баһадир, сәләтле бер кеше иде. Хәзрәти Гали тарафыннан Мисырга вәли итеп билгеләнелсә дә, аңлашылмаучанлык сәбәпле урыныннан төшерелде. Галидән соң Хәсән тарафында булды. Ул халифлектән ваз кичкәч кенә Мугавиягә бәйгать бирде. Алтмышынчы елны вафат булды.

17. Мугаз бине Җәбәл – факыйһ сәхабәләрдәндер. Рәсүлуллаһ заманында фәтва бирә торган кешеләрдән иде. Исламияткә килгәндә 18 яшендә иде. Гакабә бәйгатенә вә рәсүлуллаһның бөтен газвәләрендә катнашты. Рәсүлуллаһ аны бөтен Йәмән өлкәсенә дин вә шәригать өйрәтер, халыкны Исламияткә дәгъвәт итү, халык арасында хөкем итү өчен, икенче сүз белән әйткәндә мөфти яки шәйхүл Ислам итеп җибәрде[1]. Моннан элек Мәккәдә дә беркадәр вакытлар дин өйрәтер өчен калдырган иде. Рәсүлуллаһ Йәмәндәге бөтен вәлиләренә аңа буйсынырга, каршы килмәскә әмер биргән иде һәм бу хосуста аларга нәсыйхәтләр язган иде. Шуның өчен Мугәз бөтен Йәмән вилаятләрендә эшләрнең барышын тикшереп һәм вәгазь сөйләп йөри иде. Рәсүлуллаһ аны Йәмәнгә җибәргәндә халыкны әүвәл кәлимәи шәһадәткә дәгъвәт итәргә, әгәр кабул итсәләр, аларга Аллаһы тарафыннан биш вакыт намаз фарыз ителгәнлеген сөйләргә, моны да кабул итсәләр, байларга зәкәт түләү фарыз ителүен сөйләргә һәм Исламияткә ашыкмыйча, йомшаклык белән дәгъвәт

1 “Зәдүл-Мәгад” сахибе моның хакында: “Рәсүлуллаһ Мугәз бин Җәбәлне әл-Җәнәдкә вәли итеп билгеләде” – диядер. 1 т.,32 б. Каләм хатасы булса кирәк – авт.

итәргә кушты. Зәкәт малын алганда иң яхшы малларны сайлап алудан тыйды. Халыкка җиңеллек кылырга, өсләренә авырлыкны йөкләп өркетмәскә кушты.  Аңа имтихан өчен: «Ничек вә нәрсә белән хөкем кылырсың соң?» – дип сорады. Мугәз моңа каршы: «Аллаһының китабы – Коръән белән хөкем кылырмын», – диде. Рәсүлуллаһ: «Аллаһының китабында андый хөкем тапмасаң ни эшләрсең?» – диде. Мугәз: «Рәсүлуллаһның сөннәте белән хөкем кылырмын», –  диде. Рәсүлуллаһ: «Әгәр рәсүлуллаһның сөннәтендә дә тапмасаң ни эшләрсең?» – диде. Мугәз: «Фикеремне кулланырмын, бу турыда, аслән, кимчелек кылмам», – диде. Ошбу җавапларны ишеткәч, рәсүлуллаһ Мугәзнең күкрәгенә сугып: «Аллаһы илчесе риза булган эштә Аллаһы рәсүле илчесен муафикъ кылган Аллаһыга мактау[1]!» –  димештер.

## *Мөәзиннәре*

Рәсүлуллаһның мөәзиннәре дүртәү иде – Билал бине Рабах, Гамр бине Үмм Мәктум, Сәгъд бине Гаиз, Әбү Мәхзура Әус бине Мугыйра.

Болардан Билал Мәдинә мәчетендә мөәзин булып, иң башлап азан әйткән кешедер. Ул рәсүлуллаһ белән бөтен сәфәрләрдә булды. Рәсүлуллаһның вафатыннан соң, кайгысыннан Мәдинәне ташлап, Шам тарафына сәяхәткә китте. Хәзрәти Гомәр Шамга баргач, Билалдан азан әйтүен үтенүе, Билалның да азан әйтеп халыкны елатуы билгеледер. Егерменче елда Дәмәшкъта вафат булды. Яше алтмыштан узган иде.

Гамр анасы буенча Гамр бине Үмм Мәктум дип йөртеләдер. Атасы – Заидә бине әл-Әсам. Бәгъзеләре

1 Бу хәдис, Әбү Дәуд, әт-Тирмизи, Дәрими тарафыннан риваять ителде – авт.

моның исеме Габдулла диләр. Мәдинәдә икенче мөәзин иде. Рәсүлуллаһ бик күп сәфәрләрендә аны үзе урынына имам итеп калдыра иде. Гамр сукыр була. Тәфсир язучылар «Габәсә» сүрәсендәге «әл-Әгъмә» дигән ошбу зат диләр.

Сәгъд бине Гаиз Кубә мөәзине иде. Сәгъд әл-Караз дип билгеледер. Билал булмаган чакларда, аның урынына кала торган иде. Рәсүлуллаһның вафатыннан соң Билал Шамга киткәч, аның урынына ошбу Сәгъд мөәзин итеп билгеләнде. Габдел Малик заманында Мәдинәдә вафат булды. Үзеннән соң озак вакытлар балалары да мөәзин хезмәтендә булганнар.

Әбү Мәхзура Мәккә мөәзине иде. Мәккә фәтех ителгәч, рәсүлуллаһ аны билгеләп китте. Үзе вафат булгач, мөәзинлек вазыйфасы туганнарына күчте.

## *Кәтипләре*

Рәсүлуллаһка ошбу кешеләр язу эшен кылмышлардыр – Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Зүбәйр бине әл-Гаввәм, Гамир бине Фүһәйра, Гамр бине әл-Гас, Үбәй бине Кәгъб, Габдулла бине Әркам, Сәбит бине Кайс бине Шәммәс, Хәнзалә бине әр-Рабигъ, Мугира бине Шугъбә, Габдулла бине Равәхә, Халид бине әл-Вәлид, Халид бине Сәгыйд бине әл-Гас, Габдулла бине Сәгъд бине Әбү Сәрх, Мугавия бине Әбү Сафүән, Зәид бине Сәбит.

Мәдинәгә килгәч, иң элек рәсүлуллаһка язу эшен кылучы Үбәй бине Кәгъб булды. Зәйд бине Сәбит иң күп кәтиблек кылучы иде. Рәсүлуллаһның кушуы буенча ул яһүдичә язарга өйрәнгән иде. Габдулла бине әл-Әркам күбрәк мәктүбләр яза торган иде. Гали бине Әбү Талиб солыхнамәләр яза иде. Габдулла бине Сәгъд диннән чыгып, мөртәт булгач, Мәккәгә китеп, рәсүлуллаһ хакында күп ялалар якты.

## *Хезмәтчеләре*

Рәсүлуллаһның хезмәтчеләре ошбулардыр:

1. Габдулла бине Мәсгуд – Исламияткә иң беренче килүчеләрдән иде. Исламга килгәндә яшь кенә бер егет иде. Исламиятне кабул итү белән мүшәррәф булгач, рәсүлуллаһ аны хезмәткә алды. Рәсүлуллаһның гаилә әгъзасы кебек аның янына рөхсәтсез кереп йөри иде. Рәсүлуллаһны уята, башмакларын кидерә, мисвәкләрен саклый, аның белән бергә йөри иде. Габдулла кыска буйлы кеше иде. Гомәр бине Хаттабның аның хакында: «Тәбәнәклеккә тәбәнәк, ләкин эче гыйлем белән тулы», – диюе риваять ителәдер. Габдулла – сәхабәләрнең иң галимнәреннәндер. Хәзрәти Гомәр тарафыннан Куфага мөгаллим (мөфти вә шәйхелислам дияргә ярый) итеп җибәрелгән иде. Утыз икенче елны алтмыштан узып, Мәдинәдә вафат булды. Әбү әд-Дардага моның вафат хәбәре ирешкәч: «Аңа тиң кеше калмады инде», – диюе риваять ителәдер.

2. Әнәс бине Малик – рәсүлуллаһ Мәдинәгә килгәч тә, аның хезмәтенә керде. Бу вакытта яше унда иде. Рәсүлуллаһның вафатына кадәр аңа хезмәт итте. Әнәс иң күп хәдис риваять иткән сәхабәләрдәндер. Туксан өченче елны 103 яшендә Басрада вафат булды.

3. Гукбә бине Гамир әл-Җуһәни – бу зат күбрәк сәфәрләрдә рәсүлуллаһның качырын җитәкләп йөри иде. Мугавия тарафыннан Мисыр вәлие итеп билгеләнгән иде. Шунда 58 яшендә вафат булды.

4. Әсләгъ бине Шәрик – бу рәсүлуллаһның дөясен карый вә иярли торган иде.

5. Билал бине Рабах – хәзинәдар булып торган.



www.darul-kutub.com

6. Әймән бине Губәйд – мәшһүр Умму Әймәннең улыдыр. Бу да рәсүлуллаһның хезмәтенә тора иде.

7. Сәгъд – Әбү Бәкер азат иткән кеше. Рәсүлуллаһ аның хезмәтен бик ярата иде. Әбү Бәкердән аны азат итүен үтенгәч, ул аны азат итте.

8. Әбү Зәр (Җүндәб бине Җүнәдә) әл-Гыйфари – атаклы сәхабәләрдәндер.

9. Мугайкыйб бине Әбү Фатыйма әд-Дүси – рәсүлуллаһның йөзеге (яки мөһере) моның кулында тора иде.

10. Рабах әл-Әсвәд, **Идә Әнәсә** – рәсүлуллаһ тарафыннан азат ителгән булып, бәвваб (швейцарлык) хезмәтен үтиләр иде.

## *Шагыйрь вә хатиплары*

Исламиятне вә рәсүлуллаһны мыскыл итә торган мөшрикләргә каршы торган шагыйрь вә хатиплары ошбудыр – Хәсән бине Сәбит, Габдулла бине Равәхә, Кәгъб бине Малик, Сәбит бине Кайс бине Шәммәс. Болардан соңгысы хатип, әүвәлгеләре – шагыйрьләрдер. Хәсән – мәзкүр шагыйрьләр эчендә иң алдынгысы, иң әче теллесе вә мөшрикләргә иң каты тәэсир калдыручысы.

www.darul-kutub.com

# ЭЧТӘЛЕК

Мөәллифтән ........................................................................ 3
Гарәбстанның географик урнашуы ................................ 8
Гарәпләр һәм аларны
хасил иткән кабиләләр ................................................ 9
Җаһилият вакытында гарәпләрдә дин ........................ 13

ГАРӘПЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ ХӘЛЕ ........................ 21
Никах .......................................................................... 21
Талак .......................................................................... 22
Күпхатынлылык ........................................................ 24
Хатын-кызның дәрәҗәсе .......................................... 25
Хиҗап .......................................................................... 26
Вәэд ............................................................................ 27
Хәмер хакында .......................................................... 29
Истикъсәм би-л-Әзләм [Уклар белән хөкем итү,
ачыклау] .................................................................... 32
Мәйсир ........................................................................ 33
Ракыйт – коллык мәсьәләсе ...................................... 33
Бәхира, Сәибә һәм башкалар .................................... 35
Гадәт, әхлак, хорафат .............................................. 36
Хөкүмәт һәм мәдәният .............................................. 42
Әдәбият ...................................................................... 53
Гарәпләрдә гыйлем һәм мәгърифәт ........................ 62
Гарәпләрдә сәүдә эше, һөнәрчелек һәм игенчелек ......... 65

МӨХӘММӘД (Аллаһның салаваты һәм сәламе булсын)
ПӘЙГАМБӘРЛЕККӘ КАДӘР .................................... 67
Рәсүлуллаһның Шамга беренче сәфәре .................... 71
Шамга икенче сәфәр һәм Хәдичәгә никахлану ............ 75

www.darul-kutub.com

Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлек килгәнчегә кадәрле тормышы ........ 77
Пәйгамбәрлек........ 80
Мөхәммәд галәйһиссәламгә вәхи килүе ........ 81
Вәрака янына бару........ 82
Вәхинең киселеп торуы ........ 83
Вәхинең яңадан башлануы ........ 83
Яшерен дәгъват........ 84
Әбү Бәкер тырышлыгы аркасында Ислам динен кабул итүчеләр ........ 86
Ачык дәгъват........ 89
Сафа тавында Корәешләрне дәгъват кылу........ 91
Мөшрикләрнең Әбү Талиб янына барулары ........ 92
Мүстәһзиүн ........ 95
Газапка дучар булган сәхабәләр........ 100
Хәмзәнең Исламиятне кабул итүе........ 104
Могҗиза китерүне сорау........ 105
Корьәннән үзләренә ошамаган сүзләрне ........ 109
алып ташлауны үтенүләре........ 109
Ай ярылу мәсьәләсе ........ 112
Сәхабәләрнең Хәбәшәгә һиҗрәте [күчүләре]........ 121
Хәбәшәгә беренче һиҗрәт ........ 121
Гомәр бине әл-Хаттабның Исламга килүе ........ 123
Мөһаҗирләрнең кайтуы........ 124
Мөһаҗирләрнең кайтуы........ 124
Бойкот........ 125
Хәбәшәгә икенче һиҗрәт ........ 125
Бойкотның бетерелүе ........ 127
Кайгы елы ........ 128
Сәүдәткә өйләнү ........ 130
Гайшәгә өйләнү ........ 130
Таифкә дәгъват белән бару ........ 132
Мутгыйм бине Гади химаясында Мәккәгә керү........ 134

www.darul-kutub.com

Исра һәм мигъраж ........................................................ 135
Мәдинәгә һижрәт........................................................ 137
Ясрибкә һижрәт ........................................................ 141
Әнсариларның рәсүлуллаһны каршы
алырга чыгулары ........................................................ 145
Ясрибкә керү ........................................................ 149

ҺИЖРӘТТӘН БЕРЕНЧЕ ЕЛ ........................................................ 150
Рәсүлуллаһның гаиләсе килү ........................................................ 150
Мәчет төзү........................................................ 150
Ахирәт дуслыгы ........................................................ 151
Азан әйтелә башлау........................................................ 152
Яһүдләр белән килешү төзү ........................................................ 154
Мәккәлеләр белән сугышырга рөхсәт килү ........................................................ 155
Хәмзә бине Габделмоталлибның сәриясе ........................................................ 156
Губәйдә бине әл-Хәрис сәриясе ........................................................ 157

ҺИЖРӘТТӘН ИКЕНЧЕ ЕЛ........................................................ 157
Вәддән газвәсе ........................................................ 157
Бувәт газвәсе ........................................................ 158
Гаширә газвәсе........................................................ 158
Беренче Бәдер газвәсе ........................................................ 159
Габдулла бине Җәһеш сәриясе ........................................................ 159
Бәдер сугышы ........................................................ 161
Мәккәлеләрнең сугышка әзерләнүләре ........................................................ 162
Киңәш ........................................................ 164
Хубәб бине Мунзирнең фикере ........................................................ 166
Мөшрикләр гаскәре арасында ихтилаф ........................................................ 167
Мүбәразә ........................................................ 168
Җиңү ........................................................ 170
Ганимәт малын бүлү ........................................................ 173
Әсирләр турында сәхабәләр белән киңәшмә ........................................................ 174
Мөшрикләрнең тәэсире ........................................................ 175

www.darul-kutub.com

Бәдер сугышы хакында аятьләр иңү.............................. 175
Күдр газвәсе.......................................................... 176
Сәвикъ газвәсе....................................................... 176
Ибне Кайнукагъ газвәсе.......................................... 177
Кыйбланың үзгәрүе................................................ 179
Рамазан рузасы...................................................... 180
Зәкәт фарыз булу................................................... 180
Гает намазын канунлаштыру.................................... 181

ӨЧЕНЧЕ ЕЛ............................................................. 182
Зи Әмр газвәсе....................................................... 182
Кәгъб бине әл-Әшрафнең үтерелүе............................ 183
Бәхран газвәсе....................................................... 184
Зәйд бине Хәрисә сәриясе....................................... 184
Ухуд сугышы.......................................................... 185
Сугышка әзерләнү................................................. 186
Гаскәрнең Мәдинәгә төшүе...................................... 188
Рәсүлуллаһка хат килү........................................... 188
Габдулла бине Үбәйнең аерылып китүе...................... 191
Гаскәрнең хәрәкәте................................................ 191
Укчы фиркасының урынын ташлавы........................... 193
Мөшрик гаскәренең рухы күтәрелүе........................... 194
Рәсүлуллаһ янында сәбит калучылар........................ 195
Рәсүлуллаһ сәламәт............................................... 195
Өхедтә шәһид булган затлар.................................... 198
Рәсүлуллаһның җәрәхәтләнүе.................................. 199
Гаскәрнең Мәдинәгә кайтуы..................................... 201
Җиңелүнең сәбәбе.................................................. 201
Хәмрау әл-Әсәд газвәсе.......................................... 202

ДҮРТЕНЧЕ ЕЛ......................................................... 204
Катан сәриясе........................................................ 204
Сафүән бине Халиднең үтерелүе............................... 205

Ражигъ вакыйгасы ........................................................ 205
Биэрү Мәгунә вакыйгасы.............................................. 206
Бәни Нәзыйр газвәсе ................................................... 208
Соңгы Бәдер газвәсе..................................................... 210
Рәсүлуллаһның Үмм Сәламәгә өйләнүе...................... 211

БИШЕНЧЕ ЕЛ ................................................................ 212
Дүмәтү әл-Җәндәл газвәсе ......................................... 212
Бәни Мөстәгликъ газвәсе............................................. 212
Хандак яки Әхзәб сугышы .......................................... 221
Мөшрикләрнең сугышка чыгулары.............................. 221
Хандак казу ................................................................ 222
Хандак Мәдинәне һөҗүмнән саклый ........................... 224
Мөшрикләр ат сикертеп хандактан үтәләр ................ 225
Курайза яһүдләренең хыянәте..................................... 225
Мәдинәне саклау өчен гаскәр җибәрү.......................... 226
Рәсүлуллаһ Гатафан белән килешмәкче була.............. 226
Мөшрик гаскәрендә курку............................................ 228
Мөшрикләрнең җиңелүләре.......................................... 228
Бәни Курайза сугышы .................................................. 229
Зәйд вә Зәйнәб вакыйгасы ........................................... 232
Хиҗаб ........................................................................... 238

АЛТЫНЧЫ ЕЛ................................................................ 249
Мөхәммәд бине Мәсләмә сәриясе ................................ 249
Бәни Лихъян газвәсе .................................................... 250
Габә газвәсе................................................................. 251
Гукәшә сәриясе............................................................ 252
Мөхәммәд бине Мәсләмә сәриясе ................................ 252
Әбү Губәйдә сәриясе..................................................... 252
Зәйд сәриясе................................................................. 253
Зәйд сәриясе................................................................. 253
Зәйд сәриясе................................................................. 254



www.darul-kutub.com

Зәйд сәриясе .................................................... 254
Габдрахман бине Гауф сәриясе .................................. 254
Гали сәриясе .................................................... 255
Әбү Рафигъның үтерелүе ........................................ 255
Габдулла бине Равәхә сәриясе .................................. 256
Гамр бине Үмәйяне Әбү Суфьянны үтерергә җибәрү ..... 257
Гукәл вә Гурайнә вакыйгасы ................................... 258
Хүдәйбия вакыйгасы ............................................ 258
Юлга чыгу ........................................................ 259
Мөшрикләр турында мәгълүмат алу ............................ 259
Худәйбиягә бару ................................................ 260
Мәккәлеләр Рәсүлуллаһка кеше җибәрәләр .................. 261
Госманны Мәккәгә җибәрү ....................................... 262
Ризван бәйгате .................................................. 263
Мәккәлеләр Рәсүлуллаһка хаж кылырга
рөхсәт бирәләр ................................................. 264
Әбү Җәндәл ...................................................... 267
Ихрамнан чыгу .................................................. 267
Худәйбия мөнәсәбәте белән сүрә иңү ......................... 268
Үмм Күлсүм бинте Гукбә ........................................ 268
Әбү Бәсыйр ...................................................... 269
Патшаларга илчеләр җибәрү ..................................... 270
Мөһер ясату ..................................................... 271
Кайсарга мәктүб ................................................ 272
Кисрага мәктүб ................................................. 274
Нәҗәшигә мәктүб ................................................ 275
Үмм Хәбибәне хатынлыкка алу ................................. 276
Мукаукиска мәктүб .............................................. 278
Гассан әмиренә мәктүб ......................................... 279
Бәхрайн вәлисенә мәктүб ...................................... 282
Оман әмирләренә мәктүб ........................................ 283
Йәмәмә әмиренә мәктүб ......................................... 284

www.darul-kutub.com

ЖИДЕНЧЕ ЕЛ ........ 285
Хайбәр газвәсе ........ 285
Мубәразә ........ 287
Солых ........ 289
Сафиягә өйләнү ........ 289
Рәсүлуллаһка агулы ит тәкъдим итү ........ 290
Хәбәшәдән мөһаҗирләрнең кайтуы ........ 290
Фәдәкнең алынуы ........ 291
Вәди әл-Кураның алынуы ........ 291
Тәймә солыхы ........ 292
Халид бине әл-Вәлиднең вә аның иптәшләренең Исламга килүләре ........ 292
Әбү Бәкер сәриясе ........ 293
Гомәр сәриясе ........ 294
Бәшир бине Сәгъд сәриясе ........ 294
Галиб бине Габдулла сәриясе ........ 294
Бәшир бине Сәгъд сәриясе ........ 295
Зәтү әр-Рикәгъ газвәсе ........ 295
Гомрә казасы ........ 296
Мәймүнәгә өйләнү ........ 298

СИГЕЗЕНЧЕ ЕЛ ........ 299
Галиб бине Габдулла сәриясе ........ 299
Галиб бине Габдулла сәриясе ........ 299
Кәгъб бине Гамир сәриясе ........ 300
Муэтә сәриясе ........ 300
Сугыштан файда ........ 302
Зәтү Сәләсил сәриясе ........ 303
Хабат сәриясе ........ 304
Мәккәне фәтех кылу ........ 304
Әбү Суфьянның Мәдинәгә баруы ........ 305
Мәккәне алу өчен әзерләнү ........ 306
Хатыйбның хаты ........ 306

Мәккәлеләрнең куркуы ........ 308
Гаскәрнең Мәккәгә керүе ........ 311
Кәгъбә ачкычы ........ 314
Мәккәлеләр бәйгате ........ 314
Нотык ........ 315
Гафу ителгән һәм гафу ителмәгән кешеләр ........ 316
Лат, Гоззә, Мәнәтләрне җимертү ........ 318
Мәккәгә вәли билгеләү ........ 319
Халид сәриясе ........ 320
Хүнәйн газвәсе ........ 321
Ислам гаскәренең чыгуы ........ 322
Ислам гаскәренең бозылуы ........ 323
Әбү Гамир сәриясе ........ 325
Таиф газвәсе ........ 325
Һәвәзин вәкилләре ........ 327
Хунәйн ганимәтләрен бүлү ........ 328
Өлешсез калганга әнсариларнын кәефләре кырыла ........ 330
Рәсүлуллаһның әнсариларга нотыгы ........ 331
Җигъранә гомрәсе ........ 332
Әш-Шәймә ........ 332
Кәгъб бине Зүһәйр ........ 333
Галкамә сәриясе ........ 335

ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ........ 335
Гуяйнә сәриясе ........ 335
Халид сәриясе ........ 337
Гали сәриясе ........ 337
Гадинең килүе ........ 338
Тәбүк газвәсе ........ 339
Иганә итү ........ 340
Монафикълар ........ 340
Гозер күрсәтеп сәфәрдән калучылар ........ 341
Мәдинәдән хәрәкәт ........ 342

Әбү Хайсәмә ........................................................ 343
Әйлә халкы вә башкалар белән солыхнамә ясау .......... 343
Үкәйдиргә сәрия җибәрү ........................................ 344
Мәдинәгә кайту хакында киңәшләшү ......................... 344
Әбү Зәр ................................................................. 345
Монафикъларның явыз нияте ................................ 346
Зыйрар мәчетен җимертү......................................... 347
Аклану ................................................................. 348
«Тәүбә» («Бәраә») сүрәсе ..................................... 349
Ислам дине көч белән таралдымы? ......................... 350
Зәкәт җыю ........................................................... 355

УНЫНЧЫ ЕЛ ............................................................ 356
Халид сәриясе....................................................... 356
Гали сәриясе......................................................... 357
Әл-Вәдәгъ хаҗы ..................................................... 357
Сәфәр ................................................................... 360
Тәваф ................................................................... 361
Хаҗны гомрәгә әйләндерү...................................... 361
Минада куну ......................................................... 362
Минадагы хотбә.................................................... 364
Вәкилләр килү ...................................................... 366
Габдүл Кайс илчеләре ........................................... 368
Бәни Хәнифә делегациясе ..................................... 369
Мүсәйләмә әл-Кәззәб............................................. 370
Нәҗран илчеләре.................................................. 371
Түҗиб вәкиллеге.................................................... 372
Ибне Сәгъд вәкилләре ........................................... 372
Тай илчеләре........................................................ 373
Фәзәра илчеләре .................................................. 373
Ибне Әсәд илчеләре.............................................. 374
Ибне Мүхәриб илчеләре......................................... 374
Киндә илчеләре..................................................... 375

www.darul-kutub.com

Зыймәм бине Сәгъләбә ............ 375
Садә илчеләре ............ 376
Габәс илчеләре ............ 377
Әздү илчеләре ............ 377
Ганәс илчеләре ............ 377
Бүҗәйлә илчеләре ............ 378

УНБЕРЕНЧЕ ЕЛ ............ 379
Үсәмә бине Зәйд сәриясе ............ 379
Рәсүлуллаһның вафаты ............ 380
Әбү Бәкергә имтияз ............ 381
Әбү Бәкернең имам торуы ............ 381
Сәхабәләрдә борчылу ............ 382
Намазга чыгу ............ 382
Хотбә сөйләве ............ 382
Васыятьнамә ............ 383
Гали вә Габбас ............ 384
Вафат ............ 384
Әбү Бәкернең хотбәсе ............ 385

ЭПИЛОГ ............ 388
Рәсүлуллаһның сыйфаты ............ 388
Кием-салымы ............ 389
Ашау-эчүе ............ 390
Йокысы ............ 390
Мәҗлес, кешеләр белән аралашу ............ 390
Шәфкать вә мәрхәмәте ............ 392
Заһидлыгы ............ 393
Сабырлыгы, йомшаклыгы, гафу итүе ............ 396
Кече күңеллелеге ............ 398
Юмартлыгы ............ 400
Батырлыгы ............ 401
Тәвәккәллеге ............ 401

www.darul-kutub.com

Балалары ........................................................................ 403
Оныклары........................................................................ 404
Атасы белән бертуган абыйлары ................................. 405
Әбү Талиб........................................................................ 406
Атасы белән бертуган апалары ................................... 408
Уммәһәтү әл-муэминин
[рәсүлуллаһның хатыннары] ........................................ 410
Кәнизәкләре .................................................................... 416
Вәлиләр .......................................................................... 416
Мөәзиннәре..................................................................... 421
Кәтипләре........................................................................ 422
Хезмәтчеләре .................................................................. 423
Шагыйрь вә хатиплары ................................................. 424

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

www.darul-kutub.com

Научно-популярное издание
**Бикбулатов** Сунгатулла Нигматуллович

ХАЗРАТИ МУХАММАД (صلى الله عليه وسلم)

Фәнни-популяр хезмәт
**Бикбулат** Сөнгатулла Нигъмәтулла улы

ХӘЗРӘТИ МӨХӘММӘД
(аңа Аллаһының салаваты һәм сәламе булсын)

Оригинал-макеттан басарга кул куелды: 18.12.2014.
Форматы 84×108 1/32.
Шартлы басма табагы 18. Тиражы 1000 д.

«Хузур» нәшрият йорты. 420111 Казан, Лобачевский урамы, 6.
Тел./факс: +7 (843) 202-07-74.
**http://huzur.ru; электрон почта: huzur.inform@mail.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**
Казан, Лобачевский урамы, 6.
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте;
Казан, Газовая урамы, 19.
Россия ислам институты.

«Зур Казан» типографиясе.
420095 Казан, Серов урамы, 4а. Тел.: 8 (843) 253-66-04 Бирелгән электрон
әйләнешкә туры китерелеп бастырылды.

www.darul-kutub.com